
# КАЗАН УТЛАРЫ

11. 1992



**КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!**

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Башка күп кенә газета-журналлар кебек, матди ярдәм алу өчен, без дә **Редакция фонды** оештырдык. Татарстанда, Россиядә, БДБ дәүләтләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итәбез. Безгә ярдәм итәргә теләүчеләр булса, хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005. Для Фонда Редакции.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**(841)**

**1992**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ф. САДРИЕВ. Таң җиле. *Роман* . . . . . . . . 3
К. МОСТАФИН. Яңа шигырьләр. . . . . . . . 74
Т. ӘЙДИ. Йөртә безне язмышлар. *Сәяхәтнамә*. 78
Ә. ГАДЕЛ. Татар зираты... *Шигырьләр*. . . . . 119
Ф. ЯХИН. Корьәнгә таяну. *Шигырьләр* . . . . . 122
Г. МӨХӘММӘТШИН. Таңнар, каеннар. *Шигырьләр*. . . . . . . . . . . . . . . 124
М. ЕВГЕНЬЕВА. Әби патшаның сөяркәләре. . 128

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. ВАФИН. Табигать мине кабатлый. *Шигырьләр*. . . . . . . . . . . . . . 153
М. НӘЗИРОВ. Чакматаш. *Шигырьләр*. . . 155

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ХАТИПОВ. Язмышыбыз. . . . . . . . . 158

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Тарихыңны онытсаң — юк киләчәгең... . . . . . . . . . . . . . 166
Ф. ГАЛИМУЛЛИН. «Ни өчен?»нәр турында. . 178

СӘНГАТЬ

А. МАКЛЫГИН. Халык яше тамган моңнар бу. 184

Котлыйбыз. . . . . . . . . . . . . 188, 189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. . . . . . 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Ф. САДРИЕВА «Утренний ветерок», повествование о путешествии в Германию Т. АЙДИ, «Любовники Екатерины» М. ЕВГЕНЬЕВОЙ, стихи К. МУСТАФИНА, А. ГАДЕЛ, Ф. ЯХИНА, Г. МУХАМЕТШИНА.
«Творчество молодых»: стихи М. ВАФИНА, М. НАЗИРОВА.
«Публицистика»: статья Ф. ХАТИПОВА «Наша судьба».
«Литературная критика»: статьи Т. ГАЛИУЛЛИНА «Без прошлого нет будущего», Ф. ГАЛИМУЛЛИНА «Новый взгляд на литературу прошлых лет».
«Искусство»: статья А. МАКЛЫГИНА о творчестве композитора Ш. Шарифуллина.
Поздравления.
Дневник общественно-политической жизни.
На наших обложках: картина уфимского художника Р. Харисова «У колодца»; известная писательница К. Тимбикова.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 5.10.92 ел. Басарга кул куелды 6.11.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 23961. Заказ В-447. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

**Фоат Садриев**

# ТАҢ ҖИЛЕ

РОМАН

## 9

Кая барып бәрелергә белмәгән Нуриасма төштән соң идарәгә юл тотты. Анда автомеханик очрады. Мизхәтнең машинасын гараж янында күргән идем, белмим, басудан ашлык ташыйдыр, диде. Нуриасманың күнеле бераз тынычлангандай булды, ләкин бу бит әле малае өйгә кайтачак, алар уртак тел табачак дигән сүз түгел иде. Әгәр теге чактагы авылдан китү турындагы уйлары кабат кузгалса? Нуриасма нишләргә тиеш? Нишли ала соң? Ул борчулы уйларына батып кайтканда, кибеттән бер букча алма күтәреп Бәрия килеп чыкты.

— Исәнме, җиңгәчәй,— ул елмаеп-көлеп аның каршына килде дә кып-кызыл өч зур алма сузды.— Мә әле, чәй эчәрсең.

Нуриасма алмаларга үрелмәде. Аның карашы ачулы иде.

— Мине — алма, Мизхәтне аракы белән алдыйм дисеңме?

— Кит инде, җиңгәчәй! Әллә без туган түгелме? Эштән соң чәй эчеп чыккан икән, шуннан дөнья җимерелмәгәндер! Болай да монахка әйләндереп бетердең, дуадак каз сыман ялгыз йөри, мескен.

— Аның өчен син кайгырма, мин кайгырган да бик җиткән,— диде дә Нуриасма үтеп китмәкче булды, әмма Бәрия аның беләгеннән тотты.

— Кит әле юлымнан! — диде Нуриасма беләген тартып алып.— Үзеңнән кәҗә тәкәсе исләре килә. Тфү!

— Син ашыкма әле, җиңгәчәй, өр-яңа хәбәр алып чыктым кибеттән. Әнә теге матайны күрәсеңме?

— Күрәм, сукыр түгел лә,— диде Нуриасма юл читендәге бишекле зәңгәр мотоциклга карап куеп.

— Кемнеке икәнен беләсеңме?

— Миңа нәрсәгә ул? — Нуриасма китмәкче булды, Бәрия тагын аркылы төште.

— Бу матай сыер фермасы мөдиренеке,— диде Бәрия.

— Булса соң! Каршымда сатанып торма әле, өйдә эшем муеннан.

— Ферма мөдиренең кем икәнен әйтимме соң? — Бәрия аңа башын кыегайтып карады.— Мәдинә ул.

— Мәдинә?!

---

Ахыры. Башы 10 нчы санда.

**Хөрмәтле укучылар!** Сезне «Безнең тормыш. Безнең әдәбият» дигән сөйләшүгә чакырабыз.

— Әйе, өч көн инде. Гаделлек бар ул, җиңгәчәй. Син берүзең калдың. Мәдинә гариза биргән, Гарифҗан айнык иде, җинаять эше кузгатмавыгызны сорыйбыз, дип. Урманга барган теге ике кеше дә кирегә уйлаган.

— Гомергә чама белмичә алдаштың, Бәрия! — диде Нуриасма, аңа усал текәлеп.

— Ышанмасаң, Мәдинәнең үзеннән сора. Әнә кибеттән чыга...

Бәрия керт-керт басып китеп тә барды. Нуриасма Бәрия әйткәннәргә ни ышанырга, ни ышанмаска белмичә мотоциклга таба атлады. Мәдинә бер төргәк резина көпшә күтәреп чыгып килә иде. Аны мотоцикл бишегенә салып, хәл-әхвәл сорашкач, Нуриасма аны чәйгә чакырды.

— И Нуриасма апа, җәйләүдә көтеп калдылар, менә шушыңа гына кайткан идем, — диде ул кабаланып.

— Әкрәм рәтләнәме соң, беркөнге кебекме хәле?

— Әлегә бер килеш шул, һаман урында.

— Алай икән, — дип сузып куйды Нуриасма. — Кызым, сине гариза язгансың дип ишеттем. Хакмы?

Шуның ниндидер билгеләрен эзләгәндәй, Нуриасма аны баштанаяк күздән үткәрде. Аягында резина итек, өстендә төсе шактый уңган кара халат, башында кечкенә өчпочмаклы яулык.

— И Нуриасма апа! — диде Мәдинә әрнүле тавыш белән. — Язмый нишлим?! Башым тәмам катты. Аларны бәхетсез итеп, без бәхетле булырбызмы!

Мәдинә дымланган күзләрен күрсәтмәс өчен башын читкә борды.

— Син бит, кызым, Рәмзинең җеназасы өстендә бөтен халык алдында вәгъдә бирдең. Әле ун көн дә үтмәде аңа. Оныткан булсаң, хәзер кабатлап күрсәтәм.

— Ничек онытыйм, ничек онытыйм?! Гел минем янда бит ул...

— Соң шулай булгач? Бу бит хыянәт!

Мәдинә яшь белән мөлдерәп тулган күзләрен кинәт Нуриасмага борды, борын яфраклары, иреннәре калтырады.

— Ничек син миңа шундый сүз әйтә аласың, Нуриасма апа?! Хыянәт бит шундый әшәке нәрсә... Мин ул хакта уйлый да алмыйм! Ә син... минем болай да телгәләнгән йөрәгемне телгәләп.

Нуриасма инде бу сүзне башлаганына үкенде дә, тик рәнҗеше үкенүне җиңде.

— Ярый, ярый, анысы калсын. Ә мин? — диде ул тавышын күтәреп. — Мине уйладыңмы син?!

— Сине? — Мәдинә берни аңламаган битараф карашын аңа төбәде.

— Мине. Үземне генә калдырганыңны уйладыңмы? Башта минемчә сөйләп, хәзер миңа каршы... ялганга күчкәнсең...

— Соң Гарифҗаннар кызганыч бит. Аннары... — Мәдинә әз генә уйланып алды. — Барыбер бит инде...

— Нәрсә барыбер?

— Барыбер айнык дип справка бирелгән... Синең белән без икәү күпме тырышсак та... — Мәдинә кинәт кулларын Нуриасманың иңбашына салды, аңа ялварулы төбәлде: — Нуриасма апа, әйдә син дә күрсәтмәңне үзгәрт...

Нуриасма аның кулларын кискен генә иңбашларыннан алып куйды.

— Әллә Рәмзи каршында да, халык төртеп күрсәткәндә дә үзең генә булудан куркасың? Янында үзең кебекләр күбрәк кирәкмени?

— Миңа беркем дә кирәкми хәзер. Кешелеклелек дигән нәрсә бар бит әле.

— Кешелеклелек битлеге астында эш итүчеләр күп ул, кызым! Кемнәр белән икәнеңне уйла. Без төзегәнне сез җимерәсез дигән сүз бу!

Мәдинә ярсып китте.

— Әйтмә миңа андый сүзләр, Нуриасма апа! — диде ул әрнүле тавыш белән. — Кышын-җәен өстән каткан халат, аяктан резина итек

төшми. Сигезенче классны бетергәннән бирле тизәк ерып, шуның әче парын иснәп өч йөз алтмыш биш көн фермада мин. Шушы куллар ни җимерсен?!

Ул яргаланган, тырнаклары купшаклап, кителгәләп беткән кулларын аңа таба сузды. Нуриасма әллә нишләп китте. Бу куллар — нәкъ Нуриасмалар, Маһинурлар, Мосаллиялар куллары төсле, алар язмышы да аның язмышы иде. Бу кулларга карарга кызганыч иде...

— Их, кызым, кызым, — диде ул аның бирчәеп беткән кулларын сыпырып. — Күзгә күренмәс әйберләр җимерелә шул... Син бүген бернинди начарлык эшләмәдем, дип уйлыйсың. Булса да әз генә, энә очы кадәр генә гаебем бардыр, дип уйлыйсың. Ялгышасың, кызым. Өрфия калынлыгы гына түбән төштенме, беттем, дип уйла. Ә өрфия калынлыгы күтәрелү өчен кайчакта бер кеше гомере дә җитми. Кем белә, моның өчен берничә буын тормышы кирәктер. Ямьнлык җиңеп килә... Кем сине бәхетсез итте? Үзең ныклабрак уйлап кара тагын...

Нуриасма аның аркасыннан кагып сөйде дә китеп барды. Артына борылып карамады, әмма мотоцикл тавышы ишетелмәде. Бәлки Нуриасма игътибарга алмагандыр, чөнки ул Мәдинәнең Рәмзи җеназасы өстендә өзгәләнеп әйткән сүзләрен, аның шул чактагы һәр хәрәкәтен хәтереннән уздыра-уздыра, уйга батып кайтты. Ничә генә көн үтте, Рәмзи рухы өстендә ялган белән хыянәт калыкты. Моңа сәбәпче — газиз хатыны белән якын туганы иде... Житәкче халыкка каршы, хатын иргә каршы, бала ата-анага каршы, туган туганга каршы... Хөснуллин... Бәрия... Хәдичә... Мәдинә... Мизхәт... Тикшерүче... Врачлар... Урман кисүчеләр... Бөтенесе ялган эчендә быкырдый...

Нуриасма капканы авырлык белән генә ачып керде дә болдыр баскычына утырды. Күзе белән Маратны эзләде, әгәр ул ишек алдында булса, су алып чыктырыр идем, дип уйлады, тик онысы күренмәде... Аның күкрәге түзә алмаслык булып яна иде, күз алды томаланып-томаланып китте, колагы шаулады, ике чигәсенә ниде бәрде. Ләкин болар бар да әһәмиятсез иде. «Ә кем алдашмый соң?» — дип уйлады ул алъяпкыч итәге белән маңгай тирен сөртеп. Бу сорауга җавап эзләп утыра торгач, шундый уйга килде: ул санаганнар ялганның бәләкәе генә бит! Әле югарыдан ук килгән олы ялган — бөтен халыкны һәр минут, дистә еллар буе агулап килгән олы ялган бар бит! Авылны күтәрәбез, чәчәк аттырабыз, диделәр. Күтәрелмәде дә, чәчәк тә атмады авыл. Инде килеп хәзер әйттеләр: житмеш елдан артык авылны талаганбыз, җитте, аякка бастырабыз, диделәр. Шулай диделәр дә тагын тишек кәлүшкә утырттылар. Бастырулары шул булды. Бервакыт егерме елдан коммунизм була дигәч, и куанган иде Нуриасма! Фермага килеп бер инструктор шул турыда сөйләгәндә, Хәдичә: «Вакыт үткәреп, әкият сөйләмәгез әле», — дип чыкты да китте. Ә Нуриасма чын-чынлап ышанып, хуплап шунда чыгыш ясаган иде. Соңыннан идарәгә чакырып: «Син партия һәм совет хөкүмәте политикасына каршымыни?» — дип кыса башлагач, Хәдичә елый-елый ялварып кына котылган, диделәр. Ә хәзер ни үзгәрде? Әйберләрнең хакын күтәрмибез, дип сөйләделәр, сөйләделәр дә күз күрмәгән, колак ишетмәгән бәяләр ясадылар да куйдылар. Иң югары мөнбәрләрдән торып: «Азатлык алыгыз, һәр милләтне чәчәк аттырыйк», — дип, һәр тумыш көн авызларыннан төкерек чәчәләр, ә үзләре кораллы гаскәр, танклар белән шул сөйләгәннәренә каршы торалар. Ялганлаган саен кызарып та карамыйча тагын ни йөзең белән халык, ил каршына чыгарга мөмкин?! Моның өчен нинди вөҗдан, нинди намус кирәк? Ник болай? Кайчанга кадәр? Халык ничек түзә? Нуриасмалар моны күпмедер аңлап та яшәделәр ләбаса! Әмма элекке ялганнарны аклап, ялганнар уйлап чыгарыла торды. Ә югарыдан төшкән һәр сүз изге дип каралды, аңа ышанмыйча ярамый иде. Әз генә түзик, тиздән барысы да үзгәрәчәк, әйбәтләнәчәк дигәнгә кемнең җаны эремәсен соң?! Менә хәзер катлы-катлы ялган пәрдәләрен астан да, өстән дә умыра башлагач, бу коточкыч

хәлгә гаҗәпләнергә генә калды. Ә ялган үзе, аңа төртеп күрсәтеп торуга карамастан, кимемәде, көчәйде генә. Ялганлаучылар тагын да хәйләкәррәк була бара. Мизхәте дә шундый булыр микәнни? Аңа бит үзенә ышангандай ышанган иде Нуриасма. Мәдинәгә дә шулай ук. Бәлкем, бу дөньяда ялганламыйча яшәп булмыйдыр? Бәлкем, моңа тормышның бик мөһим, бер төп нәрсәсе сәбәпчедер? Әгәр ялган ата-ана белән баланы, ир белән хатынны кара-каршы куеп, гаиләне җимерә икән, дусны дус, туганны туган белән чәкәләштереп, нәсел-кавем җепләрен өзә икән, ник әле ул милләтләрне суештырмасын да, ил-тикле илне таркатмасын?

Ул исе-акылы китеп, хәвефле уйларына батып утырган саен, үзен бер куркыныч, сәер тойгы били баруына игътибар итте. Әйтерсең лә аның өстенә коточкыч дивар акрын гына ава иде. Аны аудармый калу мөмкин түгел, ул берүзе, янында ярдәмгә беркем дә юк иде. Дөрес, бу күренмәс диварның теге ягына чыгып, үзеңне сытылудан коткарып була. Бәлкем, шулай итәргәдер? Юк, диде ул үз-үзенә. Диварны аудармыйча тотып торучылар кирәк. Нуриасма ак нур булып аларны чакырачак. Ул үзе хәзер кирәкми, бөтен өмет аларда, аны күрүчеләрдә, аңа иярүчеләрдә. Диварның тыныч, имин ягына чыгу бөтен яшәгән тормышыңны, аның төп мәгънәсен юкка чыгару, шуны үзең аяк астына салып таптау булыр иде. Шуңа күрә ул андый котылу мөмкинлегеннән баш тартты. Бу карар катгый иде...

## 10

Автобус нәкъ кибет каршында туктады. Алар, чемодан-сумкаларын тоткан килеш кырын-кырын атлап үтеп, Күкеле туфрагына төштеләр. Автобус кузгалуга, Фәрит чемодан белән зур сумканы алды, Нәсимә ридикюле белән чүпрәк букчаны күтәрде.

Үзләренең өенә якынлашканда урамның каршы ягыннан күршеләре Хәдичә түтинең килүе күренде. Ләкин ул юл уртасыннан кайтучы Фәрит белән Нәсимәгә игътибар да итмәде.

— Хәдичәтти! — дип кычкырды Фәрит елмаеп.

Хәдичә туктап артына борылды, Фәрит белән Нәсимә кирегә — аңа таба киттеләр.

— Танымыйсыңмыни, без бит бу,— диде Фәрит, күрешергә кулын сузып.

Хәдичә ничектер каушаган кебек булды, бер урында таптанды.

— Ашыга идем... абайламаганмын. Исән генә кайтып җиттегезме?

Ул ашык-пошык кына күрешге дә борылып юлын дәвам итте. Нәсимә сумкасына иелде:

— Хәдичәтти, мә әле, күчтәнәчләр белән чәй эчәрсез.

— Юк, юк, бирниегез дә кирәкми, алганнан да болайрак, рәхмәт,— диде Хәдичә, йөгерә-атлый китеп тә барды.

Фәрит белән Нәсимә аптырашып басып калдылар.

— Йә, ярый, өйләренә кертеп чыгарсың,— диде Фәрит кул селтәп.— Хәдичәттинең кәефсез чагынарак туры килсәң, орышып ташларга да күп сорамый ул. Киттек.

Алар, кутәренеп, юлларын дәвам иттеләр.

Әнә ул газиз нигез. Күңел мөлдерәмә тулган. Менә уртасына зур чәчәк төшерелгән таныш зәңгәр капка, менә өй түрендәге юкә агачы, әнә карт тупыл, аннан да ерак түгел шомырт агачы. Фәрит кечкенә капканы ачты, алар канат белән себергәндәй чиста ишек алдына керделәр. Ят кешеләрне күрүгә, юлбарыс төсле сырлы-сырлы соры песи баласы койрыгын тырпайтып, веранда астына чумды. Ул арада өйалды ишеге ачылып китте һәм әниләре күренде. Ул былтыр Фәрит белән Нәсимә бүләккә алып кайткан вак зәңгәр чәчәкле ефәк күлмәктән иде. Әниләре аларның кайтып килүен тәрәзәдән күреп, күлмәген алыштырган, ахрысы,

хәзер изүендәге сәдәфне эләктереп азаплана, дулкынланудан бармаклары тыңламыйлар. Башына ак яулык чөйгән, чуплылары чынлап куйды. Фәриткә әнисе тагын даябыга төшкән, йөзе дә агарыбрак киткән төсле тоелды.

Баскыч сап-сары итеп юылган булганга, ул аяк киеме белән керергә кыймады, сандалиларын ычкындырырга ниятләде, әмма иелергә көче житмәде, әнисенең йөзеннән күзләрен ала алмады. Аның һәр җыерчыгы җылылык бөрки, һәр сызыгы дөньяның әллә нинди гүзәллекләреннән дә газиз һәм кадерле иде, бу йөздән башка тормышны, яшәүне күз алдына китереп булмый иде. Фәрит шактый вакыт күзләрен аңардан ала алмыйча басып торды. Ул арада Нуриасма елмая-елмая кулларын сузып баскычтан төште. Фәрит әнисенең гомер буе урак-чалгы, көрәк-сәнәк, китмән, балта-пычкы төшмәгән кулларын учларына алды.

— Исәнме, әнкәй! Исән-сау тордыгызмы?

— Исән, улым, исән! Аллага шөкер.

Гомер буе, көн саен туфрак, су, үлән, тоз, камыр белән эш итүче бу куллар, жир төсле яргаланган булсалар да, бишектәй йомшак, күкрәк сөте кебек җылы иделәр... Аларның кытыршылыгы пешкән икмәк өстенең кытыршылыгы кебек иде. Фәритнең бу кулларга битен куясы килде, ләкин моны эшләп булмый, чөнки шундый илаһи затка бит белән орыну аларны түбәнсетү кебек тоелыр сыман иде.

Нәсимә бианасын кочаклап алды, җилкәләреннән сөйде. Фәрит аңа өнәмичә карап торды. Хатынының әнисен кочаклау, сөю гадәтен ошатмый ул. Үзенә әйтә дә алмый, ләкин күңеле аның бу гадәтен кабул итми иде. Әнкәй — ул изге зат. Аны чат-чат үбеп булмый, аның алдында кайберәүләр кебек майка-трусиктан да йөреп булмый. Аның янында икәнен тою гына да — берни белән алыштыргысыз бәхет. Ул үзе дә әнисенең аны үсеп житкәч кочаклап, үбеп утырганын хәтерләми. Еллары да кырысрак булгандыр. Әнисе йомшак кына итеп башыннан сыйпар, аркасыннан кагып сөяр иде, шуннан да рәхәт нәрсә булмас иде. Ул бу рәхәтлекне хәзер дә тоя, иң авыр чакларында әнисенең шушы саран гына иркәләвен исенә төшерә... Шуңа күрә Нәсимәнең мөгамәләсен Фәрит ничектер әнисен кечерәйтү, аның изгелеген киметү дип кабул итә иде.

Алар исәнлек-саулык сораша-сораша өйгә үттеләр.

— Нигә хәбәр итмәдегез, балалар?

— Борчылып көтеп торырсыз дидек, әнкәй.

Өйдә беркем дә юк иде.

— Әнкәй, Марат кайда соң? — диде Нәсимә, борчылуын яшерә алмыйча.

— Уенда ул, уенда, — диде Нуриасма, тәрәзәгә ишарәләп.

Чыннан да, кар базы янындагы биек кычыткан артында нидер күренеп алды.

— Барыгыз, сөендерегез инде. Мин чәй куеп җибәрермен.

Нәсимә белән Фәрит атылып ишек алдына чыктылар. Кычыткан арасыннан нindидер баш түбәсе сизелер-сизелмәс кенә күренде. Ничек кергән ул анда? Нәсимә килә-килешкә:

— Марат! — дип кычкырып җибәрде.

Шулчак баш түбәсе пылт итеп өскә калыкты, аларның каршында бер ят нәрсә пәйда булды. Кем бу? Җен баласымы? Малайның бите нәрсәләргәдер буялып беткән иде. Зәңгәр майкасының уң җилкәсе төшкән, бүксә турыннан ертылган, аңа нindидер таплар тигән. Чуен кебек каралган тәнендә кояш нурлары уйный. Киндергә охшаган чалбарының ике тез башына ямау салынган, ул солдат гимнастеркасыннан алып тагылган йолдызлы ике сәдәфтә эләгеп тора. Малай яланаяк, аяклары кап-кара иде. Ул тимер тәгәрмәч тоткан уң кулын аска төшерде дә сулын каш өстенә куйды һәм ят апа белән ят абыйга авызын ачып карап тора башлады. Нәсимә тагын дәште:

— Марат улым, танымыйсыңмыни, бу бит без — әтиең белән әниең!

Малайның кечкенә гәүдәсе тез астына суккандай чайкалып куйды, күзләре елмаюдан кысылды, кулындагы тәгәрмәче төшеп китте һәм ул әтисе белән әнисенә таба йөгерде. Алар икесе дә чүгәләп аңа кулларын суздылар. Бала иң элек әнисенә килде. Нәсимә аны кочаклап алды, елый-елый битләреннән, чәчләреннән, җилкәләреннән үпте. Бер ел тулган сагынуны, нишләсәң дә, басарлык түгел иде. Менә Марат әнисеннән аерылып Фәриткә килде. Ул малаеның йомшак битен үзенең битенә терәде, юка гәүдәсен кысып кочаклаган килеш күзләрен йомып хәрәкәтсез калды. Фәрит аның нәни йөрәгенең күкрәк читлегеннән чыгардай булып дөп-дөп тибүен ишетте, колагына кайнар сулышы бәрелде, борынына үлән, туфрак, май исе керде. Ир кешегә оят иде, оят булса да, ул борынны, күзләрне, тамакны ачыттырып килгән күз яшьләрен тыя алмады... Маратның нечкә беләкләрен муенында тоюдан аның бөтен тәне рәхәт изрәде. Тукта, бәлкем, Фәрит ялгышадыр? Бәлкем, әнисе дә аның иркәләвен телидер? Ул үзе дә сизмәстән йөзен өйгә таба борды. Әнисе тәрәзәдән аларга карап елмая, үзе яулык очы белән күз яшьләрен сөртә иде. Фәрит көч-хәл белән күз яшен йотып җибәрде, әмма дәшә алмады — тамак төбеннән тавышы чыкмады.

— Безне... улым... әтиең белән әниеңне онытмадыңмы?..— диде ул тамак төбеннән кысылып чыккан ят, хәлсез тавыш белән.

— Мин чежне чагындым,— диде Марат аларның икесенә дә бик җитди карап.

Аның бу сүзләрен ишетүгә Нәсимә белән Фәрит шатлыктан егылып китә яздылар. Хакмы соң бу! Төш кенә түгелме?! Аларның «әъ-у», «әъ-у!»дан башка берни белмәгән уллары сөйләшә! Нәсимә аны тагын кочаклап алды, күтәрде, үпте, берөзлексез елады, иркәләү сүзләрен кабатлады. Ләкин Марат бу кадәр иркәләүгә түзеп тора алмады.

— Төчәм, төчәм, төчәчем килә,— диде дә әнисенең кочагыннан тыр-машып төшеп җиргә дә басты.

— Улым, мин кем соң? — диде Нәсимә.

Марат бераз вакыт әле әнисенә, әле әтисенә карап торды да:

— Чин Нәчимә әни,— диде.

Алар күз яше аша рәхәтләнеп көлделәр.

— Ә мин?

— Ә чин Чәбит әти.

— Кем, кем?

— Чәбит.

— Кем әйтте, улым?

— Чуичама әби әйтте.

Куанычтан башлары күккә тигән ата белән ана улларын икесе ике кулыннан җитәкләп өйгә юнәлделәр.

Сумкалар, чемоданнар ачылды. Нәсимә бианасына кызыл бәрхет камзул кигерде, кулына бик матур күлмәклек тоттырды. Нуриасма аларга рәхмәт укыды, кайткан саен шушы кадәр расхудланмаска иде, диде. Боларны кайчан киеп-туздырып бетерерсең, диде. Маратка якорь төшкән ленталы түгәрәк кепка белән зәңгәр матроска чыкты. Нәсимә аның битен-кулын юдырды, көч-хәл белән юмалап әлеге майкасын, ыштанын салдырды. Яңа матроска кигәч, Марат үсеп киткән кебек булды, элекке чибәрлеге кайтты.

Менә чемоданнан уенчык машина чыкты. Марат бежелди-бежелди идәндә шул машинаны йөртте, аның тавышы бөтен өй эчен тутырды.

Нәсимә ризык-нигъмәт белән өстәл өстен тутырып ташлады. Борынгы җиз самавыр да өстәл башына менеп утырды. Нәсимә анар, банан чистартып куйды, лимон кискәләде, өрек, хөрмә җимешләре юып китерде. Самавырның күңелле итеп чыжлавы астында әнисенең дә, Маратның да күчтәнәчләрнең әле берсеннән, әле икенчесеннән авыз итүенә карап утыру Фәрит өчен әйтеп бетергесез бәхет иде. Түрдә әтисе дә утырадыр кебек тоелды аңа. Шушы самавыр тирәсендә шушылай акрын гына

сөйләшеп күпмеләр утырмады алар! Шушы самавыр эченә салып күпме йомыркалар пешермәделәр! Бәләкәй чакларда бу самавырны, катыкка ком кушып, ничә мәртәбәләр чистартмады Фәрит! Чистарткан саен самавыр күзгә кебек ялтырар иде. Самавыр бүген дә элеккечә үк кояштай балкый, әйтерсең, бүген сатып алынган. Нигә без әйберләрне шулай саклый белмибез икән?

— Әнкәй,— диде Фәрит чынаяктагы чәенә өрә-өрә,— безнең чәйдән әллә күгәрчен ипие тәме, әллә таудагы исле үлән тәме килә.

Нуриасма көлеп куйды:

— Киләдер, улым, суы да, үләне дә шул бер җирдән бит.

Шулчак ишектән дүбердәшеп биш-алты малай килеп керде һәм борыннарын тартып туктап калдылар. Машина белән аюны күргәч, аларның күзләре дүрт булды. Нәсимә белән Фәрит аларның кулларына күчтәнәчләр тоттырган арада Марат уенчыклары белән мактана торды. Малайлар машинаны да, аюны да тотып-тотып карадылар, бер сипкеллесе Маратның якорь төшкән лентасыннан күзен алмады, сипкелленең күңелендә нинди көчле теләк туып килгәнен әлегә беркем дә башына китерми, ләкин ул аны ишек алдына чыккач, һичшиксез, тормышка ашырачак иде. Кыскасы, әле күрәселәр алда иде.

Малайлар чыгарга әзерләнә башладылар.

— Әни, Маратның аяк киемнәре кайда соң?— диде Нәсимә улын киендермәкче булып.

Нуриасма кул селтәде.

— Кирәкми, килен. Күрмисеңмени: бөтенесе яланаяк. Алар көн саен туфракта аунап өйрәнгәннәр инде, берни дә булмас,— диде Нуриасма көлеп.— Әйдәгез чәй эчик әле, балалар.

Алар бер сәгатькә якын әкрен генә сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр. Әниләре авыл хәлләрен, яшен-картын һәммәсен вәземләп сөйләде. Рәмзинең үлемен ишеткәч, шаклар каттылар. Хәдичәттинең аларны күрмичә үтеп баруы юкка булмаган икән шул... Фәрит әнисенең зиһенлелегенә, хәтеренең әйбәтлегенә, олымы ул, бәләкәйме — авылдагы бер генә хәлне дә игътибарсыз калдырмавына сокланып утырды. Шул ук вакытта Фәрит әнисендә нинди дер үзгәреш сизде. Башта ул аны күрмәскә, танымаска тырышты, аның таныш җыерчыкларын, күз сирпүләрен, елмаюын күзәтте, ягымлы сүзләренең һәрберсен йөрәгенә салып барды. Шул ук вакытта ул һәр секундта нинди дер җинаять өстендә тотылгандай яшерен тойгы кичерде. Әйе шул, үзгәреш бар иде. Әнисенең иреннәре күгәребрәк киткән, аның күз читләрендәге, авыз почмакларындагы җыерчыклар элеккечә шаян булып җәелеп китмиләр, иреннәре елмайганда ничектер җитди, салкын калалар. Сәбәп нәрсәдә? Авырый дияр идең, әнисенең хәрәкәтләре элеккечә житез, ашавы әйбәт. Авырса, ихата тулы малтуарны, кош-кортны карый алмас, бәрәңгесен, яшелчәсен үстерергә көче җитмәс иде. Мизхәттән ярдәм аз, ул шофер кеше, көне-төне колхоз эшендә. Юк, әнисе авырмый, аны Марат борчыгандыр. Ярый, хәзер ул шулай җен ташыдай уйнап йөри. Ә алар авылда калдырып киткәч, үзган бер елда әнисе ниләр кичермәгәндер? Шушыларны уйлагач, Фәрит үзен әнисе каршында тагын да гаеплерәк итеп сизде.

— Әни,— диде ул,— Ничек итеп Маратны савыктыра алдың син? Без бит инде өметне өзеп бетерә язган идек.

— Белмим,— диде Нуриасма көлеп.— Кайткач бераз авырып йөрде дә үзе тернәкләнеп китте, ходайның рәхмәте.

Нәсимә дә сүзгә кушылды:

— Бик интектермәдеме соң?

— Нәрсәсе интектерсен инде аның? Рәхәтләнеп яшәдем, бер елым бер көн кебек кенә үтте. Үзегезгә охшатып сөйдем, икегез дә янымда кебек тоелдыгыз.

— Ничек шулай ныгып китте икән соң ул?

— Бала туфракта аунап, шуны ашап үссен ул. Туфракта хикмәт. Үзебез дә шул туфрактан яратылган лабаса!

## 11

— Әнкәй, нишләп Мизхәт һаман юк, сәгать ун тула бит инде,— диде Фәрит.

Әнисе урын җәеп маташкан җиреннән туктады да караватына утырды. Аннары ничектер тонык, уйчан тавыш белән:

— Мизхәт кайтырмы-юкмы, мин әйтә алмыйм, балалар,— диде.

Фәритнең йөрәген нидер телеп алгандай булды. Көндез дә, Мизхәт турында сорагач, әнисенең ике генә сүз белән җавап бирүенә аптыраган иде ул.

— Ничек инде?

— Ул кичә дә кайтмады...

Башка сыймаслык хәл: Мизхәт өйгә кайтмый! Шайтан суы белән шаярмаганын белә Фәрит. Әллә соң...

— Шулай кайтмый калгалыймыни?

— Беренче мәртәбә...

Нәсимә белән Фәрит бер-берсенә карашып куйдылар.

— Берәр хатын-кызга ияләнмәгәндер бит?

Нуриасма җавап бирмәде.

— Бүгенгә йоклыйк әле, балалар. Арыдым мин...

Әниләре чыннан да арыган иде, ахрысы. Фәрит болай да аның гомер буе көн саен иртәнге өчтән-дүрттән торып төнгәчә чабуына аптырый, шулкадәр эшләүгә, йокысызлыкка түзүенә хәйран кала иде.

Фәритләр йокларга верандага чыктылыр. Марат әбисенең түшәгенә менеп ятты. Нәсимә диван-кроватьтан ястык-мендәрләрне алганда Маратның теге ямаулы ыштаны белән майкасы килеп чыкты.

— Кара инде бу әнине! — диде Нәсимә тавышын күтәреп.— Теге иске-москыларны шушында куйган!

Ул әлеге майка белән ыштанны веранданың почмагына ук илтеп ташлады. Фәритнең кәефе кырылды.

— Сиңа кайда торса да, барыбер түгелмени? Әле шуларны кигереп, малаеңны таш кебек иткән бит.

— Синең дә малаең ул!

Фәрит дәшмәде. Ишек алдына чыгып китте. Җан тынычлыгы югалган иде. Ни булды соң әле бу? Ут йотып кайттылар, балаларының саусәламәт икәнлеген күреп куану сынлы куанмадылар, һәм менә кинәт кенә әллә ни булды. Авылда хәбәр озак йөрми. Мизхәт бит аларның кайтканын ишеткәндер. Энесе белән ул һәрвакыт горурланды. Әтиләре декабрьдә дөнья куйганда Мизхәт әле юк иде. Ул январь аенда туды. Фәрит гаиләдә иң зурысы иде, аннан кечерәк Шәрифҗан, Илсөяр, шулар өстенә паралич суккан Дөррикамал әбиләре бар иде. Унсигез яше тулар-тулмас, Фәрит шахтада эшли башлады, әнисенә акча белән ярдәм итеп торды. Балалар аякка баскач, Фәрит үзе дә гаилә корып җибәргәч, әнисе акчадан бөтенләй баш тартты! Алай гынамы сиңа! Үзе әле тозлы казын, әле кагын, оекбашын-бияләен, әле башкасын җибәреп торды. Фәрит кунакка кайткан саен Мизхәткә баштанаяк кием-салым алып кайтты, аның тәртипле-итагатьле булып үсүенә сөенеп туймады. Барысы да читкә киттеләр, ә менә төпчек малай ата-баба нигезендә калды. Бер дигән өй җиткерделәр. Инде барысы да ал да гөл, тормышның бер ягы гына китек — килен кирәк иде.

Фәрит, капкадан чыгып, тупыл ябалдашы астында басып торды. Авылның бер өлеше инде тынлыкка күмелсә дә, урак өстенең кайнар сулышы һәр тарафтан аермачык сизелә. Тау башындагы ындыр табагында лампочкалар һәм зур прожектор гөлт итеп балкып тора,

механизмнар эшли, каядыр еракта әллә комбайн, әллә машина утлары җемелди.

Инде кереп китәргә әзерләнгәндә, Фәрит аяк тавышлары ишетте, озын шәүлә күренде. Бераз якынайгач, Фәрит аның Мизхәт икәнен таныды. Ахрысы ул да абыйсын күреп килде, адымнарын кызулатты һәм беренче булып Фәритне кочаклап алды:

— Абый!

Фәрит аның чандыр, тыгыз гәүдәсен кысты, шул мизгелдә барлык күңелсез уйлар юкка чыкты.

— Нишләп бик соң? — диде Фәрит.

— Бүген чык төшмәде, комбайннар туктамыйча эшләделәр...

Алар сөйләшә-сөйләшә өйалдына үттеләр. Нәсимә каршы чыгып Мизхәт белән күреште, ашарга әзерлимме, диде.

— Минем кичке рацион билгеле: ярты литр җылы сөт.

Әнисе сөтне сөзеп өйалды өстәленә куйган булган икән — Мизхәт аны күтәреп кенә эчте дә:

— Ә сез ашагансыздыр бит? — дип сорады.

— Без тук.

— Өйгә кермик инде, әни йоклаган, — диде Нәсимә.

Верандада хәл-әхвәл сорашып, күңелле генә сөйләшеп утырдылар. Фәрит энесенә эчке бер горурлык белән карап-карап алды. Чибәр иде Мизхәт. Күперeп торган көрән чәчләре колагын яртылаш каплап тора. Коңгырт күзләре һәрнәрсәгә игътибарлы, бер генә хәрәкәтеңне дә ычкындырмаслар. Син сөйләгәндә Мизхәт башын әз генә борып, карашын еракка төби һәм ул бик зур игътибар белән нидер күзәтә кебек. Шулчакта аның калын иреннәре, алга чыккан ияге аеруча сөйкемле күренә. Хәтта Мизхәтнең иреннәре бераз кыймылдый да — син әйткәннәрне эчтән генә кабатлап бара кебек. Асылда ул берни дә күзәтми, һәр сүзеңнең мәгънәсенә төшенергә теләп тыңлый. Бу бәләкәйдән үк килә.

Фәрит энесен үзе белән чагыштырып карый да ике арада уй-фикерләүдән алып тышкы кыяфәткә кадәр бик зур аерма таба. Мизхәт күп сөйләшмәс, хисләрен артык күрсәтмәс.

Никадәр түземсезлек белән көтеп алынган булмасын, һәрбер очрашуның кайнарлыгы акрынлап сүрелә бара. Фәритнең күңелендә дә әнисе әйткән аңлаешсыз нәрсәләр кабат күтәрелеп чыктылар. Ничек сорарга соң бу хакта Мизхәттән?

Аның уйларын сизенгәндәй энесе:

— Сез дә юлдан арыгансыздыр, ял итегез, — диде һәм ишек алдына чыгып китте.

Фәрит аңа иярде. Болдырдагы лампочкадан төшкән яктылыкта алар беравык сүзсез генә басып тордылар. Август төне инде суынып килә иде. Фәрит Мизхәт үзе башлап берәр сүз әйтмәсме дип көтте, әмма ул дәшмәде.

— Энекәш, — диде Фәрит аның күзләренә туп-туры карарга тырышып. — Сезнең арада ни булды?

Фәриткә ул әз генә сискәнеп киткән шикелле тоелды, ләкин энесе карашын читкә алмады.

— Кем белән? — дип сорады ул тыныч кына.

— Әнкәй белән.

Мизхәт башын аска иде һәм уфтанып әйтеп куйды:

— Әнкәй белән минем арада гына түгел шул...

— Тагын кем бар?

— Шактый кешеләр бар.

Энесенең аңардан нидер яшерүе Фәритне үпкәләтеп җибәрде.

— Без бит, энекәш, спектакль уйнамыйбыз. Мин синнән күбрәк яшәгән, киңәш булса да бирә алыр идем...

— Ачуланма, абый, әлегә берни дә сөйли алмыйм.

— Алай... Ярый, мин сабыр кеше, көтәрмен. Тик турысын әйтим, синең өйгә кунарга кайтмыйча әнине борчуыңа һич тә кул куя алмыйм.

— Дүрт аяклы ат та абына, диләр.

— Рәхмәт яхшы сүзең өчен. Кайтып керү белән шатландырдың...

Шулай диде дә Фәрит кызу-кызу атлап кереп китте.

— Абый!

Нәсимә веранданың утын сүндергән иде инде. Фәрит күлмәк-чалбарын йолыккалап салып атты да диван-кроватька ятты. Нәсимә аңа борылды:

— Йә, ни булган соң?

— Берни дә булмаган, йоклыйк әле,— диде ул һәм аңа сырты белән борылды. Нәсимәне хәзер лышык-лышык елый башлар дип көткән иде, ни гаҗәптер еламады. Бераздан Мизхәтнең дә ишекне бикләп өйгә кереп киткәне ишетелде.

Фәритнең күзенә йокы кермәде.

Ниндидер аңлашылмый торган нәрсәнең күңелне кимерүенә түзәрлек түгел иде. Алар ирле-хатынлы бер кайгы — бала кайгысы белән ут йотып кайттылар. Ләкин аларның өзгәләнүләре, бәргәләнүләре юкка булып чыкты. Инде әнисенә, язмышка, тормышка рәхмәт укырга һәм шатланырга кирәк. Тик шатлык качты. Әгәр аларның икесен дә моңа кадәр бер олы сорау борчыган булса, хәзер мең төрле сәер сорау туды, аларның барысы да аңлаешсыз, берсе дә анык түгел иде. Фәрит автобустан төшкәннән алып шушы минутка кадәр кичергәннәрен күңеленнән әллә ничә мәртәбә уздырды. Акрынлап ул Хәдичә түтинең күчтәнәчтән баш тартуында ниндидер яшерен мәгънә барлыгын аңлады. Ничек кенә кайгылы булса да, алырга тиеш иде ул аны. Чәй янында Фәрит Хәдичәттиләр турында төпченеп сорый башлагач, әниләре сүзне икенчегә борды. Ә ник алай итте ул? Әйе, нидер бар, тик аны берсенең дә кычкырып әйтәсе килми...

Нәсимә инде йоклап китте, ә аның күзенә йокы кермәде. Йомшак түшәк, балачактан ук таныш тыныч төн, ә йокы алмый. Шулай уйланып ята торгач, аның күз кабаклары авыраеп, йокы баса башлады. Кинәт... тышкы ишеккә кемдер сак кына кагылды. Фәрит аптырап калды. Кем булыр? Нишләп капкадан кергәне ишетелмәде? — дигән уй үтте аның башыннан. Ишек ярыгыннан ниндидер әйбер тыгып, билгесез кеше келәне челтерәтеп ачты. Фәрит күзләрен кысып кына ишектән кереп килүчегә карады. Ай яктысында аны юньләп танырлык түгел һәм ул, гомумән, күз күргән кешегә охшамый иде. Бәлки Мизхәтнең берәр дус егетедер? Күрше авылга барып, кызлар озатып, дус егетләрендә кунып йөргән чаклары аның да булды бит. Фәрит, ныклабрак карагач, бу кешенең илле-алтмыш яшьләр тирәсендә икәнлеген абайлады. Эре гәүдәле, куллары көрәк кадәр, тузган чәчле бу кешенең күзләре ай нурында ялтырап күренде. Менә ул як-ягына каранды, кулы белән веранда идәнен сыпыргалады һәм, нидер эләктереп, Фәритләр яткан урынга әкрен генә килә башлады. Фәритнең бөтен барлыгын курку биләде. Теге кешенең кулында Маратның Нәсимә алып биргән иске чалбары иде. Моны Фәрит аермачык таныды: ай яктысында чалбарның теге ике тимер сәдәфе ялтырап китте, бер балагы асылынып төшкән иде. Шулчак ай, күрәсең, болытлар арасына керде — веранда шактый караңгыланды. Теге кеше чалбар тоткан кулын бераз алга сузган хәлдә һаман якынлашты. Коточкыч сизенүдән Фәритнең бөтен тәне дерелдәп куйды, ул кычкырмакчы булып авызын ачты, ләкин соң иде инде: әлеге кеше чалбарлы кулы белән аның авыз-борынын китереп кысты, Фәритнең өстенә үзенең коточкыч авыр гәүдәсе белән ятты һәм тимердәй бармаклары белән бугазыннан эләктерде. Фәрит талпынырга теләде, әмма кымшана да алмады, җан ачысы белән гәүдәсен уңга-сулга боргаларга тырышты һәм... уянып китте. Йөрәге дөп-дөп тибә, маңгаена салкын тир бәреп чыккан. Иң беренче тойгы — бу коточкыч хәлнең булмавына, төш кенә икәнлегенә

шатлану иде. Уянуга карамастан, ул әле авыз-борынын эләктергән кулның һәр бармагына кадәр, хәтта чалбарның исенә кадәр тойды. Тамак тебе дә авырта башлаган — күрәсең, автобуста җил бәргәндер. Ул башын күтәреп почмакка күз ташлады — чалбар урынында иде. Фәрит тәмам тынычланды, борылып ятты. Ләкин ничә генә минут үткәндер, үз өстенә тагын теге кешенең иелүен тоюдан аның бөтен тәне калтырый башлады. Бу юлы ул Фәритнең йөзенә әлеге чалбар белән сыдырды да чыгып йөгерде. Фәрит хәзер аның чит кеше түгел, үзенең әтисе икәнен аермачык күреп калды...

Фәрит торып киенде. Бер куркыныч төш белән икешәр мәртәбә бастырылу аның өчен таныш нәрсә. Андый чакта йә урын алыштырырга, яки торып бераз йөреп керергә кирәк. Ул ишек алдына чыгып хәрәкәтсез басып торды, кереп ятуга тирән йокыга талды.

## 12

Ә Нуриасма әле һаман йокламаган иде. Ул Мизхәтнең кайтканын ишетте, аның өйгә керүен көтте.

Улы акрын гына чишенде. Нуриасма аның һәр хәрәкәтен ишетеп торды, әмма үзенең уяу икәнен сиздерергә батырчылык итмәде. Мизхәтнең кайтуы әйбәт. Ләкин нинди уй белән кайткан соң ул? Әгәр бер үзгәреш тә булмаса? Аны әнә шул куркытты. Ләкин бит Мизхәт һаман да аңа каршы якта калса, өйгә кайтып керергә батырчылык итәргә тиеш түгел иде. Ә итсә? Ул чакта нәрсә эшли ала Нуриасма?

Мизхәт, әнисе эндәшә күрмәсен дип, тиз-тиз генә чишенде һәм одеал астына чумды. Әйтерсең, одеал аны барлык күңелсезлекләрдән, бәла-казалардан саклаячак иде. Ул да шактый вакыт уйланып ятты. Фәрит абыйларының кайтканын ана шул сәгатендә-минутында ук житкерделәр. Ашлыгын ындыр табагына бушаткач, абыйлары белән күрешеп кенә чыгарлык вакытны Мизхәт, әлбәттә, таба ала иде. Аны әнисенең күзләренә карау куркытты. Ул әтисеннән үк, бәлкем әби-бабаларыннан ук канун булып калган, әнисе шуны гомере буе күз карасыдай саклаган изге, илаһи нәрсәгә кара тап төшерүен аңлады. Иң хәтәре шунда, ул нәрсәне бозмау хакында Мизхәт әнисенә күптән ант биргән иде. Моны беркем дә белмәсә дә, бөтен авыл халкы тоя иде. Мизхәтнең әлеге адымы халык алдында әтисенең дә, әнисенең дә йөзләренә төкерүе иде... Ул көне буе тикшерүчене күрергә, аңа язып биргән күрсәтмәсен үзгәртергә теләде, әмма һич тә җай чыкмады. Аннары ул моның җай чыкмаудан түгел, ә бу эшкә батырчылыгы җитмәүдән икәнлеген аңлады. Мизхәт нәрсәнедер атлап чыга алмады. Уйлый торгач төшенде: ул «нәрсәләр» түгел, тәпи йөри башлаган чактан ук тәгәрәшеп, бер кашыктан ашап үскән Гарифҗан иде. Дусты, күзләрен кысып, теш арасыннан төкерер дә: «Төрмәгә кертешкәнең өчен рәхмәт, парин», — дип әйтер төсле тоелды аңа. Һәм ул кабат Мизхәткә гомере буе дошмәсә дә, үзенчә хаклы булачак, чөнки Мизхәт белән әнисенең дөньясын ул беркайчан да аңлый алмаячак. Шул рәвешле ул үзенә карата үпкәләүләр, рәнҗешләр, бәддогалар кылысен бик ачык чамалады. Бик якын дуслар да читкә борылыр, кемнәрдер дошманга әверелер. Ахырда ул шушы язмышка ризалашты, чөнки олы хакыйкать әти-әнисе ягында, чөнки аның уллык бурычы, биргән анты боларның һәммәсеннән өстен иде. Хөснуллинның машина белән кызыктырып, аны үз кулына алырга теләве Мизхәтнең ачуын чыгарды һәм әлеге нәтиҗәгә килүен тизләтте. Тикшерүчене күрү, тагын әллә нинди комачаулар килеп чыкмаса, иртәгәсе көнгә калды...

Нуриасма сыер-сарыкларын көтүгә кугач, самавыр куйды, суыткычтан алып, пешерергә ит салды. Ул чәй эчеп туйганда, Мизхәт тә торды. Сүзсез генә урынын җыйды, сүзсез генә чыгып юынып керде, сүзсез генә өстәл янына утырды. Нуриасма ни уйларга, ни кылырга да

белмәде. Чигенергә дә ярамый, тәртәне кисәк каеру да хәтәр иде. Мизхәт бер ризыкка да кагылмыйча башын игән хәлдә өстәл янында шактый утырды.

— Әнкәй,— диде ул ниндидер ят, тоник тавыш белән.— Син миңа аңлаттың... Яңадан беркайчан да онытмам...

Мизхәткә оят иде, Нуриасма моны яхшы аңлады.

— Рәхмәт, улым, аңлагач...

Ул аның аркасыннан сөйдә дә иркенләп ашасын өчен бәрәңге бакчасына чыгып китте. Ярты чиләк чамасы яшь бәрәңге алып ихатага кайтканда, Мизхәт белән Фәрит мотоциклны сарайдан ишек алды уртасына чыгарганнар, акрын гына нидер сөйләшәләр иде.

Мизхәт эшкә китте. Фәрит мотоцикл утыргычына биле белән сөялгән килеш уйланып торды. Хәзер, Мизхәт сөйләгәннән соң, барысы да ачыкланып бетмәсә дә, аңа күп нәрсә билгеле булды, җаны тынычланып калды диярлек.

Марат та торып чыкты. Ул тагын кечкене иске майка белән Фәритнең төштә котын алган иске чалбарны киеп куйган.

— Марат, миңа су салып тор әле,— диде Фәрит. Аны чакыруы, кирәктән бигрәк, үзе янында тотасы килүдән иде, билгеле. Ул койма буенда ат сыман пошкырына-пошкырына рәхәтләнеп юынды, Марат бактан алып литрлы чүмеч белән аңа су салып торды. Тәннәрен, битләрен сөрткәндә, кояшның инде шактый кыздыра башлаганлыгын сизде. «Әни хәзер дә кояшка табына микән?» — дип уйлап куйды ул көлемсерәп. Кереп өстәл янына утырганда шуны сорады. Әнисе көлеп куйды.

— Табынам, улым, табынмаган кая,— диде ул яшермичә.— Кеше нәрсәгә дә булса табынырга тиеш. Юкса күңеленнән вакланып, үлеп бетүе бар.

Нуриасмага олы малае белән киленен, алар уртасына кереп утырган оныгын кыстый-кыстый ашатуы чиксез рәхәт иде.

— Әнкәй,— диде Фәрит,— Ык буйларын, Әби әрәмәләрен бик күрәсе килде. Бергәләп мотоцикл белән урап кайтыйк.

— Һи-и, балакайларым, мин ни эшләп йөрим инде сезнең белән,— диде әниләре.— Барыгыз, иркенләп йөрегез. Мин кайтуыгызга аш пешереп торырмын.

Алар сумкага термос белән чәй, ризык-фәлән салып, мотоциклга утырырга гына торганда, капкадан Бәрия килеп керде.

— Исәнмесез, туганнар, әйбәт кенә кайтып җиттегезме? — дип Фәрит белән дә, Нәсимә белән дә озаклап күреште.

Аны чәй эчәргә кыстадылар, ул баш тартты, яңа гына кузгалдым, диде. Нәсимә йөгереп кереп, аңа күлмәклек ситсы, полиэтилен кап белән лимон, әфлисун кебек нәрсәләр алып чыкты. Бәрия кат-кат рәхмәт укыды, әле Нәсимәне, әле Фәритне үпте, елап та алды.

— Әле дә сез бар мине туган итүче, сез генә бар! — диде мышыкмышык килеп.

Ул аларга кичкә ашка әйтергә кергән булып чыкты.

— Үзегезне генә чакырам, башка кеше юк. Җиңгәчәй, син дә керерсең,— диде Бәрия аның янына килеп.

— Керерләр, керерләр,— диде Нуриасма салкын гына.

— Син дә калмыйсың, калмыйсың,— диде Бәрия тәкрарлап.

Нуриасма дәшмәде, эре-эре атлап өйгә кереп китте. Бәрияне озаткач, Фәрит белән Нәсимә үзара аптырашып баш ваттылар. Ни булган соң бу Бәрия апага? Алар кайткан саен барлык туганнарга, шул исәптән аңа да бүләк алып кайталар, күбесендә ашта булалар, әмма Бәрия апаларының һич тә мондый эшкә вакыты җитми, очраган саен: «Кереп утырыгыз әле, чакырганны көтмәгез», — ди иде. Ә хәзер? Кешенең картайган саен күңеле йомшый диләр, әллә шуның хикмәтеме? Моның чыннан да шулай булуын бик тели Фәрит. Чөнки әтисенең сеңлесе белән әнисе арасындагы

гомер буе килгән салкынлыкны бөтен авыл белә, мондый нәрсәне тою кунакка кайткан арада да үтә кыен иде.

Нуриасма ишек алдына чыккач, Фәрит:

— Әнкәй, бик кырыс сөйләштең, һаман да Бәрия апа белән борчагыгыз пешмимени? — дип сорады.

— Мизхәт сөйләгәндер бит өченче көн кунарга кайтмаганын.

— Әйе, сөйләде.

— Шул кичне Мизхәтне дә эчереп чыгарды ул. Аның сандугач кебек сайравына ышансаң...

Башка ул хакта сүзне дәвам итмәделәр.

Мотоциклга төялеп Фәритләр урамнан үтеп киткәндә, Бәрия аларны елмаеп сәламләде. Марат кул болгый-болгый: «Бәрия апа!» — дип кычкырып узды. Аларның артыннан тузан да басылырга өлгермәде, Бәриянең әле генә елмаюдан җәелгән иреннәре житдиләнеп калды, күзләреннән сыгылып яшь чыкты. Әллә Нуриасманың төртмә кылануына гарьләнүдән, әллә Фәритләрнең бәхетенә кызыгудан чыкты яшь бөртекләре — анысын ул белми. Тик соңгы елларда Бәрия бер нәрсәне аңлады: аңа юньләп дәшми башладылар, килүче-китүче кимеде, әйтерсең лә ул юк иде. Шушыны сизгән саен, Бәрия кешеләргә тартылды, аларга ныграк якынаерга теләде. Әмма ул никадәр ныграк елышса, алар нигәдер аңардан шулкадәр ныграк читкә тайпылдылар, качтылар. Фәритләрне ашка дәшүе дә шуңа иде. Заманында авылның беренче кызы бул да, бүген сине бар дип тә белмәсеннәр әле! Уйлап карасаң, башка сыярлык түгел иде бу. Бәрия, акрын гына кереп, сарай каршындагы ялгыз бүкәнгә утырды да, авыр итеп, уфылдап куйды. Шыңгырдап торган зур нарат йорт, веранда, абзар-сарайлар, мунча — һәммәсе такта белән тышланган, ялт итеп буялган, түбәләр тутыкмый торган калай белән ябылган. Зур тимер капкалар, биек коймалар. Теләсә, боларның бөтенесен тагын яңадан корырга мөмкинлеге бар Бәриянең. Ләкин ник? Кем өчен? Яшерми, боларына да күкрәк көче түкмәде ул. Шуңадырмы, корды, корды — күңеленнән куанмады, башкаларныкыннан артыграк булсын дип кенә матапшты. Аның күзе ишек алды почмагындагы тупыл агачына төште. Кем утырткан иде икән аны: бабасымы, әтисеме — Бәрия хәтерләми. Соңгы елларда ул корыды, яшь ботаклары аста гына калды. Былтыр ул аны җирдән өч метр чамасы калдырып кистергән иде. Менә хәзер яшь үсентеләр күкрәп үсеп киләләр, югарыга үрлиләр. Агач яшәрә, тик бу нигезнең генә тамырлары инде күптән корыган, ул беркайчан да яшәрмәячәк...

... Аларның гаиләсе зур, өй тулы кеше иде. Бәрия күз өстендә каш булды. Аның җиде айдан теле ачылды, аны җыелышып җырлаттылар, биеттеләр, шигырь сөйләттеләр, табышмак әйттерделәр. Әкият сөйләсәләр — аңа сөйләделәр, көй көйләсәләр — аңа көйләделәр, җөй җөйләсәләр — аңа җөйләделәр. Иркәләсәләр — иң элек аны иркәләделәр, киендерсәләр — аны киендерләр, мактасалар — аны мактадылар. Кечкенәдән үк ул күзге каршында бөтерелде, үзен көннән-көн матуррак итеп күрергә теләде, әле чәчен бөдрәләтте, әле каш-керфеген төзәтте, әле бетчәсен сытты, әле алка такты, әле беләзек киде, сәйлән-төймә асты, күлмәк арты күлмәк, яулык арты яулык алыштырды. Мәктәптә укыганда ук иннеккерпән белән эш итәргә өйрәнде, концерт-мазар куйганда таш курчак төсле бизәнде, аның матурлыгын күреп кешеләрнең «аһ» итүенә күнекте.

Җидееллык мәктәпне тәмамлаганда, инде аның борынына ис кергән, авылда иң чибәр кыз икәнлеген, шушы чибәрлеге белән генә дә үзенә беркем дә тиңләшә алмаганлыгын ул күргән һәм аңлаган иде. Бәрия кешеләрне үзе тирәсендә бөтерелүче, аның теләкләрен берсүзсез үтәүче, аңа буйсынучылар гына дип күрде. Башкаларның шатлыгы-кайгысы да, муллыгы яисә фәкыйрьлеге дә аңа таныш түгел, ул нәрсәләрне Бәрия күрмәде, белмәде, сизмәде, тоймады, аңламады. Дөньяда аның өчен бер генә бөек зат бар — ул үзе иде. Өздереп җырлавы, табан астыннан ут чыгарып биюе, чәчрәп күзгә керүе белән дә авылда аңа тиңләшерлек

кеше юк иде. Бәрия тормышын сәхнәдән башка күз алдына да китерә алмады, үзен Казанның, Мәскәүнең генә түгел, чит илләрнең дә зур-зур сәхнәләрендә, меңнәрчә тамашачыларның басып алкышлавы эчендә, данга һәм алтынга күмелгән итеп күрде. Бәрия үзе төшкән фильмнарны караганда, авыл халкының «аһ» итеп, тел шартлатып, аңа сокланып утыруларын, җәй көннәрендә киенеп-ясанып, ак эшләпәләрдән, затлы машиналарда әниләренә кунакка кайтып төшүләрен күз алдына китереп ләззәтләнде. Бу яшерен ләззәт-хыялларны ул йөрәгенең иң кадерле урынында саклап йөртте. Аңа укытучылар да, авылның башка бик күп кешеләре дә, син сәхнә өчен яратылгансың, артистлыкка укырга кит, диделәр. Әти-әнисе дә каршы килмәде.

Тик авылдан чыгып китәргә белешмә кирәк, ә колхоз рәисе булып бер аягын сугышта калдырып кайткан Закирҗан эшли иде. Белешмә сорап баргач, ул Бәрия белән шукланып сөйләште, ай-һай ансат кына алмакчы икәнсең, аның өчен әле озаклап очрашып сөйләшергә кирәк, диде. Караңгы төшкәч, ындыр табагында эшем бар, шунда менәрсең, кара аны, беркемгә дә әйтмә, диде. Бәрия күңеле белән нәрсәдер сизенсә дә, курыкмады, караңгы төшкәнне түземсезләнеп көтте, йөгерә-атлый тауга менде. Ындыр табагында әле беркем дә юк, уракка ерак, риганың тишек-тошык түбәсен ябарга кайтарып аударылган былтыргы арыш саламыннан башка берни дә юк иде. Закирҗан Бәрияне һаман шаяртты, кытыклап алды, үзе акрын гына саламга таба атлады. «Әйдә, утырып торыйк»,— диде. Бәрия нидер сизенде, ләкин ул качарга, карышырга уйламады, киресенчә, бу нәрсәне ул күптән көтеп йөри, кай тарафтан киләсен генә белми иде. Закирҗан аңа шунда: «Ярар, Бәрия үскәнем, белешмә бирермен, тик бер үптерсәң»,— диде. Бәрия дәшмәде, Закирҗан аны кайнар иреннәре белән үбә башлады. Кызның беренче мәртәбә үбешүе, беренче мәртәбә ир-атның кытыршы битләренә кагылуы иде. Ул каядыр очты, бөтен тәнен кайнар калтырау биләде. Ул Закирҗан абыйсын кысып кочаклавын сизмәде, тоймады, ул тау башында да түгел, һавада да түгел, әллә кайда, нindидер бер кайнар ут эчендә дөрли-дөрли агып китте... Бәрия үзенең кыз чагы белән әнә шулай хушлашты. Икенче көнне ул үкенмәде, чәчен йолыкмады, еламады. Тагын идарәгә барды, Закирҗан тагын тау башына менәргә кушты. Бер айлап шулай йөргәч, Закирҗан, белешмә бирә алмыйм, районнан рөхсәт итмиләр, диде. Идарәгә баргач, сөйләшергә дә теләмәде, куып чыгарды. Моңа кадәр аңа ышанып йөргән Бәрия өчен бу алданудан да зуррак хурлык юк иде. Аны, шушы көнгә кадәр бөтен авылның күз өстендәге кашын, чатан Закирҗан алдасын әле?! Белешмә бирәм дип, ничә көннәр буе! Бәрия аны дөньядан үткәрергә ниятләде. Идарәгә барып, үзе генә калганын саклады да юри елмаеп-көлеп керде. «Закирҗан абый, белешмәң дә кирәкми, тик ындыр табагына гына меник, шулкадәр сагындым, гел сине уйлыйм»,— диде. Закирҗан ат теше кебек эре тешләрен күрсәтеп елмайды. «Ярар, бүген көт»,— диде. Бәрия беләк буе сугым пычагының кайсы төштә тотылганын белә иде. Киндер чүпрәккә уралган пычакны әләктерде дә караңгы төшүгә тауга йөгерде. Рига капкасы төбендә чүпрәген сүтеп пычагын артына яшерде дә Закирҗанны көтә башлады. Менә аның озын гәүдәсе күренде. Ул кирза итекләре белән дөп-дөп басып аңа якынлашты. Бәрия бөтен тәне белән калтырарга кереште, пычакны чытырдатып кысты, килеп җитәр-җитмәстән бугазына китереп кадарга әзерләнде. Закирҗан кыска гына сызгырып куйды — бу шартлы билге иде. Бәрия тамак кырды. Закирҗан инде өч адым ераклыкта гына... Бәриянең бөтен гәүдәсе корыч пружина булып киерелде.

— Сагындыңмы, кызый?..

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, Бәрия пычагын күтәреп аңа ыргылды. Ләкин фронт юлларын үткән Закирҗан сак иде. Ул Бәриянең беләген тимер келәшчәгә кыскандай әләктереп алды, пычак каядыр чәчрәп очты.

— Кабахәт, мин сине барыбер үтерәм, үтерәм! — дип буылып кычкырды Бәрия, сул кулы белән аның чыраен умырмакчы булды, тик Закирҗан аны якын да китермәде. Бәриянең ике беләген бер кулы белән кысып тоткан килеш, икенчесе белән яңагына чалт-чолт суккалады да:

— Яңадан очрасаң, тычкан баласы урынына сытармын! — диде һәм этеп җибәрде.

Бәрия тәгәрәп барып төште. Закирҗанның дөп-дөп атлаган аяк тавышы срагаеп юк булды. Шунда үз гомерендә беренче мәртәбә Бәрия тәне авыртудан түгел, гарьләнүдән-хурланудан үкереп-үкереп, тузанда ауный-ауный елады. Елап туктаганда ул икенче кеше иде инде... Балага узганын белгәч, ул өченче кешегә әверелде. Аның күзләрендәге элекке беркатлы шаян очкыннар вакыт үткән саен ниндидер мәкерле, чәнчүле энәләр белән алышынды...

Көз көне Бәрия: «Белешмә булды, укырга барам», — дип, шактый акча алып, Урта Азиядә яшәүче туганнарына китеп барды. Юлга чыгып, үз гомерендә беренче мәртәбә чит-ят кешеләр белән аралаша башлагач, ул аларның үзен бар дип тә белмәүләрен, санга сукмауларын күреп, тиресеннән чыгардай булды. Аны этеләр, төрттеләр, сүгенеп кычкыруларны, башкача кимсетүләрне татыды. Моңа кадәр беркем җитә алмаслык биеклектә торган, бөтен кешенең үзенә соклануына, аның һәр теләген үтәүләренә күнеккән Бәрия өчен бу коточкыч хәл иде. Аны бер карчык көмәненнән коткарды, тик ул мәңге балага узмый торган бер мескен булып калды...

Баш иярга теләмәүче мондый гаделсез дөньяның астын өскә әйләндерәсе, үзенә буйсындырасы килде Бәриянең. Ләкин аңарда андый көч юк иде. Чибәрлеге ирләрнең игътибарын җәлеп итсә дә, ул аның башкаларны буйсындыру чарасыннан бигрәк хатын-кызның үзен буйсындыру чарасы икәнлеген бик тиз аңлады. Һәм шушы аптырашлы чагында Бәрия ниндидер эчке бер тоемы белән иң көчле үч алу чарасын тапты. Аңарда кечкенәдән үк булган ул әйбер — алдау иде. Аның йөгерек зиһене өчен бер уен гына булган бу нәрсә аны кабат элекке хәленә кайтарды, ул башкалардан өстен калды. Бәрия бер генә дөрес сүз дә сөйләмәде, кемнең кем булуына карамастан, күзенә туп-туры карап юри алдашты, интеллигентләр, газапланса да, ялгыш юлга керсеннәр дип алдады. Кешеләрне шундый хәлгә төшерүе белән ул үзен алардан өстен итеп тойды, шуннан тәм тапты. Закирҗаннан алдануы өчен дә, укырга керә алмаганы өчен дә, үзе каршында баш иеп, ләббәйкә дип тормаганнары өчен дә барлык кешеләрдән үч алды.

Бәрия русчага бик тиз өйрәнде, әтисенең чәч ала торган чалгы пәкесе кебек чарланды, үткенәйде, шул пәке шикелле сиздермичә кисте, аның йөзенә чыдарлык нәрсә юк иде...

Ул елларда авыл халкы ни башына, ни өстенә, ни аягына кияргә тилмерде. Бәрия аларга, ни кирәген белеп, төрле кием-салым, товар ташый торды, дүрт-биш мәртәбә кыйммәтрәккә сата бирде. Аның акчасы күбәйде, акчасы күбәйгән саен элемтәләре дә артты. Ул берничә ай авылда яшәсә, тагын юк булды. Бәрия өчен Казан, Уфа, Мәскәү, Пермь, Сәмәрканд, Бохара якларына барып кайту мич башына менеп төшү кебек кенә иде.

Ир-ат халкын аздыру да аңа берни тормады. Бәрия өчен иң рәхәте ул азгын затларның әүвәл баш-күзләрен тондыру, үзе артыннан ач бүре шикелле ялындырып йөртү, ә ахырдан хатыннарының күз яшьләрен күрү иде. Сәхнә насыйп булмаса да, ул көн саен, сәгать саен рәхәтләнеп уйнады, уенының нәтиҗәсеннән тәм тапты. Ул үзен кайчандыр алдаган Закирҗаннан да үчен алды. Бер карчыктан бозым эшләтеп, исерек чакта Закирҗанның кызыл аракысына салдырды. Шуннан соң ул тузә алмаслык булып башы авырта торганга, гәүдәсенең сул ягы түбә чәркәсеннән аяк табанына кадәр шыбыр су булып тирли торганга әйләнде, корышты, сызланды, тилмереп үлде...

Фəритлəр киткəч, Нуриасма казларын Ыкка куып төшерде. Алар каңгылдаша-каңгылдаша ярдан аска йөгерделəр, бернинди дулкын əсəре чыгармыйча, шуып кына баргандай, су өстеннəн йөзеп киттелəр. Ул, каш өстенə кулын куеп, казларның каршы яр буендагы яшел шəүлəле турга җитүлəрен күзəтте. Элегрəк ул тирəлəрнең төбенə буй салып җитəрлек түгел иде. Аръякта печəн эшлəренең уттай кызган вакытында хатын-кызлар əнə теге комлы борынга, ə ир-атлар нəкъ шушы турга су коенырга төшəрлəр иде. Тирлəгəн, арыган тəннəргə Ык суы көч өстəр иде. Йөрəктə үткəннең татлы хатирəлəре кыймшанып куйды. И гомерлəр! Ык сулары шикелле менə шушылай сиздермичə генə аккан да киткəн шул гомер дигəнең. Нуриасма казларны төшергəн чакта яр башыннан ук борылып кайтып китəм, дигəн уен онытты, кер чайкый торган басмага керде, култыксага тотынган хəлдə судан күзен ала алмады. Җилнең əсəре дə юк, су өсте көзге кебек тигез иде. Əгəр анда-санда күбеклəр акмаса, басмадан ерак түгел чыгып торган яшел түмгəкнең бөгелеп төшкəн күрəнен агым туктаусыз селкетмəсə, Ыкның мəңгелек хəрəкəте бөтенлəй сизелмəс тə иде. Зəңгəр күк үзенең анда-санда йөзүче болытлары белəн су өстенə төшкəн. Шулар уртасында Нуриасманың да шəүлəсе чагыла. Əнə баш артында ак болыт тора, зəңгəр чəчəкле күлмəге дə, кызыл камзулы да, чəмчəле читеге дə аермачык күренə... Бу яшеллеклəр, бу сулар, бу зəңгəр күклəр һəммəсе дə кешенең тормышын ямьлəү өчен генə яратылганнардыр. Бөтенесенə бəйле, берсе икенчесендə чагыла, һəммəсе кеше йөрəгенə тоташкан...

— И Ыккаем, таныдыңмы? — диде ул, иреннəрен бөтенлəй диярлек ачмыйча. — Əйе, мин бу, синең суларыңда чупырдан үскəн чем-кара чəчле караңгыш кыз. — Аның йөзенə елмаю җəелде, күзлəрендə шаян очкыннар биеште. — Минем бу ак чəчле əби сурəтемне тизрəк агызып алып кит! Теге бот буе кыз кыяфəтендəгесе еракмы? Син бит аның тəн җылыларын да үзеңə сеңдереп алып киттең... Алып кил, зинһар, шунысын!..

Нуриасма үзенең артында кинəт тамак кырган тавыштан сискəнеп китте. Басмага Хəдичə кереп килə иде. Ул буй-буй яшел күлмəк өстеннəн кимəле сары алъяпкыч бəйлəгəн, муенына эре гəрəбə төймəсен таккан, башын, нəрсəнедер бик җентеклəп күзəткəндəй, уң җилкəсенə кыйшайткан иде. Нуриасма, үзе дə сизмəстəн, нишлəптер, ана таба бер-ике адым атлады. Хəдичə, күрəсең, басмадан чыгып китмəкче була, дип уйлады, кулларын ике яклап култыксага салды да, башын турайтып артка ташлады.

— Ашыкма, Нуриасма...

— Ə мин ашыкмыйм, — диде Нуриасма, култыксага биле белəн сөялеп.

Хəдичə кулларын кара-каршы китереп алъяпкычының күкрəкчəсенə тыкты. Нуриасманың битенə кан йөгерде. Хəдичəнең шушындый кыяфəт белəн каршына килеп басуы һəм гаепле кешегə карагандай өстəн аска карап торуы Нуриасманың ачуын чыгарды. «Мин аның каршында бер гаепле күренсəм, ул ун мəртəбə гаепле, чын-чынлап гаепле», — дип уйлады ул эченнəн. Аның Нуриасмага дошманына караган кебек көйдереп каравы, җай чыккан саен очып кунуы тəмам туйдырды. Аларны гомер буе бəйлəп торган җеплəр инде өзелə башлаган иде. Нуриасма ул җеплəрнең өзелеп бетүен телəмəсə дə, бу минутта йөрəгендə Хəдичəгə карата үпкə-рəнҗештəн башка тойгы уянмаганлыгын сизде.

— Җаның тындымы инде?

Бу сүзлəрне Хəдичə тавышын күтəрмичə, үткəндəге бер хатирəне искə алгандай гына əйтте. Əгəр уттай янучы күзлəре булмаса һəм алъяпкыч күкрəкчəсен ерта язып этүче йодрыклары сизелмəсə, аны тып-тыныч дип уйларга мөмкин булыр иде. Ул сүзен дəвам итте:

— Тынсын əйдə. Тынып озак тормас ул... — Хəдичəнең карашы нидер эзлəгəндəй су өстен айкап алды. Нуриасманың шəүлəсе турында

бераз тукталып алгач, кабат аның йөзенә күтәрелде.— Синең дә малаең бар. Күрәчәгең алда... Әле башлана гына...

— Әле дә ярый безнең язмыш синең кулда түгел. Нишләр идең шулай булса?! — диде Нуриасма барлык әрнүен чыгарып.

— Аның урынына безнеке синең кулда. Шуңа күрә шатлыгың йөзеңә бәреп чыккан.

— Минем сезгә начарлык теләгәнем юк.

— Шулаймыни?! — Хәдичә бил бөгеп исәнләшкәндәй хәрәкәт ясады, муеныңдагы гәрәбәләре шылтырап куйды, яулык астыннан чыгып бер учма чәче битенә төште.— Изге ниятгә икәненне белмәгән идем әле. Алайса Гарифҗанның хөкемгә эләкмәвен, исән-имин котылуын да телисеңдер?

— Котылса, харап итмәссеңме соң син аны? — диде Нуриасма, Хәдичәнең күзләренә туп-туры карап.

Әлеге сорау белән Нуриасманың тез астына сукты дип уйлаган Хәдичәнең бу сүзләрне ишетүгә чырае кара янды. Ул битенә төшкән чәчләрен кулы белән селтәп җибәрде дә ачу белән:

— Гарифҗан — минем бәгырь итем! — диде.

— Бәгырь итем, дия-дия сансызга әйләндердең дә инде син аны!

— Әнисе рөхсәтеннән башка кызлар култыкларга куркып яшәгән егетләр дә кызганыч,— диде Хәдичә аңа төрттереп.

— Ә синнеке яшьтән үк тәмәкегә дә, аракыга да өйрәнде. Сүз әйттермәдең, кеше арасына керсен, дидең. Хәзер инде керү генә түгел, кеше арасыннан чыгып үк китте.

— Эчеңдә нинди уйлар йөртәсең икән!

— Минем эчемдәгем тышымда,— диде Нуриасма.— Аның үзенә дә, сиңа да ул хакта аз әйтмәдем. Гарифҗан ярдәмчел дә, эшчән дә. Ә мена дуамаллыгына, уйсызлыгына син гаепле! Син генә!

Аның соңгы сүзләре Ык өстеннән еракка ук яңгырады. Хәдичә дәшмәде, ике кулы белән култыксага ябышкан килеш карашын суга төшерде, асылынып торучы чәченә дә игътибар итмәде. Нуриасма аның керфекләреннән яшь сыгылып чыгуын күреп алды.

— Әйе, дөньясы авыр булды, ялгызым тормыш арбасын сөйрәп, аңа кулым җитмәде,— диде ул, кычкырып елап җибәрүдән көч-хәл белән тыелып.

— Алдама, Хәдичә! Син аны сукыр ярату белән яраттың.

— Яраттым шул! Бердәнбер малаем бит ул. Ә хәзер күралмыйм! — шул сүзләрне әйтте дә Хәдичә үксеп елап җибәрде.

Нуриасма әллә нинди каршылыклы уй-тойгылар уртасында калды. Хәзер инде үпкә-рәнҗүләр беткән, әмма аны юату теләге дә юк иде. Кинәт Хәдичә аның ике иңбашыннан тотты да ялварулы тавыш белән:

— Мин гаебемне юарга телим! — диде.— Хәзер мин аны кулга алачакмын. Янымда гына булсын... Утырта гына күрмәсеннәр!

Нуриасма бу сүзләрнең ихлас күңелдән әйтелүенә шикләнмәде, тик алар чынбарлыктан ерак торучы, тормышка ашмас изге ният кенә иделәр. Шуңа күрә ул ни уйлаганын яшермәде:

— Күңеленә авыр алма, Хәдичә, хәзер Гарифҗанны тәрбияләргә синең генә көчең җитми инде...

Моны ишетүгә Хәдичә дөртләп кабынды:

— Ә тегендә... тәрбияләнерме?! Аннан төзәлеп кайткан кеше бармы?! Юк! Авылда калса гына, кеше булачак ул.— Хәдичә бераз тынып торды да кинәт җанланып сөйли башлады: — Тәрбиялик бергәләп! Әйдәгез, ярдәм итегез! Мин синнән бер генә нәрсә үтенәм!

— Нәрсә? — диде Нуриасма сүзнең бөтенләй көтелмәгән эзгә кереп баруына гаҗәпсенеп.

— Гарифҗанны порукага алырга кирәк! Хөснуллин да әйтә...

Нуриасма сүзсез калды.

— Ник дәшмисең? Яхшылык телим дисең бит. Мизхәт белән син башласаң... Калганнар күтәреп алыр.
Нуриасма «юк» дигән мәгънәдә баш чайкады.
— Син теләмисеңмени? — диде Хәдичә.
— Минем намусым бирәү генә...
— Синнән намус сораган кеше юк.
— Кыстама юкка...
— Харап икән! — диде Хәдичә тавышына мыскыллау билгеләре чыгарып. — Син теләмәсәң, Мизхәт ярдәмен кызганмас. Дуслык өчен ул янган утка керергә әзер.
— Минем малай өчен син җавап бирмә әле яме, Хәдичә! — диде Нуриасма кискен итеп. — Янган утка керүенә сүзем юк. Әмма ялган утына кертмәм!
— Менә, менә, качасың, аны да, үзеңне дә читтә калдырмакчы буласың! Башкаларның ник шунда муены сынмый. Электән үк шулай булдың син.
— Алайса һәммәсенә мин сәбәпче, мин гаепле икәнмен!
— Гаепле шул! — диде Хәдичә Ык буен яңгыратып. — Ник син шул көнне читтән карап тордың, ә? Ник Гарифҗанны туктатмадың?! Ул бит сине тыңлый иде. Ә Хөснуллинны? Ярый, минем малай исерек — авыз ачар рәт юк иде. Ә син бит Хөснуллинны да уеннан кайтара ала идең. Әллә шулай түгелме?
— Әйе, гаепле... — диде Нуриасма авыр сулап.
Хәдичә аның нәкъ авырткан җиренә китереп басты. Шул көнге йомшаклыгы өчен ул үзен күпме битәрләмәде, әле тагын күпме битәрләмәс, тик үткәнне, башыңны ташка орсаң да, кире кайтара торган түгел шул! Ул чакта Нуриасманың бөтен уе Мизхәттә булды, аның өчен курыкты, ул да эчә-нитә күрмәсен дип тәшвишләнде, улы үз эшенә китеп баргач та, гел аны уйлады, бүтән барлык нәрсәләр төссезләнеп читтә калдылар.
— Син бәла-каза килүен теләдең, андый нәрсәләрне синең йөрәгең алдан сизә, шуңа күрә читтән карап калдың! — диде Хәдичә калтыравыклы куркыныч тавыш белән. — Безгә аяк чалырга җай чыкканны көтеп кенә торасың. Син гомер буе бер нәрсәне кичермәдең.
— Нәрсәне?! — диде Нуриасма берни аңламыйча.
— Син аны яхшы беләсең.
— Табышмак белән сөйләмә. Ачыктан-ачык әйт, — диде Нуриасма, йөрәгендә нииндидер авыр сизенү уяна башлавын тоеп.
— Ул сиңа бик якын кеше белән бәйле...
— Кем белән? — дип сорады Нуриасма аның җавап бирүен теләмичә.
Хәзер инде ул аның Сәгыйдулланы күздә тотуын аңлаган һәм иренең исемен аның авызыннан ишетәсе килми иде.
— Үзең беләсең, — диде Хәдичә һаман әйтеп бетермичә. — Шуңа күрә Гарифҗанны батырырга телисең дә!
Үткәннәрне телгә алуданмы, Нуриасманың һаман тыныч калуына түзә алмауданмы, Хәдичә тагын елап җибәрде һәм:
— Каргышым төшсен, йорт-җирең, мал-мөлкәтең утка очсын! — дип кычкырды.
Аның зәһәр карашы Нуриасманы хәнҗәр кебек айкап-айкап үтте. Хәдичә ашыга-ашыга басмадан чыккач, тагын артына борылды.
— Сиңа бездән дә зуррак каза килсен! — диде ул һәм аяк астыннан таш алып суга томырды.
Таш басмадан ерак түгел, Нуриасманың шәүләсе өстенә килеп төште. Шәүлә әллә ничәгә өзгәләнде, аның тамчылары Нуриасманың аякларына чәчрәде. Кинәт чатнап башы авыртып китте һәм ул маңгаен тотты. Дерелдәгән керфекләре арасыннан алъяпкычының уң як атламасы иңбашыннан салынып беләгенә төшкән Хәдичәне күрде. Ул сыңар канаты сынган кошны хәтерләтеп ярдан менеп бара иде.

Нуриасма аяк-кулларының хәлсезләнүен сизде. «Нәрсә булды инде бу? — дип уйлап куйды ул күнелсез генә.— Кайтырга, бераз ял итеп алырга кирәк». Ул басмадан чыкты да акрын гына ярдан күтәрелергә кереште. Менеп житә язгач, тыны бетеп, хәл алырга туктады. Шунда кулына бер бал корты килеп кунды. Нуриасма аның чагуын көтте, ләкин корт чакмады.

— Син мине ят итмисең бугай? — диде Нуриасма бармагы белән аның канатына кагылып.— Һәм башкалар кебек чакмыйсың да. Хәер, син чаксаң да тәнгә сихәт кенә... Ә менә бәндә чакса, түз генә... Корт Нуриасманың кулыннан җиңелә күчте, зәңгәр чәчәкләр өстеннән бераз барды да очып китте.

Кинәт Нуриасма үзен бик тә, бик тә ялгыз хис итте. Әйтерсең лә ул берүзе Хәдичәләр яши торган тормышның аргы ягында йөри һәм аларча яшәмәгәнгә гаепле иде. Аның эш-гамәлләре алар өчен аңлаешсыз, әшәке булып күренәләр, ул берүзе, алар бөтенесе бергә иде. Хәдичәләр аңа гомергә бәддога укыдылар, аны гаепләделәр, ә ул гаепләүләрне күпме генә тырышса да юкка чыгара алмады. Гаепсездән гаепле булып болай яшәү коточкыч газаплы, йөрәкне туктаусыз телгәли иде. Башкалар кебек тыныч кына рәхәтләнеп яшәмәве өчен ул гомере буе үзен-үзе ашады, ләкин үзгәрә алмады. Мизхәтне артык чикләве, әз генә ялгышы өчен дә каты бәрелүләре өчен Нуриасма үзен каргады, бетереп ташлады, кайнар күз яшьләре түгеп, яшерен генә елады, иртәгәдән бөтенләй башкача яшәргә ант итте, әмма чабыш аты сабантуй мәйданына томырылып атылган шикелле, тагын элеккечә йончыткыч тормыш эзенә ярсып килеп керде... Шуның белән бер үк вакытта, күпме генә газапланса да, ул, елаганда көлеп җибәргән бала кебек, шатлыкка охшаш ниндидер бер тойгы да кичерә иде. Ул тойгы — Нуриасманың үзен газаплауларының, Мизхәткә һәм башкаларга китергән кыенлыкларының юкка түгеллеген, изге вә бөек нәрсә хакына икәнлеген белүдән туа иде. Аны кемнәр генә нинди генә хурлыклы сүзләр белән тамгаласалар да, кемнәр генә нинди генә ачулы күз карашлары белән чәнчесәләр дә, Нуриасма үзенең алар өчен буй җитмәс биеклектә торуын аңлады. Бу — аның күптәннән төзегән сафлык дөньясы, аңа ул үзе генә патша, күпме генә, ничек кенә һөҗүм итмәсеннәр, бу патшалыкка беркемнең дә теле дә, кулы да зарар сала алмаячак иде. Газаплы гомер юлында Нуриасманың кыл өстендә калгандай хәтәр һәм хәвефле хәлгә төшкән чаклары бик күп булды, әмма әлеге дөньяның күренмәс җепләре аны як-якка авудан, әшәкелек упкынына егылудан саклап калдылар...

Менә ул кайтып житте, өенә керде, караватка ятарга барганда борылып көзгегә карады һәм чак кына егылып китмәде: көзгедә аның йөзе урынында ап-ак таш иде! «Әллә мин үлгәнменме?» — дип уйлап куйды ул. Йөзенең болай таш төсенә кергәнен баркайчан да күргәне булмады Нуриасманың. Тәненә тир бәреп чыкты, ләкин йөзе коры һәм салкын иде. Ул бер йомры су алып эчте дә, мендәр салып, караватка ятты.

## 14

...Нуриасма Ык буеннан кайтып яту белән йокыга киткән иде. Күпме йоклагандыр — аңысын хәтерләми, ул күкрәге коточкыч авыртуга уянды. Терсәгенә таянып тормакчы булды, әмма гәүдәсен кыймылдата алмады. Өй эчен күзе белән йөгереп чыкты, тыңлады — әле Фәритләр әрәмәдән кайтмаганнар, сәгать унбер тулып килә, кайтуларына аш пешерергә бик вакыт иде. Ул тагын бер талпынып карады, тик күкрәге шундый чәнчеште, әллә ни калдәр тын да ала алмый ятты. Ул шунда гына тора алмаячагын аңлады. Авызы тәмсезләнеп кипкән, теле аңкавына ябышкан, ләкин су ерак иде. Тәрәзә каршындагы юкәнең шаулавы аны гаҗәпләнә-

дерде. «Кай арада җил чыккан соң әле?— дип уйлап куйды ул.— Әллә өйгә үк керә инде?» Нуриасма өстендәге одеалын җайлабрак япты. Ул туктаусыз хәрәкәтләнүче юкә ботакларын, яфракларын әле тәрәзә аша күзәтте, әле аларның идәнгә төшкән шәүләләренә озаклап карап торды. Идәндә гүя шайтан туе бара иде; челтәр-челтәр кара шәүләләр бер җыерылып килә, бер тарала, бер уңга авыша, бер сулга тайпыла, бер тынып, бөтенләй хәрәкәтсез диярлек кала... Нуриасма күкрәгендәге авыртуның да шул шәүләләр белән бергә әле ут кебек бер урынга кысылуын, әле кулларга, аякларга ук таралып сулкылдавын тойды. Йөрәк авыртамы, әллә бөтен гәүдәме — инде аерырлык түгел иде. Ул кулын күлмәк изүеннән эчкә тыгарга теләде — кулы ике сәдәф арасыннан сыймады, берсен көч-хәл белән ычкындырды, шуңа кулының хәле бетеп, салынып төште. «Алай,— дип уйлады Нурисма,— шулай бик тиз бөгәр микәнни?» Йөрәге бик нык авыртса да, дару эчә-эчә ике көн әйбәт кенә йөргән иде бит. Әллә балалары кайткач иркәләнүе генә микән? Бераз ял иттергәч, кулын изүеннән кертеп күкрәге өстенә салды һәм сискәнеп китте. Әйтерсең лә үлем аны салкын бармаклары белән капшап, өшеткеч сулышын өреп узды: чөнки кулы боз кебек иде! Ул бу халәтенә карышып тагын бер мәртәбә кузгалмакчы булды — күкрәгендә нәрсәдер чатнап сынды, күз алды караңгыланды һәм ул каядыр еракка төпсез караңгылыкка очты...

Аңына килгәндә, килене анның маңгаена, яңакларына сулы чүпрәк тигерә иде. Су, дарулар эчергәч, бераз хәл керде. Менә хәзер уколлар кадагач, авыртуы да кимегәндәй булды. Инде больница машинасының кузгалып киткәне ишетелгәнгә шактый вакыт үтте, ә Фәрит белән Нәсимә һаман өйгә кермиләр. Бернинди хәрәкәт юк. Нишләп? Бары тик юкә генә җилдә шаулый, аның кара шәүләләре генә сап-сары идәндә әле бер якка, әле икенче якка җыерылып киләләр. Алар Нуриасмага нишләптер бик шомлы күренделәр һәм ул күзләрен йомды. Ләкин челтәр-челтәр булып уйнаучы ул шәүләләр күз алдыннан барыбер китмәделәр. Фәритләрнең аяк тавышын ишетүгә ул шатланып керфекләрен ачты һәм улының борчулы йөзен, килененең елаудан кызарган күзләрен күрде. Шунда әллә ни булды: ул барысын да аңлады, икеләнерлек нәрсә калмады. Югыйсә, үзенең кабат тора алмаячагын врач килгәнче үк сизенгән иде инде ул. Шулай да күңеленең әллә кайдагы тирән һәм яшерен почмагында кечкенә генә өмет чаткысы сүнәр-сүнмәс пыскып торды. Менә хәзер шул чаткы леп итте дә сүнде... Анның әче төтене сулыш юлларына кереп тынны буды, күзләрне дымландырды.

Фәрит әнисенең одеалыннан чыгып торучы аягын әйбәтләп ябып куйды.

— Рәхмәт, улым, җылы булып китте,— диде Нуриасма берни тоймаса да. Аннары янә:— Улым...— диде һәм туктап калды.

Анның балалары йөрәгенә яра саласы килмәде, тик моны әйтмичә ярамый, алай гына да түгел, мөмкин кадәр тизрәк әйтергә кирәк иде.

— Әллә берәр нәрсә кирәкме, әнкәй?— диде Фәрит.

— Улым... Шәрифҗан белән Илсөяргә телеграмма сук...— Мин исән чакта кайтып житсеннәр...

— Юкны сөйләмә әле, әнкәй,— диде Фәрит.— Больницага да алып китмәделәр бит...

Фәрит бу сүзләрне ниндидер ышанычсыз тавыш белән әйтүен үзе үк сизде. Әнисен алдап булмаячагын ул яхшы аңлый иде.

— Үз хәлемне үзем беләм,— диде Нуриасма. Анның йөзе дә, күзләре дә тыныч иде.— Миннән генә кала торган түгел...

— Әнкәй!..

— Үзеңне нык тот, улым. Иң өлкәне — син.

Нәсимә тавышсыз гына еларга кереште.

— Килен, син дә,— диде Нуриасма акрын гына.— Кифая бик куркак. Аңа шалтырат кына... Җайлабрак әйтерсең үзең...

Шулчак Марат килеп керде, йөгереп килеп әбисен кочаклап алды. Нуриасма аның әле кибеп тә бетмәгән чәчләрен сыпырды, иңбашларыннан сөйде. Оныгыннан тәмле булып Ык суы, балык, ләм исе килә иде.

— Чү, әбиеңне борчыма,— дип Нәсимә аны читкә тартты.

— Мин Нуичама әбине яратам!— диде Марат әнисенә карышып.— Әби, әйдә тавыклага жим чалыйк!

Марат әбисен кулыннан тотып торгызмакчы булды.

— И бәбекәчләем, әз генә авырып киттем бит әле.— Нуриасма аның башын сыйпады.— Син үзең генә жим болгатып бир инде...

Марат олыларча жил-жил атлап чыгып китте. Нәсимә улы өчен сөенеп куйды, чөнки ул кайдан нәрсә салырга, ничек, күпме болгатырга — берсен дә белми иде.

— Килен, Маратка кар базыннан катык алып чыгып бир, хәзәр катык ашый ул,— диде Нуриасма.

— Әни, аны жылытыргадыр бит?

— Кирәкми, кирәкми! Шул килеш. Суган, укроп турый да ашый. Үзе белә ул. Ипи кисеп куярсың.

Нәсимә чыгып киткәч, Фәрит бер урындыкны әнисе караваты янынарак алып килеп утырды, аның одеялларын төзәткәләп куйды. Авыру кеше ни әйтмәс, бөтенесен белергә врач та алла түгел, әнисе сәламәтләнеп китәр дә, тормыш элекке эзенә төшәр кебек тоелды аңа.

— Улым, бар, телеграмма сук...

Әнисе бу сүзләрне әйткәндә башын аңа таба бормады, карашын түшәмгә төбәгән килеш керфеген дә селкетмәде.

— Әни, үткече чир генә бу...— Фәритнең аркасына тир бәреп чыкты, дөреслекне әнисеннән дә, үзеннән дә яшерергә азапланы шулкадәр кыен иде.— Аягыңа басасың әле син...

— Рәхмәт, улым, изге ниятгә торуыңа... Әнкәй бик каты чирли дип сук.— Нуриасма карашын Фәриткә күчерде. Аның күзләренә мөлдерәмә булып ялвару, үтенү тулган иде.— Бик күрәсем килә... Бар, зинһар... Үкенечле булмасын...

Фәрит дәшмәде, авыр итеп бер сулады да акрын гына чыгып китте. «Үкенечле булмасын!.. Үкенечле булмасын!..» Йомшак кына әйтелгән бу сүзләрнең коточкыч мәгънәсе аның йөрәген сулкылдатты, башын кыршау белән кыскандай авырттырды. Нишләсәң дә, әнисе хаклы, бүтән чара юк иде. Ул, почтага барып, Шәрифҗаннарга, Илсөярләргә «Әнигә инфаркт булды, хәле авыр» дип телеграмма бирде. Чаллыга шылтыратып, әнисенең сеңлесе — Кифая апасы белән сөйләште.

Фәрит почтада чакта Мизхәт кайтып туктады. Әнисенең авырып китүен ул әле белми, район үзәгендә тикшерүче янында булуы турында әйтим дип кенә кергән иде. Чиләк белән су түгәргә чыккан җиңгәчәсе җиткергән борчулы хәбәрне тыңлап та бетермәстән, йөгереп өйгә керде.

— Әнкәй, хәлең ничек?

— Әйбәт, улым,— диде Нуриасма һәм сизелер-сизелмәс баш селкеп куйды.

Мизхәт «Әллә берәр нәрсәгә борчылган идеңме?» дип сорарга уйлады да телен тешләп дәшмичә калды. Борчуларның житәрлек булуын һәм аларга үзенең дә сәбәпче икәнлеген ул белә иде ләбаса.

— Төшлегеңне ашадыңмы?— диде әнисе.

— Басуда ашадык.

— Нишләп кайтасы иттең соң?

— Мин тикшерүчегә кердем...— Мизхәт карашын әнисеннән яшерде.— Барысын да, ничек булган, шулай яздым...

Нуриасманың йөзеннән якты нур йөгереп үтте.

— Әйбәт булган, улым. Бар инде, эшеңә соңарма...

Чыгарга кузгалгач, Мизхәт әнисенең зәгыйфь кенә эндәшүен ишетте:

— Улым... бүген иртәрәк кайтырга тырыш әле...

Мизхәтнең әнисенә ниндидер яхшылык эшлисе килүдән, аның хәлен җиңеләйтә алмаудан гаҗиз күңеле сыкрап куйды. Ул ашыгып кабат аның янына килде.

— Әллә берәр эш бармы, әнкәй? — диде ул җанланып.

— Сөйләшәсе әйбер бар, улым.

— Ә хәзер?

— Хәзер генә булмый, — диде әнисе, ничектер сүзләренә тирән мәгънә салып. — Зур әйбер ул. Бар, улым, кичтән абыеңнар белән бергәләп сөйләшербез...

— Ярый алайса... — диде Мизхәт, ә үзенең күңелендә шундук мең төрле сорау туды.

Әнисе шулай ди икән, — бу инде юкка түгел. Ул өйдән бөтен гәүдәсендә таш баскандай авырлык тойган хәлдә чыкты. Әйтерсең лә әнисенең авыруы аңа күчте. Мизхәт бер утка, бер суга төшеп машинасына утырды һәм басуга юл алды...

Ул кайтканчы Нуриасманың вакыты бик күп иде әле. Шулай да врач нәрсә диде икән? — дип уйлады ул. Ничә көн? Моны белү үтә дә мөһим иде аңа. Бәлкем, көн дә узмас? Юк, алай булса, больницага алып китәбез димәсләр иде. Аңа әле берәр атна гомере бардыр кебек тоела. Йөрәк шулай сиздерә. Нуриасма кичкә кадәр уй диңгезендә йөзде дә йөзде. Аны хәзер беркем дә бүлдерми, аның берни турында да кайгыртасы, бернинди мәшәкате юк иде. Нинди генә уйлар уйласа да, бер сәер хәлне сизеп гаҗәпләнде: ул әле генә яшәп яткан тормышны һәм үзен ничектер читтән, бик ерактан күзәтә, үзенең һәм башкаларның гамәлләренә әллә кайдан ук торып бәя куя иде. Нуриасма үз-үзеннән аерылган икенче кеше кебек үзенең үзеннән һаман ераклашып баруына хәйран калды. Бу әлегә берничек тә аңлатып булмый торган сәер халәт иде...

И гомеркәйләр! — дип уйлады ул. Бәндәләрнең яшәүләре таң җиле генә шул. Бик кыска гына арада, табигатьнең уяныр-уянмас серле, моңлы чагында исә дә үтә. Чәчәкләрне, үләннәрне, агачларны, су өсләрен әз генә тибрәндерә, тере җан ияләренә кагылып, сафлык өрә, татлы йокыларыннан уятырга тели, яшәргә чакыра... Кеше гомере дә шул җил кебек тормыш күгеннән сизелмичә исә дә үтә. Бу шулкадәр дә татлы, шулкадәр дә кыска һәм аны берничек тә яңадан кабатлау, аңа кире кайтмак юк иде. Эчәр суың эчелгән, җыяр ризыгың җыелган, суласы һаваң суланып беткән. Син башка җан ияләре, башка кешеләр кебек түгел, син алар арасыннан, бу якты дөньядан инде кысрыклап чыгарылгансың, менә шушы тар караватта вакытлыча гына урын билисең. Ә әйләнә-тирәңдә тормыш элеккечә үк кайнап тора. Әнә юкә җилдә җилфердәп утыра, кошлар чыр-чу килә. Бөтенесе хәрәкәттә, һәр тереклек иясе кояштан яктылык һәм җылылык, җирдән туклык ала, зәңгәр күк астында үз урынын даулый. Кеше каядыр кабалана, каударлана, борчыла, талашасугыша нидер эшли һәм шушыларның бәхет икәнен юньләп тоймый да кала. Йөрәкнең һәр тибеше, һәр сулыш, һәр күз карашы, һәр сүз, һәр хәрәкәт, ишетелгән һәр тавыш үзе бәхет. Әгәр кешеләр шушыны аңласалар, гомер буе елмаеп-көлеп, куанышып кына яшәрләр иде. Җир йөзендә бер генә кеше дә мәңгегә кала алмаган һәм калмаячак, тугансың икән, үлү дә котылгысыз. Әмма шушы хакыйкатьне йөрәк барыбер кабул итәргә теләми. Дөньядан китәсеңне кисәтсә дә, үзе үк шуңа каршы. Хәер, аны гаепләп булмыйдыр. Туфракка нык ләп тамыр җибәргән үсемлек тә ансат кына йолкынмый. Йөрәкнең дә меңнәрчә тамыры дөньяга тоташкан бит. Йөрәкнең үзеннән үк килүче иң зур ике тамырының очы күзләр, аннары ике колак, авыз-борын, аяк-куллар. Тәндәге һәр күзәнәк — йөрәкнең вак тамырларының очы. Әнә шул тамырларның очлары кояш, йолдызлы күк, җир-су, һава кебек җисемнәр белән, үләннәр-чәчәкләр, агачлар-яфраклар белән, бөҗәкләр, кош-кортлар, җәнлекләр, барлык кешеләр белән тоташкан. Әнә шул тамырлар тәм-томнарны, искосларны, тавыш-моңнарны үзләренә алганнар, ерак үткәннәргә, бүгенгә

һәм иртәгегә китеп берекәннәр... Ул тамырлар буйлап дөньяның җем-җем итеп торучы барлык ямьнәре җылы нур булып йөрәккә киләләр һәм йөрәктән яшәү дәрте, сөю-сөелү ләззәте рәвешендә чыгып, кабат дөньяга кайтып керәләр... Гомер буе дөньядан йөрәккә, йөрәктән дөньяга хәят җылысы йөрткән бу тамырларны өзү, ай-һай, кыен шул. Туган җиреңдә нинди генә мәрхүмлекләр, җәберләр кичерсә дә, бәндәнең аны һаман сагынуы, җирсүе дә юкка түгел. Дөньяның бөтен сурәте, һәммәсе канда, йөрәктә...

— Исәнме, Нуриасмакаем!

Ул йомшак кына итеп эндәшкән тавышка күзләрен ачты. Каршысында Гыйзлениса бысып торуын күргәч, елмаеп җибәрде. Әллә йокымсырап китеп, әллә уйларына бирелеп, аның керүен сизми дә калган иде.

— Әйдә, уз, Гыйзлenисатти...

— Әле урамнан үтеп барышлый киленең әйтте дә, хәлеңне белеп чыгыйм дидем. Адәм баласын аллаһе тәгалә чирле торган итеп яраткан шул. Чир килә дә, китә дә...

Гыйзлениса көйле-көйле сөйләде, Нуриасманың хәлләрен сораштырды, авылдагы яңалыкларны җиткерде. Хәле җиңеләеп киткән шикелле тоелды Нуриасмага. Гыйзлениsattидә кешене тынычландыра торган ниндидер көч бар иде, ахрысы. Алар, чордашлары, кыен вакытларда бергәләп тә, аерым-аерым да Гыйзлениsaга баралар, күңелләрен бушатып, шуның яныннан җаннарына тынычлык табып кайталар иде. Ул кыйшаеп беткән өйдә инде ничәмә-ничә еллар ялгызы яши. Карты да, малае Рәхмәтулла да сугыш кырында ятып калган. Гыйзлениса өчен әйтерсең лә алар үлмәгән, ул алар белән аралаша, сөйләшә, алар белән яши. Аның вак җыерчыклар белән капланган ябык чыраенда беркайчан да борчылу-кайгыру галәмәтләре күрә алмыйсың, еласа да елавы ничектер кояшлы яңгыр кебек үтә, тиз-тиз күз яшен сөртә дә йә җырлап җибәрә, йә мөнәҗәт әйтергә керешә. Ул акны — ак, караны кара ди, юк нәрсә белән сине юатып маташмый. Аның кулыннан гомер буе эш төшмәде, йә ул кешеләргә бәйләм бәйли, йә әйбер тегә, йә йон эрли, йә башка шөгыль таба. Үзе сөйләп тора, кулы эшләп тора, чулпылары чылтырап ала, әйтерсең лә ул түгел, аның орчыгын тормыш агымы үзе әйләндерә, әйтерсең лә ул сизгер куллары белән йон җепләре түгел, ә бәлки тормышның тамырларын бияләй, оекбаш рәвешендә кешеләр йөрәгенә тоташтыра иде. Ул эшләре өчен гомерендә беркемнән дә бер тиен акча алмады, үзенә исә әз генә ярдәм иткән кешегә дә бурычлы булып калмау әмәлен тапты. Авылда икс абыстай булса да, халык күбесенчә аңа дәште. Гыйзлениса өйләнешүчеләрне никахлады, туганнарына исем кушты, үлгәннәрен җирләште, өчесен, җидесен, кырыгын, елын үткәреште.

Нуриасма аның шикәрдәй ак күлмәгенә, ап-ак яулыгына, бернинди яшерен очкынсыз, һәрвакыт ышаныч белән караучы күзләренә ятып төбәлде, күңеленә талгынлык җәелде. Ул аның Нәсимәгә өстәл әзерләшүен, яшьләрчә җәһәт-җәһәт атлап алгы якган бу якка чәй ташуын, ниһаять, өстәл янына утыруын түземсезлек белән көтте. Анда да Гыйзлениса үзенең чәенә үрелмәде, Нәсимә кулыннан алып, иң элек Нуриасмага чәй эчерде, шуннан соң гына урындыгына утырды, Донецкида ничек яшәүләрен сорашты рды. «Юып куйган ак йон җебем бар, бүген үк Фәрит белән Нәсимәгә оекбаш бәйли башлыйм»,— диде. Киленс өстәлне җыештырып алганны гына көтте дә Нуриасма:

— Минем басуны да урыр чак җитте бугай, Гыйзлениsatти,— диде.— Мәрхәмәтеңнән ташламассың инде... Тәнем башка кеше кагылганга чирканыр. Ә син әнкәй кебек... Әйбәтләп юып озатырсың...

— Гел яныңда булырмын, Нуриасмакаем, гомергә бергә яшәп...— Ул салкынча кулын Нуриасманың маңгаена куйды.— Төшемә кермәдең әле яшисең. Ә калганына кояләнмә. Берәүләр тамаклары кипкән саен чүмечләп су эчәләр, барыбер сусаулары бетми, икенче берәүләр бер

стакан су белән кибегүләрен басалар. Яшәү дә шулай. Кемнәрдер сабый чакта ук кояшны, җирне, күкне күрәләр дә, шуны карар өчен генә карын ерып чыккан кебек, гөнаһсыз-нисез, теге дөньяга китеп баралар: икенче берәүләрнең минем Рәхмәтуллам кебек күкрәп торган яшьлек дәверендә сулышлары өзелә. Өченче берәүләр бу фани дөньядан тәмам туйсалар да китә алмыйча интегеп яталар... Ходай күпме гомер биргән — һәркем шуны яши. Әмма ләкин ул кыскамы, озынмы — тәмен, кадерен белеп яшәргә кирәк. Бәндәләрнең гомерләре миһербансызлык, ызгыш-талаш белән дә уза, бер-берләренә изгелек кылып, игелеклелек белән дә үтә. Синеке, аллага шөкер, үкенерлек түгел, Нуриасмакаем. Тормышың күктәге кояш төсле халыкның күз алдында...

Үлем турында сөйләсә дә, Гыйзденисаны тыңлавы рәхәт иде. Аның сөйләвендә чишмәнең мәңгелек челтерәве төсле тынычландыргыч моң, бернинди бизәкләргә төрелмәгән гадилек, сафлык, ачыклык бар иде... Тормыш белән үлем, төш белән өн аның өчен үзара тыгыз бәйләнештә торучы, күп очракта хәтта аерылгысыз әйберләр, яшәешнең нindидер бер серле мизгелендә без белмәгән гайре тәэсирендә бер-берсенә әвереләләр иде. Гыйзденисa үзенең якыннарын, авыл кешеләрен гомер буе төштә күрде, аның күп кенә төшләре теге яки бу хәл турында хәбәр салулары белән бөтен авылны хәйран калдырдылар. Сугыш вакытында Гыйзденисa Рәхмәтулласының авыл башындагы басудагы каеннар арасына йөгереп кереп китүен төшендә күрә һәм урамга үкереп елап чыга:

— Рәхмәтуллам хараплар булды бит! — дип елый.

— Ни сөйлисең? — диләр аңа.

— Әлеге каеннар арасына кергән кеше исән чыкмый, — ди ул.

Бер ай дигәндә, Рәхмәтулланың «үлде» хәбәре килде. Авыл халкы төшнең рас килүенә түгел, ә Рәхмәтулланың нәкъ әнисенең төшенә кергән көнне үлгән булуына таң кала... Гыйзденисa күргән төшләрнең исәбесаны, очы-кырые юк. Менә хәзер дә ул:

— И Нуриасмакаем, теге атнада Рәхмәтулламны күрдем бит әле, — дип көйләп-көйләп сөйли башлады. — Иртән чәй эчеп утырам икән дим, күзем төшеп карасам, тәрәзә турыннан берәү үтеп китте, бик таныш төсле тоелса да, йөзен абайлый алмадым, шулай да нидер сизенеп йөрәгем сикерә башлады. Шулчак ишек ачылып китеп, Рәхмәтуллам килеп кермәсенме, Нуриасмакаем! Күрешәсем килә — урынымнан тора алмыйм. «Улым», — дип эндәшмәкче булам — телем әйләнми. Үзе гел сугышка киткән чактагы киемнәреннән — ак күлмәк, көрән җилән, башында киез эшләпә. Керү белән эшләпәсен ишекнең уң ягындагы агач чөйгә элде дә:

— И әнкәй, тамагым бик кипте, чәй яса әле, — ди.

Куян каны төсле итеп чәй ясадым да алдына куйдым. Бәбкәччәем, үрелим генә дигән иде, ат кешнәгән тавыш ишетелде.

— И әнкәй, булмады инде, мине алырга килделәр, — диде дә эшләпәсен дә кимичә чыгып йөгерде. Артыннан чыгыйм гына дигәндә уянып киттем. Туйганчы еладым, Нуриасмакаем, мендәрләрем чыланып бетте. Хәзер теге чәйне дә барам да карыйм, барам да карыйм, эшләпәсе гел шунда эленеп торадыр шикелле... Бер атна инде Рәхмәтулламның җырын җырлап йөрим. Авылдан чыгып киткәндә ул болай дип җырлады:

Ике аккош очып бара,
Агыйделдә кышлавы;
Җан бирүдән яман икән
Туган илне ташлавы.

И, гомерләр диген, Нуриасмакаем! Уйлап карасаң, кемнәр бар иде дә кемнәр юк! Картым белән Рәхмәтулламның сөякләре икесе ике кыйтгада яталар. Рәхмәтуллам бит япон сугышында иде. Исемнәрен дә,

каберләрен дә белүче юк. Без бит бәхетле, Нуриасмакаем, безне үзебезнең авылга җирлиләр, ата-бабаларыбыз белән янәшә...

Нуриасма Гыйздениса сөйләгәннәрне рәхәтләнеп тыңлады, ул чыгып киткәч тә, аның тавышы колак төбендә мөнәҗәт кебек яңгырап торды, күңеленә сафлык бирде.

## 15

Кич Мизхәт мең сорау эчендә кайтып керде. Нәсимә белән Марат мал-туар карап йөриләр, абыйсы болдыр баскычында утыра иде.

— Әнинең хәле ничек?

— Әлегә бер килеш. Ул сине сорый да сине сорый, «Әле һаман кайтмадымыни?» — ди.

Шулчак йөгереп Марат килеп җитте, Мизхәт аны гадәттәгечә килешле үк биленнән күтәреп алды, кинәт чайкалдырып башы белән җиргә таба төшерде, тагын күтәрде, тагын төшерде. Марат рәхәтләнеп көлде дә көлде. Мизхәт абыйсы магнит кисәге биргәч, Маратның башы күккә тиде.

— Әйдә, керик,— диде Фәрит.

— Кайттыңмы, улым,— дип эндәште Нуриасма, Мизхәтне ишектә күрү белән.

Мизхәт җавап бирергә дә өлгерә алмады, Марат бөтен өйне тутырып кычкырып җибәрде:

— Әби, әби, Миҗхәт абый миңа магнит алып кайткан!

Ул магнит кисәген әбисе яткан караван тимерләренә чык-чык ябыштырып-ябыштырып күрсәтте. Нуриасма аны елмаеп күзәтте.

Маратның чыгып йөгерүен елмаеп карап калдылар һәм өчесе дә шундук җитдиләнделәр.

— Утырыгыз әле, балалар...

Фәрит белән Мизхәт урындык алып әниләре каршына утырдылар. Тик ул сүз башларга ашыкмады.

— Әнкәй, хәлең бераз әйбәтләнмиме? — диде Мизхәт аңа таба иелә төшеп.

— Әйбәтләнер, улым, әйбәтләнер...

Бу сүзләрне Нуриасма әллә ничек көйләп әйтте. Аннары, башын улларына таба борып, күзләрен туп-туры Мизхәткә төбәде. Мизхәт аның карашыннан ничектер куырылып куйды. Әнисенең күзләре аңа рәнҗиләр, син мине икс-өч көн эчендә чиргә сабыштырдың, дип әйтәләр төсле тоелды. Ул үзенең үпкә сүзләрен Фәрит абыйсы каршында җиткермәкче иде, ахрысы... Мизхәт моны күтәрергә, әнисеннән гафу үтенергә үзен ныклап әзерләде. Аны куркытканы бу түгел, башка әйбер иде. Ул армиядән кайткан елны бервакыт әнисе гел күрмәгәндә-уйламаганда үлем турында сүз кузгатты, каберне әтиегезнекеннән ерак казытмагыз, диде. Рәшәткәсен агачтан ясагыз, пар юкә утыртыгыз, диде. Мизхәт аны шуннан ары тыңлый алмады, яшьле күзләре белән әнисенә рәнҗеп карады, юк сүз сөйләмә әле, әни, дип, өйдән чыгып китте. Әнисе бу хакта тагын сүз кузгатмаса ярар иде, дип, әллә ни гомер куркып йөрде. Менә хәзер әнисенең аларны нәкъ шуның өчен чакырган булу ихтималы бар һәм бу коточкыч авыр сөйләшү булачак иде. Әмма әнисе кузгаткан әйбер ул гоманлаганнарга якын да килмәде, Мизхәтне телсез-өнсез итте.

— Улым, яшең дә шактый инде...— әниләре сүзен бүлеп торды.— Башлы-күзле булу хакында уйлап караганың бармы синең?

Мизхәтнең иреннәре сизелер-сизелмәс дерелдәп куйды, йөзенә кызыллык йөгерде. Абыйсы кулларын тез өстендә кушырган килеш иелебрәк утыра иде. Дөрес ишеттемме дигәндәй, ул да башын күтәрде, авызы яртылаш ачылып калды.

— Уйлаганым бар,— диде Мизхәт, карашын кая яшерергә белмичә.

Бу хакта сөйләшү аңарда элек-электән үк нindидер кыенсыну, оялу тойгысы уята иде.

— Кайчан?

— Нәрсә кайчан?

— Өйләнергә уйлавыңны әйтәм.

Көтелмәгәндә бирелгән әлеге сорау Мизхәтне каушатып җибәрде. Аның бу турыда Зөбәрҗәткә әле сүз катып караганы юк, ә үзенең көздән калмаска дигән уе бар иде.

— Әле Зөбәрҗәт белән сөйләшүен сөйләшмәгән дә...— Мизхәт бөтен тәненең кызышуын тойды.— Быел көзләрдән калмаска иде... Әгәр син риза булсаң...

Әниләре аның сүзен әйтеп бетерер-бетермәс бүлде:

— Мин риза түгел! Риза түгел! — диде ул ашыга-ашыга.

Мизхәт белән Фәрит сүз берләшкәндәй бер-берсенә ялт итеп карадылар. Бу караштта «ни сөйли ул?» дигән мәгънә ята иде. Нуриасма моны сизми калмады.

— Мин синең өйләнүеңә дә, Зөбәрҗәткә дә каршы түгел,— диде ул аларны аптыраштан чыгармакчы булып. Тик барыбер дулкынлануын яшерә алмады.— Сиңа, улым, хәзер өйләнергә кирәк... Берничә көн эчендә...

Бу хәбәр аларны аптыраштан чыгару түгел, телсез калдырды. Ничек инде кинәттән генә? Ник? Җитмәсә үзе яшәү белән үлем арасында тартышып ятканда.

Фәрит дулкынланудан кипшенгән иреннәрен ялап алды.

— Әнкәй... ни бит...— ул тамак кырды.— Сиңа да аякка басарга кирәк бит әле...

Нуриасма олы улына күз чите белән генә ничектер кырыс итеп карап куйды.

— Минем өчен борчылмагыз... Берничә көннән терелэм мин...

Нуриасма бу сөйләшүгә көне буе әзерләнде, һәммәсен дә бизмәнгә салып кат-кат үлчәгән саен үкенеч һәм шатлык катыш бер ышанычы ныгыды: шушы берничә көн эчендә Мизхәтен башлы-күзле итеп калдыра алачак ул. Чөнки хәзер аның моны эшли алырлык үтә көчле коралы бар. Беркем дә каршы тора алмаслык ул көчле корал — аның әҗәленә тигән чире иде... Бер мәртәбә авызы пешкән кеше буларак, Нуриамса баласын өйләндерү кебек олы һәм четерекле йолада ашыктыру, көчләү кирәкмәгәнен, бу адымга баруы белән хаксыз икәнлеген дә аңлый. Әмма үз ихтыярын балаларына көчләп тагуы белән гөнаһлы булса да, кавем-кабилә тамырын саклау хакына ул моңа тәвәккәлләде һәм исән чакта беркем алдында да чигенмәячәк иде инде...

Мизхәтнең башы аска иелә барды. Әнисе әйткән сүзләрнең мәгънәсе аңа һаман да барып җитә алмый иде. Ничек инде ул авырып ятканда өйләнү турында сүз булуы мөмкин?! Бу бит бер киртәгә дә сыймый. Әниләренең аякка басам диюе дә бик сәер. Ул үзенең хәлен сизәргә тиеш. Һәрхәлдә, инфарктның нәрсә икәнен ул да, алар да яхшы аңлыйлар.

— Әнкәй, уттай урак өсте бит,— диде Мизхәт.— Син дә авырып торасың, әзерләнергә дә кирәк. Андый нәрсә кинәт кенә була алмый...

Кече малаеның сүзләренә Нуриасманың керфеге дә селкенмәде. Ул түшәмгә караган хәлдә кыймшанмыйча ята бирде. Менә аның иреннәре аз гына ачылып хәрәкәткә килделәр:

— Врач мине терелә алмас дидемени?

— Нишләп алай дисең, әнкәй? — Фәриткә кыен булып китте.

— Һаман минем чирләвемне китереп кыстырганга әйтәм...

— Соң, әнкәй, дөресе шулай түгелмени? — Ул җавап эзләп аңа карады, әмма әнисе башын читкә борды.— Син авырып ятканда... бу мөмкин эшмени?

Өйдә тынлык урнашты һәм ул шактый дәвам итте. Әниләренең күзләре еш-еш йомылды. Аның бик киеренке хәлдә, ниндидер олы нәрсәне хәл иткәндә күз кабаклары, керфекләре еш хәрәкәтләнә башлый. Ул кабат аларга карады, тик хәзер аның күзләре дымлы иделәр...

— Минем теләгем шундый, балакайларым!..— әниләренең тавышы нечектер ялварулы һәм кызганыч иде.— Әгәр минем сүземне тотсагыз, мәңге рәхмәт укырмын...— Ул тирән сулыш алды да өстәп куйды:— Тизрәк терелермен...

Менә хәзер генә Мизхәт әнисенең бу олы эшкә ашыктыруына төшенә башлады кебек. Димәк, аның өйләнүен ул үз күзләре белән күрергә тели, көзгә кадәр яши алмам дип курка.

— Син, Мизхәт улым,— диде Нуриасма балаларының хәвефле уйларын таратмакчы булып,— моннан да уңайлы вакытны таба алмыйсың. Фәрит абыеңнар монда. Хәрби кешене беләсең, Шәрифҗан абыең Ерак Көнчыгыштан икешәр мәртәбә кайтып йөри алмаячак. Илсөяр апаңнар да кайта. Яңадан болай җыелып булмаячак.

— Анысы дөрес инде, әнкәй,— дип аның сүзен җөпләде Фәрит.— Әзерләшергә дә кеше була. Җиләк-җимеш тә мул вакыт.

Нуриасма бу сүзләре өчен олы малаена сөеп карады да, балалары кире уйлаганчы, сүзне төгәлләргә булды:

— Син, улым, хәзер үк Зөбәрҗәт янына бар, сөйләшегез. Бөтенебез җыелабыз диген, аңлат... Дүрт-биш көндә хәл итәргә кирәк...

Фәрит белән Мизхәт урындыкларында һаман тораташ катып утыра бирделәр.

— Барыгыз, бар,— диде әниләре аларга эш кушкан чактагы кебек итеп.

Алар икесе дә акрын гына торып авыр сулап куйдылар, үпкәләгән балалардай, башларын игән килеш чыгып киттеләр.

Авыл өстенә караңгы төшеп килә, коры тузан, мал-туар, җылы сөт исе таралган. Тау башындагы ындыр табагында электр утлары балкый, ашлык эшкәртү машиналарының бер көйгә гүелдәве ишетелә. Мизхәт белән Фәрит сүзсез генә чыгып капка төбендәге утыргычка чүмәштеләр.

— Йә, ни әйтәсең, энекәш?— диде Фәрит тынлыкны бозып.

Мизхәт җавап бирергә ашыкмады, озак кына көттергәч:

— Ничек тә сузарга кирәк,— диде.

Абыйсы дөртләп кабынды:

— Әнине алдаргамы?!

— Нишләп алдарга? Шул арада әнинең хәле бераз әйбәтләнеп китмәсме...

— Әйбәтләнмәсә?..

— Юкны сөйләмә, абый!

— Ул хакта мин уйларга теләмим... Әнкәй бит синнән-миннән сизгеррәк. Аның ник ашыктырганын аңламыйсыңмыни?

— Аңлыйм да...

Сүз тагын өзелде. Алар икесе дә бер әйбер турында уйладылар. Уйлары шул кадәр тыгыз һәм авыр, анда сүзләргә бернинди урын юк иде. Ниһаять, Фәрит торып басты.

— Әнинең теләген аяк астына салып таптау ярамас, энекәш,— диде ул.— Вакытны бушка уткәрмик. Бар, сөйләш кәләшең белән. Әнкәйнең авырып ятуын хәзергә әйтмәскә дә буладыр.

— Ишеткәндер инде ул аны.

— Ишеткән булса, әнинең теләге шундый диярсең.

Мизхәт һаман кузгалмады.

— Халык ни дияр соң, абый?— диде ул башын һаман күтәрмичә.

— Без әнкәй турында уйларга тиеш,— диде Фәрит сер әйткәндәй бик акрын гына.— Халык аңламаган әйбернең булганы юк әле.

— Ярый алайса,— диде Мизхәт һәм мотоциклын кабызырга кереп китте...

* * *

Пионер лагерена унбиш минутта барып житте. Күңелен моңа кадәр таныш булмаган әллә нинди тойгылар биләде. Зөбәрҗәткә өйләнү турында ничә еллар хыялланды ул! Менә хәзер шатланырга кирәк иде дә бит, юк, шатланып булмый, күкрәк эчендә таш тутырып куйгандай авырлык кына. Бу хакта сүз башлау да, Зөбәрҗәтнең әлеге хәбәрне ничек кабул итәчәге дә куркыта.

Мизхәт мотоциклын лагерь коймасы буена куйды да чәер исе аңкытып утыручы шәмдәй төз наратлар арасыннан уңга таба китте. Шулчак каршысына дөп-дөп йөгереп килгән бер малай аңа бәреләә язып үтеп китте һәм:

— Зөбәрҗәт апа кинода! — дип кычкырды.

Карале син аларны, белмәгәннәре юк тишек борыннарның, дип көлемсерәп куйды Мизхәт һәм борылып әлеге малай артыннан китте. Ачык һавада кино күрсәткән урында балаларның бердәм көлешкәне ишетелә иде. Мизхәт тәрбиячеләр, вожатыйлар утыра торган арткы эскәмия турына килеп басты. Биредә бөтенесе дә табигый: ылыс, мәтрүшкә исләре, тирә-юньдәге биек абага яфраклары, күкне тулысынча диярлек каплап торучы нарат ябалдашлары арасыннан җемелдәгән сирәк-мирәк йолдызлар, аппараттан экранга таба сузылган зәңгәрсу яктылык эчендә чебен-черкиләрнең туктаусыз бөтерелүләре... Эскәмиядәгеләр Мизхәткә караштырып чышып-пышын килә башладылар, кайсыдыр чыркылдап көлеп куйды. Зөбәрҗәт башын иеп чыга башлады, аның бөдрә чәчләренең шәүләсе экранда күренеп алды. Алар үзләре йөри торган сукмактан текә үргә күтәрелә башладылар. Юан наратларның төпләренә үскән абагалар, вак куаклар аларның битләренә, кулларына, киемнәренә ышкылып калды.

— Әллә телеңне йоттыңмы? — диде Зөбәрҗәт.

Мизхәт айнып киткәндәй булды. Чыннан да, «исәнме»дән башка ул бер сүз дә әйтмәде ләбаса!

— Зөбәрҗәт, туктыйк әле, бигрәк матур сезнең монда,— диде Мизхәт.

— Туктыйк алайса...

Зөбәрҗәт аңа елмаеп карады. Каршыдан кып-кызыл шар булып ай күтәрелеп килә. Ул наратлар артыннан әйле-шәйле генә күренә... Салкынча, рәхәт, тыныч. Кошлар да сайраудан туктаган, сирәк-мирәк кенә чутылдауга охшаш тавышлар ишетелеп куя. Мизхәт ай ягына аркасы белән борылды да Зөбәрҗәткә карап тора башлады. Кызгылт караңгылыкта аның йөзе әллә нинди сихри нур белән өретелгән, искиткеч матур иде.

— Нигә шулкадәр текәлеп карыйсың? — диде Зөбәрҗәт.

Мизхәт дәшмәде.

— Ни булды сиңа? Әллә ничек сәер син бүген...

Элек очрашу белән Мизхәт, шаярган булып, аны йә кочаклап ала, йә күтәреп әйләндерә, йә үбә иде, үзе туктаусыз нидер сөйли иде.

— Ярый, Мизхәт, мин балаларым янына барыйм әле,— диде Зөбәрҗәт, тагын шактый вакыт сүзсез торгач, һәм китмәкче булып кузгалды.

Мизхәтнең тавышы үзенеке түгел иде. Зөбәрҗәт баскан урынында катып калды, ә Мизхәт кайнар кулларын биленә китереп салгач, сискәнеп үк китте. Ул аны шулкадәр каты итеп үзенең гәүдәсенә кысты, Зөбәрҗәткә хәтта тын алу кыенлашты.

— Мизхәт, син нәрсә...— дип пышылдады ул иреннәренең Мизхәтнең битенә терәлүен тоеп.— Җибәр, сөякләремне сындырасың...

Мизхәтнең тимердәй куллары аз гына бушанды, әмма Зөбәрҗәтне үзеннән ычкындырмадылар. Тып-тын урман эчендә кайнар пышылдашу авызлары гына ишетелде:

— Зөбәрҗәт...

— Әү...
— Зөбәрҗәт... беләсеңме нәрсә...
— Нәрсә?
— Беләсеңме... чык миңа кияүгә...
— Әллә синең әз генә шөрефләрең бушаган инде....
— Мин әйткәнне аңладыңмы син?
— Аңладым да...
— Өйләнешик. Шушы атнада...
Зөбәрҗәтнең нечкә тавышы урманны яңгыратып җибәрде:
— Кайчан?!
— Ник кычкырасың? Шушы атнада.
Зөбәрҗәт башын артка ташлап көлеп җибәрде.
— Син акылыңда түгелдерсең. Ни сөйләгәнеңне беләсеңме син?
— Ә нигә гаҗәпләндең? Башка планнарың бармыни?
— Юк та бит... Җибәр әле, кыен болай.
Мизхәт аны җиргә бастырды.
— Булмагач?
Зөбәрҗәтнең күңеленнән бер уй йөгереп үтте. Әллә соң Мизхәт аның уңай җавап бирүен теләмиме? Тискәре җавап ала да... Ул аның йөзләрен, күзләрен ныклап күрергә, аларда язылганнарны укырга теләде. Ләкин биредә караңгы, айның кызыл шары һаман наратлар арасында буталып йөри, аның йөз чалымнарын күрерлек түгел иде. Зөбәрҗәт аны прожекторларга таба алып китте, Мизхәтнең йөзенә үзе кебек сынап карап торды. Юк, аның йөзе гадәттәгечә, күзләрендә дә шикле нәрсә күренми. Шулай да Мизхәттә ниндидер ул аңлый алмый торган үзгәреш тә сизелә иде.
— Мизхәт, турысын гына әйт әле: гел уйламаганда-нитмәгәндә син ни дип мондый сүз кузгаттың?
— Ә син башта җавап бир, аннары әйтермен.
Зөбәрҗәт зур гына абага яфрагы өзеп алды да үзенең битенә каплады.
— Минем җавап уңай булыр...
Мизхәт аны кочып алды, абага яфрагы арасыннан кайнар иреннәрен эзләп тапты, күзләреннән үпте.
— Рәхмәт, Зөбәрҗәт, рәхмәт...
Зөбәрҗәт җиңел генә шуып аның кочагыннан чыкты.
— Мизхәт, әле бит әти-әни ризалыгы да кирәк.
— Шушы бер-ике көндә кайтып килербез.
Зөбәрҗәт көлеп җибәрде, тагын абага яфрагы алып, Мизхәтнең битеннән сыпырды.
— Ни булды соң сиңа? Мине беркем дә алып качмас... Соңрак та өлгерербез.
Тизрәк өйләнү теләге хәзер Мизхәтнең үзен дә бимәгән иде.
— Юк, юк, хәзер үк, берничә көн эчендә! — диде ул кабаланып.
— Сәбәбен әйт инде...
— Өйләнәсем килә, тагын нинди сәбәп булырга мөмкин? — диде Мизхәт һәм аны тагын кочакларга үрелде.
Ләкин Зөбәрҗәт житез генә бөтерелеп бер юан нарат артына качты.
— Әйтеп бетер,— дигән тавышы ишетелде аның.
— Фәрит абыйлар монда. Шәрифҗан абыйлар белән Илсөяр апаларны да бүген-иртәгә дип көтәбез. Туйга бүтәнчә алай җыйналып булмаячак.
Зөбәрҗәт ничек тиз качкан булса, шундый ук елгырлык белән агач артыннан килеп тә чыкты.
— Дүрт-биш көндә өлгерә алабызмы? — диде Мизхәт аның иңбашларыннан тотып.
Зөбәрҗәт баш чайкады.
— Син бит, Мизхәт, үзең турында гына уйлагансың. Ә мин?

— Шуңа күрә синең янына килдем дә...

Зөбәрҗәт ашыга-ашыга лагерь бинасына таба атлады.

— Миңа кирәргә вакыт...

— Соң нишлибез?

— Бераз уйларга ирек бир, зинһар...

— Ярый. Тик иртүк киләм.

— Юк, кич.

— Иртүк.

— Юк, кич. Сау бул!

Зөбәрҗәт кызулап веранда ишегенә атлады, барып җиткәч, «кит инде» дигән мәгънәдә Мизхәткә кул болгады, ул да шулай ук җавап бирде һәм күздән югалды. Зөбәрҗәтнең кирәсе килми иде. Ул акрын гына атлап үзләре ята торган бүлмәнең түр тәрәзәсе буена килде һәм Мизхәт мотоциклының пырылдап кабынганын, уты белән яктырта-яктырта юлга чыгып кайтып киткәнен күзәтеп торды. Зөбәрҗәтнең йөрәге дөп-дөп типте, аның йокысы качты, кирәргә кирәк дип уйлады ул һәм шулчак эчтә кызларның быдыр-быдыр сөйләнүләренә игътибар итте. Август төне тыныч, аларның сүзләре аермачык ишетелә иде...

— Шуның мотоциклы... башка кем булсын.

— Тиз китте бүген.

— Бәхетле дә инде безнең Зөбәрҗәт апа. Шундый шәп егетне эләктергән.

— Шәп микән соң ул?

— Нигә?

— Соң әнисе үлем хәлендә ятсын, ә ул кызлар артыннан чабып йөри.

— Үлем хәлендә?!

— Кем әйтте?!

— Сез ишетмәдегезмени әле? Нуриасма апага инфаркт булган бит. Медпункт мөдире Халидә апа сөйләгән. Исән калуы икеле дип әйтә ди. Балаларына телеграмма сукканнар...

Кызлар сөйләшүләрен дәвам иттеләр, ләкин Зөбәрҗәт аларның сүзләренең мәгънәсенә инде төшенә алмады. Аның өстенә кайнап торган су койган кебек булды. Нуриасма апа үлем хәлендә... Ә Мизхәт? Ул ничек монда килә алган? Ул ничек өйләнү турында уйлый ала?! Нормаль кеше шундый чакта бу турыда уйлый да алмый, уйларга хакы да юк. Моны берничек тә аңлата торган түгел. Моңа акылсыз кеше генә бара аладыр... Йә, ходаа! Ничә еллар йөреп, бер китеп, яңадан аның өчен шушында килеп, Зөбәрҗәт Мизхәтнең кем икәнен дә аңлый алмады микәнни? Әллә бөтен кешеләр дә аның кем икәнен белеп, Зөбәрҗәттән яшерделәр генә микән? Бу бит кешелексезлек кенә түгел, әллә ни бу! Бер генә бала да анасы авыр хәлдә мондый эшкә бармас.

Шомлы итеп берничә мәртәбә ябалак кычкырып куйды, агачлар арасыннан нindидер зур кош шаулап очып узды. Агарып һәм бөрешеп калган ай шары, агачлар арасыннан чыгып, буш күктә йөзә, аннан салкын нур коела иде. Зөбәрҗәт дерелдәп куйды. Ул, бүлмәгә кереп баш-аягыннан бөркәнеп яткач та, җылына алмады. Кызлар күптән йоклый иде, ә ул никадәр генә тырышып карамасын, керфек тә кага алмады. Ул әти-әнисеннән еракта шушы чит-ят урман эчендә ятуы өчен үз-үзен кызганды, «Мизхәт, Мизхәт»,— дип югалган яшьлек еллары өчен күңелен коточкыч үкенү биләде. Бәхеткә өметләнеп яшәгән ничәмә-ничә еллар бушка, бер файдасызга үткән, мәңгегә кайтарып ала алмаслык булып юкка чыккан, янган, төтенгә әйләнеп очкан иде... Ә бит Мизхәткә ул үзенә ышанган кебек ышанды. Бер кич бөтенесен чәлпәрәмә китерде. Әниең үлмәгән килеш, йортка эшче кул алып кайту хәстәрен кайгыртып йөрү өчен нинди йөрәк кирәк?! Моннан да түбәнлекнең булуы мөмкинме?!

Төне буе мендәренә кайнар яшь түгә-түгә, Зөбәрҗәт катгый уйга килде: беркайчан да кияүгә чыкмаска! «Бер кайтып киткәч, никләр килер-

гә иде миңа?!» — дип битәрләде ул үз-үзен. Мизхәткә эшче кул табылыр, инде ниятенә кергән икән, ул ике-өч көндә өйләнеп тә куяр. Әмма ләкин бу хурлыкны Зөбәрҗәт ничекләр күтәрер, ничекләр укытучылар, авыл кешеләре күзенә карар?! Юк, аның йөрәге мондый мәсхәрәне күтәрә алмый. Зөбәрҗәт, ныклы карарга килеп, акрын гына урыныннан торып утырды. Кызлар изрәп йоклыйлар, ул аларның һәрберсе белән күңеленнән генә хушлашты, кием-салымнарын эләктерде дә тавыш-тынсыз чыгып китте...

Хәвефле сигнал биргәндәй, урманны яңгыратып ике тапкыр ябалак кычкырды...

* * *

Мизхәт мотоциклын куеп кергәндә, Фәрит белән Нәсимә әнисе янында утыралар иде.

— Йә, ничек? — диде абыйсы.

Мизхәт, алар янына килеп, әнисенең хәлен белеште дә урындык алып утырды.

— Сөйләштегезме, улым?

— Әйе... — диде Мизхәт ни әйтергә белмичә.— Ул бик ашыгыч була ди.

Нуриасма башын калкытып куйды.

— Ә кайчан ди?

— Иртәгә кич җавап бирәчәк.

Фәрит тә сүзгә кушылды:

— Син аңлатып әйттеңме соң?

— Үземчә аңлаттым инде...

Әниләренең йөзенә канәгатьсезлек билгеләре чыкты. Ул бик озак бер сүз дә дәшмичә ятты. Аннары сорады:

— Зөбәрҗәт белән сөйләшүең хакмы, улым?

— Мин ничек сине алдыйм инде, әнкәй?

— Рәхмәт алайса. Инде болайга киткәч, әйтергә туры килә...— Нуриасма килененә карап торды. Аны борчыргамы-юкмы дип уйлады, ахырда ул барын да әйтергә булды.— Сине башлы-күзле итүне мин кызыктан гына кузгатмадым... Абыеннар, апаннар кайтканга да түгел. Ник ашыктырганымны сез бит яхшы аңлыйсыз, балакайларым.— Әниләре иреннәрен ялады.— Килен, әз генә су каптыр әле...

Нәсимә, аның башын кулы белән бераз күтәреп, су йоттырды.

— Рәхмәт, килен, кул-аягың сызлаусыз булсын... Мин үз хәлемне беләм, балалар. Көннәрем санаулы...

— Алай димә әле, әнкәй! — диде Фәрит ялварып.

— Әйтергә теләмәгән идем дә бит... Шулай туры килде инде... Бер караганда кычкырып әйтү әйбәт тә ул. Әчтән барыбер сез дә шуны уйлыйсыз... Мизхәт улым, Зөбәрҗәтнең теге чакта армиядән кайтуыңны көтмичә китүенә ачуланма син... Ул баланың гаебе юк. Гаеп миндә булды... Сине шәһәргә сөйрәр дип куркып, мин куштым аңа китәргә... Мин гаепле, улым, икегез каршында да... Булдыра алсагыз, кичерегез...— Әниләре туктап калды.

— Нинди гаеп ди ул, әнкәй,— диде Мизхәт ни әйтергә белмичә.— Син бит начар ният белән түгел...

— Начар булды шул... Бик үкендем дә бит соңыннан... Гаебемне йоларга ирек бирегез миңа... Үзем исән чакта бергә булуыгызны күрсәм, тыныч күңел белән китәр идем. Бу минем соңгы васыятем... Ышаныгыз миңа: вакытым бетте... Сезнең рәнҗешне күтәргән килеш китә алмыйм мин...

Өчесе дә тып-тын калып, ни әйтергә белмичә башларын иеп утырдылар. Нуриасма берничә сүз әйтте дә туктап ял итте, тагын башлады, тагын туктады, тагын башлады...

— Аннары бит... адәм баласының кендеге, әнисе карыныннан өзелү белән, җиргә тоташырга тиеш...

Нуриасма аларга барысын да аңлата алмады, күкрәгән көйдереп торучы утлы кисәү сөйләргә дә, тын алырга да ирек бирмәде. Сөйләрлек хәлдә булса да, кирәкле сүзләрне таба алмас иде. Бөтенесенә шәһәр гаепле, балаларымны шәһәр урлады, дип яшәгән Нуриасма соңгы вакытларда моның сәбәбе ниндидер бүтән нәрсәләрдә икәнен аңлый башлады. Балаларын читкә үзе дә куалашкан икән ләбаса ул. Авылда ач-ялангач килеш кәрәк-сәнәк тотып, бил бөгәргә хокук бар, ә яшәргә мөмкинлек юк иде. Җиденче классны бетергәч Фәрит техникумга укырга кермәкче булды, авылга агроном булып кайтам, дип хыялланды. Шуңа колхоздан китәргә рөхсәт сорап, Нуриасма райком секретарена кадәр барып җитте, әмма ләкин булмады. «Теләсәң нишлә, улым»,— диде Нуриасма кул селтәп. Бернинди документсыз авылдан чыгып качты мескен бала. Әнә кая барып чыкты, күмер вата. Ярый, ватсын, ил өчен анысы да кирәк. Ә татарча белмәүче ике кызы? Шәрифҗанның өч баласы? Шәрифҗанын бигрәк тә нык җәлли Нуриасма. Өч ел авыл хуҗалыгы институтына имтихан бирергә барды, өчесендә дә рус теленнән үтмәде. Күп тырыша торгач, хәрби училищега җибәрделәр, марҗага өйләнде, анысы рус теленнән имтихан алып тормаган үзе тагы. Өйләнешкәч, парлашып бер генә мәртәбә кайттылар, анда да Нуриасманың йөрәгенә кан савылып калды. Татарча сөйләшә башласалар, «ка-ка»гызны туктатыгыз», дип үпкәләде, көлсәләр, «миннән көләсез», дип үкерә-үкерә елады, аш пешерсәләр, «юри ат ите пешерәсез, мин ашамасын дисездер»,— дип бәгырьләренә төште. Шәрифҗан ялгызы гына кайтып килә дә «Ара ерак бит»,— дип аклана. Ара ерак түгел, күңел ерак — монысын Нуриасма яхшы аңлый һәм улын кызганып кайнар яшь түгә. Ичмасам үзебезнең туфракка кайтып үлә дә алмый бит инде ул. Илсөяре врач булам, диде, рус мәктәбендә укып, теләгенә иреште. Тик, институт бетергәч, үзебезгә түгел, әллә кая Урал ягына җибәрделәр. Шунда бер үзбәккә тормышка чыкты, шунда төпләнделәр. Кияү дә әйбәт, фатирлары да әйбәт, тик балалары гына ни татарча, ни үзбәкчә юньләп белмиләр. Соң шулай булгач, Нуриасманың төпчек баласын авылда калдырырга хакы юкмыни?! Хәдичәнең Суфиясен әрмән алып киткән кебек, аның Мизхәтен дә берәрсе алып китсенмени? Ата-бабаларыбызның телен, гореф-гадәтләрен белүче, моңын-җырын аңлаучы оныклары шушы нигездә дөнья көтәчәгенә ышанып үләргә хакы юкмыни аның? Бусына тагын кемнән рөхсәт сорарга? Чыгып бетмәгән җаныбызны әз генә булса калдырыгыз, үзебезчә яшәргә, ана телебездә сөйләшергә, үзебезчә җырларга-биергә рөхсәт итегезче, дип салган уртак сөрән бөтен ил буенча яңгырамыймыни?! Анда бит татар балалары гына тавышы түгел. Юк, җитте, нәселенең соңгы тамырын корытырга ирек бирмәячәк ул!.. Нуриасма уйларына бирелеп ята, балалары тилмерешеп утыралар икән бит!

— Барыгыз, йоклагыз, балалар,— диде ул.— Борчыдым инде сезне. Мизхәт улым... Зөбәрҗәттән берсен дә яшермә... Ул аңламый торган бала түгел.

— Ярар, әнкәй...

Нәсимә өйдә калды, Фәрит белән Мизхәт йокларга верандага чыктылар. Киңәш-табыш иткәч, иртәгә кичне көтмәскә, төшлектә үк Зөбәрҗәт янына икәүләп барып кайтырга кирәк дигән карарга килделәр.

## 16

Иртәнге тугызларда Нәсимә белән Фәрит чәйләп утыралар иде. Ишек алдыннан уйнаган җиреннән атылып-бәрелеп Марат килеп керде.

— Нуичама әби, Нуичама әби!

— Нәрсә, бәбекәчәем?

— Тигымәли җизни белән Фикая апа кайтты!
— Ай рәхмәт яугыры изге хәбәрең өчен!
Алар каршыларга дип кузгала башлауга, Кифая апалары белән Тимергали җизниләре күтәренеп килеп тә керделәр. Фәритләргә кул биреп уздылар да әниләре белән озаклап күрештеләр.
— И түти җаным, чирләденмени, ниләр булды соң, әле таш кебек йөри иден бит,— дип такмаклый-такмаклый Кифая Нуриасманың битләрен үпте, чәчләрен сыпырды, юрганнарын рәтләде, нишләргә дә белмәде, үзе туктаусыз елады, лышык-лышык борынын тартты.
Фәрит алгы өйгә алып чыгып җизнәсен чәй эчәргә утыртты. Ә Кифая һаман өзгәләнде, туктаусыз елады. Аның әз генә шадраrак кечкенә йөзе дә, күзләре дә Фәрит белән сөйләшкәннән бирле елый-елый кызарып беткән иде. Кечкенәдән үк бик нечкә күнелле, елак булды Кифая. Шуңа күрә аны Нуриасма «куяным», «йомшагым» дип кенә йөртте. Ире Тимергали аның турында: «Минем Кифая өч йөз алтмыш биш көннең өч йөзен елап уздыра, әгәр хөкүмәт, күз яшен бирәр киракяракка җыя торган булса, бездән дә бай кеше булмас иде»,— дип шаярта.
Нуриасма елмаеп сеңлесенең битендәге күз яшьләрен сөртте.
— Елама, куяным, картлык чире генә ул, куркырлык берни дә юк...
— Чынлапмы, түтәкәем?! — диде ул җанланып.
Нуриасма яратып аның күзләренә карады. Әле генә кайгы-сагыш, курку тулы бу күзләрдә өмет чаткысы кабынды. Тиз ышана иде Кифая, балачактан ук тиз ышана, аны алдау берни дә тормый иде. Гомер буе гөнаһсыз, беркатлы булуы өчен яратты да аны Нуриасма. Аннары Кифая үзенең барлык гадәтләре, кыяфәте белән, хәтта битендәге вак шадраларына кадәр әтиләренә охшаган иде...
— Чын, чын,— диде Нуриасма аны тәмам тынычландырып бетерү өчен.— Әз генә авырыйм да... аннары гел авырмам... Икәү бөрлегәнгә барырбыз, куянкаем...
Инде тынычланып кына килгәндә, Кифая тагын елап җибәрде. Телефон аша Фәриттән ул барысын да ишеткән, апасының юк-бар чир белән түшәктә ятмасын белә, шуңа күрә бөрлегәнгә барырбыз дигән сүз аның бөтен өметен сүндерде.
— И түти, бөрлегән дип... терелсәң әле...
Кифая башка сүз әйтә алмады, авызын яулык чите белән каплап, алгы өйгә чыгып китте, битен юды. Аннары ике зур сумка күтәреп кереп, өстәл өстен әфлисун, лимон, өрек, кара җимеш, тагын әллә нәрсәләр белән тутырып ташлады. Аның гомергә гадәте шундый, машиналарының багажнигы тулганчы азык-төлек, чүпрәк-чапрак төяп кайта. Нуриасма аны кайткан саен, бу кадәр ризыкны кем ашап бетерә, бу кадәр киемне кем киеп бетерә, ник акча әрәм итәсең, дип пыр туздыра. Ә ул яшь аралаш елмая да:
— И түтекәем, ач-ялангач вакытларда синнән бигрәк күп изгелекләр күрдем шул, ничекләр итсәм дә түләп бетерә алмам күк,— дип аны кочаклап ала...
Бу юлы аңа бер сүз дә әйтмәде Нуриасма. Кифая, урталай кисеп, чистартып, аңа бер әфлисун бирде.
— Аша әле, түти, тәннәреңә сихәте тимәсме...
— Син алып кайткач, тимиме соң инде, куяным...
Нәсимә чәйне олы якка әзерләде. Алар әкрен генә озак итеп сөйләштеләр, хәл-әхвәл сораштылар, әти-әниләрен, туган-тумачаларын хәтердән үткәрделәр. Рәмзине җирләгәндә, Кифаялар Үзбәкстандагы кызларында кунакта калганнар иде. Нуриасмадан бөтенесен җентекләп сөйләткәч, ул тагын өнсез калды, үксеп-үксеп елады. Бәләкәй Күкелегә бүген күчтәнәчләр илтә баргач, кырыгын пичәсендә үткәрәселәрен белешәбез, һичшиксез, кайтабыз, диде. Сөйләшкән сүзләренең күбесе кайгы-сагышлы булса да, бәйрәмгә дип кайтмасалар да, Нуриасманың да, Кифаяның да, Нәсимәнең дә ничектер күңелләре бушана, җиңеләя барды...

Фәрит жизнәсе белән ишек алдына чыкты. Алар белән әфлисун, өрек ашап утырган Маратны танырлык түгел иде: матроскасын, сандалиларын баскычка салып аткан да тагын теге калай сәдәфле, ямаулы чалбарын киеп куйган. Тимергали аны күреп киң күкрәгенә кысты. Марат жизнәсенең зур, сирәк чәчле башына, тирләгән маңгаена, калын кашларына, көрән күлмәге өстеннән ике яклап тартылган зәңгәр подтяжкаларына карап торды да, түгәрәк корсагыннан шуып төшмәкче булып, аяк-куллары белән тырмаша башлады. Тимергали аны җиргә бастырды, кулына берничә кисәк чәйнәгеч сагыз тоттырды.

— Әхмәт, Тигымәли жижни! — диде Марат һәм сагызны чәйни-чәйни йөгереп тә китте.

Ул ишек алды почмагындагы кычыткан арасыннан шактый зур бер нәрсә этеп чыгарды. Бу — фанерадан КамАЗ машинасына охшатып ясалган дүрт тәгәрмәчле уенчык иде. Марат аны арттан ике кулы белән этеп ишек алды буйлап йөгерә башлады. Ниндидер шестерняга калай кисәге тиюдән уенчыкның эченнән шытыр-шытыр иткән тавыш килде. Ул әтисе белән жизнәсе яныннан:

— Тү-үт, тү-ү-үт! Китегеж, Бадамач таптамачын! — дип выжылдап уза, «мине күрәсезме» дигәндәй авызын ерып аларга карый.

— Улым, ни соң ул Бадамач? — диде Фәрит, аның уенчыгына чиертеп куеп.

— Бәй, Бадамач — Бадамач инде! Йөк ташый, — диде Марат, шуны да белмисез дигән төсле.

— КамАЗмыни?

— Әйе, Бадамач! — диде Марат шатланып.— Беж аны Мижхәт абый белән икәү ячадык.— Марат инде шактый нык кыздыручы кояшка күзен кысып карап торды да әтисенең чалбарыннан эләктерде.— Әти, әйдә бачуга!

— Ник? — диде Фәрит малаеның көтелмәгән бу теләгенә аптырап.

— Чәхән абый Каенлы бачуына чакыды.

— Хәсән абыең? Ник чакырды?

— Мин Бадамач белән ачлык тачыйм ындыр табагына. Чине дә чакыды. Бодай уам, диде.

Фәритнең авыл башыннан ук җәелеп киткән ул басуга бик барасы килсә дә, жизнәсе белән Кифая апасын уйлагач, ул ниятеннән кайтты.

— Без бит жизнәң белән Бадамачка сыймыйбыз,— диде ул Маратның аркасыннан сөеп.— Тукта, син уйный тор әле...

Алар жизнәсе белән өйгә керделәр. Марат та ияреп керде, туктаусыз басуга кыстады. Нәсимә, аның өстендәге киемнәрен күреп, алыштырырга ниятләгәч, әбисе янына барып сыенды, елый ук башлады.

— Әнкәй, без өчәү Мөнәвәрә апаларга барып кайтыйк, Нәсимә синең янда торыр,— диде Фәрит.

— Бачуга баыйк, бачуга баыйк! — дип туктаусыз такмаклады Марат.

— Кияү, сез Кифая белән генә әйләнегез инде булмаса,— диде Нуриасма.— Әтисе белән басудан урап кайтсыннар.

— Соң, әнкәй, бала-чага теләге белән генә йөреп булмый бит инде,— диде Фәрит канәгатьсезлек белдереп.

— Минем теләк белән йөр, улым. Без Марат белән арыш басуында да, борчак басуында да булдык. Ура башлагач, бодай басуына алып барырга сүз биргән идем.

— Чүж бигәч, үтәгә кияк, әйеме, Нуичама әби? — диде Марат.

Моны ишетүгә, иң элек Тимергали гыжылдап көләргә тотынды, аңа өйдәгеләр һәммәсе дә кушылды. Тимергали кызарып ютәлли-ютәлли:

— Булдырдың, Марат, сүз әйтер урын калдырмадың,— диде дә ишек алдына чыгып китте.

— Улым,— диде Нуриасма,— бер уч бодай башагы алып кайт әле миңа... Сабагы белән озын итеп сындыр...

— Ярый, әни,— диде Фәрит.

Шулай итеп, жизнәләре Бәләкәй Кукелегә, Фәритләр, Бадамачны алгы бавыннан сөйрәп, басуга юнәлделәр.

Авыл башына чыккач, Фәрит тыны кысылып туктап калды. Бу таныш басуларны күрмәгәнгә шактый булган икән. Әнә басу уртасында таныш каеннар шаулап утыра. Анда сугышка кадәр кыр станы корганнар, каеннар да бишәү генә булмаган... Бу басулардан комбайннан капчыклап аз ипи ташымады Фәрит. Әле ул яшь иде, капчык күтәргәндә билләре шытырдый иде. Әрем, билчән, тарма орлыгы белән буталган дымлы икмәк исен аның беркайчан да онытасы юк.

Хәсәннең комбайны, тузан болыты күтәреп, якынлашып килә иде. Бу якка карагач, җир йөзе сары төстән генә тора дип уйларсың. Алла да, уңда да, сулда да сап-сары... Кояш зәңгәр күктән көлтә-көлтә нурлары белән басуларны тагын да жетеләндереп җибәрә. Барысы да якты, барысы да нурлы, барысы да көләч, барысы да җылы... Басу өстеннән офык буйлап рәшә йөгерә, камыллар арасыннар бөжыр балалары күренеп ала да юкка чыга, аяк астында гына чикерткәләр сайрый, камыл исе, туфрак исе сеңгән йомшак жил битләргә, муеннарга гына түгел, йөрәккә дә кагылып үтә... Фәритнең күкрәк турын нидер чәнчеп алды. Кара жир астында, күмер тузаны эчендә үткән гомере бик тә кызганыч булып тоелды аңа. Стажы тулган, ул ике дә уйламыйча авылга яшәргә кайтыр иде. Нәсимәсен дә күндерер. Ә менә житкән ике кызы кайтырмы соң? Юк, билгеле. Алар инде шәһәр балалары. Бу басу-кырлар, тын авыл алар өчен әллә бар, әллә юк. Аларның үз мәктәпләре, үз дуслары. Менә шулай, тамырлар шартлап өзелгән. Марат кызганыч. Аны да шул ук язмыш көтәрме? Әле Донецкига баргач, кабат авырый башламаса. Ни эшләп була соң? Гаиләне икегә аерып, Фәрит улы Марат белән монда, Нәсимә кызлар белән Донецкида яши алмыйлар ләбаса! Сагынулар, саргаюларны юкка гына жырламый шул татар кешесе. Биек тау башларындагы кайбер ташлар да жирне сагынып елый, диләр. Ташның күз яшьләре ага торгач, гәрәбә төсле ката. Аны мумие дип атыйлар. Мумие гаять көчкә ия, аның белән әллә нинди чирләрне дәвалыйлар. Сагыну жырлары да туган жиреннән, милләтеннән, нәсел-нәсәбеннән аерылган бәндәләрнең күңелләреннән озак дәверләр буе сыгылып чыккан күз яшьләре ул, алар да савыктыргыч көчкә ия...

Комбайн килеп житте. Хәсән сикереп төшеп Фәрит белән күреште, Маратка үзенең туфрак һәм май сеңеп каралган, ярталанган кулын сузды.

— Шәпме?

— Чәп,— диде Марат үзенең кечкенә кулын Хәсән абыйсының учына салып.

— Бадамачны алып килдеңмени?

Марат аңа җавап биреп тормады, тизрәк гозерен әйтте:

— Чәхән абый, Бадамачка бодай чал.

— Чалам, чалам,— диде Хәсән елмаеп һәм Фәриткә күз кысып алды.

Ул Бадамачның тартмасына чиләк белән элеп гәрәбәдәй бодай салды.

— Булдымы?

— Тагын чал,— диде Марат.

— Әбиеңә охшамасаң, кыек китәрсең,— диде Хәсән һәм шаркылдап көлә-көлә тагын бодай китереп салды.

— Әйдә, әйдә,— диде Марат.

— Хәзер, улым. Бар, әбиеңә алып кайтырга башак жыя тор.

Фәрит белән Хәсән яшьлек елларын хәтерләренә төшереп алдылар.

— Бервакыт нәкъ шушы төштә синең туры биян дулаган иде. Дилбегәгә уралып сөйрәлеп барганыңны оныттыңмы? — Хәсән тузаннан сөрмә тартылган керфекләрен кысып аңа карады.

— Нишләп онытыйм ди! — Фәрит яшьтәшенең җилкәсенә кулын салды. — Шунда син туктатмасаң, беткән идем мин. Ә шулай да, әллә олыгаю галәмәте, торган саен ныграк сагындыра, яшьти... — Фәритнең күзләре дымланып китте. — Син бәхетледер, Хәсән.

— Әллә инде...

— Шушы басуларга хуҗа булу бәхет инде ул.

Хәсән ап-ак тешләрен күрсәтеп кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Нигә көләсең?

— Болай гына, — диде Хәсән кинәт уйчанланып. — Бу җирләргә хуҗа булсам, ни эшләргә икәнен белер идем мин...

Фәрит аптырап китте.

— Боларның хуҗасы кем соң?

— Белмим, тик без түгел.

— Арендага алмадыгызмыни?

— Алмаган кая! Кәгазьдә без хуҗа. — Хәсән «ярар инде» дигән мәгънәдә кул селтәп куйды. — Ярар, яшьти, көн әйбәттә суктырыйм әле мин.

Ул җәһәт кенә комбайнына менде, Фәрит белән Маратка сигнал бирде, елмаеп кул болгады да кузгалып китте. Фәрит берничә минут кузгала алмыйча бер урында басып торды.

Алар башак җыйдылар да тауга, ындыр табагына юл тоттылар. Анда укытучылар, пенсионерлар эшли иде.

— О-о, Бадамач килгән!

— Исәнме, Бадамач!

— Бодай китерденмени? Кая әле бушатыйк!

Хатын-кызлар Маратны сырып алдылар, күтәреп тә, җиргә төшереп тә сөйделәр, сөйләштеләр. Бодаен бушаткач, Маратка бер бәләкәй көрәк бирделәр, ул ашлык җилгәргечкә көшелдән бодай көрәргә кереште. Фәрит бик кыен хәлдә калды. Күзләре белән эзләсә дә, бер генә көрәк тә күренмәде.

— Исәнмесез, Фәрит.

Ул, артына борылып карауга, мәктәп директоры Мәгъфүрә Зарипованы күрде.

— Исәнмесез...

— Бик әйбәт малай үстерәсез, сокланып туймыйбыз, — диде ул. — Әбисе белән гел безгә ярдәм итеп йөрделәр.

Директорның сүзләрен Фәрит кып-кызыл булып, ни әйтергә дә белмичә тыңлады, әмма «безнең тәрбиябез түгел, әнинеке» дип әйтә алмады.

— Көрәгегезне бирегез әле, мин дә бераз кыймылдап алыйм, — дип аның көрәгенә үрелде Фәрит.

— Юк, юк, сезнең гаиләдән берәү булгач, бик җиткән. — Зарипова елмаеп көрәген читкә алды. — Әгәр вакытыгыз булса, минем сездән бер нәрсә сорасым бар иде.

Алар читкәрәк киттеләр. Зарипованың йөзе җитдиләнде.

— Мин моны Мизхәтнең үзеннән сорарга тиеш идем дә... Бәлкем, сез белерсез, белмәсәгез, аның үзеннән сорарсыз...

Фәрит ниндидер күңелсез хәбәр ишетәсен сизенеп, сагаеп калды. Зарипова аның күзләренә туп-туры карады да:

— Сез беләсезме, Мизхәт белән Зөбәрҗәт арасында ни булды икән?

— Берни дә юк иде кебек...

— Бүген иртәнге алтыда Зөбәрҗәт безнең өйгә керде. Эштән азат итүне сорап гариза бирде.

— Гариза?!

— Әйе. Бүген үк Алабугага китәм, диде. Күп елаудан шешенеп беткән.

Фәрит катты да калды.

— Димәк, сез берни дә белмисез? — диде Зарипова. — Бер атна көт, лагерь ябылгач китәрсең дип карадым. Ә ул тыңларга да теләмәде, елый-

елый чыгып йөгерде. Ачуланышканнар, күрәсең. Зөбәрҗәт — минем бик яхшы укытучым, ул кабат кайткач, без шулкадәр шатланган идек... Мизхәт үзе монда комбайннан ашлык ташый. Өч мәртәбә янына бардым — сорарга батырчылыгым җитмәде. Әнигезнең хәлен белештем дә киттем... Без, бөтен авыл, аларга сокланып карадык, тиздән өйләнешерләр, дип өметләнә идек...

— Әйтүегез өчен бик зур рәхмәт,— диде Фәрит чын күңеленнән.— Мин хәзер үк Мизхәт белән сөйләшермен.

— Зинһар, мин әйтте дия күрмәгез,— диде Зарипова.

Фәрит, башына сугып аңгырайтылган кеше кебек, урынында басып калды. Зарипова әйткән хәбәр аның барлык уйларын чуалтты. Ындыр табагыннан читкәрәк киткәч, ул юлдан ерак түгел үләнгә утырды. Ашлык ташучы машиналар шушы юлдан йөри, хәзер Мизхәтне күрергә кирәк иде. «Кичә ул алдады микәнни? — дип уйлады Фәрит.— Зөбәрҗәт каршы түгел, дип әнине борчымас өчен генә әйтте микән әллә?»

— Әнә Мижхәт абый мачинасы! — Марат басудан борылып чыгып килүче зәңгәр машинага бармагы белән төртеп күрсәтте. Ул якынлашуга, каршына йөгерде.

— Мижхәт абый, мин дә Бадамач белән Чәхән абый комбайныннан ачлык кайтадым! — диде ул куанычтан авызын ерып.

Мизхәт аны руль артына утыртты да абыйсы янына килде.

— Нишләп йөрисез, абый? — Мизхәт сәгатенә карап куйды.— Лагерьга барырга әле иртәрәк.

— Марат белән йөрибез шунда...— Фәрит энесенә сынап карады, әмма аның йөзендә бернинди борчылу билгеләре күрмәде.— Энекәш, Зөбәрҗәтнең киткәнен беләсеңме син?

Мизхәтнең күзләре кысылды, ике каш арасындагы җыерчыгы тирәнәйде.

— Киткәнен? Кая?

— Алабугага.

— Ни сөйлисең син, абый?! — диде Мизхәт көлгән кебек итеп.— Мин бит аның яныннан кичә төнлә генә кайттым. Ничек Алабугага китсен ди ул!

— Киткән шул,— диде Фәрит.

Мизхәт аптырап кулларын җәйде.

— Берәр нәрсә булып, төнлә телеграмма килсә инде... Башкача... белмим... Алай булса да, миңа әйтеп китәр иде ул...

— Зөбәрҗәт эштән җибәрүләрен сорап мәктәп директорына бүген иртән гариза калдырган.

— Ышанмыйм...— Мизхәт ничектер бөкрәеп калды.— Мәгъфүрә апа бит мине күрде, берни дә әйтмәде.

— Ә ничек әйтсен ул аны сиңа? Ник?

— Әйе шул, әйе...— Мизхәт кинәт башын күтәреп абыйсына туптуры карады.— Абый, ни була соң инде бу?!

— Моны мин синнән сорарга тиеш, энекәш. Әллә әзрәк әйткәләшкән идегезме?

— Юк, абый, юк! — диде Мизхәт ярсуын тыя алмыйча.— Ышанмасаң, ипи тотып ант итәм. Берни дә юк иде, барысы да әйбәт иде...

Мизхәт, җиргә утырып, йөзен куллары белән каплады. Әгәр ул кияүгә чыгарга тәкъдим ясагач та китеп барган икән, аның башка кешесе бар дигән сүз. Хәер, бервакыт ул үзе дә әйтте бит: Алабуга педагогия институтында эшләүче бер галим белән дус идек диде. Зөбәрҗәт шул кешенең тәкъдимен бик озак көткәндер дә... Ул кеше Мизхәттән якынрак та, кадерлерәк тә, өстенрәк тә булгандыр күрәсең. Тик ул һаман дәшми, ә менә Мизхәт тәкъдим ясый. Зөбәрҗәт хәзер теге кешегә кайтып әйтә: кияүгә чыгам, ди. Шунда теге: «Мин сине беркемгә дә бирмим»,— ди, йә булмаса: «Бар чык, бәхет телим»,— диячәк. Мизхәтнең уйлавынча, Зөбәрҗәтнең кайтып китүен бары тик шулай гына аңлатып була, бүтән бернинди сәбәп юк иде.

— Энекәш, кайда тора ул?
— Кем?
— Зөбәрҗәт.
— Миңлекамал әбидә.
— Әйдә, кагылып чыгыйк әле.
— Ник?
— Соң, ул әби ни булганын белми калмас.

Мизхәт теләмичә генә ризалашты. Маратның Бадамачын машина тартмасына ыргыттылар да авылга төшеп киттеләр. Кызганычка күрә, карчык берни дә әйтә алмады. Зөбәрҗәт иртүк лагерь машинасы белән кайткан, әйберләрен чемоданына тутырган, шулай туры килде, ачуланма, дигән, әбигә акча биргән, рәхмәтләр укыган да исәнләшеп чыгып киткән...

— Ярый, энекәш, син эшеңә бар. Әнигә хәзергә әйтмибез,— диде Фәрит.— Кичкә кадәр уйлаша торыйк...

Кайтып җиткәч, Фәрит әнисе янына бераз кермичә, ишек алдында уйланып торды. Аның күзенә туры карарга ояла, эчендә әнисеннән яшерен нәрсә саклау җинаять кебек авыр иде. Шуның белән бергә авырып яткан әнисенә: шулай-шулай булган бит әле, ниндидер аңлашылмаучанлык килеп чыккан, Зөбәрҗәт кайтып киткән, дип сөйләргә дә ярамый. Тешне кысып түзәргә кирәк иде. Ул, бодай башакларын бер учмага бәйләп, сабак очларын балта белән чабып атты да әнисе янына керде. Әнисе үзе генә иде.

— Нәсимә кайда, әнкәй?
— Ул бакчага бәрәңгегә генә чыкты.

Башакларны күргәч, әнисенең йөзе яктырып китте, иреннәре елмаеп куйдылар. Ул аларны әйләндереп-әйләндереп карады, учы белән сыйпады:

— И җаныкайларым, басуыгыздан аерылыр көннәрегез җитте шул. Яшел чакларыгыз узган, саргаер чакларыгыз җиткән...

Аннары әнисе бик озак тавыш-тынсыз гына башакларга карап торды. Фәрит аңа сүз катарга да, чыгып китәргә дә кыймыйча басып торды.

— Ә шулай да арышка җитми,— диде әнисе әллә үз-үзенә, әллә Фәриткә.

Хәдичә бүген тәвәккәлләргә булды. Күпме вакыт ясый алмаган адымын менә хәзер ясарга кирәк иде. Ул теге көнне Нуриасмалардан ашыгыч ярдәм машинасы китү белән медпунктка кагылды һәм барысын да белде. Рәнҗүе шулкадәр көчле булгандыр, аның бу хакта, урамга чыгып, сөенә-сөенә кешеләргә сөйлисе, Нуриасма янына кереп: «Дөнья куласа ул, сиңа да килер дип әйттем — менә килде дә»,— диясе килде. Әмма аны нидер тыеп калды. Ул урамга чыгып сөенечен дә белдермәде, Нуриасмага кереп теге сүзләрне дә әйтмәде. Эчтән шатланса да, моны эшли алмаячагын сизде. Төгәлрәк әйткәндә, бу шатлану түгел, ә бәлки шатланырга маташу иде. Аны никадәр генә сузарга, чыңга әверелдерергә тырышса да, Хәдичә булдыра алмады. Аңа читтән кемдер текәлеп карап тора һәм эчендә нәрсә бар — һәммәсен дә үтәли күрә төсле тоелды. Нуриасма үлеп китсә? Әгәр ул тикшерүчегә дөресен сөйләгән икән, моның һич тә кемгә дә булса начарлык эшләү нияте белән түгел, ә Нуриасманың алдаша алмавыннан икәнен Хәдичә баштук аңлады бит. Үзең белән үзең генә калган хәлдә фәһем иткәндә, Нуриасма гаепсез иде. Шуңа күрә ул бу дөньядан аңа коточкыч рәнҗеп, аны каргап китәчәк һәм ул каргыш, һичшиксез, Хәдичәне тотачак, аны тотмаган суратта, балаларын, балаларының балаларын авыл халкының күз алдында үтмәс рәнҗү кебек мәңге газаплап торачак иде. Кеше гомерен өзү беркайчан да гафу ителми. Моның өчен авыл халкы гына түгел, аның оныкларының оныклары да Хәдичәгә бәддога укыячак, каберенә каш җыерып караячак... Сузмаска, Нуриасма янына керергә, кайсы алдан китсә дә — улмы, Хәди-

чәме — анысын бер алла белә, ничек кенә булмасын, аңлашырга, кешечә бәхилләшергә кирәк иде. Хәдичә шуны теләде, ләкин үзенең эчендә моңа каршы килүче көчне бүгенге көнгә кадәр җинә алмады. Ләкин гаҗәп хәл: Нуриасмадан яшерергә, халыкка сиздермәскә теләгән гаебе аның җан тынычлыгын алды һәм нәкъ әнә шул үзе аны Нуриасма янына керергә әйдәкләде...

Һәм ул бүген тәвәккәлләде. Ачы коймак пешерде, әгузе-бисмилласын әйтә-әйтә аны коштабакка салды, чачаклы сөлге белән төрде һәм, авыз эченнән белгәннәрен укып, аның янына кереп китте. Бусаганы атлап исәнләшүгә, Нәсимә самавыр янарта башлады. Хәдичә карават янындагы урындыкларның берсенә утырды, икенчесенә коштабакны куйды. Ике куллап дога кылганда, башын бераз борып, Нуриасмага күз төшереп алды. «Йә аллам, кеше булудан үткән инде бу»,— дигән уй йөгерде аның миеннән. Аны хәйран калдырганы Нуриасманың иреннәре булды. Алар мәетнеке кебек күкшелләнеп тора, элекке рәвешләрен югалткан һәм суырылып эчкә баткан иде.

— Авырып киткәнсең икән,— диде Хәдичә аның күзләренә туры карамас өчен үзенең итәк-җиңнәрен төзәткәләгәндәй итеп.— Хәлләрең ничек?

— Аллага шөкер әле, рәхмәт хәл белешүең өчен,— диде Нуриасма аңардан күзен алмыйча.

Аның борынына Хәдичә килеп керү белән тәмле хушбуй исе килеп бәрелгән иде. Хәдичә бәйрәмнәрдә генә кия торган затлы күлмәген кигән, иң матур яулыгын бәйләгән, чәчләрен әйбәйтләп тараган, гәрәбә муенсасын да таккан. Димәк, ул Нуриасма янына керергә ныклап әзерләнгән, моңа олы нәрсә итеп карый. Хәдичә Нуриасманың үзенә төбәлгән күз карашын сизде, ләкин аңа күтәрелеп карарга батырчылыгы җитмәде. Кыенлыктан чыгу өчен, сөлгене сүтеп, коймакны ачты һәм коштабакны күтәреп Нуриасмага якын китерде. Шунда аларның күз карашлары кисешеп алды һәм Хәдичә әллә нишләп китте. Аның кергәннән бирле үзенә туры карарга кыймавын, эчтән куырылганын Нуриасма күреп тора иде. Аны бу хәлдән коткару өчен ул карашын түшәмгә борды.

— Син ярата торган ачы коймак, авыз ит әле..

Нуриасма кымшанып та карамады.

— Мәшәкатьләнүең өчен рәхмәт инде,— диде ул. Аннары ачыклагандай өстәп куйды:— Әле генә килен белән чәй эчкән идек...

Хәдичәнең тәненнән эссе дулкын йөгереп үтте. «Мин пешергән коймактан баш тарта, миңа бәхиллек бирергә теләми»,— дип уйлады ул. Хәдичә үзе дә сизмәстән аягына басты, ялварып Нуриасманың күзләренә карады, һәм моңа кадәр аны тыеп торган теге көчнең чигенә башлавын тойды.

— Зинһар авыз ит, күршекәем...

Нуриасма башын аңа борды. Хәдичәнең күзләренең дымланганын күрде. Аның тәгам ризык та кабарлык рәте юк иде. Шулай да тырышып карарга булды, башкача ярамый иде.

— Алайса бер коймакның яртысын гына бир инде...

— Каяле иң тәмлесен, иң йомшагын, иң күпереп пешкәнен генә...— Хәдичә җанланганнан-җанлана барды.— Җиз иләктән иләп, ак май белән генә пешердем... Бисмиллаһир-рахман ир-рахим, әгузе биллаһи...

Ул, шулай сөйләнә-сөйләнә, бер коймакны урталай аерып, Нуриасмага тоттырды, икенче яртысы үзендә калды. Нуриасма коймакны әз генә тешләп ашыкмыйча гына чәйнәде, коймак бик тәмле иде. Хәдичә аңа карап мактау сүзе көтте һәм, әлбәттә, Нуриасма моны сизде.

— Бик уңган, тәмле булган,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә.— Үзең дә аша...

Алар икесе дә кулларындагы коймак кисәген ашап бетерделәр. Хәдичә калган барлык коймакны Нәсимәгә чыгарып бирде, кайнар чакта ашагыз, Маратка бирергә онытма диде. Ул кабат урындыгына кереп

утырды, ләкин сүз башлый алмады, арадагы киеренкелек һәм кыенсыну тойгысы бөтенесен бүлеп тора иде. Сөйләшкәндә җиңелрәк, ник дисәң, сине куркыта торган кыен әйбердән сүзләр артына яшеренеп була. Ә менә болай тын торганда, син ялангач кешедәй нишләргә белмисең: яшеренергә кирәк, әмма качар урын юк...

Нуриасма кәфендәй ак хәлсез куллары белән бодай башакларын кулына алды.

— Менә... бүген генә Фәрит Каенлык басуыннан алып кайтты,— диде.— Шунда йөргәндәй булсам да, уйлап ятам: янына үзем бармаганга Каенлык басуы рәнҗеп ятмаса ярый инде... Бер елны да бармый, сөйләшми калганым юк иде бит...

— Басуның рәнҗергә хакы юк,— диде Хәдичә авыр сулап.— Менә мин сине рәнҗеттем, малай... Гел кирәк булмаган югыйсә...

— Юк, Хәдичә, кирәк булгандыр, булгандыр...

Нуриасма башакларны сыпырды да үзе белән янәшә ястыкка куйды. Хәдичә кергәндә үк барысын да әйтергә әзерләнгән, һәр сүзен уйлаган иде. Тик алар әллә кая юкка чыктылар, теле бәйләнде дә калды.

— Алла каршына болай бара алмыйм мин...

Нуриасма беркадәр көттерде дә:

— Сиңа бәхиллек кирәкме?— диде.

Хәдичә бу сүзләрдән сискәнеп куйды, чөнки Нуриасма аның нәкъ менә шуның өчен керүен төгәл сиземләгән иде. Хәзер ничек кенә булса да, аны кузгатып монда алып кергән ул ниятне яшерергә кирәк, яшерә алмаган очракта Нуриасма каршында Хәдичә үлем саклаучы козгын хәлендә калачак иде.

— Син нәрсә... ни сөйлисең, Нуриасма!— диде Хәдичә ашыга-кабалана.— Мин синең белән хушлашырга кермәдем... Аллаһе боерып, әле синең белән күрше булып яшәргә насыйп булсын... Ни дигән сүз ди ул — бәхилләшергә... Хәлеңне белергә генә кердем...

Нуриасма ышанмаса да, Хәдичәгә бу сүзләре өчен эчтән генә рәхмәт укыды. Яшәргә өмете бар идеме шунда, ничектер әз генә моңсу да, рәхәт тә иде... Аларның икесенең дә йөрәген бергә басып, авырттырып торучы авыр таш төшеп киткәндәй булды. Әмма Хәдичәнекендә ташның иң зурысы калган иде әле. Ничә еллар буе вөҗданын газаплаган, йөрәген изгән бу гөнаһ йөген ул хәзер аударса аударып кала, аудармаса, мәңгегә үзе белән теге дөньяга ук алып китәчәк иде... Нуриасманы ул барыбер алдый алмады, Нуриасма аның нинди ният белән кергәнен барыбер аңлады. Хәзер инде әйтеп бетерергә кирәк иде.

— Мин сиңа иң зур гөнаһымны әйтергә тиешмен...— Хәдичә тамак кырып куйды, аның сулышы кысылды.— Бергә гомер кичердек, төрле чак булгандыр... Мин сиңа күптән сөйләргә тиеш идем... Мин бит... Сәгыйдулла исән чакта... аның белән...

Кинәт Нуриасма кулын селтәп Хәдичәнең сүзен бүлдерде:

— Сөйләмә!— Аның иреннәре кысылдылар.— Мин барысын да беләм...

— Беләсең?!— Хәдичәнең икe чигәсе чәнчешеп китте. «Ул барысын да белгән! Барысын да белгән!— дип хәйран калып кабатлады ул үзүзенә.— Ничә еллар буе белгән, ә сиздермәгән!»— Сәгыйдулла сөйләдеме?— диде ул калтыранган бармаклары белән яулык очын бөтерәбөтерә.

— Юк, үзем белдем...

Хәдичә карашын идәннән күтәрә алмады, әйтерсең лә Нуриасма аның үзенә карата әшәкелек кылуын гомер буе читтән күзәтеп: «Тагын ниләр эшли алырсың икән?»— дип карап торган... Ул кычкырып җибәрде:

— Гомер буе... Ник әйтмәдең?!

— Әйтсәм, син миңа бүтәнчә карый башлар идең. Ә без болай дус яшәдек...

Хәдичәнең күзләрендә хәтәр очкыннар кабынды.

— Алайса син гомер буе кылангансың, дус яшәгән булып алдагансың! Син мине күрә алмагансың! — диде ул аны гаепләгәндәй.

— Юк, Хәдичә, баштарак нидер булгандыр, әрнү димме, ачу димме... Юк, ялгышам, булмады бугай... Кояш белән ант итәм — булмады. Мин сиңа рәнҗемәдем дә...

Нуриасманың тавышы тыныч, салкын иде, чөнки ул йөрәкнең инде әллә кайчан дөрләп янып беткән почмагыннан чыга иде.

— Ничек алай була алсын?! Алай була алмый!

— Менә анысын белмим... Син бит барыбер миннән бәхетсезрәк идең...

Алар тын калып, хәтта бер-берсенең сулыш алганын ишетеп бик озак утырдылар. Хәдичәнең башы аска иелгәннән иелә барды. Ниһаять, ул ниндидер бөтенләй үзенекенә охшамаган ят, арыган тавыш белән:

— Моны күтәреп син ничек яши алдың? — дип сорады.

— Үзең әйткәнне көттем... Менә бит — әйттең. Мин дә әйттем...

— Әгәр әйтмәгән булсам?

— Мин дә әйтми идем. Син минем бөтенесен дә белгәнемне уйлап та карамаячак идең... Ялгыш уй белән китә идең дөньядан... бу берни дә сизмәде дип...

Хәдичә, бу сөйләшүдән телсез-өнсез калып, саубуллашырга да онытып чыгып китте...

* * *

Бәләкәй Күкеледән кайтып керүгә үк, Фәрит җизнәсенә Зөбәрҗәтнең Алабугага киткәнлеген әйтте. Бер болай, бер тегеләй уйлап карагач, кич җизнәсенең машинасы белән өчәүләп Алабугага китәргә карар кылдылар. Мизхәтне басу юлында очратып, бу хәбәрне әйткәч, ул аларның икесен дә аптырашта калдырды:

— Киткән икән, хәзер инде баруның кирәге юк, — диде ул тешен кысып.

Фәрит кызып китте.

— Ничек инде файдасы юк, ничек юк?! Хатын-кыз бит ул! Шайтан белсен аның нинди ният белән кайтып киткәнен? Барабыз, үзе белән дә, әти-әнисе белән дә сөйләшәбез. Аны бит без барыбер Алабугага барып сорарга тиеш идек.

— Ә мин каршы, — диде Мизхәт.

Чөнки, күп уйлана торгач, ул Зөбәрҗәтнең китүен башкачарак аңлады. Таныш кешесенә ул Мизхәт китү белән төнлә шалтыраткан, тегесе иртәгә үк кайтып җит, дигән. Әгәр шулай булмаса, ул кешенең ни әйтәсен белми торып, Зөбәрҗәт көнендә үк эштән азат итүне сорап гариза бирмәс иде... Әлбәттә, абыйсы белән җизнәсенә ул бу турыда бер сүз дә әйтмәде, чөнки алар инде хәлне берничек тә үзгәртә алмыйлар иде. Шуңа күрә аларның бер генә дәлиле дә Мизхәткә тәэсир итмәде, ул Алабугага баруга каттый рәвештә каршы килде. Ачуланыша язып әрепештылар. Фәрит «Барабыз» диде, Мизхәт «Бармыйбыз» диде. Фәрит соңгы сүзен болай дип тәгалләде:

— Мин әнкәйгә, барысы да әйбәт, кызны сорарга Алабугага барабыз, дидем. Кич иртәрәк кайт. Әгәр кайтмасаң, бел: әнкәй васыятенең үтәлмичә калуына син генә гаепле булачаксың!

Фәрит белән Тимергалинең башында мең сорау бөтерелде: Мизхәт барырмы? Теләмәсә, ни эшләргә? Барган суриттә аларны ничек каршылар? Зөбәрҗәт ни дияр? Әти-әнисе риза булырмы? Бу сорауларның күбесенә монда утырып җавап табып булмый, тизрәк Зөбәрҗәтнең үзен күрергә кирәк иде. Моңа күпмедер дәрәҗәдә табигать булышты: өйләдән соң яшенле яңгыр коеп китте, барлык урып-җыю эшләре туктал-

ды, Мизхәт өйгә кайтты. Абыйсы белән җизнәсенең капка төбеннән үк бөтереп алып кысуына ул озак түзмәде, ризалашты. Турысын әйткәндә, Зәбәрҗәтне ычкындыру аның үзе өчен дә башка сыймаслык хәл иде. Ничә еллар буе йөреп, инде бергә булабыз дигәндә, шушындый мәгънәсез, аңлаешсыз аерылышу белән ничек килешмәк кирәк? Әнисе аларның Алабугага китәсен белә иде инде, ул хәерле юл теләп, булачак кода белән кодагыйга сәлам тапшырырга кушып калды...

Алар китүгә, хәл белешергә чордашлары Маһинур белән Разия килеп керде. Чөкердәшеп чәй эчтеләр, үткән гомерләрен искә төшерделәр. Нуриасма аларга сокланып утты. Гомер буе эшли-эшли гарипләнеп беттеләр, үзләре өчен берни дауламадылар, тормыш начар булды, безне кыерсыттылар, без бернинди рәхәт тә күрмәдек, дип зарланмадылар. Зур гәүдәле, алсу йөзле Маһинурның авылда кемгә дә булса каршы сүз әйткәнен белүче юк. Унбиш яшеннән пенсиягә чыкканчы колхозда сыер сауды, пенсиягә чыкканчы алсу йөзеннән тире кипмәде. Өе мунчадан әз генә олырак, шунда кызы белән яши. Түбәсе салам иде. Өченче ел ниндидер семинар була дип урам коймаларын юдырдылар, буяттылар. Шулчакта аның салам түбәсен колхоз шифер белән япты. Кызы гарип. Алтмышынчы елның кышында икесе ат белән эскерт төбенә саламга китәләр. Күз ачкысыз буран чыга. Алар, адашып, бөтенләй икенче якка борылалар. Кызының, аяк-кул бармаклары өшеп, барысын да кистеләр... Аларның ашаганы — ипи, бәрәңге, йомырка, сөт, чәй. Ае-ае белән ит шулпасы авыз итмичә яшәү Маһинурлар өчен табигый хәл. Чөнки сыерның бозавын сл саен саталар, шунсыз өс-баш, кышлык утын, чәй-шикәр юнәтеп булмый. Ләкин иң аянычы — Маһинурның гомер буе таңнан-таңга бил бөгеп, унике сум белән пенсиягә чыгуы иде. Аяклары шеш, кәрәктәй кулларының бармаклары бөгелми. Аның өчен йөрәгенең әрнүенә түзә алмыйча, Нуриасма районга барды, райком секретарена керде. Ничәдер айдан соң Маһинур унҗиде сум пенсия ала башлады. Нуриасма аннан соң Мәскәүгә барырга хыялланды. Нәсимәнең әнисе — Гыйльменур кодагый гел чакырып тора. Аның малае Рафаэль бик зур кеше, ди. Шуның ярдәме белән Кремльгә кереп, Гыйзденисаттиның, Маһинурларның хәле турында сөйләргә, пенсияләрен арттырып кайтырга хыялланды... Тик аның ул уе барып чыкмады... Заманында авылның иң сылу кызы булган Разия көянтә кебек җиргә бөгелде, шулай йөри. Күп эшләүдән көчлек килеп, җене тарта, диләр. Дөрестер, колхозда печән чапса да, сабан сөрсә дә, урман киссә дә, ирләрдән артык кыланды, эшкә ухылдап барып ябышты, егылганын да, үләрен дә белмәде. Аны «Буран Разия» дип йөрттеләр, җенең суырылгач, туктарсың әле, дип сүктеләр. Шулай булды да. Хәзер инде Разиянең кап-кара чәчләре бәсәргән, янып торучы күзләре арыган, сулышын зур авырлык белән, авызын әллә ничә мәртәбә ачып-ябып кына ала... Ике малае да Казанда, әниләрен алып китмәкче дә булып карадылар. Разия якын да килмәде. Менә шулай зарланмыйча, тавыш-тынсыз гына яшәп яталар. Елга бер мәртәбә колхоз ике центнер бодай сатып бирсә, башлары күккә тия, колхозны да, хөкүмәтне дә мактыйлар, дөньялар тыныч, тамак тук, өс бөтен дип шөкерана итәләр... Аларның авырып үз гомерләренә бер мәртәбә дә хастаханәгә дә барырга вакытлары юк. Аларның даруы — җир дә һава, кояш та үлән. Диагноз куеп рецепт та язасы, әллә нинди чыгымнар да тотасы юк...

Нуриасма алар белән сөйләшкәндә шушыларны уйлап утты. Нуриасмалар буыны киткәч, авылда мондый кешеләр калмый инде. Авырыйсыңмы, авырмыйсыңмы, ике-өч көн саен, атна саен бер-береңнең хәлен белешергә керү, тормыш хәлләрен сөйләшеп утыру Нуриасмалар, Маһинурлар, Разиялар, Гыйзденисалар, Мосаллияләр өчен һава кебек зарур иде. Хәзер халык һәркөн каядыр кабалана, чаба, иң якын туганы, терәлеп торган күршесе белән сөйләшеп утырырга вакыт таба алмый, табигатькә чыгып, су буена төшеп узган гомере, башкарган эшләре, кылган гамәл-

ләре, иртәгәсе көне, тормышның мәгънәсе хакында ашыкмыйча, жентекләп уйланырга вакытын кызгана. Коры, жансыз, вак, кабаланучан, әйбергә мөкиббән киткән кешеләр ишәйгәннән-ишәя бара. Барысының да авызында бер сүз: «Ник бусы юк та ник тегесе юк?» Гел бүген белән яшиләр.

Менә алар өчәүләп узган гомерләрен сөйләшеп утырдылар. Бала вакытларда тәгәрәп үскән болыннарын, жиләк-жимеш жыйган әрәмәләрен, урак урган басуларын, чана шуган тауларын күңелләре белән әллә ничә урап чыктылар. Кеше йөрәгә үткәннәрдән кайнарлык алмаса, суына, тупаслана, ә истәлекләр аның тамырлары аша үткән заманнар рухын, ата-бабаларыбыз тормышының шанын алып киләләр. Хәтта үткәндәге кайгы-сагышлардан да йөрәккә төшенкелек түгел, ә бәлки жылылык һәм көч килә... Нуриасма, Маһинур һәм Разия чыгып киткәндә, тәненә хәл керүдән шатланып куйды. Ул хәтта бераз йокымсырап та алды. Кифая яңа сындырып алган әрем себеркесе белән идәнне себерде. Нуриасма әчкелтем әрем исен күзләрен йомып рәхәтләнеп иснәде. Кифая идән юарга әзерләнә башлады.

— Куяным, зинһар юмый тор әле,— диде Нуриасма.

— Нишләп, түти? — Кифая аңа гажәпләнеп карады.

— Идән чип-чиста, әрем исе таралган килеш кенә торсын әле...— Нуриасма тирән итеп сулыш алды да:— Нәсимә кайда?— дип сорады.

— Ул кибеткә генә китте.

— Бик әйбәт алайса, бик әйбәт икән...

Кифая нәрсәгәдер чыкмакчы булган иде, Нуриасма аны туктатты.

— Сиңа әйтәсе сүзем бар, куяным. Болай да сузылды...— Кифаяның курку тулы карашын күргәч, ул көлемсерәп куйды.— Курыкма инде, берни дә юк. Веранданың түрендә бер кечкенә сандык булыр, шуны алып кер әле...

Кифая көчәнә-көчәнә сандыкны алып керде, караватиянындагы ике урындык өстенә утыртты. Ул ачык-яшел төскә буялган, көмештәй елтыраучы калай белән челтәрләп бизәкләнгән иде. Нуриасма Кифаяга кечкенә ачкыч сузды.

— Мә, ачып жибәр әле...

Кифая йозакны ачты.

— Ач сандыкны,— диде Нуриасма.

Кифая калтыранган куллары белән сандыкның капкачын ачып куйды.

— Иң өстәге марляны алып минем юрган өстенә сал әле...

Сеңлесе аның кушканын үтәде.

— Әнә анда кәфенлек булыр. Жиде кисәк. Иң өстәгесен бутамыйча гына ал, нәкъ шул тәртибе белән кабат салырсың. Әнә анысы — фирка, билне буу өчен.

Кифая шикәрдәй ак ситсыдан тегелгән кәфенлекнең бер кисәген каушый-каушый тегеге марля өстенә алып салды. Икенчесенә үрелде.

— Бусы тышкы кат кәфенлек... Ә менә хәзер ала торганың — эчке катныкы. Ул икесе — күкрәкчә белән бөркәнчек. Әйбәтләп куй, буталмасын. Әнә ул кулыңа тотканы — истинжә чүпрәге. Жиде кисәк булдымы?

— Жиләү булды, түти,— диде Кифая лышык-лышык борынын тартып.

— Почмактагы бәләкәй катыргы тартманы ачып, берәмләп барла әле.

— Ачтым...— Кифая куркып кына тартмачыкның эченә бармагын тыкты.

— Кәфен тегергә ике энә, ак кәтүк булыр. Хушбуй белән канәфер дә шунда. Таптыңмы?

— Әйе...

— Кәфен астына канәфер салдырт, хушбуй сибәргә онытмагыз. Яшел чәч мендәрен күрдеңме? Кәфенләгәндә Гыйзденисаттигә бирерсең,

баш астына тыгып калдырыр. Теге кечкенә төендә чүпрәкләр — юганда тотар өчен. Кара аны, онытма!

Нуриасма бераз хәл алды. Мәһинурлар белән дә күп сөйләшкән иде, әллә шул ярамады, тын алуы шактый кыенлашты. Әмма ничек кенә булса да зиһене эшләгән чакта күңелдәгесен Кифаяга җиткерергә кирәк иде. Сеңлесенең бер гадәтен гомере буе яратты Нуриасма: Кифаяга кушылган эш эшләнми калмый иде. Бәләкәйдән үк шулай булды. Нуриасманың әйтәсе сүзләрен Нәсимәгә дә, башкага да түгел, нәкъ менә сеңлесенә әйтүенең сере шунда иде.

Кифая кире урынына салмакчы булып кәфенлекләргә үрелде.

— Сабыр ит әле, куяным, бетмәде,— диде Нуриасма.— Иң четреклесе калды. Һәрберсен алып бар, мин әйткәнне күңеленә беркет. Иң өстәге кәшимир шәл — үзеңә. Кышкы пәлтәм шифоньерда, әр-яңа. Ул да сиңа. Төсем итеп киярсең, җылымны тоеп йөрерсең...

Кифая апасының юрганына йөзе белән капланып үкси башлады. Нуриасма аның иңбашыннан сыпырды, елавыннан туктату өчен катырак сүз эзләде, тик үзенә дә әллә ни булган иде, бер сүз дә дәшә алмады, сеңлесенең туктаусыз дерелдәүче иңбашларына караган килеш хәрәкәтсез ятты. Күпмедер вакыт узгач:

— Йә, ярар, җитте,— диде.

Кифая күзләрен сөртеп башын күтәрде.

— Шәлне алып куеп тор. Гыйзденисатти юар, мин аңа әйтеп куйдым. Теге намазлык — Гыйзденисаттигә. Җәйге пәлтәмне дә аңа бирерсең. Әнә ул чәчәкле ситсы икенче юучыга булыр. Алып куй. Менә шулай. Су салып торучыга кулыңа тоткан алсу товарны бирерсең. Дүрт сөлге — тастар башы тотучыларга. Әзерләп су салучы белән комганны китереп торучыларга әнә шул яшел яулыкларны бирерсез. Өч озын шадра сөлге — гүргә иңдерүчеләргә. Әнә ул кулың белән тоткан товарлар, яулыксөлгеләр — кер юучылар, өй юучыларга. Сабыннарын, кульяулыкларын да хәергә өләшерсез. Сакларга Гыйзденисатти, Мәһинур, Мосаллия, Разиялар килер. Хәдичә белән Рабигатти да керми калмас. Мәһинурга камзулымны бирерсең. Калганнарына — әнә ул ситсылар.

Сандык бушап бетте. Бер почмакта ак чүпрәккә төрелгән төенчек кенә калды. Аны чишкәч, дүрт кульяулыкка төйнәлгән акчалар чыкты.

— Берсендә тиенлек акчалар, бала-чагага бирү өчен. Әнә анысында берлекләр. Йөз илле сум булырга тиеш. Чәчәкле кульяулыкта өчлекләр. Соңгысында бишлекләр. Бөтенесе биш йөз сум. Хәергә дә, башка кирәк-яракка да иркенләп тотыгыз. Берүк кабер казучыларны рәнҗетмәгез. Фәриткә үзем ныгытып әйтеп куярмын. Мине соңгы юлга озатканда, бәндәләр рәнҗеп кала күрмәсен.

Кифаяның инде елаганын-еламаганын аерырлык түгел иде. Шешенеп беткән иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып ул:

— И түтекәем, син бигрәк инде. Шушы кадәр әзерләнгәнсең,— диде.

— Юләр син, куяным,— диде Нуриасма аны әрләгәндәй.— Ил йоласы дигән изге нәрсә бар лабаса.

Сандыкны тутырып бикләп куйгач, Кифая тагын үкси башлады.

— Җитәр инде, куяным,— диде Нуриасма елмаеп.— Үлмим әле мин, курыкма.

— Соңрак әйтсәң дә булыр иде дә, түти, бигрәк авыр бит күңелгә...

— Ә нәрсәсе авыр? Барыбыз да җир куенына керәбез. Үзем әйтергә өлгермәсәм, син аң бул: берүк табутка сала күрмәгез — рөхсәтем юк. Ләхет алып күмсеннәр. Гомер буе җирне яраттым, җиргә тәрәлеп ятасым килә. Чип-чиста ап-ак кәфен белән күмегез мине. Чиста җиргә чиста килеш...

Аның әле Кифаяга әйтәселәре күп иде. Врач белән шәфкать туташы килеп керде дә, сүзе бүленде. Нуриасма көн саен йөрәген тыңлауларга, уколларга битараф карый, хәзер инде ниләр генә кылсалар да, файдасыз икәнен белә. Врачлар йөрәкнең үзенең эчке авазын ишетмиләр дә, аң-

ламыйлар да, аны һәр кеше үзе генә ишетә ала. Йөрәкнең табигатьтән, тормыштан килүче тамырларын юллап табу, дәвалау заманы җитәргә әле, ай-һай, ерактыр.

«Ашыгыч ярдәм» машинасы киткәч, Нуриасма черем итмәкче булды, күзләрен йомды, тик бер генә мизгелгә дә онытыла алмады. Аның уйлары берөзлексез Мизхәт белән Зөбәрҗәт тирәсендә бөтерелделәр. Нуриасма үзен коточкыч зур тәгәрмәчне тау башыннан тәгәрәтеп төшереп җибәргән кеше хәлендә сизде. Аны хәзер туктату мөмкин түгел, ул үз юлына туры килеп теләсә нинди корылманы җимереп-сытып китәчәк иде. «Әллә соң ялгыштыммы?» — дип коты очып уйлап куйды ул. Нуриасма аларны кушарга тели, мәҗбүрили. Васыятем, диде, рәнҗим, диде. Ә алар бәхетле булырмы? Ата-баба нигезенә тамыр җибәрә алырлармы? Юк, ничек кенә бизмәнләсән дә, ирексезләү кирәкми иде. Авылны да иң изге нияттән чыгып өстән бирелгән фәрманнар харап итте түгелме соң? Нуриасмалар да карышып карадылар — мәҗбүриләделәр, сезне бәхетле итәбез, муллык дөньясы ясыйбыз, диделәр.

Ахрысы гел юкка кузгатты ул бу олы әйберне. Аларны ирексезләп, үз өстенә дөньядан тагын бер гөнаһ алып китү ник кирәк? Элекке хатасын төзәтте — Алабугадан Зөбәрҗәтне кайтарды — калганын үзләре хәл итсен...

Авыл инде күптән тынып калды. Нуриасма аны һаман саклап утырган Кифая белән Нәсимәне дә, йокым килә, дип үзе янынннан куды, утны сүндертте. Аралыкта туктаусыз сайраган чикерткә тавышын тыңлый-тыңлый ул тәрәзәдән төшкән ай нуры яктысында берөзлексез үз уйларын сүтте. Күпмедер вакыттан соң, салулаган чана кабат үз эзенә төшкәндәй, аның уйлары баштагы сукмакка килеп чыкты. Нуриасма үзен күпме генә гаепләсә дә, күңел түреннән, каяндыр бик тирәннән килгән икенче бер аваз аларның — Мизхәт белән Зөбәрҗәтнең үзе исән чакта кушылуларын алга сөрә иде. Ни өчен дисәң, Нуриасма бит, төптән уйлап карaганда, аларга үз ихтыярын такмый, ә бәлки ата-бабаларының туган нигезне сакларга, нығытырга дигән васыятен генә үти. Ә ул васыять буыннан-буынга тапшырыла килде, шуны тоту аркасында нәсел агачы яшәде, тармакланды. Димәк, Нуриасманың Мизхәтне мәҗбүр итәргә хакы бар. Кеше ирекле булырга тиеш дисәк тә, ул үзенең тууы белән дә, үлеме белән дә ирекле түгел. Яшәве белән дә шулай. Үсемлекнең тормышы нинди туфракка эләгүеннән торган шикелле, бәндәнең дә йөрәк тамырларына дөнья үзенең кайнап торган канын куа, теге яки бу гамәлләргә этәрә. Юк, хәере белән булсын, Нуриасма гаепсездер, ялгышмагандыр, шулай кирәктер...

Төнге уникеләрдә Нуриасма капка ачылганын, ишек алдына машина кергәнен ишетте. Бераздан Фәрит, Мизхәт, Тимергали үзләре дә керделәр. Алгы өйдә чышын-пышын сөйләштеләр, аннары Фәрит, түр якка кереп, утны яндырмыйча гына аның янына килде. Әнисенең йокламаганын белә иде ул.

— Әйбәт кенә кайттыгызмы, улым? — дип сорады Нуриасма пышылдап.

— Әйбәт, әнкәй. Үзеңнең хәлең ничек?

— Рәхмәт, улым, бер килеш әле...

— Туйга җомга көнгә дип сөйләштек инде...

— Әйбәт булган... Әти-әнисе каршы килмәдеме?

— Башта бераз аптырадылар. Аннары ризалаштылар. Кыскасы, аңлаштык...

— Рәхмәт, улым, ял итегез инде.

## 17

Кайнар кояш астында ашыга-ашыга тамган язгы өч тамчы кебек, өч көн сизелми дә үтеп китте. Ишек алдына озын-озын баганалар утыртылды, такталар кадаклап, брезент корылды, аның эченә лампоч-

калар куелды. Тартма-тартма эчемлекләр кар базы өстендәге келәткә урнаштырылды.

Иртәгә туй дигән көнне, алдан сөйләшенү буенча, кызы Өммекамал белән Мосаллия килде. Нуриасма янына кереп хәл белешкәч, Өммекамал кече якка чыгып китте. Мосаллия Нуриасмадан өч яшькә кечерәк булса да, яшь чактагы кебек җитез иде. Ул шәмәхә бөрчек төшкән күлмәген кигән, ап-ак алъяпкыч бәйләгән, муенына гәрәбә төймәсен таккан. Авылда аш-суга Мосаллия белән аның кызы шикелле оста кеше юк. Шуңа күрә аңа гомере буе колхозда аш пешерттеләр. Мосаллия пешерсә, иске чабатаны да ашыйсың, ди Гыйзденисатти.

— Мосаллия,— диде Нуриасма акрын гына,— малаемның туе да, үземнең соңгы туем да кеше алдында ким-хур булырлык булмасын иде...

Нуриасма аңа туп-туры карады һәм Мосаллия барысын да аңлады.

— Күңелең тыныч булсын, Нуриасма,— диде ул ярым пышылдап.

— Аллага тапшырып, чәкчәк ясарга тотыныйм әле мин...

— Ашыкма, әз генә янымда бул...

Мосаллия, аның ястыгын, одеалын рәтләштергәч, урынына утырды. Алар бер-берсеннән күзләрен алмадылар. Яңадан болай озак итеп утырырга вакыт буламы, юкмы — билгесез иде. Алар бер-берсенең таныш йөз чалымнарын мәңгегә йөрәкләрендә сеңдереп калырга теләделәр. Сүзләр моңа комачаулар иде, шуңа күрә дәшмәделәр, бары тик булдыра алганча елмайдылар гына. Бу сагышлы елмаюга һәммәсе — әйтелмичә калган кадерле сүзләр дә, үтелгән гомер дә, аның ачы газаплары да, шатлык-куанычлары да сыйган иде. Нуриасма — ярар, рәхмәт, дигән мәгънәдә ым кагуга, Мосаллия аягүрә басты.

— Мизхәт чәкчәгенә кактан пар күгәрчен ясарга берүк онытма инде...

— Онытмам, Нуриасма...

Мосаллия кече якка чыкты һәм шул мизгелдән барлык төр аш-су пешерү мәшәкатьләрен үз кулына алды. Ике көнгә өйдә мәхшәр купты. Беренче көнне чәкчәк, кош теле, өстәлгә куярга кәрчә-мәрчә пешереп бетерергә кирәк иде. Дистә-дистә йомырка сытылды, былт-былт китереп агач кашык белән тугланды, җилпуч-җилпуч он иләнде, чаж-чож май эреде, әллә ничә урында куна-куна камыр басылды, камыр эченә салырга банка-банка варенье ачылды, савыт-савыт суган туралды. Тирләгән маңгайлар, кызарышкан битләр, сызганылган беләкләр, түгәрәк арт саннар дер-дер хәрәкәтләнде, туктаусыз йөгереште...

Эшнең кызып кына килгән вакытында Бәрия килеп керде, җиңнәрен сызгана-сызгана Нуриасма янына узды.

— Булышырга дәштермәгәнсең дә, җиңгәчәй,— диде ул исәнлек-саулык сорашкач.

— Әллә туйга әйтмәделәрме? — диде Нуриасма.

— Әйттеләр дә. Әзерләшергә дә кирәк бит.

— Әзерләрләр,— дип куйды Нуриасма төксе генә.

Бәрия кече якка чыгып булышырга тотынса да, Нуриасманың аңа күңеле эри алмады. Ул бер Нуриасманы гына түгел, авылның барлык халкын рәнҗетте. Сугыштан соң авыл өчен кием дисә киеме, ашыйм дисә ризыгы булмаган иң авыр еллар иде бу. Бәрия исә халыкның әнә шул мохтаҗлыгыннан файдаланды. Урта Азия якларыннан чүпрәк-чапрак алып кайтып, биш-алты бәясенә сатты. Җитәкчеләр белән Бәрия уйнадыкөлде, кирәк-ягракларын ташып торды, ә ачлыктан-ялангачлыктан җәфа чигүче халыкны күзенә карап алдады, кемнең кемлеген исәплән тормастан, җиде кат тиресен тунады. Киеме кәттә, борыны күктә булды. Теләсә нинди ирне аздыру аның өчен мөрәвәт саналды. Хатынлы ирләр белән тотылган саен, Сәгыйдулла аны эт итеп кыйнады. Тик ул мәче кебек яшәүчән иде, башы-күзе кара янып бетсә дә, берничә көннән, бизәнеп-ясанып, кашын-күзен уйнатып, ир-ат тирәсендә бөтерелә баш-

лый иде. Ул оялу, тәүбә итү дигән нәрсәне белмәде, торган саен оятсызрак, мәрхәмәтсезрәк була барды.

Сәгыйдулла Нуриасмага өйләнгәч, Бәрия әнисен аңа каршы котыртты, аларны өйдән чыгып китәргә мәҗбүр итте. Әнисе параличланып егылгач, аны юньләп карамады. Нуриасма бианасын кызганып үзләренә алып кайтты, ун елдан артык урын өстендә килеш тәрбия кылып соңгы юлга озатты.

Сәгыйдулла җан бирергә ятканда, Бәрия Казанга чыгып китте, җирләп бер атна торгач, кайтты, үксеп-үксеп елаган булды. Нуриасма аның кайнар яшьләрен үз күзләре белән күрсә дә, моның ихлас булуына барыбер ышана алмады...

Бер кышны Бәрия теге басудагы каеннарны төнлә кистереп үз ихатасына ташытты. Иртәнгә биш төп каен утырып калган иде. Каяндыр килгән исерек ирләр ул каеннарны турап, ярып, өеп тә куйдылар. Халык бик шаулагач, милиционер Хәеров аның ихатасына килә, тик шуннан чыга алмый, өендә куныш кала һәм шуның белән вәссәләм! Авыл бөтенесен дә хәтерли, авыл Бәрияне кичерә алмас. Шулай булгач, Нуриасманың ничек җаны эресен соң?! Аның теге дөньяга йөрәгендә кара кан төйнәп тә китәсе килми, Бәрияне кичерә дә алмый. Тормыштан киткәндә, кешеләр гадәттә олы җанлылык күрсәтәләр, фани дөньянықын ахирәткә алып чыкмаска тырышалар, әгәр алып чыгалар икән, бу гайре табигый хәл санала. Бәриянең халыкны алдавын гафу итә торган түгел, бу инде аның яшәү мәгънәсенә куләгә төшерер иде...

Кичкә кош телләре, пәрәмәчләр, дучмаклар, күмәчләр пешерелде, ике поднос чәкчәк бизәлде, аларның һәркайсын хатын-кызлар Нуриасмага алып кереп күрсәттеләр, аның мактавын һәм рәхмәтен ишетеп куандылар.

Кунаклар кайткач, Хәдичә кереп чыкты. Ул, Фәритләр, Тимергалиләр өйдә булганлыктан, озак тормады. Нуриасма аның олы бер уй белән кергәнлеген күз алмаларының тынычсыз биешүеннән үк аңлады. Хәдичә туктаусыз тамак кырды, кулларын куяр урын тапмады, сүзенең очы-очка ялганмады, ахырда ул: «Иртәгә керермен әле»,— дип чыгып китте. Иртүк торасы булганга, барысы да караңгы төшү белән яттылар. Нуриасманың гына иртүк торып Алабугага ашыгасы да, аш-су әзерлисе дә, башка мәшәкате дә юк иде. Ул үз уйлары белән япа-ялгыз калды. Хәдичәнең ник керүен сизенде ул. Дөньялыкта болай гына аерылыша алмыйлар иде алар.

Аны уйлары ерак елларга алып китте...

Сәгыйдулла белән Нуриасманың өйләнешүе әллә ничек кешечә булмады. Гадәттә, егет белән кыз кичке уеннарда, аулак өйләрдә очраша, дуслаша, ачуланыша, кабат татулаша. Аларга бу тәтемәде. Сугышка китәсе елны Сәгыйдулла кичә-мазардан кайтканда Хәдичә белән Нуриасманы култыклап кайткалады, шаяртып сөйләште, тик болар һәммәсе дә олы кешенең бала-чаганы үртәве генә иде.

Сугыш хатын-кызлар, малай-шалайлар җилкәсенә барлык авырлыкларын өйде. Нуриасма сабан сөрде, чәчү чәчте, утау утады, ашлык сукты. Әле кавырсыннары да катып җитмәгән кызларны кыш көне ерак урманга кудылар. Бер елны язын кар астыннан җыелган ашлык белән агуланып, кырылып бетә яздылар. Алар өч бала иде, Нуриасма белән Кифая аякка бастылар, ә энеләре авыз-борыныннан кан китеп үлде. Озакламый кара пичәтле конверт әтиләренең вафатын хәбәр итте. Йортка кара кайгы, ятимлек сагышы иңде. Шул елны Горький шәһәреннән әниләренең Сәхипҗамал апасы кунакка кайтып төште. Нуриасма теге чирдән һаман мантый алмый иде. Авыр эш бу баланы үтерәчәк, миндә бераз котаер, ялгыз башыма иптәш тә булыр дип, ул Нуриасманы үзе белән алып китте, бер заводка эшкә урнаштырды. Әмма кызның бәхетсезлегенә каршы, Сәхипҗамал апасы йөрәге ярылудан кинәт вафат булды, Нуриасманы фатирдан чыгардылар. Ул заводта бергә эшләүче Газия исемле

кызның фатирына (ул бер яһүд карчыгында тора иде) күчте. Нәкъ шул чакта Сәгыйдулладан беренче хат килеп тә төште. Нуриасма аны сәерсенеп, нииндидер бер курку белән ачты. Сәгыйдулла абыйсы үзенең хат язуына аптырамаска кушкан, адресыңны Хәдичәдән алдым дигән, автоматчылар ротасында сугышуын, немецларны үз өннәренә таба куууларын язган. «Нуриасма үскәнем, акыллы бул,— дигән.— Безнең җиңүне, исән калуны телә, мин сиңа күчтәнәчләр алып кайтырмын»,— дигән. Нуриасма хатны елмаеп укыды.

Шундук кәгазь-каләм алып өстәл артына утырды, әмма нишләптер җавап яза алмады. Ни язсын инде ул аңа? Берничә көн ул хат язарга уйлап йөрсә дә, оялдымы шунда, нәрсәседер карышты, булдыра алмады, шул килеш онытты. Айдан артык үттеме-юкмы, тагын хат килеп төште. Бусын аптырап түгел, ниндидер оялу белән үзен гаепле сизеп ачты Нуриасма. Ут эчендә йөргән кешегә кош теле кадәр җавап язып салмау әйбәтлек түгел иде. Сәгыйдулла абыйсы беренче хатын телгә дә алмаган, фронт хәлләрен язган, акыллы булырга, яхшы эшләргә, авылдашларны онытмаска чакырган. Хатның: «Исән-сау кайту насыйп булса, мин сезне әле тагын чана шуарга алып менермен, үскәнем»,— дигән соңгы юллары Нуриасманы әллә нишләтеп җибәрде. Йә алла, Сәгыйдулла абыйсы да хәтерли икән бит ул көнне! Нуриасманың җиденче класста укыган елы иде ул. Дәрестән кайтып ашауга, Бәрия йөгереп керде.

— Хәдичә апа белән сине Сәгыйдулла абый чана шуарга чакыра,— диде ул.

Бәрия беренче класста укый, абыйсы ат караучы булып эшли иде. Өчәүләп Сәгыйдуллага ияределәр. Әллә нинди матур көн иде ул. Ябалак-ябалак кар ява. Тып-тын. Кар бөртекләре, ник мине күрмисез, ник мине тотмыйсыз дигәндәй, шәлләргә, якаларга, керфекләргә, иреннәргә куналар, биткә кагылып китәләр. Дөнья каен кәүсәсе төсле аклы-каралы. Өйләр, коймалар, абзар-кура, агачлар, мал-туар юньләп күренми, барысы да чуар пәрдә эчендә эри бара. Ындыр артындагы зур өянке дә, тау да сөткә батыргандай, аклык диңгезенә чумганнар, шәүлә төсле урыннары гына шәйләнә. Дөньяда туктаусыз коелучы шушы ак яфраклардан башка берни дә юктыр кебек. Күкрәкләргә ана сөте булып пакьлек, сафлык иңә, күзләргә аклык, яктылык тула... Сәгыйдулла абыйлары алга, Хәдичә белән Нуриасма уртасына Бәрияне утырта да, чананы таудан аска этеп җибәрә, кайчакта чананың артына тезләнә дә аларның өчесен дә кочаклап ала. Алар төшкәндә колакта җил сызгыра, һавада туктатып калгандай иренеп кенә, бер-берсенә тия язып тирбәлүче исәпсез-хисапсыз күп мамык кар бөртекләре битләргә ышкылып кала, күз-керфекләргә, ерылган авызларга керә. Әллә ничә мәртәбә чана салулап, көлешә-көлешә, чыр-чу килеп тәгәрәделәр. Шулай берсендә Нуриасманың бите Сәгыйдулланың кайнар битенә туры килде. Аның бөтен тәненә ниндидер шатлыклы, җиңел кайнарлык килеп сарылды. Бу кайнарлык беренче мәртәбә аның һәрбер тамырын кымырҗытты, үзен исертте, шул ук вакытта ул күптән көтелгән, янда гына йөргән, бераз гына таныш та кебек, аның дулкыны инде бөтен барлыгына, йөрәгенә тулган, тик хәрәкәткә генә килә алмыйча торган иде. Менә хәзер ул кымшанган, шуның куанычыннан туктаусыз көләсе килә иде. Нуриасма торырга уйламады, һавадан төшүче кар бөртекләренә караган килеш көлде дә көлде... Шунда Сәгыйдулланың йөзе астан аңа таба якынлаша башлады. Нуриасма аның ап-ак тешләрен, кара калын кашларын, карлы бүреген, сәер елтыраучы күзләрен аермачык күрде һәм ниндидер кыргый көч тәэсирендә чырыйлап читкә тәгәрәде. Бу бер мизгелдә генә булды, ләкин ул мизгел бөтенваклыклары белән аның хәтерендә мәңгегә береген калды һәм бүтән кабатланмаячак иде. Ул тәүге мәртәбә уянуы белән, шул чактагы җиңел һәм шаян, саф һәм пакь кар бөртекләре белән, чана шуучы бала-чагаларның язгы тургайлар кебек чыр-чу килүе белән, шуларның бөтенесен бергә җыеп, Сәгыйдулланың кайнар бите аша «ә» дигәнчә барлык тамырларга

таралуы белән, тыштагы ак салкынлык эчендә кайнар ялкын булып леперләве белән аның гомерендә дә, җир йөзендә дә мәңге кабатланмаячак иде. Нуриасма, әлбәттә, бу хакта уйламады, аның әле моңа якынаерлык тормыш тәҗрибәсе юк иде. Ул, ник икәнен дә белмәстән таудан түбән йөгерде, үзләренең ындыр читәне аша бәрәңге бакчаларына сикерде. Аның бар дөньяны яңгыратып җырлыйсы, дер селкетеп биисе, сикерәсе, чабасы, тәгәри-тәгәри мәтәлчек атасы килде. Шулчак ул җәйге яңгырдан соң гына була торган яшен исен тойды... Әллә язгы бөре, чәчәк исе идеме бу? Юк, бөтенесенеке бергә бугай. Ашыкмыйча гына бер-берсенә ышкыла-ышкыла төшүче кар бөртекләренең эчендә ләйсән яңгыры исе, яшен яктылыгы, бөре, чәчәк, башак исләре ияреп төшә иде. Нуриасманың йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып дөп-дөп типте, тирә-юньне күмгән ак тынлыкта аның тавышы аермачык ишетелде, әйтерсең лә барлык галәм, хәрәкәтеннән туктап, тып-тын калып, шуны тыңлый иде. Нуриасма үз-үзен белештермичә кабат тауга йөгерде...

Әнә шул көннән бу серле, аңлаешсыз, әмма әйтеп бетергесез татлы бу кайнар дулкын канга, йөрәккә сеңде, әле бер чакта, әле икенче чакта йә ургып килеп чыкты, йә сак кына яшерен кыймылдап куйды. Ак кар бөртекләре белән шаяра-шаяра әлеге чана шуу аларның тормышында тәүге һәм соңгы мәртәбә булды. Сәгыйдулла сугышка китте. Нуриасмалар яз көне мәктәптә имтихан тапшырдылар. Балалык бетте, колхозда эшләү башланды.

Сәгыйдулланың икенче хатындагы: «Тагын чана шуарга алып барырмын, үскәнем»,— дигән сүзләр аның йөрәгендә әнә шул хатирәне яңартты. Аңа шул көн гомеренең иң бәхетле мизгеле булып тоелды. Кем белә, бәлкем ул чынлап та шулайдыр. «Кешенең бәхете ак кар кебек матур булып күренә дә эреп юкка чыга микәнни?— дип уйлады Нуриасма. Аны ничек озайтырга, ничек кабатларга? Ни өчен газаплар, җәбер-золым бәндәләрне туктаусыз газаплый соң? Әтисенең, энесенең гомерләрен өзгән бу сугыш нәрсәгә? Күпме адәм бүген кан-яшь эчендә ята, күпме адәм Нуриасмалар, Газиялар кебек туган туфракларыннан, газиз әниләреннән читтә газапланып гомер кичерә.

Хат аның өчен шул газапларны оныттыручы, шатлык китерүче бер тылсымлы көчкә әверелде. Бәлкем Сәгыйдулла абыйсы өчен дә аның хатлары шулай ук кирәктер? Аңа мондагыдан мең мәртәбә кыенрак, куркынычрак түгелмени?

Һәм Нуриасма беренче җавап хатын язды. Тау шуганны син дә онытмагансың икән, диде, кар бигрәк ак булып, күс булып, эре булып яуган иде, диде. Өченче хатында Сәгыйдулла шул чакта кайсының ниләр эшләгәнен, ни дип кычкырганын, кемнең ничә мәртәбә егылганын, Хәдичәнең аягын авырттырганын, Бәриянең елап кайтып китүен көлке итеп язды.

Хатлар акрынлап башка төс ала бардылар. Сәгыйдулла әле егетең бармы соң, анда шәһәрдә танцыларга йөрисеңдер, күңелледер, дип язды. Беркая да чыкканым юк, икешәр смена эшлибез, танцы кайгысы юк дигән җаваптан соң, ярар, сугыш беткәч, авылга кайткач, мин сине вечерларга, кичке уеннарга үзем алып чыгармын, үскәнем, дип язды. Аннары пилоткасын кырын салып, медальләрен, погоннарын балкытып, елмаеп төшкән фоторәсеме килде, аныкын да сорады. Нуриасманың фотосын алгач, аның искиткеч чибәрләнүен, үсәнлегән, җиткән кыз булуын мактап язды, мондый кызның табан асты туфрагы булсаң да, оят булмас, дигән иде. Бу юлларны укыганда, Нуриасманың йөзе уттай янды, аңа рәхәт тә, куркыныч та булды, ниндидер билгесез әйбер, ул ничә еллар буе үзенә якын китермәгән әйбер аңа кире кага алмаслык, чигенмәслек рәвештә якыная, аны туктату мөмкин дә түгел, Нуриасма язмышына буйсынган, аны туктатырга омтылмый да иде кебек. Шулай да ул: «Сәгыйдулла абый, миңа әллә нинди сүзләр язма әле, яме»,— дигән җавапны юллады. Ә аңа каршы турылыгы, рәхимсезлеге белән куандыр-

гыч һәм якынлаша баруы белән куркыткыч җавап алынды: «И, күршекәем! И, Нуриасма үскәнкәччәем! Андый сүзләрне мин сиңа күптән әйтергә тиеш идем. Мин бит сине яратам! Авылда чакта мин сине үскәнем итеп яратсам, хәзер җиткән кыз буларак яратам. Шулай булмаса, синең адресыңны юллап хат язар идеммени?!»

Бу сүзләр, аның йөрәк кылына кагылып, бөтен барлыгына якты моң, кайнарлык тараттылар.

Аһ, ул тилмереп көткән көн! Килде ул көн — ниһаять, бетте сугыш. Димәк, авылга да кайтарачаклар. Ләкин әнисе белән Кифая, кайтырга берүк ашыга күрмә, монда тормышлар әле бик авыр, дип хәбәр салдылар. Сәгыйдулла исә июнь башында килгән хатында: мин исән, синең янга кайтам, өйләнешик, дип язды. Ул бу вакытта Нуриасманың инде бала күтәреп йөрүен белми иде, әлбәттә. Әйе, тормыш катлаулы, Нуриасманың җаны кебек кадерле, әле бер генә атналык Фәрите бар иде. Ничек язарга моны Сәгыйдуллага? Ничек карарга аның күзенә, ничек аңлатырга, ничек акланырга? Бу сораулар һәр көн, һәр сәгать аның җанын телгәләделәр...

Газия бер өер егетнең башын әйләндерде, үртәде, алдады, теләсә кайсы белән үбеште, теләсә кайсы белән кунарга китте. Нуриасманы да чакырды, иярмәгәч, юләр, үкенерсең әле дип тиргәде. Нуриасма үзенең Газиядән өстен калуына куанып яшәде. Башкаларның түбән төшүе — аларның үз эше, ә менә ул үзе ничек кенә булса да саф калырга тиеш дип уйлады. Ләкин Газия балага узгач, йөри торган егете моны сизенү белән юкка чыкты, Нуриасманы яшен суккан кебек булды. Ул бит моның яхшылык белән бетмәсен белеп торды, күреп торды, үзе читкә китте, ә Газияне йолып кала алмады, аңа бер-ике мәртәбә әйтү белән чикләнде. Газия аңа нәфрәт белән, җикереп җавап биргәч, кара коелгач, бер сүз дә әйтмәс булды. Үзенең читкә тайпылуын, саф булып калу дип уйлавы белән ул тирән ялгышканлыгын соңыннан, эш узгач кына аңлады. Газиянең баласы үзендә калгач кына...

Хаты артыннан Сәгыйдулла үзе дә кайтып төште. Йә, хода, Нуриасманың аның белән очрашканда кичергәннәре! Дошман пулясы каршында калтыранмаган Сәгыйдулла урындыкка лып итеп утырды, бик озак телен әйләндереп сүзен әйтә алмады.

— Нуриасма, син кияүгә чыктыңмыни? — дип сорады ул ишетелеришетелмәс тавыш белән.

— Юк, болай гына, — диде Нуриасма ут булып янган йөзен кая куярга, күзләрен кая яшерергә белмичә.

«Бу баланы Газия тапты, ләкин мин аны коткарып калдым, бала хәзер минеке!» — дип ничек әйтәсең?!

Алар шактый сүзсез утыргач, Сәгыйдулла болай диде:

— Мин сине яратам, өйләнешик.

— Син мине бала белән алырга риза буласыңмыни?

— Баланың ни гаебе бар, Нуриасма?

— Син ичмасам сорашыр идең!

— Сорашмыйм. Теләсәң, үзең сөйләрсең. Теләмәсәң, беркайчан да бер сүз дә сорамам.

Һәм алар өйләнешеп яши башладылар. Ел ярымнан авылга бала күтәреп кайтып төштеләр. Фәрит бик ябык, кечкенә, чирләшкә иде, аның яшь ярымлык малай икәнен беркем дә белмәде. Сәгыйдулланың әнисе Дөррикамал Фәриткә шикләнеп карады, бу баланың бер генә җире дә безнең нәселгә тартмаган, дип, Нуриасмага шиген белдерде, әмма Сәгыйдулласы каршында бу хакта авыз ачып ләм-лим бер сүз әйтмәде. Фәрит аркасында булса кирәк, ул баштан ук Нуриасманы яратмады, кызы Бәрия белән аңа каты-каты бәрелде, җәберләде, тик Нуриасма дәшмәде, чөнки ул үзен бианасы каршында гаепле дип санады. Бәрия әле баланың Сәгыйдуллага охшаган-охшамаганлыгын аерырлык түгел, аның мондый теләге дә юк иде.

Авылга кайту белән Нуриасма фермага Хәдичә янына бозау карарга керде. Сәгыйдулланы бригадир иттеләр. Хәдичәнең әтисе дә, ире дә сугышта үлгән, ул сукыр әнисе белән икәүдән-икәү генә яши иде. Сугыштан кайткан солдатлар яучы җибәреп карасалар да, ул әнисен калдырып кияүгә чыкмады, ә йортка керүче табылмады.

Авылга кайтканда ук Нуриасманың дүрт айлык көмәне бар иде инде. Бервакыт йөрәге авыртып, Сәгыйдулла хастаханәгә алып баргач, аңа бала табарга ярамый, диделәр. Ул каршы килде.врачлар яшермәделәр, исән калуың икеле, диделәр. Нуриасма моны Сәгыйдуллага әйтмәде. Бәбиләренә ике атна кала Кифаяга барысын да сөйләп бирде, әнисенә әйтмәскә кушты. Кифая әле кияүдә түгел иде. Баланы барыбер табам, диде ул аңа. Әгәр мин алай-болай булсам, Сәгыйдуллага кияүгә чыгарга тырыш, чыга алмасаң да, баланы ташлама, диде. Сәгыйдулланы да, бианасын да шатландырып малай туды. Нуриасма исән калды. Аңа Шәрифҗан дип исем куштылар. Өй эче яктырып, җылынып киткәндәй булды. Ләкин бәла шактый соңрак, бөтенләй көтелмәгән-уйламаган җирдән килде.

... Сәгыйдулла белән тора башлаганда, ул теге чактагы кайнар һәм серле тойгының янаруын, дәртләндереп үз гәүдәсендә уйный башлавын сизгән иде. Аннары ничектер тормыш бертөрлегә әйләнде, куанычы-шатлыгы кимеде. Ярата идеме ул Сәгыйдулланы? Белми. Аңа тартылган чаклары булса да, сиздермәде, яшерде. Аңа Сәгыйдулланың «үскәнем» дип дәшүе ошый, үзе дә «абый» дия иде. Ирен кысып кочаклыйсы, үбәсе, бөдрә чәчләреннән сыйпыйсы килгән чаклары булса да, ул аларның һәммәсеннән дә үзен-үзе тыйды, әлеге теләкләрен эченә бикләп: «Мин аны яратам бит»,— дип яшерен генә куаныч тапты.

Сәгыйдулласы хис-тойгыларын белдерә, аны иркәли башласа да, ул, эченнән әйтеп бетергесез рәхәтлек кичерүенә карамастан, шуны яшерде, иренә юри битарафлык күрсәтте, гыйшык-мыйшык уйнау кебек нәрсәләрдән өстен торучы зат булып кыланды, аны читкә тибәрде.

Мондый хәл озак дәвам итә алмады, бәла килде. Аның килүенә Нуриасма үзе сәбәпче иде. Тик ул моны бик соң аңлады...

Әүвәл ул Сәгыйдулланың үзенә суына башлавын сизде. Тора-бара ире эштән бик соңарып кайтты, йә булмаса фермалардан, складлардан урыйм дип, кичләрен юкка чыкты. Нуриасма боларның берсен дә игътибарга алмады. Аның ферма мәшәкатьләре белән тулы үз тормышы бар иде. Бианасы: «Шул бозауларың янында дөмегәсең инде», дип әрләсә дә, Нуриасма өйгә кайткач, Фәрите белән Шәрифҗанын әз-мәз булса да иркәләү әмәлен тапты, ә Сәгыйдулласына җылы сүз катарга дәрте дә, вакыты да булмады. Алар икесе ике якка чыгып киттеләр, икесе ике яктан кайтып керделәр, ике вакытта утырып ашадылар, ике яктагы урынга ятып йокладылар. Бу Нуриасма өчен табигый тоелды, аның күңеле шатлык кичерә, барыбер дә ул бәхетле, аның ике баласы, ире, авылда күреп сөйләшергә, барып булышырга әнисе белән сеңлесе, рәхәтләнеп эшли торган эше бар иде. Бу инде кан-яшь түккән сугыш еллары түгел, ирләр кайтып төшкән, халык арткан, балалар туа башлаган дәвер иде. Күңелдә тормышлар яхшырып китәр дигән өмет-шатлык яши иде. Нуриасманың йөрәк астында инде кызының йөрәге тибә иде...

Менә шундый чакта ул үзен тетрәтәчәк көн якынлашадыр дип уйламады да. Чөнки һәммәсе әйбәткә таба бара, һәммәсе дә шуңа юралган иде...

Җәйге кич иде бу.

Сәгыйдулла дежур көнем, фермаларны әйләнәм, дип чыгып китте. Нуриасма кайтмый калган бозауны эзләп тауны урагач, Хәдичәләрнең бакча артына төште. Анда зур-зур өянкеләр утыра, аларның тирә-юнен ерып чыккысыз әрекмән, әрем, алабута, тиле бәрән орлыгы, эт эчәгесе каплаган иде. Шуларны саклана-саклана ерып атлаганда, ул ике кеше шәүләсе күреп туктап калды. Әле сүнеп тә бетмәгән кичке шәфәкъта

аларның берсе ир-ат, икенчесе хатын-кыз икәне шәйләнде. Нуриасманың йөрәге жу итеп китте. Шәүләнең берсе — Сәгыйдулла иде. Хатын-кызын башта Нуриасма танымады. Иелеп берничә адым атлады...

— Җаным, бәгърем, багалмам, бердәнберем,— диде хатын-кыз һәм Сәгыйдулланың муеннарына сарылды, аны кат-кат үбә башлады. Бу — Хәдичә иде...

Әллә саташаммы дип уйлады Нуриасма.

— Нинди тәмле син, Хәдичә,— диде Сәгыйдулла.

Аның еш-еш сулаганы ишетелде.

— Тәмле булсам, аша, мәнә мин синеке, йә аша! — диде Хәдичә чытлыкланып.

— Чү, юләр, ишетүләре бар! — Сәгыйдулла аның иреннәрен үзенең иреннәре белән томалады...

Нуриасманың йөрәге чәнчешеп куйды, ул эшнең нидә икәнен хәзер генә аңлады. Ул ни алга, ни артка бер адым да атлый алмады, әйтерсең лә аякларын җиргә кадаклап куйганнар иде. Нуриасма хәтта тын да ала алмады, әйтерсең, кемдер аның бугазыннан буды, күзләре хәрәкәтсез калдылар, куллары да икесенә ике потлы гер аскандай асылынып төштеләр. Ул таш сын шикелле басты да катты. Бөтен тәненә ниндидер ялкын капты, авызы, теле кипте. Әйтерсең, ул бу дөньяны ташлап, аңлаешсыз, баш җитмәслек, үлс дөньяга күчте. Ул аның моңа кадәрге тормышын еракта калдырды, юк итте һәм Нуриасманы үзенә суырып алды...

Менә Хәдичә, ягымлы көлеп, Сәгыйдулланы җиңелчә генә этеп җибәрде дә юан өянке кәүсәсе артына яшеренде.

— Тота алсаң — мин синеке, ашарсың. Йә, тот! — диде ул мут көлеп.

Сәгыйдулла аны тотмакчы булды, тик Хәдичә төлке житезлеге белән чытлыклана-чытлыклана кәүсәне әйләнеп йөрде. Сәгыйдулла тота алмагач, ахырда ул үзе кинәт каршысына килеп чыкты һәм аңа сарылды, алар бер тән булып беректтеләр...

— Юк, котыла алмыйм мин синнән, мәңге котыла алмыйм...— дип пышылдаганы ишетелде Сәгыйдулланың.

Хәдичә исә бик ягымлы итеп:

— Ә нигә котылырга? Без кемгә комачаулыйбыз? Мин бит сине тартып алырга җыенмыйм.

— Ышан сиңа...

— Ә тартып алсам? Нуриасманы яратасыңмыни?

— Бүрәнәне яратып буламы соң? — диде Сәгыйдулла бераз дәшми торганнан соң.

Нуриасманың түбәсенә китереп суккандай булды, тамагын нидер яндырды, тик ул елый алмады...

Алар тагын бер тән булып беректтеләр. Хәдичә кайнар пышылдап:

— Әйдә, җаным, әйдә...— диде.

— Бар, син алдан атла...

Менә Хәдичә тавыш-тынсыз гына өйләренә йөгерде, Сәгыйдулла аның артыннан иярде. Нуриасма мөлдерәп, тораташ катып тора бирде.

«Сәгыйдулла, тукта!!!» — дип кычкырасы килде аның, әмма теле әйләнмәде. Шулай да ниндидер көч ярдәмендә аякларын җирдән аерды һәм алар артыннан ташланды. Куралар, агач ботаклары аның битләрен сыдырды, ул боларның берсен дә сизмәде, ник, ни өчен икәнен дә белмичә, алар артыннан иярде. Менә Хәдичә үзләренең бәрәңге бакчаларындагы мунчаларына кереп юк булды. Нуриасма бакчадан түгел, тыкрык читәне буеннан иелеп, ире артыннан атлады. Сәгыйдулла бакча уртасындагы ызаннан кайтты да мунчага кереп юк булды, мунча ояндысының ишек келәсе чыкылдап эленде. Шул чыкылдау тавышы Нуриасманың колагынна мылтыктан аткан кебек ишетелде, ә ядрәсе йөрәгенә керде. Ул шашынып калды. Читәннән сикереп төшеп, мунчага таба йөгермәкче булды. Әллә читәнгә менәрлек хәле юк иде, әллә моның

ярамаганлыгын аңлау аны тыеп калды. Юк, хәзер үк авыл Советы председателе Шакиржанов абыйны алып килергә. Андый чакта хатын-кызлар шулай эшләделәр. Ул Шакиржановка йөгерде. Аягында иске галош булуын да, өстендә ертык күлмәк, башына яулык бәйләмәгәнен дә уйлап тормады. Шакиржановлар авылның икенче башында ук яши иделәр. Нуриасма анда кайсы яклап барып житкәнен — күпер ашамы, әллә тар тыкрыктан төшеп басмадан чыкканмы, берсен дә хәтерләмәде. Башында: «Алар бергә, алар икесе мунчада...» дигән уй гына кайнады, бүтән берни дә юк иде. Нуриасма Шакиржановларның капкасына килеп орынуга, һау-һаулап эт өрә башлады. Шунда гына ул бераз айнып киткәндәй булды. Алып бардың ди, халыкка фаш иттең ди. Йә шуннан? Кемнән көләләр? Күпме хатыннар шулай ирләрен чит түшәктән сөйрәп алып чыктылар һәм бары үзләре генә көлкегә калдылар. Ул ни үле, ни тере килеш әнә шуны уйлады. Капка төбендә бик озак басып торды. Ә эт өрде дә өрде. Ул арада өйдә ут алдылар. Ишек ачылды һәм Шакиржановның:

— Әллә кеше бармы? — дигән тавышы ишетелде.

Нуриасма читән артына чүгәләде, иреннәрен тешләде һәм бер сүз дә дәшмәде. Шакиржанов кереп китте. Нуриасма шунда гына очкылык тоткандагыдай коры үксү белән үксергә кереште һәм өйләренә сөйрәлеп кайтып китте.

Капкадан кергәндә, ниндидер бер өмет чаткысы да кабынып алды: «Бәлки Сәгыйдулла өйдәдер?» Ләкин ул кайтмаган иде. Нуриасма, тып-тын гына кереп, сәкегә — балалары янына ятты, күзенә йокы кермәде, йөрәге туктаусыз чәнечте.

Сәгыйдулла ярты төн үткәч кенә кайтты. Тып-тын гына керде дә ятты.

Нуриасма ул төнне керфек тә какмады. Аның белән уйнап үскән, бергә эшләүче Хәдичә... Берлиннан ук урап, авылга, әнисе янына да кайтмыйча, Горький шәһәренә килеп, баласының кемнән икәнен дә сорамыйча, Нуриасмага берсүзсез өйләнгән Сәгыйдулла... Ни булды? Хәдичә кем? Сәгыйдулла кем? Нуриасма кем? Алар ни өчен икәүләшеп Нуриасмага хыянәт иттеләр?

Ул бит бер гөнаһ та эшләмәде, ни берсе, ни берсе белән телгә килмәде, аларның икесе өчен дә җанын ярып бирергә әзер булып яшәде, Хәдичәдән сер сакламады, ул ике айдан артык больницада ятканда, сукыр әнисен, барлык йорт эшләрен, фермада бозауларын карады.

Ни өчен болай булды соң?

Бәлкем Сәгыйдулла белән Хәдичәнең бу очрашуы беренче мәртәбә генә, ниндидер ялгышлык кына булгандыр? Ул иртән фермага киткәндә Сәгыйдулла караватта ятып калды. Нуриасмага ул йокламый, аның чыгып китүен көтеп ятадыр кебек тоелды.

Фермада Хәдичәне күргәч, йөрәге сикерә, тәне калтырана башлады. Ул бу халәтен сиздермәскә тырышты, аның белән гадәттәгечә исәнләште. Ләкин тавышы коры, төссез, үзенеке түгел иде. Хәдичә моны шундук сизде.

— Әллә салкын тигерденме, малай? — диде ул саран гына елмаеп.

Нуриасма аның бераз агарыбрак киткән йөзенә җентекләп күз ташлады, аларны фаш итүче билгеләр эзләде. Аның туры карашыннан Хәдичәнең битләренә кызыллык йөгерде, озын кара керфекләре тетрәнеп киттеләр дә, ул башын аска иеп, бозауларның астын чистартырга кереште. Нуриасма көне буе, һәр минут Хәдичә белән Сәгыйдулла турында гына уйлады, ул аен күпме генә онытырга, читкә куарга теләсә дә, көче җитмәде. Бозаулары белән элеккечә сөйләшә, аларны иркәли башласа, үзе дә сизмәстән, бер урынга баскан килеш туктады да калды. Аннары, эчтән кемдер кычкырып уяткандай, дертләп китте һәм эшенә кереште. Йөргәндә дә, утырганда да, ашаганда да ул бары шуны турыда гына уйлады, башы таш булып катты. Сәгыйдуллада бер

үзгәреш тә сизелмәде. Артык сүз сөйләшмәде, кайтты, ашады, ял итте, чыгып китте.

Теге көннән соң күпме үткәндер, Сәгыйдулла кояш баегач, печәнлекне урап кайтам, дип чыгып китте. Нуриасманың күңеленә тагын шом төште. Хәер, аның беткәне дә юк иде, ул тагын да көчәеп китте, йөрәк күкрәк читлеген җимереп чыгардай булып ярсыды. Тагын очрашалардыр. Барыргамы? Юк, бу түбәнлек, дип үзен-үзе тиргәде ул. Ләкин икенче уй инде аны шунда әйдәкләде...

Сәгыйдулла белән Хәдичә шунда иде. Ул аларны күрмәде, ә акрын гына сөйләшкәннәрен ишетте. Нуриасма тавыш-тынсыз гына, мәче кебек атлап, алар янына якынлашты. Ниһаять, өянке кәүсәсе артыннан үрелеп ул аларны күрә алды. Хәдичә аякларын сузып җирдә утыра, Сәгыйдулла аның алдында башын салып, чалкан ята иде.

— Нәрсәдер чаштырдады кебек,— диде Хәдичә.

Нуриасма агач кәүсәсен ике кулы белән чытырдатып кыскан килеш тын алудан да туктап калды. Сәгыйдулла торып утырды, як-ягына каранды да:

— Кайтырга вакыт,— диде.

Хәдичә нидер әйтеп көлеп җибәрде һәм аны кочаклап тагын алдына аударды.

— Муенны суырма, эз калдырасың,— диде Сәгыйдулла пышылдап, ә Хәдичә эндәшмәде, аны үпте дә үпте...

— Кузгалыйк...

— Китмә, тагын әз генә тор...

— Җитте.

Сәгыйдулла аның кочагыннан ычкынып аягүрә басты.

— Әйдә тор,— диде ул Хәдичәгә иелеп.

Шулчак Хәдичә әллә нинди үзәк өзгеч тавыш белән кинәт елап җибәрде.

— Ни булды? — диде Сәгыйдулла аның каршына тезләнеп.

— Синең ник килгәнеңне беләм...Сез ирләр барыгыз да бер иш...— диде Хәдичә үкси-үкси.

— Мин бит иртәнгә кадәр синең янда кала алмыйм, Хәдичә...

— Әйе шул...— Хәдичә шыңшып елаган эт кебек сузып-сузып үкседе.

— Ни булды соң сиңа? Болай кыланганың юк иде бит.

— Ялгызлыктан да кыен берни дә юк! — диде Хәдичә елавыннан туктый алмыйча.— Яшьлек үтеп китте бит! Мин син уйлаганча кабахәт тә, азгын да түгел!

— Кем сине азгын ди...

— Беләм мин... Нинди оятсыз мин, нинди оятсыз! Бу гөнаһларны кем юар?! Әсгатем сугышта үлеп калмаса, без дә өйләнешеп, балалар үстереп яшәмәс идекмени?!

— Язмыштан узмыш юк...— Сәгыйдулла аны үпте, чәчләрен сыпырды.

Хәдичә, кинәт елый башлаган кебек, кинәт туктады да. Сәгыйдулла тагын аның алдына ятты.

— Карале, Хәдичә, йолдызлар ничек якты җемелди! — диде ул.

— Юк, алар уты сүнгән кисәү башлары кебек пыскыйлар, күзгә әче төтеннәре генә керә,— диде Хәдичә, Сәгыйдулланың башын кискен генә тезләреннән этеп төшерде дә, сикереп торып, бакчаларына таба йөгерде.

Нуриасманың йөрәге урыныннан купты. Әгәр хәзер аны шушында Сәгыйдулла күрсә, сугар да үтерер кебек тоелды. Ул, өянке кәүсәсенә береккәндәй, хәрәкәтсез калды. Сәгыйдулла әз генә басып торды, аннары тыкрыкка таба атлады. Нуриасманың йөрәге төшеп үк китте: ул Нуриасмадан алда кайтып керсә, ни булыр?! Сәгыйдулла, аның уйларын сизгәндәй, кире борылды һәм Нуриасма ябышкан өянкегә ышкыла язып китеп барды. Димәк, идарә ягыннан кайтырга уйлады. Аның аяк тавышлары басылуга, Нуриасма тыкрыктан өйгә элдерде...

Ул өченче мәртәбәсендә үзен алар артыннан барудан тыеп калды. Өйдә ята алмады. Сәгыйдулла кайтканчы, абзар-кура арасында, ишек алдында буталып йөрде, бөтен барлыгы янды, көйде... Юк, кайнар яшьләрен түксә түкте, ул кабат алар янына бармады. Уттай янган тәненең, аякларының шул якка тартылуын тыю өчен коточкыч көч кирәк иде. Бу әле һаман да чын түгелдер, ул ялгышадыр, бу бер төш кебек саташу гынадыр, йә булмаса ул акылдан язгандыр кебек тоелды...

* * *

Нуриасманың уйларын кемнеңдер ишек дөбердәтүе бүлде. «Бик соң бит инде, уникенче яртылар бардыр, кем булыр?» — дип уйлады ул.

— Кифая.

— Уяндым, түти, хәзер...

Кифая көне буе йөгерүдән ут булып сызлаучы аякларын көчкә сөйрәп чыгып китте.

— Кем бар? — диде ул йокылы-уяулы тавыш белән.

— Без бу, Кифая апа...

— Илсөяр!

Кифая ишекне ачуга, Илсөяр аны кочаклап алды, икесе дә күз яшьләрен сөрттеләр. Шуннан соң гына Кифая аның ире Үзбәк (иренең милләте дә, исеме дә шулай иде) һәм кысык күзле өч кара малае белән күреште. Барысы да түр өйгә уздылар.

Илсөяр кул биреп күрешкәч, әнисен кат-кат үпте, аның чем-кара чәчләре Нуриасманың битләрен кытыклады, ул кызының тән җылысын, таныш исен тойды. Еламаска, елмаерга кирәк иде, тик күз яшьләре елмаюдан көчлерәк иде...

— Әнием...

— Кызым...

— Шундый сагындым...

— Мин дә, кызым... Кайтып өлгердең бит...

Нуриасма оныкларына яшь аралаш карап: «Минем каннарым», — диде, йөзләрендә Сәгыйдулланың һәм үзенең чалымнарын табып шатланды.

— Балаларны шулкадәр җирдән алып кайтуыгызга рәхмәт, кияү, — диде Нуриасма. — Сиңа да рәхмәт, кызым...

Илсөяр әнисенең пульсын тикшерде, йөрәген тыңлады, ниндидер дару бирде.

Чәй яңартылды. Йокылы-уяулы басып торучы малайларга Нәсимә идәнгә урын җәеп бирде, алар яту белән йоклап та киттеләр. Фәрит, Тимергали, Мизхәт керде, бер-берсенең хәлен сораштыра-сораштыра чәй эчтеләр.

Аларның бер табында гөрләшеп утыруын Нуриасма сөенә-сөенә карап ятты. Илсөяр әледән-әле әнисе янына килде, аңа анарын да, өреген дә, йөземен дә авыз иттерде. Нуриасма бәхетле иде. Хәзер аның ике генә кайгысы калды: беренчесе туй, икенчесе Шәрифҗанны күрү. Илсөяре картаймаган, гәүдәсе төз, йөреше житез. Ул, гаиләдә бер кыз булгач, арада иң кадерлесе иде. Сәгыйдулла аны үлеп яратты, чамасыз иркәләде, тик, ни гаҗәптер, Илсөяр бозылмады, абыйлары белән бик тату үсте.

Сәгать төнге уникене сукты. Ирләр барысы да печәнлеккә чыгып киттеләр. Илсөяр, әнигә якынрак булам дип, малайлары янына идәнгә ятты.

Кыз алырга китәргә санаулы сәгатьләр генә калды... «Йокларга, йокларга...» диде Нуриасма. Йоклаган сурәттә генә йөрәге ял итә алачак, шул чакта гына ул түзә, өлгерә алачак... Йокларга, йокларга, йокларга...

Санаулы сәгатьләр бик тиз үтеп китте. Нәкъ сөйләшенгән вакытта бөтен өй эче, ихата тирәсе бердәм хәрәкәткә килде. Менә ак күлмәк, кара

костюм-чалбар кигән Мизхәткә ияреп Фәрит, Тимергали, Үзбәк Нуриасма янына керделәр.

— Без кузгалабыз инде, әнкәй,— диде Мизхәт.

Нуриасма улына яратып карап торды, иреннән бер як чите белән елмайды.

— Хәерле юл, улым,— диде. Аннары озын итеп сулыш алды да өстәп куйды: — Барыгыз, балалар, исән йөрегез. Мин сезне көтәм әле, киленне көтәм...

Капка төбендә бер «Волга», Тимергалинең «Москвич»ы һәм колхоз автобусы көтеп тора иде инде. Фәрит, Үзбәк, Бәрия, якыннарыннан, туганнарыннан берничә егет һәм кыз баян уйнап, җырлап машиналарга утырдылар. Хатын-кызлар хәерле юл теләп, киңәшләрен биреп капка төбеннән озатып калдылар.

## 18

Кече як белән түр якны аеручы ишек ачылып китте һәм анда Илсөяр белән Хәдичә күренде.

— Тагын мин әле,— диде Хәдичә исәнләшеп.

— Утыр, Хәдичә...— Нуриасма күзе белән генә урындыкка күрсәтте.

Хәдичә урындыкка, Илсөяр әнисенең аяк очына утырды. Хәдичә Гарифҗанның хәле әйбәтләнүен әйтте. Бераз һава хәлләре, башка вактөякләр турында сөйләделәр дә туктадылар. Озын гомер юлында бергә үрелгән, чияләнгән тормыш чатының берсе өзелер алдыннан һава торышы хакында сөйләшеп утырып булмый иде.

— Кызым, бар әле, теге яктагыларга булыш,— диде Нуриасма. Илсөярнең күзләренә аңларлык караш ташлап.

Ул чыгып китте, әмма берсе дә сүз башлый алмады. Хәдичә үзенең Сәгыйдулла белән булуларын берсе дә белмәде, Нуриасма уена да китермәде дип гомер итте. Баксаң, беркемнең дә ул хакта әйтмәве аның гөнаһын беркем дә белмәгән дигән сүз түгел икән. Нуриасма каян белгән? Аңа кем әйткән? Шушы сорауларга җавап табу өчен Хәдичә хәзер аның белән кара гүргә кереп ятарга риза булыр иде. Моны Нуриасмадан сорап та булмый, моңа аңардан башка беркем дә җавап бирә дә алмый иде...

— Нуриасма! — диде Хәдичә аңа ялварып. — Синең алдагы гөнаһым берничек тә җуела торган түгел...

Тамак төбен томалаган төен аңа сүзен дәвам итәргә ирек бирмәде.

— Гаепсез кеше юк... барыбыз да гаепле,— диде Нуриасма аның хәленә кереп. Аннары тыныч, гадәти тавыш белән болай дип өстәде: — Гомер буе бергә яшәдек... Минем дә төрле чак булгандыр... Мин бәхил синнән, Хәдичә...

Хәдичә, үз колакларына үзе ышанмагандай, аңа күзләрен тутырып карады: аны ничә көннәр буе куркытып, йөрәгенә кара кан булып урнашкан утлы төерне Нуриасманың шулай җиңел генә таратып атуына ышанасы да килми иде. Хәдичә йөзен ике кулы белән каплады да тавышсыз гына елады, тормышындагы мәңге кичермәячәк шул гөнаһы өчен үзен каһәрләп яшь койды. Шул рәвешле озак утырды ул. Аннары акрын гына торды, күзләрен яулык почмагы белән сөртте дә:

— Рәхмәт, рәхмәт...— диде һәм чыгарга кузгалды.

— Хәдичә, саклашырга керсәң, миңа җиңелрәк булыр иде...

— Керәм, Нуриасма, керәм...

— Туктале, Хәдичә, онытып торам икән ләбаса! Илсөяргә генә дәш, зинһар...

Хәдичә ишекне ачып Илсөярне чакырды.

— Кызым, Гарифҗанның балаларына тәм-том биреп чыгар әле,— диде Нуриасма.

— Кирәкми, кирәкми,— дип Хәдичә кул селтәде.— Үзегезнең олы мәшәкатьле чагыгызда нинди бала-чага кайгысы ул!

— Ярый, әни, бирермен,— диде Илсөяр.— Әйдә, Хәдичә апа...

Алар чыгып киткәч, аның уйлары үткәннәргә йөгерде, нишләптер Хәдичә белән икесенең кыз чакларын искә төшерде ул. Очып кына йөрерләр иде, йөзләреннән елмаю китмәс иде, ару-талуның ни икәнен белмәсләр иде. Бөтен нәрсә матур иде, тәмле иде, ямьле иде. Тәүлегенә биш-алты сәгать йокы житә иде. Нинди матур, кадерле чаклар булган... Аның уйлары яшьлектән бүгенгегә, бүгеннән үткәнгә күчә-күчә бөтен гомер юлын урадылар, һәм Нуриасма күп кенә нәрсәләргә моңа кадәр беркайчан да куя алмаган бәясен куйды. Бу уйлар гомер юлында ясалган хаталарны төзәтү әмәлләрен аермачык итеп күрсәтәләр иде. Тормышын бөтенләй тамырдан үзгәртеп, йөз мәртәбә игелеклерәк яшәп буласы булган. Ләкин бу уйларның шушылай соңарып, инде барысы да сүнеп беткәч, дөнья белән бәйләүче соңгы тамыр өзелергә торганда, йөрәк үзенең соңгы тибешләрен саный-саный гына ясаганда килүе бик сәер һәм үкенечле иде...

Уйлар аны теге көннәргә алып китте... Шул чакта әнисенең борчылып килүен Нуриасманың мәңге онытасы юк.

— Кызым,— диде ул сулышы кабып.— Кияү йөри дип ишеттем... Хәдичә белән. Хакмы?

Нуриасманың тәне эсселе-суыклы булып китте. Әнисеннән оят иде аңа.

— Ни сөйлисең, әнкәй, язмаганны,— диде ул тыныч күренергә тырышып.— Кем әйтә аны?

— Кифая ишетеп кайткан...

— Гайбәт җыеп йөрмәсен, әйт син аңа, әнкәй,— диде Нуриасма.— Без менә дигән яшибез, берни дә юк.

— Ай рәхмәт, кызым, җанымны тынычландырдың,— диде әнисе чын күңеленнән шатланып.

Бүтән беркем дә Нуриасмага бу хакта әйтмәде. Ләкин ул кешеләрнең күз карашында үзенә карата үзгәреш туган бик яхшы күрде. Кемдер яшерен генә елмаю, көлемсерәү белән караса, икенчесенең күзе кызгану белән тулы иде. Нуриасма үзенең авылда тамга салынган кеше кебек аерылып торуын сизде. Аңа башкаларга караган кебек карамыйлар. Бусы аңа Сәгыйдулла белән Хәдичәнең йөрүенә караганда мең мәртәбә авыррак, хурлыклырак иде. Баш чатнап, юләр кеше кебек шашыну чоры үтте, уйлану, кайбер нәрсәләрне бизмәнгә салу чоры житте. Көнләштеме ул аңардан? Көнләште, билгеле. Шушы хәлләргә дә көнләшмәсәң, җаның булмаска кирәк. Көнләшүгә, бәлкем, гомер буе түзәргә дә мөмкиндер. Аңардан зуррак нәрсәләр бар бит әле. Бу — үзеңне аяк астына салып тапталган, мәсхәрәләнгән итеп күрү. Моның көзгесе — авылдашларының йөзе, башка берниндн дәлил дә кирәкми иде.

Вакыты-вакыты белән аның, кешеләр арасына чыгып, бу ике азгынны хурлыйсы, адәм мәсхәрәсенә калдырасы килде. Ләкин болай итсә, ул бригадир булып эшләүче Сәгыйдулланың да, үзенең дә дәрәҗәсе төшәчәген уйлап туктап калды. Алай гына да түгел, аның хәленә кергән атлы булып, Сәгыйдулла белән авыз чайкарга маташучыларга, астыртын гына җайлап суктырырга теләүчеләргә ул юри елмаеп-көлеп җавап бирде, халык арасында таралган әлеге сүзләрне юкка чыгарды. Шулай итеп, гайбәтчеләр иң кирәкле, иң төп дәлилдән — Сәгыйдулланың йөрүен Нуриасманың үз теле белән раславыннан мәхрүм калдылар.

Тормышның бөтенлеге булмау барыбер эчтән җанны суырды. Беркөн төшлеккә кайткач, Нуриасма көзге каршыннан үтеп барганда, нишләптер борылып карыйсы итте. Тавыкларга җим алып чыгып барган җиреннән ишеккә җиткәч, нәрсәсендер оныткандай туктады. Ниндидер көч аны кире борылып, көзге каршына килергә мәҗбүр итте һәм ул аптырап калды. Аңа күз төпләре күгәргән, сүрән карашлы, яргаланган иреннәре

әрнүле кысылган бер ят хатын карап тора иде. Чәчләре тузып яулык астыннан чыккан, чуар күлмәгенең күкрәк турына апара каткан. Бүген бер кара бозау борыны белән төртеп алган иде шул. Ул үзенең башын алга таба сузыбрак,карчыклар төсле бөкрәебрәк торуын күрде. Күкрәкләр эчкә баткан, чөнки инде аның күптән күкрәкчә кигәне юк. Оегы сыдырылып төшкән, куллары яргаланган. «Кем соң бу, минме? Кем мине шушындый хәлгә төшерде?» — дип коты очып сорады ул үз-үзеннән һәм «Тормышның авырлыгы, мәшәкатьләрнең муеннан булуы»,— дип җавап бирде. «Ә сугыш елларында хәзергедән җиңел идемени?» — дип кабат үз-үзеннән сорады ул. Җавап урынына күз алдына һәрчак пөхтә, килешле киенүче Хәдичә килеп басты. Аның белән бергә эшләүче, сукыр әнисен караучы Хәдичәнең нишләп һәрчак кашы каралтылган, иннек-кершән сөртелгән, ислемае сибелгән соң? Нуриасма шунда бер нәрсәне аңлады: аның уйлары, эш-гамәлләре пакь калса да, тышкы кыяфәте белән ул гайрәт чигерерлек дәрәҗәдә түбән төшкән иде. Нуриасма шактый вакыт уфтанып, хәйран калып утырды. Аннары кискен сикереп торып, иске күлмәген салып атты, күкрәкчәсен, зәңгәр күлмәген киде, чигүле алъяпкычын бәйләде, өр-яңа оеклар киде. Чәчен тарап үргәч, битенә сизелерсизелмәс кенә иннек сөртте, пудра тигерде. Бианасының аптыраулы карашы астында Нуриасма гаепле кешедәй кызарып чыкты.

— Мәскәүгә җыендыңмы әллә? — диде ул гадәттәгедән дә кырысрак тавыш белән.

— Кибеттән әйләнәм әле...

Нуриасма ишеккә юнәлде. Урамга чыккач та кеше очраган саен, ояла—ояла гына исәнләште, һәркем аңа гаҗәпләнеп карады. Нуриасма башта оялса да, акрынлап эшендә дә, өйдә дә, урамда да пөхтә киенеп йөрергә өйрәнде.

Ләкин Сәгыйдулланың аңа булган мөнәсәбәте үзгәрмәде, хурлыклы тормыш дәвам итте. Аның йөрәгенә ярый торган серле ачкычны Хәдичә каян алды соң? Нуриасма яшеренеп кенә гел аны күзәтә башлады һәм үзенең акрынлап нииндидер олы хакыйкатькә якынлаша баруын сизде. Хәдичә һәрвакыт дәртле, гәүдәсе уйнаклап тора, зур кара күзләрендә әллә нинди очкыннар уйный. Ир-ат заты булса, ул башын аз гына бер якка кыйгайтып, каш астыннан күз чите белән генә чытлыкланып—мутланып карый, серле итеп елмая, ап-ак тешләрен күрсәтеп әледән-әле көлә. Ирен өстенә зәңгәрсу миң төртелгән булыр. Ир-атларны ул туктаусыз үрти, кешесенә карап телен дә чыгарып күрсәтә, этеп җибәреп читкә дә йөгерә. Нуриасма өянке төбендә Хәдичәнең Сәгыйдулланы шашып үбү-кочуларын исенә төшерде. «Бүрәнәне яратып буламы соң?» — дигән сүзләрнең дә мәгънәсе бөтен тирәнлеге белән ачылып китте аңа.

Ире белән шукланганы, аны иркәләгәне, кочаклаганы, үпкәне бармы соң аның? Бу сорауга уңай җавап биреп булмый иде. Ник? Теләмәдеме? Юк, теләде, бик күп булды аның Сәгыйдулланы шашып үбәсе, иркәлисе килгән чаклары. Тик ул үзен Сәгыйдулла каршында, имеш, бернинди андый теләкләре юк һәм булырга да мөмкин түгел җитди зат итеп күрсәтергә тырышты. Моңа, бәлкем, аны бәләкәйдән үк ир-аттан тәненне дә, күнелендәген дә яшерергә, аларга кагылдыртмаска өйрәтү сәбәп булгандыр. Моны бозу хаясызлык, әшәкелек, хәтта гөнаһ саналгандыр? Ләкин Хәдичә дә, башка татар хатыннары да бу кануннарны җимергәннәр ләбаса! Кыскасы, Нуриасма аларның тормышларының болай булуына Сәгыйдулла түгел, нәкъ менә үзе гаепле икәнлеген аңлады. Нуриасма үзен-үзе мәҗбүр итә-итә яшереп, тыеп калдырган назны ул башкалардан алырга мәҗбүр иде. Ә бит Сәгыйдулласы аны яратуы хакында, өйләнешкәч, күпме ягымлы, җылы сүзләр сөйләмәде! Ул сүзләр, аның кайнар сулышы хәзер дә Нуриасманың колагын яндырып торалар. Шул чакларда ни өчен ул: «Мин дә сине яратам, миңа да синең белән бик рәхәт!» — дип бер генә тапкыр булса да әйтмәде икән? Бер генә сүз булса да. Югыйсә Сәгыйдулла аңардан ничәмә-ничә мәртәбәләр:

«Мине яратасыңмы?» — дип сорады. Нуриасма йә дәшмәде, йә сүзне икенчегә борды. Шул чакта ничек түзде икән Сәгыйдулланың йөрәге?! Ул да бит Нуриасманың үзен яратуын кычкырып әйтүеннән өметен өзсә дә, башкача булса да, сиздерүен тоясы килгәндер. Нинди каты бәгырьле, мәрхәмәтсез булган Нуриасма! Ничек нык рәнҗеткән икән ул аны! Ничек Сәгыйдулла һаман түзә икән?! Ул менә шундый һич көтелмәгән уйларга килде.

Хәзер ялгышны төзәтергә кирәк иде.

Ничек төзәтергә? Ул көне буе шукланырга, шаярырга төрлечә планнар корып йөрде, ә кичен Сәгыйдулла кайткач, коелды да төште. Аның күзе уйнамый, теле әйләнми, кулы күтәрелми, аягы хәрәкәтләнми иде. Чөнки мондый хәлнең Сәгыйдулла белән ике арада беркайчан да бер генә мәртәбә дә булганы юк иде. Сәгыйдулла аны күп тапкырлар иркәләде. Нуриасма шуңа бөтен җаны-тәне белән эреде, ә үзе битараф булып кыланды, аңа сарыласы килсә дә читкә тайпылды, чөнки бу аңа тыйнаксызлык булып тоелды. Нишләптер Сәгыйдулланың күзләреннән үбәсе килә иде аның. Тик бер генә мәртәбә дә үпмәде. Хәзер исә бөтенесе янып күмерләнгән, теге теләк тә барлы-юклы, йөрәгендә рәнҗүгә охшаш тойгы гына бөтерелә иде. Теге чакларда күңелендә талпынган теләкләрен яшергән булса, хәзер инде ул юкка чыккан теләкләрен бар итеп күрсәтү зарур. Бу аңа кешенең табигатенә каршы килеп алдаганы, яшергәне өчен бирелгән җәза иде. Элек дөресен әйтмәгән өчен ул хәзер алдарга, кыланырга, үзендәге бик аз, сүнәр-сүнмәс кенә пыскучы тойгы-теләкләрне дә зур итеп, көчле итеп күрсәтергә тиеш иде. Ул моны ничек эшләргә кирәген күз алдына китереп, шуңа әзерләнеп торса да, вакыты җиткәч, булдыра алмады, чөнки аның моны беркайчан да эшләп караганы юк, ул аңа бөтенләй таныш түгел иде. Иң гаделе, иң акыллысы, әлбәттә, һәммәсен дә ачыктан-ачык сөйләп бирү, мин сине телим, иркәләвеңне телим, элек тә теләдем, юри генә кыландым, дип әйтү иде. Болай турыдан-туры әйтергә аның көче җитмәде, хәзер, инде эш узгач, моны әйтү оят иде. Аннары мондый нәрсәне әйтеп кенә ышандыра торган түгеллеген, аның сулаган һава шикелле тормышның һәр көнендә, һәр мизгелендә сизелеп торырга тиешлеген ул хәзер яхшы аңлады. Әгәр элекке чакларда йомшак куллары белән аны кочып алса, ялкындай тәненә кысса, уттай иреннәре белән аның күзләреннән, муеннарыннан үпсә, Сәгыйдулла аңардан читтә йөрер идемени? Нинди бәхетле көннәр кичергән булыр иде алар! Ул көннәрне кайтару өчен хәзер Сәгыйдулла белән икесе арасында калыккан, аларның бик нык аерган бер чикне үтеп чыгарга кирәк, бу исә мөмкин түгел иде. Күпме генә омтылса да, Нуриасманың аңа көче җитмәде...

Шулай да бер көнне ул үзен җиңде. Сентябрьнең җылы һәм якты бер иртәсендә алар, тарантаска утырып, Кара яр тирәсенә казларын барларга киттеләр. Кайтышлый камырлык, төлҗимеш җыярга ниятләделәр. Сәгыйдулла атының аркалыгын төшереп үләнгә җибәргән арада Нуриасма, читкәрәк йөгереп, бик куе эт шомырты куагы эченә яшеренде. Менә Сәгыйдулланың тавышы ишетелде:

— Нуриасма!

Ул җавап бирмәде.

Сәгыйдулла аңа дәшә-дәшә эзләнә башлады, ә Нуриасма тып-тын гына посып утыра бирде. Менә Сәгыйдулла аңа якынлашты, тик күрмәде, Нуриасмадан ике адым гына читкә килеп басты да кулларын авызына куеп:

— Нуриасма-а-у-у! — дип кычкырды.

Ыкның теге ярыннан кайтаваз гына җавап бирде. Шулчак Нуриасма кинәт:

— Һайт! — дип кычкырып җибәрде.

Сәгыйдулла сискәнеп артына борылуга, Нуриасма көлә-көлә читкә ташланды.

— Әле син шулай мине тинтерәтмәкче буласыңмыни? — диде Сәгыйдулла һәм аңа таба килә башлады. Нуриасма чырыйлап качты, шактый йөгергәч, Сәгыйдулла аны куып җитте һәм кулыннын эләктереп алды. Ул еш-еш сулый иде.

— Каптыңмы?!

Шунда Нуриасма ялт борылды да Сәгыйдулланың муеныннан кочып алды, аякларын тездән бөкләп асылынып калды. Сәгыйдулла аны биленнән кочып үзенә таба кыса башлауга, Нуриасма җитез генә аның кулларыннан шуып төште, тагын куаклар эченә йөгерде. Сәгыйдулла аю кебек лас-лос аның артыннан атлады, үзе туктаусыз: «Ну, тотсам!» — дип сөйләнде. Ахырда ул аны күлмәгеннән эләктерде, Нуриасманың аягы бөрлегән сабагына эләкте, алар икәүләп биек үләнгә егылдылар...

Ул көнне кич алар бер-берсенә моңа кадәр карамаган күзләр белән карадылар. Бу соклану да түгел, әле мәхәббәттә түгел, әллә нинди балаларча беркатлы шаянлык тулы караш иде. Бу карашны алар бер-берсенә яшерен рәвештә генә ташлап алдылар һәм аның әнә шул яшеренлеге үзе бер рәхәтлек бирде. Бу ниндидер уен кебек ләззәтле иде, моны һич тә югалтасы килми иде.

Серле караш, үткәндә-сүткәндә, яшерен рәвештә генә, йомшак кына кагылып йә чеметеп узу, сугып алу гадәткә әйләнеп китте. Балаларны кулына алырга юньләп вакыт таба алмаган Сәгыйдулла алар белән әвәрә килә башлады. Абзар-кура арасында эш эшләп йөргән Нуриасманы яшерен сагалау аның гадәтенә әверелде, ул аны эләктереп коча, үбә торган булды. Нуриасма да кыланып элеккечә читкә борылмады, аны кысып кочаклады, үпте дә өйгә кереп юк булды. Сәгыйдулланың назга сусаган күңеле басылды. Ул ихатада күбрәк булышты, авыз эченнән җырлап йөри торганга әйләнде, Хәдичәне онытты. Яңа тормыш башланды. Бу тормыш кызык та, мәгънәле дә, рәхәт тә иде. Элек ире өйдә күренүгә, йөрәген әрнетеп нидер тырный торган Нуриасма аның эштән кайтуын бизәнеп-ясанып дүрт күз белән көтә торган булды. «Ни бу?» — дип шатланып сорады ул үз-үзеннән. Шундук җавап та бирде: «Мин бит аны яратам, мин аннан башка яши алмыйм!»

Әйе, бу шулай иде. Моңа кадәр ник шулай яшәлмәгән? Нуриасма үзен харап итсә яки аерылса, гел дә яшәләсе булмаган. Ул кеше бәхетенен кулга тотып та, бернинди бизмәнгә салып та булмый торган, күзгә дә күренми торган әйберләргә бәйле икәнлегенә төшенде. Аларның йөрәген белән тоеп була, саксыз карасаң, югалтуы бик тиз, әмма кабат аларны алтын-көмешләр бәрабәренә дә табу мөмкин түгел икән. Нуриасманың йөзен янә елмаю нурлады...

Әлеге серле елмаю аның иреннәреннән Сәгыйдулла үлгәнче китмәде...

## 19

Нуриасма туйга әзерлекне белеп, сизеп, күреп ятты, йөрәге шатлыктан кызу-кызу типте. Ул зиһененең эшләвенә, күзенең күрүенә, колагының ишетүенә куанып бетмәде. Тагын әз генә чыдасын иде йөрәккәе. Бала табарга ярамый дигәч тә, түзде бит әле ул. Өч балага түзде. Бүгенге куанычны гына күтәрер, иншалла...

Нуриасма Кифая белән Илсөярдән барлык урын-җирен, өс-башларын алыштыртты, чәчләрен тарап үрдерде. Алар аның ин яраткан күлмәген кигерттеләр, ал чәчәкле яшел яулыгын бәйләттеләр, хушбуй сиптеләр.

— Бик зур рәхмәт сезгә, мин дә туйга әзерләнгән кыз кебек булдым, — диде Нуриасма бәхетле елмаеп.

Бу мәшәкатьләр аны шактый нык арытты. Ул, берничә йотым салкын су эчкәннән соң, тирән итеп сулады да күзләрен йомды һәм шундук йокымсырап китте...

Кифая белән Илсөяр тавыш-тынсыз гына алгы өйгә чыктылар һәм гаҗәпләнүдән икесе берьюлы кычкырып җибәрделәр: ишектән полковник погоннарын елкылдатып Шәрифҗан кереп килә иде.

Кифая белән Илсөяр аны берьюлы кочаклап алдылар. Шәрифҗанның кулындагы чемоданы идәнгә төште...

— Их, абый, әнинең хәле әйбәт түгел,— дип пышылдады Илсөяр.

Ә Кифая бер сүз дә әйтә алмады, туктаусыз күз яшьләрен сөртте. Хатын-кызлар, эшләрен бүлеп, аларга карап торалар иде. Шәрифҗан Нәсимә, Өммекамал, Мосаллия һәм башкалар белән күреште дә тизрәк түр якка — әнисе янына узмакчы булды. Ләкин Илсөяр аны туктатты.

— Абый, әз генә сабыр ит, әни әле яңа гына йоклап киткән иде,— диде.

Шәрифҗанның күңелен хәвефле ут көйдереп үтте. Йөрәк авырулы кешеләрнең бөтенләйгә йоклап китүләрен дә яхшы белә ул. Тик бу хакта кычкырып әйтеп булмый иде. Ул туфляларын салып куйды да:

— Мин аны уятмам, аяк очларыма гына басып керермен,— диде.

Камчатка тикле Камчаткадан «әнием» дип кайтып, аңа берничә адым калгач, ишек төбендә көтәргә нинди йөрәк түзсен соң?! Шәрифҗан ишекне акрын гына ачты да аяк очларына басып түр өйгә узды. Аның артыннан Кифая, Илсөяр, Нәсимә атлады. Шәрифҗан әнисенең караваты янына ук бармакчы иде дә, сеңлесе аны терсәгеннән тотып туктатты. Ләкин соң иде инде. Нуриасма аларның керүен сиздеме, әллә үзе шулай бик азга йокымсыраган идеме, акрын гына күзләрен ачты.

— Исәнме, әнкәй! — диде Шәрифҗан һәм күрешергә кулларын сузып аның янына килде.

Нуриасма бер генә мизгелгә аңышмый торды, аннары, улының кайтуын аңлагач, елмаюдан йөзе яктырып китте.

— Кайттыңмы, бәбекәем?! — диде ул һәм бераз кырынаеп кулларын Шәрифҗанга сузды. Улы әнисенең кечерәеп һәм саргаеп калган ябык кулларын учларына алды, аларның җылысы бөтен тәненә йөгерде... Ул әнисенең йөз чалымнарының тирәнәюен, җыерчыкларының артуын күрде. Аларның ничектер моңа кадәр беркайчан булмаганча суырылып һәм катып калганлыгы әнисен эчтән коточкыч әрнүләр, сызланулар көйдерүе хакында сөйли, аны хәтта беркадәр ят итеп тә күрсәтә иде...

— Утыр, улым,— диде Нуриасма.— Мин тора алмаганга ачуланма инде...— И әнкәй, син бит гомерең буе аяк өстендә...Шәрифҗан урындыкка утырды, нидер әйтмәкче булып авызын ачты, тик әйтә алмады, чаларган башын кинәт иеп, әнисенең кулларына маңгаен куйды, яңакларын терәде... Нуриасмага улының йөзендәге һәр сызык таныш иде, ул аларны бармаклары, куллары белән генә түгел, йөрәге белән дә тойды. Ул аның кысылган иреннәренең калтырануын, сакал-мыек төкләренең катылыгын сизде, битләреннән агып төшүче кайнар күз яшьләрен сизде... Малаеның күз яшьләрен аңа ничәмә-ничә мәртәбә сөртергә туры килгәндер. Ә менә хәзергеләре сөртә торган күз яшьләре түгел иде. Шәрифҗан күпме генә тыярга тырышса да, алар күңелнең әллә кайсы көтмәгән җиреннән сыгылып чыктылар. Ул барлык җегәрен туплап үксүен, сулкылдавын эченә йотты, әмма күз яшьләрен туктатырга көче җитмәде. Шәрифҗан бу йомшаклыгы өчен оялмады, әнисең юатасы урында күз яшьләре күрсәтеп борчуы өчен уңайсыз иде аңа. Әнисе барысын да тойды, аңлады. Малаеның көмештәй агарган чәчләреннән, укалы погоннарындагы сизелер-сизелмәс калтыранып куючы йолдызлардан күзен алмаса да, Шәрифҗан аның өчен һаман сабый, җанының да кадерле бәгырь ите иде.

— Кайтып җитүең өчен рәхмәт, улым,— диде ул тамак төбенә бөялгән төерне тизрәк куарга теләп.

Нуриасма белә: күңелендәге сүз белән әйтсәң, җиңелрәк булып китә.

Шәрифҗан башын күтәрде, кульяулыгы белән ашыга-ашыга күз яшьләрен сөртте.

— Күңелем йомшап китте бит, әнкәй... — диде ул гаепле кеше шикелле.

— Сагынганныкыдыр, улым. Килен, балалар исән-саулармы?

— Бик күп итеп сәлам әйттеләр. Аларны алып кайтырга җай килмәде. Ачуланма инде, әнкәй...— И улым, җир читләреннән үзең кайтып җиткәч тә бик зур рәхмәт...

Шәрифҗан, чемоданын ачып, күчтәнәчләр чыгарды. Әнисе белән Кифая апасына да, Илсөяр белән Нәсимәгә дә бүләкләр бирде. Ул Себер үләннәреннән ясалган дару да алып кайткан иде. Аны шундук кашыкка салып Нуриасмага эчерделәр. Биш минут та үтмәгәндер, ул күкрәгенең йомшап, сулышының киңәеп китүен сизде, улына рәхмәтләр укыды, әллә кайларда йөрсә дә, минем турыда уйлаган бит, дип куанды. Шәрифҗан өч ел элек кунак булып киткәннән соң кайта алмады һәм Нуриасманың аны бик тә күрәсе килгән иде. Менә хәзер улының якында гына утыруы, аның белән сөйләшүе Нуриасмага чиксез рәхәт иде, ул барлык бәпкәләрен канат астына җыйган каз кебек бәхетле иде...

Алар шактый озак утырдылар. Шәрифҗанның балачактагы шуклыкларын, Фәрит белән сугышуларын, Кифаяны елатуларын, Илсөярнең хәйләкәрлекләрен көлешә-көлешә искә төшерделәр.

Ялгызы калгач, ул черем итеп алмакчы булды. Ләкин күпме генә ятса да, керфеккә керфек тә какмады һәм үзендә ниндидер үзгәреш тойды. Менә ничә көннәр инде ул үзен тормыш беркайчан да кайтмаячак теге дөнья кешесе дип санады. Яшәүнең бер йотым татлы ширбәт шикелле генә булуы, үлемнең акыл җитмәслек гадилеге, йөрәк күтәрә алмаслык дәрәҗәдә гаделсезлеге шушы көннәр эчендә генә аның зиһененә бөтен ачыклыгы, рәхимсезлеге белән барып җитте. Нуриасма инде тормышка таба борылу, нәрсәне дә булса яңадан башлау, төзәтү мөмкин түгел икәнлеге белән берсүзсез килешкән иде. Ләкин менә хәзер, гел көтмәгәндә йөрәге аңа нидер сиздергән төсле тоелды. Аның гәүдәсе җиңеләйде, рухы яктырып китте. Аңа хәзер бер нәрсә ачык иде: ул әле киленен дә каршы алачак, туйны да үткәреп җибәрәчәк. Бусы шикләнүсез. Ә ничек шикләнүсез? Чөнки моны аңа йөрәге сиздерә, ә ул аңа ышана. Йөрәкнең үтәли күрә торган ниндидер тылсымлы көче бар. Багучы дип йөртелә торган кешеләргә ул көч күп бирелгән була. Чалпы карчыгы шундый иде. Ул Нуриасмага Сәгыйдулласының үләсен сиздерде, нәкъ тугыз айдан соң олы кайгы килер, үзеңне нык тот, диде. Чалпы карчыгы бер генә атнага ялгышкан иде... Күз күрмәгәнне йөрәк күрә. Әгәр ул Нуриасмага яшәү турында менә хәзер хәбәр сала икән, бәлкем ул аягына да басар? Аның бит бер тәгам ризык җыя алмыйча сырхап яткан, якты дөнья белән хушлашкан чаклары элек тә булгалады. Төрелде бит, моңа кадәр яшәде. Әллә Шәрифҗан алып кайткан дарудан, әллә башкадан, аның күз аллары яктырып китте, күкрәгендәге авыртуы да бераз басылгандай булды. Кем белә, бәлки аңа Мизхәтнең баласын күрергә дә насыйп булыр? Бу хакта уйлау рәхәт иде. «Тукта,— дип сискәнеп куйды ул.— Мин бит үземне үзем алдыйм! Гомергә алдамаганны менә хәзер яшеренеп кенә алдап ятам түгелме?! Алдаумы соң бу, әллә өметме?» Моңа кадәр үзара тигез генә ялганып килгән уйларының ул чуала башлавын, бер төенгә бәйләнгән мең җепнең очына чыга алмагандай буталуын сизде. «Алдау белән өмет шулай бер-берсеннән аера алмаслык дәрәҗәдә охшаш микәнни соң?— дип хәйран калып уйлады. Нуриасма дүрт баласының тормышын күз алдыннан үткәрде, аларны бәхетле иттем, диде. Әмма шундук шикләнеп каршы да килде. Шиге иң кечесе һәм иң олысы белән бәйле иде. Мизхәт армиядә чакта Зөбәрҗәт белән икесе арасына кергәне өчен ул үзен кичермәде һәм кичермәячәк. Инде менә хәзер шул үзенең хатасын төзәтәм дип аларның өйләнешүләрен ашыктырды, хәтта мәҗбүриләде. Авырып киткәч, инде бөтенесе белән

килешкән көннәрендә, ул үзенең хаклылыгына тамчы да шикләнмәгән, башкача була алмый, бары тик шулай гына тиеш дип уйлаган иде. Ә менә хәзер каяндыр икеләнү баш калкытырга азапланa. Бәлкем хәзер дә ана сабырсызланмаска, катышырга кирәк булмагандыр? «Инде соң шул»,— дип уйлады ул ачынып.

Фәриткә килгәндә, анысы тагын да четереклерәк һәм ул хакта Нуриасма гомере буе баш ватты. Фәрит аның үз каны түгел, шулай да тормышның иң авыр башы аңа эләкте, апайларын да ул карап үстерде, йорт эшләрен дә ул эшләде. Шуңа күрә Нуриасма аны үз балаларыннан артык күреп яратты, шул ук вакытта йөрәгендә гомер буе ана карата ниндидер яшерен кызгану хисе дә утырды. Бәхетле итә алдымы икән ул аны? Бәлкем ул бүтән кеше кулына эләксә, әлеге авырлыкларны да күрмәс, бәхетлерәк тә булган булыр иде?

... Фәритнең үз анасы Газиянын кыз чагында егетләре күп иде, тик арада Усман исемлесе кайсын кыйнап, кайсын куркытып таратып бетерде. Усман телгә беткән иде, Газиянын артыннан тотам да калмады, туктаусыз мәхәббәт сүзләре сайрады, ә тегесе шул сүзләргә эреде дә акты. Газия балага узып шактый юанайгач, Усман сүзсез-хәбәрсез югалды. Ул эшеннән дә, тулай торагыннан да киткән иде. Бер бүлмәдә яшәгән дус егетенә әйтеп калдырган: мина өметләнмәсен, баласыннан котылу хәстәрен күрсен, дигән. Гел шыр-шыр көлеп, кәҗә бәтие шикелле сикергәләп йөргән Газия кара кайгыга төште, беркем белән сөйләшмәс, көлмәс булды. Нуриасма аны юатты, баланны икәүләп карарбыз, Усманың кайтып килер, дип тынычландырырга маташты, әмма Газия аны тыңларга да теләмәде. Ул заводтан чыкты, авылга кайтып китәм, диде, китә алмады. Соңгы вакытта алар хуҗа карчык белән Нуриасмага гел бәйләнеп, гаеп табып кына тора башладылар. Ниһаять, бер көнне хуҗа карчык:

— Якын туганым торырга килә, үзенә фатир юлла,— диде. Нуриасма башка квартирга күчте. Ике-өч көннән Газиянын хәлен белергә дип барган иде, карчык аны өйгә кертмәде, сине күрәсе килми, дип борып җибәрде. Нуриасма елый-елый аптырап кайтып китте, һич тә моның сәбәбенә төшенә алмады. Ял көнне түзмәде, кабат элекке квартирасына юл тотты. Якшәмбе көнне кичен хуҗа карчык, гадәттә, бер туганнарына мунча керергә китә, шунда кунып та кала иде. Газия үзе генә булса, кертми калмас, хәлләрен сорашырмын, юатырмын, дип уйлады ул. Күк йөзен кургашындай авыр болытлар каплаган караңгы шомлы төн иде бу. Ул таныш ишек төбенә килеп житкәч, туктап калды. Карчык өйдә түгелме икән, дип тәрәзәдән сөйләшкәннәрен тыңламакчы булды. Кинәт якында аяк тавышлары ишетелде. Нуриасма стена буендагы кирпеч өеме артына чүгәләде. Тәрәзәдән төшкән яктылыкта ул чыгучының хуҗа карчык икәнлеген таныды һәм кулына ниндидер төргәк тотканлыгын күрде. Менә карчык төргәген шәле белән каплады, алан-йолан каранды да йөгерә-атлый Нуриасма яныннан үтеп китте. Шунда аның йөрәге төшеп киткәндәй булды: карчык узганда, сизелер-сизелмәс кенә бала елаган тавыш ишетелеп калды. Нуриасма ни уйларга да белмәде. Димәк, карчыкның кулында Газия баласы! Кая алып бара ул аны? Нуриасма ушына килгәнче, карчык урамга чыгып югалды. Ул аның артыннан ташланды, күздән яздырмыйча ераклатып кына ана иярде. Әллә нинди аулак караңгы урам-тыкрыклардан алар бик озак бардылар. Ахырда карчык ялт борылып бер ишек алдына кереп китте. Нуриасма ул барган яктан түгел, урамның икенче ягыннан атлый иде. Адымнарын акрынайтып, артыннан керергәме-кермәскәме икәнен хәл итәргә дә өлгермәде, карчык килеп тә чыкты, шәлен ябына-ябына кирегә дә йөгерде. Ул бераз ерагайгач, Нуриасма, урамны аркылы чыгып, әлеге ишек алдына керде һәм ун-унбиш кенә адым җирдә яткан аксыл төргәкне күрде, мәче баласы мияулаган шикелле генә сузынкы тавыш та ишетелде. Шаулашып яңаша подъездлардан кешеләр чыга башлады. Нуриасма төргәкне эләктерде дә

ишек алдыннан чыгып йөгерде, күкрәге турыннан килгән бала тавышы аның йөрәгеннән өзде. Кая барырга? Таптым, дип милициягә яисә больницага кертеп бирергәме? Юк, моның берсен дә эшләү аның көченнән килмәде. Квартирга кайту турында уйларга да ярамый иде. Ул барырдай бердәнбер урын булып вокзал калды. Аның аулаграк урынын табып, чүпрәкне сүтеп җибәрде. Баланың кып-кызыл йөзе ачылды, янына имезлекле шешә белән сөт тә куелган иде. Нуриасма әлеге төнне әллә өнендә, әллә төшендә, әллә тере, әллә үле хәлдә вокзалда үткәрде. Ул баланы үзендә калдырырга ният итте. Бу уңайдан Нуриасма бер утка, бер суга төште, әле тыннары кысылырлык дәрәҗәдә куанды, әле коты очып куркып калды. Ә шулай да ниятеннән кайтмаска булды. Моның өчен иң элек эзне югалтырга, баланы үзенә яздырырга кирәк иде. Икенче көнне баласын күтәреп ул шәһәр буйлап квартира эзләп йөрде. Ахырда бер рус карты белән карчыгы аны кертергә риза булдылар. Шул көнне үк эштән чыгаруларын сорап гариза бирде, әни авырган, авылга кайтам, диде. Әллә аңа ышандылар, әллә болай каршы төшәсе итмәделәр, ул артык шау-шусыз гына кирәкле язуларын ала алды.

Карт белән карчык икесе дә авыру иде. Нуриасма өйдә җен урынына эшләде, аларның кием-салымнарын ап-ак итеп юды, үтүкләде, кибеткә чапты, аш-су әзерләде. Күкрәгемдә сөтем юк дигәнгә карт белән карчык ышандылар, аларның балалары булмаганга күрә Нуриасманы да, сабыйны да үз иттеләр.

Газия баласын эзләп тилмереп йөридер дигән уй тынгылык бирмәде. Бер атна узганчы да түзмәде, ул кабат иске квартирасына китте. Әгәр Газия уфтанса, баласын эзләсә, китереп бирергә булды. Әмма яһүд карчыгы ялгыз гына иде, Газия авылына кайтып китте, диде. Нуриасманы кабат үзе янына торырга чакырды. Ләкин бу йортка аның өчен юл киселгән иде инде...

Баланы яздыру мәшәкатьләре хәвеф-хәтәрсез генә үтте. Нуриасма бер төзелеш конторасына җыештыручы булып урнашты. Сәгыйдулла кайтып төшкәндә тормыш үз эзеннән бер көйгә бара башлаган иде инде...

Бу тарихны ул Фәриткә сөйләмәде. Ник аңа мәңге төзәлмәс яра ясарга? Ул яраның Нуриасма йөрәгенә тирән итеп уелганы да бик җиткән...Ул күзләрен йомды, дөм караңгы булды. Тик озакка түгел. Караңгылыкның бер читендә башта бер ак тап күренде, аннары икенчесе, өченчесе, дүртенчесе... бихисап күп ак таплар хәрәкәткә килделәр, ябалак-ябалак кар ява башлады. Һәр тараф тын һәм торган саен ныграк агара, яктыра барды. Кар бик озак яуды, тик Нуриасма чана шуарга тауга менмәде, ул хакта уйламады да. Шулай да аңа барыбер рәхәт, нindидер таныш тойгы бөтен барлыгын биләгән иде. Ул учын алга сузды, ләкин кар бөртекләренең учына төшүләрен дә, салкынлыкларын да сизмәде. Ява торгач, кулын ап-ак кар каплап ук китте, нишләптер гел эремәде, кар бөртекләрендәге теге язгы бөре, яшен исләре дә юкка чыккан иде, әйтерсең лә кар түгел, мамык ява иде...

— Нуичама әби, Миҗхәт абый катын алып кайта!

Маратның тавышына ул күзләрен ачып җибәрде.

Ул арада Илсөяр белән Кифая, аларның үкчәсенә басып Нәсимә йөгереп керде.

— Кайталар, кайталар! — диделәр алар, чиксез дулкынланып.

Нуриасма йөрәгенең еш-еш тибә башлавын сизде.

— Барыгыз, бар...— ул яулык читен, чәчләрен төзәткәләп куйды.— Әйбәтләп каршылагыз...

Барысы да чыгып йөгерделәр. Алгы өйдә дә, өйалдында да хатын-кыз чабулый башлады. Капка төбен халык сырып алган иде инде. Шәрифҗан йөгереп барып капканы ачты. Аллы-гөлле шарлар, тасмалар бизәлгән машиналар җыр-гармун тавышлары астында сузып кычкырта-кычкырта бирегә якынлашып киләләр иде. Марат җитәкчелегендә Илсөярнең кара малайлары, тагын бер өер бала-чага машиналарга таба

йөгерде. Ал, яшел, зәңгәр, сары шарларын уйнатып, иң элек ак «Волга», аннары Тимергалинең яшел «Москвич»ы, кунаклар төялгән тагын берничә җиңел машина һәм иң соңгысы булып автобус капка төбенә килеп туктады. «Волга»ның арткы утыргычында Мизхәт белән Зөбәрҗәт. Мизхәтнең классташы — иңбашына аркылы сөлге бәйләгән Наил тирә-юньгә учлап-учлап конфет сибеп җибәрде, бала-чага, чыпчык өере җимгә ташлангандай, чыр-чу килеп конфет чүпләргә керештеләр. Нәкъ шул вакыт Фәрит белән Шәрифҗан йөгереп диярлек кара-каршы килделәр дә кысып кочаклаштылар, әллә дулкынланудан, әллә беркем берни аермаслык шау-шудан, бер-берсенә әйткән сүзләрен дә юньләп ишетмәделәр... Алар өйалдына уздылар. Менә машина баскыч төбенә үк якынайды, ул туктартуктамастан ук Наил, сикереп төшеп, арткы ишекне ачып җибәрде. Мизхәт төшеп Зөбәрҗәтнең кулыннан алды, ул басарга аягын сузуга, Кифая аның аяк астына меңдәр ташлады. Зөбәрҗәт аны житез генә үрелеп алды да җиргә төште. Баскычтан күтәрелүгә, Шәрифҗан алар белән күреште, котлады.

Нуриасма һәммәсен дә ишетеп ята иде инде. Ул күкрәгенә кулын салган килеш авыз эченнән берөзлексез кабатлап йөрәгенең түзүен генә теләде... Менә яңа кар төсле ап-ак бөркәнчек ябынган, ап-ак күлмәк кигән Зөбәрҗәт, кара костюм-чалбардан, кар шикелле ак күлмәктән аның Мизхәте килеп керде.

Менә Зөбәрҗәт Нуриасманың янына ук килде. Хәзер аның калку күкрәген, ак муенын, дулкынланудан алланып чыккан йөзен, бәхетле елмайган иреннәрен Нуриасма аермачык күрде.

— Исәнме, әни! — Зөбәрҗәтнең тавышы дулкынланудан сабый баланыкы шикелле нечкә булып яңгырады.

«Әни» сүзен ишетүгә Нуриасманың ике күзен яшь пәрдәсе каплады, ул үзенең алдында ак шәүләдән башка берни дә күрмәде. Бу тавыш шулкадәр дә тансык, якын, мәрхәмәтле иде. Зөбәрҗәт, аны сак кына кочаклап, битеннән кат-кат үпте, аның яңа яуган кар төсле ак бөркәнчеге Нуриасманың яңакларына тиде һәм ул алардан аермачык булып язгы бөре, яшен исе килүен тойды...

— Рәхмәт, әни,— диде Зөберҗәт аның колагына ул гына ишетелерлек пышылдап.

Бу минутларда Нуриасмадан да бәхетле кеше юк иде. Зөбәрҗәт кемнеңдер кулыннан алдан әзерләп куелган ак ефәк шәлне үрелеп кенә алды да сүтеп бианасының өстенә япты. Нуриасма ялтырап торучы шома тукымага, аның чукларына бармагын тигереп карады — ефәк яңа яуган кар төсле салкынча иде...

— Кызым...

Нуриасма «рәхмәт» дип әйтергә теләде, әмма теле, иреннәре аңа буйсынмады, ул иягенең калтыравын, йөрәгенең сулкылдавын сизде. Ниһаять, соңгы көчен җыеп:

— Рәхмәт, кызым...— диде һәм: — Зурлагансың...— дип өстәде.

Ул арада кода белән кодагый кул биреп күрештеләр. Кода Әнвәр исемле булып, бик мәһабәт гәүдәле, кып-кызыл чырайлы, чәчләренә дә, калын кашларына да ак бәс сарган кеше иде. Мәгъфия кодагый Нуриасмадан да бәләкәйрәк чандыр гәүдәле, шомырттай кара күзләреннән әллә нинди җылы нур бөркелә иде.

— Миңа рәнҗемәгез инде, зинһар,— диде Нуриасма гаепле кеше кебек.

— Каян чыккан ди ул рәнҗү! — диделәр кода белән кодагый икесе беравыздан.

— Сабыр итә алмадым бит... ашыктырдым...

— Бернигә дә борчылма, кодагый,— диделәр тегеләре.

Зөбәрҗәтнең башка туган-тумачалары да килеп күрештеләр. Нуриасманың туй вакытында бирергә дип әзерләнгән бүләге бар иде. Йөрәгенең моңа кадәргегә караганда бик хәтәр сулкылдавы ашыгырга мәҗбүр итте: ул аны хәзер үк тапшырырга булды.

— Балакайларым! — диде Нуриасма Мизхәт белән Зөбәрҗәткә.— Минем сезгә амәнәтем бар. Ул безнең ата-бабаларыбыздан килә...

Нуриасма күкрәк турындагы одеялын акрын гына ачып җибәрде. Барысы да тып-тын калдылар. Аның күкрәге өстендә мең еллык имән кайрысыдай соры һәм кытыршы тышлы Коръән ята иде. Мизхәт аны шундук таныды. Кулдан күчереп язылган бу китапның саргайган битләрен аның озаклап актарганы, үзләренең шәҗәрә агачы ясалган соңгы битен хәйран калып карап утырганы бар иде. Бу Коръән өйнең буй җитмәслек биек, иң ышанычлы һәм кадерле урынында сакланды.

— Изге китап бу,— диде Нуриасма.— Аның һәр сүзенә күз нурлары сеңгән... ата-бабаларыбызның... Мәңге саклагыз... буыннан-буынга...

Мизхәт китапны ике куллап алмакчы булды.

— Улым, шәл өстенә куй син аны...

Мизхәт китапны әнисе өстенә җәеп салынган шәлнең нәкъ уртасына куйды. Коръәннең аскы тышлыгындагы кайнарлык бармаклары аша бөтен гәүдәсенә йөгерде. Нуриасма Зөбәрҗәткә дәште:

— Яхшылап шәлгә төр, кызым...

Зөбәрҗәт бер генә мәлгә аптырап калды.

— Кызым, төр,— диде Мәгъфия кодагый акрын гына.

Зөбәрҗәт иң элек шәлнең аяк ягын күтәреп каршы якка китереп каплады, аннары караваттан идәнгә таба асылынган бу як кырын теге якка бөкләп салды һәм шул рәвешле дүрт яклап бөкли торгач, Коръәнне төреп бетерде һәм алып күкрәгенә кысты.

— Барыгызга да рәхмәт,— диде Нуриасма. Аңа кунакларны үзе янында озак тоткарлау гаять кыен иде.— Күңел ачыгыз...

Хәзер Нуриасманы бер генә кайгы биләде — туй беткәнче түзү, таңны күрү. Соңгы мәртәбә таң атканны бик тә, бик тә күрәсе килде аның. Ул ястык почмагын уң кулы белән чытырдатып кысты, аны сизде, шушы сиземне югалтмаска кирәк иде. Әледән-әле тәннәрен капшап, сыпырып карады — сизә иде, димәк, өмете бар иде.

Ул сөйләнгән бер генә сүзне дә колагыннан ычкындырмаска тырышты, ишетелмәгәнен кабатлап сорады. Аңа әле Илсөяр, әле Кифая, әле Өммекамал, әле башкасы туйда ни сөйләнгәнне, ни эшләнгәнне җиткереп тордылар...Төнге уникеләр тулганда, Нуриасма бөтен гәүдәсенең, күз кабакларының авыраюын, йокысы килүен сизде. Ләкин ул онытылудан курыкты, үз-үзенә «инде түзәргә күп калмады» диде, барлык көчен туплап сөйләшергә, ишетергә, күрергә тырышты. Тик язмышны алдап булмый иде, ахрысы. Сәгать ничәләр булгандыр, нинди дер бер мизгелдә ул «ә» дигән арада бөтен тәненең йомшап, ишелеп төшүен тойды. Моны аның янындагылар да сизде. Бу әйбәт билге түгел иде.

Аның күкрәгенә эчтән нидер тыгылды һәм ул тирән итеп түгел, шул урынга кадәр генә сулады. Болай тын алу кыен иде, ул күкрәгенең еш-еш күтәрелүен, сулышының тирәнгә төшеп җитә алмавын сизде. Ничек кенә булмасын, ул әле аңында иде.

— Бетәме... туй?..

Нуриасманың бу соравы түшәмгә төбәлгән хәлдә ялварып бирелде һәм аның ник ялваруын янәшәдәгеләр бик яхшы аңладылар.

— Бетте инде, бетте,— диде әле генә ишек алдына чыгып кергән Мосаллия.

Ул аны алдамады, инде әйтер сүзләре әйтелгән, ашасылар ашалган, эчәселәр эчелгән, кунакларны биләгән җыр-биюләр кайнарлыгы гына һаман сүрелми, шул сәбәпле генә Хәсән туйны ябарга җай чыгара алмый тора иде.

Нуриасма ястыкның почмагын тагын да ныгытыбрак кысарга теләде, тик кулы тыңламадымы, сизмәдеме, ястыкның почмагы юк иде инде... Ул аерылышу сәгатенең сукканлыгын аңлады. Авызы тагын тәмсезләнде, теле тагын кайнар көлгә батыргандай хәрәкәтләнә алмады. Гыйздениса аның хәлен аңлап шундук авызына берничә калак су салды.

Нуриасмага җиңел булып китте, теле купты, әмма тамагы ут янды, әйтерсең лә эчтән ялкын күтәрелеп авызга менә иде. Шулай булса да, нишләптер, янадан су эчәргә теләмәде, китергән калакны баш чайкап кире какты...

Вакыт бик тә кадерле иде.

— Балалар керсен...— ул бу сүзләрне телен көч-хәл белән генә әйләндереп әйтте.

Гыйздениса ым кагуга, Кифая белән Илсөяр елый-елый өйдән чыгып йөгерделәр. Нуриасма үзе белән гомер кичергән Разияларга, Мәһинурларга, Мосаллияларга, Гыйзденисаларга, якыннарына карады, әле барысын да булмаса да, күбесен таныды, ләкин торган саен күз алдын соры томан каплый баруын сизде. Аның янәшәсендәге кешеләр, тәрәзәләр, матча, аңа асылган яктырткыч — һәммәсе, һәммәсе, нииндидер кабыкка төрелгәндәй, икеләтелгән шәүлә аша күренделәр. Өйдәгеләр аңардан бер-бер артлы бәхиллек сорарга керештеләр. Теге дөньяга китүче белән мәңгегә хушлашу йоласы тирән мәгънәле булса да, бик авыр иде. Нуриасма аларны бәхилләвен йә бер сүз белән, йә баш кагып, яисә керфек сирпеп белдерде...

Ул аларның йөзләрен ачык күрмәсә дә, һәрберсен таныды һәм гәүдәсенә хәл кереп киткәндәй булды. Ул ирен читеннән ике тешен күрсәтеп серле елмайды. Әле иң мөһиме әйтелмәгән иде.

— Килен,— диде ул ак шәүләгә карап.

Бу сүзне ишеткәч, Мизхәт белән Зөбәрҗәт аңа якын ук килделәр. Нуриасма аларның каралып торган авыз-борыннарын, күзләрен дә аерган кебек булды.

— Килен... минем улым бик әйбәт... кыерсытма аны...

Шулвакыт атылып-бәрелеп, Бәрия килеп керде. Ул салган баштан җырлап-биеп йөреп, җиңгәсе янына керергә соңарган иде. Ә дөресен әйткәндә, аның уенча Нуриасма әле кимендә бер атна ятачак, балаларының аның белән бәхилләшеп йөрүе урынсыз иде. Шулай да башкалардан калу килешмәс дип, ул керергә булды. Җиңгәчәсе янына килгәч, Бәрия аптырап китте. Әле туй башланганда, аның күзләре дә пыялаланмаган, йөзендә дә җан әсәре бар иде. Бәрия үз гомерендә беренче мәртәбә кызгануга охшаш тойгы кичерде, ләкин бу чын кызгану түгел һәм аның ничек тууын ул үзе дә аңламады. Әнисе үлгәндә дә, Сәгыйдулла абыйсын җирләгәч тә Бәриянең андый тойгы кичергәне булмады, бу аның өчен бөтенләй ят кичереш иде.

— Җиңгәчәй, мине таныйсыңмы? — диде Бәрия.

Нуриасма дәшмичә шактый карап торды, иреннәр кыймылдады, тавышы чыкмады. Гыйздениса калак белән аның авызына берничә мәртәбә су салды. Шунда Нуриасма барысын да гаҗәпләндереп кинәт:

— Таныйм,— диде.

Аның тавышы ачык булып һәркемгә барып җитте.

— Мине бәхиллисеңме, җиңгәчәй?

Бәрия йөзен кемнеңдер сугуыннан сакларга әзерләнгән кеше төсле ике кулын бармакларын бераз бөкләгән килеш иияк турына күтәрде һәм Нуриасманың күзләренә туп-туры төбәлде. Бәриянең үз гомерендә бер мәртәбә дә аның күзенә болай текәлеп караганы юк иде.

Нуриасма каенсеңлесенең һәр сүзен ишетте, әмма җавап бирмәде, күзләрен йомды. Чөнки җавабы әзер түгел иде. Тормыш белән тулысынча алыш-биреш ясап бетердем дип уйласа да, ул барысына да өлгерә алмаганлыгын аңлады. Бәрия хакында ул уйламаган түгел, кат-кат уйлаган, аның кылган гөнаһларын, үзен рәнҗетүләрен кичергән иде. Әмма ул аны бәхилләсә, Сәгыйдулла истәлегенә тап төшерер, ә иң хәтәре Нуриасмага авыл кешеләре рәнҗерләр кебек тоелды.

— Җиңгәчәй?! — дип ачыргаланып кычкырды Бәрия.

Башкага өметләнергә берниндн хакы булмаса да, ул Нуриасмадан моны көтмәгән иде. Җиңгәчәсе күзләрен ачмады, әйе дә, юк та димәде,

ләкин ул тере иде, сүзен әйтерлек иде. Бәриянең ни соравын аңлап ята иде — моны өйдәгеләр һәммәсе дә күрде һәм аңлады.

Гыйзделиса, Нуриасманы бу газаптан коткарырга теләп, Бәриянең иңбашына йомшак кына кагылды.

— Бар инде, кызым, чык,— диде ул акрын гына.

Бәрия, сукыр кеше кебек әллә кая төбәлгән хәлдә, аякларын сөйрәп атлый-атлый чыгып китте, аны барысы да күз карашы белән озатып калдылар...

Ул беркемне күрмичә, беркемгә дәшмичә урамга чыгып җитте. Инде таң беленгән иде. Бер генә мизгел, бу кайсы төш дигәндәй, як-ягына каранып алды да башын иеп өенә йөгерде, йозакны аяк астына бәрде, өйалды ишеген киереп ачылган килеш калдырып, өй эченә керде дә, ут-мазар яндырмыйча, матурлап күпертеп җыештырылган караватына капланды...

«Бәхиллек бирмәде, миңа гына бәхиллек бирмәде»,— диган хурлыклы уй аны чыгырыннан чыгарды. Авыл тарихында бәхиллек бирмәү хәлләре бик сирәк була торган хәл иде...

Ул караватыннан шуып төште дә кабаланып карават астыннан кара сандык сөйрәп чыгарды, аны шартлатып ачты. Сандыкның эченә йөзлекләр, иллелекләр, егерме бишлекләр, унлыклар кырын бастырып, тыгыз рәтләргә тезеп куелганнар иде. Бәрия аларга беренче мәртәбә күргәндәй карап торды. «Ярабби! Шундый матур башланган тормыштан шушы кара сандык кына калдымыни соң?! — дип коты очып уйлады ул.— Нишләп? Ник?!» Ул, җавап эзләгәндәй, затлы келәм эленгән стеналарга, сервант тулы сервизларга карады, таң нурыннан алсуланган кыйммәтле челтәрләрне, пәрдәләрне күз карашы белән капшады... Бөтенесе буш, кирәксез, әһәмиятсез иде...Нинди мәгънәсез тәгәлләнү... Башлануы нинди күркәм иде... Ник болай булды соң?! Ярабби! Бөтенесен алдыйм дип ул үзен генә алдаган булып чыга түгелме соң?! Бу уйдан аның күз аллары караңгыланып китте. Бу — коточкыч иде! Ул нишләргә белмичә өйнең урта бер җирендә басып торды, шашынган кешедәй әле бер, әле икенче якка карады, тик өйдә бер җан иясе дә, хәтта мәче дә юк иде. Ул «лырык» итеп урындыкка утырды, терсәкләрен өстәлгә куеп башын учлады, бармаклары арасыннан инде бәсәрә башлаган чәчләре асылынып төште. Ул тавышсыз гына елый, күзеннән мөлдерәп аккан яшьләре ирен читләреннән тозлы булып авызына керәләр иде...

«Ник соң мин кешеләрне күралмадым? Ник мин аларга миһербансыз булдым?» — диде ул үз-үзенә һәм шушы ачык куелган сорауга ачык җавап эзләде. «Барысы да Закирҗаннан башланды»,— диде ул, әмма шундук бу фикернең ялган икәнлеген сизде. Гомер буе ялганланган, ә менә хәзер ялганларга ярамый иде. Закирҗан чакырмаса, ул барыбер кемне дә булса табачак иде — бусын ул яхшы хәтерли. Шуңа күрә аның Закирҗанга булган ачуы да әллә ни озакка бармады, онытылды. Ул аңа бозым ясатканда да нәфрәттән бигрәк, «Моны алдадым әле»,— дип үзен миннән өстен куеп, көлеп йөрмәсен, дип ясатты. Соң алай булгач, сәбәп нәрсәдә? Ник күралмады ул кешеләрне? Бәрия урамы-урамы белән авылны хәтереннән үткәрде һәм үзе нәфрәтләнгән, ни өчен дә булса чыннан да күрә алмаган бер генә кешене дә тапмады. Бу ис-акыл китәрлек хәл иде. Әгәр Бәрия яшь чакта артистлыкка китсә, сәхнәгә менә алса, әлбәттә, үзе дә әшәкеләнмәс, гомере дә мондый аяныч булмас иде. Дөньясыннан әллә шуның үчен алдымы соң ул? Бәрия нидер сизенә башлады, ләкин зиһене белән аңа барып җитә алмады. Юк, турысын әйткәндә, Бәрия аңа барып җитәргә теләмәде, курыкты. Чөнки бу аек акылга сыярлык түгел иде. Әмма күпме генә карышса да, бая үзе барып җитә язган теге куркыныч, үкенечле нәрсәдән күпме генә качарга омтылса да, кача алмады, кешеләргә һәм үзенә кылган иң зур җинаятенә килеп төртелде. Бу җинаять йөрәге теләмәгән, күңеле кире каккан әшәкелекне эшләүдән гыйбарәт иде: аның авылда бер генә күралмаган кешесе дә булмагач, ул гомере буе

аларны кұралмаучы ролен уйнаган гына лабаса! Бу бит коточкыч хәл! Димәк, аның бөтен тормышы, чибәрлеге, зиһене, зирәклеге, уңганлыгы гомере буе шул әшәке уенга сарыф ителгән! Асылында андый булмаган килеш әшәкелек кылу ник кирәк булган соң?!! Шушының белән үзеңне алардан өстен итеп тою бәрабәренә алынган ләззәт өченме? Җинел тормыш дулкынында уйнаклый-уйнаклый йөзгәндә бу уйлар ник ялгышып та килмәделәр икән? Аның авылда беркемгә дә нәфрәтләнмәвен, үчләшмәвен, күңеле белән әйбәт, миһербанлы икәнлеген үзе дә сизмичә болай гына уйнаганлыгын һәм ялгышын хәзер генә күргәнлеген, бәлкем, кешеләргә аңлатып булыр? Ләкин моны аңлатудан кемгә җиңеллек килер соң? Әнисенең, Сәгыйдулла абыйсының, Закирҗанның җир астында черегән сөякләренәме? Үлеп ятучы Нуриасмагамы? Аның тарафыннан мең мәртәбә алданган авылдашларынамы? Юк, кешеләргә үзе түктергән кадәр кан-яшь түгә-түгә, чәчен йолкый-йолкый сөйләсә дә, аңа беркем дә ышанмаячак. Хәтта бөтенләй башкача яши башласа, бу акчаларын аларга тигезләп өләшеп чыкса да, аны аңлый алмаячаклар, акылыннан шашкан дип көләчәкләр генә иде... Бер генә мәртәбә дә уңай яктан телгә алырлык нәрсәсе булмаган мондый тормыш кирәкми иде. Ул кискен торып басты, шкафның аскы тартмасыннан шактый зур шешәгә салынган нашатырь спирты алды. Ләкин куллары дер-дер калтырый башлады, ул аны ашыга-кабалана урынына куйды. Юк, аның мондый эшкә көче мәңге җитмәячәк. Яшәгәндә каргасалар да, ичмасам күмгән чакта каргамасыннар, дип уйлады ул. Моның өчен нидер эшләргә кирәк иде, тик Бәрия аның ни икәнен белмәде. Шулай да иң беренчесе итеп җиңгәчәсеннән кабат бәхиллек сорарга булды. Моның өчен чәчен-башын тарарга, юынырга, үзен кеше кыяфәтенә китерергә кирәк иде...

* * *

Нуриасма түземсезлек белән таңны көтте. Ул гомере буе таң белән торды, таң белән ятты. Җир йөзендә таңнан да матуррак нәрсә юк. Таң атканда бөтен нәрсә — сулар-һавалар да, үләннәр, чәчәкләр, җиләк-җимешләр дә шифалы. Барлык тереклек ияләренең җан җылысы җир өстенә җәелгәндә таң җиле булып исә. Нуриасма Маратны җиде мәртәбә Ык буена алып төшеп, таң суы белән юындырды, таң суы эчерде. Таң суы, таң чыгы, таң җиле күңел чирләрен дә дәвалый... Менә таңның ал нурлары өйгә керде.

— Килдеңме? — диде Нуриасма. — Рәхмәт... Мин сине көттем... Тагын күрдем.... Нурыңны күзләремә алам...

Аның тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты, кайбер сүзләре генә аңлашыла иде.

— Әллә саташа инде, — дип пышылдады Маһинур.

— Тавышланмагыз, таң белән сөйләшә ул, — диде Мосаллия.

— Тиздән мин китәрмен... — диде Нуриасма. — Мине ямьсез итеп күрсәтмә... Мине юксынма, балаларны да үзең белән торырга күнектер... — Ул матур итеп елмайды.

Инде тавышы бөтенләй ишетелмәсә дә, аның әле зиһене эшли иде.

«Менә, җиркәем, синең куеныңа, ата-бабалар янына барам, — диде күңеленнән. — Гомер буе туендырдың, яшәттең. Рәхмәт, бик күп матурлыкларыңны күрдем. Яшәп тә, күреп тә туя торган түгел син. Миннән соң да ямьле бул...»

Ләкин Нуриасма уен төгәлли алмады, аңа нидер булды, күз алдыннан таң яктысы юкка чыкты, әллә нинди шәүләләр генә йөгереште. Ул тимердәй авырлык белән нәрсәнеңдер күкрәгенә таба кысыла баруын тойды...

... Кинәт бернинди газап-әрнү калмады, тып-тын булды һәм ябалак-ябалак кар ява башлады, бөтенесе аклыкка күмелде. Аннары, кар бөртекләре сары, кызыл, яшел, зәңгәр, шәмәхә төсләргә керделәр, туктаусыз

бөтерелделәр... Якында гына басудагы биш каен күзгә чалынды... Ул арада, барлык төсләр буталып, кап-кара кар яварга тотынды, алар йолкынган кара йон төсле эриләр һәм бик акрын төшәләр иде. Акрыная бара-бара бөтенләй хәрәкәтсез асылынып калдылар, аз гына күренгән аклыкны да, теге биш каенны да тораташ караңгылык томалады...

... Фәрит агач бакчасы яклап өй кыегына сөялгән баскычның аратасына утырып хәл алмакчы, күңелендәге авыр уйларын таратмакчы булды. Ләкин аратага Маратның теге иске чалбары эленгән иде. Ул аны читкә атмакчы булып кулына алды да, аңа, беренче мәртәбә күргәндәй, озаклап карап торды, тәрәзәдән төшкән яктылыкта ялтыраучы тимер сәдәфләрен бармагы белән басып-басып карады. Шулчак ул үзенең иң башына кемнеңдер йомшак кына кагылуына күтәрелеп карады. Аның каршында Кифая апасы басып тора иде.

— Әллә таныйсыңмы? — диде ул, пышылдап.

— Кемне? — диде Фәрит берни аңламыйча.

— Ыштанны әйтәм. Танымыйсың бугай...

— Ник танымаска? Маратныкы.

— Маратныкы! — дип куйды Кифая үртәгән төсле итеп.— Әни көндез миннән юдырып элдерде аны.

— Киярлеге калмаган инде моның...— диде Фәрит.— Ямау өстенә ямау.

— Их, Фәрит, ул бит син киеп йөргән ыштан! — диде Кифая үпкәләү катыш әрнүен белдереп.

— Нәрсә?! Ни диден син?!

— Синең ыштаның...— Кифая апасы өйгә кереп китте, ә Фәрит башына суккандай катып калды. Чалбарны кулына алып, яктыгарак килде, бөтен җирен рәттән карарга кереште, бердәнбер кесәсен әйләндерде. Кесә ашъяулык төсле шакмаклап сугылган киндердән иде. Шунда ул барысын да хәтеренә төшерде...

... Бу чалбарны әнисе әтисенең сугыштан киеп кайткан гимнастеркасыннан теккән, шуның сәдәфләрен таккан иде. Кесәсез генә иде ул башта. Бик үтенеп сорагач, әнисе иске ашъяулыктан бер кесә ясап бирде. Фәрит, чалбарның кесәсенә әйбер салып, кош тоткандай урамга чыккан иде, малайларны кызыктырган, мактанган иде... Ничә еллар буе әнисе Фәрит кигән чалбарны саклаган! Ул аны сандыгының иң түрендә кадерләп тоткандыр, сагынып, сөеп яшерен генә алып карагандыр. Ул ике куллап тоткан килеш чалбарга йөзе белән капланды һәм елап җибәрде. Кинәт аның йөрәгендә нидер чеңләп өзелгән кебек булды, ул сискәнеп китте, чалбарны тоткан килеш, елавын да яшермичә өйгә, әнисе янына атылды. Бер генә сүз, бер генә сүз! «Рәхмәт!» дип әйтергә генә өлгерергә кирәк иде... Бер генә сүз!..

Ул ишекне ачып бусагадан атлаганда ук ниндидер сәер, шомлы тынлыкка игътибар итте.

— Әнкәй!!!

Аның аһылдап кычкырган тавышы бөтенесен дә сискәндереп җибәрде. Бөтенесе дә ялт итеп аңа карадылар, бөтенесе дә борылды, кыймшанды. Әнисе генә керфеген дә селкетмәде... Аның кулы идәнгә тия язып салынып төшкән иде инде...

Аның артыннан ук Бәрия килеп керде. Кемдер түр тәрәзәне ачып җибәрде, Зөбәрҗәтнең ал шәфәкъ сеңгән челтәр-пәрдәләрен селкетеп өйгә таң җиле бөркелде... Таңның тәүге саф тирбәлеше өлгергән иген исләре белән Нуриасманың караваты янына сөрлегеп үкседе, аның ак маңгаен, әле ябылып бетмәгән күзләрен, битләрен һәм иреннәрен сыйпады, иркәләде дә алгы өйнең ачык тәрәзәләреннән чыгып очты. Ул аның тән һәм җан җылысын сеңдереп, Нуриасма гомере буе омтылган, җанына рәхәтлек, йөрәгенә көч алган Ык буйларына, болыннарга, әрәмәләргә, иген басуларына шул җылыны таратырга очты, аның инде бүтән беркайчан да алар янына килмәячәген хәбәр итәргә ашыкты...

...Табигать йокысыннан уянырга әзерләнә генә иде әле. Ык ярындагы тал, балан, шомырт, каен яфраклары жинелчә генә лепердәшеп куйдылар, аларның ботакларына кунып сайраучы кош-корт тавышлары бер сагаеп, акрынаеп алдылар да елагандай нечкәрделәр, моңлырак яңгырый башладылар... Кичтән умартасына кайтып житә алмыйча, зәңгәр чәчәкнең уртасына кереп йоклаган бал корты озын сабакның жилдә чайкалып куюыннан чак кына егылып төшмәде... Басу читендә үсеп утыручы бодай сабагын төптән чәйнәп, ачкылт сүленең таныш тәмен татый башлаган тычкан туктап калды, ялт-йолт каранды... Кабык күлендә йөзүче бер оя чүрәкәй үрдәк таң жиленең исүенә куанычтан куркылдашып куйды. Мылтык тоткан ике кара шәүләгә шул гына кирәк иде...

Иртәнге тынлыкны чатнатып ату тавышы гөрселдәде. Үрдәкләр һавага күтәрелделәр. Яңадан бер-бер артлы ике тапкыр ату тавышы яңгырады, тирә-юньгә сасы төтен исе таралды. Кошлар, котлары алынып, пар өянке ягына очтылар, бал корты чәчәктән егылып төште. Һава дулкыны бодай сабагын кимерелгән урыныннан сындырып екты, тычкан чыелдап качты. Ана үрдәк тәненә яндырып ядрә керүен сизде, һавага кан исе таралды... Ул, балалары белән хушлашып, берничә кычкырды да, мәрхәмәтсез кулларга эләкмәс өчен, әле генә үзләре күтәрелгән күлгә таба борылды... Кайнар каны белән бергә гәүдәсеннән хәле китә барса да, ул канатларын соңгы көчен жыеп селкеде, күлгә килеп житү белән таш кебек туп-туры аска томырылды. Иртәнге шәфәкътән алланган су өстенә якынайгач, инде аңа кереп киткәндә, ул үзенең шәүләсен күрергә өлгерде...

* * *

Кадерле укучым!

Әгәр битләреңнән назлы жил иркәләсә, сандугач сайраулары, агач яфраклары лепердәшкән авазлар йөрәгеңә кереп, бәгыреңне өзсә, бел — бу әниең рухы булыр.

Әгәр тәңкә-тәңкә карлар яуганда аларның исеннән, сафлыгыннан башың әйләнеп китсә, башаклар жырыннан әсәренеп калсаң, бел — аларда әниеңнең йөрәк жылысы, аның рухы канатын сирпеп киткән чак булыр.

Әгәр елмаючы бәхетле йөзләр күрсәң, зәңгәр күктә ак болытлар йөзсә, кояшлы жылы яңгыр яуса, йолдыз-йолдыз булып язгы тамчылар тамса, бел — аларда әниләр жанының яктысы булыр. Аларның һәммәсе дә әниләр йөрәгеннән өзелеп төшкән. Безнең бу якты жиребез, ай-кояшлы, йолдызлы күк, серле галәм — һәммәсе дә әниләр йөрәге белән жылытылып, яктыртылып калган.

Кадерле укучым!

Әгәр башыңа зирәк фикер килсә, иҗади ачыш ясасаң, данга ирешсәң, кешеләргә шатлык өләшсәң һәм жирдә эзең калдыра алсаң, бел — болар барысы да газиз әниеңнең күкрәк сөтеннән, аның кытыршы кулларыннан, аның жылы күз карашыннан.

Әгәр син жирдә лаеклы итеп яши алмасаң, кешеләргә кайгы салсаң, сиңа хурлыклы нәфрәт тамгасы салынса, дөньяда бәхетсезлек таратып йөрсәң, бел — болар берсе дә әниеннән түгел, бары үзеңнән генә, бу синең әниеңнең йөрәген, йөзен, күкрәкләрен рәхимсез төстә таптавыңнан, пычратуыңнан гына.

Әгәр син шатлансаң, ләззәт алсаң, бәхетеңне тапсаң, бел — болар һәммәсе дә әниеңнең йокысыз төннәреннән, кайнар күз яшьләреннән, «балам, бәгырь итем» дип күргән ачы газап-михнәтләреннән.

Мин, кадерле укучым, әниләрнең бөек рухы турындагы татлы да, ачы да уйларым белән синнән аерылам...

**Камил Мостафин**

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Яңадан чык әйдә кырга, анда чирәм
нинди куе, нинди яшел, нинди үскән...
Сузыл җиргә, күзләреңне күккә төбәп,
бәхетеңне көтмәсәң дә биеклектән.

Явыз тормыш, кыен язмыш, кыска гомер,
нинди авыр бу аһәңнең аккордлары!
Ничек үсә, каралмыйча, ромашкалар,
ничек калган бу аланда бал кортлары?

Тыңлап кара ерактагы адымнарын
сиңа якын һәм сиңа ят кешеләрнең,
сүгенгәнен — алданган һәм арганнарның,
пышылдавын — моңлыларның, сүзсезләрнең.

Тыңлап кара кычкырганын горурларның,
аңлап кара ачы сүзен каршыларның,
үксегәнен ятимнәрнең, гариплэрнең,
үксезлеген, тиңсезлеген ярсуларның...

Аңлый алсаң,— аңлап кара чор алдында,
җир алдында — көчсезләрне, көчлеләрне,
ак төсләрен саклап калган чәчәкләрне,
кешелеген саклап калган кешеләрне...

* * *

Ватан!
Йөзә заман диңгезендә.
Учакларын кемнәр яккан соң?
Кояшларын кемнәр югалткан соң?
Бәхетләрен кемнәр тапкан соң?

И кешеләр, безнең өметләрне
чит йолдызга алып китмәгез,
бу күкләрне, берүк, каргамагыз,
бу суларны, берүк, сүкмәгез!

Хыял каберләре арасында —
төркем-төркем кеше... Ни көтә?
Поездларга утырып, чит җирләргә,
ят якларга язмыш, җыр китә.

Ах, кешеләр, безнең сагышларны
чит илләргә алып китмәгез,
бу ташларны, берүк, каргамагыз,
бу туфракны, берүк, сүкмәгез!

Яңа көннәр килә. Әллә кемнәр
безнең язмышлардан көләрләр,
моңсу далалардан зәңгәр көртләр
безнең кайгыларны күмәрләр.

И кешеләр, безнең ялгышларны
яңа чорга алып китмәгез:
бу сүзләрне, берүк, каргамагыз,
бу хисләрне, берүк, сүкмәгез...

## Хыялны озатканда

Бәхилләшү минутлары житте,
хисләр янды, дөнья чуалды,
бүген таңда шәрә кырга чыгып,
озатабыз тәүге хыялны.

Безнең юлдан шашкан җаннар узган,
мәрхәмәтсез булган көннәре,
алар салган хыял сараенда
бүген уйный мәхшәр җилләре.

Анын шыксыз, шомлы залларында
конфет кәгазьләре очалар,—
бизәкләре күзне камаштыра,
шаккатыра, ләкин — буш алар.

Җирдә кара күкнең күптән сүнгән
кояшлары ята коелып.
Хәл аласы килә, юлда үскән
таныш тирәкләргә сыенып.

Тирән үзәннәрдә нәни өйләр
посып утыралар, моңаеп.
Йолдызларга кагыласы килә,
кыяларга басып, тураеп...

* * *

Нинди атауларда яши күңел?
Нинди таңнар аңа җылы бирә?
Омтылганда олы максатларга,
ник күңелгә әллә ниләр кирә?..

Шәһәр базарыннан узган чакта,
соңгы алмаларның тәмен татып,
нигә истә кала күз карашы
иске кием сатып торган картның?

Нигә һаман китми йөрәгемнән
бер сабыйның үксеп елаганы:
«Күрмәдеңме, абый, курчагымны?»,—
диеп, өзгәләнеп сораганы?..

Ә бер яшь кыз минем автобуска
ашыгып кергән чакта иртә таңда,—
сәер язмыш, уйларымны бутап,
күңелемдә нинди шәмнәр яга?..

* * *

Башкисәрләр була — корбан эзли,
комсыз җаннар була — байлык эзли,
шашкан җаннар була — гауга эзли,
бала җанлы кеше — нәрсә эзли?

Ах, аңарга башка җаннар кирәк,
төннәр җитсә,— тулы айлар кирәк,
буш булса да,— җылы сүзләр кирәк,
чит булса да,— моңлы күзләр кирәк.

Сез, кешеләр, кызганыгыз аны,
йөзегезне сез ачыгыз аңа,
и сылулар, күккә айлар менгәч,
бер алдагыз — эндәшегез аңа!

Ул ишетеп алыр, йөгереп чыгар,
җавап бирер, сөйләр... Сез тыңларсыз.
Ул кулларын сузар — айга, сезгә,
ул елмаер, көләр — сез еларсыз...

## Өнсез этләр

Урамнарда, озын тыкрыкларда
өнсез этләр йөри... Йоннары
киезләнеп беткән. Зур шәһәрдә
бигрәк хәтәр йөргән юллары.

Ашаткан да кемдер, әчерткән дә,
аннан туйган, куып чыгарган...
Өйсез этләр, ах сез, бәхетсезләр,
язмыш корбаннары, чыдамнар...

Киләләр дә кайчак, кешеләрдәй
күзгә карап тора бер читтә.
Гаепледер кебек — бу тормышта,
хәерчедәй, җиткәч шул чиккә.

Үги җаннар... Ә бит уйлап баксаң,
гаепләре шул ук һаман да:
алар туган мәрхәмәтсез илдә,
алар яши шашкан заманда.

## Аһәң

Кузгалдылар — уйлар, хисләр, төсләр,—
оркестрлар әзер уйнарга.
Шаярдык һәм көлдек... Инде менә
һәркайсыбыз әзер еларга.

Өйләр туңган... Җәллад балтасыдай,
боз ялтырый урам, мәйданда.
Хәтер һәм үкенеч — безнең белән,
без табасы өмет кайларда?

Тәрәзәләр күккә төбәлгәннәр,
дөнья көтә... сулый... һәм тыңлый,
уйлар сыймый бүген җәнҗал башка,
чиксез һаваларга җан сыймый.

Пышылдасаң, кырау коелыр күк
йолдызлардан, айдан, ботактан...
Хәзер... менә хәзер... көй башланыр,—
серле әмер килә еpактан.

Трубачының — туңган иреннәре,
күр, ябышкан алар бакырга,
хәзер, менә хәзер моң ишелер
шәрә җанга, шашкан акылга.

Ул ишелер, безне шаккатырып
һәм калдырып телсез,
аннары
ул агызып китәр әллә кая
безнең ятим, сукбай җаннарны...

* * *

Уза вакыт, уза — камаштырып күзне,
кара төсне ялгап ак һәм соры төскә.
Көннәр очкан чакта, барыр юлны күзлик,
артка карaганда,— карыйк астан өскә.

Анда — дәвер, анда — замандашның зары,
авылдашым юлдан атлап килә көчкә,
аның көннәренә, аның төннәренә,
аның гомеренә карыйк астан өскә.

Анда — сабыйларның тәүге хыяллары,
анда — гүзәл язлар әверелгән көзгә,
туган илебезнең кара күкләренә
бер күз ташлыйк әле әйдә астан өскә.

Анда — елмаюлар, анда — ялгышулар,
анда безнең сагыш җырлар булып үскән,
узган мәхәббәтнең шаян күзләренә
карап торыйк әле әйдә астан өскә.

Еpактагы моңнар янгырыйлар һаман,
безнең җәрәхәтле йөрәкләргә тиеп...
Үткән замананың хәвефләре — ачы,
ялгышлары — яман, йолдызлары — биек...

## Тәүфикъ Әйди

# ЙӨРТӘ БЕЗНЕ ЯЗМЫШЛАР

АЛМАНИЯ СӘЯХӘТНАМӘСЕ

Капкалар ачылды.

Әле кайчан гына бездә кемгәдер чит илдән хат килеп төшү шактый хәвефле бер вакыйга санала иде. Миңа исә 1989 елның көзендә хат кына түгел, кунакка чакыру кәгазе китереп тоттырдылар. Кая диген әле — Көнбатыш Алманиягә (Германиягә)! Тәвәккәлләп барыргамы, әллә бармаскамы?

Дөрес, илгизәрләр тегендә-монда һәрвакыт йөри тора, елына меңәрләгән генә түгел, миллионлаган гражданнар үз йомышы белән яки бүтәнчә дәүләт чиген атлап чыга. Күпчелеге, билгеле, социалистик илләргә, туристлар көтүенә кереп. Ләкин туганнан бирле коммунистик тәрбия алган илдәшләрне анда буржуйлар коткысына бирелеп ул-бу хәлгә тарымасын өчен, күз өстенә күз саклый иде элек: каты куллы җитәкче белән уяулыгы шөбһәләндермәслек һич югы бер шымчы (сексот!) янәшәндә бөтерелә иде. Капиталистик илгә бару өчен, әүвәл әнә шундый «көтүдә» социалистик дәүләтләргә өч мәртәбә сәфәр чыгып, сексотларның «ышанычлы» дигән фәтвасын казанырга кирәк иде. Бигрәк тә партия-совет түрәсе яки аларның тугрылыклы куштаны булмаган бәндәгә!

Дөрес, соңгы дәвердә халыкара бәйләнешләргә дә хөррият җилләре тәэсир итә башлады. Сәяси яктан! Ә менә кесә ягыннан... хет каравыл кычкыр. Илгизәрләргә сиксәненче елларда 34 тиенгә сатылган ГФРның бер маркасы хәзер йөзләрчә мәртәбә кыйммәтләнде! Бер нәни чынаяк кофе — ике марка, бер кабымлык сосиска өч марка бәяләнгәндә, хәләл акчаңны суга салу кебек түгелме соң бу?

Халыкара паспортны, илчелек рөхсәтен, сәяхәт билетларын юнәтер өчен айлар буе төрле-төрле бусагаларны таптарга, шуның өчен Мәскәүгә махсус ике мәртәбә барып кайтырга, кабат-кабат сәгатьләр буе чиратларда тинтерәргә дә туры киләчәк ич әле!

Әмма 1990 елның марты уртасында Рәсәй башкаласының Киев вокзалында «Мәскәү-Кельн» поездына утырганда барлык икеләнүләр, «Интурист» кассасында шабыр тиргә батып биш сәгать буе чират тору, әллә никадәр бүтән михнәт чигүләр онытылган иде инде. Карлы-бозлы яңгыр ява, аяк асты — чыпыр су, акыллы кешеләр өйдә генә утыра торган ямьсез вакыт. Ләкин бу газаплар, ходайның хикмәте, күңелдәге яңа

---

Тәүфикъ ӘЙДИ (1941) — *әдип, «Елан угы» романы, «Божра» повесте, хикәя һәм очерк китаплары авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Сәяхәтнамә кыскартылып басыла.

җирләргә аяк басарга ашкыну, «тимер пәрдә» артындагы ят дөньяны үз күзен белән күрергә омтылу дәртен сүндерә алмый икән.

Проводникка билетымны һавалы-тәкәллефсез генә күрсәтеп, халыкара вагонга керәм. Шулай, бу инде сезгә Канашка бара торган пычрак, караңгы «әрҗә» генә түгел — коридорының да полировкалары, никельләре ялык-йолык итеп тора. Идәндә — келәм. Купелары — өч кешелек, анда юынгычына, салкын суына кадәр бар. Кием элгечләре чаршау астында. Затлы туалет шкафы эчендә, ишеген ачуга, үзеннән-үзе гөлт итеп ут кабына. Ятаклары берсе өстендә берсе өч катлы, минеке — иң югарыдагысы икән. Мин әле анда төнлә чамасыз бөркү булачагын уйлап уфтанмыйм, сәфәргә җыену мәшәкатьләре артта калуыннан җиңел сулап, хәтта кәефләнеп, юлдашларым — ике яшүсмер белән танышырга керешәм.

Абыйлы-энеле немесләр икән. Гаиләләре белән Алманиягә күчеп китеп баралар. Ишле гаилә — өч буын, унсигез җан. Калганнары — күрше купеларда, вакыт-вакыт урын алмашып, минем янда төрлесе төрле гәп корып ала. Кузбасстан, шахтерлар. Әти кешенең стажы — утыз биш, олы улыныкы — биш ел.

Нәкъ менә Алманиягә барганда юлдашларымның немес булуы бик әйбәт — тегене-моны сорашкалап, аларча сүз байлыгымны арттырырмын, шулай ят илдә иркенрәк йөрергә әзерләнермен, дип уйлыйм. Баксаң, юлдашларым мин укыган немес язучылары әсәрләренең күбесен ишетмәгәннәр дә, күрмәгәннәр дә. Инде ничә буын Рәсәйдә яшәгәнлектән, туган телләрен дә җуеп бетерә язганнар.

— Без сөргендә үстек, — диде иртән купебызга кереп утырган гаилә башы. — Тайгада, урыс арасында яшәдек. Аннары гына Кузбасска күчеп килдек. Шахтада төрле милләт кайный, арада татарлар да күп иде. Әти-әни немесчә сөйләшкәнлектән, мин дә бераз сукалыйм. Ә балаларының кайсы төшенә, кайсы юк. Алмания тормышына ияләнү җиңел булмас. Бер киявебез бөтенләй урыс егете әле, гаиләбез ишле генә түгел, катнаш та!

— Нигә китәсез соң? Хезмәт хакы түбәнлектәнме? Фатир кысанлыктанмы?

— Китәргә булдык инде, — ди немес агае ипле генә. — Болай Кузбасста да кешедән ким яшәмәдек. Фатирыбыз да, акча ягы да кешенеке чаклы иде. Бригадабыз алдынгы булганга, күбрәк тә ала идек. Шулай да... Советлар илендәге хуҗасызлык, оешмаганлык йончытты безне. Һәр тармакта! Эчүчелек чамадан тыш таралган. Рәсәйдә уңай якка борылыш тиз генә булмас әле.

— Әллә сезгә ятсытыбрак карадылармы?

— Юк. Кеше эштә бик тиз сынала бит ул. Хөрмәт итәләр иде безне. Ләкин үзебез канәгатьлек таймадык. Гомер уза, тормышыбызны көнеллдән санап булмый иде. Телебез дә югала, башкасы да. Шуңа күрә былтыр олы кызыбыз Германиягә күчеп китте. Ире белән. Шул безне дә күчәргә өнди башлады. «Сагынам!» дип хат арты хат яудырды. Ирексездән шуның янына кузгалдык менә.

Кызын юатыр өчен генә унсигез кешеле гаилә башлыгы гомер иткән җиреннән дәррәү кубамы соң? Сагынган кеше үзе ансатрак кайтып килә ала ич. Димәк, абзыйга сылтау гына кирәк булган...

Юлдашларым кулында совет немесләры язмышын яктырткан журналларны күргәч, мин үз фаразымның дөреслегенә тагын бер мәртәбә ышандым.

Немесләр Рәсәйгә XVII йөздә үк күчеп килә башлый. Аларның Идел, Днепр елгалары, Кара диңгез буйларында тамыр җибәрүенә урыс патшалары үзләре юл ача, чакырып китерә дә төрле уңайлыклар бирә. Һөнәрле, тырыш халык империянең сүлпән тормышына яңа рух өрер, аның матди нигезен ныгытыр, дип өметләнәләр. Бу өметләр чыннан да аклана. Күчеп килгән немесләр арасыннан озакламый оста һөнәрчеләр,

житез эшкуарлар гына түгел, Рәсәй әдәбиятын, сәнгатен, фәнен баеткан Д. Фонвизин, А. Фет, К. Брюллов, И. Крузенштерн, Ф. Беллинсгаузен, Ф. Литке, Б. Якоби, П. Шмидт, О. Шмидт кебек күренекле шәхесләр дә үсеп чыга. Немецләр революциядә дә актив катнаша, мисалга, Казанның үзәк урамына исеме кушылган Николай Бауман — шуларның берсе. Революциядән соң корылган Идел буе Немес Автономияле Республикасы бөтен милли җөмһүриятләр арасында матди һәм мәдәни үсеше ягыннан тиз арада зур казанышларга ирешүе белән танылa. Бөек Ватан сугышы дәверендә Советлар Союзы Герое генерал С. Волкенштейн, партизаннар командиры А. Герман, разведчик Р. Зорге һәм башкалар җиңүгә шанлы өлеш кертте. Әмма сталинчыл җитәкчелекнең гаделсез милли сәясәте совет немесләренә дә кагыла — бөтен ил күләмендә аларның мәдәни учаклары ябыла — күп кенә җитәкчеләре кулга алына. Алмания сугыш башлагач исә, автономияле җөмһүриятләре таратыла, бер гаепсез немесләр тулаем Себер, Казагыстан төрмәләренә илтеп ябыла, сөргеннәргә сөрелә.

1957 елда бу гаделсезлекләргә нinfдидер дәрәҗәдә чик куела, кайбер милли мәдәният учаклары тергезелә башласа да, Идел буе немесләре республикасы яңадан аякка бастырылмый, халкының бергә тупланып яшәве өчен тиешле шартлар тудырылмый. Бу эш үзгәртеп кору дәверендә дә юлга салынмагач, өметләрен өзгән немесләр Алманиягә күчеп китәргә керешә: 1988 елда — илле мең, 1989 елда — йөз мең. Бу агым торган саен көчәя бара, — соңгы елларда икешәр йөз меңгә якынлаша, чөнки Алмания авыр хәлдә калган милләттәшләренә булышу мөмкинлеген таба. Күрше купеда барган Вольдемар Крамер белән танышу миңа моны хәйран ачык күзалларга ярдәм итте.

Вольдемар — типсә тимер өзәрлек таза-сау ир-егет. Ул шахтер юлдашларыннан зыялылыгы белән аерылып тора. Әллә сынар, әллә хушкүңеллелеген күрсәтер өчен, танышкач, ул:

— Сез дә Дойчландка бөтенләй күчеп барасызмы? — дип сорады.

— Халкымның тарихи ватаны Алмания булса, икеләнмәс идем. Язмышыбыз мәңгегә Идел буена бәйләнгән, миңа күреп кайту да бик җитә.

Җавабым Вольдемарга ошады, ахры. Бөтен мөгамәләсеннән дустанә сөйләшүе сизелә башлады.

1952 елда Томск өлкәсендә туган, 1957 елга кадәр тайга уртасында үскән икән. Аннары Казагыстанга күчеп килгәннәр. Новосибирск энергетика институтын тәмамлагач, Җамбыл (Казакъча һәм татарча язылышы. Урысча «Джамбул»), шәһәрендә урнашкан.

— Сәүдә идарәсенә үлчәүләр инспекторы булып эшкә кергән идем, — диде юлдашым. — Чамалыйсыздыр, «төшемле» эш ул. Әйбәт яшәдек. Ләкин шулай да, хатынымның туганнары чакыргач, моннан биш ел элек ГФРга күчеп киттек. Әни белән туганнарым Җамбылда калган иде, әле шуларны күреп, кунактан кайтып баруым. Совет паспортын да саклаган идем, СССРга аяк басар өчен рөхсәт сорап тинтерәргә туры килмәде.

— Германиядәге тәртипләргә күнегү кыен булмадымы соң?

— Үзегез уйлап карагыз, — диде Вольдемар. — Алмания читтән күченеп кайтучы милләттәшләрен үз хисабына алып, ике ел асрый. Бу үзенне яңа шартларга ияләштерү, тормыш итәргә әзерләнү дәвере санала. Шушы чорда немес телен өйрәнергә, яңа һөнәр үзләштерергә тиеш. Шушы вакытта ай саен гаилә башлыгына — 1200 марка, гаиләнең бүтән әгъзаларына — берәр мең, балаларга 170 әрне (алар күп булса, җан башына ярдәм күләме дә үсә) түләп тора. Дәвалау, дарулар — бушлай. Күченгәндә бөтен чыгымнарыбызны — билет бәяләрен, багаж өчен түләүләрне хөкүмәт үзе каплый, аннан тыш һәр гаиләгә җидешәр мең марка ярдәм бирә, ватанга аяк басу көнен бәйрәм итәр өчен һәр кешегә янә 600 әр марка өләшә. Вакытлыча урнашкан лагерьда көнкүреш уңайсызлыклары

кичергән өчен гаилә башлыгына 230, бүтәннәргә 200 әр марка күләмендә бер мәртәбә ярдәм күрсәтә. 1956 елга кадәр туган затларга, сөргендә булган өчен, унбишәр мең марка түли, ягъни нимес булган өчен җәбер татыганнарына Алмания хәерхаклык күрсәтә. Менә шулай каршылады безне тарихи ватан, гаиләбез ике ел дәвамында дәүләттән 104 мең марка күләмендә ярдәм алды. Әлбәттә, халкыбызга хас төгәллек белән бик күп тиешле документларны рәсмиләштергәннән соң!

Ирле-хатынлы Крамерлар Алманиягә уллары белән күчеп килә, монда аларның икенче балалары туа. Килүгә аларны кунакханәнең бер бүлмәсенә урнаштыралар, аннары вакытлыча яшәргә барактагы торакка күчерәләр. Биш айдан соң инде ике ярым бүлмәле ($52м^2$) фатир тәкъдим итәләр. Моңа риза булмагач, күчеп килүләренә тугыз ай тулганда 3,5 бүлмәле ($98м^2$) фатир бирәләр.

— «0,5 бүлмә» дигәне балалар өчен кечерәк ханәне аңлата. Җәмгысе дүрт бүлмәле фатир ул чынлыкта,— ди Вольдемар.— Без шунда яшәгән өчен аена 600 марка түлибез, ягъни гаилә кеременең унике проценты. Керемебез әзрәк булса, дәүләт фатир хакын түләргә булышыр иде. Аннары шунысы да бар: акча әрәм итәргә теләмәсәң, тотылган әйберләрне Германиядә бушлай табу мөмкинлекләре киң. Хуҗалар искергән мебелен кварталга бер мәртәбә урамга, өе турысына чыгарып куя ала. Аны сату бик кыен эш, теләгән кеше бушлай алып китсә генә инде. Кичкә кадәр аларны берәү дә алмаса, шәһәр яки авыл хакимияте идарәсе машиналары мебельне пресслап чүплеккә илтеп атачак. Тотылган, әмма тузмаган кием-салымны социаль ярдәм хәзинәсенә тапшыру гадәте дә бар. Аннан шулай ук бушлай хәйран матур киемнәр сайлап алырга мөмкин.

Бер уңайсыз ягы — Алманиядә совет дипломнарын танымыйлар икән. Вольдемардан да инженерлыкка урнашыр өчен белемен күтәрүне таләп иткәннәр. Тагын баш ватасы килмәгәнлектән, ул автозаводка механик булып урнашкан. Хатыны — монтажчы. Салымнарны басып калганнан соң, Вольдемар — 2700, хатыны — 2100 марка ала. Ике бала үстерүләре өчен дәүләт аларга ай саен 340 марка ярдәм түли. Гаиләнең кереме менә шулай туплана. Әйтергә кирәк, Алманиядә хезмәт хакы товар бәяләренә караганда күбрәк арта, шунлыктан монда тормыш дәрәҗәсе елдан-ел яхшыра гына бара. Тугыз-унике маркага — ирләр күлмәге, 200 — 300 маркага әйбәт костюм-чалбар, ун-унбиш маркага бер килограмм сыер ите алырга мөмкинлеген искәртсәк, Вольдемарлар хәлен күзаллау кыен булмас. Күчеп килгәннән соң ук кесәсенә тиктомалдан шулкадәр акча агып керә башлагач, ул тотылган «Фольксваген» җиңел автомобилен сатып алган. Алты мең маркага.

— Алты-җиде мәртәбә арзанрагын да табып була иде, әйбәтрәгенә кызыктым,— ди юлдашым.— Җиңелкәем өр-яңа шикелле, бик яхшы йөри. Дойчландта кыш кыска, юллар төзек, шунлыктан металл тиз тутыкмый, тәгәрмәчләр тиз тузмый. Машина сатып алуның исә монда бер гаҗәбе дә юк. Рождество бәйрәме алдыннан заводыбыз бер айлык хезмәт хакы күләмендә күчтәнәч акча бирә, ә еллык ялыбыз — утыз алты көн. Бу һәр завод-фабрикада шулай икән, хәтта болардан юмартраклары да бар. Менә сиңа хезмәт иясләрен изүче, аларның җелеген суыручы капиталист-ерткычлар! Шөкер, яшәп була фатерландта!

Алмания тормышына әйбәт иялэшүен исбатлагач, Вольдемарның совет дипломын да танырга булганнар. Әмма шуңа лаек дәрәҗәдә яңа эш якын-тирәдә табылмаганлыктан, ул инженерлыкка кул селтәгән. Яшәгән җире ямьле, аны бүтәнгә алыштыру гөнаһ. Дәрәҗәлерәк вазифа башкарыйм әле, дип көн дә әллә кая еракка эшкә йөрү ялыктырыр, хезмәт хакының шактый үсүе дә алай талчыгуны акламас иде.

Мин әле Алманиянең тормыш дәрәҗәсен ишетеп кенә беләм. Әмма эчемнән уйлыйм : Вольдемарның дүрт кешелек гаиләсе ватанына кайтып төпләнер өчен, аңа әле бер тиен файда китермәсә дә, ике ел дәвамында

дәүләттән 104 мең марка ярдәм алган. Әҗәткә түгел, ата-баба җирендә яңадан тамыр җибәрер өчен. Совет акчасына күчергәндә, бу суммага кырык биш «Жигули» машинасы сатып алырга мөмкин булыр иде. Шуның өстәвенә, аларга бушлай немес теле өйрәтәләр, яңа һөнәр үзләштерергә булышалар, бик тиз фатир бирәләр. Мебельне, кием-салымны да бушлай табу юллары бар икән!

— Тарихи ватанына кучеп кайтучы немесләргә ГФР ничек булышуын СССРда яшерергә тырышалар,— ди Вольдемар.— Калганнары да кызыгыр, дип куркалар, күченү ташкынын шулай зәгыйфьләндерергә өметләнәләр, ахры.

Яшерерсең дә! Аның бит әле бүтән яклары да бар. Әйтик, Татарстанга кайтып урнашырга теләгән милләттәшләребезгә хөкүмәтебез нинди ярдәм күрсәтә соң? Ул бит канэчкеч капитал ялчысы түгел, хезмәт ияләре үзләре сайлап куйган газиз хакимият! Әмма беләбез: илдән сөрелгәндә тартып алынган хәләл милекләре дә кайтучыларга кире бирелми ләбаса. Югыйсә тарихи ватаныннан ярдәм, шәфкать көтәргә һәр халыкның, һәр кешенең хакы бар.

Республикабыз җитештерә торган байлык әз түгел, ләкин ул шунда тир түгүчеләргә эләкми. Үз малына үзең хуҗа булмау, колониянең колы, авыр, кара эшләрне башкаручы алашасы гына хәлендә гомер сөрү аркасында бу. Бер башкалабыз Казанда гына да бүген күпме гаилә торак хәлен яхшыртырга чират тора!

Мин шуларны уйлап барган арада поездыбыз чик буендагы Брест станциясенә килеп туктаган лабаса. Вагоныбызга чик сакчылары, тамгачылар килеп керде. Менә шушы минутларда без дә демократия, хөррият канат җәя башлавына тагын бер мәртәбә иман китердек: өч ел элек Болгариягә — социалистик илгә чыгып барганда ыштан бөрмәләребезгә кадәр тентегән тамгачылар бу юлы купебыз ишегеннән башларын тыгып:

— Корал, наркотикларыгыз юкмы?— дип кенә сорадылар. Дөрес, бозау каләр маэмайлары иснәп, ниндидер приборлары нәрсәнедер барлады, әмма минекедәй арык чемоданнарны ачтырып тормадылар, бөтенләй күчеп китүчеләрнең симезрәк бөктәрләрен генә махсус бинага алып китеп карарга булдылар. Мәшәкатьтән болай ансат котылуга сөенгән без, бәхетлеләр, дәррәү перронга коелдык — поездыбыз озын күчәрле тәгәрмәчләрен кыска күчәрләргә алыштырганны шушында ике сәгатьтән артык көтәргә туры киләчәк иде...

Ниһаять, поездыбыз Буг елгасының сул ягына таба йөгерә. Польша җирләре башлана. Монда җиңелчә киенгән игенчеләр кырларын сукаларга, тырмаларга керешкән. Зур булмаган бакчаларда ат белән буразна сызалар. Вагоныбыздагы илгизәрләрнең бер ишесе аларны мыскыллы көлемсерәү белән күзәтә. «Теләктәшлек» профсоюзы капитализмга бик ашкынган иде, әлләни ерак китмәгәннәр әле, янәсе: ат белән сукалыйлар, йөкне дә ат белән генә ташыйлар. Өч-дүрт әрҗә лимонад, биш-алты капчык он төяп КамАЗ, ЗИЛ куарга күнеккән халык тәккәбберлеге ничек инде күршеләренә шырпы кадамый түзсен?!

ГДРда машиналар күплеге, юллар төзеклеге күзгә ташлана башлый, ГФРда исә шушы сыйфатлар яңа баскычка күтәрелә. Монда тагын шунысы күңелгә ята: дәүләт чикләрен үткәндә бездәгедәй сәгатьләр буе мыштырдау юк — чик сакчылары да, тамгачылар да үз эшләрен поезд барган көе үти. Багажларын, паспортларын күрсәткән илгизәрләргә рәхмәт әйтергә дә онытмыйлар.

Гомер буе географик картадан гына күрә алган әллә ничә илне берьюлы үз күзләрең белән тамаша кылып бару кызык та, күңелле дә. Белоруссиянең, Польшаның һәм Алманиянең табигатьләре бер үк диярлек, әмма аңа һәр милләт үз бизәкләрен төшергән. Бу — корылмаларның архитектурасында гына түгел, табигатькә мөнәсәбәтләрендә дә, хуҗалык итү хосусиятләрендә дә күзгә чалына. ГФРда, мәсәлән, биек-биек тор-

балар күккә бездәгедәй кара корым бөркеми, юл буйларында тәртипсез таралып-чәчелеп яткан бер әйбер дә күренми. Утарлар пөхтә-көяз, яз башы гына булса да, басу-кырлары инде эшкәртелгән, сыек яшел яфраклар ярып, сары чәчәк болытын бөркәнеп утырган куаклар тирә-якка хуш ис тарата, җәйге рух бирә. Әле кар эрергә һич тә җыенмаган озын кышлар иле сәяхәтчеләренә Алманиянең март һавасы шуңа күрә бигрәк тә тансык, манзаралары бигрәк тә күңелгә хуш.

Көндезге уникедә, кайсы ил гаебе аркасындадыр, нәкъ бер сәгатькә кичегеп, Һанноверга килеп җиттек. ГФРның төньягындагы, безнеңчә әйткәндә, бер өлкә үзәге. Мин монда совет поездыннан төшеп калып, илнең көньягындагы Ной Үлм шәһәренә баручы Алманиянекенә утырырга тиешмен. Перронда күземә ташланган беренче гаҗәп нәрсә — багаж арбалары. Юлаучыларның йөкләрен төяп перроннан вокзалга, шәһәр транспорты тукталышына, аннан перронга алып китәр өчен икән. Мәскәүнең Ширәмәт аэропортыннан аермалы рәвештә (СССРның бөтен җирендә анысы да юк!), һәркем түләүсез файдалана. Аларны берәү дә караулламый, ләкин арбалар югалмый, һәрчак юлаучыларга хезмәт итәргә әзер!

Тиешле перронны эзләп табып, Киль поездын көтеп алу кыен булмады. Вагон чиста, купелары пыяла белән генә бүленгән, тамбуры иркен, аның идәненә келәм түшәлгән, диварларына юл белешмәләре, сәфәр уңаендагы авылларның һәм шәһәрләрнең матур-матур манзаралары сурәтләнгән рәсемнәр ябыштырылган. Ямьле, ниндидер бер музейга эләккән кебек тоясың монда үзеңне!

Янә дикъкатькә лаек бер нәрсә — ревизорларның сәгать саен билет тикшерүе. Монда инде «куяннарга» хөррият юк! Билетта тикшерүчеләрнең код саны, минутына кадәр тикшерү вакыты мөһерләнә.

Кыңгырауларын күңелле челтер-челтер китереп, вагоннан вагонга күчмә буфет йөреп тора — тәгәрмәчләр өстендәге кешe биеклегендәге шүрлекләрдә күз явын алып тора торган ниндu генә тартмалар, шешәләр, калай яки пластмасс савытлар юк! Аларда — сыра, фанта, кока-кола, каһвә, бутербродлар. Күршемдәге карчык бутерброд белән пластмасс чәйнектә каһвә алды. Каһвәсе бер стаканнан артмый, бутерброды — өстенә чикләвек мае ягып бер-берсенә капланган уч төбе кадәр булки телемнәре. Бер кабырга бетми, икe кабырга җитми! Кызыксынып күзәтеп торам: күпме түләр икән шулар өчен? Ун марка! Безнең акчага күчерсәң, 1990 елгы уртача дүрт көнлек хезмәт хакына тиң. Ләкин Алманиядәге көндәлек хезмәт хакының уннан бер өлешен генә тәшкил итә бу. Димәк, ике ил арасында хезмәт хаклары аермасы бик зур икән. Шөкер, гади совет кешесе, немесләрдәй, корсак колы түгел, ул табигать ярата, юл буе тәрәзәдән күзен алмый. Һанновер-Мюнхен тимер юлы исә гаҗәеп матур җирләр аша уза: әүвәл тип-тигез кырлар, мөлдер сулы елга-күлләр, аннары тар үзәнлекләр, биек тау итәкләре, дисгәләгән шәһәрләр һәм авыллар артка таба йөгерә. Халыкның бик тыгыз урнашуы сизелә — бер шәһәрне узарга өлгермисең, икенчесе башлана. Көньякка таба барган саен таулар биегәя, тоннельләр ешрак очрый. Поездыбыз боргаланасыргалана әле елга ярыннан, әле Альп калкулыклары сыртыннан йөгерә, әмма уртача тизлеге йөз чакрымнан һич тә кимеми. Борынгы университет шәһәрләре Һейдельберг, Геттинген, индустрия мәркәзе Франкфурт, заманында Рәсәй революционерлары ояланган Штутгарт. Экспресс аларда ике-өч минутка гына тукталып ала да янә алга чаба. Тиз чапса да, ипле бара — кинәт кузгалмый, кинәт туктамый, як-якка чайкалмый, теләсәң — укы, яз, теләсәң — креслоңны янтайтып куй да черем ит. Биштәреңдә ризыгың бар икән, сыйлану да гонаһ түгел, өеңнән тыгып чыккан бәлешең Алман поездында аеруча тәмле булачак. Җитмәсә, ул ватандарлык хисләреңне уятып, капитал вәсвәсәсенә бирешмәскә көч өстәр!

Тамак ялгагач, күршемнең кәефе күтәрелдеме, хаҗәт нәрсәсен белешергә теләдеме, миннән нидер сорады. Саксон шивәсендә!

— Их фирштәе дүйтеш шлихет.

Әбекәем миңа ничектер шөбһәләнебрәк, сагаебрак карап торды-торды да шыпырт кына күрше купега күчеп утырды. Нәрсә дип мине ташлап китте инде ул? Кыңгыраулы буфеттан үзе белән бергә сыйланмаган, табындаш булмаган, алман ризыгын санга санамаган өченме? Әллә гел тәрәзәдән карап баруымны ошатмадымы? Начар сүз дә әйтмәдем ләбаса үзенә — «мин немесчә начар аңлыйм», дип кенә искәрттем. Чит ил кешеләрен өнәмәүләре дә бар, «гаст-арбайтерлардан» — кунак эшчеләрдән туйган алар. Билгеле, безгә моны төшенү шактый кыен. Чөнки нәкъ менә шул кунак эшчеләр хуҗаларга тотынырга чирканган яки авырсынган бөтен кара эшне, пычрак эшне башкарып килә ич. Түбәнрәк хезмәт хакына! Шуңа да карамастан, немес әфәнделәр болайрак уйлый, күрәсең: «Хәерче илләрдән киләләр дә эшче көчләр базарында безгә көндәшлек итәләр. Белемнәре, мәдәниятләре түбән, немесчә дә сөйләшә белмиләр!» Тик мондый фаразларның поездда бергә барган күршенә нинди мөнәсәбәте бар?! Аһ, җавап биргәндә мин елмаерга онытканмын, ахры. Бу халык бер-берсенә шунсыз сүз кушмый бит. Тәрбияле кеше өчен елмаю монда мәҗбүри йола дияргә мөмкин. Ә без, кешелек дөньясының коммунизм төзү белән мавыккан «алгы сафы», андый «вак-төяккә» әһәмият биреп торабызмыни инде? Вакланмыйбыз, билгеле. Без сәяхәттә дә асыл совет кешесе булып калабыз. Капкалар ачылды, мондагы бернигә дә исебез китмәгән төсле йөрик әле Европа буйлап!

## Кайтып булмый тиз генә

Сталинчылык афәте халкыбызга күз күрмәгән, колак ишетмәгән бәла-казалар китерде. Миллионнарча кеше туган нигезеннән куылды, төрмәләрдә һәм сөргеннәрдә һәлак булды. Могҗиза белән исән калганнары җисми һәм рухи имгәтелде, аларның бик күбесе ата-бабасы җиренә әйләнеп кайтырга базмады, Ерак Көнчыгышка, Төньякка, Себергә һәм Урта Азиягә сибелеп, буйдак, тол гомер кичерде яки, кырыс язмышка буйсынып, шундагы җирле халык ирләре, хатын-кызлары белән никахлашып, туган телен һәм мәдәниятен әкренләп югалта барып, ят мохиткә сеңде. Бөек Ватан сугышы халкыбызны яңа фаҗигаләргә дучар итте: кырылу, җәрәхәтләнү, сибелү тагын да дәһшәтлерәк дәрәҗәгә җитте. Бу гарасат бәхетле булырга туган йөз меңләгән ир-егетләрне сакал-мыек чыкмас борын кара гүргә кертте, йөз меңләгән җиләктәй кызларыбызны мәңгегә тол калдырды. Сугыш җәһәннәменнән күпме солдат һәм офицерларыбыз хурлыклы әсирлеккә эләгеп, крематорийларда көлгә, концлагерьларда туфракка әйләнде, аннан котыла алганнары, ватанга кайткач, сатлык җан исемен күтәреп, тагын да катырак режимлы Сталин лагерьларына озатылды, Идел-Урал легионына тупланган алтмыш меңнән артык әсир дә әнә шунда китерелеп юкка чыгарылды. Алтмыш меңнән артык сау-сәламәт ир харап ителде, димәк, алтмыш меңнән артык хатын-кыз үксез калды, ике йөз меңнән артык бала туа алмады. Алардан үрчергә тиешле тагын ике буынны да истә тотсак, татар халкы шул легионерлар бәхетсезлеге аркасында гына да бер миллион чамасы ишәюдән мәхрүм булды.

Без озак еллар сәламәт әхлакны, шәфкатьне онытып, бер-беребезне сыйныфларга, акларга-кызылларга, ватанчылларга-сатлыкларга бүлеп гаепләдек, эзәрлекләдек, астык-кистек... Гасыр башында Тукай телгә алган ун-унбиш миллионнан тагын да үрчисе урында, без соңгы сиксән ел эчендә җиде миллионга калдык, анысының да әхлакый түбәнәюенә, рухи фәкыйрьләнүенә тәгәрәдек.

Фронтта һәр әсир төшкән сугышчы хаин, сатлыкмыни? Аларның бәхетсезлегенә беренче нәүбәттә сталинчыл җитәкчелек үзе гаепле. Атарга корал кытлыгы (Сталинград окопларына татар полклары агач мылтык белән барып керә!), көрәшне оештырырлык командирлар җитмәү

күпләрне котылгысыз хәлгә төшерә. СССРның кайбер халыкара килешүләргә кул куймавы совет солдатларын әсирлектә җан сакларлык ризыктан мәхрүм итә. Азат ителгән очракта, алар, ватан алдындагы гөнаһларын юар өчен, кырыс җәзага тартыла. Сталин режимы аларны әнә шулай өчләтә үлемгә дучар кыла. Югыйсә, җиңүдә аларның да өлеше бар, чөнки күпчелеге, әсир төшкәнче фронтларда шулай ук ватан өчен кан койган, хәтта әсирлектә дә фашистларга каршы көрәшкән.

Алмания ватанына әйләнеп кайтучы әсирләрен чәчәкләр тотып каршы ала, тормышларын көйләп җибәрү өчен, аларга матди ярдәм күрсәтә. Безнең кешелекле мөнәсәбәтебез исә җәзасын мул алган солдатка да ятсытып, түбәнсетеп караудан узмады. Алар әсир язмышын үзләре теләп алмаган, димәк, ярдәмчел, шәфкатьле мөнәсәбәткә дә лаек иде.

Безнең әдәбият, матбугат чит илләрдә төпләнеп калган әсирләрнең сугыштан соңгы тормышын бөтенләй диярлек яктыртмады. Яктырткан хәлдә, аларның ватанчыллыгы бишектән үк чамалы булуын, соңрак исә капиталга сатылуларын, төрле разведка үзәкләренә ялланып, дошманга хезмәт итүләрен исбатларга тырышты. Шик тә юк, арада андыйлар да булгандыр. Ләкин әсирләрнең бөтенесенә кара тамга салу аек акылга һич тә сыймый.

Болгар бабаларыбызның ислам динен кабул итүләренә 1100 ел тулу бәйрәмендә мин Германия Федератив Республикасыннан килгән Минһаҗ Исмәгыйли белән дә очраштым һәм сөйләшеп утырдым. Чувашстанның Шыгырдан авылында туган, инде кырык алты ел буе гомерен чит илдә уздырган сиксән яшьлек бу карт мөлаем, пөхтә кыяфәте, халкыбызның мәдәни казанышларын киңрәк күрергә-белергә омтылуы белән игътибарымны җәлеп итте. Без танышып һәм гәп корып алгач:

— Казан бик матурланган хәзер. Сез, энем, шушында, татар иленең мәркәзендә яшисез, милли мәдәниятебезне үстерүгә хезмәт итәсез. Эшегез меңнәргә кирәк, сез чыгара торган «Казан утлары» журналын Алманиядә дә зарыгып көтеп алабыз, бик бәхетле кеше сез,— диде һәм үз язмышын сөйли башлады. Әүвәл гаҗәпләндем, аннары кызгандым мин бу картны. Әдәбиятыбызга яшьтән мөкиббән, хәтта, мәкаләләр, шигырьләр дә яза башлаган булган икән ул. 1928 елда Касыйм татар педучилищесын тәмамлаган һәм туган авылында балалар укыткан. 1933 елда Казан университетының география факультетында белемен күтәрә башлаган, сталинчылар үҗәтләнеп «халык дошманнарын» эзли башлаган көннәрдә иминлеген кайгыртып, Шыгырданнан бик еракка китеп югалырга мәҗбүр булган — Үзбәгстанның Маргелан шәһәренә килеп урнашкан. Монда ул мәктәптә укыткан, бер үк вакытта Ташкент университетында үзе дә белем алуын дәвам иткән. Диплом казангач, мәктәп директорлыгына тәгаенләнгән. Монда шулай ук тыныч җир эзләп килгән шагыйребез Зыя Ярмәки белән танышып, дуслашып яшәгән. Соңыннан ул «Зыя Ярмәкигә» дигән шигырендә:

Күз алдыма килә Кукан урамнары,
Ташлык белән Маргеланныңораннары.
Арык буен яңгыратып көлә-көлә
Синең белән сер серләшеп торганнарым.
Вакыт дигән нәрсә бик тиз ага икән,
Ваемсыз чак очып артта кала икән.
Шатлык эзләп күпме генә ашкынсаң да
Язмыш хәсрәт күлләренә сала икән,

— дип әлеге елларны сагынып һәм уфтанып исенә төшерә. Чөнки язмыш аны чыннан да хәсрәт кенә түгел, газап күлләренә дә сала.

М. Исмәгыйли 1941 елның сентябрендә фронтка алынган, күп сугышларда катнашкан, Курск-Орел дугасындагы бәрелешләрдә өлкән политрук дәрәҗәсендә яраланып әсир төшкән. Шуннан соң инде газаплы лагерь еллары башланган. Көрәш фашизмны тар-мар итү белән тәмамланса да, ярты үлеккә әверелгән Минһаҗ Исмәгыйли тагын биш ел үлем

белән яшәү арасында җәфаланган, хастаханәләрдә аунаган. 1951—1978 елларда автозаводта кара эшче булып хезмәт иткән, аннары, сәламәтлеге начараю аркасында, пенсиягә чыккан.

Ул ватанын өзелеп сагынган, туган иленә кайтырга талпынган, әмма утызынчы еллардагы рәхимсез гаепләү һәм җәзалауларны яхшы исендә тотканлыктан, Сталин тарафдарларының һәм куштаннарының әсирләргә ничек каравын белгәнлектән, кайтырга батырчылык итмәгән.

Минһаҗ абзый сугыш алдыннан тиңдәше Фатыймага өйләнеп, нәни улы белән кызын сөю бәхетенә ирешә. Озак еллар узгач кына нарасыйларының сугыш вакытында ачтан үлүен ишетә. Хатыны исә ризык хакына киемнәрен сатып йөргәндә тотылып гаепләнә — ун елга Себергә озатыла. Әлбәттә инде, Минһаҗ абзый үзенең исәнлеген һәм кайда икәнлеген белдерүдән шул йөрәк парәләренең иминлеге хакына да ваз кичеп яши. Күңелендәге давыллар куен дәфтәренә генә теркәлә:

Оныта алмыйм зәңгәр күзләреңне,
Зифа буең, нурлы йөзеңне.
Җил-давыллар купты дөбер-шатыр
Һәм каплады баскан эзеңне.
Без икебез киттек ике юлдан
Таң атканчы торып, иртәдән.
Көчле җилләр чыкты, давыл купты,
Салды алар юлыма киртәләр...

Фатыйма бу елларда Себердә иң авыр эшләрне башкара, ач-ялангач, авыру-сырхау чакларында да ирен һәм балаларын уйлап ачыргалана. Минһаҗының хәбәрсез югалуы хакында «кара кәгазь» алса да, һаман өмет белән яши. Чөнки ул 1944 елның июнендә иренең коралдаш иптәшеннән төрле урау юллар аша бик юанычлы бер хат ала.

«Мин Минһаждан 1943 елның 29 декабрендә Старая Русса шәһәре тирәсендә аерылдым,— ди анда Галимҗан Әхмәтҗанов.— Мин иң якын күргән иптәшем, татарлар өчен, аларның дәрәҗәләрен күтәрер өчен, сугышчанлыгын үстерер өчен җаны-тәне белән бирелеп хезмәт иткән дустымнан аерылып киткәндә, уң канатым сынган шикелле булды. Дәхи дә шуны сорыйм, «кара кәгазь» ни вакытта килде — минем шуны беләсем килә. Минһаҗ, суга чумса да, коры килеп чыга торган кеше. Минем белән хезмәт иткән дәверендә ул дүрт мәртәбә хөкүмәт бүләгенә лаек булды — ике тапкыр «Сугышчан дан өчен», бер «Батырлык өчен» медальләре һәм «Кызыл йолдыз» ордены алды... Шушы көндә дә ул сау булырга тиешлегенә күңелем шиксез ышана. Минһаҗны уйлап бер дә кайгырмагыз, ул исән булырга тиеш».

Себер суыгы, язмышның сөргенгә дучар итүе түгел, вәйран ителгән ояның, кайнар хисләр нигезләгән гаиләнең инде беркайчан да тергезелмәячәген белү сындыра Фатыйманы. Тоткынлыктан азат булгач, ул Шыгырданга юл тота, еллар буе хәерле хәбәр көтеп яши. Иренең исән икәнлеген, әмма иленә генә түгел, үзенә дә тугрылык саклый алмавын, ватанына юлы киселүен ишеткәч, үзенә үзе кул сала...

Минһаҗ абзый исә СССРга беренче мәртәбә 1982 елда гына аяк баса ала.

Сугыш өермәсенә эләккән миллионлаган фаҗигале язмышның берәве генә ул М. Исмәгыйли тормышы. Казан шәһәре уртасындагы «Татарстан» кунакханәсендә сөйләшеп утырганда, без аның гомер юлының күп бормаларына туктала алмадык. Милләттәшләремнең читкә сибелү тарихы, андагы тормышы белән кызыксынуымның тирән икәнлеген күреп, ул мине Алманиягә махсус китерергә вәгъдә бирде. Бу вәгъдәсен тормышка ашыруга ул чын-чыннан һәвәслек күрсәтте — ГФРда инде Минһаҗ абзыйның гомер йомгагын сүтәр өчен мөмкинлек ифрат киң булды. Ул минем барлык сорауларыма да тулы җавап бирергә тырышты.

Сугыштан соң Алманиядә хәрби әсирләр күп була, аларның байтагы моннан кая да булса китәргә дә теләми. АКШ-Англия авиациясе үз-

ләренә хас рәвештә шәп бомбага тотканлыктан, 1945 елда Үлм шәһәре дә хәрабә хәленә килгән була. Әмма хәзер, монда кайчандыр сугыш булган, дип уйларга да мөмкин түгел. Монда АКШ аеруча булышкан — хәтта хәрби әсирләр өчен дә торак йортлар салып биргән. Билгеле, алар әлләни купшы түгел. Шулай да андый йортта яшәргә тәкъдим итсәләр, бездә күпләр риза булыр иде. Минһаҗ абзый да шундый фатирларның берсендә яши. Ике бүлмәле, коридорлы, бәдрәфлс. Ваннасы зал һәм кухня вазифасын бергә үтәгән бүлмәдә. Шунда ук сыек ягулык яга торган камин сыман мич тә бар. Сунын салкыны гына килә. Әмма фатирга түләү хакы чагыштырмача бик арзан — аена нибары 150 марка гына, ягъни Алманиядәге уртача көн ярымлык хезмәт хакы бәрабәрендә. Өч катлы йортның һәр подъездында шундый алтышар фатир. Аскы катта (подвалда) кирәк-ярак саклар өчен алты хуҗага да аерым-аерым келәт көйләнгән.

Минһаҗ абзыйның фатиры яхшы җиһазланган — тормыш итәр өчен мебеле, бүтән кирәк-яраклары бар. Төрле-төрле биш-алты сәгать, әллә ничә магнитофон дисеңме, затлы өстәл-урындык, диваннар, караваткафлар, сервизлар, телевизор һәм башкалар. Кием-салымы санап бетергесез, шкаф тулы китаплар. Бөтен дөнья фәлсәфәчеләре, тарихчылары, нимес матур әдәбияты, шәрекъ шагыйрьләре, урыс һәм татар классиклары... Минһаҗ абзый аларны иркен укып кына калмый, ятлап та өлгергән әсәрләре күп икән, урынын, вакытын туры китереп, сүзләрен әнә шул акыл ияләренең фикерләре белән дә ныгытып куя.

— Минһаҗ абзый, Сез СССРга дүртенче мәртәбә барырга җыенасыз. Туган җирләр шулай бик тә сагындырамы? — дип сорадым мин аңардан.

— «Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил», дип тикмәгә генә җырламыйлар, — диде ул. — Бу җырны, бәлки, нәкъ менә минем кебек кешеләр чыгаргандыр. Язмыш бәндәләргә туган җирләрдән аерылу ачысын бирмәсен икән! Өлкәнәя барган саен җирсү хисе көчәя. Үз ватанында туган телеңдә аралашып, татар җыр-моңын ишетеп гомер итүгә ни җитә?!

— Казанда да эмиграциядә яшәгән кебек хәзер.

— Энем, барның кадерс беленми, — диде ул, минем белән килешмичә. — Дөрес, сталинчылар милли сәясәтне афәтле юлга керткәнлектән, татарга зур зыян ясалган. Әмма илдә күп нәрсәне төзәтеп була. Алманиядә яки бүтән мәмләкәттә инде татар тормышын тиешенчә көйләп булмый. Монда без килмешәк кенә. Татарстанда үзгәрешләр бара хәзер, татар бик сәләтле, тырыш халык бит ул. Ниместән бер дә ким түгел. Үзе тапкан малга хуҗа да була алса...

— Чит илләрдәге милләттәшләребез Казанга еш килә хәзер, — дидем мин. — «Илкәйне сагынам, аһ, шуны бер барып күрергә!» диючеләре тагын да күбрәк икән. Әмма күчеп кайтучылар күренми. Аларны бездәге ярлылык куркытамы, әллә ватанны, милләтне сөюләре чамалымы?

— Рәсәй хәзер Николай патша заманнарындагыча түгел, әлбәттә, шактый алга киткән, — диде Минһаҗ абзый уйланып. — Әмма алдынгы илләрне куып җитәргә бик-бик ерак әле. Адәм баласы матди исәп-хисап белән генә яшәми, тик моны онытып бетереп тә булмый. Менә мин үзем ватаныма тартылам. Илһамнар җыры, Туфаннар, Сибгатлар шигыре кайткан саен колагыма керә дә күңелемнән китми. Ташлыйсы иде дә бөтенләйгә кайтасы иде ватанга. Ләкин мин сиксән бер яшькә чыктым ич инде. Илдә укыдым, шуннан соң биш кенә ел эшләргә өлгердем, шуңа ватанымны яклап сугышкан ике фронт елын да өстәсәң... Юк, илем миңа пенсия түләсен өчен ул гына бик аз шул. Мин моңа өмет тә итмим. Көчле чагым әсирлектә узды, сәламәтлегем ифрат какшаган иде, мең үлемнән могҗиза белән генә исән калдым. Аннары Алманиядә эшләп пенсиягә чыктым. Ләкин, үзара килешү төзелмәгәнлектән, илемә кайтсам, Алма-

ния пенсиямне анда җибәреп мәшәкатьләнмәячәк. Менә ни өчен кендегем ГФРда бәйләнеп тора.

Университет тәмамлаган булса да, Минһаҗ абзый Алманиядә кара эштә генә эшли алган. Аның бер сәбәбе — әсирлектә калуына бәйләнгән, әлбәттә. Әмма монда икенче нәрсәне дә искә алу хаҗәт — немесләр әйбәт эшне чит ил кешеләренә бирергә артык яратмый. Үз илендә ул һәр тармакта үз белгечләренә мөмкинлекләрне киңрәк ача. Башка милләттәшләребез кебек, М. Исмәгыйли дә аптырап калмый, сәләтен бүтән яктан үстерергә, үзенең һич тә төшеп калган кеше түгеллеген немесләргә дә исбатларга әмәл таба: Гете, Шиллер, Һейне, Лютер һәм башка язучыларның әсәрләрен туган телләрендә укып, шуларның байтагын яттан да сөйләп, немес хезмәттәшләрен таң калдыра. Эшендә төгәл, җитез булгач, завод хуҗалары да ярата, шушы көнгә кадәр, инде пенсиягә чыгуына унике ел тулуына карамастан, бәйрәм көннәрендә чакырып алып, сыйлап җибәрәләр.

Татарларның тел өйрәнергә, фикер йөртергә сәләтләрен югары бәяләгән төрки телләр өйрәнүче профессор Һанс Бенсинг Гаяз Исхакый ярдәмендә байтак милләттәшләребез белән таныша, шул исәптән, Минһаҗ абзый белән дә дәвамлы аралаша. Немес галиме Тукай, Исхакый иҗатларын югары бәяли, галимнәребездән Габдулла Батталны, Садрый Максудыйларны хөрмәт итә. «Төркиләр арасында татарлар — иң алга киткән кавем. Мәдәниятләре борынгы, әмма язмышлары фаҗигале»,— дия торган була. Ул Тукайның кайбер әсәрләрен немесчәгә тәрҗемә итә, шуларны Минһаҗ абзыйга да укып күрсәтә.

Без әнә шулай әллә кемнәрне искә алып, гәп корып утырганда, телефон шалтырады. Минһаҗ абзый секунды белән татарчадан немесчәгә күчеп, пулеметтан аттыргандай, тиз-тиз сөйләшә башлады. Башка шәһәрдә яшәүче әлеге немес профессоры шалтырата булып чыкты. Әсирлектә калган татарлар әкренләп картая, юкка чыга бара, Бенсинг әфәнде үзе дә таушалган, күзе дә зәгыйфьләнгән, телефон аша сирәгәя барган дусларын барлап, хәл белешеп, күңелен таба икән.

— Нацист немесләргә бөтенләй охшамаган ул,— ди Исмәгыйли.— Безне үз күрә.

Әмма мин хәзер инде сүзебезне Исхакыйга борып җибәрәм. Күренекле язучыбызны Минһаҗ абзый беренче мәртәбә Ной Үлмдә генә күрә, әсәрләрен дә Алманиядә генә укый ала. Әмма бу танышу аңарда аеруча тирән тәэсир калдыра. Төркиягә баргач, беренчеләрдән аны эзләп таба, кызы Сәгадәт ханым белән соңрак хат алышып яши.

— Искиткеч бай иҗаты өчен яраттым мин Гаяз абыйны,— ди Исмәгыйли.— Татарда йөз елга гына түгел, мең елга бер килә торган талант, кабилият иясе. Чичән, даһи! Сүзләре агымсу кебек агылып тора, шул арада сөйләмен мәкаль, әйтемнәр белән дә җәүһәрләвен күрсәгез икән! Аны җыелган халык таң калып, авызын ачып тыңлый иде. Тиңсез нотыкчы. Мәгънәле сөйли иде. Шуңа күрә Гаяз Исхакыйның үлеме татар өчен генә түгел, барлык төрки кавемнәр, Идел-Урал халыклары өчен дә зур югалту булды. Аны башкорт, чуваш, ар, чирмеш, мукшылар да белә, ул үзе дә алар белән иркенләп сөйләшә иде. Алманиягә килер иде, татар әсирләрен җыяр иде дә милли бурычларыбыз, татарның хәле турында сөйләр, безне тарихыбызны өйрәнергә, туган телебезне сакларга өндәр иде. «Ят кавемнәргә өйләнеп, милләтебезне пычратмагыз!» — дияр иде. Гомере буена кайгырткан нәрсәсе — милләтен яшәтергә, аны үстерергә тырышу булды. Аны үз кубызына биетергә маташып, зур байлык тәкъдим итүчеләр дә очраган. Әйтик, һитлерчылар. Әмма ул: «Мин милләтемне акчага сатмыйм, үз юлымнан барам!»— дигән. Шулкадәр сәләте, эшчәнлеге белән, теләсә, баеган булыр иде, әмма тапкан малын ул милләтебезне хөрриятькә чыгару көрәшенә багышлады. Аның зур язучы, зур җәмәгать эшлеклесе икәнлеген бүтән милләт вәкилләре дә төшенде. Вафаты хакында ГФР, Төркия, АКШ матбугаты игълан итте. Мин дә

Ной Үлмдә чыга торган «Украинские вести» гәзитендә сөекле язучыбыз турында мәкалә бастырдым...

Әлбәттә, Алманиядә яшәгән милләттәшләребез арасында М. Исмәгыйлигә караганда Гаяз Исхакыйга якынрак торган, аралашкан һәм хезмәттәшлек иткән кешеләр дә булган һәм бар. Алар инде хәзер исәннәр арасында санаулы калып бара. Исхакыйны Алманиягә чакырып китерүче, аны ил буйлап йөртүче, хөрмәт күрсәтүче, серләшүчеләр дә, М. Исмәгыйли түгел, нәкъ менә бүтәннәр. Ләкин шулай килеп чыкты ки, хөрмәтле язучыбыз турында миңа алар белән әңгәмә корырга туры килмәде. Минһаҗ абзый исә мәшһүр әдибебез турында сөйләде дә сөйләде.Үзе күреп белгәнне дә, кешедән ишеткәнне дә.Чөнки...

Исхакыйның йогынтысы шактый ук шифалы була Исмәгыйлигә. Эмиграциядәге басмаларда, үзе әйтүе буенча, ул биш йөзләп шигырь һәм мәкалә бастыра. Алманиядә әсирләр өчен туган телебездә «Идел-Урал» гәзите, «Татар әдәбияты» журналы чыгарыла. Сугыштан соң ГФРда «Азат ватан», «Безнең фикер», «Таң йолдызы» журналлары бастырыла. Төркиядә «Казан» журналы нигезләнә. Чит илләрдәге милләттәшләребез менә шулар белән азыклана, шуларны чыгаруда катнаша. Минһаҗ Исмәгыйлинең искәртүенчә, аларда татарга, ватанга каршы зыянлы фикерләр әйтелми. Сталинның казарма социализмына, милли хокуксызлыкка тәнкыйть уклары яудырыла, билгеле. Әмма шунсыз нинди гуман, кешелекле җәмгыять яши алсын соң? Әнвәргали Айдагулов, Әкрам Фәйзуллин, Габделхалик Галимзадә, Мәхмүт Таһир, Әмрулла Агый, Гариф Солтан, Надыйр Дәүләтләр мәкалә, шигырь, хикәяләр бастыра аларда.

Бер заман чикләрдәге тимер пәрдә алына, чит илләрдә дә Казан басмаларын алдыру мөмкинлеге туа. Мөхәммәт Гайнуллин, Ибраһим Нуруллин кебек галимнәрнең, Әмирхан Еники, Нури Арыслан, Гамил Афзал кебек язучыларыбызның әсәрләре дә татар диаспорасына (читтә азчылык булып яшәүчеләргә) барып җитә. Бер яңа китап, журнал килеп ирешә исә, милләттәшләребез аны, күбәйтү машиналары аркылы чыгарып, АКШка, Австралиягә, Япониягә, Финляндиягә — бөтен дөньяга сибелгән танышларына җибәрәләр. Тормыш инде рәтләнә төшкән, чит илдә калган милләттәшләребез иркенрәк сулыш ала башлаган көннәр килә. Зур кыенлык белән сузылган бәйләнешләр яңа өметләр уята. Кайтып күрергә иде ватанны, бәлки, инде безгә дә тимәсләр, без бит — язмыш корбаннары, ихтыярсыздан ят җирдә калдык, дигән уйлар уяна күңелләрдә. Чыннан да, озакламый СССР илчелекләрендә хәрби әсирләргә кырын караш кими төшә, ләкин бу вакытта инде күпчелеге житмешкә аяк баса, илен сагынучыларның күпчелеге якты дөнья белән саубуллашырга да өлгерә. Замана җилләре исән калганнарын төрле кыйтгаларга, мәмләкәтләргә таратуын дәвам итә. Алардан калган үрчем гадәттән тыш аз санлы. Аларның байтагы, аталары күзен йомганчы ук, Курт, Клара, Альфред рәвешендә яши-яши, татарлыгын тәмам югалта, кәрван эзен әнә шулай ком күмә.

Минһаҗ абзый Казанда очрашканда үзенең сугышчан орден һәм медальләр белән бүләкләнгән булуын бөтенләй телгә алмады. Мин моны Ной Үлмгә баргач, әллә нинди әйләнеч юллар белән Алманиягә дә килеп җиткән фронтташ дусты хатыннан гына белдем. Димәк, үзен тәти күрсәтер өчен артык ашкынмый ул. Яшисе гомер яшәлгән, аны бизәүдән хәзер инде мәгънә юк, дип караса кирәк. Бу инде мине, сөйләгәннәрен тикшереп карарга мөмкинлегем булмаса да, Минһаҗ абзыйга ышанырга этәрә. СССРга инде дүрт мәртәбә килеп айлар буе яшәп киткән, чит илләрдәге милләттәшләребез турында мәгълүматлар җыю, аны безгә дә җибәреп тору белән шөгыльләнгән кешенең ихласлыгына, инде сиксәнне узуына карамастан, халкыбызның катлаулы үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланып яшәүче затның намуслы булуына ышанасым килә. Кырык үлемнән котылып калган, хәзер матди мохтаҗлыктан аптырамаган пенсионерның рухи тынычлык эзләве, ата-баба җиренә сәҗдә кылып,

аңа иминлек теләп, сагыну тулы шигъри сәламнәр юллавы табигый. Каргау, сүгү, гаепләү, җәзалау заманы артта калып бара, без хәзер аңлашуга, бер түбә астында җыелуга йөз тотабыз. Европадан шундый җилләр исә!

Ной Үлм вокзалында озатып калганда, Минһаҗ абзый кулымны кысып:

— Берничә айдан кайтам мин, энем. Бу юлы Үзбәгстанга да барырга телим. Фатыйма каберенә таш куясым килә!— диде.

Узасы аралар нинди ерак. Исмәгыйлинең үз сүзләре белән әйткәндә:

Альп тау башлары, ай-һай, биек,
Йөрмәсә дә арыслан-киек.
Кем уйлаган безнең araларны
Альп-таулар аерыр диеп?

Ләкин ерак аралар да сагыну хисен сүндерә, сүрелдерә алмый икән.

## «Азатлык» сөйли

Германиянең Мюнхен шәһәренә дә барачагым билгеле булгач, республикабызның «Ватан» җәмгыяте вице-президенты Дамир Гыйсметдинов:

— Сез анда «Азатлык» радиосына керми калмагыз,— дип киңәш итте.— Казан радиосы Сергач белән Сарманнан ары ишетелми. Безгә исә бөтен милләттәшләребезгә җәмгыятебезнең бурычлары турында сөйләргә кирәк. Моның өчен нигә әле «Азатлык»ны да файдаланмаска? Аның тавышы бөтен дөньяга тарала. «Ватан»ның идарә әгъзасы буларак, сезнең «Азатлык» аша чыгыш ясарга тулы вәкаләтегез бар.

Дөресен әйткәндә, СССРда яманаты сатылган бу радио үзәгенә барырга шушы сөйләшүгә кадәр икеләнеп йөргән идем мин. Татарстаннан читтәге милләттәшләребез тормышын, аларның фән һәм мәдәният өлкәсендәге казанышларын өйрәнүче бер каләм иясе буларак, мине Көнбатыш Европа уртасында озак еллар өзлексез эшләп килүче татар редакциясе, әлбәттә, бик кызыксындыра иде. Телисеңме-юкмы, татар диаспорасы турындагы мәгълүматлар беренче нәүбәттә хәзер шунда туплана, бу үзәкне күрмәскә, танымаска тырышу, алардан мәгълүмат алуны чикләү халкыбызны тулаем танып-белүгә, аның мәдәни эшчәнлеген яктыртуга аяк чалачагын мин яхшы аңлый идем. Әмма А. Ф. Панфиловның «Азатлык радиосы» пәрдәсе артында» («За кулисами «Радио Свобода», Мәскәү, 1974) дигән китабында язганнарга ышансаң, бу үзәкне, әлбәттә, белгән догаларыңны укый-укый, әллә ничә чакрымнан әйләнеп узарга кирәк иде.

Китап салкын сугыш елларында язылган, анда «Азатлык» хезмәткәрләрен гаепләүнең исәбе-хисабы юк. Фашистик СС, гестапо гаскәрләрендә хезмәт итү, җәза отрядлары сафында сугышу, коммунизмны күралмау, әхлакый бозыклык һәм башка, һәм башка «гөнаһлар» фаш ителә анда. Башкалар белән бергә, татар-башкорт редакциясе хезмәткәрләре Шиһаб Нигъмәти белән Гариф Солтанга да каты элгә автордан.

Хәзер казарма социализмы, тоталитар режим тәртипләрен, аның берьяклы идеологик карашларын тәнкыйть белән анализлау, күп кенә дәгъвалардан һәм бәяләрдән баш тарту заманы. Димәк, Панфилов китабының да искерүе, «Азатлык»ның бар тарафыннан фәкать шакшылык, яманлык эзләүнең акланмавы табигый. Шулай да әлеге китапның кайбер дәлилләрен игътибарга алырга кирәк.

Теге яки бу кешене, имеш-мимешләргә нигезләнеп бәяләгәнче, үзен күреп сынау яхшырак. Менә шуңа күрә мин Мюнхенда «Азатлык» радио-

сы хезмәткәрләреннән аулакта калмадым. Кача да алмадым, чөнки бу шәһәрдәге аз санлы татар колониясенең зур гына өлеше теге яки бу дәрәҗәдә әлеге радиога бәйләнгән.

Мюнхен шәһәре үзәгендәге Инглиз бакчасында урнашкан «Азатлык» һәм «Азат Европа» радиолары әллә ничә канатлы зур бинада эшли икән. «Ирекле авазлар» таралуга ачуы кайнаган тоталитар режимнар бу станцияне кат-кат шартлатырга маташканлыктан, хәзер ул уяу саклана — портфельләр тикшерелә, үзең дә, самолетка утыргандагы кебек, магнитлы дуга эченнән үтәсең. Якты коридорлар, унайлы кабинетлар, камил техника. «Азатлык» элекке СССР халыкларының егерме ике телендә тапшырулар алып бара, бу тапшыруларны әзерләүдә биш йөздән артык кеше катнаша. Аларның туксаны урыс редакциясендә эшли икән.

Миңа урыс редакциясе мөдире урынбасары Евгений Кушев белән танышырга туры килде. «Диссидентлыгы», ягъни хөррият даулавы өчен, ул заманында Мәскәүнең Лефортов төрмәсенә ябылган, җитмешенче еллар азагында гына хатыны һәм баласы белән эмиграциягә киткән. Чем-кара чәчле, бераз кысыграк күзле Евгенийны татар редакциясе егетләре:

— Тамыры безнең халыктан аның, үзе Себердән. Фамилиясе дә «кош» сүзеннән,— диделәр.

Әллә әнә шул каны тартты инде, ул мине дә якты йөз белән каршы алды. Тегене-моны ачыклагач, урыс телендә өч интервью бирүемне үтенде. Татарстанда милли мөнәсәбәтләр, Себер татарларының автономиясе, татар язучыларының үзгәртеп кору яклы көрәше һәм урыс, яһүд агымнарына мөнәсәбәте турында сөйләвемне теләде. Мәскәү радиосы мондый рухта саф татар мәсьәләләрен кузгатырга ашыкмый, кузгатса да, ул анда мине чакырмаячак. «Азатлык»ның урысча тапшырулары колачы белән Мәскәүнекеннән бер дә калышмый, дөньяның һәр тарафына барып ирешә. Нигә әле халкымның уянуы, табигый хокукларын кайтару өчен көрәшүе, хезмәттәшлеккә, дуслыкка омтылуы хакында сөйләмәскә? Шулай итеп, урыс телендә өч мәртәбә эфирга чыктым.

Казакъ, үзбәк, төрекмән редакцияләре дә, Урта Азиягә барып йөрүемне, кардәш төрки әдәбиятларны, аерым язучыларны яхшы белүемне ачыклагач, үз телләрендәге тапшыруларда катнашуымны үтенделәр. Канатларны алай ук киң җәяргә кыенсындым, шулай да, Себердә казакъ мәктәбендә укыган көннәрем искә төшкәч, әле берничә ай элек кенә күренекле казакъ язучысы Җосыйфбәк Аймаутовның йөз еллыгын бәйрәм итүдә катнашуыма таянып, казакъ теленең һәм мәдәниятенең бүгенге хәле, үсеш мәсьәләләре хакында фикерләремне уртаклашырга булдым.

Үзләренчә бәйсез яшәсәләр дә, «Азатлык» хезмәткәрләренең ватанга тартылуы аннан килүчеләргә мөнәсәбәттә аерымачык абайлана. Бу бигрәк тә төрки редакцияләргә кагыла. Аларга үз республикаларыннан кунаклар сирәгрәк килгәнлектән, кардәшләрен күрү дә тансык. Үзбәк, төрекмән, кыргыз, уйгыр хезмәткәрләрнең минем белән кызыксынулары да шуңа бәйләп аңлату дөресрәк булыр.

Татар редакциясенә бер тирәдә өч мәдәни эшлекле — шагыйрь Равил Бохараев, мин һәм журналист Римзил Вәлинең килеп төшүе аларда бераз көнләшү дә уятты бугай. Милләттәшләребезнең кунаклары белән исә горурланулары һәм бераз масаюлары да сизелеп калды. Уен эшмени: ватан белән бәйләнешләры ныгый, димәк, аларны нииндидер дәрәҗәдә таныйлар, хезмәттәшлек итүдән дә баш тартмыйлар. Ни заман битенә төкереп килгәннән соң, күнелләрдәге юшкынны таратырлык, бозны эретерлек адым ич бу.

Тәкъдимнәрнең һәммәсен кабул итмәсәм дә, милләттәшләремнең дәрәҗәсен күтәрү максатында, төрки редакцияләр хезмәткәрләре алдында бер озын нотык тотарга туры килде. «Татар халкының үткәне, мәдәни казанышлары, төрки кардәшләре белән бәйләнешләры» хакында сәгатьтән артык сөйләдем һәм сорауларга җаваплар бирдем. Кәгазьдән укыма-

вым ошадымы, казакъ, үзбәк, уйгыр, төрек сүзләрен дә катнаштыргалавым уңай тәэсир иттеме — мине игътибар белән тыңладылар. Башта әңгәмәмне эфирга чыгару хакында килешмәсәк тә, алдыма микрофон куелган иде. Фәрит Иделле үзе өчен яздырадыр, дип уйладым. Соңыннан ул аны махсус тапшыру итеп файдаланырга рөхсәт сорады. Әнә шулай минем «Азатлык» аша сөйләвем тагын да артты. Чөнки мин инде «Казан утлары» журналы», «Ватан җәмгыяте», «Татар матбугаты дөньясы», «Прозабыз турында уйланулар» дигән махсус тапшыруларны элегрәк яздырган идем. Аларны унар минутлы өлешләргә бүлгәнлектән һәм атна саен берсен генә эфирга чыгарганлыктан, мин Казанга кайтканнан соң да, тавышым шактый озак «Азатлык» дулкынында яңгырап торды. Ул чыгышларым турында Пермь, Уфа, Ташкент, Себер, Кырым, Финляндия якларыннан хат-хәбәрләр алдым. Димәк, чыннан да, Казан ишетелмәгән җиргә «Азатлык» дулкыны иркен барып җитә икән!

«Азатлык» радиосының тагын бер кызыклы ягы — рестораны. Аның буфетында дистәләгән төр коньяк һәм шәраб. Әмма хезмәткәрләр арасында эш сәгатендә дә, аннан соң да мин кызмача кешене күрмәдем. Икенче кызык — радио директорының залда буш урын эзләп йөрүе булды. Билгеле, урын бик тиз табылды, әмма аңа бирәү дә куштанланып маташмады. Ул монда тиңнәрнең берсе, нәкъ бүтәннәр кебек кеше иде. Өченчесе — төрки редакцияләр хезмәткәрләренең һәрвакыт, бер гаилә баласы кебек, мәгълүм почмакта туплануы. Һәркем үз телендә сөйли, кемдер аңламаса, төрекчә төшендереп җибәрәләр. Төрки телләрнең дөньяда көн саен шулай берьюлы актив кулланыла торган бүтән җире бар микән? Бик кызык та, күңелле дә тәэсирләр уята ул. Бәлки, Германиядә үзеңнең килмешәк кенә икәнлегеңне онытырга, нииндидер рухи тотрыклылык, әйбәт кәеф сакларга да булышадыр әле ул.

Радионың татар-башкорт редакциясе эше белән мине аның мөдире Фәрит Иделле таныштырды. Елмаюы йөзеннән бер дә китми торган ягымлы кеше ул. Озын буйлы, таза гәүдәле, җирәнрәк чәчле, нәни сакаллы, әз генә алга таба бөкрәебрәк йөри торган зат. Әдәпле, игътибарлы, әмма, кунак килде, дип эшен ташлаучы бәндә түгел. Гомумән, монда коридорга чыгып озын-озак тәмәке тарту, ләчтит сатулар юк. Соңгарып килүне, алдан таюны да күрмисең.

— Фәрит әфәнде,— дип мөрәҗәгать иттем мин аңа,— СССРда демократия һәм хәбәрдарлыкның киңәюе сәбәпле, «Азатлык» авазы да Идел-Урал буйларына бик иркен килеп җитә. Элек тапшыруларыгыз томаланып, бастырылып торганда, татар җәмәгатьчелеге сукыр, саңгырау рәвештә сезне «дошманнар оясы» дип атарга мәҗбүр иде. Ләкин сез, мөгаен, редакциягезне алай бәяләүгә рәнҗегәнсездер?

— «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясендә татар халкына һәм, тулаем алганда, СССР халыкларына яманлык теләүче бер генә кешене дә белмим мин. Без кеше хокуклары, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы гамәлгә ашырылуын яклаганлыктан, «сталинчылык һәм торгынлык еллары» дип билгеләнгән заманда да халыкара җәмәгатьчелек таныган демократик принципларга нигезләнеп эшләдек. Һәр милләтнең теле, мәдәнияте иркен үсәргә тиеш, халык матди яктан житеш яшәр өчен иң нәтиҗәле җитештерү ысулларын, җитештерү бәйләнешләрен, милек формаларын сайлап алырга хокуклы, төрле бәхәс һәм каршылыкларны халыкара кануннарга таянып, сөйләшүләр юлы белән хәл кылырга кирәк, дип сөйләдек. СССРда гына түгел, кайбер бүтән илләрдә дә кеше хокукларының һәм милли тигезлекнең бозылуын фаш итеп тордык. СССРның бүгенге җитәкчеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре хәзер нәкъ менә шундый рухта фикер йөртә, үткәндәге фаҗигаләрне ача, иҗтимагый тормышны халыкара кануннарга туры китереп үзгәртеп кора. Шулай булгач, безнең бөтен гөнаһыбыз — СССРның яңа җитәкчелеге игълан иткән юлга элегрәк басуыбызда гына! Безгә кара ягып карьера ясаган Мидхәт Абдуллин һәм бүтән «каһарманнарга», мөгаен, тәүбә итәргә бик вакыт инде.

«Азатлык» радиосының әхлакый йөзен, эшләү тәртибен, кагыйдәләрен АКШ хөкүмәте каршындагы Халыкара радиотапшыру советы билгели һәм ул кануннарның үтәлешен җентекләп күзәтеп тора икән. Ул кагыйдәләрдә түбәндәге юллар да бар: «АКШ сәясәте теләсә кемнең дәүләт чикләренә бәйсез рәвештә һәм теләсә нинди юл белән хәбәрләр һәм фикерләр эзләүдә, алуда һәм таратуда ирекле булуын — иман ирегән яклауга юнәлдерелә. «Азатлык» кешеләрнең бер дәүләттән икенчесенә күчеп китү, фәнни, мәдәни, экономик алыш-биреш ясау ирегән яклый, диненә, җенесенә, милләтенә, расасына, социаль чыгышына карап, аларның хокукларын чикләүне гаепли.«Азатлык» сепаратистларның мәйдан дәгъваларын якламый, көчләүгә өндәүне, аерым төркемнәрне, катлауларны бер-берсенә каршы котыртуны өнәми, берьяклы карашлар уздырудан, сәяси кинәшләр бирүдән саклана. «Азатлык» төгәл һәм дөрес хәбәрләр генә тапшырырга, әдәпле, ихтирамлы эш итәргә, фикерләрнең күптөрлелегенә юл ачарга, объектив сөйләргә тиеш. Халыкара килешүләрдә беркетелгән кеше хокукларын, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын яклау, хәбәрләрне һәм идеяләрне планета халыклары арасында ачыктан-ачык таратып, «Азатлык» халыкара тынычлыкны, иминлекне ныгытырга хезмәт итәргә тиеш...» Мюнхеннән әнә шундый «тиеш»ләрне күздә тотып тапшырулар алып баралар. Радио-телевидениесе, матбугаты канунсыз җитәкчеләр ихтыярына буйсынган илләрдә хәбәр тарату нәзек иләк аша гына саркып чыга, ул, гадәттә, берьяклы була. Менә шундый илләрнең җитәкчеләре сөйми дә инде «Азатлык»ны. Золымнарын, гаделсезлекләрен фаш итә ич ул!

«Азатлык» радиосы 1953 елның беренче мартында эшли башлый. Аның барлык чыгымнарын АКШ конгрессы каплый. Салкын сугыш башланган елларда СССР матбугаты, радиосы Көнбатыш илләре хакында тискәре хәбәрләр таратуны кинәйтә, дошман образын барлыкка китерергә тырыша. АКШ җәмәгатьчелеге менә шундый шартларда СССР халыклары телләрендә бәйсез хәбәрләр таратучы бер үзәк коруны файдалы саный. «Азатлык» хакыйкатьне белергә булышуны күздә тота. Әнә шул көннәрдә татар-башкорт редакциясенә дә нигез салына.

Туган телебездәге программа эфирга беренче мәртәбә Казан (Мәскәү) вакыты белән көн саен унсигез сәгатьтә чыга һәм бер сәгать дәвам итә. Егерме өч сәгатьтән егерме дүрткәчә аны кабатлап тапшыралар, аннары шушы ук программа иртәгесен җиде сәгатьтән тугызгача тагын яңгыратыла. Себердәге һәм Урта Азиядәге милләттәшләребез өчен Мәскәү вакыты белән дүрт сәгатьтән бишкәчә кабатлана, ул як халкы йокыдан уянган чак була бу. Татар программасы унтугыз, егерме биш, утыз бер һәм кырык бер метрлы дулкыннарда эфирда яңгыратыла. Әйтергә кирәк, «Азатлык»ның татарча тапшырулары Идел-Урал, Себер, Урта Азиядән читтә дә ишетелә, аның татар редакциясенә төрле илләрдәге мөһаҗир милләттәшләребездән байтак хатлар килеп тора.

Казанның татарча тәүлегенә өч сәгать чамасы гына сөйләвен искә алсак, «Азатлык»ның туган телебездә биш сәгать буе тапшырулар алып баруы, милләттәшләребезнең хәбәрдарлыгын тәэмин итүдә гаять әһәмиятле роль уйнавын раслый. Әйтергә кирәк, «Азатлык»тагы татар редакциясе эш күләме ягыннан казакъ, кыргыз, төрекмән, үзбәк редакцияләреннән калышмый. Тапшыруларның сыйфаты җәһәтеннән дә безнекеләр элек-электән бүтән төрки редакцияләргә үрнәк булып килә. Ләкин хәзер хезмәткәрләр саны буенча татарлар казакълардан, үзбәкләрдән калыша башлаган. Өлгерә алмаулары аркасында, дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе көннәрендә ярты сәгатьлек, калган көннәрдә бер сәгатьлек программалар әзерлиләр һәм шуны эфир вакытларында кат-кат тапшырырга мәҗбүр булалар.

Тыңлаучылар шаһит, «Азатлык» бик үк камил татар әдәби телендә сөйләми. Чөнки хәзерге хезмәткәрләрнең барысы да ватаныннан читтә туып үскән, шунлыктан сөйләмнәрендә төрек, уйгыр, казакъ аһәңнәре дә чагылып китә. Хәзерге хезмәткәрләрнең берсе дә радиода, җитмәсә,

татар редакциясендә эшләр өчен махсус әзерләнмәгән. Халкыбызның тарихын, телен һәм әдәбиятын алар әти-әниләре ярдәмендә үзлекләреннән өйрәнергә мәҗбүр булган. «Азатлык» АКШ карамагында эшләгәнлектән, инглизчә, ГФРда яшәгәнлектән, немесчә белергә тиешләр. Фәридә Хәмит Кытайда туган, Төркиядә һәм Финляндиядә яшәгән, Истанбул университетында сәнгать тарихын өйрәнгән. Нури Рәсүл углы Румыниянең Күстәнҗә шәһәрендә туган, Истанбул икътисад институтында белем алган. Фәрит үзе Кытайның Дайрин шәһәрендә дөньяга килгән. Төркиядә үскән, университетта экономика нигезләрен өйрәнгән. Кытайның Голҗа шәһәрендә туып үскән Илчен — Төркиядә университет тәмамлаган физик. Редакциянең иң өлкән хезмәткәре — Фәрит, 1943 елгы. Иң яше — Илчен, 1964 елгы.

Фәритнең әнисе гаҗәп бай күңелле кеше була, ул өч баласын тәрбияләүгә искиткеч күп көч сала, нахак гаеп белән бәлагә тарыган — 1945 елда Кытайга килеп кергән Совет гаскәре тарафыннан СССРга дошманлык эшләүдә гаепләнеп, Себергә алып китеп төрмәгә ябылган, аннары ГУЛАГ тоткынына әйләндерелгән иренең юклыгын да сиздермәскә тырыша. Туган телебезне, җырыбызны сабыйлары күңеленә ул сала, халкыбызга мәхәббәт тәрбияли. Шуңа күрә Фәрит Истанбулда Татар җәмгыяте клубын оештыруда дәртләнеп катнаша. Төрле уңай белән милли кичәләр, бәхәсләр уздыра, ул кичәләргә сиксән-туксан егет һәм кыз җыйнала. Татар яшьләре шунда бер-берсе белән танышып, күпләр шунда кәләшле, кияүле була. Фәритнең әнә шулай татарларны оештырып йөрүе ерактагы милләттәшләргә дә барып ишетелгән, ахры, университетта укып йөргән чагында (1969 ел) аны радиога эшкә чакыралар.

СССРда «Азатлык»ка төксе караш әле дә җуелып бетмәгән. Чит илдә туган, чит илдә үскән татар өчен «Азатлык»ның татарча тапшырулары ком чүлендә юлыккан салкын саф чишмә сыман тансык, ят телләрне, ят җырларны өзлексез ишетеп торудан йончыган колакларга бер шифалы дару, бәлзәм ич ул. Аны Кытай, Корея, Төркия, Япония һәм бүтән мәмләкәтләрдәге милләттәшләребез дә сусап көтеп ала. Шуңа күрә «Азатлык» тәкъдимен Фәрит бик шатланып кабул итә, бөтен дөньяга сибелгән татарларга Кол Гали, Тукай телендә мөрәҗәгать кылуны бик зур бәхет саный...

Фәрит әфәнде миңа өстәлендә яткан бер өем конвертны алып күрсәтте — илебезнең төрле почмакларыннан җибәрелгән иде алар.

— Советлар Берлегендәге үзгәртеп кору хәрәкәте курку, икеләнү хисләрен шактый киметте,— диде әңгәмәдәшем.— Ватандагы радио тыңлаучыларыбыз хәзер безгә язудан тартынмый башлады. Атна саен дистәләгән хат килә. Теләк-тәкъдимнәрен язалар, рәхмәтләрен әйтәләр, тәэсирләрен уртаклашалар. Хатларга без бик җаваплы карыйбыз, Татарстан радиосы бирә алмый торган мәгълүматларны эфирга чыгарабыз, дөнья хәлләре белән тәфсилләбрәк таныштырабыз, чит илләрдәге милләттәшләребез тормышын киңрәк яктыртабыз. Хатларда белдерелгән теләкләрне искә алып, тапшыруларыбызда татар музыкасы язмаларын ешрак яңгыратабыз.

— Чит илләрдәге милләттәшләребезгә тарихи ватанның һәр казанышы кадерле,— ди Фәрит. Анда яңа җырлар туа, әдәби җәүһәрләребез барлыкка килә, сурәт, бию сәнгатебез үсә, яшь буынга мәдәни мирасыбыз тапшырыла, тарихи хәтеребез яңартыла. Әкренләп булса да, шулар безгә дә килеп җитә. Шулар белән ризыкланабыз, горурланабыз, талантлы иҗатчыларыбызга рәхмәт укыйбыз. Читтә, башка халыклар арасында азчылык рәвешендә яшәү милли гореф-гадәтләребезне, туган телебезне, мәдәниятебезне сакларга һәм үстерергә мөмкинлек бирми. Алар бары тик Татарстанда гына сакланырга һәм үсәргә мөмкин. Моны исә туган телебезгә дәүләт теле статусы, Татарстанга суверенлык статусы бирмичә гарантияләү мөмкин түгел. Татарстанда җәмагатьчелекнең менә шушы мәсьәләләрне күтәрүе куандыра. Белем алуны яследән институтка кадәр

туган телдә жайга салу, бу уку йортларында, урысчадан тыш, янә берничә чит тел өйрәтүне дә көн тәртибенә ныклап куясы иде. Хәзер инде инглиз, нимес, испан, гарәп, француз телләрен белмәгән бәндә укымышлы санала алмый. Безнең жиде кеше эшләгән редакциябездә татар, төрек, инглиз, нимес телләрен белү мәжбүри саналса, кайберләребез шулардан тыш, кытай, уйгыр, казакъ, румыйн, урыс, фин телләрендә дә иркен сөйләшә, тагын берничә телне аңлый. Шунсыз Көнбатыш дөньясына, халыкара мәйданга чыгу кыен. Татарстанның исә дөнья халыклары белән хезмәттәшлек итәргә матди байлыклары да, рухи хәзинәләре дә житәрлек.

Алманиягә үзбәк, казакъ артистлары, сәнгать коллективлары гел килеп тора. Җыр-бию ансамбльләре концерт куя, сурәтчеләре күргәзмәләр оештыра. Дөрес, татар артистлары да Африкага, Япониягә, Финляндиягә, Италиягә барды. Әмма Көнбатыш дөньяның үзәге Алмания, Англия, Франция һәм АКШ, шушы илләрдә танылган очракта гына татар дигән мәдәни милләт барлыгын күпләр беләчәк. Әлегә безне тарихи татар-монголлар белән бутау дәвам итә, чи ит ашаучы кыргый бер кавем саныйлар.

Фәрит Иделлене менә шушы нәрсәләр бик борчый.

* * *

Мюнхендәге очрашуларыбыздан соң күп тә үтмәде, «Азатлык» радиосы хезмәткәрләреннән әүвәл Фәридә Хәмит, аннары Фәрит Иделле, «Ватан» җәмгыяте чакыруы буенча, Татарстанга килделәр. Хәтта исеме гел сүгелеп кенә телгә алына торган Гали Акыш та Казан туфрагына аяк баса алды. Әле кайчан гына «диверсант» саналган затлар башкалабызның театрларында, музейларында булдылар, шәһри Болгарга сәяхәт ясадылар. Сабантуй бәйрәмебездә катнаштылар, мәчеткә барып гыйбадәт кылдылар, «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре белән очраштылар, халыкара «Идел» лагеренда татар яшьләре белән аралаштылар. Шунысы гажәп: беркайда берни шартламады, алар йогынтысында безнең карашларыбыз тамырдан үзгәрмәде, без ватаныбызның дошманнарына әйләнмәдек. Бары үзебезне һәм дөньяны яхшырак танып белә башладык та, язмыш жилләре ерак-еракларга илтеп ташлаган милләттәшләребезнең әлеге өчесе Шиһаб Мәржани, Габдулла Тукай, Салих Сәйдәш жирләнгән изге туфракка тезләнеп, кайнар күз яшьләрен тамызды һәм, тарихи ватанына мәхәббәтен арттырып, шуның белән үзен бинитһая бәхетле тоеп, кендекләре ирексез береккән алман жиренә — Германиягә кайтып китте. Татарстанда барган үзгәрешләргә шатлануларын,үзләренә кунакчыллык күрсәткән кешеләргә рәхмәтләрен, шушы сәяхәт уяткан тәэсоратларын Фәрит Иделле белән Фәридә Хәмит «Азатлык» радиосыннан сөйләделәр, Гали Акыш исә Төркия гәзит-журналларында язып чыкты, әнә шулай йөз меңләгән тыңлаучылар, укучылар жөмһүриятебез турында яңа мәгълүмат алды, дөньяга яхшы даныбыз — «дошман» дип саналган кешеләр белән дә татулык урнаштыра, хезмәттәшлек итә белү сәләтебез барлыгы таралды.

Тагын бераздан исә Мәскәүдә «Азатлык» радиосының хәбәрчелек бюросы ачылды.

Хәзер инде радиоалгычыгызны кабызыгыз да «Азатлык» сөйли!» дигән дулкынны эзләп табыгыз!..

### Милли каһарман

Гали әфәндене болай атау илдә кемнәр өчендер сәер тоелыр. Берәүләр мыскыллы көлемсерәп куяр, икенчеләре өнәмичә кашын жыерыр. Татарстан халкының күпчелеге аны гомумән белмәгәнлектән, моңа гажәпләнәсе дә юк. Республикабызда гына түгел, хәтта, бер үк шәһәрдә,

янәшәсендә генә яши торган милләттәшләребез дә Гали әфәнденең бу дәрәҗәсен танып бетерми кебек.

Мин Алманиягә барырга җыенганда Мидхәт Абдуллин белән Салих Батыевның «Татарстан АССР: чынбарлык һәм буржуаз мифләр» (Казан, 1977) китабын кабат актарып чыктым. Анда авторлар татар тарихын бозып күрсәтүче «буржуаз милләтче, советка каршы «Идел-Урал» оешмасын төзүче һәм рухландыручы Гаяз Исхакый гонаһларын фаш итеп киләләр дә, «Исхакыйның яла яга торган концепцияләрен Т. Дәүләтшин, Г. Акыш, Б. Мусабай һ. б. коралланута алды»,— диләр (6 бит). «Т. Дәүләтшин, Г. Акыш... бөтен совет җәмһүриятләре, шул исәптән, Татарстан да, янәсе, «икътисадый яктан үзәк хакимият тарафыннан эксплуатацияләнә», дигән фикер тараталар», имеш (166 бит).

Китапны укыган саен эченә шом йөгерә. Мөһаҗир Гали Акыш: «Үзәк партия һәм совет органнары милли әдәбиятка басым ясый»,— дип раслый икән. Ярый әле М. Абдуллин белән С. Батыев дигән уяу каһарманнарыбыз табылган, алар «мөртәтнең яла ягу рухындагы уйдырмалары»н вакытында фаш итә алганнар.

Ной Үлмдә, Алманиянең тотрыклы тук тормышка ия аулак бер шәһәрендә, пенсиядәге кара эшченең кунагы рәвешендә тыныч һәм рәхәт кенә сыйланып ятканда, хуҗам Минһаҗ абзый:

— Бүген безне алып китәргә Мюнхеннән Хәйретдин белән Гали киләчәк,— дип хафага салды.— Алар инде, энем, кунакны минем шикелле генә сыйламас, хатыннары — яннарында, байлыклары — җитеш. Икесе дә — журналист. Гали Акыш — милли лидерыбыз!

Дөрес, мөһаҗирлектәге бүтән милләттәшләр белән дә танышасы килә. Ләкин Абдуллин белән Батыев әлеге китапларында «Ватанның җирәнгеч сатлыгы Г. Акыш» дип шапылдатып мөһер суккан кеше белән бәйләү ахырда яхшыга илтер микән? Гали Акыш — хәтәр киек, бары күләгәсе төшсә дә, үзеңне пакьләп бетерә алмассың. Дөрес, Минһаҗ абзый аның хатынын мактый: «Зарифа — Финляндия кызы, бик эшчән, кайгыртучан, кешелекле, Ной Үлмгә берничә сәгатькә килгән арада да табын янында кунак булып кына утырмый, өемне җыештырырга, керләремне юарга тотына»,— ди. Димәк, анысы эшче канынннан?!— дип уйлыйм эчемнән.— Шундый әйбәт кыз ничек итеп «адәм актыгы» Галигә кияүгә чыкты икән?

Минһаҗ абзый фатирына килешенгән вакытта өч кеше килеп кергәч, мин аларның олпат гәүдәле, карчыга борынлысын — гайрәтлерәк күренгәнен Гали Акыштыр дип фараз иттем, әмма ул — юка гәүдәле, терекәмештәй елтыр күзле, ягымлы елмаюы, гаять тә кечелекле мөгамәләсе, илтифаты, тыйнаклыгы белән игътибарымны казанганы булып чыкты. Тора-бара бу «мөртәт» миңа үзен тәмам яраттырды — ул кешене тыңлый белә, аңа ихтирам белән каравын бөтен кыяфәте, фигыле белән раслый иде. Бик затлы, тансык сыйфат бу! Икенчедән, үз иманын, карашларын көчләп такмый, ни өчен шундый фикергә килүен аңлата гына. Өченчедән, аның милләтпәрвәрлеге, татар халкы хокукларын яклап көрәшкә кушылуы һич тә малкуарлыкка, төшемле вазифа биләүгә яки шөһрәт казануга бәйләнмәгән — халкын яклау, аны күтәрергә тырышу Гали Акышның ихлас иманы, әхлаклы яшәү рәвеше икәнен күреп, мин чын-чыннан сокландым. Чөнки соңгы елларда татар милли хәрәкәтенә кушылган кешеләрнең юлбашчылыкка омтылган байтагы шушы көрәш дулкыны сыртында шәхси уңышка ирешүне — тоталитар система шартларында бикләнгән юлларны ачып, депутат, түрә булуны, бүтәннәр хисабына баюны максат итте. Арты тәһарәт, алды әдәп күрмәгән кайберәүләр, хәтта, хаҗга да китеп барды — тәүбә итәр, рухи пакьланыр өчен түгел, хаҗи исеме белән гонаһларын капларга, аннан да бигрәк, бай Согуд Гарәбстанының доллар хәеренә бераз мал җыеп, кызык-тамаша күреп кайтырга өметләнеп! Ә Гали абзый хәләл хезмәте белән казганган пенсия акчасына компьютер алып Татар иҗтимагый үзәгенә бүләк итә. АКШ-

ның бер яшь галименә — Ловелл Бизанеска егерме алты сәгать буе халкыбызның тарихы, мәдәнияте, милли-азатлык көрәше хакында сөйли — гомер буе казганып туплаган белемен уртаклаша. Мин таң калып:

— Гали әфәнде, дөньяда сездән баерак татарлар да бар, әмма алар милли яңарыш хәрәкәтебезгә ярдәмгә сезнекедәй кыйммәтле бүләкне җибәрмәде. Акчагыз кызганыч түгелме?— дидем.

— Шулай булыша алуыма шатланам гына,— диде ул.

— АКШ егете сез сөйләгәннәрне диктофоннан кәгазьгә күчерер, аны фәнни аппарат белән тәэмин итеп, тиз арада китап чыгарыр. Үз исеменнән. Каләм хакына баер, шөһрәт тә казаныр. Моннан сезгә бер файда да килмәячәк ләбаса.

— Ловелл әфәнде халкыбыз турында дөресен язачак, милләтебез хакында Көнбатыш дөньясына киң мәгълүмат бирәчәк. Инглиз телендә, АКШ галиме буларак. Үзебезне дөньяга таныту мохтаҗлыгы зур. Шуны киметсәк, файдасын да күрербез. Мин, гомумән, гомерем буе халыкара конгресс, симпозиумнарга үз хисабыма барып, әсирлектәге халкым турында чыгышлар ясадым, докладлар сөйләдем. Һәрвакыт бушлай!

Кайдан килеп чыккан, нинди тормыш юлы узган соң бу татар Дон-Кихоты?

Гали Акыш Кытайның Хайлар шәһәрендә 1918 елда туган. Көнчыгыш Кытай тимер юлы салынган дәвердә бу якларга байтак кара эшче, кечәге игенчеләр күчеп килгән, арада күпмедер чын һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һәм аларның приказчиклары да булган. Җәмәгатьчелеккә аларның мәгълүмрәге, мөгаен, соңрак язучылыгы белән танылган Шакир Мөхәммәдевтер. Гражданнар сугышы еллары мөһаҗирләр санын тагын да күбәйткән. Шунлыктан, бу дәвердә кытайлар Хайлар халкының бары яртысын — ун меңен генә тәшкил иткән. Алты-җиде мең урыс, 1100 татар, байтак украин, әрмән, грузин, яһүд, корей, монгол, япон да яшәгәнлектән, шәһәрдә төрле тел яңгырап торган. Әмма урамда аларның, нигездә, өчесе өстенлек иткән — кытай, урыс, татар телләре.

Тимер юл салынуга бәйле рәвештә укымышлылары да шактый тупланганлыктан, Хайларда урыслар мәдәни яктан югарырак торган. Идел-Уралда нәкъ менә шулар белән тиңләшергә омтылган милләттәшләребез Хайларда да бирешмәскә тырышкан — 1920 елда ук биш сыйныфлы милли мәктәп ачканнар. 1921 елда мәчет тә салганнар. Мәктәптә укытыр өчен исә Идел буеннан Хатыйп Халиди, Рабига Бәкер кебек укымышлы мөгаллимнәрне чакырып китергәннәр. Алар шәкертләренә ислам дине нигезләре, Коръән, ана теле, төрек-татар тарихы, география, табигать белеме, арифметика, өченче сыйныфтан башлап урыс теле сабакларын өйрәткән. Гали, шушы мәктәпне тәмамлаганнан соң, урыс гимназиясендә белем алган.

Хайлар — Ерак Шәрекътә милләттәшләребезнең иң күп тупланган шәһәре була. Мондагы татар җәмгыяте хатын-кыз һәм яшьләр түгәрәкләрен да барлыкка китерә. Дини бәйрәмнәрне милләттәшләребез бергәләп уздыра, әдәби кичәләр дә үткәрәләр. Мәктәпнең зур залына йөзләгән тамашачы сыя, аның бер башына сәхнә дә ясап куела. Һәвәскәрләрне җыр-биюгә, спектакльләр куюга мөгаллимә Рабига Бәкер җәлеп итә. Г. Камалның «Беренче театр»ы, Г. Исхакыйның «Җанбаевич»ы, М. Фәйзинең «Галиябану»ы, Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә»се һәм бүтән пьесалар уйнала — елына ким дигәндә ике әдәби-музыкаль кичә уздырыла. Аларны мондагы бүтән кардәш милләт вәкилләре дә яратып тамаша итә.

Атаклы язучы, журналист һәм сәясәтче Гаяз Исхакыйның 1934 елда Ерак Шәрекъкә килүе мөһаҗир милләттәшләребезнең үзара тыгызрак туплануына, мәдәни тормышлары җанлануына сәбәп була. Кытайда гына түгел, Кореядә һәм Япониядә дә татарлар күпләп яшәгән шәһәрләрдә милли җәмгыятьләр корыла, аннары шул җәмгыятьләр, вәкилләр сайлап, Ерак Шәрекътәге милләттәшләребезнең уртак корылтаен җыя,

Мәркәзи Идарә сайлый, соңра шуның җитәкчелегендә яшьләрдә милли хис уяту, туган телне, мәдәниятне саклау эшен юлга сала, атналык «Милли байрак» гәзитен, татарча китаплар, бигрәк тә, мәктәп дәреслекләрен басарга керешә. Шушы эшләргә рух өргән Гаяз Исхакый татар яшьләре белән очрашуга, аларда милли горурлык тойгысы тәрбияләүгә аерым бер игътибар бирә, аларны милләтебезнең терәге, алтын баганасы булырга өнди.

Урыс гимназиясендә укып йөргән уналты яшендәге Галигә бөек язучының кайнар нотыклары шулкадәр тирән тәэсир итә ки, ул, инде дистәләрчә еллар узгач та, ихлас рәхмәт хисләре белән:

— Минем аңлы, милли рухлы кеше булып җитлегүемдә дүрт илаһи зат — әнием Латыйфә, әтием Хисаметдин, укытучым Хатыйп Халиди һәм гомерлек остазым Гаяз Исхакый биниһая зур роль уйнады, — ди.

Шуңа күрә, гимназияне тәмамлагач, ул, һич тә икеләнмичә, үзен Ерак Шәрекътәге алты меңләп милләттәшенә хезмәткә әзерләргә карар бирә — тугыз иптәше белән Мисырга, Каһирә шәһәрендәге мәшһүр әл-Әзһәр университетына китеп бара.

Әмма нәзберек егеткә пирамидалар иленең коры һавасы килешми — аңа укуын өзәргә туры килә. Моннан инде Гали яшь йөрәгенә туган халкы хокуклары өчен мәңге сүнмәс көрәш очкынын салган рухи атасы Исхакый янына — Варшавага юл тота. Ләкин, кызганыч ки, ул монда да уңмый. Чөнки 1939 елгы мәкерле Һитлер-Сталин килешүе бәйсез Польшаны дөнья картасыннан юкка чыгара. Баш өсләрендә кара болытлар куера башлаган остаз белән шәкерт, «Милли юл» журналы архивларын, язучының шәхси китапханәсен һәм кульязмаларын җыештырып алырга да өлгермәстән, авыр елларда ярдәм кулын сузган, Рәсәйнең азчылык халыклары бәйсезлеге өчен көрәшүчеләрне үз канаты астына алган, хәзер исә ике ерткычның аяусыз һөҗүменә җан ачуы белән каршылык күрсәткән, канга баткан дуслар иленнән ашыгыч рәвештә чыгып качарга мәҗбүр булалар.

Ватансыз калган мөһаҗир язмышы. Ярый әле, кайчандыр бәйсезлегебезне якламаган өчен дә, соңрак безне кайгыртыр дәрәҗәдә куәтле булмаганы өчен дә үпкә һәм дәгъвә белдерә торган Төркиябез бар — шәрекътә дә, гарептә дә афәткә очраган кан кардәшләрен ахыр чиктә һәрвакыт ул сыендыра. Монда Гали (улла) Акыш Истанбул университетының икътисад факультетында белем алырга керешә. Аннары ике ел солдатта була — Төркия гаскәрләрендә хезмәт итә.

Икенче Бөтендөнья сугышын җиңүче төсендә тәмамлаган, Рәсәй патшаларының җылы диңгез буйларын кулга төшерү хыялын күңеленә һич тә ят итмәгән Сталин һәм аның яраннары «пантөркист», «панисламист»ларны сыендырган Төркиягә кырыгынчы-илленче елларда дипломатик басымны ясап кына тора: тегеләй итмәгез, болай итмәгез — күршеләргә дошманлык күрсәтү, дип санаячакбыз югыйсә! Икътисадый һәм хәрби яктан Совет империясеннән шактый калышкан, аның басып керүеннән җитди хәвефләнгән төрекләр үтә сак сәясәт тотарга мәҗбүр була. Алар, бер яктан, куәтле Көнбатыш белән якынаю юлларын эзли, икенче яктан, Сталинның ачуын кабартмаска тырыша — илдәге мөһаҗирләрнең мәдәни җәмгыятьләренә чаклы яба. Бары 1952 елда НАТОга кереп, Совет янавына каршы ышанычлы киртә куйгач кына, хәлләр үзгәрә башлый. Польша, Алмания, Кытай, Корея, Япониядәге татар колонияләре зир-зәбәр китерелгәч, мөһаҗирләребезнең яңа дулкыны шушында килеп урнашуы һәм милли-мәдәни мөхитләрен сакларга омтылуы Төркиядә Г. Исхакый эшен дәвам итәргә шартлар тудыра. Гали Акыш өлкән буын милләттәшләре Мәҗит Сакмар, Камал Локман, Хәйрулла Бату, Кәбир Канбир, Равил Агыш, Әмрулла Агый, Хәмит Рәшит һәм бүтәннәр белән бергә татар халкының милли бәйсезлеген дәгъваларга керешә — 1960 елда тергезелгән Милли Мәркәздә ул секретарь вазифасын үти башлый. 1963 елда «Идел-Урал дәгъвасы һәм Совет империализ-

мы» дигән конференциядә төп докладны ясый, аннары шушы докладын һәм конференциянең бүтән материалларын аерым китап итеп бастырып чыгара. Вакытлы матбугатка мәкаләләр яза, 1985 елда Истанбулда «Идел-Уралда хөррият көрәше» хезмәтен бастырып чыгара.

Кайдан калыкты соң бу Советлар берлегендә үзгәртеп кору, демократия һәм хәбәрдарлык дигән иҗтимагый хәрәкәт? Элек мөһаҗирләрне ничек теләдең, шулай гаепләргә, туйганчы сүгәргә, шул чара белән сәяси капитал тупларга, карьера ясарга, ягъни уяулыгың өчен мактадырга, бүләкләнергә, түшемле, дәрәҗәле урынга менеп кунакларга, матурны киеп, тәмлене ашап, киң вә уңайлы виллаларга оялап, «базарга да левковуйда, абзарга да левковуйда» гына җилдереп, күпчелек халык социализм төзү михнәтләреннән баш та күтәрә алмаганда, аларга уңлысуллы акыл сатып, инде түрәләр өчен корып өлгертелгән коммунизм оҗмахында рәхәтләнеп яшәргә мөмкин иде. Нәкъ менә шушы юлга басып, Мидхәт Абдуллин белән Салих Батыев — тарих фәннәре кандидаты, Камил Фасеев белән Яхъя Абдуллин фәлсәфә фәннәре докторы, Фасеев белән Батыев, хәтта, Татарстан Югары Советы президиумы рәисе дәрәҗәләренә дә ирештеләр. Мөһаҗирләрне сүгү, билләһи, оттырышсыз, файдасы мотлык гарантияләнгән шәп шөгыль, чөнки фашлаучыларның үзләрен түгел, язган мәкаләләрен, китапларын да гади совет кешесе күрә алмаячак — эмигрантлар иҗаты Дәүләт иминлек комитеты /ДИК/ архивыннан бары шушындый уяу һәм ышанычлы «галимнәргә» генә биреп торыла иде.

Ә бүген мин, гадиләрнең берсе, Мюнхендә, Г. Акышның «Идел-Уралда хөррият көрәше» китабын, бүтән хезмәтләрен укып, авторы белән сөйләшеп утырам. Ул иҗат җимешләренә фикеремне белдергәнче, әле кичә генә рухи дөньябызның пәйгамбәре һәм казые ролен берьюлы өстенә алган М. Абдуллин һәм С. Батыевның алда аталган китабының 161 битенә күз салыйк.

«Г. Акыш, оятсызлыкның гаҗәп дәрәҗәсенә житеп, Совет хөкүмәте сугыш елларында татар халкы рухын күтәрү өчен динне файдаланды, дип раслый. «Фронтка китүче солдатларга вәгазьләр сөйли иде», ди ул.

Бөек Ватан сугышы дәверендә дингә каршы көрәшнең «йомшавы» мәгълүм хакыйкать ләбаса. Христиан руханыйлары кебек, мөселман муллалары да һәм догасын, һәм сәдака акчаларының хәтсез өлешен Совет Гаскәренә багышлады. Хөрмәтле авторлар моны архивта ачыклый алмаса, Диния нәзарәтендә белешергә мөмкин иде. Әмма алар болай мәшәкатьләнми, «дошманны» сытуларын бик кыю дәвам итә: «Әрсез ялганның сәбәпләре, Г. Акышның Бөек Ватан сугышы елларында ватанына хыянәт итүен искә алсак, бик әйбәт аңлашыла».

Фән докторы Яхъя Абдуллин да чая каләмдәшләреннән калышырга теләми, «Татар мәгърифәтчелек фикере» (Казан, 1976) китабында: «Ватанын сатучы Г. Акыш... һәм башкалар татар халкы тарихи үткәнен бозып аңлатуны, Совет чынбарлыгыбызга пычрак ягуны дәвам итәләр» (6 бит.),— ди.

Ә мин хәзер аптырап утырам: Гали Акыш Кытайда туган, күпмедер гомерен Мисырда, Польшада, Финляндиядә һәм Төркиядә уздырган, инде байтактан бирле Алманиядә яши. Аның ватаны шушы илләрнең берсе булырга тиештер ләбаса? Әйтик, тумышы буенча — Кытай, гражданлыгы буенча — Төркия, яшәгән җире буенча — Алмания. Ә бит аны бу илләрнең берсендә дә сатлык исәпләмиләр. Ә син аны тот та «ватанын сатучы», «ватанына хыянәт итүче» дип игълан ит! Фән докторы дигәч тә... болай ярыймыни? Халыкара хокук буенча яла яккан өчен саллы гына җәза бирү каралган!

Әгәр инде Г. Акышның ата-бабасы Рәсәйдән, хәзерге Мордва республикасының Юнә авылыннан чыккан кешеләр, дисәк, бусы — хак. Әмма Хисаметдин абзый да, Латыйфа ханым да илне сатып киткән затлар түгел. Хисаметдин 1901 елда ук дүрт абыйсы белән бергә Маньчжуриядә

сәүдә итә башлый, революциягә кадәр үк гаиләсе белән Хайларда тамыр җибәрә. Аннары... ватандарлык ата-баба буенча билгеләнми, юкса нәсел башы Алмания, Мажарстан, Польша, Румыйния һәм бүтән дәүләтләргә тоташкан миллионнарча белорус, мажар (венгр), немес, поляк, румыйн, украиннарны — әлеге илләргә каршы сугыштан кан койган совет граждannarын да ватаннарына хыянәт итүдә гаепләргә кирәк булыр иде.

Г. Акышның «Идел-Уралда хөррият көрәше» китабын мин игътибар белән укып чыктым, ләкин анда «татар халкы тарихи үткәнен бозып аңлатуны да, совет чынбарлыгына пычрак ягуны» да очратмадым. Дөрес, бу китап безгә колонизаторлар яки аларның куштаннары язып биргән «тарих»ка охшамаган — авторның үткәндәге вакыйгаларга һәм шәхесләргә үз карашы бар, катлаулы тормыш кичергән ата-бабаларына тугрылыклы, намуслы кеше фикеренә ия ул. Шуның белән бергә, гыйльми яктан дәлилле һәм объектив булуы, күләме кечкенәлегенә карамастан, мәгълүматка байлыгы, совет галимнәре файдаланмый торган чыганакларга да таянуы белән игътибарга лаек. Мисалга, автор, Татарстан белән Башкортстан республикалары үзләре җитештергән байлыкның уннан бер өлешен генә файдалана, дип совет матбугатында чыккан төгәл саннарны китерә. Хәзер безнең гәзит-журналлар, радио-телевидение ике республиканың савым сыеры кебек савылуын көн саен яңадан-яңа дәлилләр белән раслый, депутатларыбыз парламентларда моңа чик куярга чакыра. Ләкин М. Абдуллин бүген нигәдер аларга «совет чынбарлыгына пычрак ягалар», дип бәйләнми. Чөнки хәзер инде һәркемгә ачык: Көнбатыш советологлары, шул исәптән, Г. Акышлар да СССР чынбарлыгы турында һәрвакыт дөресен язганнар. Аларның бөтен «гөнаһысы» — хакыйкатьне СССРда рөхсәт ителгән заманнан күпкә элегрәк фаш итүдә генә булган!

Ә инде «үзәк партия һәм совет органнары милли әдәбиятка басым ясый» дигән фикергә килсәк, Г. Акыш бик йомшак әйткән әле. «Тимер пәрдә» калын һәм нык киртә булганлыктан, СССРдан җитәрлек хәбәр ала алмавы комачаулагандыр, бәлки. Әмма без бик яхшы беләбез: «Үзәк» күрсәтмәләрне яудырып кына торды, аларның Татарстандагы Ф. Табиев, М. Вәлиев, С. Батыев, М. Мусин кебек югары дәрәҗәле капраллары татар язучыларына, йә кабинетларына чакырып алып, йә иҗат берлекләре җыелышларына килеп, йә матбугат аша әледән-әле акыл өйрәтеп тордылар, үзләрен тыңламаган «киребеткәннәрне» сүгәргә яки алар иҗатына халыкка бару юлын бикләргә дә күп сорамадылар. Бу хакта Салих Баттал, Нурихан Фәттах, Әбрар Кәримуллин, Рабит Батулла һәм бүтән язучыларыбыз бик күп дәлил китерә ала.

Г. Акышны милләтчелектә гаепләргә дә җирлек юк — безне урыслар һәм Рәсәй белән тату яшәргә өнди ул. Әгәр хәзер аның бу хезмәтен Казанда бастырып чыгарсак, кемнең кемгә пычрак атуын тавыклар да аңлар, дип уйлыйм. Ә бу хезмәт кирәк, бик кирәк. Чит ил авторларын «фаш итүчеләрне» акылга утыртыр өчен генә түгел, тарих фәнебезгә шифалы саф җилләр исеп керсен, зиһенебез яңа мәгълүматлар белән баесын өчен файдалы булыр иде бу басма.

Ләкин югарыда язылганнардан Гали Акыш безнең барлык галимнәребездән дә галимрәк икән, дигән ялгыш фикер тумасын. Ул соңгы дәвердә уналты ел буе «Азатлык» радиосының татар редакциясендә эшләгән журналист. Идеология прокурорларыбыз еллар буе аның исемен юкка гына «буржуаз милләтче» Гаяз Исхакыйга теркәп чәйнәмәде — Гали әфәнде, чыннан да, остазы исән чакта ук ул башлаган эшкә җигелә һәм шуны бүген дә хәленнән килгәнчә дәвам итә. Гыйлемгә генә кереп баткан тикшеренүчедән әүвәл, ул — гамәли сәясәтче, оештыручы.

Мәгълүм ки, Г. Исхакый, Идел-Урал штатлары Милли Мәҗлесе эшлекләләре Садрый Максудый, Фуат Туктар белән бергә бәйсез Татар дәүләте коруны дәгъвалар өчен, урау юллар узып, 1920 елда Халыкара Париж конгрессына килә. Дөнья язмышын хәл итәргә алынган Көн-

батыш мәмләкәтләре, әлбәттә инде, Рәсәй хәрабәләре өстендә нинди дә мөстәкыйль «бусурман» дәүләтен калкытуга ашкынып тормый, теләсәләр дә, моны гамәлгә ашыруга кодрәтләре җитми. Парижда максатларына һич тә якынаймаган милләттәшләребез шуннан соң, яклау өмет итеп, Төркиягә килеп егыла. Әмма бу заманда кайчандыр бөтен Европаны өркетеп торган хәлифәлек үзе дә мөшкел хәлгә төшкән була — төрек халкының бәйсезлеге кыл өстендә кала. Шушы шартларда Садрый Максудый төрек милли-азатлык көрәшен башлап җибәргән Мостафа Кәмалга кушыла. Советларның курчак автономиясен танымаган, туган халкының ирек ала алмавына җаны әрнегән Исхакый исә, инкыйлаб юлындагы таныш көрәштәше Йозеф Пилсудский үз иленең хөкүмәт җитәкчесенә әверелгәч, аның теләктәшлегенә өметләнеп, 1926 елда Польшага килә һәм монда «Идел-Урал» бәйсезлеге комитеты»н кора. «Милли юл» журналы менә шушы комитет басмасы рәвешендә барлыкка килә, Варшавада әзерләнә һәм Берлин типографиясендә басыла.

1930 елда Польша хөкүмәте ярдәмендә Варшавада Идел-Урал, Төркестан, Әзербайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия һәм Көнчыгыш Карелия блогы корыла һәм аңа «Прометей» исеме бирелә. Бәйсезлек өчен көрәшүнең бөтен фаҗигаларын бик мул татыган, шуңа күрә изелгән милләтләргә теләктәшлек белән караган поляк халкы Исхакый һәм аның тарафдарларына кулыннан килгәнчә булышырга тырыша. Әмма 1939 елда Польша үзе һәлакәткә дучар ителгәч, «Прометей» да юкка чыга. Бары 1952 елда гына шуның дәвамы рәвешендә һәм шул ук составта Париж блогы корыла. Әлеге оешмаларда остазына булышуны үзе өчен мәртәбә санаган Гали Акыш, Исхакый вафат булганнан соң, аның вазифаларын башкаруны да үз өстенә ала һәм утыз сигез ел буе көрәшне дәвам итә. Бу көрәш тоташ лагерьга әйләндерелгән ватанда милләтләрнең хокукларын кинәйтүгә, аларны чын азатлыкка чыгаруга, шәхес ирекен җәелдерүгә файда биргәнме-юкмы — монысы башка мәсьәлә, мөһаҗирләр эшчәнлеген шуңа бәйләп кенә бәяләү бик үк гадел булмас иде. Шулай да икеләнмичә әйтергә мөмкин: аларның халыкара мәйданда СССРда кеше хокуклары, милли ирекләр кысылуы, милли үзбилгеләнү хокукының кәгазьдә генә язылуы хакында даими шаулап торуы Кремльне битараф калдырмаган. НКВД еш-еш «профилактик» чаралар күргән, җөмләдән, Г. Исхакыйга Япониядә һөҗүм оештырган, «Идел-Урал бәйсезлек комитеты»нда аның уң кулы булган Гариф Кәримине үтерткән. Димәк, Гали әфәнде дә хәвеф-хәтәрле юлга аяк баскан — ут белән уйнаган!

Шунысы да мәгълүм булсын: бөек язучыбызның соңгы көннәрендә Гали әфәнде гел аның янында кизү торган, әйтеп яздырылган васыятьхатны нәкъ менә ул кәгазьгә төшергән. Үлем түшәгендәге Исхакый шул хатында: «Гали Акыш — минем иң ышанычлы ярдәмчемдер»,— дигән һәм кулын куйган.

Швейцариянең Берн шәһәрендә «Кеше хокуклары һәм үзбилгеләнү буенча Европа комитеты» дигән җәмәгать оешмасы бар, аның эшендә Австрия, ГФР, Швейцария парламентлары депутатлары, галимнәр, журналистлар — күренекле җәмәгать эшлеклеләре катнаша. Комитет ел саен ике конференция үткәрә, брошюралар чыгара һәм җәмәгать фикерен халыкларның үзбилгеләнү хокукын яклауга җәлеп итә. Шушы җәмгыятьнең докторлык титулы, христианлыгы булмаган бердәнбер әгъзасы — Гали Акыш. Англиядә шундыйрак эш алып баручы «Европа әлемтә төркеме» дә аңа күзәтче-әгъза булуны тәкъдим итә. Гали әфәнде кире какмый, бу оешмаларның конференцияләрендә унбиш ел буе катнашып килә һәм анда татар халкының хәле турында сөйли. Әгәр ул бүген: «Мин татарны халыкара мәйданда телгә керттем!» — дип горурлана икән, бәлки, моңа мыскыллы елмаерга һич тә кирәкмидер? Республика дип аталса да, Татарстан соңгы дәвергәчә Тышкы эшләр министрлыгын булдыра алмады, шунлыктан, фидаи Г. Акышның табылуына сөенү аңлашыладыр.

Гали әфәнденең Исхакый мирасын барлауда, аның йөз еллыгы уңаеннан мәшһүр язучыбызга һәм җәмәгать эшлеклебезгә багышланган истәлекләр, мәкаләләр җыентыгын туплауда һәм бастыруда дәртләнеп катнашуын да мактап телгә алуыбыз хаҗәт. Аның туган халкын сөюе шул дәрәҗәдә ки, хәтта, үзенә мичкә-мичкә дегет сылаган бәндәләргә дә рәнҗеми:

— Нишләмәк кирәк, тоталитар режим мәҗбүр иткәндер инде аларны,— дип гафу кыла.

Дистә еллар буе яманатын саткан Татарстанга килгәч тә ул тирәюнендә бөтерелгән ДИК шымчыларына каш җыермады, ягымлы елмаеп, әйтәсе сүзен әйтте, хәтта, күчтәнәчләреннән дә өлеш чыгарды. Казан һәм Чаллы мәйданнарында Татарстанга бәйсезлек даулаган нотыкчыларны тыңлаганда, Сөембикә манарасы янында кичке тамашаны караганда, башкалабыз зиратында Мәрҗани, Тукай каберләренә баш иеп дога укыганда, үзенә бүләк ителгән бер чемодан татар китабын ата-бабасы туган Юнә авылына алып барып, милли матбугатка сусаган укучыларга тапшырганда, аның күзләре яшьләнүен күрү таш йөрәкләрне дә эретерлек иде.

Тыштан карасаң, юка гына гәүдәле, уртача гына буйлы, бүтәннәрдән әлләни аерылып тормаган гадәти бер карт. Ә бит аның бөтен гомере илдән-илгә йөреп белем эстәүдә, туган халкы сулышын киңәйтерлек, озайтырлык мөмкинлекләр эзләүдә узган. Мәҗлесенә карап, кайда — гарәпчә һәм төрекчә, кайда — немесчә һәм урысча мөрәҗәгать иткән һәм тыңлаучыларны, укучыларны татарның бәйсезлек өчен көрәшенә теләктәшлек белдерергә, аңа булышырга өндәгән, милләттәшләребезне исә туган телебезнең, җырыбызның үлемсезлегенә ышандырырга тырышкан, сүзе һәм гамәле белән шуларны бергә тупларга омтылган. Бу һич тә арттыру, аны бизәп-ясап күрсәтү түгел. Чит илләрдәге милләттәшләребез Гали әфәндене 1991 елда юкка гына Бөтендөнья татар лигасы рәисе итеп сайламады. Рухи сафлыгы, идеалларына тугрылыгы, ихласлыгы, көрәштә тәвәккәллеге һәм эзлеклелеге белән ул, бәлки, кайберәүләргә Дон-Кихот кебек тоеладыр. Татар Дон-Кихоты! Чынлыкта исә һәммәбез шатланырга тиеш: ярый әле безнең азатлык хәрәкәтендә шундый каһарман да бар!

### Упкын эчендә

Әгәр без сыйныфсыз җәмгыять корырга керешмәгән булсак, илдә хөррият, шәхес һәм милләт иреге, законлылык канат җәйгән булса, Икенче Бөтендөнья сугышы бүтәнчәрәк тәмамланып, Европада аннан соңгы сәяси тормыш та башкачарак акмас иде микән? Теге якка әсир төшкән сугышчылар саны шактый азрак, андый бәхетсезлеккә юлыкканнарның язмышы күпкә җиңелрәк булмас идеме? Ул очракта инде Көнбатыш белән Көнчыгыш идеологик яктан болай каршы тормас, әнә шул капма-каршы ике лагерь мөнәсәбәтләренә кайберәүләрнең язмышлары фаҗигале төстә үрелмәс иде, бәлки?

Болай баш вату хәзер инде файдасыз,— диярләр.— «Узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!»

Дөрес, килешәм. Әмма Мюнхендә өлкән яшьтәге кайбер милләттәшләрем — кичәге сугыш әсирләре белән очрашу шундый уйларга этәрде мине. Бигрәк тә инде яманатлары сатылганнары белән күрешкәч, аларның бүтән шартларда тормышлары ничегрәк дәвам итү мөмкинлеген күзаллыйсым килде. Әсирләрнең ихтимал гөнаһларын киметеп күрсәтер өчен түгел, тормыш катлаулылыгын, адәм баласының еш кына давыл бөтереп алган каурый хәлендә калгалавын онытмас өчен кирәк бу.

Мин бу сәяхәтнамәмнең бер-ике өзеген гәзитләрдә бастырып чыгаргач, редакцияләргә тиз арада ике хат килеп төште. Берсе — Мәскәүдән,

икенчесе — хәтта, чит илдән, ГФРда яшәп калган әсирдән. «Соңгы вакытта кайберәүләр Германиягә барып, сатлык җан Шиһаб Нигъмәти, Гариф Солтан, Ильяс Габдулла һәм башкаларда кунак булып, Муса Җәлилне үтертүче хәшәрәтләрдән бүләкләр алып кайткач, шулар турында мәкаләләр бастыра башладылар,— дигән иде мәскәүле.— Совет язучысы, журналисты исемен күтәрүче шундый бәндәләргә оят! Белеп торсыннар: сатлык җаннарны яклаучылар үзләре дә иң каты җәзага тартылыр — без аларны болай гына калдырмаячакбыз!..»

Германиядән җибәрелгән хатта янау артык сизелми, әмма әләк исе килми, дип әйтү кыенрак. Совет халкы җитмеш ел дәвамында нигездә өч катламга — әләкчеләргә, җәзалаучыларга һәм корбаннарга бүленгән шартта, бу хатлар мине әлләни гаҗәпсендермәде. Аларда исемем телгә алынмаган, югарыда саналган әфәнделәр хакында әлегә минем һични язганым, димәк ки, бастырганым да юк, әмма авторлар бер нәрсәне дөрес ишарәли — әлеге кешеләр белән очрашуым хак иде. Моны ачыклау бик кыен булмагандыр, чөнки Мюнхендә миннән соң да байтак илгизәр, шул исәптән, без белгән һәм белмәгән милләттәшләр дә барып кайтты, үзләре санап киткән кешеләрдә алар да кунак булды!

Германия хатында бер бик әһәмиятле искәртү бар — «ватаннан килүчеләр алдында әлеге әфәнделәр милләтпәрвәр, сөттән ак, судан пакь кеше ролен уйныйлар, кыска очрашу вакытында Совет кунакларына аларның чын йөзләрен ачуы кыен», дигән ул. Килешәм, бик ихтимал. Германиягә «сатлык» дип танытылган затларны тикшерер, аларны хөкем итәр өчен бармаганлыктан, мин үз өстемә прокурорлыкны да, адвокатлыкны да алмыйм. Нинди кодрәтле Дәүләт иминлек комитеты (ДИК) да бу четерекле эшне камил һәм объектив башкармаганда, гаепләү карарларын шактый дәрәҗәдә стукачлар, эгоистлар, көнчеләр, карьеристлар «шаһитлыгына», утызынчы еллардан килгән «уяулык» традицияләренә нигезләнеп язганда, миңа бу караңгы өлкәгә тыгылмау — иң яхшысы. Ләкин фаҗигале адымнарның этәргеч көчләрен, шартларын ачыкларга тырышу, мөгаен, язучыга гөнаһ түгелдер?

Әйтик, хәләл көчең белән тапкан, берничә буын нәсел-нәсәбең тырышлыгы белән барлыкка китерелгән бөтен мөлкәтеңне тартып алалар да үзеңне Себергә сөрәләр, аннары шуның ачысы, гарьлеге басылып өлгермәгән килеш, сине ватан өчен «изге сугыш»ка җибәрәләр. Шул солдатның «изгелек», «изге ватан» төшенчәләре ни дәрәҗәдә ихлас һәм тирән булырга мөмкин? Без аңардан ватан өчен гомерен бересүзсез корбан итүне көтәргә хаклымы? Ә бит Оренбург ягы егете Вәлиулла Төхфәт нәкъ менә шундый язмышка ия. Дөрес, ул аңлы рәвештә үзе теләп әсир төшмәгән — намуслы сугышкан, ләкин «даһи» юлбашчыбызның һәм аның тирәлегенең үтә оста «җитәкчелек» итүе аркасында чолганышта калган, фронтта була торган рәхимсез очрак аны дошман кулына тоттырган. Фашист лагерьларыннан качу омтылышы бик көчле булмаган икән, менә монысы инде ватанда «иркәләүләрнең» тәме китеп бетмәүгә дә бәйләнгәндер. Бер аңарда гына түгел, меңнәрдә, миллионнарда!

Кулак малае булганга, аңа югары, хәтта урта белем алу да «изге ватанында» тәтеми, билгеле. Шуна күрә ул немесләр күзендә дә сәяси грамотасыз санала, тәрбия эшенә җәлеп ителми, бары кара хезмәт кенә башкара. Әмма гаҗәп тырышлыгы, пөхтәлеге, эшкә иренмәве белән ул югары белемле Минһаҗ Исмәгыйли кебекләрне шактый артта калдыра — тормыш юлын, күргән-кичергәннәрен тәфсилләп тасвирлаган тулы бер китап яза, аны гарәп һәм латин әлифбасында акка күчереп төпли, аннары шуны немесчәгә дә тәрҗемә итә — аның кемлеген белсеннәр әле! Вәлиулла абзыйның гарәп хәрефеннән латинчага күчергән, машинкада үзе басып, үзе төпләгән китаплары арасында: Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре», С. Рәмиевнең «Шигырьләр»е, Г. Исхакыйның «Теләнче кыз»ы, «Зөләйха»сы, «Зиндан»ы, «Кыямәт»е, Г. Газизнең «Татар тарихы», Г. Мансуровның «Татар провокаторлары» һәм күп кенә

күмәк җыентыклар бар. Ул югарыда саналган китапларны милли әдәбиятыбызны укырга мохтаҗ мөһаҗир милләттәшләребезне азыкландыру өчен күчереп язган һәм күбәйткән бит.

«Безнең арада иң акыллысы — Вәлиулла»,— дип аны, мөгаен, юкка гына телгә алмаганнардыр. Куркулар басыла, юллар ачыла төшкәч, ул Алманиягә илдә калган хатынын өч мәртәбә, энесен-сеңлесен, кызы белән ике улын әллә ничә тапкыр китерткән, аларга өч җиңел автомобиль, биш мотоцикл һәм бүтән затлы әйберләр бүләк итеп җибәргән. Миллионер булганлыктан түгел, әсир солдат Германиядә югары хак түләнә торган эшкә ничек керә алсын инде? Гомере буе эчмәгән-тартмаган, тапканын саклап тоткан, шуның аркасында гына ватанында «кулак токымы» дип тинтерәтелгән газизләренә булыша алган ул.

— Хатынымны Алманиядә бик калдырасым килде, әмма туган илкәйне сагынуына түзә алмас, шуннан аеруым өчен миңа рәнҗер, дип уйладым. Алманиядә тол калган хатын-кызлар күп очраса да, алар белән оешып, бала үрчетәсем килмәде, гел илдә калган нарасыйларымны, шуларга ничек булышуны уйлап гомер иттем,— диде ул миңа.

Вәлиулла Төхфәт — һөнәре буенча хисапчы. Шуңа күрәме, аның өендә педант немецләрне дә сокландырырлык пөхтәлек, тәртип. Килгән хатлар, алыш-биреш кәгазьләре, кульязмалар һәммәсе папка-папка тегелгән, эстамп, келәм зәвык белән эленгән, мебель уңайлы итеп тезеп куелган. Тәрбия эшендә эшләгән — «Азатлык» радиосының татар редакциясенә җитәкчелек иткән әфәнделәр, пенсиягә чыккач, татар журналларын карап баруны, бигрәк тә, өйгә алдыруны туктатканнар. Ә Вәлиулла Төхфәт, гади бер техник хезмәткәр, үзен азыкландыру өчен «Казан утлары»на быел да язылган — шүрлекләрендә шул басманың утыз еллык төпләмәләрен күрергә мөмкин.

Мин башта, тимер юлга орынып торганлыктан, аның кооператив фатиры яшәү өчен уңайсыздыр, поездлар узган саен дер селкенүе, гүләү-дөбердәүләрдән коткара алмавы белән тынычлык сөйгән карт кешенең сәламәтлеген какшатадыр, дип уйлаган идем. Станция ыгы-зыгысына да якын шундый җирдә фатир арзанрак сатылгандыр — аның 130 мең маркага гына бәяләнүенә кызыккандыр инде, янәсе. Әмма немецләр әйбәт кора белгәнгәме, әллә Вәлиулла абзыйның өч бүлмәсенә дә, хәтта, коридор, ашханә, лоджийларына чаклы йомшак келәмнәр түшәлгәнгәме, тәрәзәләренә калын пәрдәләр эленгәнгәме, аның өе тыныч, тыштан чит-ят тавышлар әлләни ишетелми иде. Вәлиулла абзыйның затлы, якты, ямьле өендә утырганда мин ирексездән күптән түгел Самарада күрешкән Ләйлә Кәримованы исемә төшердем. Ул гражданнар сугышында катнашкан, Ленинның ялкынлы чыгышларын тыңлаган, Надежда Крупскаяның милләттәшләребезгә сөйләгән нотыкларын татарчага тәрҗемә итеп йөргән, аннары һәркемгә бәхет китерәчәк коммунизм җәмгыятен гомере буе төзегән. Күн тужурка киеп, биленә наган асып сыйнфый дошманнарның тамырын корытып мәш килгән яшьлек еллары, шул дәвердәге һәм соңгырак батырлыклары турында әле сиксәнгә житкәч тә пионерларга-комсомолларга сөйләп, аларны тәрбияләүдән бушамаган карт коммунист иде ул. Мин аның бер бүлмәле фатирына килеп кергәч, акшары коелган ялангач, ала-кола диварларны, калҗыган урындыкларны, ач тараканнар, кыргаяклар йөгерешеп йөргән аш өстәлен күреп шаккаткан идем. Азин комсомолкасы әлеге диварның буе житкән һәр тарафында кандалаларны шулкадәр күп сыткан ки, минемчә, ул үзен яңадан Гражданнар сугышы елларындагыча — канлы замандагыча яшәүгә дучар иткән иде. Карт коммунистларның һәр җирдә, һәрчак акыл сатуыннан, икейөзлелегеннән, фанатиклыгыннан туйгангамы, Самара пионерлары һәм комсомоллары Ленин гвардиясе солдаты Ләйлә Кәримованың өенә килеп, дезинфекция ясарга уйлап та карамаган иде. Гаилә корырга да вакыт тапмаган, бөтен аңлы тормышын кызыл идея таратуга гына

биргән большевичканың үзе барлыкка китергән шундый тирәлектә рәхәт чигүенә комачауламаска тырышканнардыр инде!

Ә Ләйлә Кәримовалар тырышлыгы белән тамыры корытылган Вәлиулла Төхфәт Мюнхен кырыендагы комфартабельле фатирында муллыкта һәм туклыкта яшәп ята. Идеаль пакьлыкта! Лоджиенда гөлләр, кипарислар үсә, тәрәзәләренең кайсылары егерме метрдагы тимер юлны каплап торган бөдрә каеннарга, кайсылары тротуардан ук башланган ямь-яшел иген кырына караган. Өе дә, андагы барлык җиһаз да бары тик хәләл хезмәт җимеше, монда инде, шөкер, Ләйләләр гвардиясе килеп, аның малын кычкыртып тартып ала алмаган. Ә бит алар миллионнарның милкен талап кына чикләнмәде, көнкүрешләрен дә җәһәннәм газабына әйләндерде, газиз гомерләрен сөргеннәрдә, төрмәләрдә кисте. Вәлиулла абзый — мактаулы социализм лагереннан сугыш гарасаты аркасында очраклы рәвештә аерылган һәм исән-имин калган миллионнарның берсе. Билгеле, мин аны чамасыз бәхетледер, дип уйламыйм, чөнки ватаныннан мәхрүм булуны Көнбатыш хөррияте дә, матди җитешлек тә алмаштыра алмый. Ләкин миңа «корбан» Вәлиулланың гомер көзе — аның үзе теләп сайлап алмаган язмышы «җәзалаучы» Ләйләнекеннән яктырак, ямьлерәк, ә иң мөһиме, гөнаһсызрак тоелды. Бу нәрсә: сәламәт орлыкның — тырыш татар игенчесенең геннарының җиңүеме, саташу, демагогия колларыннан өстен чыгуымы? Белмим. Әмма бу турыда без кайта-кайта һәм бик ныгытып, күмәкләшеп уйларга тиештер.

* * *

Техник хезмәткәрләрнең икенчесе, югары белемлесе — Ильяс Габдулла. Казанның Бишбалта бистәсендә туган, Нәриман Нәриманов исемендәге татар мәктәбендә укыган, аннары институт тәмамлап, дипломлы инженер булган. Утызынчы елларда Казанның Мулланур Вахитов исемендәге заводында эшләгән. Чаллының такта яру заводы баш инженеры, Екатеринбургта «Уралмаш»ның техник инспекторы булган Ильяс Украинаның Копанище поселогында да җаваплы вазифалар үтәгән. Гаскәри хезмәтен Польшада, Совет Армиясенең хәрби төзелеш идарәсендә башлаган.

— Командирыбыз Сергей Горбачев сугыш дәверендә полковниктан генерал дәрәҗәсенә кадәр үсте,— диде Ильяс абзый.— Монда татарлардан ялгызым гына идем, полковник Сергей мине яратты, әмма аны бүтән хезмәткә күчергәндә, яңа җиргә үземне дә алып китүен үтенергә башыма килмәгән. Аның урынына билгеләнгән яңа командир исә мине ошатмады, хәрби курсларга озатты. Лейтенант дәрәҗәсен алганнан соң дивизия штабы башлыгы урынбасары итеп билгеләндем, тик мине монда беркетеп калдырмадылар. Сталинград фронтының бер пехота батальоны командирына адъютант кылдылар. Минем өчен чын алгы сызык сугышы шушында башланды. Бәрелешләрнең берсендә миңа шартлавыннан контузия алганмын. Аңымны җуеп күпме ятканмындыр, һушыма килгәндә мин инде дошман кулында идем. Шуннан лагерь михнәтләре башланды инде, сиксән җиде килограммнан кырык алтыга калганчы ябыктым.

Мине Мюнхенгә алып китәр өчен Ной Үлмгә килгән өч кешенең берсе — ап-ак чәчле, зур карчыга борынлы, олпат гәүдәлесе шушы Ильяс Габдулла иде. Сиксәнен тутырган ялгыз пенсионерның буш вакыты күп, күңелендә җирсү хисе дә куерса, туган-үскән җиреннән, кендеге киселгән Казан каласыннан ватандашы килүен ишеткәч, ничек инде бер сәгатьлек юлга чыкмый түзсен ул?

Ильяс абзый, үзе сөйләүдән бигрәк, әңгәмәдәшләрен тыңларга һәвәс гаять игътибарлы бер кеше булып чыкты. Мюнхен шәһәренең истәлекле урыннарын, аның тирә-ягындагы елга-күлләрен, урман-паркларын, тауларын-үзәннәрен тамаша кылдырырга әзер икәнлеген алдан ук искәртеп

куйды, аннары әллә ничә мәртәбә телефоннан шалтыратып, моңа кайчан вакытым тиясен белешкәләп торды. Әмма мин мөһаҗир милләттәшләремнең шәхси китапханәләрендә байтак кызыклы китап-журналларга беренче мәртәбә юлыкканлыктан, аларның илдә кулыма керәсенә ышанып бетмәгәнлектән, Мюнхендә шуларны укырга утырдым. Үзенчәлекле архитектурасы, тирә-ягының матур табигате — Альп таулары итәге белән чын-чыннан мактана ала торган шәһәрне тамаша кылып хозурланырга минә шунлыктан да вакыт җитмәде. Шулай да Ильяс абзый миңа кайбер истәлекле урыннарны — сыра бәйрәмнәре уза торган мәйданнарны, мәһабәт чиркәүләрне, төрекләр ачкан мәчетләрне, шәһәрнең баш тимер юл вокзалын, олимпия үзәген, искиткеч бай супермаркетларны күрсәтергә өлгерде, хәтта, Вәлиулла Төхфәтләргә, Шиһаб Нигъмәтиләргә дә алып барды.

Мине иң гаҗәпләндергәне — инженер Ильяс абзыйның диндарлыгы булды. Шәхси китапханәсе бай, әмма аның шактый өлеше — туксан тугыз төрле басылган Коръән, аның тәфсирләре, ислам фәлсәфәсе җыентыклары. Гарәп, немец, төрек телләрендә. Арада үзе язган, машинкада баскан, брошюра итеп төпләнгәннәре дә бар. Машинка дигәннән, Ильяс абзыйның латин, гарәп, урыс хәрефләре куелган биш машинкасы бар, минем белән кибеттә йөргәндә, тагын берне, яңаны сайлап маташты. Юл буе сөйләгән сүзе — татарның динсезлеге, имансызлыгы, шуның аркасында аның бүген бозылуы, бүтән халыклар эчендә бик тиз эреп бетә баруы турында булды.

Безнең «уяу»лар нигә бәйләнә икән аңа? Сөйләве буенча, ул бит әсирлектә татар легионына язылган милләттәшләренә дә дин кертергә, аларны хәмердән аерырга тырышкан, соңгы гамәле белән кайберәүләрнең ачуын да бик каты кабарткан. Дрездендә Галимҗан Идриси җитәкчелегендә ачылган Ислам институтында белем алгач, мөселманлыгы тагын да көчәйгән. Әсир мулла, сугыш беткәч, «Дин һәм тормыш» журналы чыгара башлаган. Бәлки әнә шул диндарлыгы аркасында дипломлы инженер христианлык көчле Алманиядә пенсиягә чыкканчы гади электромонтер булып эшләгәндер? Чөнки ул, иптәшләре ни кадәр үгетләсә дә, үзенең башлыгына — чибәр һәм чагыштырмача яшь, зәңгәр күзле әсир монтерга өметле карашлар ташлый торган немес марҗасына, «кяфирә» дип, өйләнергә теләми. Гомерлек буйдак Ильяс мөселманлыкның пагърак һәм хаграк дин икәнлеген исбатларга омтылып, немес побы белән бәхәскә керә. Кайда бәхәсләшә бит — мөселманлыкны ят күргән Алманиядә. Гәзит-журналларга үз туксанын туксан дип мәкаләләр яза, брошюралар бастыра. Немес теләндә! Ислам диненең немесләр арасына үтеп керә башлавына болай да эчләре пошкан кайбер кяферләр чыдамый — «бусурман миссионерын» бер көнне кыйнап аталар. Икенчесендә исә ашына агу салалар — аны америкaн докторлары көчкә үлемнән коткарып кала.

Күр инде, кая гына барып тыкшынмый бу татар! Пенсиягә куып чыгарылгач, дус немесләре: «Анда барма, зыяны тияр»,— дип үгетләүгә карамастан, Ильяс Габдулла Иорданияга, Сүрия, Израил, Төркиягә юл тота. Төркиядә дә әллә ничек шик уята ул, кырык өч көнгә төрмәгә ябып куялар үзен. Көн аралаш кыйнап, Керенский һәм бүтән урыс сәясәтчеләре турында сорау алалар, аннары әйбәтләп кенә илдән сөрәләр!

Эшеннән ирексезләп чыгарылган Ильяс Габдулланың хезмәт стажы Алманиядә таләп ителгән күләмгә тулмый, шуңа күрә пенсиясе дә бик әз — дүрт йөз марка гына бирелә. Мондый очракта демократик илләр арасында гомуми хезмәт стажын берләштереп санау гадәте дә бар икән. «Фашист концлагерьларында узган гомеремне стажга кертмәсләр,— дип уйлый Ильяс абзый,— әмма СССРда эшләгән ун елым, Совет Гаскәре сафларында дошманнарга каршы сугышып уздырган ике елым бар ич әле. Германия СССРдан ул унике еллык хезмәт өчен пенсия түләүне таләп итмәячәк, бары ватанында чакта паразит, җинаятьче булмаган-

лыгын, гомерен эшләп уздырганлыгын гына ачыклаячак, шуннан соң үзе өстәячәк ул акчаны».

Шундый уйлар белән ватанына, кайчандыр үзе эшләгән заводларга үтенечләр язып җибәрә. Шаярма, Ильяс Габдулла! Кадрлар бүлекләрендә кайда да ДИКнең ышанычлы кешеләре эшли бездә. Кара син бу оятсыз легионерны, сатлыкны, белешмә кирәк булган, имеш, ана. Тоттырдылар ди, көт!

Әмма шулай да үтенечкә бер заман җавап килә бит әй. «Казан утлары» журналының 1976 елгы 11 санында Альберт Яхинның аның турында тозлы-борычлы мәкаләсе басылып чыга. Монда инде аның кайда какырганына, кайда төкергәненә чаклы телгә алынмый калмый. Кайда эшләсә, шунда хезмәт тәртибен бозган, социализм төзелешенә таяк тыгып йөргән икән ул. Димәк, белешмә урынына да шымытыр гына сиңа!

И. Габдулла үзенә шулкадәр кара ягылуына гаҗәпләнә, нәфрәтләнә, әмма моңа каршы нишли алсын соң ул? Альберт Яхин артында кодрәтле ДИК торуын чамалый лабаса әсир-мөһаҗир.

Дөнья шәфкатьсезләрдән генә тормый, билгеле. АКШның хәрби әсирләрне яклаучы бер җәмгыять оешмасыннан бер урыс агае И. Габдулла язмышын ачыкларга алына, аның 1943 елдан башланган тормышы турында шәһадәтнамәләр җыя һәм шулар нигезендә пенсияне тугыз йөз маркага кадәр күтәртүгә ирешә. Соңрак, Алмания тагын да ныграк аякка баскач, моңа тагын дүрт йөз марка өстәлә. Германия шартларында бу бик күп түгел, билгеле. Әмма торгынлык еллары сәясәтенә тырышып хезмәт иткән фән докторы А. Яхинның пенсиясе, мөгаен, Ильяс абзыйныкының чиреге дәрәҗәсенә дә җитмәс. Чөнки ул табынган социализм кануннары буенча: «Һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хезмәтенчә!»

Илебездә тоталитар режим зәгыйфьләнгәч, идеологик калыплар берәм-берәм юкка чыга башлагач, сиксәнен тутырган Ильяс абзый Совет консулына барып, илен кайтып күрергә рөхсәт сораган. Аның кемлеген ачыклаганнан соңдыр инде, дипломатыбыз:

— Мөмкин. Күреп кайтыгыз соң, — дигән.

Мине Мюнхеннән озатып җибәрергә дә килгән чал чәчле, монсу карашлы бу карт, сугыш гарасаты чыкмаса, нинди тормыш юлы узган булыр иде икән? Ул диндарлыкка, ихтимал, бирелмәс, чөнки үзен бу дөньяда бик көчсез бер мәхлүк тоймас иде. Югары белемле башы белән гади электромонтер хезмәтен дә башкарып йөрмәс иде. Тәҗрибәсе арткач, бәлки, әле үсәр, берәр заводның абруйлы белгече яки житәкчесе дә булып китәр иде. Гаилә корыр, балалар үстерер, картлыгын шулар белән мәйханә килеп кичерер иде. «Сатлык» ярлыгының ни икәнен дә белмәс иде ул.

Сугыш чыккан да Ильяс Габдулланың һәм бүтән миллионнарның язмышын шундый зир-зәбәр китергән ки, хәзер инде без алар хакында бер миһербанлы сүз әйтергә дә икеләнеп торабыз. Гаделлекмени бу?

* * *

Әмма шул ук вакытта, Икенче Бөтендөнья сугышында немецләргә әсир төшкән сиксән меңләп татарның берсенең дә ватан алдында гонаһысы юк, аларның һәммәсе сөттән ак, судан пакь булган дип раслау да ярамас. Бу хакыйкатькә хыянәт булыр иде. Меңәрләп, дистә меңәрләп исәпләнгән сугышчы арасында кыйбласызлары, гаиләләре, кардәшләре, коралдаш иптәшләре алдында җаваплылык хисен югалтканнары, нәрсәгәдер кызыгып, өметләнеп яки газаплауларга чыдый алмыйча, хәрби серне чишкәннәре дә очрагандыр. Андыйларны хурлык белән тамгаламасак, газиз гомерләрен корбан иткән меңнәрчә якыннарыбызның рухлары безне гафу итмәс. Шул ук вакытта акны ак,

караны кара дип тану сәламәт әхлакның мәҗбүри шарты, ансыз кеше кешелеген җуеп бетерер иде.

Ислам дине өйрәтүләре буенча, адәм баласының ике иңендә ике фәрештә — Нөнкир белән Мөнкир утыра, алар безнең һәр гамәлебезне — гөнаһлыларын да, саваплыларын да кыямәт көнне бизмәннәр өчен язып бара, имеш. Оҗмахка яки тәмугка эләгүебез әнә шул язмыш тактасына теркәгән язуларны укыгач, бәяләгәч кенә хәл ителә, диелә изге китапта...

Ходайның сөеклесе булсак та, безгә, адәм балаларына, аның зирәклеге җитеп бетми: бер-беребезне хөкем итәр өчен еш кына бары сыңар шаһитлыкка таянабыз, язмышлар тактасының кайсы элгә — гөнаһлар теркәлгәнеме, саваплырныкымы — анысы өчен артык кайгырмыйбыз. Мондый мөнәсәбәт тоталитар режим чиновникларына аеруча хас иде, гадәттә алар гөнаһлар тактасы белән яратыбрак эш итте. Моны Ш. Нигъмәтиләрне, Г. Солтаннарны гаепләгән мәкаләләрдән дә бик ачык күрәсең: аларның бер генә яхшы сыйфатларын, игелекле гамәлләрен дә телгә алмый авторлар!

Шиһаб Нигъмәтинең олы улына — Маркс, уртанчысына — Нигъмәтулла, өченчесенә Ирек исеме кушуы гына да бик кызык. Баласына исем кушканда һәркем ихлас була — зәвыгын, хыял-идеалларын, иманын ачып сала. Беренче исем Шиһабның марксизмга табынуын, икенчесе — атабабасын хөрмәтләвен, өченчесе — нәселенә, халкына ирек, азатлык теләвен чагылдыра. Тагын шунысы да игътибарга лаек дип уйлыйм: Ш. Нигъмәтинең исән булуы, Алманиядә торып калуы һәм «Азатлык» радиосында эшли башлавы ачыклангач, аны каралта торган материаллар тупларга керешүчеләр «сатлык»ның туган авылы Рәнчеккә баралар, әмма Шиһабны яманлаучыларны тапмыйлар. Хатыны Бәдриҗамал: «Минем өчен яхшы ир иде», — дип тикшерүчеләрнең гомумән кәефен кыра!

Шиһабетдин Нигъмәти туган авылында алган сабактан соң Тубыл җидееллык татар мәктәбен тәмамлаган, аннары өч айлык укытучылар курсында белемен күтәргәч, туган ягында үзе балалар укыта башлаган. Тиздән яшь комсомолец Свердловскидагы Урал коммунистлар университетына укырга җибәрелгән. Комсомол юнәлтүе буенча, колхозларны ныгыту эшендә катнашкан, 1934—1939 елларда Рәнчек мәктәбенә мөдирлек иткән. Гаскәри хезмәткә алынгач, кыска гына вакыт эчендә рота политругыннан алып яраланган батальон командирын алыштырган өлкән лейтенантка кадәр үсәргә өлгергән. Солдатларны сугыш һөнәренә өйрәткән, теткәләнгән батальоны белән дошманның ике полгына каршылык күрсәткәндә кабат яраланган һәм тигезсез сугышта һушсыз хәлдә әсирлеккә эләккән. Аңлыйсым килә: шундый кеше ничек кинәт кенә «хәшәрәт сатлык»ка әйләнде икән?

Ш. Нигъмәтинең әсирлектәге һәм аннан соңгы тормышы турында сөйләвен сәгатьләр буе тыңлап утырдым, ләкин ишеткәннәремне хәзер үк — шаһитлар яки документлар раслаганчы, кәгазьгә төшерәсем килми. Аның язмыш такталарын тулысынча укыр өчен исә иркенрәк вакыт кирәк. Ул кайнаган вакыйгаларда Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Рәхим Саттар һәм бүтән мәгълүм шәхесләр дә катнашуын искә алсак, Берлиндә һәм Варшавада, Вустраууда һәм Мюнхендә, тагын әллә кайларда тәгәрәп йөргән серле йомгакны сүтәр өчен, упкын эченә илтеп ташланган солдатның нинди авыр сынауларга дучар ителүен, сират күперен кичкәндә кайда ничек тапкырлык һәм егетлек, кайда җебегәнлек һәм вак җанлылык күрсәтүен сүрәтләр өчен махсус язу кирәклеге аңлашыла. Тик бусы — киләчәк эше. Монда исә мин матбугатта элегрәк чыккан мәкаләләрне бераз тулыландыру, гаделлек өчен Нөнкир тактасы янына Мөнкирнекен дә кую зарурлыгын төшенеп, бераз яңа мәгълүматлар китердем, әмма халкыбызның үзбилгеләнү һәм бүтән хокукларын яклауга, «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе эшен юлга салуга Ш. Нигъмәти керткән өлешкә бөтенләй кагылмадым. Ул өлеш исә шактый зур һәм игътибарга лаек.

* * *

Мулюков, Керенский, Колчак, Власов һәм шулар кебек бүтән «совет дошманнары», «сатлыклар» турында урыс галимнәре һәм язучылары даими язып торганда, киночылары фильмнар төшергәндә, мондый эшкә украин, белорус, үзбәк, казакъ һәм башка халык вәкилләре дә керешкәндә, тарихи үткәннән якты сәхифәләр, тәрбияви каһарманлык кына эзләүдән туктап, хурлыклы вакыйгаларны, антигеройларны да матбугат мәйданына, театр сәхнәсенә һәм экранга чыгарганда, безгә дә берьяклылыктан котылырга вакыт. Чынбарлыкны бизәмичә кабул итәргә, үткәнне бөтен катлаулылыгы, каршылыклылыгы белән сурәтләргә иде. Сәнгать һәм тарих бары шул очракта гына безгә тормыш мәктәбе була ала.

Әлегә кадәр бары тик тискәре сыйфат-фигыльләре генә танытылган татар әсирләренең берсе — Гариф Солтан. «Нимесләр белән хезмәттәшлек иткән, Муса Җәлилне саткан, «Азатлык» радиосында эшләп, Советка каршы көрәшкән» куркыныч дошман!

Мюнхендә минем каршыма исә ягымлы, әдәпле бер кеше килеп басты. Аңа һич тә алтмыш жиде яшьне биреп булмый иде. Шагыйребез Дәрдмәнднең авылдашы, дөресен әйтим, халкыбыз тарихын, әдәбиятын, сәяси хәлен тирән белүе, гомуми мәгълүмат хәзинәсенең байлыгы белән мине бик гаҗәпләндерде һәм сокландырды. Икеләнмичә расльш алам: ул Алманиядәге милләттәшләребез арасында бүген иң укымышлысы, мөгаен, бездәге фән докторы дәрәҗәсендәге кеше. Дөрес, ул докторлык диссертациясе якламаган, әсирләр лагереннан котылгач, сугыштан соң Алманиянең Һамбург университетында юридик факультетны тәмамлаган да «СССР милләтләре статусы нигезендә Татарстан Автономияле Җөмһүрияте хәле» дигән диплом эше генә язган. Әмма шәхси китапханәсендәге ул файдаланган йөзләрчә-меңнәрчә китап-журнал белән танышсаң, Г. Солтанның гомер буе белемен күтәрүенә ышанасың. Безнең байтак галимнәребездән өстенлеге дә бар — татар һәм урыс телләрен камил белүдән тыш, ул инглизчә һәм нимесчә иркен сөйләшә һәм яза, күп кенә мәртәбәле халыкара конференцияләрдә, симпозиумнарда докладлар укый.

Мин шул докладларның берсе — Азия һәм Африка халыклары язучыларының 1962 елда Каһирәдә уздырылган икенче конференциясендә сөйләнгәне белән танышып чыктым. Залда утырган Совет язучылары вәкилләре Г. Мөсрипов, К. Яшен аны тыңлаганда эчләреннән, мөгаен: «Без әйтергә җөрьәт кылмаганнарны ярды да салды лабаса бу!» — дип сөенгәннәрдер. Чөнки Г. Солтан шушы конференциядә колониализмның барлык төрләрен, җөмләдән, СССРда азчылык милләтләренең үзбилгеләнү хокукы кәгазьдә генә булуын, милли аңны, мәдәниятне үстерүгә уңайлы шартлар тудырылмавын, иҗат ирегенең буылуын фаш итеп, дәлилле чыгыш ясый, СССРдагы милли мөнәсәбәтләрне, рухи тормыш шартларын, Совет һәм КПСС житәкчелеге уздырган сәясәтне анализлый. Докладны бүген туган телебездә бастырып чыгарсак, авторга бәрәү дә «яла яга, ялганлый» дип дәгъва белдерә алмас, без бүген таныган хакыйкатьнең моннан утыз ел элек халыкара сәхнәдән чатнатып әйтелүенә генә гаҗәпсенеп куяр. Татар совет язучылары ялварып та бара алмаган конференциядә милли хокукларыбызны дәгъвалаучы милләттәшебез табылуга сөенер!

Шушы ук елны ул Багдадта бөтендөнья мөселманнарының бишенче конгрессында «СССРда мөселман халыкларының хәле» дигән доклад сөйли, анда тарихи планда бер гасырлык дәверне яктырта. Авызлары бикле, әмма күңелләре кан елаган СССР вәкилләренең кайберләре монда инде докладчының хакыйкатьне ачуына шатлануларын шыпырт кына булса да Г. Солтанга белдерергә, рәхмәт әйтергә кыюланалар. Совет хөкүмәте АКШ гражданына әверелгән «сатлык жан» Г. Солтанны кон-

ференциягә чакырган өчен Гыйрак хөкүмәтенә протест белдерә. Гариф әфәндене шәхси таныган мөфтинең Касыйм шаһка мөрәҗәгать итүе генә халыкара җыйналышта тирән эчтәлекле, бай мәгълүматлы янә бер докладның сөйләнүенә, соңыннан гарәп һәм инглиз телләрендә басылып чыгуына мөмкинлек бирә.

1964 елда Нью-Йоркта Бөтендөнья ярминкәсе үткәрелә, шул уңайдан анда һәр көн мәгълүм бер мәмләкәтнең, милләтнең яки берничә кардәш халыкның сәнгатен танытуга багышлана. Бу вакытта АКШта СССРның төрки кавемнәре вәкилләре, Германия һәм Ерак Шәрекъ аша күчеп килеп, инде ике меңгә җиткән була. Алар ярминкә җитәкчелегенә үз милли көннәрен үткәрергә рөхсәт сорыйлар һәм моңа ризалык алалар. Концерт әзерләү өчен комиссия корыла һәм аның башлыгы итеп Гариф Солтан сайлана.

Концерт программасына Идел-Урал һәм Кырым татарлары, Төньяк Кавказ халыклары һәм әзербайҗан җыр-биюләре кертелә. Бөтен АКШка сибелгән мөһаҗирләр арасыннан сәләтле һәвәскәрләрне, милли киемнәрне эзләү башлана. Концертны аңлатмалар белән инглизчә алып барырга ирландияле Эфна Голдн — «Америка тавышы» радиосында татар редакциясе (1950—1952) техник секретаре булганда телебезне өйрәнгән кыз ризалык бирә. Алабама штатыннан Суфия Дәүләт АКШ гимнын башкаруны үз өстенә ала.

Төрле милләтләрнең күмәк концерты булса да, программаның яртысын безнең җырлар-биюләр тәшкил итә. «Баламишкин»ны Кәүсәр һәм Рамазан Вәлиуллалар, Рөстәм Яхинның «Табын» җырын Суфия Дәүләт, Габдулла Сакмарның «Урал» көен Хафиз Шаһмай яңгырата, «Әпипә»не Гариф Солтан белән Хәлимә Шаһмай бии. Пианинода Баян Якуп төрле көйләребезне уйный, Ләйлә һәм Арысланбәк Таймаслар үзенчәлекле бүтән биюләребезне башкара. Алкышларга күмелгән концерт барышында американнарга әсир милләтләр турында байтак мәгълүмат та бирелә.

Концерт ошаганлыктан, матбугатта аңа багышланган мәкаләләр, фотосурәтләр дә басыла, тамашачылар аны кабатлауны үтенеп, ярминкә җитәкчелегенә мөрәҗәгать итә. Тамашаны оештыручылар истәлекле медальләр белән бүләкләнә. СССР консуллыгы вәкилләре генә бу бәйрәмдә катнашудан баш тарта.

Күзгә-күз сөйләшеп утырганда да, кеше алдында да Гариф Солтан кат-кат:

— Әсир төшкәч, концлагерьларда җәфалануым, аннары Алмания хөкүмәт идарәсенең Көнчыгыш министрлыгында татар бүлеге башлыгының рәсми тылмачы булуым, соңрак «Азатлык»ның татар-башкорт редакциясендә эшләвем, Совет тоталитар режимын, СССРдагы милли тигезсезлекне даими фаш итеп торуым, татар-башкортларга чын ирек даулавым һәммәсе дөрес,— диде.— Шуның өчен илдә мине сүгәләр, каһәрлиләр икән, дәгъвам юк. Ә менә Муса Җәлилне, аның иптәшләрен сатуда гаепләүләре белән килешә алмыйм. Алманиянең бөтен архивларын актарып чыксыннар — Җәлилне чагуымны исбатларлык бер шаһәдәтнамә дә табылмас. Нахакка гаепләү рәнҗетә. Уйлап карагыз: мин Җәлилне берничә мәртәбә генә күрдем, алар төркеменнән гел читтә булдым. Серләрен белер өчен араларында буталу, бергә кайнашу кирәк ич. Очраклы рәвештә генә тотылды алар. Казармада эшкә китүчеләр киезе астына листовка тыкканнар. Провокациядер бу, дип уйлап, легионерлар үзләре ул листовкаларны немесләргә илтеп биргән. Шуннан инде тентү, тикшерүләр киткән. Без Җәлилне коткарырга теләдек, шуның өчен төрле чаралар күрә башладык, әмма бу кайгыртуларыбыз шул көннәрдә Һитлергә һөҗүм ясалу аркасында, уңышсызлыкка очрады. Фюрергә кул күтәрүчеләргә үч итеп, кулга алынган меңләгән немес тә атып үтерелде, мондый шартларда Җәлилне һәм аның иптәшләрен гафу иттерүгә ирешү мөмкин булмады. Мин үземне әйтмим, тылмачның мөмкинлеге чамалы, Шәфи Алмаз кебек, немесләр алдында абруйлырак кешеләребез дә алар-

ны бәладән йолып алырлык кодрәткә ия түгел иде. Үзләренең шикләрен яки мине өнәмәүләрен ялган шаһитлык өчен нигез иткән милләттәшләрем табылуы мине чиксез нәфрәтләндерә. Аңлашыла инде: НКВД тикшерүчеләренә немецларга тылмачлык кылган татар солдаты фашистның үзеннән дә гөнаһлырак күренә. Ватанга алып кайтылган әсирләрнең кайберләре исә, шулай үз язмышымны җиңеләйтә алырмын, бәлки, дип кайтмаучыларны әләкли. Ләкин аларга ни өчен һәркем ышанырга тиеш?

Алмания архивларын күздән кичерү немец телен әйбәт белгән кешегә дә җиңел эш түгел. Ул архивларның тулы саклануына да ышаныч юк. Шулай да эзләнү кирәк иде, имеш-мимешкә, теге яки бу кешенең үзенә ошау-ошамавына, җиңелчә фаразларга таянып кына, аны гаепләмисе иде — бу яктан Гариф әфәнде, әлбәттә, хаклы. Аңа карата ничек булгандыр, әмма бездә НКВДның бик озак еллар чәч аласы урында баш алу белән шөгыльләнүе кемгә дә сер түгел хәзер.

Минем бу язмаларым гаепләнүченең дә фикерен һәм теләген ачыкларга булышыр, дип өметләнәм. Гадәттә, суд гаепләнүчегә дә сүз бирә, ләкин бу мөмкинлек әлегә кадәр Г. Солтанга карата тудырылмаган иде.

Бу уңайдан шуны да әзеп әйтү кирәктер: үзенең раславынча, Гариф Солтан беркайчан да герман хәрби киемен кимәгән, татар легионына язылмаган һәм анда хезмәт итмәгән. Алайса аның яманатын ни дип саттык соң без? Аңа кара ягуны илленче-алтмышынчы елларда нигә аеруча көчәйттек? Әллә соң безгә караңгы бүтән мажаралары да бармы аның?

Күпләр хәтерлидер, нәкъ менә алтмышынчы елларда КПСС һәм СССР хөкүмәте җитәкчесе Н. С. Хрущев АКШка барды һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасында (БМО) зур нотык сөйләде. Бу нотыгында ул кайнар дәрт белән колониализмны хөкем итте, СССРның азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшүче барлык илләрне һәм халыкларны яклавын, аларга шул көрәштә бөтен куәте белән булышуын һәм булышачагын, дөньяда тигезлек һәм гаделлек урнаштыруны изге эш санавын белдерде. Нәкъ менә шушы көннәрдә БМОда СССРда милли мөнәсәбәтләр һәм урыстан тыш милләтләрнең хәле турында бер белешмә-доклад таратыла. Гарәп, инглиз, француз телләрендә. Ул белешмәдә Н. С. Хрущев нотыгының икейөзлелек үрнәге булуы, СССРда азчылык милләтләрнең кызганыч хәлдә яшәве, РСФСРдан башка Союздаш республикаларның хокуклары кәгазьдә генә калуы, милли телләрнең һәм мәдәниятләрнең үсеше тоткарлануы, диннең кысылуы, милли республикаларның икътисадый яктан талануы, чимал чыганагы итеп кенә файдаланылуы, СССР һәм КПСС мәркәз җитәкчелегендә генә түгел, республикалар җитәкчелегендә дә урысларның төп һәм хәлиткеч урынны биләве конкрет һәм күп санлы дәлилләр белән исбатлана. Бу белешмәне бөтендөнья матбугаты күтәреп ала — төрле телләрдә басып чыгара. Җәмәгатьчелек Совет сәясәтенең әхлакый бозыклыгы, Н. С. Хрущевның Совет империализмы йогынтысын өченче дөнья илләренә җәяргә ашкынуы, аның ахыргы максаты Азия һәм Африка халыкларын да яңа коллыкка төшерү, аларны да үз мәнфәгатендә файдаланырга тырышу икәнлеге хакында шаулый. Бу белешмә, әлбәттә, Н. С. Хрущевның да, бүтән Совет җитәкчеләренең дә җенен чыгара. СССР Дәүләт иминлек комитетына (ДИК) пиндирәк күрсәтмә бирелүен чамалау кыен түгел. Белешмә-докладның ахырына аның авторы исеме һәм адресы акка кара белән басылган була: «Гариф Солтан. Советлар Берлеген өйрәнү институтының Нью-Йорк филиалы фәнни хезмәткәре, «Азатлык» радиосы хәбәрчесе».

Бу исем инде ДИК өчен яңалык булмый, чөнки Г. Солтан илленче елларда ук «Азатлык» радиосының татарча тапшыруларында актив катнаша, СССРның икътисадый, сәяси, мәдәни хәлен даими анализлап, тоталитар системаның гөнаһларын, гаделсезлекләрен даими фаш итеп тора. Эфирда гына түгел, төрле илләрдә һәм телләрдә басылган матбугатта да халыкара гыйльми корылтайларда да үз сүзен әйтә. «Төрки

халыкларның хәле» (Анкара), «Ислам һәм коммунизм» (Нью-Йорк) һ. б. дәрәҗәле симпозиум, конференцияләрдә аның докладларын халыкара атаклы галимнәр генә түгел, АКШ һ. б. илләрнең сенаторлары, конгрессменнары, парламент депутатлары, җәмәгать эшлеклеләре дә игътибар белән тыңлый.

АКШка баргач биргән бер интервьюсендә РСФСР президенты Б. Ельцин: «Марксизм тәгълиматы нигезендә коммунистик җәмгыять төзү тәҗрибәсенең СССР кебек бик зур илдә уздырылуы бәхетсезлек булды»,— дип белдергән иде.

Ә бит Н. С. Хрущев та, СССРның һәм КПССның аңа кадәрге һәм аннан соңгы җитәкчеләре дә «бәхетле коммунизм җәмгыятен» төзүне бөтен дөньяга, хосусан, Азия һәм Африка илләренә дә җәяргә, димәк ки, бәхетсезлекне тагын да киңрәк таратырга атлыктылар. Өченче дөнья илләренең бәйсезлек өчен көрәше СССР тышкы сәясәтенең әлеге мәмләкәтләргә үтеп керү һәм аларны үзенә буйсындыру омтылышын тагын да көчәйтте — Азиядән һәм Африкадан алдынгы капиталистик илләрне кысрыклап чыгару хыялын дөрләтте. Моңа ирешү өчен патша Русиясендәге артта калган колониаль халыкларның социализм төзү дәверендә матди, мәдәни, сәяси яктан алга китеп, чәчәк атып, иркле, бәхетле, тигез хокуклы милләтләргә әверелү әкиятен өзми-куймый тәкърарлый, шуны исбатлар һәм Азия-Африка халыкларына үрнәк итеп күрсәтер өчен, җитәкчеләрен чакырып китерә, аларны «күргәзмә» авылларга һәм шәһәрләргә алып барып сыйлый, шул илләргә әлеге «бәхетле Совет республикалары» вәкилләрен тәҗрибә уртаклашырга җибәрергә тотына...

Димәк, кешелеккә яңа бәхетсезлекләр киләсен Борис Ельциннан күпкә элегрәк аңлаган Г. Солтан үз алдына Совет империализмының мәкерле сәясәтен ачып бирүне максат итеп куя. Фикерләре һәм дәлилләре ни дәрәҗәдә объектив, гадел һәм дөрес икәнлеген белер өчен, аның «Мөселман-гарәп дөньясында Совет пропагандасының тышкы шәкелләре» («DERGI», 1956, № 7) мәкаләсеннән кайбер өзекләр китерик.

«Совет хөкүмәте мөселман дөньясында, аерым алганда, Урта һәм Якын Көнчыгышта сәяси һәм икътисадый йогынтысын көннән-көн арттыру өчен... рәсми дипломатик чаралардан башка, төрле пропаганда формаларын куллунудан да баш тартмый. Бу мәсьәләне тикшерү... мөселман милләтләргә карата Совет сәясәтенең икейөзлелеген ачып салачагы да игътибарга лаек. Чөнки Совет хөкүмәтенең Советлар Берлегендәге мөселман-төрки милләтләренә карата тормышка ашырган колониализм сәясәте белән гарәп дөньясында ясаган сәяси пропагандасы — капма-каршыдыр... Бәйсезлекләренә күптән түгел ирешкән гарәп һәм бүтән мөселман милләтләренең әхлакый йөзен, уйлау үзенчәлеген билгеләгән өч нигез бардыр ки, болар — исламчылык, милләтчелек һәм колониячелеккә дошманлык. Социализм белән капитализм арасындагы көрәштә «колония һәм ярым колонияләрдәге буржуа-милли азатлык хәрәкәтләрен»... киләчәк дәвердә үз файдасына хезмәт иттерергә теләгән коммунистларның тактикасына яраклы рәвештә, Совет хөкүмәте бу мәсьәләләрне үзенә бер пропаганда чарасы кылган... Исламчылыкны хуплавын Советлар Берлегендәге мөселман диния нәзарәтләре һәм мөфтиләр эшчәнлегенә юл кую мисалында, милләтчелеген һәм колонизаторларга дошманлыгын... Төркестандагы, Кавказдагы һәм Идел-Уралдагы союздаш һәм автономияле мөселман җөмһүриятләрен үстерү гамәлендә сурәтләп, үзен колонияләрдәге милләтләр тарафдары итеп күрсәтергә омтыла. Гүя, мөселман милләтләрен үз йогынтысына алырга тырышкан Көнбатыш капиталистларыннан аермалы буларак, Советлар үзләрендәге мөселман халыкларына хөррият һәм бәйсезлек биргән».

Шуннан соң автор Советлар Берлегендәге дин тоту ирегенең, мөселман халыклары, республикалары үсешенең чын хәле турында дәлилләр китерә. Баксаң, СССРда дин тоту ирегә түгел, дингә каршы үгет-нәсихәт тарату ирегә генә яши икән. Диния нәзарәтләре Совет хөкүмәте һәм Коммунистлар партиясе сәясәтен уздырырга мәҗбүр ителгән. СССР Конституциясе (124 матдә), Җинаятьләр кодексы (122—127 матдәләр) дин тотучылар ирегеп бууга хезмәт итә, имеш («DERGI», 88 бит). «Төркестан, Кавказ һәм Идел-Уралдагы төрки һәм мөселман җөмһүриятләре,— ди автор,— кәгазьдә генә мөстәкыйль дәүләт санала. Хакыйкатьтә исә бу җөмһүриятләр сәяси, икътисадый һәм мәдәни яктан Африка колонияләрендә иң артта калган милләтләр дә ия хокуклардан мәхрүм (Шунда ук. 93 бит)... Совет колониализмының икътисадый сәясәте Төркестан, Идел-Урал һәм Кавказны Русия икътисадының бер өлеше хәленә төшерү, аларны матди яктан мәркәзгә бәйләүдән гыйбарәт. Бу максатта Төркестан бары мамык игәргә мәҗбүр ителә, бөртекләләр мәсьәләсендә Русиянең мәркәз өлкәләренә баглана... Мамыгы исә үзәк өлкәләргә алып китеп эшкәртелә... Татарстан белән Башкортстан бөтен Советларда чыгарылган нефтьнең 62,1 процентын бирә, аның табышы исә тулаем мәркәз кесәсенә кереп бара (Шунда ук. 93 бит). Бер үк вакытта мөселман милләтләренең милли үзенчәлекләрен җую эше дә алып барыла. Моның өчен алар ватаннарыннан читкә таратыла, мәсәлән, татарлар һәм башкортлар Көнчыгыш Себердәге сәнгать мәркәзләренә җибәрелә. Мөселман җөмһүриятләренә исә урыс һәм украиннар күчереп китерелә. 1956 елның башына кадәр, мәсәлән, Казагыстанга һәм бүтән җөмһүриятләргә 400 мең урыс һәм украин җибәрелде (94 бит)... Совет колониализмы ялгыз икътисадый һәм сәяси басымнан, көчләүдән генә гыйбарәт түгелдер. Ул колониализм идарәсе астындагы милләтләрнең тел, дин вә мәдәният мәсьәләләренә дә тыкшына» (95 бит) — ди автор һәм моңа мисал итеп 1956 елда Ташкентта төрки республикаара бер конференция уздырылуын һәм анда төрки халыкларга урыс телен «икенче ана теле» рәвешендә укыту тәкъдим ителүен китерә. «Моннан Мәскәүнең мөселман милләтләрен тиз генә урыслаштыру сәясәтен тормышка ашыруы ачык бер сурәттә аңлашыладыр (96 бит)... Совет хөкүмәте мөселман милләтләрен әдәбият, сәнгать һәм тарихларына тыкшынудан да баш тартмый. Тупас бозу һәм фальсификацияләүгә дә барган Совет хөкүмәтенең бу өлкәдәге сәясәтен бөртекләп өйрәнсәк, Совет колониализмының милләтләр өчен нинди дәһшәтле бер хәвеф тәшкил итүен аңларбыз» (96 б).

Автор мәкаләсен мондый нәтиҗә белән тәмамлый:

«Һәрбер динне, җөмләдән, ислам динен дә инкарь иткән хәлдә, Совет хөкүмәте тышкы сәясәтендә бу диннән файда күрмәкче. Хәлбуки, эчке пропагандасында бу хөкүмәт дингә дошманлыгын һичбер заман яшерми. Ленин үз әсәрләрендә коммунизм фәлсәфәсен тәшкил иткән диалектик материализмның асылында динсезлек гыйлеме булуын, аның бөтен диннәргә дошман булуын ап-ачык яза. Бу караш КПСС программасында да бик анык урын ала... Совет хөкүмәте тышкы пропагандасында үзен милләтләрнең бәйсезлеге тарафдары итеп күрсәтә. Хәлбуки, икътисады һәм сәясәте нык бер мәркәзчелек принцибына таянган коммунистик идеология милләтләрнең үзбилгеләнүенә принципта дошмандыр. Совет хөкүмәтенең үз кулы астына алган төрки-мөселман мәмләкәтләрендә колониаль сәясәт алып баруын күп мисалларда күрдек. Төркестан, Идел-Урал, Кавказ һәм Кырымның КПССның тактика һәм стратегиясеннән туган сәясәтенең әүвәлге корбаннары булулары мәгълүм» (96 б).

Гариф Солтан хезмәтләрен уку бүген инде безне шаккатырмый. Ул әйткән фикерләр, ул китергән дәлилләр яки шуңа охшаш мәгълүматлар, карашлар татар матбугатында хәзер бик еш дөнья күрә килә. Ләкин аның мәкаләләре тоталитар режимның иң куәтле дәверендә, марксизм — изге,

КПСС житәкчеләренең һәр сүзе — закон саналган заманда язылган. Бөтен «изге» нәрсәләргә кусәк күтәргән кешегә, бигрәк тә, әсирлеккә эләккән бәндәгә совет идеологиясе сакчылары, аларның тугрылыклы хезмәтчесе ДИК нинди чара күрергә тиеш иде? Кул сузымы җирдә булса, аны төрмәгә илтеп тыгар, сөргенгә сөрер, ким дигәндә, диванаханәгә ябып куяр иде. Гариф Солтан исә, АКШ гражданлыгына кучеп, Алманиядә һәм океан артында яшәде. Шуңа күрә, ул эфирга чыккан радиодулкынны бастыру, аның әсәрләре нәшер ителгән басмаларны СССРга якын да җибәрмәү белән чикләнергә туры килде. Шөкер, ватандашларыбызны әнә шулай «явыз дошман» тәэсиреннән ышанычлы рәвештә саклый алдык. Ләкин ул «мөртәт» чит мәмләкәтләргә «акыл сатуын», Совет чынбарлыгына «яла ягып», иң гадел һәм хак тәгълиматны «каралтып» күрсәтеп, болай да «капитал изүеннән җәфа чиккән» меңнәргә һәм миллионнарга шик-шөбһә орлыклары чәчүен дәвам итте. Без моңа һич тә битараф карап тора алмый идек. Шунлыктан, «иленә хыянәт иткән» дигән гаебе өстенә «Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен саткан» дигән гаепне дә куштык! Җирәнеп карасын аңа дөнья!!

Шуны да искәртәсе килә: Мюнхендә мин танышкан әсир-мөһаҗирләрнең барысы да — милли аңлы һәм милли хисле җаннар. Әгәр без намуслы һәм йөрәкле кешеләр икән, бүгенге хәбәрдарлык шартларында кайчандыр уйларга да җөрьәт итмәгән кайбер фикерләребезне, шул исәптән, әсир төшкән татарларның «сатылу» мәсьәләсенә кагылганнарын да мәйданга чыгарырга тиеш.

Татар Рәсәйнең дә, СССРның да икенче сортлы милләте иде. Урыс халкы Октябрь революциясеннән соң да татарны тиңсенмәде, димәк, аны изүен дәвам итте. Сугыш башлангач, изүче белән изелүче, кулларына корал тотып, нимес яуларына каршы сугышка китте, әмма алар икесе дә гел бер уйда, гел бер теләктә, бер үк хәвеф астында иде, дип расларга мөмкинме соң? Юк, әлбәттә! Нимес җиңсә, урыс үзе җиңелүчегә әйләнәчәк, аның хәле тамырдан үзгәрәчәк, татарның хәле исә элеккечә үк калачак — ул бер изүчене икенчегә генә алмаштырачак иде. Аңа ирекле булу өчен һәр икесенә каршы сугышырга кирәк, ләкин ул аларның аерым алып берсен генә дә җиңәрлек түгел иде. Иң акыллысы — аңа ике арыслан сугышыннан исән-имин читтә калу иде, ләкин татарны сугышучы якларның берсе Совет Гаскәренә, икенчесе — нимес легионына ирексезләп кертеп, үз максатларына хезмәт иттерүдә, «туп ите» рәвешендә файдалануда булды. Бу гаҗәп тә түгел, җиңгән милләт борын-борыннан җиңелүчене, уртак мәнфәгатьләрне саклау өчен, дигән булып, яңа дошманга каршы сугышның иң хәтәр җиренә илтеп тыга һәм, үзенчә, икеләтә ота: иске һәм яңа «дошманын» үзара сугыштырып, аларны бер-берсеннән кырдыра! Мондый очракта азчылык милләт вәкилләренең арысланнарның берсеннән дә яхшылык көтмәве, тегесенә дә, бусына да хезмәт итәргә теләмәве, үз жанын сакларга омтылып, коточкыч упкын эчендә бәргәләнүе ачык лабаса. Алармы сатлык? Кайберәүләрнең нимесләргә әсир төшүне үз халкына, үз милли дәүләтенә хыянәт санамауларын аңларга бик була, минемчә. Моны колонизаторларның, империя тарафдарларының һәм аларның ирекле яки ирексез куштаннарының гына танымавы табигый. Чөнки алар инде ничә гасыр элек үк татарны Рәсәй дигән гөл үссен һәм чәчәк атсын өчен яралган туфрак итеп кенә санарга гадәтләнгән.

Эш монда берничә дистә «мөртәтне» акларга маташуда түгел, принципта. Әгәр милләт тере икән, үз йөзен саклап яшәргә тели икән, аның үзенә генә хас гореф-гадәтләре, әхлакый төшенчәләре, кануннары, икътисадый, мәдәни, сәяси программалары да була. Ул телдә, фикердә, гамәлдә бүтәннәргә тагылмый, ятлар җырын җырламый, үзбаш юл ярып бара. Упкын эченә илтеп ташланган уллары-кызлары язмышына да ят йогынтылардан, диктатлардан азат үз карашын булдыра. Татарның шунсыз яңадан ирекле, мөстәкыйль милләткә әверелүе мөмкин түгел.

Тормышта бөтенләй башка сыймаслык очрашулар да булгалый икән. Кичләрнең берсендә Хәйретдин Көләчйөз:

— Сезнең белән бер күршебез танышырга тели. Укымышлы үзбәк егете, ул да бөтен төрки халыклар белән кызыксына, телләрен өйрәнә,— диде.

Үзбәгстанга кагылышлы ике китап язып да ничек инде мөһаҗир үзбәк егете белән күрешүдән баш тартыйм ди? Бәлки аның ата-баба җире хакында сорашасы киләдер, ә мин Ташкент, Сәмәрканд, Бохараларны барып күргән кеше, кардәш халык арасында күпме дусларым, танышларым бар.

Бераздан күрше егете килеп тә керде. Ялгызы гына түгел, хатыны, ике нәни баласын да ияртkән. Түм-түгәрәк йөзле, кара кашлы, елмайганда ияге чокырлана торган сөйкемле бер ир икән.

— Тимер Хуҗа,— дип таныштырды ул үзен.— Илдән килгән кардәшемезне күрүемә җөдә шатмын, тәкъсир. Хәлләрегез яхшымы? Юллар арытмадымы? Хәйретдин бәй сезнең хакта «Төркестанны да яхшы беләде» дигәч, шатландык әле мәнә, без — илдән илгә күчеп йөреп, читтә үскән мөһаҗирләр, тәкъсир.

Татарчалап сөйли ләбаса бу. Үзбәкчәсенә төрек аһәңнәре хас икән. Ә хатынының теле үзбәкчәрәк кебек. Озынчарак йөзле, аксыл чырайлы, тыйнак холыклы, әмма бик теләп аралаша. Бу өйдә аларның үз кеше икәнлеге күренеп тора: балалары, чишенеп ташлагач ук, Хәйретдин чирүе белән уенга кереп онытылды, без озак «гәперешеп» утырганлыктан алар берзаман кочаклашып йоклап та киткәннәр иде инде.

Тимер әфәнде төскә яшь күренсә дә, инде бормалы тормыш юлларын хәтсез кичеп өлгергән икән. Төркиядә туып-үскән, урта белем алган. Атасы Пакыстанда илчелектә эшләгәндә, шунда күчеп барып, урду телен өйрәнгән. АКШка күчеп барганнан соң инглиз телендә университет тәмамлаган. Алманиягә килүенә инде ун ел тулган, шул арада Тимер нимес телен үзләштергән һәм кандидатлык диссертациясен язган. Әкияттәге кебек, билләһи!

— Мин төрки телләрнең чагыштырма сүзлеген төзи башладым, аның аерым өлешләрен бастырдым да инде,— диде ул.— Төрки халыкларны берләштерер өчен телләрен үзара якынайтырга кирәк. Гаспралы әйткәнчә, «телдә, фикердә, эштә берлек» булсын. Безне ят халыкларга йотылудан шул гына коткарачак.

— «Елан угы» романымның бер каһарманы да гел шушы сүзләрне кабатлый,— дидем мин.— Төрки халыкларның көчен берләштереп, Бохара җөмһүрияте бәйсезлеген сакларга комарлана.

— Ничәнче елда?

— Романда 1920 ел вакыйгалары сурәтләнә.

— Анда Госманхуҗа Булатхуҗаев телгә алынамы соң?

— Ничек кенә әле! — дидем.— Бохара бәйсезлеге өчен көрәштә юлбашчы булган миллионер-сәүдәгәрне, кодрәтле министрны әйләнеп узып китеп буламыни инде? Юк, ярамый иде.

— Госманхуҗа Булатхуҗаев минем дәдәм!

Колакларыма ышанмыйча, Тимергә карап катып калдым. «Елан угы»нда гәүдәләндерелгән каһарманнарның яки аларның прототипларының күбесе давыллы егерменче, шомлы утызынчы елларда һәлак булган, дип уйлый идем мин. Сиксәненче елларда очраткан Җәлил Байбулатов — романымда тасвирлаган Бохара вакыйгаларының мин күрергә өлгергән бердәнбер тере вәкилен соңгы могикан дип исәпли идем. Әсәрне язганда тарих китаплары, саргаеп беткән архив документлары гына ярдәм итте. Госманхуҗа Булатхуҗаев исә унтугызынчы йөзнең өченче чирегендә туган, ничек инде гел елмаеп торган бу яшь-яшь ир-егет аның улы була алсын икән?!

Минем ни өчен тынып калуымны төшенепме, Тимер:

— Мин туганда әтиемә йитмеш ике тулган икән,— диде.

1923 елны Бохара җөмһүрияте хөкүмәтендәге гаять дәрәҗәле вазифасын — хәрби назыйрлыгын ташлап, 700 кешесе белән басмачыларга, Әнвәр пашага кушылган Госманхуҗа сәүдәгәрнең соңгы язмышы миңа билгеле түгел, әсәремдәге вакыйгалар 1920 ел белән чикләнә иде.

— Әтием 1923 елда милли азатлык өчен көрәшүче бохаралыларга корал эзләп Әфганстанга киткән,— диде Тимер.— Әмма инглизләр булышырга теләмәгән, ул арада урыс илбасарлары һөҗүм иткән, бер кайнар бәрелештә Бохара гаскәре баш әмерчесе Әнвәр паша һәлак булган. Большевиклар әтиемне читтән торып үлем җәзасына хөкем иткән. Шуңа күрә аның Бохарада калган тарафдарлары аңа әлегә ватанына кайтмый торырга киңәш иткән. Ул Төркиягә юнәлергә мәҗбүр булыпты.

Икенче кичне Тимер мине үзләренә алып чыкты, бай китапханәсе, атасының фотосүрәтләре белән таныштырды. Чынлап та, барлык төрки халыкларның кулга төшерә алган сүзлекләрен, галимнәребезнең хезмәтләрен зур көч куеп җыйган икән Тимер. Инглиз, немес, урду, фарсы, төрек, үзбәк телләрен белүе генә җитмәгән, татарча да иркен укырга һәм язарга өйрәнгән, укыганын ансат төшенә. Аның киштәләрендә дистәләрчә халыкның басма сүз үрнәкләре тезелеп тора. Тик бүген ул бу китапларны тәмам онытты, Казанда яшәгән татар язучысының үзбәк әдәбиятын яратып укуы, китапларында Төркестанны гәүдәләндерүе аңа шифалы бәлзәм кебек тәэсир итте.

Төрки телләрнең Радлов, Будагов кебек күренекле галимнәр төзегән чагыштырма сүзлекләрен беләбез. Соңгы дәвердә бу авыр эшкә Мәскәүдә яшәгән милләттәшебез, күренекле тел галиме, әдәбиятчы, фән докторы Әмир Нәҗип тә алынып карады. Эшен нигездә тәмамласа да, вакытында нәшир таба алмаганлыктан, аның күп томлы сүзлеге басылып бетми, картотека, кульязма хәлендә торып калды. Тимер Хуҗа хезмәте һәвәскәрлектән профессиональ югарылыкка күтәрелерме, кайчан да булса китап хәлендә оешырмы? Уңай җавап бирү әлегә мөмкин түгел. Шулай да немес теле диңгезе Мюнхендә яшәгән бер мөһаҗир егетнең төп эшеннән калган вакытын шундый мәгънәле шөгыльгә бирүе сөендерә.

Алманиядә мин казакъ, уйгыр, төрекмән, кыргыз егетләре белән дә очраштым, әмма Ной Үлмдә яшәүче карачай карты Оштана Көчерек бигрәк тә хәтердә калды. Язмышы белән әллә ничек бәгырьне сызлатты ул.

Оштана абзый Карачай автономияле өлкәсенең Өчколан район үзәгендә туган, таза, матур булып үскән, яшьли төрле яктан сәләтен ачкан — моңлы тавышы белән җырлаган, оста көрәшкән, шуңа күрә аны унбиш яше тулганда ук Карачай җыр-бию ансамбленә эшкә алганнар. Җырчы һәм көрәшче итеп. Алты ел буе гастрольләрдә йөргән. 1938 елда солдатка алынган. Фин-Совет сугышын исән-имин кичкән, Балтыйк буен һәм Көнбатыш Украинаны СССРга «кушу»да катнашкан, каһарманлыгы өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән. 1941 елның декабрендә Сумск тирәсендә барган сугышларда яраланып, немесләр кулына эләккән. Концлагерь михнәтләрен, Алманиядә торып калу хурлыкларын кичергән Оштана сугыш тәмамлангач, илгә кайтырга теләмәгән, чөнки бу вакытта инде туган халкы ватаныннан сөрелгән. Әти-әнисе шул фаҗигаләр эчендә ачлыктан кырылган, абыйсы исә, «бәхет илен» саклап, сугышта элегрәк һәлак булган.

Без аның белән Ной Үлмнең аулак урамнары буйлап әллә ничә мәртәбә сәйран чигеп йөрдек. Шулчак Оштана абзыйдан:

— Туган җир сагындырмыймы? — дип сорадым.— Күршегез Минһаҗ абзый әнә кайтып-килеп йөри. Ленин ордены кавалерына да юл ачыктыр.

Ул күңелсез генә:

— Йөрәк бозар өчен кайтыйммы? — диде.— Бертуганнарым юк, якын кешеләремнең каберләре кайда икәнлеген дә белә алмаячакмын мин анда. Консуллык аркылы бервакыт җиңгәм эзләтеп тапкан иде. Ятимлектә, фәкыйрьлектә җәфалангач, бер таянычым була алмасмы, дип өметләнгәндер инде, бәлки. Ә минем канатларым каерылган, тәнемдә генә түгел,

йөрәгемдә дә яра өстенә яра иде. Хәер, кайтсам, тотып алып йә сөргенгә олактырырлар, йә төрмәгә үк тыгып черетерләр, дип хәвефләнгәнгә дә, җингигә җавап бирергә кыймадым. НКВДның ниндидер «сатлык» карачайны чебен урынына да күрмәве бик ачык иде ләбаса.

— Хәзер берәүгә дә тимиләр.

— Әмма безнең дә гомерләр узган, туннар тузган шул инде хәзер. Тере мәсткә әйләнеп беттек. Илдә бай Көнбатыштан мул күчтәнәчләр белән кайтучыларны көтәләр, ә минем пенсиям үземнән артмый — дарулар сатып алырга, дәваланырга китеп бетә.

— Безнең Татарстанга, Казанга кайтыгыз,— дидем мин.— Күчтәнәч өмет итмибез, кардәш халык яшәгән республиканың һавасы, ризыгы яраларыгызга им булмасмы. Тиздән Минһаҗ абзый да кайтып китсә, әсирлектәге иптәшләрегездән ике шәһәргә бер ялгызыгыз каласыз ич. Туган телегездә сөйләшергә бер җан иясе дә таба алмассыз.

— Шулай шул,— дип авыр сулады Оштана карт.— Төрекләр күп килде килүен, тик алар башка икән. Малкуарлар. Без — татар, комык, карачай — бөтенләй бер кавем икән. Серебез килә.

Минһаҗ абзый сөйләве буенча, Оштана концлагерьдан котылып, ирекле яши башлаганда әле күрекле ир булган, тол алман хатын-кызлары бик ошаткан үзен. Әмма ул аларның берсенә дә өйләнмәгән, гыйшык уенына да исе китмәгән. Фатирына ни телевизор- радио, ни юньле мебель алып куймаган, имеш. Ризыгының да юне-коты юк, коры-сары белән туклана икән. Хәзер эчке авырулардан җәфалана, көн дә шифаханәгә бара. Укуга да һәвәс түгел, урыс хәрефен гомумән танымый, нимесчеке белән дә кызыксынмый, рухы концлагерьда тәмам сынганмы? Халкының ватаныннан сөрелүен, ата-анасының, кардәшләренең, дус-ишләренең фронттан еракта, тынычта кырылып бетүен ишеткәч, дөньяга күңеле суынганмы? Ни бәхет күргән соң ул бу дөньяда?

Икәүләп аулак урамнар буйлап йөргәндә мин аның каткан күңелен йомшатырга тырыштым. Башны югары, рухны нык тотарга тиешлегебезне искәрттем. Фикеремә каршы төшмәде, әмма кабынып, дәртләнеп тә китмәде. Җырчы, көрәшче Оштана түгел, аның бары тышкы кабыгы, күләгәсе иде бу. Минем кайчан китәсемне белгәч:

— Үзем озатышып куярмын, таксига да үзем түләрмен,— дип кисәтеп куйды.

Вәгъдәсендә торды, бер сәгать алдан килеп керде дә куеныннан свитер тартып чыгарды.

— Бу кием — сиңа бүләгем, чемоданыңа тыгып куй!

— Рәхмәт, әмма мин аны ала алмыйм,— дидем мин катгый тестә.

— Әллә син, энем, авыруымнан шикләнәсеңме?— диде Оштана абзый үпкәләгән тестә.— Өр-яңа, берәү дә кимәгән кием бу. Илдә язучы кеше ялангач йөрмидер, беләм. Шулай да ал әле син бүләгемне. Минем гомер күп калмады ич инде, бер кардәшлек истәлегем булсын, карышма!

Үлм шәһәре вокзалында мине ике карт — сиксәнне тутырган Минһаҗ Исмәгыйли белән җитмештән узган карачай Оштана Көчерек озатып калды. Язмыш шушы шәһәргә, Альп таулары итәгенә китереп аткан әсир солдатларның соңгы ике могиканы. Минһаҗ абзый ябыккан, көчләрәк җил чыкса, авып китәр сыман тотрыксыз басып тора. Аның янындагы Оштана әле гәүдәгә нык күренә. Озын буйлы, карап торырга ярыйсы ук таза. Ләкин бу тыштан караганда гына шулай. Эчтән исә ул Минһаҗ абзыйдан да чирлерәк.

Сугыш тәмамлаганда төрки халык вәкилләре — казакъ, кыргыз, үзбәк, әзербайҗан һәм бүтәннәр күп җыйналган монда. Урамнарда үзенчәлекле телләре гел яңгырап торган. Әмма вакыт аларны рәхимсез җилгәргән, кайсын кая чәчкән дә сипкән. Бер ишесе, алман халкына донор булып, шушында картайган һәм берәм-берәм якты дөнья белән саубуллашкан. Варис булырга тиешле үрчем — катнаш никахтан дөньяга килгән балалар алманнарга сеңеп беткән.

Көнбатыш Европада — яз. Дунайның югары агымында, Альп таулары итәгендә дә — кояшлы җылы һава. Табигать яшәрә, гөлләр чәчәк ата, Үлм тимер юл вокзалы тирәсендәге скверда очына-очына кошлар сайрый. Син дә мәшәкатьләреңне оныт, күңелсез уйларыңны башыңнан чыгар, тирә-ягыңа сокланып һәм елмаеп кара, татар баласы! Сәяхәттә күпме яңа җирләр, яңа кешеләр күрдең, тәмле-татлы ризыклар авыз иттең, яңа җырлар ишеттең. Син — бәхетле җан!

Сәгать дөресләрлек төгәллек белән әнә инде мине Һанновер шәһәренә алып китәчәк «Мюнхен-Киль» поезды перронга якынлаша. Һанноверда мине ватаныма алып кайтачак «Кельн-Мәскәү» поезды көтә. Бар да әйбәт, чырай сытарга һичбер сәбәп юк. Ә шулай да моңсу. Мин инде озатучыларыма күз салырга да куркам — хисләрем тышка түгелер сыман.

Вакыт җиле тиздән бу ике картны да башка дөньяга күчерер. Дунай елгасы гына аерып торган, чынлыкта бер шәһәргә әйләнгән Үлм белән Ной Үлмдә татар-карачай телләре, бүтән төрки шивәләр кебек, мәңгегә тынып калыр, аларның кайчандыр монда яңгыравы да онытылыр, чөнки һәр тел, һәр халык ватанында гына тотырыклы яши ала. Әгәр берегеп гомер итүнең кадерен белсәләр, көрәшче рухын сакласалар!

* * *

Үлм — бөек астрофизик Альберт Эйнштейнның туган шәһәре. Хәзер галимнең исеме шушы каланың гына түгел, бөтен Германиянең горурлыгы. Ләкин тарих әле кайчан гына аны күрше шәһәрләрдә дә танымауларын хәтерли.

Бервакыт Аугсбург каласында: «Лекция укырга Үлмнән Эйнштейн килә икән», — дигән хәбәр таралган. Галимлеге чамалы Курт әфәнде укымышлырак күршесе Фриц әфәндедән:

— Кем соң ул? — дип сорый икән.

— Ничек аңлатырга икән аны сиңа? — дип аптыраган Фриц.— Чагыштырмалылык теориясен уйлап чыгаручы кеше ул.

— Анысы нәрсә инде тагын?

— Менә син әйт әле,— дигән Фриц.— Йөзлек кыйммәтле акчамы, арзанлымы?

— Әгәр син миңа бирәсе булсаң — арзанлы, әгәр мин сиңа бирәсе булсам — кыйммәтле.

— Биш бөртек чәч күпме, әзме? — дип сораган тагын Фриц.

— Әгәр башта үссә — әз, әгәр ашка төшсә — күп,— дигән Курт.

— Ярты сәгать озак вакытмы, кыскамы? — дип янә сораган Фриц.

— Әгәр мин синең хатыныңны сөяргә барсам — кыска, әгәр син минем хатынымны сөяргә килсәң — бик озак! — дигән Курт.

— Менә шушы төшенчәләрдән чагыштырмалылык теориясе килеп чыга да инде,— дигән укымышлы Фриц.

— Ул нәрсә, шундый сафсата сатып, бездә акча сугарга өметләнәме әллә? — дип ачуланган Курт. — Шарлатан!

Бу язмаларны да кем — озын, кем — кыска, кем — әз, кем — күп, кем — кызык һәм мәгънәле, кем сафсата гына дип санарга мөмкин. Ничек кенә бәяләнмәсен, мин Көнбатыш Германиянең бер төбәген, татарның алман иленә килеп эләккән һәм әле дә шунда яшәп ятучы бер өлешен күрдем, аларның язмышын, бүгенге хәлләрен үзем танып-белгәнчә, тойганча шушы сәяхәтнамәмдә чагылдырырга тырыштым. Язу — миннән, хөкем — укучыдан.

Дөнья чуар, дөнья катлаулы, дөнья бниһая киң — шул киңлекләрне иңләтеп йөртә безне язмышлар.

1990—1991.
Ной Үлм-Мюнхен-Казан.

## Әхмәт Гадел

### Татар зираты. Нури Арслан кабере

Көн бик сүрән бүген. Кояш та юк.
Думбра моңы ишетелә алыстан...
Шигърияттән арысланнар китә.
Көтү-көтү килә шакал,
барслар...
Менә шулай!
Әйдә, тыныч йокла,
Илне рәнжетмәдең, Арыслан!
Тыныч йокла!..
Кичер, туган!
Әлвидагка, ерак идем, кайта алмадым.
«Бәхил!» дигән сүзеңне ишетә алмадым,
Кабереңне генә кочам.
Кичер, шагыйрь...

Калай аңыт[1] кына моңсу,
язулары уңган...
Кая соң ул «варислар»ың синең?
Алар белән иде ич дөнья тулган!..
Көн бик сүрән...
Инде бер ел бүген,
тулы бер ел...
Син юк арабызда!
Ялкын булып төштең дә күнелләргә,
Китеп бардың, яра өстәп булган ярабызга!
Их, Арыслан!

### Дидактик дәрес

*Улыма*

Кеше булса — башы бар,
Башы барның ашы бар,
Ашы барның гаме бар,
Гаме барның яме бар.

---

Әхмәт ГАДЕЛ (1942) — *шагыйрь, кырымтатар һәм татар телләрендә дөнья күргән «Чам», «Көмеш кылган җырлары» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

[1] Аңыт — истәлек таш, искә төшерүче.

Яме барның җаны бар,
Җаны барның аңы бар.

Аңа барның саны бар,
Саны барның шаны бар...

Бу нәсихәт җитми дисәң,
Бездә, улым, тагын бар.

* * *

Биек күктән безгә җитәр:
Күз нурының сәламе:
Галәмнәргә ашыйк икәү,
Кочыйк чиксез галәмне.

Канатлардай каерылмыйк,
Тыйыйк яман хисләрне.
Аерылмыйк, аерылмыйк;
Саклыйк газиз ишләрне.

Дәрьяларга ташлан, дисәң,
Ташланам, сулар кочар.
Упкыннардан калып исән,
Җаным тик сиңа очар!

Ялгыз калу, аерымлык —
Явыз дошман башына!
Аерылмыйк, аерылмыйк
Хак тәгалә хакына!

## Дәрт

Дәртемә дәрман булырлык,
Дөнья, синдә бер зат бармы?
Янгынымны сүндерерлек
сулы чоңгылың, әйт, бармы?

Язны алып килгән кошлар
төннәрен сайрап туярмы?
Җирне төрле төскә манып,
рәссам-Кояш гел чыгармы?

Күк һәм җирнең кодрәтләре
рухка канат бирә алырмы?
Туган-үскән уймакларны[1]
бу күзләрем күрә алырмы?

Күңел таша. Әллә шашам?!
Җырлар булып оча зарым.

[1] Уймак — аймак, төбәкнең кечесе.

Шатлык булып, моңнар аша,
килерсеңме, назлы ярым?!

## Эшханәм

Бу — минем куышкаемдыр,
бу — минем мәгарәм.
Ихлас, ризамын биредә
үлсәм дә тәгәрәп.
Бар өметем тик каләмдә,
минс шул яшәтә.
Төшенчә-уйларым аша
күңелемне яшәртә.
Мин монда савыгып китәм,
онытыла хастам.
Мин күктәге бөркет сыман —
ә бар дөнья аста!
Телим икән болыт ярам,
кыяларны сыйпыйм.
Телим икән шигырь язам,
телим — дога укыйм!
Мин үзем кол, үзем — сәхиб,
хуҗа түгел беркем.
Чыгып булмас читлегем бу
һәм... бердәнбер иркем!

## Фәрит Яхин

### Коръәнгә таяну

Дөнья гаме йөрәкләрне утка салса,
Бәгырь канын дөрләп-дөрләп ялкын алса,
Шагыйрьләрнең алларында кояш батса,
Кара төннең шәме булып аем калка.

Хәсрәт күле ярларыннан ташып чыкса,
Ермак табып, гөлдер-гөлдер чишмә акса,
Инеш булып, елга тулып, мохит тапса,
Җаннарыма терәк өчен аем калка.

Килеп киткән дәлиленә җавап тапсам,
Күңел шәмен кара төндә һаман яксам,
Рәхмәтеннән — өлеш бирер, җанга — хак сан:
Мөэмин булсаң, хәсрәтеңә — Коръән калкан.

### Болыт, Болын, Кояш

Күк салынды өстенә якты көннең,
Болыт көтте Микаилның бер өнен...

Егылдылар — кемнәр саткан хак денен...
Кыз эзләде егеттә күркәм тиңен.

Җәймә җәеп, болын көтте: «Кил, җанаш!»
Йөрәкләрдә пеште кайнап чын дәрт-аш...

Бу көн минем иелде күк торур баш,
Бәгыремә төшеп басты авыр таш.

Болын тапты кояшны үз йөзеннән,
Тамчы төште болытның мең күзеннән.

Ышык эзлим җанашымның сүзеннән,
Чәчәк-чәчәк болын өсте, бүз үлән...

Күк ачылды, бәхетеңә пәрдә суз!
Эз калмады, энәдән югалды күз...

### Оят

Килер көннең канатлары сынды,
Бәгырь канатлары сынмасын!
Бер гомердә ике хакыйкать бит
Чәкештеләр килеп сынга сын.

---

Фәрит ЯХИН (1960) — *галим, филология фәннәре кандидаты. Шигырьләре көндәлек матбугатта, күмәк җыентыкларда күренә килә. Казанда яши.*

Кызылланып-яшелләнеп, яшьнәп,
Безнең уттан еллар янмасын,
Ирләр кирәк — заманага терәк,—
Мәйданнарга салган җан, башын...

Денне сатып алган малың бармы,
Бөтен байлык — ике хакыйкать:
Фанилыкның хыялыннан кайтып,
Бакыйлыкта килер мең оят.

## Юксыну

Күңел юксынган чагында
Болында йөрдем, кырда:
Кошлар зар-хәбәр салганда
Мин сине таптым җырда...

Чәчәктән күчеп чәчәккә —
Чыландым күз яшенә;
Ник болай, читләрдә йөртеп,
Язмыш синнән яшерә?

Тиргәп битараф елларны,
Юлларны алга дәштем...
Шулкадәр сөйгән өченме
Бу кадәр моңга төштем?

Сине юксынган чагымда
Сагышның үзен кочтым;
Эзләсәң, табарсың, бәгырь:
Мин инде җырга күчтем.

## Гарифҗан Мөхәммәтшин

### Таңнар, каеннар

* * *

Таңнарның бар яктысы,
Яшьлек кебек татлысы,
Гөлләр кебек затлысы —
Бергә үткән таңнар ул.

Таңнарның бар моңлысы,
Кара төндәй шомлысы,
Кыллар кебек зыңлысы —
Ялгыз иткән таңнар ул.

* * *

Рәсәй бит ул,
«Бөек» бит ул,
«Бердәм» бит ул,
«Бүленмәс»;
Өс ялангач,
Тамаклар ач, —
Бөек булгач
Беленмәс!

* * *

Бизәкләренең күплеге,
Төсләрнең назлылыгы —
Әйтерсең лә бу болыннар
Әбкәмнең намазлыгы!

* * *

Мин көзләр күк сабыр булдым,
Син — язлар күк дуамал,
Мондый чакта көчсез икән
Иң әчкерсез догалар.

Көзләрне яздан аерган
Җәйләр әле узмаган,
Җәйге чәчәкләр күк керсез
Вәгъдәләр бар — бозмаган...

---

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941) — *шагыйрь, «Килегез, дусларым», «Уеннан уймак» исемле китаплар авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Балтачта яши.*

* * *

Үткәндә язмыш җилләре,
Өшетеп, үзәгенә —
Һәркем дә белә торгандыр
Үз хәлен үзе генә.

Сагышларымда буылып
Шатлыклар көтеп яшим...
Кабат болытлар кабара,
Кабат камчылый яшен.

* * *

Яшәдек бер канун белән:
Бозылмасын ранжир, диеп,
Уйламадык, борчылмадык
Тукта, кемдер рәнҗер, диеп.

* * *

Капчыкта саклармын, димә —
Без ул,
Таш капчыкны да җимердек —
Без ул!

* * *

Язлар кабатлана, дисең,
Кабатланмый икән шул,
Унсигездәге күк, йөрәк
Яфрак ярмый икән шул.

Күзләр кабатланмый, дисең,
Кабатлана торгандыр,
Сары каеннар күк, йөрәк
Утсыз яна торгандыр.

* * *

Чәчәк бүләк иттем сиңа
Мин ул көнне — бер болын!
Шул чәчәкләр арасында
Буталды ике толым.

Буталды ике толым —
Берсе синең гомер юлың,
Берсе минем гомер юлым...

Тыңлап торам бер ялгызым
Хатирәләр булып кайткан
Күктәге август зыңын.

* * *

Кабат үтәм шушы юллардан мин
Дөнья куып арыгач, җир урап,
Бу җирләрнең тузаны да башка —
Йомшаграк, якын, җылырак.

Үрләренә генә бак син аның —
Пар артышлар чыккан «биләмгә».
Ятып ауныйм яшел чирәменә —
Җирдә тиңсез яшел келәмгә.

Иртән чыккан бәллүр кояшсыман
Көлеп тора һәрбер тузганак,
Тузганагы хәтта якын аның —
Тузганаксыз нинди туган як!

Туган якның якты хатирәсе
Гомер буе җанны тартадыр,
Кайда гына гомер кичерсәң дә
Юлың барыбер шунда кайтадыр...

* * *

Беләм, аңлыйм: сиңа авыр,
Миңа да җиңел димә,
Җаным тоташ давыл, димә,
Минеке дә шул тирә.

Ике давыл — бер зилзилә,
Ике йөрәк — бер җилкән,
Җилкәннәр җилдә сынала —
Сынатмыйбызмы икән?!

## 1992 — Маймыл елын каршылаганда әйтелгән тост

Кил син безгә, кил син, Маймыл елы,
Төкле булсын, туган, аягың,
Сиңа кадәр килгән маймылларга
Охшап тора әле бар ягың.
Маймылларга бездә кытлык бүген,
Җитми бездә, туган, лидерлар.
Ничек җитсен, Рәсәй түгел сиңа
Люксембург яки Нидерланд.
Йә демократ, йә либерал булып
Биек мөнбәрләргә басарсың,
Биш йөз көннән, йә киләсе көзгә
Безгә коммунизм ясарсың.
Маймыл елы гына түгел, туган,
Килде безгә маймыл заманы,
Маймылларга хәзер мөмкинлек зур —
Үлчәп торасы юк чаманы.
Җимерерсең, таркатырсың барын,

Аннан килеп кабат җыйнарсың,
Кардәшләрен җыеп ГКЧП,
Яки ЧП ясап уйнарсың.
Ә кешеләр сокланырлар сиңа,
Кул чабарлар сиңа шау килеп,
Туктаталмас ачлык, ялангачлык
Маймылизация шаукымын.
Маймылга бит ни кылса да ярый,
Мамылга бит бары да килешә.
Ни чыгарыр болар яңадан дип,
Юккамыни чит ил көлешә.
Кил син безгә, әйдә, маймыл елы,
Маймыл арасына сыярсың...
Мамыл булыйк, туган,
Юкса бу заманда
Соңгы акылыңны җуярсың.

## УЙМАК УЙЛАР

*(Мәхәббәт турында)*

Ни дуслыкка, ни мәхәббәткә омтылмаган кеше шуларның икесен дә югалткан кешедән мең тапкыр ярлырак.

ЖАН ПОЛЬ.

Сөю — кешеләрнең иң кызыклы һәм иң гафу ителә торган йомшаклыгы.

Ч. ДИККЕНС.

Кешенең мәдәни югарылыгы хатын-кызга мөнәсәбәт белән билгеләнә.

М. ГОРЬКИЙ.

Теләсә кайсы җәмгыятьтә хатын-кыз күз яшьләрен коя икән, бу — ирләргә каршы иң зур гаепләү сүзе.

Д. ПИСАРЕВ.

Каршылыклар һәм киртәләр мәхәббәт утын көчәйтә генә.

В. ШЕКСПИР.

Гашыйклар шундый күзлек кидерә ки, аның аша бакыр — алтын, фәкыйрьлек — байлык, су тамчылары энҗе булып күренә.

М. СЕРВАНТЕС.

Миндәге син яраткан кеше, әлбәттә, миннән күпкә яхшырак. Ләкин син мине сөй, һәм мин үземнән яхшырак булырга тырышачакмын.

М. ПРИШВИН.

М. Евгеньева

# ӘБИ ПАТШАНЫҢ СӨЯРКӘЛӘРЕ

## Укучыларыбызга бер сүз

*Хәтерегездәдер, журналыбызның былтыргы җиденче санында «Явыз Иванның хатыннары» дигән әсәрне тәрҗемә итеп чыгарган идек. Сезнең игътибарга урыс патшаларының шәхси тормышына кагылган тагын бер тәрҗемә тәкъдим итәргә булдык. Бик урынлы бер сорау туарга мөмкин: «Нәрсә, татар әдәбиятының төп мөнбәре саналган журнал, татар әдипләренең иҗаты белән риза булмыйча, «пешкәнрәк» җимешләрне күршеләр бакчасыннан эзлиме? Яисә сенсация артыннан куамы?» Түгел, әлбәттә. Болгавыр һәм тиз үзгәрүчән заманнар килде. Без, татарлар, хәзер җиде юл чатында басып торабыз: кайсы юлны сайларга? Ә киңәш бирүчеләр җитәрлек: шулар арасында кемдер безне кирегә, Рәсәй кочагына борылырга өнди, бөек державаны мең еллар буе бергәләп, берәмтекләп җыйдык, аның тарихында төрле-төрле чорлар очраса да, маяк булырдай алтын баганалары да бар, аларның исемнәре — Иван Грозный, Бөек Петр һәм Бөек Екатерина, калганнары да кул кушырып утырмаганнар, державаның түбәсен сипләгәннәр, ныгытканнар, искиткеч зур һәм гаҗәп ил төзегәннәр, ди. Һәм безне шулар рухына таянырга чакыра. Хуш, бик әйбәт. Тик кемгәдер таяныр өчен, андыйларның рухын-хәятен дә яхшы белергә кирәк бит. Менә ни өчен без бүген халыкта «Әби патша» дип йөртелгән Екатеринаның шәхесенә мөрәҗәгать итәргә булдык. Ә киләчәктә, шәт, Бөек Петр белән дә якыннанрак танышырбыз әле.*

## Екатеринаның яшьлек маҗаралары

Әби патша Екатерина II 1729 елның 21 апрелендә туган. Аның әтисе, принц Христиан-Август Ангальт-Цербстский, уч төбе кадәр генә зурлыктагы немец кенәзлеге хөкемдарының төпчек энесе була. Төпчек балага ата мирасыннан мәче генә кала дигәндәй, ул бик ярлы яши, шуңа күрә аңа тамагын туйдырыр өчен ниндидер кәсеп эзләргә туры килә. Хәер, Пруссия короле Бөек Фридрих букча асып ипи телеме эстәргә чыгарып җибәрми аны. Кесәсендә сукыр бер тиене булмаса да, байбәтчә бит. Померааниягә губернатор итеп билгели. Принц Христианның хәләл җефете — Рәсәйгә хуҗабикә булачак Әби патшаның анасы — тумышы белән Гольштейн-Готторп кызы Иоанна-Елисавета, яшь чагында үтә дә чибәр һәм шактый җиңел холыклы хатын булган, диләр. Шулай да ул танышларын бик оста сайлый белгән, күрәсең: хәтта Бөек Фридрих үзе, башы-күзе әйләнеп, гүзәл хатын белән мавыга башлый һәм нәтиҗәдә Бөек Екатерина дөньяга килә.

Менә ни өчен Пруссия короле бер билгесез немец губернаторының кызын, кулыннан килгән бөтен мөмкинлекләрдән файдаланып, урыс тәхетенең варисына ярәштерергә тырышкан.

Тиз мавыгучан кайнар темпераментын Бөек Екатерина әнисеннән мирас итеп алган. Әтисе булып саналган принц Христиан хәләл җефетенең итәк асты романнарын башына да китерми. Принцларга хас зиннәтле сарайларда да яшәмиләр алар, торган җирләре гап-гади бер йорт була. Сабый кызчык Софья Августа Фредерика Эмелия (Екатеринаның немец чиркәве биргән исеме әнә шундый) тузанлы урамда кара халык балалары белән аунап үсә. Әнисенең холкы җиңел булуга карамастан, кулы бик авыр булган: кечтек кенә гаебе өчен дә ул кызын аяусыз яңаклап торган. Шул хакимлек сөючән дорфа немец хатыны урыс императорларының нәселләре белән туганлык тота, дип кем әйтер иде икән? Чынлыкта, принц Гольштейн-Готторпский белән алар ике туган балалары булалар, ә анысы урыс императрицасы Елисавета Петровнаның бертуган сеңлесе Анна Петровнага өйләнә. Еллар үтсә дә, Елисавета Петровнаның йөрәгендә мәңге җуелмас эз саклана: ул Гольштейн-Готторпскийлар йортын беркайчан да онытмый. Тәхеткә менеп утыру белән ул үзеннән алдарак башына таҗ кигән яшь патша Иоан Антонович Брауншвейскийны, ата-аналары белән бергә, Архангельск губернасына сөрә һәм шундук үзенең бертуган кардәшенең улы принц Карл-Ульрихны чакыртып, Петр исеме биреп чукындыра һәм тәхет варисы итә.

Килмешәк цесаревичны Елисавета Петровна, балигъ булуга, башлы-күзле итәргә карар кыла, чөнки тәхетнең нәселдән-нәселгә күчүен тели. Төрле иләрдән кәләш эзләү башлана. Ә Петр Федоровичка читтән беркем дә кирәкми, ул муеныннан фрейлина Лопухинага гашыйк һәм моны патшабикәгә җиткерә. Елисавета Петровнаның җен ачулары чыга: Лопухинаның әнисе, сарай статс-дамасы, кайчандыр аның күлмәк сайлый белмәвенә төрттереп, аны бик уңайсыз хәлдә калдырган була. Елисавета Петровна тиз арада Лопухинаның әнисен дәүләткә хыянәт итүдә гаепли һәм башта аны тәгәрмәчкә бәйләп җәзалап үтерүгә хөкем иттерә, ә соңыннан, бераз күңеле йомшарып, җәзаны үзгәртә: өлкән яшьтәге статс-даманың телен кисеп ташлыйлар һәм, Троицкий мәйданында халык алдында камчы белән суктырганнан соң, Себергә сөрәләр. Елисавета Петровна, гомумән, урыс патшалары арасында иң беренче булып «мәрхәмәтлелек» күрсәтә башлаган кеше: үлем җәзасын ул тел кисү белән алмаштырган. Шулай итеп, аның заманында Рәсәйдә меңнәрчә кеше телсез кала. Сүз җаеннан әйтеп китик, Екатерина II дә аның эзеннән китә: тәхеткә утырган көнне ул, йола буенча, җинаятьчеләргә амнистия бүләк итә һәм Рәсәй урамнары теле киселгән кешеләр белән тула. (Пушкинның «Капитан кызы» повестендагы телсез башкортны исебезгә төшерик. Тәрҗ. искәрмәсе).

Лопухина белән эшне бетергәч, Елисавета Петровна, Пруссия короле тәкъдиме белән, принцесса Софья-Федерика кандидатурасына туктала: әлбәттә, монда эшне бу ярлы кыз файдасына аның Елисаветаның яшьлек мәхәббәтенең туганнан туган сеңлесе булып чыгуы хәл итә. Елисавета Петровна булачак киленне алдында балавыз булып эри, ул хәтта аның әнисе белән икесенең юл чыгымнарын да Рәсәй дәүләте өстенә ала. Төкле аягың белән килеп кенә җит, килен!

Әмма беренче күрешүдә үк Петр Федоровичның кәләштән күңеле кайта: икәү генә күзгә-күз калуга ул Софья-Федерикага Лопухинаны яратуын әйтә һәм бары тик шул кызга гына өйләнергә теләвен яшерми. Ләкин Софьяга Петрның яратуы-яратмавы барыбер! Аңа ничек тә урыс патшасы хатыны булырга кирәк. Петр Федоровичка чигенергә урын калмый: чиксез хакимиятле тутасының ихтыярыннан чыгып кая китә алсын соң ул?! Софья-Федерика, әнисе белән бергә, Петербургта яши башлый. Чая кыз французчаны су урынына эчә, ә бу, императрица уйлавынча, ходай биргән иң зур сәләт. Принцессага кичекмәстән урыс телен, православие дине кануннарын өйрәтә башлыйлар. Кыз укуга һәвәс булып чыга: бик теләп урыс телен өйрәнә, латинча сукалый башлый, Тацит, Вольтер, Дидро китапларын яратып укый һәм шул арада сарай тормышын җентеклəп күзәтүне дә онытмый. Ботенесе дә киләчәктә кирәк булачак!

Әйтергә кирәк, ул чорда патша сараендагы гореф-гадәтләрне әхлакый яктан бик тотрыклы булган дип булмый, шуңа күрә Екатеринаның туйга чаклы ук ирләр белән гыйшык-мыйшык уйный башлавы бер дә гаҗәп түгел. Иң беренче каш сикертүләрен ул сарай Дон-Жуаны дип аты-чабы чыккан Чернышевка багышлый. Чернышев белән аның арасында чын мәгънәсендә шухыр-мухыр булдымы икән, юкмы — тарих бу турыда тулы мәгълүматлар калдырмаган, әмма Чернышевның принцесса белән үзен бик тә әдәпсез һәм булачак кияүнең ачуын китерерлек дәрәҗәдә кыю тотуы базар хәбәре булып йөргәне билгеле. Петр Федорович кәләшенең Чернышевка дәрт белән күз

атуын бик тиз күреп ала һәм хурлана башлый. Принцессаның якыннары аңа ут белән шаярмаска киңәш итәләр, юкса тәхет варисы белән туй ясаудан колак кагарсың, патшабикә булу хыялың да җимерелер, янәсе. Чернышевны вакытлыча чит илгә таярга мәҗбүр итәләр. Ил капкасы аңа бары тик тәхет варисының туе узгач кына кабат ачыла.

Екатеринага уналты яшь тулган көнне иртүк, бөтен йоласын китереп, искитәрлек зур туй ясыйлар: ниһаять, ул Петр Федорович белән икәүдән-икәү генә кала. Борынгы гореф-гадәт буенча, Елисавета яшьләрне үзе кияү келәтенә кертеп яткыра. Ә икенче көнне иртән бөтен сарайга аяныч хәбәр тарала: имеш, Екатерина кияү кочагында туңып үлә язган!

Елисавета яшь ирдә дәрт уята алмауда киленен гаепли, киңәшләр бирә. Әмма ай үтә, ел үтә, Екатеринаны һаман да түшәгендә җылытучы юк. Сүз нәрсә турында барганы аңлашыладыр. Эш болай булса, урыс тәхете вариссыз калачак бит!

Елисавета киленен тагын бик каты орыша һәм аңа ничек кенә булса да иренең күңелендә наз уятырга боера.

— Миңа хәләл иремне кочагыма алу берни дә тормый,— дип җавап бирә аңа Екатерина.— Ләкин варис хәзрәтләре миңа үзе бик салкын карый.

Озакламый Петр, авырып, түшәккә егыла һәм ире хаста чакта Екатерина швед илчесе граф Поленберг белән «шаяра» башлый. Тик бу роман озакка сузылмый. Чит илгә куылган Чернышев Петербургка өйләнеп кайта һәм тәхет варисы хатыны алдында үз-үзен оятсыз тотуы белән бөтен сарай халкын шаккаттыра. Екатерина башта аны күрергә дә теләми, ләкин кеше сүзенә төкереп караучы егет бервакыт үзе аның йокы бүлмәсенә бәреп керә...

Рәсәйгә килен булып төшкәндә Екатеринаның юл сандыгында ни бары өч гади күлмәк, берничә эчке вак-төяк киеме һәм шул чама кулъяулык була. Хәзер ул искиткеч купшы тормышта үкертеп яши. Елисавета аңа «вак-төяккә тотар өчен» күп итеп акча бүләк итә, аның өчен сарайдан зиннәтле апартаментлар аерып бирә һәм һәр ихтыяҗын үтәргә әзер торучы бик күп статсдамалар билгели. Сәнәктән көрәк булган хатын Рәсәй акчасын туздырырга бик тиз өйрәнә, ул хәзер инде үзен Рәсәйнең һәм урыс казнасының шәхси хуҗабикәсе, дип саный. Елисавета биргән акчалар гына җитми, муеннан бурычка бата. Алман иленә кайтып киткән әнисенә исәпсез-сансыз акча җибәрә.

Екатеринаның Андрей Чернышев белән чуалуы һәм тагын аның ике энесенә яшерен каш сикертүе тиз арада Елисаветага ишетелә. Бертуган Чернышевларны, кулга алып, төрмәгә ябалар, әмма Екатеринаны бу да туктатмый, ул Андрейга наз тулы гыйшык хатлары язып тора һәм аңа төрлечә ярдәм итәргә тырыша.

Ә Елисавета Петровнаны, элеккечә, килененең Петр белән үзара мөнәсәбәте бик нык борчый. Ул Екатеринаның балага узуын зарыгып көтә, әмма моның һаман эзе дә күренми. Чернышев төрмәдә чакта Елисавета Петровна Екатерина свитасына Чоглокова дигән статс-даманы билгели, ә аның ирен шундук камергергер итеп куя. Чоглоковлар бер-берсен бик нык яратышып яшиләр, шулай да Екатерина тиздән камергергерын үзенә карата.

Ә бит ул вакытта аңа нибары унсигез яшь тула. Шундый әшәке кыланышларын күргәч, ире Петр Федорович аның белән араны бөтенләй өзә, аерым бүлмәдә йоклый башлый. Хәзер аның бердәнбер юанычы булып ау этләре, катыргыдан ясалган крепость белән уйнау һәм үз-үзенә бүтән төрле кызыклар табу гына кала. Бик сәер кеше булган ул. Китап та укымый, дәүләт эше белән дә кызыксынмый. Ә Екатерина, киресенчә, үзенең бөтен буш вакытын,— ирләр белән мәхәббәт уены уйнаудан артканын, әлбәттә — дәүләт белән идарә итү серләренә төшенүгә сарыф итә, сарай хезмәтчеләреннән җор сүзләр өйрәнә, табышмаклар, мәкальләр ота, үзе тирәсенә офицерлар арасыннан якын ахирләр җыя. Бар булган гомерен затлыдан-затлы кием алыштыруга, берсеннән-берсе купшы мәҗлесләр, бәйрәмнәр оештыруга һәм ирләр белән рәхәт күрүгә багышлаган Екатеринадан Елисавета Петровна шикләнә башлый, аның тирәсенә үзенең шымчыларын билгели. Ул аның үзеннән акыллырак һәм хәйләкәррәк икәнен күрә, тәхетен югалтудан курка.

Өйләнүенә тугыз ел узуга карамастан, Петр Федоровичның һаман да баласы булмавы Елисаветаны бик нык тирән хафага сала. Әмма Рәсәй тәхетен Гольштейннар нәселеннән чыккан вариска калдырырга теләве шулкадәр көчле була ки, хәзер инде ул Екатеринаның теләсә нинди ирләр белән өстерәлүенә бармак аша гына карый башлый — тик балага гына уза күрсен! Һәм менә

бервакыт аның яшерен хыялы тормышка аша, әмма бигрәк тә Екатерина үзе моңа шатланып туя алмый: чөнки тәхетне үзендә саклар өчен аңа бердәнбер чара булып шул калган була. Баланың атасы Петр Федорович булмавын Елисавета бик әйбәт белә, әлбәттә, ләкин бөтенесенә дә күз йома. Ә Екатеринага үзенең йөккә узуын законлы иренә ничектер аңлатырга кирәк бит. Ул алдапйолдап булса да ирен яңадан кочагына ала һәм чынлап та берничә көн аның хатыны булып тора.

Нәкъ шул вакытта патша сараенда кертинкә кебек чибәр һәм мәһабәт гәүдәле бер егет, Польшаның киләчәктә булачак короле, Август Понятовский күренә башлый. Екатерина шундук акылыннан язардай булып аңа гашыйк була һәм, императрица дип игълан ителгәч тә, бу турыда онытмый. Хәер, болары хакында соңыннанрак. Әлегә булачак ана киң күңелле Елисавета карамагында яши: патшабикә аңа «тырышлыгы» өчен йөз мең тәңкә акча бүләк итә, әйтеп бетергесез кыйммәтле энҗе-мәрҗәннәр белән күмеп ташлый. Ә Павел тугач, аны халыкка, Елисавета Петровнаның Разумовскийдан тапкан малае, дип игълан итәләр, ә Екатеринаның авырга калуы турындагы хәбәр ялган иде, без моны усал күзләрне яздырыр өчен генә шулай эшләдек, дип аңлаталар. Екатерина әнә шулай кыенлык белән көтеп алган үз баласын беркайчан да кулына алып иркәләмәгән. Бала тугач та, императрица Елисавета аны, Екатеринадан тартып алып, бала бишеген үзе янындагы бер бүлмәгә урнаштырырга боера һәм аны үз баласыдай тәрбияли башлый. Елисаветага Екатеринаның инде кирәге калмый: Рәсәй тәхетенә варис табып бирде, шул җиткән! Екатеринаның, ана буларак, үз баласына гомер буе салкын каравы әнә шуннан да килеләр, бәлки.

Үз иркенә калгач, Екатерина «кече патша сарае» оештыра һәм үз сәясәтен башлап җибәрә. Тиздән Англия илчесе Вильямс белән Август Понятовский аның иң якын фаворитларына әйләнәләр.

Шул чордагы канцлер Бестужев, Екатеринаның Понятовский белән чуалуына бик уңай карый, хәтта үзе аларга очрашырга ярдәм итә, чөнки ул Екатеринаның сөяркәсен Польша тәхетенә утыртырга чамалап йөри. Ә менә иң гаҗәбе шунда: Екатеринаның законлы ире Петр Федорович та Понятовскийны бик якын күрә: бервакыт, мәсәлән, Франция, Пруссия һәм Англия илләре, урыс тәхете тирәсендә бетерелүче Вильямс, Понятовский, Екатерина һәм Бестужев арасында йөргән мөкерле хәйләләр ярдәмендә, Рәсәйне тарихка «җидееллык сугыш» исеме белән кергән орыш-талашка кушылырга мәҗбүр итәләр. Нәтиҗәдә урыс гаскәре бер файдасызга илле меңнән артык солдатын югалта, ә Екатерина Вильямс аша Англиягә дәүләт серен җибәреп ятуда, аның икенче сөяркәсе Понятовский шул ук Вильямска ярдәм итүдә гаепләнә. Вильямсны үз иленә куалар, Екатерина бик кыенлык белән генә, атна буе Елисавета Петровна каршында тезләнеп ялваргач кына, гафу ителә, ә Понятовскийны җәзадан, тәхет варисы Петр Федорович үзе яклап алып кала. Кемне дисез? Хатынының сөяркәсен! Елисавета шулай да Понятовскийны илдән куарга карар кыла, әмма әле генә гафу ителгән Екатерина, көтмәгәндә гомерендә беренче мәртәбә Елисавета Петровнаның теләгенә каршы бунт күтәрә! Ә бит үзе елап-сыкрап, ялынып кына сарайда кала алды! Теле киселеп, Себергә үк сөрелүе дә бик мөмкин иде. Менә бу асылъяр дисәң дә, асылъяр! Кыскасы, Понятовский Петербургта кала. Бу инде — алар арасында гыйшык эшләре дәвам итә алачак дигән сүз. Екатерина якын сердәше Бестужевны да үз канаты астына ала:

— Курыкмагыз. Мин сезнең белән. Бармак очы белән дә кагылдырмаячакмын мин сезгә. Беркемнән дә! — дип тынычландыра ул аны. Екатеринаның кавырсына кайта башлаганны күрсәтә торган ачык мисал болар.

## Сәхнәдә — Екатеринаның бердәнбер никахлы ире Петр Федорович

Петр Федорович мокыт ир булмый, әлбәттә: хатынының Понятовский белән кети-кети уйнавын бик әйбәт белгән ул. Әмма көнләшмәгән. Екатеринаның фаворитлары белән бергә, бөтеннәрне ышандырырга тырышуына караганда, ул ата кабахәт бозык ир булган, имеш. Ләкин моңа ышанырга ярамыйдыр, могаен. Дөресен генә әйткәндә, Петр, ходай акыл өләшкәндә бераз соңрак калган

дигәндәй, бик сүлпән зиһенле һәм авыр газаплар кичергән кеше була. Беренче мәхәббәте белән аз гына да исәпләшмичә, Елисавета аны дорфа рәвештә җаны сөймәгән немец принцессасына өйләндерә. Ә ул сөйгән кызы Наталья Лопухинаны гомергә онып алмый һәм, кочләп тагылырга риза булганы өчен, Екатеринага зур үпкә саклый. Заманында Екатеринаның сөйкемле сөягенә исе китмәгән бердәнбер кеше — аның үз ире Петр Федорович булгандыр.

Җитмәсә, көннәрдән беркөнне патша сараенда Елисавета Воронцова дигән искитәрлек гүзәл бер кыз күренә һәм Петр Федорович шундук аңа гашыйк була. Һәм җаны-тәне белән дошман күргән хатынын аерып, шул кызга өйләнергә хыяллана башлый.

Понятовский Екатерина янына төн саен диярлек килеп йөри, ә Петр аның үз хатынының бүлмәсеннән иртәнгә таба гына чыгып киткәнен бик яхшы белеп тора.

Хатынына талак дияр өчен моннан да кулайрак сәбәп юк ич! Петр сиздермичә генә Понятовскийга тозак оештыра. Гадәттәгечә төн җитеп, Понятовский кереп киткәнен көтеп торалар да бөек княгиняның йокы бүлмәсе ишегенә каравыл куялар. Андый-мондый нәрсәне күз алдына китермәгән Понятовский иртән сөяркәсе яныннан чыга, аны шундук кулга алалар.

— Нәрсә эшләдегез сез бу вакытта бөек кенәзнең хатыны бүлмәсендә? — дип сорыйлар аңардан. Понятовский авызына су капкандай бер сүз дә дәшми.

Әмма Екатерина шушы четерекле хәлдән дә котылу юлын таба.

Шулай итеп, Понятовский, берни булмагандай, моннан соң да кичләрен Екатерина янына йөрүен дәвам итә, ә бөек кенәзнең үз йокы бүлмәсендә төн дә фавориткасы Воронцова куна. Елисавета Петровна да, гауга-мазар чыкмый калгач, бик канәгать.

Шулай да бер-ике атнадан соң Елисавета Понятовскийдан Рәсәйдән китүен үтенә: бәладан баш-аяк дигәндәй. Петр юкка-барга да шырпы кебек тиз кабынып китүчән кеше, еш кына үз карарын үзе боза, кызулык белән әллә нинди низаг күтәрүе бар.

Екатеринаны фаворитыннан аералар. Понятовский — Екатеринаның мәхәббәт карьерасында беренче ир түгел, әмма ул аның иң беренче сөйгән кешесе. Ул аңардан Анна исемле кыз бала таба, тик бу баланы ай күрә, кояш ала.

Бу вакытта Екатеринага егерме сигез яшь тулган була инде. Сарайда аның хәзер ныклы үз урыны бар, күпләр аның белән исәпләшәләр, хәтта Елисавета да аның үткен акылын һәм көчле ихтыярын танырга мәҗбүр, ул еш кына Ауропадагы сәяси мәсьәләләрне хәл иткәндә килене белән киңәшләшә. Министрлар да, тәхет варисына караганда бөек княгиняны өстенрәк күрә башлыйлар. Тәхет варисы Петр Федорович үзе дә хәзер хатынын ышанычлы терәк, дип саный. Иң кыен чакларда аңардан ярдәм сорый.

Үләренә күпмедер калгач, Елисаветага бөтен нәрсәдән курку зәхмәте иярә. Үз бүлмәсендә ялгыз калудан да курка ул, кайда да аны элек үзе газаплап үтерткән кешеләрнең өрәкләре сагалап торган кебек тоела. Эз югалтыр өчен ул беркайчан да бер бүлмәдә ике төн рәттән кунмый, һәркемнән шикләнә: барысы да аның үлемен телиләр, янәсе. Хәтта үз ире Разумовскийны да шикле кешеләр исәбенә кертә, ул аны янына якын да китерми. Ә төн ләззәте өчен, бер гап-гади унтер-офицер Иван Шуваловны тота.

Менә шул чорда патша сараенда дөнья күрмәгән вәхшилекләр башлана.

Елисавета Петровна, сарай дамаларыннан кача-поса, төннәрен үзенең яңа сөяркәсе унтер-офицер белән үткәрә, ә Екатерина үзенең кабул итү бүлмәсен такта белән икегә бүлдерә: бер ягында аны һәрвакыт нинди дә булса бер фавориты көтеп утыра, ә икенче якта министрларны кабул итә. Шул ук бүлмәдә, ширма артында, Екатерина «тышка чыгар өчен» кирәк-яраклар куелган. Екатерина хәтта хатын-кызга гына хас сыйфатларын югалтуын да уйламый: еш кына ул, ширма артында «тышка чыгып» утырган килеш, кабул итү бүлмәсенә кергән сарай кешеләре һәм министрлар белән сөйләшә, хәзер алар үтенечләрен Екатеринага әйткәч кенә рәсми патшабикә Елисавета янына керә алалар. Ә Петр Федорович, минем катнашым булмагач, бер-бер артлы каян ала икән ул балаларын, дип хатыны өстеннән зарланудан узмый.

— Монысын каян алды икән инде ул, бер Алла белсен! — дип аптырый ул сарай дамасы Головина алдында. Аптырар да шул: Понятовский Рәсәйдән куылганнан соң Екатерина инде өченче мәртәбә буйга уза бит!

Соңгысы Екатеринаның Нарышкин белән очрашуларының җимеше була. Ул әле һаман да Понятовскийны оныта алмый, ләкин шундый котырган темпера-

менты белән, монах хатыннар кебек, салкын мендәрен кочаклап ятмас ич инде! Ул, гомумән, ир-ат затыннан башка бер минут та тора алмый. Ире ир булса иде! Ирлек хисләрен чүп урынына аяк астына салып таптаган өчен Петр Федорович хатынынннан үч алу хыялын, Елисавета Петровна үлгәнче, күңел түрендә биклəп тота: тәхеткә генә менеп утырыйм, шундук монастырьга яптырам мин ул фәхишәне, дип тутасы янына Газраил килгәнен дүрт күз белән көтә.

Ә ул арада Конбатышта бик җитди хәлләр башлана. Канцлер Бестужев, Франциянең котыртуына буйсынып, Рәсәйне Пруссиягә каршы сугышка күтәрә. Тик ул дигәнчә барып чыкмый: Пруссия короле җиңеп куймасынмы! Менә шунда инде шактый кызыклы фактлар ачыла: сугыш вакытында Екатерина Пруссия короле Фридрих белән хатлар язышып торган икән! Ул гына да түгел, 1757 елда Фридрих Мемель шәһәре янында авыр хәлдә калгач, Екатерина генерал Апраксинга һөҗүм башламаска әмер биргән дә, шуның аркасында гына немецлар тар-мар ителүдән котылып калган, имеш.

Патша сарае һәм бөтен Рәсәй, Екатеринага ачудан, кырмыска оясына таяк тыккандай гөж килә. Бестужевны кулга алалар һәм аны дәүләткә хыянәт итүдә гаеплиләр. Екатерина да, үз нәүбәтендә, калтырап төшә: чөнки Елисавета аны, Бестужевның яшерен шымчысы дип, шулай ук кулга алырга карар кыла. Бөтен Рәсәй дә таләп итә моны. Екатеринага монастырьга ябылу куркынычы яный иясе аны, һич югында, иреннән аерып, Германиягә куып җибәрәчәкләр.

Әмма Екатерина бу юлы да котылып кала. Бестужев эшен тикшерүне әле генә граф титулы алган Шуваловка һәм Трубецкой белән Бутурлин кенәзләргә тапшыралар.

Екатерина бер төн эчендә аларның өчесен дә үзенең сояркәсе итә!

Шувалов Екатеринаны йолып калу өчен бөтенесен эшли. Һәм Елисавета, килене белән килешүен аңлатып, беренче башлап аңа кул суза. Екатерина тагын бәйрәм итә.

Озакламый Екатеринаның күзе сугышта әләккән әсиргә, Пруссия короленең флигель-адъютанты граф Шверинга төшә. Аксөяк әсиргә, качып китмәсен дип, ике офицерны сакчы итеп билгелиләр. Шуларның берсе, әзмәвердәй искиткеч таза гәүдәле, көчле һәм чибәр кеше була. Аны күргәч, Екатерина ушын югалта.

Атаклы фаворит Григорий Орловның карьерасы әнә шулай башлана.

Кая инде хәзер Понятовский кебек «вак-төяк» фаворитларын истә тоту! Екатерина, акылдан шашардай булып, Григорий Орловка табына башлый. Сугыш кырында кыю йөрәкле гаскәри, ә сөюдә наз кадерен бәяли белүче гайрәтле кеше була ул. Ә Екатеринага, яшерен максатларына ирешү өчен, нәкъ әнә шундый кеше кирәк тә.

Екатерина хәзер төннәрен Григорий Орлов белән күңел ача башлый, ә анысы, боек кенәз хатынының «бакчасында кыяр ашавын» яшереп тә тормый. Тик ул үзе бик көнчел кеше булып чыга: еш кына юк-бар сәбәптән дә гауга куптара, яннарында чит кеше бар дип тә тормыйча, үз кадерен үзе яхшы белеп, Екатерина белән артык таләпчән һәм дорфа кылана. Сояркәсенең үзенә башы-күзе тонып ябышканын күрә иде ул. Холкында садизм гадәтләре булган барлык хатын-кызга нәкъ әнә шундый ирләр ошый, ә Екатеринага җенси садизм хас. Бу аның нервыларын рәхәт кытыклый гына һәм дәртен дүртпочмаклата. Орлов — Екатерина өчен һәрьяклап кадерле табыш: сояркә буларак та, киләчәктә тугры корал буларак та. Ул аңа киләчәктә бәяләп бетергесез файдалар күрсәтәчәк әле. Бүре этедәй елгыр Орлов өчен гвардия полклары җаннарын да аямыйлар. Һәм Екатерина моның белән исәпләшмичә булдыра алмый. Шулай итеп, сарайда аның яклылар артканнан-арта бара һәм, озак көттермичә, шактый куәтле партия барлыкка килә. Аның җан дуслары арасында Екатерина Воронцова-Дашкова һәм чиксез властька ия булып өлгергән яңа канцлер Панин да бар.

Императрица Елисавета 1762 елның 5 гыйнварында кинәт вафат була. Аның урынына тәхеткә Екатеринаның ире Петр менә. Котелмәгәнрәк хәл була бу. Петербургта, Елисаветаны Екатерина белән Панин, властьны үз кулларына тизрәк төшерер өчен, агулап үтергәннәр, дигән имеш-мимешләр тарала...

Петр Федорович, тәхеткә хуҗа булуга, иң беренче эше итеп Пруссия белән Рәсәй арасындагы сугышны кырт туктата. Гаскәрләр Рәсәйгә кайтарыла һәм Пруссия белән сепарат солых төзелә. Рәсәйнең союздашлары Франция, Испания һәм Австрия, шаккатудан, үз күзләренә үзләре ышанмыйлар. Ул гына бер хәл, Петр үзенең яраткан Фридрихына, кирәк чакта бергәләп саклау һәм яуга чыгар өчен, Рәсәй белән союз төзергә тәкъдим итә! Бу — Елисаветаның се-

ясәтен ташлап, бөтенләй капма-каршы якка борылу дигән сүз. Рәсәйнең Версаль буенча элекке дуслары, корольләр һәм аларның илчеләре, Петрның кан дошманнарына әйләнәләр.

Екатеринага шул гына кирәк тә иде инде.

Петр патша үзе дә, аның армиясе дә Пруссия үрнәгендә немец мундирына киенгәч, аңа карата булган нәфрәт тагын да көчәя төшә.

Петрның эчке сәясәте дә мәрхүмә тутасыныкыннан аерылып тора. Беренчедән, ул бөтен Рәсәйне дер селкетеп, куркытып торган яшерен канцелярияне юкка чыгарды: монда кайчандыр аның сөйгән кызының әнисен, гүзәл хатын Лопухинаны, ерткычларча газаплап, харап иттеләр... Петр, теле киселеп, гарипләнгән бәхетсез хатынны сөргеннән кире кайтара.

Соңгысы җәмәгатьчелек арасында хуплап каршы алына, әлбәттә. Әмма ул, фавориты Воронцованың киңәше белән, эшне бозып ташлый: Бөек Петрның барлык дворяннар да мәҗбүри рәвештә гаскәрдә хезмәт итәргә тиеш, дигән указын гамәлдән чыгара һәм православие руханиларының биләмәләрен тартып ала.

Үзенә терәк булган армиянең тормышын кискен кырыслата. Солдатларның кечкенә гаепләре өчен дә таяк белән суктыра башлыйлар, ә сугтыру саны икешәр-өчәр мең белән исәпләнә. Елисавета заманында хөрмәт казанган күп кенә солдатлар, «анакай»ларын тәхеткә күтәргән карт гренадерлар, аяусыз таяк астында җан бирә. «Идарә итү — алдан күрә белү ул»,— дип кабатлый торган була Екатерина. Ире Петр алдан күрә белми шул. Ул, алдан күрә белмәү генә түгел, бөтенләй берни дә күрми торган тома сукыр. Петр Екатеринаны ирекtә калдырып, Воронцова белән аерым җирдә яши башлый.

Екатерина бу вакытта бавыры астында чираттагы «мәхәббәт җимешен» күтәреп йөртә инде. Григорий Орловтан монысы.

Бу хәлне күргәч, барысы да ачыктан-ачык: «Петр императрицаны монастырьга бикләп, уйнаштан тапкан малае Павелны төрмәгә ябачак һәм Воронцовага өйләнәчәк»,— дип сөйли башлыйлар.

Әмма чамадан тыш әкрен кыймылдавы һәм икеләнеп маташуы харап итә Петрны. Агалы-энеле дүрт бертуганы белән бергә, Орлов Екатеринаның төп таянычы була: әнә шулар инде Петрның таякларын «ашап туйган» гвардия полкларын Екатерина ягына аудара. Ә гаскәрләр, сөенә-сөенә, Екатеринаны тәхеткә мендерергә риза булалар. Панин белән княгиня Дашкова да властьны тизрәк алмаштыру ягында тора.

Француз илчесе барон де-Бретейл дә яшерен фетнәгә бөтен көчен сала. Солдатлар белән офицерларны үз ягына аударыр өчен бик күп акча кирәк. Ә Петр Екатеринаны акча мәсьәләсендә бик азындырмый. Француз илчесе аңа чикләнмәгән кредит тәкъдим итә. Екатерина уңга-сулга акча өләшә башлый һәм аның ягына дүрт йөз солдат чыга: ул хәзер, бер дә шикләнмичә, үз язмышын алар кулына тапшыра ала иде. Офицерларның күпчелеге болай да аның ягында инде. Яшерен рәвештә власть алмаштырыр өчен болар — баштан ашкан инде. Петр берни дә сизенми, чөнки Екатерина искиткеч сәләтле һәм оста артистка булып чыга: Петр, хатынын, чәчен кыркытып, монастырьга җибәрүне билгесез вакытка чигереп, ваемсыз рәвештә яши бирә. Руханилар белән гади халыкны үзенә каратыр өчен Екатерина көн саен, траур киеме киенеп, вафат булган Елисаветага җеназа намазлары уздыра һәм, православие гореф-гадәтләрен якын даирәләре арасында «мәҗүсилек калдыгы һәм кыргыйлык» дип атаса да, дини кануннар кушканның бөтенесен җиренә җиткереп башкара.

Һәрвакыт икейөзлелек җиңә шул! Бу элек тә шулай булган һәм шулай булачак та. Руханилар белән халык алдында үзен шулай хәйләкәр төлке кебек тотуы белән бергә, Екатерина чын йөзен үз ирennән яшерүне дә онытмый: аны үтерергә ныклы карар кылып куйган инде ул. Ул хәзер һәр адымында, аңа ярарга тырышып, ире белән якты чырай күрсәтеп сөйләшә, чакырмасалар да еш кына иренең бүлмәсенә килеп керә һәм хәтта аның фавориты Воронцова белән дә үзен бик ягымлы тота.

— Монастырьга ябар, дип курка! — дип көлә генә беркатлы Петр.

Фетнә билгеләнгән вакыт җитәр алдыннан гына Екатерина бала таба: сабыйга граф Бобринский дигән исем кушалар. Григорий Орловның малае. Шулвакыт Екатерина Орлов алдында, Петр III үлгәч, аңарга кияүгә чыгарга һәм, өлкән малае Павелны тәхет варислыгыннан мәхрүм итеп, шушы сабыйны варис итәргә тантаналы рәвештә ант итә.

Ә Петр тагын да усалрак кылана башлый. Солдатларны таяк белән суктырып үтерү белән берррәттән, кемнең кем булуына карамастан, сарай халкын

да кыйната ул. Юк кына сәбәп табып, Лев Нарышкинны, Строганов һәм Волковны кыйнатып ташлый. Ә чибәр Екатерина, киресенчә, барысы белән дә үзен йомшак тота, ягымлы сөйләшә, һәркемнең күңеленә керә белә, шуңа күрә аны барысы да чын күңелдән яраталар, ә Петр белән аның фавориткасын җен урынына күрә алмыйлар.

Фетнә буласы көнне Екатерина үзен якын күргән гвардеецлар каршына чыгып баса: шундый тыйнак һәм чибәр, ярдәмгә мохтаҗ кебек тоела ул аларга... Фетнә булачагы турында алдан кисәтелгән солдатларның бер өлеше шундук түземсезлек белән тизрәк эшкә тотынырга теләк белдерә.

Петр бу вакытта үзенең сөяркәсе Воронцова белән Ораниенбаум кальгасында була. Шулчак офицер Перфильев аны фетнә күтәреләчәге турында кисәтә, әмма Петрның исе дә китми: ул бары тик поручик Пассекны гына кулга алырга боера. Чөнки Перфильев аны Екатеринаның иң якын кешесе дип атаган була.

— Фетнә ачылды! Пассек кулга алынган!

Екатерина Воронцова-Дашкова әнә шул сүзләр белән Екатерина янына йөгереп килеп керә һәм исе-акылы китеп туктап кала: императрица кичкенә лаканда чәлтәрле якаларын һәм җиңнәрен юып маташа...

— Нишлисез сез, государыня?! — дип кычкырып җибәрә Дашкова. — Сезнең гомерегез кыл өстендә тора. Ә сез кер уасыз!

— Усам ни булган? — ди Екатерина исе китмичә. — Мине Рәсәйгә императрица булырга әзерләп үстермәделәр ич. Кер юуның кемгә зыяны тигәне бар. Нәрсә булды?

— Харап булдык! Заговор ачылды!

Дашкова, Екатерина кушуы буенча, Измайлов полкында тревога күтәрергә боера. Ләкин фетнәчеләр никтер бераз шөлләп калалар. Базымсыз Федор Орлов та кирегә чигенә башлый. Әмма, Екатеринаның бәхетенә, Федорның туганнары Григорий белән Алексей шундук дилбегәне үз кулларына алалар. Иртәнге бишләр тирәсендә Алексей Орлов Екатеринаны Петербургка алып китә. Петербургка җитәрәк аларны Григорий Орлов белән кенәз Барятинский каршы ала. Тиз генә, арыган атларны яңалары белән алыштырып, Измайлов полкы казармаларына чабалар. Барып җитеп, барабан кага башлауга, аларны берни аңламаган солдатлар уратып ала. Григорий Орлов аларның алдына чыгып баса һәм:

— Яшәсен императрица Екатерина, Рәсәйнең бердәнбер законлы патшасы! — дип кычкырып җибәрә.

Хәтта фетнә турында алдан хәбәрдар булган солдатлар өчен дә көтелмәгән хәл: чөнки аларга, Екатерина бары тик регентша, ягъни багавыл гына булачак, ә император итеп аның олкән малае Павел Петрович игълан ителәчәк, дип аңлатканнар иде.

Әмма соң инде: гаскәр, зур алкышлар белән «Ура!» кычкырып, Орловның сүзләрен күтәреп ала, каяндыр бер изге атаны табып китерәләр, солдатлар Рәсәйнең яңа патшасына ант итә һәм шуның белән эш тә бетә. Сабый яшендә булганлыктан берни белми калган Павел әнисенең бу хыянәтен беркайчан да гафу итми: Екатерина ике куянны берьюлы атып ала — ирен дә бәреп төшерә, үз улын да тәхеттән мәхрүм итә. Екатеринаны Павелга багавыл итәргә чамалап торган Панин каршы төшәргә базмый. Екатерина бер минут эчендә бөтен властьны үз кулына алып өлгерә, барлык полклар аның ягына күчә.

Ә Петр шик-шөбһәсез йөри бирә. Фетнә аның туган көненә туры килә: ул үзенең сөяркәсе һәм тагын унҗиде дама белән, яхтага утырып, Ораниенбаумнан Петергофка китеп бара. Нәкъ шул минутларда Петр сөяркәсенең бертуган апасы аның хатынын тәхеткә утырту белән мәшгуль...

Екатеринаның үзен императрица дип игълан итүен ишеткәч, Петр Кронштадка таба юл ала. Әмма аны диңгез кальгасына кертмиләр: Рәсәйдә хәзер император юк, императрица гына бар, дип җавап бирәләр аңа. Ә ул арада халык Петербургка кайткан Екатеринаны алкышлый инде... Халык — сарык, дип юкка гына әйтмиләрдер, ул һәрвакыт җиңүче ягында!

Петр бик кызганыч һәм мескен хәлдә бер ярдәмчесез кала. Элекке дуслары барысы да аны ташлап китәләр. Гаскәр аңа бары тик ачы нәфрәт белән генә карый, шуңа күрә ул Екатеринаның чиксез хакимлек итүенә куркыныч кеше түгел инде. Әмма алдан күрә белүче Екатерина аның исән калуын теләми. Екатеринага риза булмаучылар кайчан да булса Петрны үз максатларында файдалануы мөмкин. Петр хатынына, Голштиниягә китәргә рөхсәт сорап һәм үзенең аяныч хәлен аңлатып, бик җылы хат сала. Ләкин бу вакытта аның өчен

казематта, бәхетсез император Иоанн Антонович янында, аерым урын әзерләп куелган була инде.

Петрдан хат алгач, Екатерина Ораниенбаумга Григорий Орловны җибәрә: ул, кенәз Голицын һәм поручик Измайлов белән бергә, Петрны рәсми рәвештә тәхеттән ваз кичәргә күндерергә һәм аны кулга алырга тиеш. Берьялгызы калган Петр карышусыз-нисез тәхетеннән баш тарту кәгазенә кул куя. Аны, каретага утыртып, көчле сак астында Ропшадагы биләмәсенә алып китәләр. Аның белән бергә Алексей Орлов, кенәз Барятинский һәм капитан Пассек китә.

— Петр белән нишлибез инде хәзер?—дип сорый Екатерина сөяркәсе Григорий Орловтан.—Нишләргә дә белмим, җан тынычлыгым калмады. Крепостька япсаң, аны яклаучылар фетнә күтәрүе мөмкин. Голштиниягә китәргә рөхсәт итү дә куркыныч.

Исән император ашып узган зиначы Григорий Орловка да комачаулый, әлбәттә.

Фетнә алдыннан алган вәгъдәсе буенча, Екатеринага өйләнергә хыяллана ул. Шул максаты өчен тәхеткә күтәрде дә ул аны. Әмма Екатеринага, ире тәхетеннән бәреп төшерелгән булса да, ул исән чагында бүтән кешегә кияүгә чыгу уңайсыз. Григорий Орлов бертуган энесе Алексейга «императрицаның күңел тынычлыгы бозылмасын өчен» нишләргә кирәклекне аңлата.

Ә Алексей Орлов нишләргә кирәклекне үзе дә бик әйбәт белә. Ропшада Петрны сарайның бер түр бүлмәсенә урнаштыралар. Алексей Орлов, Барятинский, Потемкин һәм Зубов аңа бер генә минутка да ялгыз калырга мөмкинлек бирмиләр. Петрның карт камердинеры да шунда.

Бервакыт камердинер, һава алырга дип, бакчага чыга: күз ачарга да өлгерми, аңа көтмәгәндә кемнәрдер ташланалар һәм каядыр алып китәләр.

Бәреп төшерелгән патша ялгызы калгач, Алексей Орлов аның белән низаг куптара. Әмма Петр аның нинди максаттан тавыш күтәрергә сәбәп эзләвен яхшы аңлый. Петр, телен аркылы тешләп булса да, каршы дәшмичә тыелып кала, теләге барып чыкмавын күргәч, Орлов Петрга сугып җибәрә. Бу—алдан үзара килешенгән билге була: фетнәчеләр таянычы калмаган бәхетсезгә күмәкләшеп ташланалар. Үлем ачысы белән, кыргыйларча чыелдап кычкырган тавыш яңгырый... Кенәз Барятинский куркуыннан бөрешеп каткан императорның аркасына үткен хәнҗәрен батыра.

Авыр яраланган патшаны кыйнауны дәвам итәләр, кемдер аның яшь баланыкы кебек нечкә муенына үреләр...

Шул ук көнне кич Екатерина Алексей Орловтан хат ала: ул, күз яшьләре белән ялварып, «анакаеннан» гафу итүен үтенә.

«Анакаебыз безнең, миһербанлы государыня! Ничек кенә батырчылык итеп языйм икән мин сиңа бөтен дөреслекне... Бәланең аяк астыннан чыкканын сизми дә калдык. Әгәр дә син безне үз мәрхәмәтеңнән калдырсаң, харап булабыз без... Государьга кул күтәрү турында башыбызга да кермәгән иде, ләкин өстәл янында утырганда, ул тик торганнан, басымчак холыклы кенәз Барятинский белән әрепләшә башлады. Аралап өлгермәдек, государь тынсыз ята иде инде...»

Екатерина Орловны да, Барятинскийны да, бүтәннәрне дә бик шатланып кичерә, әлбәттә. Гафу кылып кына калмый, «патшага кул күтәрү турында башларына китермәгән» кешеләргә зур бүләкләр өләшеп чыга.

Ә немец принцыннан Рәсәй тәхетен тартып алган хәерче немец княжнасы бик канәгать: ул берьюлы тәхеткә дә, ирекле мәхәббәткә дә хуҗа булды.

— Кайчагында чибәр булу шулкадәр әйбәт нәрсә икән!—дип, ахирәте Екатерина Воронцова-Дашкова белән шатлыгын уртаклаша ул.

## Яңадан-яңа сөяркәләр

Укучылар алдарак сөйләгәннәрдән Екатеринаның холкын-табигатен бераз төсмерли башлаганнардыр. Шәһвәт сөючә, хәйләкәр, байлык күрсә иманын сатарга әзер торган мәкерле хатын сәясәтне мәхәббәт белән бергә бик оста бәйләп бара.

Ирен сарык бәрәне урынына чалдырганнан соң, кайгыга батып тол хатын булып кыланып, йөзенә өметсезлеккә төшкән кеше битлеге яба. Өстенә кара кайгылы траур киеме кия, дин йоласына туры китереп, чиркәүләрдә җеназалар

уздыра һәм Петрның мәетен, фани дөньядагы дәрәҗәсенә ярашлы рәвештә, олылап җирләргә әмер бирә.

Тәхеткә хуҗа булганчы, Екатерина Григорий Орловка, Петр үлгәч, хатының булачакмын, дигән вәгъдә биргән иде. Ул моның белән Орловны императорның үлемен ничек тә булса тизләтү чарасын уйланырга мәҗбүр итте.

Григорий Орлов, шуны истә тотып, императрица сараена урнаша. Екатерина үзенең йокы бүлмәсе кырында гына аты чыккан «фаворитлар бүлмәсе» булдырган иде: аның сояркәләре, бүтәннәр белән алыштырганчы, әнә шунда яшиләр.

Григорий Орлов үзен Рәсәйнең рәсми булмаган императоры итеп тота башлый. Императрица күренекле куштаннары яисә министрлары сөйләшкәндә ул, бернинди әдәп белән санашмыйча, киеме-ние белән кушеткада ята, патшабикәне чит кешеләр алдында кочаклап үбәргә тотына, көрәктәй зур кулларына ирек бирә, кыскасы, бернидән дә тартынып тормый, хәтта аның өчен башкалар кызара торган була, ә императрицаның күзләренә рәнҗүдән яшь бәреп чыга. Әмма Екатерина аны тыярга кыймый, чөнки ул аны ярата да, аңардан шөлли дә.

Императрица Орловка Дәүләт Советы рөхсәтеннән башка кияүгә чыга алмавын әйтә.

Хафага төшкән Орлов, туганнары белән бергә, һәркайда бу никахның Рәсәй өчен кирәклеген аңлатырга керешә: тәхетнең рәсми варисы Павел Петровичның тазалыгы ташка гына үлчим, янәсе, ул үлә-нитә калса, урыс тәхете ятим калуы мөмкин, шуңа күрә, алдан ул тагын бер варис өзерләп кую эчне тишмәс!

Тиздән Дәүләт Советының тантаналы утырышы җыела һәм Екатерина анда Григорий Орлов белән никахлашырга теләвен белдерә.

Моңа каршы чыгарга беркем дә базмый. Зур көч җыеп өлгергән Григорий Орловтан барысы да куркалар: Екатерина аңа, бер миллион тәңкә акчага өстәп, ун мең җан крестиян бирә һәм, Шәһрезада әкиятләрендәге кебек, аны хәерчедән искиткеч байга әйләндерә.

Әмма, кыюлыкка килгәндә, ул вакыттагы тәхет варисын тәрбияләп үстерүче Панин да өркеп калучылардан түгел. Панин Орловларга, императрица өчен көнләшү өстенә, карасояктән аксөяккә әйләнүчеләр, дип җирәнеп карый. Хәер, ул үзе дә әллә нинди затлыдан-затлы аксөяк нәселеннән түгел, әмма зирәк акыллы һәм тирән белемле булуы аңа лаеклы рәвештә сарайда югары урын билэргә мөмкинлек бирә, ә Орлов, күкләргә менәргә хыялланса да, бик надан, дорфа һәм ялкау кеше ләбаса.

Сенаторлар, авызларына су кабып, дәшми утырганда, Панин мәһабәт гәүдәсен турайтып торып баса һәм һәр сүзенә тирән мәгънә салып:

— Императрица ни теләсә, шуны эшли ала,— ди.— Ләкин Орлова ханым беркайчан да безнең императрица булмаячак!

Орловның йөзе кәгазь кебек ап-ак була. Ә Екатерина, киресенчә, бик канәгать. Панин нәкъ ул ишетергә теләгән сүзләрне әйтеп салды! Тәхеттән колак кактырачакбыз, дигән сүзләрне әйтергә аңа Екатерина үзе үк өйрәтеп куйгандыр әле, бәлки.

Чынлап та, Орлов бер гап-гади солдатның оныгы гына ич: Бөек Петр аның бабасын, баш күтәргән укчыларны җәзалаганда, кыюлыгы өчен гафу иткән иде. Петр батыр йөрәкле укчыны дворян кызы Зиновьевага өйләндерде һәм туй көнендә дворянлык титулы бүләк итте. Шул көннән алып, укчы солдат Орел Орловка әйләнде һәм Иван, Григорий, Алексей, Федор һәм Владимир исемле биш малай үстерде. Малайлар барысы да үтә чибәр һәм таза егетләр булып үсеп җиттеләр: Рәсәйдә алардан да таза гәүдәле һәм гайрәтле ир-ат юк.

Григорий Орлов, Екатеринаның фаворитына әйләнгәч, сенатор итеп билгеләнә, граф һәм генерал-адъютант титулларына ия була. Фетнә башлап йөрүчеләр арасында катнашканы өчен олкән абыйсы Иван да шундый ук исемнәр белән бүләкләнә.

Григорий Орлов, үз-үзенә артык нык ышанып, масаюы һәм башсызлыгы белән нык аерылып тора. Ул Екатеринага:, «Әгәр дә теләсәк, без сине тәхеткә ничек утырткан булсак, шулай ук алып та ташлый алабыз!» — дип ачыктан-ачык ычкындыра.

Горур императрицага аның шапырынуы, әлбәттә, ошамый. Орловның минминлеге аның күңелен суындыра. Ул инде хәзер Орловка нинди зур бурычлы булуын да оныта. Утырышта Панин Кирилл Разумовский да яклап чыккач, Екатерина аларның икесенә дә рәхмәтле караш ташлый. Ә Григорий Орловка ясалма сагыш белән:

— Мин сине бик яратам, җан дустым, ләкин, әгәр дә без синең белән никахлашсак, безнең икебезне де Петр III язмышы көтәчәк бит.— ди. Ә үзенең йөрәгендә яшерен шатлык нурлары балкый.

Орлов аны туйдырып, маемлатып бетергән инде. Өстәвенә, Мәскәү белән Петербургта, йөрәгенә шом салып, шау-шулы чуалышлар куба. Халык арасында, патшабикә үзенең ирен үтергән кеше белән никахлашырга тели икән, дигән яман хәбәр тарала. Екатеринаның башына таҗ кигән көннәрнең истәлеге итеп, махсус корып куелган триумф капкасыннан портретларын алып ыргыталар.

Армия дә Орловка карата ризасызлык белдерә башлый. Эш шунда, артиллериянең генерал-аншефы буларак, ул коралларны яңарту өчен кулына бирелгән ике миллион акчаның яртысын, азгын тәти хатын-кызлар белән типтереп, туздырып бетерә, ә икенче яртысын Екатеринага бүләк итә.

Ә Екатерина шул акчага аның өчен бик кәттә мәрмәр сарай салдыра һәм аңа «Рим империясенең кенәзе» дигән титул юллатып ала.

Әмма шулай да ике ел эчендә Орлов Екатеринаны тәмам гарык итеп, биздереп бетерә. 1771 елны Екатерина Орловны Мәскәүдә таралган ваба чире белән көрәшергә җибәрә. Эпидемиядән акылдан шашарга җиткән халык, фетнә күтәреп, андагы архиепископны үтереп ташлаган икән. Курку белмәгән Орлов, егетлек күрсәтәм дип, вабага баткан шәһәргә китәргә ризалыгын белдерә, ә Екатерина аңа бик шатланып ак юл теләп кала. Орлов Петербургтан китүгә, Екатерина берничә көн буе Высоцкий исемле бер бик көяз поляк егете белән кәеф кора: патшабикәнең күзенә очраклы гына чалынган була ул.

Мәскәү фетнәсе бик тиз бастырыла. Орлов тантаналы рәвештә Петербурга әйләнеп кайтып керә һәм Екатерина аны, теләсә-теләмәсә дә, кабат җылы куенына алырга мәҗбүр. Ул аңа ире Петр-III үтерелгәннән соң бушап калган Ропшадагы сараен һәм аның тирә-ягындагы берничә квадрат чакрым җир-суны, крәстияннары-ние белән бергә, бүләк итеп бирә.

Бу вакытта Румянцев Дунай елгасы артында сугышып йөри, ә Екатеринаның башын көнбатыш Польша төене борчый. Императрица Польша тәхетенә үзенең элекке сөяркәсе Август Понятовскийны утыртырга карар кыла. Орлов көнләшүдән котырып кайнап чыга. Понятовскийны король итеп, Екатерина аңа кияүгә чыгарга тели, ахры, дип уйлый ул.

— Мин сезгә элекке сөяркәгезне король итәргә юл куймаячакмын!—дип өстәл төеп кычкырып җибәрә ул Югары Совет утырышында.

Канцлер Бестужев белән Панин аның мондый әдәпсезлекләренә күнеккәннәр инде. Екатерина бу юлы аңа каршы бер сүз дә дәшми, әмма үзен император кебек тота башлаган Орловның тупас кыланышларына чик куярга дигән ныклы карарга килә. Орлов тулы хуҗа булып сарайда яши, аның аерым өстәле һәм сансыз хезмәтчеләре бар, көндәлек кесә чыгымнарына тотар өчен казнадан аена ун мең сум акча алып тора, шулар өстенә ул биләмәләреннән һәм меңәрләгән крепостной крәстияннәреннән бик күп салым җыя, орденнары һәм күренекле титуллары, затлы сарайлары һәм зур-зур алпавыт йортлары санап әйтеп бетергесез, әмма ул, боларга гына риза булмыйча, императрицаны да үз кубызына биетергә чамалый! Тик Екатеринаны белеп бетерми шул: императрица—һәр кешенең сүзен игътибар белән колак салып тыңлый, ә хәл кылуны үз ихтыяҗыннан чыгып кына эшли торган кеше.

Екатерина, беренче җай килеп чыгу белән үк, Орловтан мәңгегә котылу әмәлен көтә һәм бу юлы аңа кире әйләнеп кайтырлык урын калдырмый. Дунай артындагы орыш урыс гаскәрләре файдасына тәмамлана һәм патшабикә Орловны Фокшанга Рәсәй исеменнән солых төзергә җибәрә.

Берни сизенмәгән Орлов, Төркиягә барасын белгәч, бик нык шатлана: тагын да зуррак тантана белән әйләнеп кайтырмын, дип уйлый ул. Солых төзү түгел аның уенда, Константинопольне кулга төшерү турында хыяллана ул. Яссыга барып җиткәч тә, Екатеринага, үзен сәргаскәр итеп куюны һәм Византияне басып алырга рөхсәт итүен таләп итеп, хат җибәрә.

Бу вакытта ул аның «фаворит булмасына» Екатеринага Панин табып биргән икенче сөяркә кереп урнашканын башына китерми әле. Екатерина Васильчиков дигән бер егет белән мавыга башлый һәм аны үзенең йокы бүлмәсе янына урнаштыра. Петербург моңа шакката. Искәрмәгәндә-нитмәгәндә, җәмгатьчелек фикере белән әз генә дә исәпләшмичә һәм оятсыз рәвештә, ачыктан-ачык зина кыла башласыннар әле!

Васильчиков, кай яктан гына алма, телгә дә кертмәслек бер мескен һәм мокыт кеше була, шунлыктан Екатеринаның аның белән «шаяруын» бары тик тупас һәм оятсыз рәвештә зина кылу белән генә аңлату мөмкин. Ике атна

дигəндə ул аңардан тəмам гарык була һəм, азаккы тапкыр кайнар тəн үткəргəннəн соң, иртүк аңа, бер минут та кичекмəстəн «фаворит бүлмə»сен бушатып, Петербургтан Мəскəүгə сөрелүе турында язу тапшыра: анда Васильчиковны Петербургка кире кайту хокукыннан мəхрүм ителүе кисəтелгəн.

Екатерина, гомумəн, элекке сөяркəлəре белəн «мəхəббəт яңарту»ны яратмый. Шул ук сəбəптəн ул бервакыт кайчандыр үзенə бик якын һəм кадерле булган Станислав-Август Понятовскийны да, хəтта бик кыска вакытка гына күрешергə үтенсə дə, кабул итми.

Шул чорларда Екатерина графиня Брюсны бик якын дус күрə башлый.

Графиня Брюс озакламый патша сараенда үзенə күрə бер арадаш баскычка əйлəнə: хəзер императрицаның йокы бүлмəсенə аны читлəтеп бер генə кеше дə үтə алмый. Хəзер бөтен нəрсəне аның рекомендациясе генə хəл итə.

Александр Васильчиков язмышы белəн килешергə мəҗбүр була. Əмма бер дə аны оттырды дип əйтмəссең: ул «фаворитлар бүлмəсе»нə билгесез бер ярлы офицер булып килеп керде, ə аннан граф, камергергер титуллары алып, изге Александр Невский ордены кавалеры булып һəм мəңге тошендə дə күрмəгəн зур билəмəлəр һəм йөзəрлəгəн мең крестияннəр хуҗасы сыйфатында килеп чыкты! Һəм болар бөтенесе дə — «анакай» белəн ике атна кунган өчен...

Григорий Орлов тиздəн үзенə «урынбасар» табылганны ишетə. Ташып торган дуамал холыклы һəм тупас Орлов, котырган ачуына буйсынып, Петербургка чаба. Авызында бер генə сүз аның: ул кайтып җитүгə, адəм актыгы саналган көндəшен дə, үзенə хыянəт иткəн императрицаны да бəреп кенə үтерəчəк! Əмма ул властьның үз кулыннан ычкынганын һəм үзенең, барлык гади кешелəр кебек, Екатерина хөкеме астында калганлыгын бик тиз тоя: ниһаять, Петербургтан китəргə ризалык биреп, Панин корган тозакка капканлыгын аңлый ул. Панин, Орловны Екатеринаның куеныннан кысрыклап куып чыгарып, үзе фаворит булырга омтыла. Лəкин Екатеринаның үз-үзен онытып, кайнар иркəлəвен хəтерендə тоткан Орлов, патшабикə аны һаман да яратадыр, дип өметлəнə. Аягы астында җир убылганын сизми əле ул. Орлов кабалана-кабалана Петербургка чапкан арада, Васильчиковны сарайдан куалар. Екатерина хəзер борынын җыерып, җирəнеп кенə искə ала Васильчиковны һəм «унышсыз тəкъдиме» өчен Брюсочкасын битəрли. Сарай халкы арасында императрицаның «авыз итүчесе» дип аталган графиня Брюс, исе китмичə, җилкəлəрен генə җыера:

— Укабыз коелмас əле,— ди ул аны юатып.— Берсе белəн авызыбыз пеште, икенчелəрен килəчəктə өреп кабарбыз.

«Авыз итүче» ханым күптəн түгел генə Потемкин белəн чуала башлаган була: ул шуны Екатеринаның фавориты итеп урнаштырырга чамалый. Шуның өчен ул башта күклəргə чөеп мактаган Васильчиковның «карьерасы»н җимерергə үзе дə ярдəм итə. Екатеринаның йокы бүлмəлəренең берсендə назланып яткан Васильчиковны сөреп чыгарырга Потемкин кушыла. Генерал-поручик Потемкин өмерне кабатлаганны көтеп тормый, шул ук секундта җиренə житкереп үтəп тə куя.

Четерекле боерыкны шундый зур осталык белəн башкарып чыккан генералны Екатерина Петербургка якынлашып килгəн Григорий Орловны каршыларга җибəрə. Кайчандыр Орлов көнчелек белəн Потемкинның бер күзен бəреп чыгарган була, аны күргəч, йөрəгенə шом йөгерə. Циклоп кебек сыңар күзле Потемкин, алагаем зур гəүдəсе һəм йөзендə ярылып яткан дүртпочмаклы дəрте белəн Екатеринаның нəфесен уятса да, шул күптəнге ызгыш аркасында, берничə ел майлы чүлмəк тирəсендə төлке кебек бөтерелеп йөргəннəн соң гына, фаворит дəрəҗəсенə күтəрелергə җөрьəт итə.

Потемкин Орловка императрицаның указын тапшыра: анда аңа яңа күрсəтмə алганчы беркая да китмичə, сак астында Гатчинада яшəргə кушылган.

Əйтергə кирəк, Екатеринаның беренче «романнары» бөтенлəй үк аның бозыклыгыннан тормаган. Понятовский, Орлов, Нарышкин һəм Салтыковлар белəн ул эчкерсез күңелдəн яратып-сөеп мавыга. Картая башлагач кына ул чын мəгънəсендə өстерəлчек хатынга əверелə. Екатерина соңгы сулышына кадəр «мəхəббəт»кə сусый, дəрт учагында янып яши, ə бу — бары тик табигый сəлəткə бай, зирəк акыллы һəм көчле рухлы хатын-кызларга гына хас. Балык канлы хатын-кызлар, гомерлəренең соңгы елларына кадəр дəрт саклый алмыйлар. Екатеринаның хискə бай табигате яшəү көчен һəм эшкə егəрлекне ирлəр назыннан таба, алар аңа авыр чакта таяныч була. Ə сөяркəлəрен биялəй урынына берсе артыннан икенчесен алмаштыруы күбрəк аларның үзлəренең Екатеринага хыянəт итүлəре белəн бəйле, өстəвенə сөяркəлəре, патшабикə аларны үзенə ныграк иялəштергəн саен, йөгəнсезрəк һəм талымсызрак була

барганнар. Шуңа күрә, Екатерина аларны берәм-берәм «фаворит булмәләрен»нән куып чыгара торган, ләкин бөтенләй ирсез тору да аның өчен түгел. Тик шунысы бар, Екатерина нинди генә акыллы тышкы сәясәт алып бармасын, эчке ил эшләрендә нинди генә зирәклек күрсәтмәсен, фаворитлар болагае дәүләткә бихисап зыян китергән. Фаворитсыз калуга, Екатерина тынычсызлана башлый, зиһене тарала, үз-үзенә урын табалмый этләнә һәм дары кебек тиз генә кабынып китүчәнгә әйләнә. Тагын да шуны өстәргә кирәк, һәр сөяркәнең дөньяга үз карашы була бит: Екатерина еш кына, чираттагы фаворитының теләгенә карап, Рәсәй политикасын кырт кирегә үзгәртә. 1778 елда Франция илчесе Керберон үз хокүмәтенә Петербургтан болай дип хәбәр итә: «Рәсәй белән эш итү бик тә кыен, чөнки Екатерина, гадәттә, чираттагы фаворитларны яңа кандидат табылганчы ук куып җибәрә, ә министрлар «фаворит булмәсе» буш чакта дәүләт белән идарә итү машинасын туктатып торалар. Бу һәрвакыт яңа фаворитның сәясәтенә яраклашу кыен булмасын өчен шулай эшләнә».

Минә ни өчен Екатеринаның барлык басып алуларын очраклы гына тормышка ашырылган дип санарга мөмкин: Безбородко, мисал өчен, Кырымдагы тоз кайнату урыннарын кулга төшерергә тели, императрица, моны ишеткәч, Кырымны басып алыр өчен бөтен көчен куя, соңрак аның шул ук сөяркәсе Польшада биләмәләр тотарга хыяллана башлый. Каты куллы Панинның тештырнагы белән моңа каршы торуына карамастан, Екатерина Польшаны бүлгәләргә фатиха бирә. Күрәсез, Екатеринаның басып алудагы уңышлары бер дә алдан ныклап уйланылган сәясәт җимешләре түгел. (Автор бу җитди мәсьәләгә бик җиңел карый: Рәсәйнең бөтен тарихы аның күрше илләрне басып алуга омтылуын күрсәтә, шуңа күрә урысларның канына сеңгән сәясәтне аерым «сөяркәләр»нең кәефенә генә сылтау чиктән тыш беркатлылык булыр иде. *Тәрҗ. искәрмәсе.*)

Васильчиковка тупас рәвештә ишеккә төртеп күрсәткәннән соң, Екатерина сөяркәләренең ятагы бик озакка суынып тормый.

Дөрес, «мәхәббәт»тән ял иткән арада, Екатерина үз биләмәләрендә, ягъни Рәсәйдә, вак-төяк чүплердән арынырга кирәк таба һәм конкрет эшкә керешә: тәнендә аккан немец каны һәрнәрсәне җиренә җиткереп, тәгәл тәртип ясарга куша аңа. Беренчедән, ул крәстияннәрне тулы мәгънәсе белән крепостнойга әйләндерә: Екатеринага кадәр крәстияннәрне җирдән күчереп янсә гаиләләрне бер-берсеннән аерып сатарга рөхсәт ителмәгән була. Екатерина хәзер крәстияннәрне үзе дә теләсә күпме һәм гаиләләрне теләсә ничек бүлгәләп сата, дворяннарга һәм алпавытларга да шулай ук эшләргә ирек куя: балаларны аналарыннан, аналарны ирләреннән башка рәхәтләнеп саталар. Моңа кадәр ишетелмәгән бу вәхшилек Екатеринаның Рәсәй халкына чиктән тыш дәрәҗәдә мәсхәрә белән каравын күрсәтә.

Петербург газетасында хәзер: «Кием тегә, кер юа һәм үтүкли белә торган сазаган кыз сатыла. Шунда ук җиңел ат арбасы да алырга мөмкин»,— кебек вәхши игъланнар гадәти хәлгә әйләнә. Екатеринага кадәр бер генә урыс патшасы да мондый тәвәккәллеккә бармый. Хәтта кансызлыгы белән аерылып торган Биронның да мондый рәсми колбиләүчелек кертергә кыюлыгы җитмәгән!

Екатерина чорында крәстияннәрне ачыктан-ачык «кол» дип йөртә башлыйлар. Хуҗасының имансызлыгына крәстияннең зарланырга хакы булмый. Алпавытлар аларны ике дә уйлап тормыйча рекрутлыкка сатканнар, судсыз-нисез Себергә сөргәннәр, җанын алганчы сыек чыбык «ашатканнар», гаиләләреннән аерганнар.

— Крәстиянне кеше дип булмый, әлбәттә,— дип аңлата Екатерина.— Шулай да аны йорт хайваны исәбендә булса да асрарга кирәк.

Икенчедән, Екатеринага Шлиссельбург төрмәсенең тома өлешендә сабый чагыннан ук череп яткан Иоанн исемле императордан мәңгегә котылырга кирәк. Турысын гына әйткәндә, ул сабыйны ирекгән Екатерина мәхрүм итмәде, аның үз анасы Анна Ивановна, канга баткан тәхетен баласына тапшырып өлгермичә, фани дөнья белән бәхилләшә, ә Елисавета Петровна, тәхеттә сабый балага караганда чибәр хатын утыру килешерәк төшә дип, аны төрмәгә яптырган иде... Күп сулар акты инде ул хәлләрдән соң. Ә халык төрмәдә-базда үскән бәрәңге сабагына әйләнгән мескенне һаман онытмый! Императрицаның яшерен әмере белән Иоанн Антоновичны буып ташлыйлар...

Шулай да мондый вак-төяк мәшәкатьләр, халык арасында әледән-әле яңарып торган шау-шулар һәм фетнәләр патшабикәнең ир-атларга булган дәртен сүндерә алмый. Сөяркәләр исемлеге арта тора.

Екатерина үз гомерендә бары тик бер генә сөяркәсе белән араны бик озак

үзми: ул да булса Орловка кадәр үк аның кочак җылысын татыган Панин. Панинның караваты Екатерина үлгәнче патша сараенда тора. Көнләшүнең нәрсә икәнен дә белми торган, азга да риза һәм искиткеч акыллы кеше үзе. Ә сәбәбе бик гади: чөнки аның Екатеринадан башка тагын бик күп гүзәл һәм яшь кәнизәкләрдән торган зур хәрәме бар. Екатерина янына ул атнага бер генә тапкыр, сагындырып кына кереп чыга. «Аш төрләндерергә» яратучы Панин, Екатеринага «хыянәт итүе» белән бергә, аның үзенә дә «хис яңартырга» комачауламый, алай гына да түгел, озын буйлы, наз аңлаучы гади офицерлар арасыннан фаворитларны императрицага ул үзе табып китерә. Панинның үзенә җитди көндәш булырлык кына булмасыннар: андыйлары аның кулыннан идарә эшләрен тартып алырлар. Екатеринага булган йогынтысыннан мәхрүм итүләре бар бит. Менә ни өчен ул үгез кебек гайрәтле Орлов белән хәйләкәр Потемкинны бөтен җаны-тәне белән дошман күрә һәм зирәклеге аркасында гына аларны үз юлыннан читкә алып ташлый ала.

Әмма дүрт аяклы ат та абына бит, Екатерина Васильчиковны куып та өлгермәде, Панин аңа Потемкинга игътибар итәргә киңәш итә: бу циклопны ул баштарак үзенә зыян итәрлек кеше дип исәпләми. Ә Потемкин, Екатерина кебек үк, оста актер булып чыга. Дан-шөһрәт артыннан куган хыялларын бик зур осталык белән күңел төбенә яшерә белә ул.

Екатеринага Потемкин, ир кеше буларак ошаса да, аның сыңар күзле булуы бераз кәефен кыра, әлбәттә. Сарай халкы аны, гариплегенә төрттереп, циклоп дип йөртә. Әмма графиня Брюс патшабикәгә Потемкинның хатын-кызны назлый белүен шулкадәр тәмләп сөйләп бирә ки, тегесенең авыз сулары килә!

Көннәрдән бер көнне иртән Потемкинны Роджерсон дигән табиб янына чакыртып алалар, государыняның фавориты булачак кандидатларны гадәттә, һәрвакыт аның илегә аша үткәрәләр. Потемкин, ниһаять, үзенең сәгате сукканлыгын аңлый: «Авыз итүче» графиня Брюс Потемкин турында Екатеринага: «Циклоп башы-күзе тонып сиңа гашыйк булган, эчтән генә янып-көеп йөри, әмма нәрсәгә дә булса өметләнергә базмый»,— дип сөйләнеп куя. Табиб, тикшереп, «сәламәтлеге менә дигән» фикер әйткәч, графиня Брюс сөяркәлеккә кандидат циклопны: «Булдыра алган кадәр кыюрак кылан!» — дип кисәтә-кисәтә, Екатеринаның йокы бүлмәсенә озата.

Потемкин үз өстенә йөкләнгән «кыюлык»ны искиткеч зур сәләт белән башкарып чыга, күрәсең, чөнки икенче көнне иртән иртүк Екатерина аңа генерал-лейтенант дигән исем бирә, шуңа өстәп маяга бер миллион сум акча һәм «кешечә яшәр» өчен Миллионный дип аталган урамнан затлыдан-затлы җиһазландырылган искиткеч матур сарай бүләк итә.

Акыллы, булдыклы ирләр менә ничек итеп бер төн эчендә, миллионнарның төшләренә дә кермәстәй бөек карьера ясый алалар Екатерина чорында!

Шулай итеп, Потемкин фаворитлар бүлмәсенә хуҗа була, ләкин сынау моның белән генә тәгәлләнми әле: сөяркәләр күрше бүлмәдә генә ятсалар да, алар белән хат язышып сөйләшергә яраткан Екатерина аңа икенче көнне менә нинди хат тапшырта:

«Генерал-лейтенант әфәнде һәм кавалер! Сез, күңелем сизә, мине көтәкөтә ялчыгып беткәнсездер. Сезгә карата күңелемдәге уйларымның нинди икәнлеген белдерер өчен, ә мин һәрвакыт сезгә яхшы теләктәштә, сезне артык ялчыктырмыйм һәм шушы хатым белән бүген кон азагындарак Санкт-Петербургка барып җитәчәгемне хәбәр итәм, ә кичен мине, бер мескен юлаучыны, үзегезнең юмарт ризык-нигъмәтләрегездән авыз иттерерсез дип өметләнеп, сезгә дә сугылачакмын. Сезнең шәхсән миңа һәм тугрылыклы хезмәт иткән сөекле ватанга карата булган кайнар мөнәсәбәтегезне яхшы белгәнгә күрә, мин сезгә чөгә балыгы табуны ышанып тапшырам, чөнки бик күптәннән бирле ул искиткеч тәмле балык шулпасын татып караганым юк».

Екатерина бу хаты белән Потемкинга, фаворит булу — ватанга хезмәт итү белән бер, дип каравын ачыктан-ачык белдерә. Фаворитларына бу «хезмәт», ул уйлаганча ошагандырмы икән, анысы икенче мәсьәлә. Картая төшкәч, Екатерина куплар өчен моның бик күп «тәмле нәрсә» булмаганлыгын аңлый.

Әлегә Потемкинга килик. Бу фасылда Петербургта чөгә балыгы үзе түгел, аның исе дә калмый! Екатерина, әлбәттә, моны әйбәт белә һәм ул яңа сөяркәсен аңлы рәвештә башкарып чыга алмаслык йөкләмә каршына куя. Императрицаның кушканын тапмаса, үзен нинди киләчәк көткәнен Потемкин бик яхшы аңлый, әлбәттә.

Әмма Потемкинның бәхете болыт артына ук кереп качмаган икән, чынлап еласа, сукыр күздән дә яшь чыга ди, бер ак сәүдәгәрдә очраклы гына шундый

балык сакланганын килеп әйттеләр, ә анысы — тилеләрдән түгел, бер балык өчен... йөз мең сорамасынмы! Потемкин чыраен да сытмый, шундук, кесәсеннән чыгарып, тегенең учына сала һәм моның өчен беркайчан да үкенми. Икенче көнне иртән императрица аны үзенең шәхси генерал-адъютанты итеп билгели, һәм Григорий Александрович шул көннән чикләнмәгән властька хуҗа була.

Потемкин үзен ниндидер Васильчиков кебек малай-шалай урынына кимсеттермәячәген Екатеринага шундук сиздерә. Ул аннан үзен Дәүләт Советы әгъзасы итеп сайлатуын таләп итә. Екатеринаның чәчләре үрә тора. Ул ике ут арасында кала: Потемкинның анда сайлануы граф Панинга бер дә ошамаячак!

— Бик яхшы. Ул чагында мин монастырьга китәм,— ди Потемкин. Сезнең җилкәдә әрәмтамак булып яшисем килми минем. Мин Рәсәйнең һәм үземнең данымны күтәрер өчен хезмәт итәргә телим һәм моңа лаеклылыгым бүтәннәрнекеннән ким түгелдер, дип ышанам!

Екатерина аны төрлечә иркәләп, юмалап карый, сарай халкы аның яңа роленә күнеккәнче бераз көтәргә куша, ләкин Потемкин, аның ай-ваена карамыйча, үз сүзендә каты тора. Екатерина төн буе елап чыга... Ә икенче көнне иртән Потемкин сенатор итеп билгеләнә: моны ишеткәч Панин шартлардай була, чөнки ул болай уеннан уймак чыгар, дип уйламый. Потемкин тиздән империя дилбегәсен бөтенләй үз кулына ала.

Орлов кебек үк, Потемкин да, императрицага өйләнергә карар кылып, акай-чукай килеп бетә. Морадына ирешер өчен ул төрле хәйләләр корып карый.

Потемкин бик зирәк кеше була, җор теллелеге һәм шаянлыгы белән аерылып тора. Теләсә кем булып сөйли белә, усал-усал сатирик хикәяләр яза, сәнгать һәм әдәбият белән якыннан таныш.

Дәүләт Советына кертелгәч, Потемкин империянең тышкы һәм эчке сәясәтен тулысынча үз кулына ала. Иң башлап ул Екатеринаның элекке фаворитлары Чернышев белән Алексей Орловны Петербургтан еракка кудырта: соңгысын императрица, егетнең бертуган абыйсы Григорий Орловка сырты белән борылгач, үз кулына төшергән була. Алексей Орловны, үз юлында түмгәк булып тормасын өчен, Италиягә илче итеп Панин җибәрә, ә Алексей кире әйләнеп кайтканда Петербургта Потемкинның якты йолдызы калыккан була инде.

Алексей Орлов белән Потемкинның үз исәп-хисабы була. Потемкинның сыңар күзенә әнә шул Алексей җитә инде: Петр Өченчене бәреп төшергән вакытта Потемкин, үз дәрәҗәсеннән узып, аңа ниндидер кимсетүле бер сүз әйтеп ташлый. Абруйлы Орловлар белән бергә фетнәдә катнашкач, Потемкин үзен алар белән бериш кеше, дип саный башлый, ахры. Ләкин горур Орлов аңа шундук алай түгеллекне үзенчә «йодрыгы белән аңлата»...

## Шәһвәткә табынган карчык

Потемкин һаман да әле үзенә көннән-көн ныграк ияләшә барган Екатеринага өйләнү хыялын ташламый. Соңгы сүзен кистереп әйтмәгән патшабикәне монастырьга китү белән куркытмакчы була.

— Болай никахсыз яшәүне Ходай тәгалә язык саный, Зоренькам,— дип үгетли ул аны.— Мондый кыланышларыбыз белән без кара халыкны юньсезлеккә котыртабыз, вәсвәсә таратабыз, Алла безне ярлыкамас моның өчен!

Ләкин Екатерина аның кәмит кенә уйнавын бик әйбәт белә. Фавориты белән ул да шундый ук кәмит уйный.

— Нишлисең бит, җан дустым. Хак тәгалә сине шулай үз юлына бик нык чакыра икән, мин синең изге ниятеңә каршы төшә алмыйм, монастырьга кит,— дип тыйнак кына уфтанып куя ул. Потемкин болай боргалану-сыргалануның бернинди дә нәтиҗә бирмәвен тиз аңлый. Хәлбуки, Екатеринаның үзенә тугрылыклы булмавын яхшы белсә дә, фаворитлар бүлмәсеннән моңа кадәр куып чыгармавына да бик шат ул хәзер. Екатерина кайчагында ишек төбендә сакта торучы зур гәүдәле гвардеецлар һәм сарайда яшәүче хезмәтчеләр белән дә «шаяргалап» ала. Очраклы рәвештә аның нәфесе төшкән ирләр белемле яки ниндидер бер тома наданмы — болар берсе дә аның өчен әһәмиятле түгел. Әмма императрица галиҗанәбләренең мондый авантюралары беркайчан да бер төннән артыкка сузылмый, ә күбрәк бер сәгатьлек кенә була.

Екатеринаның рәсми сөяркәләре шулкадәр күп булган ки, тарих битләрендә андый кыска вакытлы «геройлар»ның исемнәрен дә, биографияләрен бирер-

гә дә урын табылмаган. Ләкин шулай да кайберләре, кеше ышанмаслык анекдотлар рәвешендә булса да, буыннан-буынга күчеп, сакланып калган.

Екатерина җәен дә, кышын да бер үк вакытта — кичке сәгать унда йокларга ятып, иртәнге биштә тора торган булган. Бу вакытта аның өлгер камер-фравы Перекусина, алданрак торып, зур каминны дөрләтеп җибәрә, кайнар кофе әзерләп куя.

Бервакыт Екатерина, нишләптер, иртәнге бишенче яртыда ук уянып китә. Кыш көне була бу хәл. Камин сүнгән, ә бүлмәдә ата куян туңып үләрлек зәмһәрир суык. Камер-фрау Перекусина белән кизү фрейлина чаршау артында гырлап йоклап яталар.

Ә бу төнне аның ятагы буш була. Екатерина бу төнен үзенең яраткан Патша авылы сараенда ялгыз йоклый, чөнки сөяркәсе Потемкин ни сәбәптәндер Петербургта кунып калган чак була.

Туңыбрак уянса да, патшабикә, тәмләп йоклаган фрейлина белән камерфрауны уятырга уңайсызлана. «Каминны үзем ягып җибәрим әле», — дип уйлый ул һәм утын эзләп чыгып китә. Императрица, дөресен әйтергә кирәк, хезмәтчеләре һәм асраулары белән йомшак мөгамәлә иткән, беркайчан да аларны артык вак-төяк эшләр белән мазасызламаган. Бәлки, аның күңелендә бу минутта ниндидер яшерен өмет тә уянгандыр? Булачак назны хатын-кыз җанының җиденче тамыры белән тоя, диләр ич! Һәм ул алданмый. Озын коридорның түр башында Орлов белән Потемкинны да көнләштерерлек гаять зур гәүдәле бер кешене күреп, Екатерина ирексездән туктап кала. Менә теге билгесез кеше, коточкыч зур утын бәйләме күтәреп, патшабикә янына якынлаша. Екатерина тынсыз кала: адәм ышанмаслык анча да зур кочак булыр икән! «Нинди Геркулес икән бу?!» — дип уйлый ул сокланып. Ир патшабикә янына килеп җитә. Үзе бик яшь һәм чибәр генә, киеме генә кара халыкча.

— Сез кем? — дип сорый аннан әби патша.

— Мич караучы, патша галиҗанәбләре.

— Ә! Сез мине беләсездер? — дип елмая Екатерина. Хезмәтчеләренә ул һәрвакыт «сез» дип дәшә торган була.

— Сарайда ярты еллап эшлим инде мин, патша галиҗанәбләре.

— Ә нишләп соң сезне моңа кадәр беркайчан да күргәнем булмады?

— Минем эшем нәкъ сез йокыдан торган вакытта, иртәнге биштә бетә, государыня. Миңа шулай кушылган.

— Суык миңа. Үтенәм сездән, рәхим итеп минем йокы бүлмәмдә каминны ягып җибәрегез, — ди императрица.

Мич ягучы искәрмәгән шатлыгыннан чәч төпләренә кадәр кызара. Әмма бичара хезмәтче әлегә үзен моннан да зуррак бәхет көткәнен белми әле. Утын алып кереп, каминны дөрләтеп җибәргәч, крепостной Геркулес чыгып китәргә кузгала.

— Ашыкмагыз. Мин һаман да нык өшим, тагын утын кертегез.

Егет, түбәнчелек белән баш иеп, императрицаның боерыгын үти. Ә Екатерина һаман бер үк сүзне кабатлый:

— Мин өшим. Җылытыгызчы мине.

Мескен кол беравык куркып кала. Ни җитми икән инде тагын?! Мич кыза торгач, шартлардай булып гүли башлады ич инде. Патшабикәнең ни теләгәнен аңламый иде шул ул. Мөгаен, аны хәзер коточкыч авыр җәза көтәдер. Йә Себергә, йә солдатлыкка сөрерләр, яисә җәзалап үтерерләр!..

— Җылытыгыз инде мине, — дип елмая Екатерина һәм баһадир янына ук килеп баса. — Государынягызны ничек җылытырга кирәклеген аңламыйсызмыни сез?

Екатерина, ниһаять, ачыктан-ачык хәрәкәтләр белән ишарәләп, аптырашта калган колга нишләргә кирәклекне күрсәтә һәм куркудан акшарлы мичтәй агарынган баһадирның йөзе шундук алсуланып китә: вәт юләр, патшабикәнең фаворитлар һәм солдатлар белән ничек «җылынуы» турында бер генә мәртәбә ишетмәде ич ул!

Һәм Геркулес шулкадәр нык «җылытып» күрсәтә ки, Екатеринаның рәхмәте әйтеп бетергесез була:

— Афәрин, капитан әфәнде!... Искиткеч шәп, полковник әфәнде!... — дип кайнар пышылдый ул аның колагына.

— Фамилиягез ничек сезнең? — дип сорый патшабикә мич ягучыдан, аны бүлмәсеннән чыгарып җибәргәндә.

— Чернозубов, бөек патша галиҗанәбләре, — дип оялып кына җавап бирә тегесе.

— Патшабикәгезне җылытуыгыз вакыйгасы истәлегенә бүгеннән алып сез Теплов дип йөртеләчәксез. Ватанга күрсәткән яхшы хезмәтегезне билгеләп, рәхмәт белдерәм, полковник әфәнде! Хушыгыз!

Чернозубов шул ук көнне императрицаның фәрманын алды: анда аңа нәселдән-нәселгә күчә торган дворян титулы, Теплов фамилиясе бирелүе, Черниговгуберниясеннән ун мең крепостной крәстиян бүләк ителүе һәм бер минут та кичекмәстән Петербургтан китәргә кушылган боерык язылган була. Шул Тепловның нәселе әле дә анда яши һәм оныклары үзләренең кайдан килеп чыкканлыклары турында горурланып шушы риваятьне буыннан-буынга сөйлиләр.

Менә бервакыт Пугачев фетнәсе күтәрелә. Алпавытлар кулында җәберзолымнан башканы күрмәгән халык, хыялында саклаган ирекне вәгъдә иткәч, Пугачев ягына чыга. Екатеринаның тәхете, халык дулкынына чыдамыйча, чайкала башлый. Нәкъ шулчакта Салтыкова дигән бер кансыз алпавыт хатыны шау-шулы хөкемгә тартыла. Дөрләп янган учакка кипкән утын өстәгән кебек була бу: ул ерткыч хатын, чәчләрне үрә торгызырлык әшәкелекләр белән җәфалап, үзенең йөз егерме җиде крепостной кызын үтерткән була. Ә аның биләмәсендә көн күрүче бер рухани шул мескен корбаннарны, югарыга хәбәр итеп тормыйча гына, җирләп барган. Гаепсез кызларга армай (җәллад) ролен кем үтәгән дисез? Шул бичара кызлар кебек үк мескен лакейлар, крепостной крәстияннәр!.. Һәрвакыттагыча, хуҗа алдында тәлинкә тоту, мескенлек һәм куркаклык — халыкны коллыкта тотарга ярдәм иткән богаулар әнә шулар инде...

Екатеринаның фаворитлары да кара халык белән шул канәчкеч алпавыттан ким кыланмаганнар. Хәер, арада закончалык сакларга тырышучылар да юк түгел. Румянцевның биләмәләрендә, мәсәлән, колга, гаепләре нинди генә булса да, чи тал белән мең дә җиде йөздән артык сугу катгый рәвештә тыелган. Җанны тетрәндерерлек кече күңеллелек түгелмени бу?!.

Болар өстенә, Екатерина патшалык иткән чорда бертуктаусыз сугышлар чыгып тора, ә бу, билгеле, халык арасында һәрвакыт ризасызлык тудыра. Кырымны басып алу сугышы, икенче төрек сугышы, Швеция белән сугыш, Польшаны бүлгәләү өчен сугыш, Персиягә яу чабу — болар барысы да бер-бер артлы, бер озын чылбыр булып тезелеп, дәвам итә. Рәсәй җире үскәннән-үсә, күрше дәүләтләр исәбенә киңәя, аны хәзер беркем дә йөгәнли алмый.

Әмма сугыш бушка бирелми, исәп-хисапсыз акча тора ул, халык бөлгенлеккә төшә. Беренче төрек сугышы гына да халык кесәсеннән кырык сигез миллион чамасы акча суырып ала. Ә дәүләт бюджеты — сиксән миллион чамасы, ул бөтенләе белән Екатеринаның фаворитларына гына тотыла. Күзгә ятышлы булсын өчен, әйберне алтынга манарга кирәк бит!

Пугачев тирәсенә илнең бөтен ягыннан кешечә яшәүдән өметләрен өзгән крәстияннәр агыла. Аран малы урынына саналганчы, чуалышта үлеп калуны өстенрәк күрә алар. Пугачев фетнәсе дүрт ел дәвам итә. Фетнәчеләр ярты Рәсәйне тар-мар китерәләр һәм тагын да ныграк бөлгенлеккә төшерәләр.

Фетнә Екатеринаның җиңүе белән тәмамлана (Дөресрәге, «бөек полководец» Суворовның җиңүе белән. *Тәрҗ. искәрмәсе.*)

Пугачев фетнәсеннән исән-имин котылгач Екатерина рәсми тәхет варисы саналган улы Павел һәм килене Наталья Алексеевна Гессен-Дармштадская белән Мәскәүгә килә, әмма халык аны, фетнәдән коткарган өчен кулдан үбәсе урынга, салкын кара чырай белән каршылый.

Тәхет варисы Павел Петрович — әбисе тиешле Елизавета Петровнаның иркәләвендә үскән кеше, ул үлгәч, үксез ятим калды. Әнисе Екатерина, үз баласы булса да, яратмый иде аны, шуңа күрә ул кыерсытылган боек бала булып үсте. Әнисенең фаворитлары да аяусыз рәвештә мыскыл итәләр аны, төрле әшәке сүзләр белән мәсхәрәлиләр һәм, иң гаҗәбе шунда, Екатеринага нишләптер ошый бу. Шулай булгач, Павелның үз әнисенә ни өчен тирән нәфрәт белән каравы аңлашыладыр. Өстәвенә, Екатерина, аның әтисен үтертеп, Павелга күчәргә тиеш тәхетне тартып алган иде!

Екатерина улын бик иртә башлы-күзле итә: Вильгельмина исемле Гессен-Дармштадт принцессасын чукындырып, Наталья Алексеевна дигән исем бирә. Павел үзе кебек үк кайнар идеалист һәм хыялый кызга бик нык ияләшә; ул балага бары тик унбиш кенә яшь әле.

Екатеринаның ничек яшәвен күзәтә торган һәм бигрәк тә Рәсәй халкының нинди авыр шартларда иза чигүен аңлый башлагач, Наталья бөтен җаны-тәне белән бианасының кан дошманына әйләнә. Ләкин бөртек чаклы тон күбәләгенең зур учак тирәсендә бөтерелүен хәтерләтә бу. Озакламый Екатеринага

Наталья Алексеевнаның Павелны, сарайда үз партиясен төзеп, тәхеткә үзе хуҗа булырга күндерүен җиткерәләр. Павел күптән «җинаятьче немец хатыныннан» (ул әнисен әнә шулай атый) әтисенең үлеме өчен үч алу өчен, тәхеттән бәреп төшереп, хурлыклы рәвештә аны монастырьга ябу турындагы хыялын йөрәк түрендә йөртә.

Ләкин Павел, яшьлеге аркасында, эч серен Панинга һәм башка шундый ышанычсыз кешеләргә ача. Екатеринаның шымчылары кайда да бар. Екатерина килененең башына җитәргә карар кыла һәм акыл сәләтенә бай Потемкиннан киңәш сорый. Фавориты патшабикәне Екатерина Зорич исемле кендек әбисе белән таныштыра: ул хатын яшерен бала төшертүдә һәм иртә «авыз иткән» хатын-кызларны уйнаштан туган балаларыннан коткаруда теше коелган кеше. Екатерина кан исе белән өретелгән эшләр белән кулын пычратырга яратмый иде, шуңа күрә ул четерекле мәшәкатьләрне фаворитына тапшыра.

— Киленемнең сәламәтлеге ташка үлчим генә,— ди Екатерина Зоричка һәм мәрхәмәтлек йөзеннән аңа кулын үбәргә рөхсәт итә.— Бала табу газапларын күтәрә алмас, дип куркам.

— Әйе шул, анакай, син хаклы, мөгаен күтәрә алмас! — дип ясалма авыр сулап, аңа Потемкин кушыла.— Бөек княгиня бултерек сарык бөтие кебек шундый зәгыйфь, шундый сыек бала!

Наталья Алексеевнаның ана булырга әзерләнеп яткан караваты аның үлем түшәгенә әйләнсен өчен фаворит белән кендек әбисе бөтен мәшәкатьләрне үз өсләренә алалар. Зоричны Потемкин томшык сарысы чыкмаган студент чагында ук үзенең соярксе иткән була, шуңа күрә ул аның алдында икеле-микеле кыланып маташмый:

— Бөек княгиня үләргә тиеш. Государыняга куркыныч кеше ул,— дип ачыктан-ачык аңлата ул түшәген суындырса да, арасын өзмәгән элекке соярксенә.

Бөек княгиняны тулгак тота башлагач, Зорич аның эчемлегенә әкренләп, ләкин котылгысыз тәэсир итә торган ачы сала: булачак ана да, аның бавыры астыннан якты дөньяга чыгарга ашыккан баласы да агуланалар.

Наталья үле бала таба һәм үзе дә шундук җан бирә.

Павел бу хәлдән соң, авыр кайгысыннан башын югалтып, өметсезлеккә төшә, әнисеннән шикләнеп, цесаревнаның тәнен ярып карауларын таләп итә. Ләкин ул берүзе берни дә эшли алмый инде, цесаревнаның гәүдәсен ярмыйнитми генә күмәләр. Ә Екатерина малаен хатынының бүтәннәр белән үзенә хыянәт итүенә ышандырырга тырыша. Шикләнергә урын калмасын өчен ул хәтта «оста куллы» колларының берсеннән цесаревнаның кулына охшатып язган ялган хатлар әзерләтә: хатының синең уфтануыңа лаек түгел иде, янәсе!

Өч айдан Павел Мария Федоровна исемле бер бик тә тар карашлы һәм куркак җанлы кызга өйләнә, ә бу килене, акылга сай булуы аркасында, Екатеринага куркыныч тудыра алмый.

Кырым кампаниясе башлангач Потемкин, урыс гаскәрләренең башлыгы буларак, Кырымга юнәлә. Бендер каласын алгач, Екатерина аңа, Очаковны да шулай ук җиңел алуына ышану билгесе итеп, зиннәтле энҗе-мәрҗәннәрдән генә эшләнгән зур чәчәк бәйләме бүләк итеп җибәрә.

Ә ул чәчәк бәйләме аларның икесе арасындагы мәхәббәтләре каберенә куела.

Потемкин Кырым татарлары белән илбасарларча сугыш алып барган арада, ирләрдән туймас Екатерина граф Безбородконың шәхси сәркатибе Заводскийны «соя» башлый.

Шул көннәрдә ул үзенең йокы бүлмәсенә уңайлылык өчен кайбер үзгәрешләр кертә. Аның караваты янына махсус пружинага зур көзге элеп куялар: аны кирәкмәгән чакта өскәрәк күтәртергә, ә кирәк икән — аска төшерергә мөмкин. Ә фаворитның караваты шул көзгенең артында гына тора. Әгәр дә бүлмәгә искәрмәгәндә кем дә булса килеп керсә, Екатерина шул көзгене тиз генә аска төшерә һәм кергән кеше аның артындагы икенче караватны күрми. Гади дә, уңайлы да!

Шулай итеп, дәүләт белән идарә итү эшләре көзге ярдәмендә гыйшыкмыйшык уеннарына тагын да ныграк якынлаша.

Бу вакытта патшабикәнең колак сердәше Екатерина Воронцова-Дашкова сарайдан читләштерелә инде.

Соңгы чорда Екатеринаның нәзек табигатьле дәртле нәфсесе яшь кызларга таба борыла. Потемкин аңа кайчандыр Молдовиядән бер бик тә үтә чибәр чегән кызы алып кайтып бүләк иткән иде, олыгая башлаган патшабикә, ниһаять, шуңа

гашыйк була. Ә Париж монастырьлары мәктәпләре үрнәгендә дворян кызлары өчен ачтырган Смольный институтының чыгарылыш имтиханнарында аның үткен күзе Суворовның кызына төшә. Кыз бик ошый аңа.

— Миңа бирегез кызыгызны,— ди ул атаклы генералиссимуска.

Суворов, тәҗрибәсез яшь кызның башын әйләндерерлек ыспай кавалерларның сарайда күп булуын сылтау итеп, катгый баш тарта.

— Курыкмагыз, мин аны үземнең йокы бүлмәмә урнаштырачакмын!— дип түземсезләнеп, тел төбендәге саксыз әйтеп ташлый Екатерина. Бүтәннәр кебек үк, Суворов бөтенесен дә: сарайдагы фаворитларны да, күзгеле ширманы да, әби патшаның соңгы вакытта лесбиянкалар мәхәббәте белән мавыгуын да яхшы белгәнгә, патшабикәнең бу шикле вәгъдәсе аны аз гына да тынычландырмый, әлбәттә. Койрыгын ныграк кыссаң, куян да шырпы кабызыр, ди. Кырыс карт моңа теше-тырнагы белән каршы төшә:

— Үлемем кирәк булса, мин синең өчен, ике дә уйлап тормыйча, җанымны корбан итәм, государыня анакай,— диде ул.— Ә Суворовочкамны сиңа бирмим!

Екатерина ачуына буылып, беравык тын алыштыра алмыйча тора. Шулай да ул үзсүзле карттан кызын көчләп тартып алырга кыймый. Суворов урынында берәр кол яисә холоп булса, сөйләшеп тә тормас иде ул. Дворян иде шул бу минсенгән карт, ә югары катлам арасында ризасызлык кузгату бик хәтәр нәрсә. Императрица йөзен чытып булса да Суворовны, майлы калҗа кебек тоелган кызы белән бергә, аны сарайга якын китерүне дә тыеп ерак биләмәләренең берсенә сөрдә. Хәер, карт сугышчы моңа бары куанды гына: үз чүплегендә әтәч тә үзе мирза, диләр ич!

Екатеринаның сөяркәсез бер көн дә түзә алмавын яхшы белгән Потемкин үзе юк чакта адъютантларын аңа «урынбасарлар» итеп калдыра. Алар сыңар күзле түрәләренә беркайчан да аяк чалмаячаклар. Ләкин урыслар, изге урын буш тормас, диләр...

1780 елда Потемкин очраклы рәвештә Ланской исемле бер бик чибәр егетне күреп кала һәм аны императрицага күрсәтә. Тышкы кыяфәте белән егет Гамлетны хәтерләтә. Тирән сагыш тулы хыялый зәңгәр күзләре һәркемнең игътибарын үзенә җәлеп итеп тора. Киләчәктә үзен көткән аянычлы язмышын сизенгәндер, бичара. Аз гына алсуланып торган, сакал да чыкмаган, сөт кебек ап-ак йөз, мәрҗән кебек матур тешле кечкенә авыз, аксыл-бөдрә чәчләр, карлыгач канатыдай кыйгач кара кашлар. Ланскойны яп-яшь чибәр кызга охшаталар. Шул ук вакытта ул киң җилкәле, тыгыз ботлы, зур гәүдәле кеше. Рәсемдәге кебек, фәрештә йөзле андый ирләр һәр хатын-кызга да бертигез ошамый. Екатеринаны һәрвакыт бераз кырысрак, ирләрчә гайрәтле кыяфәтләр үзенә тартучан. Ләкин, «аш тәрләндерү» йөзеннән, нишләп әле, кыска вакытка булса да, хатынҗәмәкне хәтерләткән кыяфәтле, егерме яшьлек малайны алмаска? Бу сөер егеттән башка аның, чын наз өчен, Панины, Потемкины, Безбородкасы, Корсаковы һәм Хвостовы бар ич, ә алар берсе дә йөзләре белән хатын-кызны хәтерләтми. Ланской бөек государынясының мәрхәмәтеннән баш тартырга базмый: ул, әби патшаның кәнизәге булудан гарьләнсә дә, артык нык басынкы кеше булганга күрә, Екатеринаның сүзеннән чыга алмый. Хәер, аның яшендәге егетләргә үзеннән өлкәнрәк хатыннар ошыйрак та төшә бит. Чикләнмәгән хокуклы хакимәнең капризы озакка сузылмас, үтәр... Ләкин, беркем көтмәгәндә, кыска вакытка гына шаярып алырга теләгән падишаның картаеп килүче җанында чын-чынлап яз чәчәге ата башламасынмы! Шушы артык оялчан, нечкә билле чикерткә революцияләр башлануы куркынычын да, Польша белән булган кичектергесез җитди эшләрне дә, тынгысыз Потемкинның Һиндстанга яу белән барырга хыялланып, тинтерәтүләрен дә оныттыра. Ланской, бәлки, Екатеринага чаклы хатын-кызлар затын бөтенләй татып карамагандыр. Ул Екатеринага, анасына берекккән яшь бала кебек, бик нык иялөште, чын күңеленнән аның белән иркәләнә, назлана.

Екатерина Ланскойны, төрек солтаннары үзләренең яраткан кәнизәкләрен күз карасыдай саклап тоткан кебек, биклəп асрый башлый: ул аны хәтта «авыз итеп караучы» графиня Брюска да күрсәтми. Яшь егетнең күңелен аздырырга әзер торучы козгын хатыннар бик күп шул сарайда! Екатерина бердәнбер фрейлина Протасовага гына шикләнмичә ышана ала.

Ланскойны императрица колак ишетмәгән, күз күрмәгән зиннәтле байлык һәм алтын-көмешләргә күмеп ташлый. Екатерина аны, гадәттәгечә, граф титу-

лы, иксез-чиксез җирләр, дистәләрчә мең крепостной крестияннәр һәм флигель-адъютант чины кабул итәргә мәҗбүр итсә дә, ул сәясәткә һәм ил белән идарә итүгә катнашудан баш тарткан бердәнбер фаворит була. Шушы Адонис хатын-кызларга гына хас нечкә күңеле һәм шагыйрәне назлы иркәләве белән үзенә шулкадәр нык иялəштерә ки, патшабикә еш кына, чалара башлаган башын аның киң җилкәсенә куеп, елый да икән.

— Бүтәннәргә булган бөтен үпкәләремне күз яшем белән агызып чыгарып бетерәсем килә,— ди императрица андый чакларда.

Ниһаять, 55 яшьлек Екатерина, бүтән андый кайнар мәхәббәтне үлгәнче таба алмаячакмын, дигән фикергә килә. Карт хатын иде инде ул. Аның тынгысыз йөрәге əзләнүләрдән тәмам арыды. Хәзер теләгәнен шушы адашып килеп кергән малайда тапкан кебек тоела иде аңа.

Көтмәгәндә генә императрица, Панин белән Потемкинны чакыртып, аларга бөтен җаны-тәне белән үзенә бирелгәнлеген тиешенчә бәяләү йөзеннән һәм мәңге үзенеке итәр өчен, Ланскойга кияүгә чыгарга теләве турында белдерә.

— Ул миңа беркайчан да хыянәт итмәде,— ди ул Потемкинның күзенә туп-туры карап.

Потемкин кинаяне бик яхшы аңлый. Ул үзе «анакаена» бер генә мәртәбә хыянәт итмәде ич.

Бу тарихи сөйләшү 1784 елның маенда була. Ә бер айдан... ярәшелгән егет Ланскойны ниндидер сәер чир газапларга тотына, табиплар моны берничек тә аңлата алмыйлар. Бәхетсез егетне циклоп Потемкин агуларга кушкан иде: акылын җуйган императрица аны артыграк ярата башлады шул...

Шушы хәлләрдән соң, Екатеринаның мәхәббәт маҗаралары турындагы сарай елъязмаларында кеше ышанмаслык ак тап хасил була: фаворитлар бүлмәсендә тоташ биш ай буе ир-ат затыннан бер кеше дә күренми!

Әмма Екатерина, нинди генә авыр булмасын, кайгылардан һәм югалтулардан сыгылып төшә торгач зәгыйфь ихтыярлы натуралардан түгел. Биш айдан соң аңарда кабат гадәти шат күңел, яңа кешеләр белән аралашуга омтылу һәм хатын-кыз бәхетенә сусау уяна. Гомерне күз яше түгеп үткәрү аның өчен ят нәрсә. Тик, шулай да, тирән кайгы аңа дәүләт эшләренә җитди игътибар бирергә комачаулый. Эшлекле Потемкин патшабикәнең йөрәгеннән мәрхүм Ланскойның истәлеген кысрыклап чыгарырга карар кыла.

Ланскойга алмаш табу ниятеннән ул гвардия офицерлары белән таныша башлый, аларның характерларын, фигыль-холыкларын күзәтә. Тиздән Потемкин Петр Ермолов белән Александр Мамоновка туктала. Ул кичекмәстән аларның икесен дә берьюлы үзенең адъютантлары итеп билгели һәм Ермоловны, юк йомышны бар итеп, императрица янына җибәрә.

Гап-гади офицер, әмма аның тышкы кыяфәте ниндидер сәерлеге белән күз явын тартып тора. Сарайда аны, ак зәнҗи, дип йөртәләр. Ап-ак, әмма Африка зәнҗиләренә генә хас бөдрә чәч, калку яңаклар, дәрт ташып торган калын иреннәр һәм кар кебек елтыр тешләр. Ә Екатерина үбешергә чакырып торгандай калын иреннәр янышан тыныч кына уза алмый.

Хисси кабарынкы иреннәре белән җелеп итеп торган ак зәнҗине күргә, Екатерина үзенең йөрәгендә кабат җәй башлануын, әле һаман да яшьләрчә назлы мәхәббәттән, кайнар иркәләүләрдән башка яши алмавын аңлый. Ә берничә көннән Ермолов, тулы хокуклы флигель-адъютантка әверелеп, биш ай элек кенә нечкә күңелле, тыйнак һәм онытылмас Ланской яшәгән затлыдан затлы бүлмәләргә кереп урнаша инде.

Моны ишеткәч, хәйләкәр Потемкин, сыңар күзен елтыратып, канәгать елмая, ләкин ак зәнҗи Ермолов, Ланской кебек, сак астында дөньядан аерылып яшәргә теләми, биллиард, кәрт уеннарын үлеп ярата ул һәм еш кына, сарайны ташлап, шундый дәртле уеннар оясына, җилбәзәк хатын-кызлар янына чыгып ычкына.

Әлбәттә, Екатеринага ошамый бу. Махсус эшләгәндәй, Потемкин нәкъ шул вакытта аның янына үзенең икенче адъютантын, Александр Мамоновны җибәрә: монысы да Екатеринага бик ошап кала.

Ермоловның кулына йөз мең тәңкә акча салалар һәм ул да, барлык вакытлы фаворитлар кебек үк, Петербургка яңадан аяк басмаска кушылган катгый әмер ала. Аның җылы урынына, суынганчы, Мамонов менеп кунаклый. Хәер, императрицаның йокы бүлмәсе дип аталган «бәхет кунасына» менү өчен бәркет канатлары кирәкми, артык озын булмаган бормалы-сырмалы баскычтан

күтәрелү дә җитә. Арттан аларны башлап «авыз итүче» Брюс ханым да этеп тора әле җитмәсә!

Кирәк бит, яңа пешкән фаворит шундук үзен җирдәге алиһә янына күтәрелергә беренче булып ярдәм иткән Потемкин алдында ачу китергеч дорфа тота башламасынмы! Искиткеч түбән җанлылык һәм тар күңеллелек бит бу, әмма Мамонов императрицага моны циклоптан көнләшүе белән аңлата. Болай аклануы патшабикәнең җанын балавыз кебек эретә. Үзе өчен ирләр көнләшкәнгә нинди генә хатын-кыз битараф калыр икән?!

Екатерина Мамоновның, Таврида каһарманы Потемкинны мыскыллап, тупас рәвештә әшәкеләнүен туктату гына түгел, киресенчә, фаворитларның өстәл артында, сөяк бүлә алмаган этләр кебек, ызгышуларын куанып бетә алмыйча күзәтеп утыра. Потемкин, күпме генә көч түксә дә, алыптай олы гәүдәле, калмыкка охшаган Мамоновның ныгып килгән урынын зәррә кадәр дә кымшата алмый...

Хәзер Рәсәйдә бер генә җитди вакыйга да Мамоновтан башка булмый инде: Екатерина аны хәтта бөтен дөньяны дер селкетеп торган канцлер Безбородко урынына куярга уйлап йөри. Ә бит нәкъ әнә шул «Рәсәй Вольтеры», гайрәткә һәм акыл сәләтенә бай Безбородко, Кечерусияне мәңгегә коллыкка төшерер өчен, көчле һәм хәйләкәр Кирилл Разумовскийны гетманлыктан алып ташлап, кырык мең хохолны үзенә крепостной иткән иде! Ә Кырымны яулатып, анда шәхси тоз кайнату заводлары ачтыруы?! Чит илләр белән бөере аша гына сөйләшүе?! Безбородко сәнәктән көрәк булган нindидер Мамоновка бирелүне үзе өчен түбәнлек саный һәм ул аңа каршы аяусыз көрәш ача. Ә Мамонов көннән-көн көчлерәк һәм оятсызрак була бара. Хәтта Польша короле Понятовский аңа ике иң югары орден җибәрә.

Мамоновның киң күкрәгендә һәрберсе йөзәр мең торган сансыз күп брильянтлар белән бизәлгән Александр Невский ордены балкый берзаман.

## Әби патшаның соңгы сәяркәләре

Картлык көннәре җиткәч, императрица Екатерина «үзенең хуҗалыгын» барлап чыгарга, ягъни Рәсәй буйлап сәфәр кылып кайтырга карар бирә.

Моны ишеткәч, аңынчы бака күлендәге ләкләк кебек тыныч яткан алпавытлар куркуга төшәләр, хәер, власть башында торучы «дөнья хуҗалары» да шыр җибәрәләр. Әби патшаның фаворитлары, тиз генә киңәш мәҗлесе җыеп, сәяхәт иткәндә патшабикә күңелен күтәрерлек берни дә очратмаска тиеш, дигән уртак фикергә киләләр. Крәстияннәрне һәм башка вак-төяк халыкны катгый кисәтеп куялар: кем дә кем берәр төрле зары белән Екатерина каршына килсә, пешкән таяк белән суктырылып, яисә башка төрле газап белән җәзалап үтереләчәк!

Екатеринаның патшалык буйлап сәяхәт итүен тоташ бер бәйрәмгә әйләндерделәр: патшабикәне кайда да бәйрәмчә матур киенгән шат крәстияннәр ипи-тоз белән каршы ала, үзләренең тормышлары белән канәгать булуларын кат-кат әйтеп рәхмәт укый, өсләреннән хакимлек иткән алпавытларын кылган мәрхәмәтлекләре өчен күкләргә күтәреп мактый!

— Менә күрәсезме инде, аларга ирекнең кирәге дә юк, алар үзләрен кол хайван хәлендә дә бик яхшы хис итәләр! — ди Екатерина, борынын җыерып, үзен озатып йөрүче сәяркәләре Потемкин белән Мамоновка. Тантаналы каршылауны никадәр матур оештыра алуны бигрәк тә граф Петр Борисович Шереметьев күрсәтә. Ниләр генә булмый анда! Екатеринага иң нык ошап калганы шул була: крепостной артистларның балетыннан соң, граф әби патша белән аның сәяркәләренә тәпиләренә сүс уралган ак күгәрченнәр тоттыра һәм аларны ирекке очырып җибәрүләрен үтенә. Куркып калган кошлар бердәм югарыга томырылалар. Шулвакыт төнге караңгы күктә, Екатеринаның вензелен ясап, балкыш дөрли башлый...

Диңгез артларыннан махсус кайтарылган затлы ризыклардан гына торган төшке аш графка илле меңгә төшә...

Канев шәһәрендә патшабикәне Август Понятовский каршы ала. Рәсәй тәхетендә утырган карчыкны кабул итү элекке сәяркәсенең кесәсен өч миллионга җиңеләйтә. Хәер, бу вакытта Понятовскийның үз башында да таҗ бар инде, Польша короле була торып, кесәләре буш тормас...

Озак сәфәр кадерле хатынны алҗытмасын өчен, Потемкин кулыннан килгәннең бөтенесен дә эшли, тошләрдә яисә хыялда гына күз алдына килердәй уңайлыклар уйлап таба. Патшабикәнең алтын йөгертелгән көймәле арбасына утыз шеп ат җигәләр. Арба берничә бүлектән тора: берсе императрица кабинеты, икенчесе сигез кешелек кунакханә, аш бүлмәсе, зур булмаган китапханә, бәдрәф һәм башка шуның ише уңайлыклар җитәрлек була.

Потемкин белән Мамонов патшабикәне тарихи сәяхәткә өзерләргә казнадан бирелгән акчаның санап бетергесезен янга калдырып өлгерәләр. Хәер, Кечерусиядәге Безбородко да алардан калышмый.

Шунлыктан, Екатеринаның күңелле сәяхәтенең Рәсәй халкына дүрт миллионга төшүе бер дә гаҗәп түгел.

Екатерина бу сәяхәтеннән Петербургка бик нык канәгатьләнеп кайтып керә: фаворитлары белән бергә көне-төне кайгыртуы аркасында Рәсәй әнә ничек чәчәк атып утыра ич! Димәк, хәзер ул кадерле вакытын сөяркәләренә күбрәк бүлә ала.

Тик алары соңгы вакытта, нишләптер, «кәҗәләнә» башладылар шул. Мамонов та, Ланской кебек үк, үз хәленнән үзе бик нык ояла. Шуңа күрә, ахры, ул патшабикәдән артыгы белән түләтергә дә тырыша. Акчалата да, башкача да. Гомумән, Екатеринага сөяркәләре бушка килмәделәр: Мамоновка чаклы гына да, аларның койсез күңелен күрер өчен, ул дүрт йөз миллионнан артык акча тоткан иде инде! (Ул чорда бер сыерның уртача оч тәңкә торганын искә алсак, бу акчаларның күләмен чамаларга була. Тәрж. искәрмәсе.)

Мамоновтан тугрылык таләп итсә дә, Екатерина үзе вакыт-вакыт һаман да «аш тәрләндереп» алгалый: бер төнен ул, атап әйткәндә, мәсәлән, парадта очраклы күреп калган Казаринов исемле бер яшь офицер белән үткәрә һәм иртәсен аңа, азыклы ат арымас, дип, дүрт йөз мең торган биләмә бүләк итә.

Императрица анча исәпсез-хисапсыз күп акчаларны үз кесәсеннән алмый, әлбәттә. Әмма Екатерина, күпме генә бүләкләр бирмәсен, абайламастан атлытунлыга әйләнгән Мамоновның йөрәген сатып ала алмый: үзенә күрә туры сүзле, саф йөрәкле кеше ул. Һәм әнә шул туры сүзлелеге харап итә дә инде аны.

Күптән түгелрәк кенә Екатерина үзенә хезмәткә княжна Елисавета Щербатова дигән бик яшь бер фрейлинаны алган була. Аңа унҗиде яшь һәм ул, Мамонов кебек, беркая да чыкмыйча, сарайда тора. Патша авылы сараенда сак астында яшәүче фаворит белән фрейлина, язмышлары охшаш булгангамы, еш кына очрашалар һәм алар озакламый, бер-берсен аңлашып, кайнар сөешә башлыйлар. Унҗиде яшьлек зифа буйлы сөйгән кызы белән чагыштырганда, юан гәүдәле карт Екатерина Мамоновка күңел болгандыргыч җирәнеч булып тоела. Көннәрдән бер көнне ул Щербатова янында бик соңлап, караңгы төшкәч кенә кайтып керә. Аны көтә-көтә көтек булган Екатерина, яшь кызларча кыланып, аңа үпкәсен белдерә һәм, йомшарып, гадәтенчә кочагын җәя. Әмма Мамонов ишек төбеннән ары кузгалмый.

— Государыня-анакай,— ди ул бераз таптанып торгач,— мин һәрвакыт туры сүзле булдым. Мин хәзер, моннан соң сезнең белән, бөек галиҗанәб, үземә йөкләнгән изге вазифаны үти алмыйм.

Мондый мәсхәрәне Екатерина көтми, әлбәттә. Ничек инде шушы ахмак үз теләге белән патшабикәсеннән баш тарта? Екатерина андый мөгаләмәгә күнекмәгән! Яшерен-батырын түгел, Ланскойдан башкалар барысы да, качып-посып булса да, Екатеринага хыянәт итәләр иде. Ләкин бит алар, патшабикәләренең бөек мәрхәмәтен югалтудан куркып, сирәк-мирәк бәхетләренә тигән мәхәббәт маҗараларын аңа белдермәскә тырышалар иде һәм алар беркайчан да буйсынудан чыкмадылар.

Екатеринаның тавышыннан бозлы салкын бөргән кебек була:

— Ни булды, мохтәрәм әфәнде?—дип сорый ул, горур башын югары чөеп.—Сез онытыласыз!

— Мин бүтәнне сөям, бөек галиҗанәб.

— Кемне?

— Княжна Елисавета Щербатованы. Мин сездән, бөек галиҗанәб, аның белән никахлашырга рөхсәт итүегезне сорыйм. Безнең бүгенге хәлебез шуңа мәҗбүр итә.

— Яхшы. Рөхсәт итәм. Ләкин алдан ук сезгә белдереп куям: мин сезне ватанга каршы җинаять эшләүче кеше дип саныйм. Минем гомеремнең Рәсәйгә нинди кадерле икәнен яхшы белүегезгә карамастан, патшабикәгезнең кәефен

кырасыз, ә минем күңел тынычлыгым һәм кәефемнең югары булуы дәүләт өчен кирәк.

Мамонов кызарып баш ия һәм утлы табага баскандай чыгып йөгерә.

Рияллы сөяркәсе чыгып киткәч, Екатерина сарайдагы бер асрау кызны исенә төшерә: кайчандыр аңа Потемкин гашыйк булган иде. Ул чакта патшабикә яшерен канцеляриягә җитәкләүче Шешковскийдан шул оятсыз кызны кая да булса олактыруын үтенде. Юк, кызны үтерергә кушмады ул, ул бары тик бөек патшабикәсенә көндәш булырга базган кызны кая да булса мәңгегә ябып куярга гына кушты. Яшәсен, тик аннан ул беркайчан да чыкмасын гына.

Шешковский артыграк тырышып ташлады. Ул теге мескен кызны төзелеп яткан таш дивар эчендә баскан килеш күмеп калдырырга боерган. Аннан ул кыз, чынлап та, беркайчан да чыга алмады. Хезмәтчеләре артык ярарга тырышканга патшабикә үзе гаеплемени? Петр III не, законлы үз ирен, ул үтерергә куштымы? Беркайчан да. Орловлар үзләре башбаштакланып хәл иткәннәр.

Екатерина авыр сулап куя. Мамонов сөйгән патшабикәсен явызларча мәсхәрә итте. Күз карашын гына алыйк! Екатерина Мамоновның күзләрендә күптән яшереп йөргән җирәнү хисен ап-ачык күрде... Үч, кичекмәстән үч алырга кирәк!..

Императрица бик озак баш вата һәм, ниһаять, уйлап таба. Екатеринаның теләге буенча, Мамоновның туен, бик зурлап һәм затлы итеп, сарайда үткәрәләр. Шүрләп, мескенләнеп калган Лизаньканы туйга императрица үзе киендерә, бөхет әҗәре итеп, аңа ун мең тәңкә алтын, ә яшь кияүгә өч мең крепостной крәстиян бүләк итә һәм, аларга өстәп, бәяләп бетерә алмаслык кыйммәт ике бриллиант балдак бирә.

Туйлар узгач, ике атнадан соң Мамоновларның Мәскәүдәге йортларына (Екатерина, гадәтенчә, аларны Петербургтан сөргән иде) төн уртасында солдатлар бәреп керә. Алар күз ачып йомганчы граф белән графиняны путалар белән бәйләп ташлыйлар. Мамонов, исенә килеп, кычкырып җибәрә, ләкин аны таныш бер тавыш туктата:

— Тынычсызны чыгармагыз, хөрмәтле әфәнде. Барыбер файдасыз. Монда керергә беркемнең дә кыюлыгы җитмәячәк.

Мамонов Мәскәү полицмейстрының тавышын таныды.

— Ни хакыгыз бар сезнең безне бәйләргә? — дип сорый Мамонов, өне алынып.

— Без монда государыня кушуы буенча, ә аның әмере алдында бар хокуклар да тез чүгә.

Мамоновны, канәфигә күчереп, бәйләп куялар. Лампага ут алалар... Сөеклe хатынының күлмәген умырып төшерәләр... Яшь хатынның ачыргаланып кычкырган тавышына, чынлап та, беркем дә йөгереп керми. Бичараны ире алдында солдатлар башта туйганчы чиратлап чыга, аннан соң аркасы тоташ кара канга әйләнгәнче каеш чыбыркы белән яралар. Мамонов алдында әдәп саклап сөйләшкән полицмейстер белән солдатлар чыгып киткәндә графиня һушсыз ята. Шуннан соң гына йорт хезмәтчеләре, кереп, хуҗаларын чишәләр. Екатеринаның «мәрхәмәтен» татыган ир белән хатын бик озак чирләп түшәктә ята. Ә терелгәч алар, «падиша әмере алдында барлык хокуклар тез чүгә» торган туган илләрен калдырып, мәңгегә чит илгә китеп баралар...

Яңа фаворит — дан-шөһрәт сөючән һәм тәккәббер Платон Зубов озакламый үзенең бертуганы Валерьяны, императрицаның кайнар йөрәгеннән кысрыклап чыгарып, берүзе кала. Платонга ул вакытта нибары егерме өч кенә яшь, шуңа карамастан ул алдын-артын салкын канлылык белән нык уйлап эш итүче, битенә дуңгыз тиресе каплаган циник кеше була. Императрицаны ул бик тиз арада үз кубызына биетә башлый. Ни гаҗәп, тәҗрибәле Екатерина аның теләсә нинди дуамал теләгән үтәргә әзер тора.

Императрица Платон Зубов белән чуала башлаганда аның циклопы Потемкин Яссы каласында була. Екатерина керткән йола тарифы буенча, сөяркәләрә, гадәттә, башта граф титулы гына алалар, берәр искитмәле батырлык күрсәтә алсалар инде, дәрәҗәләре дә зурая төшә. Ә Зубовны ул, өч көн эчендә, өч сугыш каһарманы саналган һәм Новороссия белән Кырымны басып алган герой Потемкинга бериш итеп тиңли. Кемне диген әле, ватанга өч тиенлек тә файда китермәгән бер маңка малайны! Потемкин, моны ишеткәч, ачуыннан шартлардай булып кара көеп чыга: йортындагы бөтен савыт-сабаларны, җиһазларны

бөреп вата, бер гаепсезгә, тик торганда, барлык йорт хезмәтчеләрен, хәтта өзелеп сөйгән кенизәген дә тукмап ташлый.

— Йә мин, йә — Зубов! Икебезнең беребез үләргә тиеш!

Потемкин, бөек княгиня Наталья Алексеевнаны, Ланскойны һәм тагын бүтәннәрне ачы бирeп үтерткән кебек (тарих башкаларның исемнәрен сакламаган), Зубовны да зәһәр ашатып дөмектерергә була. Ул үзенең юлына киртә булган кешеләрне ничек алып ташлау турында ике уйлап, баш ватып торучылардан түгел. Потемкин, шундук ат җиктереп, Петербургка чаба... Әмма Зубовның гомер кояшы сүнмәгән булган икән, гайрәтле Потемкин юлында очраган беренче тукталышта ук, йөрәге ярылып, җан тәслим кыла...

Потемкин кинәт үлгәннән соң, Екатеринаның актыккы көненә кадәр Рәсәйдә һәм сансыз күп зиннәтле патша сарайларында Платон Зубов идарә итә. Рәсәйнең топ хуҗасы да шул елгыр егет була. Тәкәббрлектә һәм купаюда Рәсәйдә аңардан да арттырып җибәргән кеше булмагандыр. Министрлар белән, хәтта күпмедер ел тәхет варисы булып, соңыннан үзсүзле әнисе тарафыннан читләштерелгән Павел Петрович белән дә ул, иң түбән дәрәҗәле лакей белән сөйләшкән кебек, сүзен теш арасыннан сөзеп кенә сөйләшә. Дөрес, моның өчен ул бер генә кат үкенмәдe: тәхетка менгән Павел Петровичның гафу итүен ялварып, аягы астында атналар буе аунарга туры килде аңа! Ләкин болар соңрак. Әлегә илгә ул үзе муен, үзе баш. Хәер, бу чорда Екатерина үзе дә, чиксез власте белән масаю һәм тәкәбберлек дигәндә, ким-хур түгел. Бөтен Аурупаның күзен кызыктырган Польшаны төрле илләр арасында бүлгәләгәч, Варшавадан әби патшага Польша корольләренең гасырлар буе берсеннән берсенә күчеп килгән алтын тәхетен ганимәт итеп алып кайтып бирәләр. Иң соңгы булып, шул тәхеттә аның элекке сөяркәсе Август Понятовский утырган була. Сарай халкына Понятовскийны ничек «хөрмәт итүен» күрсәтер өчен Екатерина полякларның горурлыгы булган шул тәхетнең уртасына тишек тиштерә һәм, «хаҗәтен башкарганда» уңайлы булыр, дип бәдрәфенә куйдырта! Сәгате суккач, әнә шул уңайлы урында утырганда җан бирә дә инде ул...

Платон Зубовның доньяда иң нык яратканы — акча. Аннан да комсыз кара бай һәм убыр кебек казнаны камсап имгән кеше әби патша тирәсендә булмагандыр. Ланской, Мамонов кебекләр, Потемкинны әйткән дә юк, сәнгать белән мавыгып, рәсемнәр, сыннар һәм шуның ише сәнгать әйберләре җыйса, аның бер белгәне Екатеринадан үзенә һәм якын туганнарына билә мәләр, крепостной крәстияннәр һәм акча теләнү иде. Ике ел эчендә генә дә ул патшабикәдән өч миллион ярым көмеш акча суырып ала, ә бу кайбер борынгы бөек нәселләрнең гасырлар буе җыйган бөтен байлыгына тиң. Иксез-чиксез җирләрен һәм крәстияннәрен санаган да юк.

Хәер, әби патшаның сөяркәләрен, берсен мактап, берсен хурлап тору дөреслеккә хилаф булыр: Потемкин белән Безбородко гына да, дәүләт белән идарә иткәндә, мөмкинлектән файдаланып урлаудан тыш кына да, иллешәр миллион сум акча өрәм-шәрәм итеп бетерәләр.

Биш бертуган Орловлар Екатеринага унҗиде миллионга төшәләр. Шулай ук, иксез-чиксез җирләрне һәм акчага сатыла торган крәстияннәрне исәпкә кертмичә.

Ланской чагыштырмача очсызрак, сигез миллионга гына төшә, ә инде тагын да кайтышрак Корсаков белән Зоричны искә алып тору да кирәкмидер: бер-ике төнлек сөяркәләргә бирәр миллионышар да башларыннан ашкан!

Васильчиковка җиде мең крәстиян, зиннәтле зур мәрмәр сарай, ярты миллионлык алтын-көмеш савыт-саба һәм ел саен бирелә торган егерме мең тәңкә пенсия әләгә.

Ә менә Потемкинга зарланырлык урын калмаган булырга тиеш: алдарак әйтеп үткән илле миллион акчадан һәм санын үзеннән башка беркем белмәгән урлаудан тыш, патшабикә аңа, үз кулы белән язып, кырык мең крәстиян, тугыз миллионлык алтын-көмеш савыт-саба, энҗе-мәрҗән әйберләр белән зиннәтле җиһазландырылган зур мәрмәр сарайлар бирә.

Орловлар да язмышларына үпкәли алмый: аларга, бишесенә, җәмгысы илле мең крәстиян, унҗиде миллионлык алтын-көмештән ясалган савыт-саба һәм зиннәтле биек сарайлар тия...

Рәсми фаворитларыннан башка, игътибар иткәнсездер, әби патшаның бер көнлек төн дуспары күпме булуын беркем дә санамаган. Аның караvы, ул

«бәхетле» төн кошлары үзләре кайнар назларының әби патшага күпмегә төшкәнен тәфсилләп сөйләп бирә алырлар иде: кагыйдә буларак, патшабикә андыйларга кимендә йөзәр мең акча, зур биләмә, мең крепостной крәстиян һәм алар үлгәнче түләнәчәк зур пенсия билгеләгән. Ишеткән белән күргән бер түгел, без монда колакка кергәннәрне генә сөйлибез.

Фаворитларга тигән җирләрнең чын бәясен шул чор кешеләре генә әйбәт белгәннәрдер, безгә аларның исәпсез зур акча торганлыгы гына ачык билгеле, ә менә бер крепостной крәстияннең бәһасе безгә килеп җиткән: җан башына көмеш өч йөз тәңкә түләгәннәр! Димәк, казна байлыгына күсе кебек ияләшкән Орловларга гына да унбиш миллионлык коллар җаны тигән...

Ә хәзер, чагыштырып карар өчен, тагын бер санны хөтерегезгә төшерергә рөхсәт итегез: Бөек Екатерина II заманында Рәсәй патшалыгының бер еллык бөтен дәүләт бюджеты 80 миллион чамасы булган...

1794 елда бар Рәсәй бердән зар елый: элекке хәерче немец принцессасы Софья-Августа-Фредерика-Эмелия (Екатеринаның немец чиркәве биргән исеме әнә шундый) соңрак уннарча күрше халыкны, империягә «кушып» бәхетле иткән Бөек Екатерина дөньяны һәм дистәләгән сәяркәләрен ятим калдыра.

Русчадан **Ризван ХӘМИД** тәрҗемәсе.

♣♣♣♣♣♣♣♣♣♣

*Киләсе санда*

## Әхмәт Тимер: Бөек шәхесләребезнең берсе

«Ата милләтче», «пантөркист», «пантөркизмнең атасы» дип тамгаланган, «изүче сыйныф вәкиле», «фабрикант токымы», «татар буржуйлары партиясенә нигез салучы» дип сүгелгән Йосыф Акчурага багышланган мәкалә шулай атала.

Ни өчен Йосыф Акчура Төркия парламентына берничә мәртәбә депутат итеп сайланган? Күп кенә илләрнең хөкүмәт башлыклары Й. Акчураны нилектән һәрвакыт хөрмәт белән кабул иткәннәр? Аның вафаты уңаеннан Истанбул университеты ни өчен бөтен дәресләрне туктатып, кайгы көне игълан кылган?

**Бу сорауга җавапны журналыбызның 12 санынннан әлеге мәкаләне укып табарсыз.**

# Мөнир Вафин

## Табигать мине кабатлый

Табигать мине кабатлый:
Мин көләм — Кояш көлә;
Мин елыйм, мине уздырып,
Елый яңгыры белән...

Мин сызам — табигать моңсу,
Мин очам — канатлана...
Картаеп, китсәм беркөн мин —
Монысын кабатламас...

* * *

Телләрдән богаулар алынды,
Сөйлибез кушмыйча, тыймыйча.
Телләрне тыймагач иркенлек,—
Дулыйлар авызга сыймыйча.

Яше юк, карты юк — тигезлек.
Тавышы көчлеләр заманы.
Вакыттыр адәмнәр затына,
Яхшыдан аеру яманны.

Ил гүя олы бер трибуна.
Бар халык — докладчы оратор.
Тыңлаучы кешеләр юк икән,
Ходайны үзенә каратыр.

Дулыйлар уздырып бер-берсен,
Күп еллар дәшмәгән өчендер...
И акыл, туктатып барсын да,
Телләргә үз эшен төшендер.

* * *

*(Шаяру)*

Төннәр буе сине кочам,
Их, йомшаксың барыннан!
Ахры кендек бәйләнгәндер
Аерылгач та карыннан.
Соңгы сулышкача бергә.
Аерым тик көндезләрен!..
Бу дөньяда ярый син бар,
Рәхмәт сиңа... мендәрем!

---

Мөнир ВАФИН — *Уфада яшәүче яшь шагыйрь. Шигырьләре көндәлек матбугатта күренә килә.*

* * *

Күзләреңдә мин үземне күрәм.
Йомма син аларны,
Йомма, түз.

...Гомер буе шәүләңне йөретә
Шул чакта йоммаган
Минем күз.

## Чәчләрең

Һәр миңеңне, күзләреңне сөйдем,
Җаваплады шулай алар да.
Безнең мәхәббәткә сокланган дай,
Пар күгәрчен йөрде яннарда.

Шундый була икән ул сөюләр:
Бер-берсен сөйде чәчләр дә.
Чәчләр сөйде, ләкин башка уйлар
Кузгалдылар тиле башларда.

Һәм син киттең, соңгы кабат та бит,
Борылмадың хәтта артыңа.
Ә чәчләрең һаман минем якка,
Хуш, сөеклем, диеп тартыла.

* * *

*Бер кискән икмәк телеме*
*кабат ябышмый.*

*Халык мәкале.*

Киселгән икмәк шикелле,
Бер гаилә киселде.
Бер якта хатын кисәге,
Ә бер якта ир иде.

Кайда тартылырга белми,
Коелып калды валчык.
...Телемнәр бик тиз каттылар,
Валчыкны йотты... балчык.

## Һәркемнең үз байлыгы

Нәни Самат өчен уенчыклар:
Машинасы, тубы, атлары.

Әнисенә — йөзек, алка салган
Шкатулкалары, каплары.

Әбисенә — сандык төбендәге
Өчпочмаклы солдат хатлары...

# Марис Нәзиров

## Чакматаш

Тәү карауга гади таш —
Боздай салкын чакматаш.

Берсен бәрсәң берсенә —
Мең-мең чаткы күренә.

Гөлт итеп ут үреләә.

...Йә, бәрел күңелемә!

## Нидер булыр кебек

Тагын ниләр күрәсем бар килер көндә?

Изүләрем ачып, каршы чабам җилгә,
Җилдәй җитез чаптар атта күптән җиләм...

Әле ярсып, боздай җаным эри назга,
Кабатланыр диеп яшьлектәге язлар.

Яз бөресе кебек, күңелемдә өмет
Яфрак булып яралырга тора, көлеп...

Тагын нидер булыр кебек тиздән:
Кабынырга әзер мин бер җылы сүздән...

## Йорт казлары

Кыйгак... Кыйгак...
Кыр казлары оча җырлап,
Кайтаваздай тынлык ярып,
Канатларны көчле кагып.
Юл ала әллә кайларга,
Югала ашып тауларга.

Кыйгак... Кыйгак...
Алар киткән якка карап,
Йорт казлары йөри чабып,
Канатканчы канат кагып.
Омтылганда болытларга,
Бәреләләр кыекларга.

---

Марис НӘЗИРОВ — *Башкортстанда яшәүче, татар телендә иҗат итүче шагыйрь. Башкорт телендә дөнья күргән берничә китап авторы.*

Ә төшкәчтен килеп җиргә,
Каурыйларын чәчеп җилгә,
Ыңгырашып, сыкрап, елап,
Ярсып, соңгы көчне җыйнап,
Каңгылдыйлар: «Кыйгак...» «Кыйгак...»

Казлар, казлар,
Мин аңлыймын сезнең зарны:
Очмыйча син түзеп кара
Иңнәреңдә канат барда!
...Яшәп кара!

* * *

Печән мәле. Болыннарда
Чалгы кайрыйлар чаң да чоң...
Чаң да чоң...

Ә кайдадыр нәкъ шул чакта
Кылыч кайрыйлар чаң да чоң...
Чаң да чоң...

Ике дөнья? Ике моң?!

## Мәкер

Җиргә төртеп аударып, богаулаган —
Мәкер.
Арканы юк, җебе юк, тышаулаган —
Мәкер.
Каның сеңгән җаннарга кизәндергән —
Мәкер.
Сикереп менеп җилкәгә, тезләндергән —
Мәкер.
Балдан татлы авыздан сүзне урлаган —
Мәкер.
Кара битен яшереп акка уралган —
Мәкер.
Уймак кадәр яманны филдәй кабарткан —
Мәкер.
Сөямен дип каршылап, арттан ук аткан —
Мәкер.
Сукырайтып дөньяны, күзне чукыган —
Мәкер.
Онытасың юк, дип колакка тукыган —
Мәкер.

...Ә шулай да, никтер,
Изгелекне генә саклый бу хәтер.

## Кыяр-кыймас кына

Авырып егылдым. Күз йомдым,
Үлем килде янга кабарып.
Кара көн, кара ут, кара кул...
Тирә-юньдә бары каралык.
Йөрәгемә тора кадалып.

Авырып т螺елдем. Күз ачтым,
Арып, изрәп бактым яктыга.
Ап-ак көн, ап-ак ут, ап-ак кул...
Бөтен дөньяга гүя ак кына.
Пакь дөньяга бастым сабый сыман
Кыяр-кыймас кына, сак кына.

...Яшәү кадерен белдем чак кына!

* * *

Күңелемне бер сүз — бер куз шомландыра:
— Китәселәр китә тора... Китә тора...

Юк, китмиләр... Ишетелә таныш чыңнар,
Күз алдыма килеп баса газиз сыннар.
Әнкәм сыны. Калган утыз биштә килеш...
Күзләрендә сагыш иде — әче җимеш.
Иреннәре саклый һаман соңгы моңны:
«Өч баламны калдырамын... өч улымны...»
Әткәм сыны. Алтмышына яңа кергән,
Төшермәгән дөнья йөген һаман иңнән.
Маңгаенда сугыш юлларының сыры.
(...Бакчабызда, әткәй, алмагачлар корый).
Энем сыны: япь-яшь, егермедә көе...
Иреннәренә кагылган тәүге сөю.
Ул яшәргә тиеш еллар — чаптар атта
Көтә аны моңсу гына язмыш-чатта...

Күңелемне бер сүз — бер куз шомландыра:
— Китәселәр китә тора... Китә тора...
Таныш аваз колагымда күпме чыңлар:
Мәңге бергә газиз затлар — тере сыннар.

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Фәрит Хатипов

# ЯЗМЫШЫБЫЗ

Татарстан парламенты мөстәкыйльлек турында Декларация кабул иткәч, күңелләрдә өмет чаткылары ялтырап китте, әчкә бераз җылы керде. Башка кавемнәр белән тигез хокук алу, иреккә чыгу — халкыбызның иң татлы, изге хыялы, мөкатдәс омтылышы ул. Хәзерге цивилизацияле бөтен кешелек дөньясы моны табигый, нормаль хәл дип саный, милләтләрнең азатлыгы һәм бердәй хокук принцибы барлык халыкара килешүләргә беркетеп куелган. Шуны гамәлгә ашыру юнәлешендә колониаль илләр бәйсезлек алдылар.

Әмма реаль хөррияткә бару юлы шактый сикәлтәле, каршылыклы булып чыкты. Россия хөкүмәте үз дәүләтенең һәм элекке союздаш республикаларның бәйсезлеген таный, ә татар халкының моңа хакы юк дип карый. Шушы мәсләкне үзебездәге бер төркем депутатлар һәм рус телендәге кайбер газеталар бик тырышып үткәрәләр. Әмма моның асылын ачык итеп әйтеп бирергә кыюлыклары җитми. Алар Татарстанны Россия составыннан чыкмаска кыстыйлар. Сорау туа: безнең җөмһүриятнең Россия составына кергәне бармы соң? Без бит Явыз Иванның басып алуы нәтиҗәсендә генә Рәсәй эчендә торып калганбыз. Автономия игълан ителгән чакта да Татарстан белән килешү төзелмәде. Ул Рәсәй хөкүмәте карары белән генә оештырылды. Җөмһүриятkә татарлар яши торган төбәкнең үзеннән уч төбе кадәр җир кисеп бирелде, ә халыкның 75 проценты аның чит-читендә калдырылды, территориясе тирә-яктан автономияле республикаларга, өлкәләргә тураклап бетерелде. Шулай итеп, татар халкының дүрттән өч өлеше, һәрхәлдә, Идел-Урал арасындагы берничә миллион кеше үз милли дәүләтчелегендә гомер кичерүдән мәхрүм ителде.

Россиядән чыкмаска өндәү асылда, ирек дәгъва итмәгез, буйсынган хәлдә яши бирегез, дигәнне аңлата. Тик берәүнең дә үз фикерен болай ачык итеп, яшермичә әйткәне генә юк.

Вакыт-вакыт мөстәкыйльлек хәрәкәтенә һөҗүм аеруча көчәеп китә, янау, өркетү киң колач җәя. «Вечерняя Казань» газетасында азатлык яклыларны «милләтче, фашист» дип атаган материаллар басылып чыкты. Ләкин пружинаны никадәр ныграк кыссаң, аның каршылык күрсәтү көче, язылу куәте шулкадәр арта төшә бит. Игътибар итик: илнең утлы нокталарындагы низаглар башлыча милли мәсьәләнең хәл ителмәгәнлегеннән, иреккә омтылышны хөрмәт итмәүдән, ваграк халыкларны буйсынуда яшәтергә тырышудан килеп чыга.

Еш кына бик хөрмәтле иптәшләр: «Менә без элегрәк бер коллективта әллә ничә милләт кешесе бер гаилә кебек яши идек, бернинди милли аерма сизелми иде».— дип искә алырга яраталар. Моны алар ихлас күңелдән әйтәләрдер, дип уйлыйм. Аларга милли аерма, чыннан да, сизелмәгәндер. Чөнки һәммәсе урысча гына сөйләшә, шулай тиеш санала, милли мәсьәләгә кузгату исә шактый хәвефле, өметсез иде.

Ләкин милләт шулай куркынычлы нәрсәмени соң ул? Түгел, дип уйлыйм. Милләт — ул асылда һәр шәхескә бик якын, аңлаешлы кешеләр бердәмлеге: әти-әнисе, кардәш-ыруы, авылдашлары, илдәшләре, аңа акыл-зиһен бирүчеләр, сөйләшергә, җырларга өйрәтүчеләр, уртак рухи мирасның иҗатчылары, саклаучылары, кыскасы, милләтне уртак рухи мөлкәтле ишле гаилә рәвешендә күз

алдына китерергә була. Туганнарыңны, токымыңны ярату кебек, халкыңны якын күрү, үз итү дә бик табигый, нормаль күренеш.

Шул ук вакытта ул «Ватан» төшенчәсе белән дә бик тыгыз бәйләнгән. Милләт — Ватанның аерылмас бер кисәге, иң газиз, җанга якын, кадерле бер өлеше ул. Халыктан башка — Ватан, Ватаннан башка халык нормаль яши алмый. Һәр милләт — зурысы, кечесе — мәңгелеккә омтыла, гомумкешелек хәзинәсенә үзенең рухи казанышларын өзлексез өстәп торырга тели.

Хәтерегездәдер, элек СССР дип аталган илдә социализм, коммунизмда милләтләр бетәчәк, һәммәсе бер милләт булып оешачак, дигән күрәзәчел караш та туды, вак милләтләрнең юкка чыгу процессы социализм, коммунизм җәмгыяте белән бәйләп аңлатылды. Бу антигуманистик «теория» әле бүген дә рәсми рәвештә кире кагылмады. Киресенчә, аны «фәнни» нигезләргә омтылу сизелә. «Словарь иностранных слов» дигән белешмәдә мондый юллар бар:

«Ассимиляция — ... — слияние одного народа (или его части) с другим путем усвоения его языка, обычаев и т. п. и утраты своего языка, культуры и национального самосознания; естественная ассимиляция происходит в благоприятных для народов условиях (напр., в СССР и социалистических странах в условиях полного равноправия народов) и носит характер слияния малых народов с более крупными этническими общностями, насильственная ассимиляция происходит в условиях национального, религиозного и т. п. гнета и носит характер подавления некоторых народов». (Москва: изд. «Русский язык», 1979, с. 57.) Шушы юнәлештә фараз кылу мәркәздә чыга торган барлык белешмәләрдә дә теркәлгән һәм ул асылда ассимиляцияләүче зур этник төркем идеалын чагылдыра. Шулай итеп, социалистик формациядә милләтнең ул кадәр кадере юк, аның йотылуы, эреп югала баруы монда тик канәгатьлек, куаныч тойгысы гына тудыра, тик капиталистик, колониаль илләрдә генә кешеләрне борчуга сала булып чыга. Әмма моның чыннан да шулаймы, түгелме икәнлеген белер өчен бездән — вак этник төркем вәкилләреннән сорап карарга кирәк иде. Әйтик, дәү балык бәләкәй чабакны йотканда, зурысы да, кечесе дә бердәй хис кичерә микән?

Ләкин бит милләт, вак булса да, чабак түгел. Һәм аның тарихтан төшеп калуы да берәр үсемлек яки җәнлек төренең югалуы гына түгел. Кыргыйлык, колбиләүчлек, феодализм, капитализм дәверләрендә исән калып, бүгенге көнгә килеп җиткән халык ничәмә гасырлар буена бөртекләп туплана килгән рухи хәзинәне, сыналган традиция, гореф-гадәт, йолаларны, әхлак-тәртип кагыйдәләрен үзендә саклый. Аның йөз аклыгы, горурлыгы булган бер әдип үзе генә дә — гаҗәп катлаулы, бай дөнья ул. Кавемнең андый гали затлары ун гына, йөз генә дә түгел. Матур әдәбият янына тагын җыр, бию, рәсем, архитектура, фольклор, халыкның юморы, фәлсәфәсе, мәгърифәте, һөнәре килеп кушыла. Н. Исәнбәтнең калын-калын өч томлы китапларында гына да һәркайсы энҗе бөртегенә тиң 40 мең мәкаль — халык зирәклеге тупланган. Ул байлыкны кайсы бизмәннәрдә үлчәп була? Бармы андый үлчәүләр?

Бу рухи милек туган төбәк белән аерылмас бердәмлектә яши. Телебезнең нәфислеге, җыр-көйләребез, мәкаль-әйтемнәребез гүяки газиз җирләребезнең тирән катламнарына сеңгәннәр, урман-елгаларга, болын-тугайларга кереп посканнар. Кереп посканнар да, шулар арасыннан шигърият-моң булып, риваять-легендалар булып килеп чыгалар. Шуңа күрә дә илгә һәм халыкка мәхәббәт тойгылары үзара бик тыгыз бәйләнгән, халык күңелендә алар аерылмас бердәмлектә яши. Һәр икесе дә җанга сихри бер ләззәт, соклану, сөенеч хисләре бөрки, адәм баласын туган төбәгенә бәйләп тота, ычкынырга, кубарылырга ирек бирми. Җирен, халкын сөймәгән, ихлас хөрмәт итмәгән кеше чын патриот та була алмый. Без боларның берсеннән дә ваз кичәргә теләмибез. Азатлык безгә тарихтан төшеп калмау, йотылмау, эреп югалмау өчен кирәк.

Әмма җөмһүрият мөстәкыйльлегенә каршы төшүчеләр юк-бар имеш-мимеш, коткы тараталар, суверенитет татар булмаган кешеләрне кыерсытачак, дип ышандырырга тырышалар. Ләкин болай раслау өчен бер генә төрле дә дәлил юк! Иҗтимагый, дәүләт оешмаларының бер генә документында да кайсы да булса халыкның хокукын чикләү турында язылмаган. Дәүләт азатлыгы, киресенчә, Татарстанда яшәүче барча милләтләрнең дә тигезлеген, иркле яшәешен тәэмин итәчәк.

Азатлык, мөстәкыйльлек идеясе барча кавемнәрнең дә милли хисен ихлас хөрмәтләүне күздә тота, ул һич тә конфликтка корылмаган. Күреп торабыз бит: тик халык иреген басып, тыеп тору гына киеренкелек, чуалышлар китереп чыгара, азатлык исә каршылыкны бетерүгә хезмәт итә.

Мәсьәләнең тирәндә ята торган тагын бер четерекле ягы бар: нинди дә булса халыкның иреген дәверләр буена кысып тору «өлкән» милләт рухында буйсындыру психологиясе тәрбияли, әхлагын гариплътә, бүтәннәрне тез чүктереп яшәтү генә табигый, дигән алама караш тудыра. Үкенечкә каршы, ул психология бәгъзе милләт күңелендә инде, сиздермичә генә, шактый куәтле тамыр җибәреп өлгергән. Буйсындыру системасы үз нәүбәтендә вак милләт кешеләренә дә тискәре йогынты ясый, ризасызлык, кимсенү, ышанмаучылык тудыра.

Без Рәсәй хөкүмәтенең әлеге буйсындыру психологиясеннән арынуын, киң күңеллелек күрсәтүен, халкыбызның ирекке омтылышына хөрмәт белән каравын телибез. Асылда ул моннан бер нәрсә дә оттырмый, киресенчә, ота гына — татар халкының чын ихтирамын яулап ала, буйсындыру мөнәсәбәте керсез дуслык бәйләнешләре белән алышына. Тарихта моның бик ачык мисаллары бар.

Егерменче еллар башында Урта Азиянең барлык мәмләкәтләре дә — Рәсәй составындагы автономияле республика, Кыргызстан исә автономияле өлкә була. Таҗикстан, Кыргызстанның халкы ул чорда миллион ярымга якынлаша, Төрекмәнстанның миллион ике йөз илле мең чамасы тәшкил итә. Егерменче, утызынчы елларда, ягъни Сталин хәкимлеге дәверендә, шуларның һәркайсы Союздаш республика статусы ала, мәсьәлә дөрес, гадел хәл ителә... Хәзер «бердәм һәм бүленмәс Россия» хакына аларны Рәсәйгә кушу дәгъвасе берәүнең дә башына килми. Ә без соң, җиде миллионлы халык, башкалардан кай ягыбыз белән ким? Безнең дә бит мөстәкыйль дәүләт булып торган чаклар бар иде. Моннан мең дә җиде ел элек, 985 елда, Рәсәй белән Идел Болгары арасында дуслык, хезмәттәшлек килешүенә кул куела, татулык мөнәсәбәтләреннән тайпылмау турында антлар бирелә. Бүгенге көндә Рәсәй хөкүмәтенә Явыз Иван мәслләгән дәвам иттерүгә караганда тагын да борынгырак һәм зирәгрәк әлеге килешү традициясен яңарту күп тапкыр акыллырак булыр иде.

Соңгы вакытта, күпләр хәтерлидер, җөмһүриятнең мөстәкыйльлегә тавышка кую юлы белән хәл ителергә тиеш, дигән сүзләр бик еш яңгырап торды.

Кайберәүләр референдумны, реванш алырга җыенгандай, ашкынып көттеләр. Һәм менә Татарстан парламенты, әлеге таләпкә колак салып, референдум игълан итте. Бу карар, табигый, күңелләрне кабат җилкендереп җибәрде. Шул ук вакытта җанда билгесез бер сагаю, хафалану да бар иде. Бер милләтле дәүләтләрдә тавышка кую, гадәттә, үз җае белән, шома үтә. Бездә исә хәл башкачарак. Казан ханлыгы үзенең бәйсезлеген Иван патша гаскәрләренең басып алуы нәтиҗәсендә югалтты. Һәм әлегә кадәр, дүрт ярым чамасы гасыр үткәч тә, сугыш нәтиҗәләрен юкка чыгару турында ике ил арасында солых төзелгәне юк. Бу дәвер эчендә безгә күрше мәмләкәттән бик күп халык агылды. Аеруча соңгы елларда, КамАЗ, ЕлАЗлар төзелә башлагач, тар гына җиргә берничә йөз мең кеше күчереп тулды. Шулай итеп, хәзер җөмһүриятебезнең төп халкы белән читтән килүчеләрнең саны нигездә тигезләште.

Мондый шартларда референдум үткәрү ифрат четерекле иде. Инде карар кабул ителгәч, Мәскәү кешеләренә сорау ошамый башлады. «Рәсәйдән чыгарга ризамы?» — дип сорарга кирәк иде, янәсе. Ләкин бит чыкканчы керергә кирәк. Безнең исә беркайчан да Рәсәйгә тавышка кую, килешүләр нигезендә кергән булмады. Кермәгән җирдән чыгалармыни? Киресенчә, Рәсәй Татарстан җиренә керде. Димәк, болай сорау хакыйкатькә хилафлык китерер иде. Татарстан парламенты исә сорауны нәкъ менә мөстәкыйльлек, тигезлек ноктасына юнәлдерде. Ягъни, җир йөзендәге барлык мәмләкәтләр кебек, Татарстан мөстәкыйльлек алырга хаклымы? Сүз әнә шул хакта барды. Башка аныклаучы сүзләр, ике төрле аңлауга юл калдырмас өчен, төп сорауның мәгънәсен ачып, төшендереп бирде, бүтән мәмләкәтләр белән килешеп яшәү омтылышын күздә тотты. Сорау, шулай итеп, суверенитет турында Югары Советта бер тавыштан кабул ителгән Декларация рухында, бик дөрес һәм зирәк куелган иде. Безнең кайбер депутатлар: «Без ул чакта Декларациянең мәгънәсен бик үк төшенеп җитмәгән идек», — дип чыктылар. Димәк, алга таба һәр фикерне дөрес аңлардай депутатлар сайларга кирәк булачак.

Мәскәү әһелләре, аптырагач, РСФСРның ике йөз ямаулы Конституциясенә таянмакчы булдылар. Сталин, Брежнев төзеп калдырган Конституцияне алга сөреп, милләтләргә, дәүләтләргә мөстәкыйльлек бирүне Конституция танымый, дип бардылар. Игътибар итегез: хәзер инде СССР үзе юк, ә халыкны буйсындырып тотарга булышырдай булгач, тоталитар империя законы да ярап тора

икән, ә! Ләкин андый Конституция хәзер барлык халыкара хокук нормаларына каршы килә, гамәлгә яраксыз.

Референдум уңышлы үтте. Ләкин шулай да Мәскәү Татарстанны әле тиз генә кулдан ычкындырырга теләми кебек. Инде икенче көнне үк эфирга мәркәздән: референдум гына мәсьәләне хәл итми, дигән шыңшулар яңгырады. Азатлык өчен көрәшнең яңа баскычы, халык ихтыярына нигезләнгән этабы башланды.

* * *

Бүгенге демографик ситуация дә, турысын әйтергә кирәк, милли азатлыкны кысу чыганагына әверелде. Инде хәзер үк руслар күпләп яшәгән төбәкләрдә татарларны депутат итеп үткәреп булмый башлады. Рус иптәшләр тик үз милләтенең вәкилләрен яклап кына тавыш бирәләр. Колонизация шаукымына бирелеп, миллионлаган руслар, уңдырышлы җирләрен ташлап, ятим калдырып киттеләр һәм, тыгызлый-тыгызлый, башка республикаларга кереп урнаштылар, аларны хәзер тулысы белән яки, Молдовадагы кебек, бер өлешен рус дәүләтенә әйләндерергә тырышалар. Инде шулар кабат туган җирләренә, кан кардәшләре янына кайта башласалар, бу хәл нишләптер драма, фаҗига дип бәяләнә. Югыйсә туган туфракка кайтып төшүдән дә табигыйрәк, сөенечлерәк нәрсә дә юк бит инде. Ни өчендер аларга качак кушаматы тагыла. Асылда исә алар туган җирләреннән качып киткәндә качак була, борылып кайткач, киресенчә, качак булудан туктыйлар. Эмиграция гадәти санала икән, әйләнеп кайту, буш җирләрдә җиң сызганып хуҗалык итә башлау да гадәти дип бәяләнергә тиеш.

Тормышның кырыс, ачы җилләре татар халкын да бөтен ил буйлап чәчте. Хәтсезе шунда тупланеп калды. Әмма туган төбәгенә, Татарстанга кайтырга теләүчеләр була икән, хөкүмәт аларга күченергә, урнашырга, тернәкләнеп китәргә булышырга бурычлы.

Демография мәсьәләсе гомумән дә хөкүмәтнең, иҗтимагый оешмаларның игътибар үзәгендә торырга тиеш. Дөресен әйткәндә, Ф. Табеев, Г. Усманов кебек уйламый эш итү, бер гигант янында ботенләй кирәксезгә икенче гигант — Алабуга трактор заводы төзергә керешүне тик бездә генә очратырга мөмкин. Мондый мәгънәсезлекләргә инде зур чик куяр вакыт җиткәндер, дип уйлыйм. Без үзебезнең бердәнбер җиребездә азчылык булып калырга тиеш түгелбез. Азчылык булдыңмы, син инде үз дигәнеңчә, иркәле яши алмыйсың.

Ә шулай да демографик ситуациянең уңай якка авышу ихтималы бармы соң? Ул халыкның үзенә бәйләнгән. Статистик мәгълүматлардан беленүенчә, башлыча шәһәрдә гомер кичерүче милләт кешеләре артуга түгел, кимүгә таба бара — бала бер-ике бөртектән артмый. Безнең милләтнең байтак өлеше әле, ходайга шөкер, авылда, яши, милли рухны саклап, учакны сүндерми тота. Анда сабыйлар күбрәк туа. Безнең бүген бөтен ышанычыбыз әнә шул хәзинәдә. Минем милләттәшләргә, гаилә корган яшьләргә, урта буын кешеләренә ихлас күңелдән мөрәҗәгать итәсем килә: һәркайсыгызның гаиләсе бәхетле, тигез булсын, бер-ике бөртек белән генә чикләнеп калмагыз, күп балалар, балдан татлы күп оныклар үстерегез! Тормыш гел болай бәрәкәтсез булып тормас, бер рәтләнер, эзгә төшәр. Сезнең ишле, тәүфикъле балаларыгыз сөенеч, шатлык чыганагы, үсә төшкәч, ил өчен дә, үзегез өчен дә арка таянычы булыр. Аренда, ферма хуҗалыклары да корып җибәрсәгез, балалар иң ышанычлы ярдәмчеләрегез булып җитешерләр, мул тормышка чыгарга булышырлар, сәләтләрен күрсәтерләр, милләтебезнең ныгуына, үсүенә, ишәюенә йогынты ясарлар.

Суверенитетка каршы нигез итеп кайберәүләр тагын, саламга ябышкандай, катнаш гаиләләр булу фактын файдаланмакчылар. Әйтерсең, мөстәкыйль җөмһүрият катнаш гаиләләргә каршы яуга җыена, әйтерсең, башка республикаларда бер генә катнаш гаилә дә юк.

Әмма, шуның белән бергә, бу мәсьәләне күрмәмешкә салышу да дөрес булып бетмәс, чынында бар бит андый проблема, реаль яши һәм мәгънәсе, нәтиҗәләре турында җитди уйлануны таләп итә.

Элегрәк, гадәттә, бер милләт кешеләре өйләнешә иде. Ыруга башка дин вәкилен кертү гонаһ, гадәттән тыш хәл саналды. Авылда, ягъни башлыча бер халык гомер кичергән төбәкләрдә, бу гадәт әле дә үзгәрешсез дәвам итә. Башлыча шәһәр җирендә генә катнаш гаиләләр барлыкка килә.

Бер кавем кешеләреннән торган гаиләдә милли рухи уртаклык тулы саклана. Тел-музыка, йола-гадәтләр дә һәр ике якка да бердәй аңлаешлы. Эфирда

үз көйләрең агылганда, радио, телевизорның колагын борып куючы юк, ул моңнар икесенең дә күңеленә бердәй хуш килә.

Рухи гармония милли аерманың ни дәрәҗәдә булуы белән дә бәйләнгән. Әйтик, татар, башкорт арасында бик зур уртаклык бар. Гаилә корганда, бер-берсенең мәдәниятен, әхлак-гадәтләрен үзләштерү артык мәшәкать тудырмый. Әмма, шулай булган хәлдә дә, гаилә иминлеге, бөтенлеге милли үзенчәлекләргә бик сак, игътибарлы булуны, хөрмәт белән карауны таләп итә.

Безнең күп кенә милләттәшләребез Урта Азиягә китеп оя корды. Моның җитди сәбәпләре дә бар. Идел буендагы ачлык, мохтаҗлык та, көньяк табигатенең юмартлыгы, кешеләренең киң күңеллелеге дә, егетләренең безнең кызларны ошатуы, калым түләмичә өйләнү мөмкинлеге дә, тел, йолаларның якынлыгы, дин берлеге дә монда мәгълүм роль уйнаган булса кирәк. Әгәр дә аралашу, бәйләнешләр табигый үзәндә барса, алфавитыбыз бердәй төзелсә, радио, телевидение тапшыруларын һәр тарафтан тыңлау, карау мөмкинлекләре булса, безнең аралар әле тагын да ныграк якынаер иде, бер-беребезнең күңел җәүһәрләреннән хәбәрдар булып торыр идек.

Урта Азия җирендә гаилә корып, төпләнеп калгач, милләттәшләребез төрки халыкларның тел, йолаларын үзләштерәләр, балалар үстерәләр һәм... кардәш кавемнәрне ишәйтәләр. Әгәр дә безнең кыз казахка яки үзбәккә чыга икән, аның инде балалары да казах яки үзбәк була. Бу юл, шулай итеп, башкаларны арттырган дәрәҗәдә татар халкының кимүенә таба алып бара.

Инде татар-рус гаиләләренә килик. Катнаш гаиләләрне рус иптәшләр тик бер генә яктан, уңай, прогрессив тенденция дип кенә бәялиләр. Аларны да аңларга була. Мондый гаилә төзүдән рус милләте бернәрсә дә югалтмый. Гаиләнең катнаш булуын рус кешесе хәтта бөтенләй сизмәскә дә мөмкин. Аның милли яшәешендә берни дә үзгәрми, элеккечә кала. Рус кешесе гомер буе татар белән донья көтсә дә, аның бер генә авыз сүзен дә белми, өйрәнүне кирәксенми дә. Чөнки аралашу урысча гына бара. Безнең халык моңа тулысынча җайлашырга, татар кешесе икәнен онытып торырга тиеш иде. Мондый тирәлектә, билгеле инде, балалар да тик «өлкән» милләт мәдәниятен генә үзләштереп үсәләр. Безнең халыкның теле, әдәбияты, фольклоры, җыр-моңы, биюләре алар өчен чит нәрсә булып кала. Башка халык гадәтләренә генә буйсындырылып тәрбияләнгән бала туганнары белән гапләшә дә алмаска мөмкин. «Әйтелмәгән васыять»тә сурәтләнгәнчә, андыйлар, тыңлаган булып, ияк кагып, елмаеп кына торалар. Алар татар халкы белән уртаклык сизмиләр. Димәк, бу тармакта татар милләтенең үсеше тукталып, киселеп кала. Бу — ассимиляциянең бер күренеше. Шунлыктан булса кирәк, урыслар катнаш гаиләләр кору масштабын тагын да киңрәк җәеп җибәрергә телиләр.

Әлбәттә, катнаш гаиләдә дә, яратышып яшәүчеләр булган кебек, аерылышулар да аз түгел. Бу очракта, башка сәбәпләр белән беррәттән, ике як өчен дә тигез рухи тирәлек булмавы да үзен сиздерә, әлбәттә. Катнаш гаилә турында миңа бик яхшы таныш булган кайбер иптәшләрнең фикерен ишетергә туры килгәне бар. Аларның һәркайсы инде озын гомер юлы узган, марҗа хатыннары да бик әйбәт кешеләр, үзара тату яшәгәннәр. Әнә шул татар агай-энеләр, бөтенләй көтмәгәндә, ничектер ачылып китеп: «Шулай да үз милләтең кешесенә өйләнү хәерлерәк буласы булган икән»,— дип ычкындырганнар иде. Болай дигәндә алар, бәлки, гомер буена гаиләдә милли хисләреңне басып, томалап тору мәҗбүриятен дә, балаларының үз токымыннан аерылуын, тел белмәвен дә күз алдында тотканнардыр.

Гаилә кору, кемгә өйләнү, кемгә чыгу мәсьәләсе, бигрәк тә милли мөнәсәбәтләр белән бәйләнгәне — бик нечкә, индивидуаль мәсьәлә. Шуңа күрә бәгъзе берәүләр аны яктыртмаска киңәш итәләр, халыклар дуслыгына, интернационализмга зыян китерүе ихтимал, дип саныйлар. Биредә гәп мәхәббәтне чикләү, катнаш гаиләләргә каршы чыгу турында бармый. Сүз катнаш гаиләнең язмышына фикер нуры төшерү хакында бара. Моны һәркем яхшы белеп торсын иде.

* * *

Киң күләмле ассимиляциягә илтүче иң туры һәм кыска юл — милли мәгариф тамырына балта чабу. Чит телдә тәрбияләп, баланы инде бакчадан чыкканда ук туган теленнән мәхрүм итәргә була. Манкорт өзер. Шуңа күрә шовинистик администрация милли тәрбия, белем системасын корытуга бөтен көчен сала.

Матбугат битләреннән күренүенчә, хәзер илдә татар сабыйларының ни бары җиде проценты, үз баланың җидесе генә ана телендә белем ала, калганнары рус мәктәпләрендә укый («Социалистик Татарстан», 26 октябрь, 1989). Шулай итеп, белем, тәрбия системасы «халык мәгарифе» дип йөртелсә дә, мәгариф эше халыкның үз теленнән мәхрүм ителгән булып чыга, «халык мәгарифе» дигәнебез мыскыл кебегрәк яңгырый.

Әмма мәгарифеннән колак кагуда да татар халкының үзен гаепле итеп күрсәтмәкче булалар, ата-аналар ихтыярына сылтап калдырырга телиләр. Бу сүзне мәктәп һәм ата-аналар белән бертөрле дә алыш-биреше булмаган, алар белән бер тапкыр да сөйләшеп карамаган кешеләр дә, уйлап-нитеп тормастан, механик рәвештә әйтеп җибәрәләр. Ягъни безнең халык үз телендә гыйлем бирүне кирәксенмәгән дә, җыелып, чит телдә укытырга ният кылган булып чыга. Ләкин бит дөресендә бу мәсьәлә буенча бер тапкыр да референдум үткәрелмәде, съезд, корылтай карарлары да чыгарылмады. Без дә балалар үстердек, укыттык. Әмма, шуларның әти-әнисе буларак, татар мәгарифе бетсен дип тавыш биргәнебез булмады, безнең әти-әниләребез авызыннан да андый кыргый өн чыкмады. Бу эш бик шыпыртын башкарылды. Матбугат битләрендә дә хәбәр күренмәде. Педпрактика вакытында безгә Буа районының Суыксу урта мәктәбе укытучылары, мәгариф министрлыгы, фәннәрне русча укытырга кушып, приказ чыгарды, мәктәпләргә таратты, дип сөйләделәр. Ләкин моңа укытучылар да, балалар да әзер түгел иде. Ун еллап интектек. Ахыр килеп кабат үз телебездә укытуга күчтек, диделәр алар.

Бу коллектив, күрәсез, акыл белән эш иткән. Ят телдә укыту сабыйларны рухи гариплэндерү икәнлегенә төшенгәннәр алар.

Ләкин күп җирдә зирәклек, мостәкыйльлек, кыюлык җитмәде, туган телнең җегәре, социаль-рухи вазифасы, газизлеге санга сугылмады, телгә кизәнү — халыкның җанын, бәгырен телгәләү икәнлеге искә алынмады. Милләтне конституцион хокукыннан — үз телендә укытудан мәхрүм итәргә бирәүнең дә хакы булмаса да, милли мәгарифкә һөҗүм «уңышлы» төгәлләнде.

Штанин ишеләр безгә: әгәр Рәсәйдә калсагыз, барлык милли, мәдәни ихтыяҗлар канәгатьләндереләчәк, дип ышандырмакчы булалар, җәннәт вәгъдә итәләр. Менә инде үзгәртеп кора башлаганга да җиде ел үтеп китте. Татар халкына милли мәктәпләрен, бакчаларын кайгырту турында Рәсәйдә берәр карар кабул ителдеме соң? Юк бит. Икенче бер кавем шивәсендә укыту хәзер инде инерция белән бара бирә. Җөмһүриятебезнең башкаласында ярты миллионлап татар яши. Шунда, ике-өч бортек гимназияне исәпкә алмаганда, бер татар мәктәбе юк. Мәктәпләрнең ябылуы татарча укытуның кадрлар базасын җимергән, калада татар мөгаллимнәре нибары 5—6 процент калган (Гарданов Х. Ш. «Пути перестройки народного образования и проблемы воспитания подрастающего поколения». ТОЦ: Материалы учредительного съезда: Казань, 1989). Инде хәзер шушы хәл татар мәктәпләрен тергезмәү өчен сәбәп булып хезмәт итә: ана телендә укытырдай кадрлар юк бит, милли мәктәпне ничек итеп ачмак кирәк? — диләр. Ләкин бит бер уку йорты өчен дә мөгаллимнәр күктән төшми. Административ аппарат милли кадрларны тузгыта белгән икән, әзерләү җаваплылыгын да үз өстенә алырга бурычлы.

Тоташ татарлар яши торган район, авыл җирләрендә дә йә гел русча гына укыталар, йә өйбәтрәк укытучылар, зиһенлерәк балалар рус классларына беркетеләләр дә, татар классларына әзерлексезрәк педагоглар һәм сәләтсезрәк балалар сайланып кала. Шушы чара ярдәмендә ясалма рәвештә рус классларының абруе күтәрелә, татар классларын кимсетеп карау сәясәте уздырыла, сәләт төрлелеге милли җирлеккә күчерелә, кытыршылык тудыруга хезмәт иттерелә. Кайда монда интернационализм?

Шулай да сабый өчен кай телдә уку җайлырак? Гыйлем алу — закончалыкларны төшенү дигән сүз. Дөрес материалы нигездә тел белән аңлатыла. Димәк, аны үзләштерү өчен иң әүвәл сүзләрне белү фарыз. Һәм менә шунда инде газиз туган телебез риясыз, ихлас ярдәмгә килә. Җир йөзендәге теләсә кайсы эре телләр кебек, безнең тел дә иң катлаулы күренешләрне, кануннарны бөтен тирәнлеге, нечкә төсмерләре белән аңлатып бирердәй, бала зиһенен яктыртырдай куәтле, бай тел. Үз телендә укыганда, сабыйга һәр сүз таныш. Ул педагог әйткәнне, китапта язганны, һава сулагандай, мәшәкатьсез, тоткарлыксыз үзләштерә, төшенчәләр аңына иң кыска юл белән барып җитә, ансат аңлашыла, хәтерендә тирән уелып кала. Төшенгәнен укучы җиңел генә сөйләп тә бирә ала,— аңа, сүз эзләп, күршегә керәсе түгел. Гомумән, үз телендә, аңлаешлы, якын шивәдә белем

алу мөмкинлеге күңелдә канәгатьлек, куаныч хисләре кузгата, үзеңне горур, азат, бәхетле тоясың.

Инде сабыйның хәленә кереп карыйк. Башка телдә укый башлагач, ул аптырап кала. Сүзләр, төшенчәләр таныш түгел. Сабак аңлашылмый. Әле русчаны бераз үзләштергәч тә ул һәр сүзне әүвәл үз теленә тәрҗемә итә, шуннан соң гына мәгънәсе аңына барып җитә. Инде шуны барлы-юклы сүз запасы белән сөйләп бирү аның өчен тагын да читенрәк. Кыскасы, хәтсез вакытлар буена аңа программа материалын үзләштерүдән дә бигрәк икенче телне өйрәнү мәсьәләсен хәл итәргә кирәк була. Укытучыларның күзәтүенчә, мондый көчеш баланың аң үсешен берничә елга тоткарлап тора. М. Мәхмүтов мондый шартларда укуның сыйфаты төшүе, белемнең саегуы турында яза. (М. Махмутов. Татарская школа вчера и сегодня.— «Вечерняя Казань», 22 апреля, 1989 г).

Берзаман татар баласы рус телен үзләштерә, билгеле. Ләкин аның бәрабәренә үз телен, әнисе сөйләмен оныта, аның ямен, шигъриятен, газизлеген тоймый башлый. Күрше телен белү үзмаксатка әйләнеп китә. Икенче шивәне өйрәнү хакына ана теле корбан ителә. Инде хәзер үк милләттәшләребезнең байтак өлеше ана телендә сөйләшә белми, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр үз халкы арасында аңлату, оештыру эшләре алып бара алмый, докладлар сөйләү, мәкалә язу кебек шөгыльләр кулыннан килми. Соңгы елларда бездә сөйләү культурасы шактый түбәнәйде, калькалаштыру киң таралды. Моны без телевизион чыгышларда, әңгәмәләрдә һәркөн күреп торабыз. Ике телле дип йөртелгән халыкның ярты өлеше бер теллегә калып бара, русча гына аралаша ала, ыруыннан, халкыннан бизә.

Югалту тел белән генә дә чикләнми. Ана телендә мәктәп күрмәгән бала халыкның җыр-моңын, биюен, мәкаль, мәзәкләрен, гореф-гадәтен, фәлсәфәсен, әхлак-тәртип кагыйдәләрен дә үз итә алмый. Ул әче куыш, муртайган агачка охшап кала. Татар мәдәниятеннән читләшкән, шул ук вакытта рус культурасының, рухының да бөтен төсмерләрен үзләштермәгән. Ике арада калган. Тотрыклымы, ышанычлымы ул бәндә? Ил аңа таяна аламы? Кистереп әйтүе читен.

Рухи геноцид милләтнең интеллектуаль җегәрен зәгыйфьләндерә, мәдәни чишмәләребезне бер-бер артлы томалый тора. Рус мәктәпләрендә укып чыккан яшьләр арасыннан хәзер милли сәнгатькә кадрлар килү туктады. Татар ясләләре, бакчаларының бетерелүе тагы да хәтәррәк. Ул милли рухны ныгымаган килеш, яшь вакытта ук корытуга хезмәт итә.

Соңгы вакытта рус мәктәпләрендә укучы татар балалары ана теле, әдәбиятыннан авыз итә башлады. Бакчаларда атнасына ярты сәгатьлек татар теле дәресе кертелде. Ләкин моны мәсьәләнең тулы хәл ителеше дип буламы соң? Бакчада балалар, көненә уникешәр сәгатьтән, атнасына 60 сәгать була. Димәк, сабыйлар татар сүзләрен бөтен вакытның 120 дән бер өлешендә ишетәләр, ә түбәнрәк группадагылары аннан да мәхрүм. Рус мәктәпләрендә ана теле, әдәбияты, чит тел кебек, фән буларак кына өйрәнелә. Калган барлык дәресләр, җыелыш, тәрбия чаралары, уеннар, түгәрәк утырышлары, аралашу русча бара. Татар теле, әдәбиятының сәгатьләре дә әле чит телнекеннән 2—4 тапкырга, рус теленекеннән 5—10 мәртәбәгә ким, ягъни ана теле, әдәбияты үтә гадиләштерелгән, кыркылган, йолкынган программа буенча үтелә, рухи хәзинәбезнең муллыгын, ямен, нечкә бизәкләрен сиздерерлек, тойдырырлык дәрәҗәдә түгел. Күңелгә шик тә төшеп куя: без соң болай үзебез дә берзаман ата-баба җирендә читләр, ятлар булып калмабызмы? Биредә татар җыр дәресләре дә кертелми. Яшьләр көйләребез-моңнарыбызны аңлаудан, тыңлап ләззәтләнүдән, җырлап бирүдән ерак торалар. Аның каравы, кайбер мәктәпләрдә православие тәгълиматы өйрәтелә икән. Шундый әзерлектән соң балаларыбызны чукындыра башларга да ерак калмас. Өстәвенә, әле шушы белем учреждениеләре министрлык отчетларында, ирония белән әйткәндәй, татар милли мәктәбе графасына кертеп йөртелә.

Кыскасы, ялгызы гына тел, әдәбият дәресләре әле мәсьәләне хәл итми. Алар күлмәкнең төймәсен хәтерләтәләр. Әлегә төймә бар, күлмәк үзе — татар милли мәгарифе юк. Асылда алар күзгә төтен җибәрү, сәдака биреп халыкны юату, ассимиляция процессын үзгәрешсез калдыру өчен генә уйлап чыгарылган. «Ата-ана теләге» дигән нәрсә дә — мәкерле бер уйдырма гына. Ул һич тә сәбәп түгел, ә бәлки башка бик күп сәбәпләрдән килеп чыккан нәтиҗә генә.

Моннан берничә ел элек вузга керүчеләргә иншаны татар әдәбияты буенча язарга рөхсәт бирелде. Әмма бу хокуктан әлегәчә университет һәм пединститут

абитуриентлары гына файдаланалар. Татарстан җирендәге башка вузлар администрациясе ул кагыйдәне кирәк тапмый һәм моның өчен бернинди җавапка тартылмый.

Яшь буынны халкыннан читләштерү хәрәкәте алга таба да хәзерге шөкә барса, ана телендә ясле, бакча, мәктәпләр тергезелмәсә, якын арада җиде миллионлы татар халкының милләт буларак юкка чыгуы, кызыл китапка теркәлеп калуы ихтимал. Инкыйразның Гаяз Исхакый әйткәнгә караганда да иртәрәк килеп җитүе мөмкин. Бу язмыш хәзер бик реаль төсмерләнә. Ул сәламәт яшәештән тайпылу, административ-партократия аппаратының халык алдындагы җинаяте дип бәяләнергә, тарихка теркәп калдыру өчен хакимият әһелләренең исемнәре тулы күрсәтелергә тиеш. Әле моңа кагылышлы байтак документларны, архивтан алып, көн яктысына чыгарасы бар. Әгәр дә башка берәр мөстәкыйль зур милләт яшьләрен бер генә төбәктә үз телендә укытудан тыйсаң, бу хәл дөнья масштабында яңгырар, олы шау-шу куптарыр иде. Безнең халык сабыр. Бөгыренә барып тия торган мәсьәләнең хәл ителешен күркәм түземлек, чыдамлык белән көтә.

Аппарат әһелләре исә моңарчы бертөрле дә җитди үзгәреш кертмәү, һәммәсен элеккечә калдыру өчен юк-бар сылтау, сәбәпләр эзләү белән шөгыльләнде, милли мәктәпләрне тергезүнең хәл ителмәслек дәрәҗәдә катлаулы булуын исбатларга тырышты. Әйтерсең, безнең мең еллык мәдәният, мәгариф булмаган да, бу өлкәдә бертөрле дә тәҗрибә тупланмаган. Гаҗәп хәл: укыту тәрбия эшен чит телгә күчерү бик шома үткән иде бит. Аны кабат халыкның үз теленә кайтару нишләп алай бик катлауланып китте соң әле? Милли мәгарифне бетерә белгәч, администрация аны тергезә белергә дә бурычлы түгелмени?

Иң әүвәл бу хакта закон кабул итәргә һәм аны тайпылышсыз тормышка ашырырга кирәк. Чөнки тиешле күрсәтмә булмау аркасында гына күп җирдә милли мәктәпләр, бакчалар ачылмый тора. Фольклор практикасы вакытында безгә Зеленодольск районының Бишнә урта мәктәбе директоры: «Кабат татар телендә укыта башлау өчен Министрлар Советының рөхсәте булырга тиеш»,— дип аңлаткан иде. Бу закон ясле, бакчаларда тәрбияләүне, мәктәп, вузларда, башка төрле уку йортларында халыкның үз телендә укытуны гарантияләргә тиешле. «Ата-ана теләге» дигән нәрсә моңарчы милли мәгарифне корытуга гына хезмәт иткәнлектән, закон андый хәйлә, мәкерләргә юл куймаска тиешле. Бары тик милли мәктәп, бакчаларны халыкка кайтарганда гына, татар теле реаль гражданлык хокукы алачак. Милли мәгариф тергезелмәсә, ана теленең абруен күтәрү хакындагы сүзләр буш хыял гына булып калачак.

* * *

Һәрбер кеше тормышында гомумдәүләт яшәешендә үтә җитди күренеш булганга күрә, хәзер милли мәсьәлә үзенә бөтен җәмгыятьнең дикъкатен җәлеп итә. Халыкның үзаңы уяна башлады. Ул үз хәленә, язмышына текәлебрәк карый, киләчәге турында җитдирәк уйлана.

Милләтнең мөстәкыйльлеге, үзбилгеләнү хокукы барлык прогрессив, цивилизацияле дәүләтләрдә дә иң фундаменталь, гуманистик принциплардан санала. Бу хокук Хельсинки актында беркетелгән. Заманында Советлар Союзы да аңа кул куйды, ягъни ил аны берсүзсез таный, ул хокукны тулы тормышка ашыруны үз өстенә ала. Хәзер инде халыкның азатлыкка, мөстәкыйльлеккә, тигезлеккә омтылышы, рухи кыйммәтләрне саклап калырга теләве белән исәпләшмәү мөмкин түгел. Бары тик шул нигездә генә халыклар арасында чын дуслык, хөрмәт, бер-береңә ышану атмосферасы туа ала.

Тәлгат Галиуллин

# Тарихыңны онытсаң — юк киләчәгең...

1

Әдәбият үсешенә анык кына бәя бирү, аның кан басымын, йөрәк тибешен дөрес билгеләү җиңел түгел. Берәүләр: «Яңартып кору, демократия өчен көрәш дәверендә сүз сәнгате күтәрелеш кичерә башлады һәм замана чалымнарына, халык язмышына сизгер яңа буын иҗатка килде», — дип тәкрарласа, икенчеләре әдәбиятның барлык тукымаларына сеңгән агулы торгынлык чирс, кризис турында сүз куерта. Г. Афзал исә, мыек астыннан гына елмаеп, әдәбиятка мондый бәя бирә: «Мин-минизм алга киткән заман, Романтизм артка чиккән заман».

Әйе, хәзер әдәбият үзенең эчке халәтенә туры килмәгән, табигый яшәү рәвешенә ят булган, аңа өстән кочлап тагылган гарасатлардан котылу, арыну, чистарыну юлларын эзли. Тик әле ул һаман да сыйнфый көрәш рухы, ура-патриотизм, уртак ватан өчен горурлык хисе белән чирле. Холыкка сеңдерелә килгән буйсынучанлык, коллык, куркаклык, читтә калырга омтылу психологиясе байтак язучыларга тормыш һәм язмыш бусагасын атлап, эчкәрәк үтәргә ирек бирми. Чөнки бу йогышлы авыруларны тоталитар режим җитмеш ел дәвамында милли әдәбиятларның тәненә, җанына сеңдерә килде. Үз дәүләте һәм иң гади сүз ирекe, бернинди хокукы булмаган милли язучылар хәтта үзләрен бар нәрсәдән мәхрүм иткән тираннарга мәдхия әсәрләр язу дәрәҗәсенә дә төштеләр. Хисап фәненә мөрәҗәгать итсәк, мөгаен, Сталинга һәм деспот режимына, тоталитар коммунасына багышлап язылган шигырьләр саны буенча татарлар хәтта грузиннарны да (алар күпме генә зарлансалар да, үз милләтенә Җо абзый льготаларны күп бирде) уздырып җибәргәннәрдер. Ләкин бу «мавыгу» татар әдәбиятына бернинди дә абруй өстәмәде.

Аннан килеп, татар халкы — үз тарихында күпне күргән һәм азатлыгы өчен бик озак еллар буе уңышсыз көрәшә-көрәшә талчыккан, йончыган, шул юлда фидаи җанлы улларын, затлы нәселләрен корбан иткән борынгы милләтләрнең берсе. Зиһен көчен, җегәрен, геннарын саклардай, үстерердәй үз дәүләте булмау халыкны тиз арыта һәм ул табигый талантын башка милли җирлекләрдә үстерергә мәҗбүр була. Урыс, үзбәк, башкорт, казакъ, кыргыз, төркмән, төрек, балкар, кумык әдәбиятлары үсешенә килеп чыгышлары буенча татар нәселеннән булган язучылар аз өлеш керттеме икән? Туган телен җуеп, рухи куәтен башка мохиттә яңгыратучылар саны буенча элеккеге урыс һәм совет империясе халыклары арасында татарлар беренчелекне яһүдләргә генә бирә торгандыр. Хәзерге урыс телле әдәбиятка гына да күпме татар хезмәт итә? Аларның исем һәм фамилияләрен үзгәртеп, башка дингә күчкәннәре дә җитәрлек.

Мәдәни, сәяси җәһәтләрдән үсеп, итагатьлек хисләре уянып, кылмаган гөнаһлары өчен әрләнгән, каһәрләнгән татарыңа, бәлки, киләчәктә бу милләтләр дә бер рәхмәт әйтерләр әле? Империячел фикерләү, электән килгән идеологик доктрина әлегә чаклы фәнни объективлыкны кешегә дә санамады бит.

Шул ук вакытта татар халкы бер милләткә дә бурычлы түгел, аңа үкенер, гафу үтенер урын юк. Бу хәл — үзе бер милли горурлык чыганагы.

Уртак илдә тулы буйсынулы тормыш белән яшәүгә мәҗбүр ителгән халыклар арасындагы аерма тарихи үткәндә ята. Ләкин үткән белән бүгенге тормыш тыгыз үрелгән. Әле дә азатлыктан мәхрүм булган халыклар үз милли аңнарын, кешелек

сыйфатларын тарих катламнарын күтәрү аша гына мәдәни дөньяга җиткерә алалар. Әмма, тарих дигәч тә, татарыңа Адәм белән Хавага ук әйләнеп кайту кирәк түгел. Сүз үз милли тарихыбызны, бигрәк тә аның фаҗига белән тулы буыннарын, сәнгать югарылыгына күтәрү хакында бара. Ә фаҗига ул һәрдаим яңгырый, ул — һәрвакыт яңача, кабатланмас.

Тарихыбызны әлегәчә әдәбиятта тулы көчкә яктырта алмау, аның бик күп буыннарын тел яшергән килен төсле генә сурәтләү исә безнең гаеп түгел, ә бәлабез...

«Безнең тарих — сезнең кулда», — ди сугышчылар янына килеп чыккан XIII гасыр шагыйре Кол Гали С. Хәкимнең «Дуга» поэмасында.

Тарих ул — дөреслек юлы, хакыйкать, аерым кешеләр ихтыярына бәйле булмаган вакыт категориясе, үлчәм берәмлеге, һәр иманлы кеше тарих аша узарга тиеш.

Г. Афзал тарихны халыкка тиңли, аның изгелеген яклап чаң суга:

*Әшәке кеше була,*
*Әшәке халык булмый,*
*Әшәке тарихчы була,*
*Әшәке тарих булмый.*

«Тарихыңны онытсаң — юк киләчәгең, яшәү серс узганнарга күз салуда», — дип яза Н. Арсланов «Егетлек турында» шигырендә. Әйтерсең лә безнең чор әдипләре Тукай һәм Пушкин әйткән фикерне ачыклыйлар, яңарталар.

Тукай үз халкының олы тарихын өч сүзгә сыйдырган: «Без тарихта эзлебез...» Шагыйрь бу канатлы гыйбарәдә ата-бабаларның үткәне белән горурлануын, кемнәргәдер бу хакыйкатьне искә төшереп, колагына киертеп тору кирәклектән гасабилануын, татарның киләчәге өчен борчылуын әйтергә теләгән. Дөрес, бу тезмә матбугатта кирәкле-кирәксез, урынлы-урынсыз файдаланудан үзенең мәгънәсен, эчтәлеген, төсен җуя башлады.

Тарих — һәркемгә туган баласы кебек якын, газиз. Үз милләтенең үткәнен, шатлык һәм фаҗигасен, бөеклеген һәм үрләрен югалтуын, кыскасы, үсештә калдырган «әзен» белмәгән кешене — маңкорт, урыслар исә «Иван, не помнящий своего родства» диләр.

Киң катлам укучы өчен чыгарылган тарихи әсбапларда, дәреслекләрдә татар тарихы моңа кадәр гел берьяклы яктыртылды. Рәсми сәясәт яулап алучы, җиңгән халык җырын җырлады, беренчесен җиргә салып таптау исәбенә икенчесен күккә чөйде. «Дәреслекләрнең күбесе ялганга корылган. Безгә тиз арада үз тарихыбыз турында, ничек булган шулай басып таратырга кирәк. Югыйсә, яшерен-батырын түгел, безгә кыргыйларга караган кебек карыйлар», дип язды З. Әһлиуллин («Казан утлары», 1991, 6 сан).

Рәсми әдәбиятта татар тарихы төп-төгәл өч кисәккә бүленә килде. Беренчесе — Алтын Урда, Казан дәүләте белән бәйле һәм янәсе кан коюлардан, сугыш, талаулардан гына торган ханнар, феодаллар дәвере. Андагы татарлар да артта калган, ярым вәхши халык итеп күрсәтелде.

Иван Грозный гаскәре Казан илен ут һәм кылыч аша уздыргач, морзалар һәм руханилар тарафыннан изелүдән азат ителгәч, татар халкы үз үсешенең киң, якты юлына чыга, урыс һәм аның мәрхәмәте аша Аурупа халыкларының рухи, мәдәни казанышлары җимешләреннән авыз итә башлый, янәсе. Әйтерсең лә, Гаяз Исхакый «Зөләйха» драмасында тасвирлаган татар халкын ил буйлап тарату, Лука Канашевич, Ильминский куллары белән көчләп чукындыру, дөньяда тиңе булмаган геноцид булмаган. Гүя барысы да иләк авызлар тараткан гайбәт кенә. Әйе, татар халкының җир йөзеннән юкка чыгуы өчен барысы да эшләнгән. Англиянең Оксфорд шәһәрендә чыгарыла торган «Урта Азия күзәтүе» журналында басылган мәкаләгә таянып, Ф. Зарипов болай яза: «Хәзер инде менә Россиянең татар халкына карата үткәреп килгән геноцид сәясәтенең йомгагына күз салыйк: әгәр 1552 елда Россия империясе территориясендә урыслар һәм татарлар бер чама булса, бүгенге көндә татарлар 7 миллион гына, ә урыслар 12 тапкыр күбрәк — 140 миллионга якын». («Социалистик Татарстан», 1992, 31 гыйнвар).

1917 елдан соң, хакимияткә большевиклар килгәч, барлык халыклар өчен салынган итле бәлештән татар халкы да бераз авыз итә. Бәхет, азатлык, тигезлек күктән яуган иләһи яңгыр төсле, партия, хөкүмәт биналарын бизәгән кызыл әләмнәрдән иңеп тора. Халык тарихын бишьеллыклар темпы алыштыра. Үзе аңлап та җиткермичә, изге нияг белән, Такташ большевизм символының зыяны халыклар өчен коточкыч бер явыз көч, афәт булып күтәрелүен «Гасырлар һәм минутлар» поэмасында болай күз алдына бастыра:

*Җир шары өстендә Ленин*
*Шәүләсе көн-төн йөри.*
*Уң кулында канлы байрак,*
*Сул белән*
*Куркынычъ елларны алга өстери.*

*Ул, кояш нуры кебек нурлар сибеп,*
*Төрмәләр, подвал, заводларга керә,*
*Йә, коточкыч байрагын тоткан килеш,*
*Ул кинәт килеп чыга зур*
*Парламентлар өстенә!..*

Әйе, Такташтан аермалы буларак, без «канлы байрак»ның алга киткән мәмләкәтләрне хәерчелеккә төшерүен, күпме халыкны илсез, җирсез калдыруын, парламентларны юкка чыгарып, тоталитар режимнар коруын, төрмә-подвалларны үз иленең алдынгы, зыялы уллары белән тутыруын күрдек. Ленин сул кулы белән «алга өстерәгән» «куркынычъ еллар»дан әле хәзер генә, зур авырлык белән, маймалаган арба төсле ыңгыраша-ыңгыраша гына чыгып барабыз.

Нигез ташларын Ленин салып калдырган җәмгыятьтә татар һәм башка кайбер халыклар тарихын фальсификацияләү, хаким милләтне үстерү бәрабәренә, рәсми сәясәт дәрәҗәсенә күтәрелде. М. Худяков, Л. Гумилев кебек берничә намуслы тарихчы гына дәүләт машинасының хәтәр юнәлешен үзгәртә алмады. Намусларын байрак иткән һәм күтәреп кенә йөртеләсе галимнәрнең беренчесе юкка чыгарылса, икенчесе яшь гомерен Сталин төрмәләрендә, «бөек» төзелешләрдә үткәрде. Репрессиянең төп сәбәбе уртак: галимнәр, имеш, Алтын Урда һәм Казан ханлыклары тарихын субъектив өйрәнү, бәяләү юлына бастылар.

Дөресен әйткәндә, совет чорында татар халкының үткәнен сәяси һәм әдәби иңләүгә рәсмиләштерелмәгән тыю салынды. Хәер, «Идегәй» дастаны буенча 1944 елгы карар шул тыюны кәгазьгә уеп кую, закон рәвешенә кертү булгандыр инде.

Олы тарихны әнә шулай киртәләп кую, объектив үсеш кануннарын, борылыш-чигенешләрен исәпкә алмыйча әзер кысага утырту матур әдәбиятка да тәэсир итте, аның үсешен чикләде. Болгар чоры, Казан ханлыгы турында без әле хәзер генә, Союз таркала башлагач кына, уйлау һәм фикер әйтү, язу хокукы алдык.

Дөресен әйткәндә, Мәхмүт Галәүдән соң тарихи роман безнең әдәбияттан бөтенләй диярлек юкка чыкты. Драматургия белән поэзиядә дә шул ук хәл күзәтелде. Н. Исәнбәтнең «Спартак» драмасын, М. Җәлилнең «Алтынчәч» әсәрен исә тарихи жанрга искәрмә белән генә кертеп була. «Тарихи» дип атала килгән «Матур туганда», «Онытылмас еллар», «Язгы җилләр» кебек үз чорының данлыклы эпик әсәрләре төбендә исә татар халкына «бәхет өстәгән» — 1917 ел белән бәйле вакыйгалар, ягъни большевизм тарихы ята... Аңа алмашка 1941—1945 еллар сугышы темасы килде. Божра кысылды.

## 2

1992 елның гыйнвар ае азакларында «Казан утлары» журналы редколлегиясенең киңәйтелгән утырышы үткәрелде. Сүз басылган әсәрләр һәм шуңа дәгъва иткән кулъязмалар тирәсендә барырга тиеш иде. Әмма фикер сөреше шактый киңәйде, әңгәмә киерәнке төс алды. Хәзерге татар әдәбиятының үсешеннән канәгать калып, аның казанышлары өчен сөенеп, очынып, шатланып сөйләгән әдип булмады диярлек. Сөйләшүдә дәүләт премиясе лауреатлары, фән докторлары, усал тәнкыйтьчеләр катнашты. Фикер ялкыны күбрәк проза халәте мисалында дөрләде.

Сөйләшүдән очкан очкыннарны бергәрәк туплаасак, шундыйрак хөкем чыгар: «Хәзерге дәверне, безне бүген бимазалаган, тын йокыларын качырган, чәчләрне агарткан кайгы-хәсрәтләрне күз уңына алган әсәрләр аз языла. Басылганнары да сыйфат ягыннан әллә ни түгел. Һәрхәлдә, тарихи үткәнгә багышланган роман-повестьлардан күп кайтышраклар. Булсын олы характерлар тудыру җәһәтеннән, булсын сурәтле фикерләр ноктасыннан...»

Тарих — җиде йозаклы серле сандык, чытырманлы кара урман ул. Аның башы гасырлар чатында күмелгән. Әзсез югалган слублэрне яту ифрат авыр, җаваплы, саваплы эш. Болай фараз кылучылар күпчелек булса да, сөйләүчеләрнең беришесе бөтен әдәбиятыбыз тарих ягына авышып бармыйммы дигән шик-шөбһә дә белдерде. Нефть чыгаручылар, игенчеләр, Чаллыны, Түбән Каманы төзүчеләр турында шаушылып-шапырынып күпме әсәрләр сырлады, түшкә лауреат билгеләре тактык, тик аңа карап кына бу байлык татар халкына тәтемәде. «Кара алтыныбызның бер өлешен

булса да үзебезгә калдырыгыз», — дип әле дә кул сузып шул ук Мәскәү кенәзенә барабыз. КамАЗга «ассоциация» дигән тамга салып, мөлкәтебезне читкә сатып бетерәләр. Ә тарих никадәр генә фаҗигале, әрнүле, йөрәк өзгеч шомлы булмасын — ул безнеке, минеке, синеке! Үзен татар дип санаган һәркемнеке... Сөйләшүдә бу фикер үзәктә торды.

Чыннан да, тарих катламнарын күтәргән әдәби әсәрләргә халык бик нык сусады. Инде ничә буын үзенең үткәнен, кем икәнлеген, каян килеп чыгуын белмичә фани дөньяны куйды. Сыйнфый көрәш рухында тәрбияләнгән, үз тарихына, үлеп-бетеп барган, мәхлүк татар язмышына төкереп караган «интернационалист» буыннар үсте. Тиран үлеп, гильотинаны ремонтлаган арада, илдә демократия җилләре исеп, тезгеннәр бушамаса, тарихыбызны бөтенләйгә дә югалткан булыр идек.

Бүгенге татар әдәбиятында чал тарих сәхифәләренә игътибар артуны берәү дә инкяр итә алмас. Н. Исәнбәт, А. Расих, И. Нуруллин, Н. Фәттах, М. Хәбибуллин, Ә. Баянов, М. Госманов, Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Р. Харис, Г. Рәхим, Батулла, Ф. Латыйфи, Җ. Рәхимов кебек төрле жанрларда эшләүче каләм ияләре тарихның ком барханнары, яндырылган калалар, көлгә әйләндерелгән салалар астында калган рухи байлыкларны, шәхеснең азатлык һәм үзен-үзе саклап калу өчен көрәш эзләрен табалар, аны бүгенгеләргә ирештерү рухы белән яшиләр. Төрле буын язучылары каләменнән төшкән әсәрләрне ватандарлык тойгысы халыкка, җиргә, үткәнгә мәхәббәт хисе якынлаштыра.

Тарих ишегенә теләсә кем шакый алмый. Халыкның үткәнен иңләү өчен әзерлекле, тәҗрибәле, шуңа алынырга хакы булган язучылар кирәк. Бу юлга яңа дәвердә, Хрущев «җепшегендә», аягын чылата-чылата һәм беренчеләрдән булып Нурихан Фәттах чыкты. «Итил суы ака торур» романына алынганчы ул фикерләү үсеше өчен кирәкле байтак әсәрләр язды, бастырды. Беренче тарихи романына тотынганчы ук аның ифрат зур эш башкаруы, фәнни, археологик, этнографик хезмәтләрне, архивларда тузан җыеп яткан кульъязмаларны, халык иҗаты җәүһәрләрен ныклап өйрәнүе, зиһенне, хисе аша үткәрүе дә мәгълүм. Бу хәл романның тыгыз эчтәлегендә, соң чиккәчә кысылган эчке пружинасында, һәр күзәнәгенә табигатьне, кеше холкын, рухын сыйдыруга омтылудан килгән сәнгатьчә эшләнешендә күренә.

Тарихи әсәр язырга алынган шәхеснең эзтабар булуы, гадәти кеше игътибар итмәгән чыганакларда, тарихи өзекләрдә мәгънә күрә белүе һәм хыялга, интуициягә искитмәле бай булуы мөһим. Шуннан килеп, милли романчы һәрвакыт башка халыкларга хөрмәт, ихтирам белән карарга, дуслык, солых һәм мәслихәт кебек үлмәс кануннарны юлдашы итәргә тиеш.

Менә шул сыйфатлар яңа чор тарихи романының беренче карлыгачлары булган Н. Фәттах кыйссасында һәм бу катлаулы жанрга шулай ук бай тормыш, иҗат юлы үтеп килгән Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» романнарында тәгаен чагыла.

Тарихны буып торган тышаулар алып ташланып, шлюзлар ачылган икән, үткәнне җанлы образлар, кичереш-хатирәләр аша иңләгән әсәрләр киләчәктә дә аз язылмас. Әмма иманым камил: Н. Фәттахның «Итил суы ака торур», М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романнары әдәбият тарихында калыр. «Тарихи роман жанры да булган бит әле бездә, җәмәгать! Уяныгыз, як-ягыгызга, үткәнегезгә карагыз», — дип беренчеләрдән чаң супканнары өчен генә дә түгел, әлбәттә.

Бу әсәрләр хакында тәнкыйтьтә фикерләр әйтелә тора. Бирелә әлеге романнарга тарихилык төсмере бөркеп торган берничә үзенчәлеккә генә диккатьне юнәлтәсе килә. «Геройсыз роман — XX гасыр ачышы» дип күпме генә лаф орсак та, олы эпик әсәрне укмаштырып, әйдәп баручы олы язмышлы, көчле ихтыярлы шәхес булырга тиеш. Шул билгеләргә ия булган Алмыш белән Кубратны әлеге романнардан төшереп калдырып карыйк. Ике әсәр дә убылып төшәр, роман исеменә дәгъва итүдән туктар. Милләтне дә, димәк ки, әдәбиятны да шәхес күтәрә. Олы рухлы җаннар аны алга әйди, дип юкка гына әйтмиләр, күрәсең.

Н. Фәттах та, М. Хәбибуллин да үзәк геройларын бизәп, матурлап, илаһилаштырып, былина, дастан баһадирлары итеп сурәтләү юлына төшмиләр. Алар — чор җимешләре. Хакимиятләре көчсезне буйсындыруга, җәберләүгә, деспотик изүгә, талауга корылган. Шул ук вакытта алар ыру, нәсел, киләчәк көннәр ихтыяҗларын башкалардан тирәнрәк аңлыйлар, алданрак сизәләр. Гәвамны буйсындырып, тәртиптә, әхлакта тоту ихтыяҗы Алмыш белән Кубратны күп тәңрелектән, потка табынудан баш тартып, үзәкләшкән идарәне яклый, саклый, нигезен ныгыта алырлык дин кабул итү, ныгытылган шәһәрләр, калалар төзү, сәүдә, һөнәр, игенчелек, терлекчелек кебек өлкәләрне үстерү, гаилә кору, балалар турында кайгырту, олыларны санга сугу, шул ук вакытта һәммә эшне илне басту хаҗәтенә буйсындыру кебек шөгыльләрне үзәккә куялар. Шуннан һич кенә дә тайпылмыйлар. Романнарны бизәгән күп санлы образлар:

хатыннары, балалары, якыннары, дус-дошманнары, мәхәббәт интригалары, әсәр укылсын өчен кертелгән мәкер, хәйлә, хыянәт, алдау, пычак белән арттан кадаулар, ерткычлар белән орышулар, никахсыз бала табулар — һәммәсе төп образларны җанлы, канлы, колоритлы итеп сурәтләү максатына буйсындырылган.

Шунысы да мөһим: Болгар дәүләте турында сакланган чыганакларда һәм урыс, кытай, грек, рим елъязмаларында әлеге каһарманнар хакында азмы-күпме мәгълүмат булу да аларга ышанычны арттыра. В. Ян, И. Калашников романнарының менә инде ничәмә еллар дәвамында мөкиббән китеп укылуының сәбәбе нәрсәдә? Тарихка тирән үтеп керә белүдә, сәнгатьлелектә, диярсез. Анысы да бар. Әмма уңышның серә әлеге китларда гына түгел. Үзәктә берничә гасыр дәвамында дөньяны тетрәткән, иң эре мәмләкәтләрне калтыратып торткан тарихи шәхесләр тора. Әдәби сурәтчеләре тарихи һәм тормышчан күзаллауларга якын. Тарихи шәхесләр турында ышандырып, үзләре күргәндәй итеп сурәтләү, вакыйгалар хакында елын, аен, көнен, сәгатен, һава торышын күрсәтеп бару, классицизм әдәбияты таләпләренә якын тәгәллек — һәммәсе үзенә җәлеп итә, ышандыра.

«Итил суы ака торур», «Кубрат хан» романнары да үзәккә алынган тарихи чорның реальлеге белән алдыралар.

Шул ук мөхтәрәм авторларның «Сызгыра торган уклар», «Илчегә үлем юк» романнары бездә кул чабып каршы алынмады кебек. Баксаң, үзәктә шул ук татар халкының ерак бабаларының катлаулы, буталчык язмышы ята. Авторларның тормыш һәм язучылык, дөньяны кабул итү һәм аңлау тәҗрибәсе дә арткан, дип фараз кылырга мөмкинлек бар. Үзәккә алынган чорлары да шул ук диярлек: Н. Фәттах ераккарак, төрки халыкларның тәүге кабиләләре, дәүләтләре борынлану чорына ук китсә, М. Хәбибуллин исә Казан ханлыгына таба хәрәкәт итә. Мажаралы, мавыктыргыч сюжет сызыклары, кайнар мәхәббәт низагълары бар, батырлыклар да аз эшләнми. Әмма әйдәп баручы, табигатьтәге бушлыкны тутыручы, яңгырны вакытында яудырып, җилне дә кирәк көннәрендә генә истерүче үзәк герой, тарихи шәхес булмагач, романнар мажаралы, хыялый әкияти әсәрләр булып кабул ителә.

Яшәү һәм берләшү өчен көрәш авырлыгын, Көнчыгыш деспотизмының һәм мәкерлегенең көчен һәм көчсезлеген реалистларча ачып биргән, халыкны халык иткән илаһи рухның чыганаклары, ерганак-чишмәләре турында җитди уйландырган, укучыны үзенең кара урман кебек серле сюжет лабиринтлары җәтмәсендә адаштыру сәләтенә ия «Сызгыра торган уклар» романында реаль чынбарлыкны хыял җимеше, фантазия алыштыра. Ерак бабаларыбызның чалымнарын тануы кыен.

«Илчегә үлем юк» романында тарихи фон ныклырак җирлеккә утыртылган булса да, геройларның язучы хыялы җимеше булуы соклангдыру хисен киметә.

Әлбәттә, язучы хыялында оешкан, уйдырма сюжетлы әсәрләр дә язылырга һәм басылырга тиеш. Укучы җир катламы төсле төрле-төрле бит. Әмма бернәрсә бәхәссез: элек-электән тарихи фактларга таянган, булган хәлләрне тулыландырып, шуларны иҗат үзәгенә алган әсәрләргә өстенлек бирелә килә.

Ни өчен О. Форшның «Радищев», Ю. Тыняновның «Пушкин», «Кюхля», С. Злобинның «Салават Юлаев», А. Толстойның «Петр I» романнары тарих «басымын» һәм тормыш дөреслекләрен чагылдыру, сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре нисбәтеннән төрле баскычларда торсалар да, укучы арасында ныклы абруй сакладылар. Чөнки үзәккә реаль тарихи чор, олы язмышлы шәхесләр алынган.

Тарихи жанр таләбен вакытында аңлаган каләм ияләре соңгы елларда үз әсәрләренең үзәгенә татар халкы тарихында атылган йолдыздай эз калдырган реаль кешеләрне күтәрәләр. Бу тенденция элегрәк драматургиядә балкып алды. Н. Фәттахның «Кол Гали», Т. Миңнуллинның «Канкай улы Бәхтияр» — шул юнәлештә эзләнүләр үрнәге. Кешенең көндәлек тормышында таяныч була алырдай документаль, реаль эчтәлекле хезмәтләр әдәбиятка ышанычны арттыра. «Мажаралы, уйдырма хыял уены нәтиҗәсендә генә туган әсәрләргә ихтыяҗ кими бара» дип язуы белән, бәлки, тәнкыйть хаклыдыр.

А. Расихның «Ямашев» романында, Җ. Тәрҗеманов язган Лобачевскийның Казан тормышына, И. Нуруллинның Тукай, Фатих Әмирханнар истәлегенә багышланган әсәрләрендә реаль тарихи җирлек өстенлек итә.

А. Гыйләҗев белән А. Литвин иҗат иткән мажаралы, мавыктыргыч сюжетлы, күп юнәлешле «Августның алтысына кадәр...» романының нигезендә дә документаль башлангыч ята. «Роман-хроника» дигән атама үзе дә менә шул башлангычның әһәмиятен ассызыклый. Әйтергә кирәк, ныклы, төпле, документаль нигездә язылган өлешләре җиңелрәк укыла, ышандыра төшә.

Тарихи тема шагыйрьләрне дә үз агымына алып керде. Тарих һәм поэма, тарих һәм шагыйрь... Төрле яссылыкларда яткан бу төшенчәләрне нинди җирлектә янәшә куеп, бер үремтәдә карап була икән?

Безнең олы һәм фаҗигале, үкенечле һәм батыр тарихыбызда «ак таплар», өйрәнелмичә, сер «саклап» яткан битләр, мәгарәләр җитәрлек. Соңарып богаудан арына килгән милли тарихи аңыбыз роман-поэмаларда гына түгел, еш кына шигырьләрдә дә лирик кичереш дулкынын билгеләи. Г. Саләхнең «Хәтер җебе», Н. Акмаловның «Сират күпере», «Иң борынгы бөек философлар», М. Шәйхинең «Суар капкасы», «Хуҗалар тавы», «Борынгы Буләр җыры» шигырьләре үткәнне хис, тойгы белән иңләргә омтылу үрнәкләре.

Яшь шагыйрь Р. Сүлти җырына илһамны, рухи ялкынны ерак үткәннән таба.

*Җырым минем, кылларында —*
*Итил шавы,*
*Чулман шавы,*
*Болгарымның гөлләр чагы,*
*Казанымның гөрләр чагы.*

Икенче бер шигырендә ул халыкның данлы үткәнен бүгенге бәйсезлек, дәүләтчелек өчен көрәш максатына буйсындырырга омтыла: «Чик кирәкме? Искә төшсен Болгар-йортым чикләре, Алтын-Урда чикләре, Казан-илем чикләре...» («Чик кирәк»).

Нәкъ менә татар тарихы һәм мәдәнияте белән бәйле, аның алтын баганаларына багышланган поэмалар уйдырма әчтәлекле тезмәләргә караганда хәтердә ныграк уелып кала: М. Әгъләмов «Акмулла арбасы», «Тукайдан хатлар», З. Мансуров «Балкыш», Р. Фәйзуллин «Сәйдәш», С. Хәким «Кырыгынчы бүлмә», И. Юзеев «Соңгы төн», «Очты дөнья читлегеннән...», Р. Харис «Җәлилчеләр». Шул хәтлесе сөенечле, күпчелек поэмаларны Акмулла, Тукай, Җәлил, Сәйдәш кебек, олы язмышлы, күренекле шәхесләрнең тормыш юлы, эшчәнлеге якынлаштыра.

Озак еллар дәвамында абстракт һәм гомуми тарих мәнфәгатьләрен кайгыртып йөргән романтик И. Юзеев тә татар тарихына, Җәлил, Тукай образларына әйләнеп кайтты.

Әлбәттә, тарихны иңләү юлында романның үз мөмкинлекләре, шигырьнең үз ихтыяҗлары бар. Проза әсәренең кеше характерын, холкын нечкәләү, гореф-гадәтләрне шәрехләү, сәяси тормышны иңләү мөмкинлекләре зуррак. Шигырьдә исә вакыт белән ара якынлашырга, төрле-төрле чорларда урын алган вакыйгалар берсен-берсе тулыландырырга, ярашырга мөмкин. Г. Моратовның күләме буенча зур булмаган «Алма — риваять» триптихы, Адәм белән Һавадан башлап, кешелек үткән олы тарихны да, «Бер алманы, әй, бишкә бүләек» җырының мәгънәви әчтәлеген дә, Троя, Сталинград, Нагасаки шәһәрләре фаҗигаларын да сыйдырган. Шагыйрь тормыш күренешләрен эзлекле сурәтләү юлына төшмичә, символик күзаллауларга таянып, үткәнне, бүгенгене, киләчәкне уртак вакыт төшенчәсенә җыя. Һәр буын — мәңгелекнең бер мизгеле, чылбырның бер буыны. Романда исә болай «кылану» гайре табигый саналыр иде.

Тулаем алганда, замана язучыларын татар дәүләтчелегенең иң беренчел дәверенә игътибарсызлыкта гаепләү дөрес булмас. Чал тарих сәхифәләрен сәнгать чаралары белән иңләүгә хәрәкәтне туктатуы кыен. Бу яктан Ә. Баянның «Алтын кашбау», Г. Рәхимнең «Аяз көнне яшен», Р. Харисның болгар дәүләте белән урыс кенәзләре арасында төзелгән дуслык солыхының мең еллыгына багышланган «Ант суы» поэмалары игътибарга лаеклы.

Әчтәлекләре, жанр үзенчәлекләре нисбәтеннән төрле-төрле булган бу әсәрләрне ике уртак максат берләштерә. Берсе — урта гасыр дәүләтләре арасында Болгарның мәдәни, сәяси, игътисадый яктан нык алга киткән, көчле ил булуын күрсәтү. Ә. Баян белән Г. Рәхим әсәрләренең үзәгендә шул олы максат ята.

*Үргә басып, өркеп кешни Вакыт —*
*Унөченче гасыр уртасы.*
*Йорт-диварлар тетелеп, эри металл,*
*Дөрләп яна нигез — чор ташы.*
*Атлап ята, илләр һәм Аллалар.*
*Җыя алмый ята Җир аунап, —*

дип яза Ә. Баян кырыс дәвер образын тудырып.

Хыял канатында тарихка юл алып, шагыйрь Идел-Чулман буйларында мул тормыш белән гөрләп яшәп, чәчәк атып утырган Болгар илен тасвирлый. Башкаларны талау исәбенә көн итәргә өйрәнгән монгол явы болгарлар өстенә өерелә. Даланы чирүен берничә тапкыр куып җибәрсә дә, дошманга каршы берүзе сугышкан Болгар иле җиңелә, яндырыла, талана, халкы буйсындырыла.

Авыр сынау көннәрендә кешеләр икегә бүленә. Берәүләр дәррәү дошманга каршы күтәрелә (галим, фикер иясе Баян), икенчеләре илен, халкын, намусын, мәхәббәтен сату һсәбенә булса да, гомерен озайту турында кайгырта (Балтамар, Изух).

«Аяз көнне яшен» поэмасында Болгар иле җимерелеп, елан тавы куенында Казан шәһәренә нигез салыну вакыйгасы үзәккә алына. Болгар-татар халкының җир йөзендә калу-калмавы кыл өстендә. Шәһәрләр яндырылу, халык кырылу, җиңүчеләр алдында тез чүгү, бил бөгү, тәлинкә тоту, сатылу чоры башлана. Менә шул хәтәр чорда халык арасыннан милләтнең иң яхшы сыйфатларын җыеп алган Илбакты кебек батыр йөрәкле узаман күтәрелә һәм, яһүд пәйгамбәре Моисей төсле, исәннәрне үзе белән алып китеп, халыкны юкка чыгудан коткарып кала.

Сәхнәдә опера булырак та яңгыраган, әмма, кызганычка каршы, репертуардан алып ташланган бу әсәр (Ә. Бакиров көе белән), «Алтын кашбау» шикелле үк, бер хакыйкатькә инандыра: татар халкы элек-электән яшәү өчен авыр, тигезсез көрәш алып барган, киләчәге һәрдаим куркыныч астында торган, шул ук вакытта аның һәр чорда ялангач йөрәген, гаҗиз җанын югары күтәреп, юл яктыртып барырдай пәһлеваннары Баян, Илбакты, Сөембикәләре, Батыршалары үсеп чыккан.

Болгар дәверенә багышланган әсәрләрнең икенче бер кыйммәтле сыйфатына игътибарны юнәлтәсе килә. Урыс елъязмаларына, халык иҗаты әсәрләренә таянып, рәсми тарих фәне монголлар белән татарларны ике атамалы бердәм халык дигән фикер урнаштырды. Ул гына да түгел, Чыңгыз-Бату баскынчыларының бөтен әшәкелеге, явызлыгы, кыргыйлыгы хәзер татар дип аталган халыкка сылап калдырылды. Ауропада шул тәгълимат кабул ителде. «Саф» монголлар тарих хөкеменнән бөтенләй читтә калды.

Хәзерге урыс язучылары каләменнән төшкән әсәрләр дә татарга каршы шовинистик махмырны куерта торалар. Аның югары үрнәген В. Чивилихин «Память» эссесендә биреп калдырды. В. Пикуль аны кабатлады. Хәзерге романист Д. Балашов татарга яла ягуда өлкән каләмдәшләреннән һич кенә дә калышырга ниятләми. «Ветер времени» исемле иң соңгы романнарының берсендә монгол сүзе әйләнештә юк диярлек, урысны җәберләү, ясак җыю, алдау, хәрәмләү исәбенә яшәгән татар станы ордынка, явыз татарлар гына бар. Юынырга сабын җиткереп кара! Тарихны шул чаклы бозу, чалыш көзгедә аша күрсәтү, хакыйкатьне аяк астына салып таптау, чеп-чи ялганны дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрү мәдәни мохиттә була аламы? Юктыр, башка шундый мисалны табуы кыен булыр.

### 3

Илбакты кебек батыр ирләр нигез ташларын салган Казан ханлыгына да көнче, хөсет, ач күзле күршеләр, ерактагы зур нәфесле кардәшләр тыныч яшәргә ирек бирмиләр. Бигрәк тә Алтын Урда таркалганнан соң хәлләнеп алган урыс империясенә кайгы-хәсрәтсез яшәвен дәвам итәр өчен яңа җирләр, казнасына өстәмә байлыклар кирәк була. Аның юлында, бугазга кадалган сөяк төсле, кодрәтле дәүләт — Казан иле тора. Аны йотмыйча, Идел буеның уңдырышлы кара җирләренә, диңгезләргә чыгып булмый.

Иван Грозный 1552 ел походына ныклап, еллар дәвамында әзерләнә. Хакимият бүлешеп, хатын кочагында мәрткә киткән татарның борын төбендә ныгытма — шәһәр салып куя, чиркәүләр кора. Зур хәрби көч туплау өстәвенә, христиан мәмләкәтләренең ризалыгын, ярдәмен ала. Әйтик, артиллерия һәм шартлату эшләре белән җитәкчелек итүгә, Казан уртасында үзенә иң мәһабәт һәйкәлләрнең берсе корылган химик Бутлеровның бабасының бабасы инглиз полковнигы Бутлер чакырыла. Басып алынган территориядән аңа бик зур биләмә җирләр бүләк ителә. Чуаш, ар, мукшы, чирмеш халыкларын, Касыйм, Сергач мишәрләрен хәйлә, мәкер белән сатып алу, куркыту, өркетү юнәлешендә зур әзерлек алып барыла. Казанда яшәүче әрмән диаспорасы һөҗүм башында үк сусаклагычларның, су юлларының серен сата, урыс гаскәрләренә кирәкле башка хәбәрләрне ирештерә тора. Казан язмышы алдан ук хәл ителгән була.

Бу мәгълүматлар һәркемгә таныш, тарихчылар ризыгына кул сузарга җыенмыйм. Әлеге фаҗига соңгы елларда иҗат ителгән берничә әсәрнең нигезенә ятты, аның турында шуңа гына искә алып китүем. Батулланың «Сөембикә кыйссасы», Ә. Рәшитовның «Сөембикәнең казан халкы белән хушлашуы», Ф. Латыйфиның «Хыянәт» әсәрләрен күздә тотам мин.

Артист, режиссер, драматург, күпләгән шук әсәрләр авторы Батулланың изге тарихи темага алынуы үзе бер батырлык. Күләме белән шактый саллы романга

аерым китап булып, тулы көенчә басылып чыкканчы, гомумән бәя бирү, мөһер сугу бурычын өстемә алмастан, Сөембикә образына гына тукталып үтәсем килә.

Татарның олы тарихында, Сөембикә кебек, халыкның рухында, әхлакый күзаллавында, сурәтле фикерләвендә үрнәк өлге, фәрештәдәй изге җан булып сакланган шәхесләр күп түгел. Бәлки, аңа тиңе юктыр да. Сөембикә — татар кызы гына түгел, ничәмә буыннарның күңел түрендә яшәгән азатлык, баш бирмәү, тез чүкмәү, дәүләтчелек байрагы да. Күпчелек халыклардагы шикелле үк, ул һәр чорның кеше турындагы идеалына, хыялына җавап бирә. Андый шәхесләрне тарихи зарурият күтәрә, халык әдәбияты аның рухын гасырлар дәвамында җанында саклап, буыннан-буынга илтә.

Батулла җырларда, риваятьләрдә, мөнәҗәт-бәетләрдә, елъязмаларда сакланган саран истәлекләргә таянып, легенданың зәңгәрсу томанына төренгән, беркадәр идеаллаштырылган Сөембикә образын тудыра. Автор аны артык вакласа, җиргә төшерсә, характерының җитешсезлекләрен тәфсилләсә, халык андый Сөембикәне кабул итмәс, күңеленә үткәрмәс иде шикелле.

Батулла халык рухында, әхлакый-фәлсәфи күзаллавында урынлашкан «киек каз юлы»на тугры калган хәлдә, героинясен шатлана-кайгыра, сөя-сөелә, рухи һәм матди дөньяны тулаем кабул итәрдәй җанлы, тулы канлы шәхес итеп сурәтләргә омтыла.

Шул ук вакытта Сөембикә башкаларга охшамаган, берәүне дә кабатламый. Ул башбирмәс, башкисәр булып, сугыш уеннары белән мавыгып үсә; көтмәгәндә кылыч-калканын ташлап, китапханәгә кереп бикләнә. Ирләрдән җил, хатыннардан төтен исе килеп торган гади халыкны якын күрә. Яшәү — аның өчен аралашу, туктаусыз хәрәкәт. Торгынлыкны җене сөйми. Кыскасы, аның характерында, холкында якыннары да аңлап җитмәгән эчке рухи бөтенлек, үз билгесе, тамгасы, сынау, сынамышлары бар.

Дөрес, аның балалык, яшьлек елларына, ирдәүкәләнеп, «тилереп» йөрүләренә романда урын һәм вакыт күбрәк бирелгән дигән тәэсир кала. Ул өлешләре авыр укыла, үзе артыннан өермәдәй алып кереп китә алмый.

Тынгысыз характеры, бәйсез тормышка омтылуы Сөембикәне халыкның бөек кызы дәрәҗәсенә күтәрә. Аңа үз эчке азатлыгын кыргый гореф-гадәтләр эчендә саклау өчен ифрат көч куярга туры килә. Кая карама чикләү, кимсетү, хатын-кызны кешегә санамау. Ногай далаларында килешкән ырым-гадәтләр Казанда батмый. Ташып торган җегәрле шәхес чынбарлык белән бәрелешә, конфликтта бәргәләнә. Казанлылар мәнфәгате өчен үстерелгән бакча да, мәктәп-мәдрәсә дә кемгәдер охшамый, дошманнары аның иң изге ниятләреннән дә гаеп эзлиләр.

Тарихның олы хәрәкәте эчендә аерым шәхес җәфалана, үзенә тиешле урынын, шөгылен табып җиткерә алмый. Ә һавада киләчәк фаҗига исе. Акрынлап геройның иҗтимагый язмышы үзәккә калка.

Сөембикә тәкъдиренә язылган юлны горур һәм тәкәббер үтә. Аның корычтай ихтыярын, кристаллдай саф әхлагын гайбәт тә, зиндан да, ярты дөньяны калтыратып торган явыз Иван белән очрашу да куркытмый. Ул үлеменә пәһлеваннарча килә, үлемен җиңеп үлә.

«Сөембикәнең Казан халкы белән хушлашуы» поэмасында Ә. Рәшитовны халыкның яраткан кызына мөнәсәбәте борчый. Поэма ваклауны, детальләштерүне өнәми. Шагыйрь ярым тарихи, ярым легендар Сөембикәнең кешелекле, тормышчан, җанлы образын тудыруга ирешкән.

*Ни диеп елыйсыз, әбиләр?*
*Абзыйлар, кайгыгыз ни икән?*
*Батырлар, ник бөек сез болай?*
*Тик бер сүз җавапка:*
*— Сөембикә...*
*Рәхимле, шәфкатьле, сөекле*
*Сөембикә — бер иде ул илдә.*
*...Бу иңрәү-сыкрауны ишетеп,*
*Моңайган шикелле Идел дә.*

Болгар патшалыгы һәм Казан ханлыгы чорыннан бик аз сакланган елъязмалар, халык иҗаты әсәрләре, буыннар хәтере китереп җиткергән истәлекләр, авторлар ихтыярына, максатына, фикер һәм хис агышына буйсыналар. Бик күп өзекләрне шагыйрь хыялы тулыландыра.

Тормышны иңләүдә, әлбәттә, романның мөмкинлекләре киңрәк. Батулла тарихи җирлекне күз алдына бастыруга зур әһәмият бирә, Сөембикәне, аның нарасый улын хурлыклы, фаҗигале язмышка китергән сәяси буталышларны, Казанга каршы

Мәскәү алып барган астыртын, мәкерле интригаларны, Шаһгали кебек сатлык җаннарны сурәтләүгә урынны кызганмый.

Дөрес, вакыты белән Батулла әсәрен юри катлауландыра, исемнәр, атамалар белән дыңгычлап тутыра, һава җитешми башлый. Бигрәк тә беренче яртысында. Буш хәрәкәт эчендә кайнау шуннан килеп чыга.

Сөембикә үлеменнән соң күңелдә дә, Казанда да шомлы бушлык. Дөрес, кала кайный, дәрли, сыкрый, соңгы көрәшенә әзерләнә. Кырым, Әстерхан ханлыклары, башкорт җайдаклары көчле христиан доньясы белән орышырга Казанның берүзен калдыралар. Ә шул ук кара көч, аждаһа тиздән үзләрен дә йотачак.

Ф. Латыйфи Казан фаҗигасе турында сөйләүне Батулла «тукталып» калган җирдән алып китә. Казан даирәләре Иван алдында тез чүгеп, ялагайланып, Сөембикәне малае белән Мәскәүгә озатса да, дәүләтен коткарып кала алмый. Кальганың муены үлем элмәгендә.

Менә шунда халыкның сәламәт уллары дошман явына каршы көрәшкә күтәрелә. Яшь хан Ядегәрне кара болыт төсле һәрьяклап Казанны чолгап алган урыс чирүенең күплеге куркытмый. Тарихи шәхес, дин әһеле Кол Шәрифкә дә мөһим урын бирелә романда. Ул — җитлеккән акыл иясе, халыкның киләчәге турында уйланып, борчылып яшәгән олы зат буларак күз алдына баса. Шул фонда сатлык җан Камайныңваклыгы, мескенлеге, шәхес буларак юкка чыгуы тулырак ачыла.

Автор чыганакларга, елъязмаларга таянып, реаль тарихи җирлекне тоеп, Казанны яклаучыларның батырлыгына дан җырлый.

Ф. Латыйфи, Батулла шикелле үк, тасвир үзәгенә алынган чорның көнкүрешенә, кием-салымына, бизәнү әйберләренә шактый тирән үтеп керә алган.

Гегель тарихи материаллар белән шөгыльләнүче кешеләрне, үткәнне күрәзәлек итүче пәйгамбәрләр, дип атый. Чыннан да, тарихи роман очраклы вакыйга, хәйлә белән эш йөртә алмый, аның нигезендә анык концепция, зарури мәҗбүрият ята. Автор агачлар артында урманны, аерым хәлләр, вакыйгалар куелыгында тарихи закончалык буларак вакыт хәрәкәтен сиземли, күрә белергә тиеш.

«Хыянәт»нең геройлары вакыты белән безнең коннәр, яңартып кору, империяне таркату чоры кешеләре теле белән сөйләп, фикерләп куялар. Бу табигый, чөнки Казан ханлыгының вәхшиләрчә, кыргыйларча юкка чыгарылуы тарихын белмичә, андагы алдынгы һәм кара көчләр хәрәкәтенә төшенмичә җөмһүриятебезгә тулы мөстәкыйльлек алу кыен булачак.

Кол Шәрифнең урыслар белән орыш алдыннан гаскәр башлыкларына, дин әһелләренә мөрәҗәгатен укып карыйк. «Инде янә шунысын да фараз итик, Казан кеби көчле, шанлы, тамыры нык мәмләкәтне тар-мар китергән көч ургылып Иделбуйлап китәр, Хазар, Азак, Кара диңгез ярларына таралыр. Ары таба — көнчыгышына таба тамыры нык мәмләкәтләр юк... Мул ризыктан бу кавем котырып үрчер... Хәзергә без сан ягыннан бер чама. Тора-бара икеләтә, соңра өчләтә, янә дүртләтә кимербез. Коллыгыбыздан котылмасак, тора-бара унлата... Шулай дәвам итәр. Иң яхшы угыл-кызларыбыз коллыктан, котылу өчен христиан кавеменә күчәр... Без шушыны телибезме?!»

Дин башлыгының күрәзәлеген тарих тулысы беләнаклады. Әйтерсең лә безнең каршыда XX гасырның соңгы чиреге мулласы чыгыш ясый.

Дөрес, әсәрнең тел-стиль чараларын «заманчалату» урта гасыр колоритын ачуга бераз комачаулый. Аннан килеп, роман геройлары мәкаль-әйтем куллану белән артык мавыгалар, һәркайсы Нәкый Исәнбәтнең өч томлык мәкальләр китабын ятлап килгән диярсең. Яшь язучының олы темага алынуы, олы тарихның кадерен белеп, анда үз темасын, юнәлешен, фәлсәфәсен табуы куанычлы күренеш, әлбәттә.

Татар халкы XVI гасыр уртасында кичергән фаҗига турында әлегәчә тиешле бәһасен алмаган тагын бер әсәр бар. Шул чор шаһите каурыеннан төшкән «Казан патшалыгы турында кыйсса» ул. Аны 1959 елда, Хрущев хакимлеге дәверендә, хәзерге урыс теленә җайлаштырып проф. Н. Водовозов чыгарып калган иде.

Әлеге кыйссага өлкән агайлар бик сакланып һәм сирәк мөрәҗәгать итә. Хрестоматияләргә дә җиз иләк аша үткәреп кенә кертәләр. Ни өчен дисезме? Хикмәт шунда: билгесез шагыйрь Иван Грозныйның Казанны яулап алу сәясәтен аклау, үз патшасын дан мөнбәренә күтәрү максаты белән юлга чыкса да, кыргый үч алу, дәүләт дәрәҗәсендәге геноцид, халыкны тоталь юкка чыгару күренешләрен читләтеп үтә алмый, фактлар белән төгәл эш итә, әйтер сүзнең кадерен белгән кеше буларак, нәтиҗәне курыкмыйча ясый. Акны кара дип расларга теле әйләнми. Әгәр ул коммунистлар фиркасында торса, мөгаен: «Без Казанга халык соравы буенча, анда яшәгән христианнар каршында интернациональ бурычыбызны үтәү өчен килдек һәм, алар гозерен үтәп, каршылык күрсәткән татарларны тәрбияләү ниятен-

нән, якты, бәхетле киләчәк өчен 5 мең чирмешне, 500 затлы нәселне гаиләләре белән (марксизм семьяны бүлгәләүгә каршы), сәяси үсеш дәрәҗәләре түбән, сыйнфый көрәшне аңларга теләмәгән 12 Арча кенәзен туфракка иңдерергә булдык»,— дип язар иде.

Кыйсса авторына рәхмәтле булырга тиешбез, ул мондый икейөзлелек, фарисейлык юлына басмый, намусы кушканча, мөмкин булганча хакыйкатькә тугры кала.

Урыс елъязмачысы казанлыларның фидакарь батырлыгы белән соклануын яшерә алмый, аерым урыннарда: «Бер татар илле дошман белән орышты, хатын-кызлары тиз генә уктан атарга, кылыч тотарга өйрәнеп, сугыш киемнәренә төренеп, үлгән укчыларның урынын алды»,— дип яза (бу эпизод Ф. Латыйфи әсәренә уңышлы кереп киткән).

Елъязмачы Казан халкын юкка чыгаруның коточкыч манзарасын тасвирлый. Аккан каннан урамда күлләр хасил була, канлы балчык атларны суырып ала. Бигонаһтан куркыш юк, чиркәүгә тиенлек шәм куйсаң, христиан дине теләсә нинди явызлыкны кичерә бит. Патшадан әмер шундый: яшь, чибәр хатыннарны Мәскәүгә озатырга, сугышчыларга кулланырга бирергә, ир-ат җенесен юкка чыгарырга, буе арба биеклегеннән узмаган балаларны, «Казанская сирота» дип хәер эстәргә чыгарып җибәрергә. Урыс — «мәрхәмәтле» халык: христианлыкны кабул иткәннәрен үстерер, аларны Циолковский, Карамзин, Тургенев, Купринnap дәрәҗәсенә күтәреп, дөньякүләм мәртәбәдә йөртер, үзен яулап алучыларның данын үстерергә мөмкинлек бирер.

«Казан патшалыгы турында кыйсса» хәзерге рәсми тарихның тагын бер уйдырмасын, ялганын фаш итә. Казан дәүләтен юкка чыгаруның максаты, сәбәбе турында фикер йөртергә кирәк булганда, империячел тарихчылар юха елandай бөргәләнәләр, чүп өстенә чүмәлә өя баралар. Янәсе, казанлылар Мәскәү тарафларына туктаусыз һөҗүмнәр ясап, бимазалап, тынычлыкны бозып торганнар. Бу мифны статистика исемле ай шикелле һәрнәрсәгә битараф фән чәлпәрәмә китерде. Килешүләрне урыс ягы еш рак бозган икән.

Имеш, Иван Грозный походына чаклы урыс әсирләре Казанда бик начар хәлдә тотылган да, аларны азат итү ихтыяҗы туган. Мөселманнар чиркәүләрне ватып, христиан динен мәсхәрәләгәннәр дигән уйдырма да тарихка аек һәм җитди мөнәсәбәт буларак кабул ителә алмый. Мәгълүм булганча, Болгар, Казан дәүләтләрендә барлык диннәр дә иркен яши.

Казан ханлыгын җимерүнең нигез сәбәбен шул ук чор язучысы сабыйларча самимилек белән ачып сала. Урыс дәүләтенең җитәкче даирәләрен, ач күзләрне Казанның байлыгы, алтын-көмеше, затлы ташлары, келәмнәре, кыскасы, мул наны иләсләндерә. Коралы халыкны үстерү өчен сәяси җим отышлы: тел башка, дин үзгә, басурманның илен ват, җимер, халкын тапта, тура, ас, кис!

Комсызлык явызлыкка, вәхшилеккә алып килә, берәүне дә уклар яңгыры куркытмый, һәркем шәһәргә беренче керү турында хыялланa. Чөнки аңа байлыкның симез калҗасы эләгәчәк.

Кыйсса авторы Казанны талау вакыйгасын гаять төгәл тасвирлый, аның бик күпкә барачак нәтиҗәсен дә күзаллый.

*И тогда наши многие воины,*
*Что в земле находили сокровища,*
*На всю жизнь богатели от этого,*
*И хватило богатства казанского*
*Сыновьям их, и внукам, и правнукам!*
*И не нужно им было заботиться*
*О домашней нужде и потребностях,*
*И они веселилися с женами,*
*Со своими детьми беззаботными.*
*Так они, мало дней потрудившиеся,*
*На всю жизнь тем себя обеспечили!*

Рафаэль Мостафин юкка гына Кабан күле төпләреннән юк алтынны эзләргә чакыра. Җиңү, Казанны коткарып калу турында гына уйлаган татар халкы байлыгын яшерергә дә өлгермәгән булса кирәк. Барысы да дошман кулына төшкән...

## 4

Татар халкы үз дәүләтен һәм кешелек хокукларын, үзен әйдәп барырлык, көрәшкә күтәрерлек лидерларын югалтуы өчен ике патшага аерата «бурычлы»: Иван Грозныйга, Иосиф Сталинга... Дөрес, Рәсәй һәм Совет империяләренең башка

түрәләрс дә «яулап алынган, таланып яткан халыкка хет бер яхшылык эшлим әле» дип берсә дә сикереп төшмәде. Казанның 800 еллыгын билгеләп үтәргә рөхсәт бирмәүне генә искә алыгыз!

Әмма татар халкын мескенлек, хәерчелек, наданлык упкынына шул ике тиран ташлады. Алар кылган явызлыкларга кешелек тарихыннан чагыштыру өчен мисаллар табуы кыен.

Фәрит Яхинның «Үсеш» шигырендә татарның әнә шундый мескен, кимсетелгән хәле, сындырылган рухы шактый төгәл, куертылган алымнар аша күзалдына бастырыла:

*Очкын күзем сүрелде...*
*Сөяк бирсәң — кимерәм,*
*Калҗа бирсәң — симерәм,*
*Дошманыңа мин өрәм, —*
*Эт хезмәтендә торам!*

Болгар, Алтын Урда, Казан тарихларын чалыш көзгә аша күрсәтү Сталинның Иван Грозныйны «прогрессив патша» дип бәяләвеннән соң көчәйде. Рәсәй тарихында да тиңе булмаган канэчкеч вәхши турында Алексей Толстой, паласта мәтәлчек атып Сталинның кәефен күргәннән соң, шашына-шашына драма-дилогия яза. Явыз Иванга багышланган фильмны Сталин аеруча яратып карый. Тираннарга бербереен аңлау өчен вакыт, милли, сәяси чикләр һич кенә дә киртә була алмый, күрәсең.

Сталин диктатурасы чоры әдәбиятта киңрәк, тирәнрәк яктыртуны таләп итә. И. Сәлаховның «Колыма хикәяләре» Сталин тираниясенең бер ягын гына, анда да әдәбиятта шактый яктыртылган, күзгә бәрелеп торган кыйбласын күз уңында тота. Дөрес, бу чор А. Гыйләҗевның «Өч аршин җир» әсәрендә (пьеса вариантында тулырак), М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повестенда, Ә. Еники, Г. Бәширов язмаларында азмы-күпме бәяләнә. Иң соңгы әсәрләрдән Г. Тавлинның «Афәт» романы шул чорның коточкыч караңгы, куркыныч, чиркангыч атмосферасын күз алдына бастыра. Әсәр төгәллеге, ныклы документаль нигезгә утыртылган булуы белән дә җәлеп итә.

Татар һәм башка халыклар башына коточкыч афәт булып төшкән Сталин режимын китереп чыгарган XX гасыр тарихын һич тә онытырга ярамый. Шагыйрьләр бу темага әледән-әле әйләнеп кайталар.

З. Мансуровның «Хозыр галәйһиссәләмне эзләү» поэмасы — үткәннең әхлакый, рухи, фәлсәфи казанышларына таянып, хәзерге халәтебезне аңларга омтылуның бер үрнәге. Үлчәм берәмлеге, дәверләрне сынау алымы итеп изге Хозыр Ильяс алына.

Менә шул үзәк образ шагыйрьгә шактый олы мәсьәләләрне күтәрергә, бигрәк тә XX гасырның канлы фаҗигасен иңләргә җай тудыра. Бүлекләргә бирелгән атамалар гына да поэманың юнәлешен, фикер сөрешен күзалларга мөмкинлек бирә: «Коммунистик үгез. Канлы намазлык», «Намус җаннан кадерле», «Балаларын ашый инкыйлаб», «Төрмәләрдә чөрету тәҗрибәсе», «Канлы аваз», «Тиран өчен бишек җыруы», «Каргалган авыллар...» Күңелгә шом, йөрәккә чиркану, куркыныч үтә. Хозыр картка бу вәхши дөньяда, варварлар станында урын юк.

*Кермәгәне өчен колхозына,*
*тиңләштереп корткыч кулакка.*
*Хозырыңны совет хөкүмәте*
*әллә сөрде микән ГУЛАГка?!*

*Япкаңнардыр бәлки япоңнарның*
*шпионы, диеп, бу мужик?!*
*«Империя зла» исеменә*
*юкка гына лаек булмадык.*

Совет чорында татар халкы ил күргәнне күрде, «Империя зла»ның түбән башкалардан азрак татымады. Ә бит аның канынnan яратылган бавырдашларын шул ук канда тончыктыру ничәмә гасырлар дәвам итә. Шагыйрь бу хакта да искә төшерә.

*Богауларга тузган болгарларны,*
*Сордең, гәүр, аттың, астың да...*
*Кунеккәндер инде көнкүрешкә*
*культикларның култык астында.*

*Казаныңны Иван казаматка*
*Әйләндергәч, якты көн нигә?*
*Карышмасаң Рәсәй карынында,*
*караңгыга күзләр күнегә.*

М. Каюмовның «Угры» шигъри хикәясе дә шул чор турында. Үзәктә — 30 елларның гадәти бер авыл малае. Дәү әтисе совет властен яклап сугышуына карамастан, кулакка чыгарыла, атасы югала, абыйсы сугышка алына, ач, ятим малай ашлык урлап тотыла. Конвойдан качып, ил буйлап йөргәч, Кореядан орден тагып кайта. Ә аны тентеп, төрмәгә озаткан элеккеге рәис Шәйхи әле дә исән, чәчләре ак, яланаяк, куллары калтырый. Үткәндә кылганнары өчен үкенә.

Шигъри чаралар вакыйга канвасын төгәл итеп, динамикада сурәтләргә мөмкинлек бирә. Бердән, «Табаларга салган балык кебек, язмышкае утта кызган җир», «...Яраланып ауган болан кебек, ыңгыраушты басу капкасы», «Агачны бер яшен сукса әгәр, корыткачны, диләр, телгәли» кебек сурәтләре рухи дөньяга үтеп керү мөмкинлеген киңәйтсә, икенчедән, автор шәхсидән гомумигә, чорның коточкыч явыз шәүләсен тудыруга омтыла:

*Әсир төшкән дошман явы түгел,*
*Илнең «әсирләре» теләлеп*
*Конвой булып китте таш калага,—*
*Бәндәсенә бирсен түземлек!*

Тарих үзенең балаларын сыный. Һәрдаим үзенә тугрылыкта сыный. Ә вакытның көтәргә вакыты юк. Һәр көн гомерне кыскартып кына калмый, үз яңалыкларын да өсти тора. Н. Арсланов тарих белән замана арасындагы мөнәсәбәтнең мәгънәсен, эчтәлеген болай күзаллый:

*Хәят белеп тора:*
*Картлар үлеп тора,*
*Яшьләр күреп тора,*
*Язмыш көлеп тора...*

Әйе, илдә урнашкан бүгенге хәлләр тарихи үткәнебезне иңләргә, аңларга, сурәтләргә мөмкинлек бирә. Элек-электән татарга ирек, азатлык бик азга, санаулы мизгелгә генә бирелә килде. Форсатны кулдан ычкындырырга ярамый, тарихыбызны каршыларга юлга чыгыйк. Ул — туачак буыннарның юлдашы, киңәшчесе, таянычы булсын. Тарихка уелган һәр тәрәзә киләчәгебезгә якты нурлар сирпесен!

# «НИ ӨЧЕН?»НӘР ТУРЫНДА

Булачак укытучылар белән совет хакимияте елларындагы татар әдәбияты турында сүз алып барганда, миңа еш кына сораулар яңгыры астында калырга туры килә:

— Һ. Такташ ни өчен солтангалиевчеләргә багышланган шигырен «Син дошманын минем» дип атаган?

— Кәрим Тинчуринны аның юбилей тантанасы бик зурлап үткәрелгән кичнең төнендә кулга алалар. Бер төн эчендә кеше дошман булып әверелә аламыни?

— Г. Ибраһимов ни өчен революциягә кадәрге әсәрләрен кешенең «үзәгенә үткәреп» яза да, егерменче еллардан соңгы иҗатын исә сәясәт белән сугара башлый?

Әнә шулай — сорауларның иге-чиге юк. Яшьләрнең кызыксынучан күзләре синнән җавап көтә.

— Әйе, яшьләр,— дим мин,— сез сүзне бик олы максатка — әдәбиятның эстетик һәм социаль ягын бердәм итеп карау ягына юнәлдерәсез. Чыннан да, иҗтимагый аңның бер күренеше һәм сәнгать төре буларак, матур әдәбият бу ике якның катнашмасыннан гыйбарәт. Берәр әсәрне укыганда кеше йә күз яшен түгеп алмаса яки рәхәтләнеп көлеп җибәрмәсә, ләззәтләнүдән яки нәфрәтләнүдән авыр сулап куймаса, бу хикәя яки роман үзенең бурычын үти алмаган дип санарга мөмкин.

Шул ук вакытта, матур әдәбият җәмгыятьтә бара торган көндәлек яки дәвамлы вакыйгаларга да битараф кала алмый. Күп вакыт бусы алгы планга да килеп чыга. Монда язучыны гаепләп булмый. Тик бер шарт бар — әсәр сәнгатьчә камил һәм тәэсирле булсын.

Әмма тарихта кешеләрнең сәясәткә аеруча нык бирелгән вакытлары була. Егерменче-утызынчы һәм безнең хәзерге елларда, әнә шулай. Гадәттә, мондый вакытта, укучыны да әсәрнең сәяси юнәлеше күбрәк кызыксындыра, шуңа күрә язучы да шушы ихтыяҗга юнәлеш тота.

Мәсәлән, 1940 елның февраль-март айларында М. Җәлил Казанда һәм Мәскәүдә Ш. Камалның иҗади эшчәнлегенә утыз ел тулу уңае белән докладлар ясый. Ул өлеге чыгышларда менә нәрсәләр әйтә: «Ш. Камалның көче, беренче чиратта, аның иҗатының партияле һәм идеяле булуында». (Җәлил. М. Әсәрләр, 4 том, 1976, 223 бит.) Дөрес, М. Җәлил Ш. Камалның язучы буларак көче «аның иҗатының халыкчан булуында, хакыйкатькә хезмәт итүдә, гуманизм идеяләренә тугрылыклы булуда» икәнен дә әйтә. Әмма, шулай да, күргәнебезчә, иҗатның партияле һәм идеяле булуына «беренче чиратта» игътибар ителә. Югыйсә Ш. Камалның сүз рәссамы булуы аның байтак әсәрләре, аеруча «Акчарлаклар» повесте белән күзгә бәрелеп тора. Ләкин аңлашылса кирәк, докладчыга шул еллар мохите белән исәпләшергә туры килгән.

Бу урында шуны әйтәсе килә: әгәр партиялелек һәм идеялелек сәнгатьлелекне тәэмин итүче шарт булсалар, К. Маркс, Ф. Энгельс, В. Ленин, В. Плеханов, Н. Бухарин һәм башкаларны иң бөек язучылар дип санарга туры килер иде. Ләкин, юк — болар тарихта иҗтимагый теоретиклар һәм сәясәтчеләр булып кереп калдылар. Алар язучылыкка дәгъва кылмадылар, үзләрен сүз сәнгате эшлеклеләре итеп санамадылар. Димәк, язучы үзенә хас сыйфатлары белән сәясәтчеләрдән аерылып торырга тиеш. Дөрес, язучы да сәясәтче, ләкин ул — образлар белән эш итүче сәясәтче. Әгәр шулай булмаса, Ю. Фучикны, Г. Лорканы, М. Җәлилне, А. Алишны һәм башка каләм әһелләрен фашистлар юк итмәсләр иде.

Әйе, язучы — нинди дә булса идеология вәкиле, ул шуны әсәрендә аңлы рәвештә үткәрә. Ләкин ул язучы икән, моны сәнгать көче белән, әдәби образлар, үтемле сүз ярдәмендә эшли. Шул рәвешле, чын әдәби әсәр турында сүз барганда, һәрвакыт аның эстетик тәэсир көче, шуны тәэмин итүче чараларны билгеләү алгы планга чыгарга тиеш. Киресенчә булган очракта, әдәби әсәр турындагы тәнкыйть хезмәте сәяси публицистикага әйләнеп кала. Бу хәл, телисеңме-теләмисеңме, мәктәптә әдәбият укытуга да тәэсир ясый.

Институтларда һәм университетта да булачак укытучыны әдәби әсәргә социологик анализ ясарга өйрәтәләр. Һәрхәлдә, соңгы елларга кадәр ул, нигездә, шулай булды. Икенчедән, дәреслекләр, программалар да социологик бәя бирүгә шактый күп вакыт бүлә. Хәзер исә безгә әдәбиятны сүз сәнгате итеп

карарга кирәк. Ягъни, үзәктә сәнгатьчә анализ, эмоциональ анализ торырга тиеш.

Мәсәлән, дини хисләргә мөнәсәбәте булган әдәби әсәрләрне алыйк. Совет дәүләте житмеш өч ел буе мәктәпнең диннән аерым булуын әйтә килде, ләкин ул үзе дингә битараф калмады. Алай гына да түгел, дингә һөҗүм алып барылды. Дәреслекләргә дингә каршы файдаланырдай әсәрләр махсус сайлап алынды. Ә татар әдәбиятында андый әсәрләр күп. М. Колый, Г. Кандалый, Г. Тукай, М. Гафури, Һ. Такташ һәм башкаларның аерым әсәрләре моңа мисал була ала. «Мәктәптә атеистик тәрбия» дигән нәрсә ничә дистә еллар буе идеология эшендә мактаулы урынга куела килде. «Мулла белән абыйстай», «Кара йөзләр», «Нәни разбойник», «Гает корбаны» кебек әсәрләрне дәрестә үтә башладыңмы, максатларның иң зурысы итеп «укучыларга дингә каршы тәрбия бирү» куела иде.

Бала, шул рәвешле, икейөзле булырга өйрәнде. Өйдә ул әби-бабайларның, әти-әниләрнең дингә, аның белән бәйле гореф-гадәтләргә хөрмәт белән каравын күрде, ә мәктәптә исә аңа киресен тукыдылар. Шулай итеп, олылар, аның күз алдында бер-берләрен инкарь иттеләр, бала исә аларның берсенә дә ышанмас булды. Бер нәрсәгә дә ышанмау үзе үк куркыныч әйбер. Әнә шулай итеп, кешеләргә генә түгел, рухка да инану бетерелде.

М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте — дин һәм шәригать кануннарын «гаепләү акты» кебек сүзләрне еш укырга туры килә. Әлбәттә, әсәрдән мондый нәтиҗә дә чыгарырга урын юк түгел. Күңелләре саф мәхәббәт хисләре белән тулы егет белән кызны дин-шәригать кануннары буенча хөкем итәләр. Әйе, әгәр дә кешеләр бозыклык эшләсә, шәригатьтә әнә шундый җәзалар каралган. Ләкин бу очракта андый хөкемгә тартырлык гонаһлары бармы соң Закир белән Галимәнең? Юк! Ник дигәндә, алар бит сөйләшеп кенә утырганнар. Тик онытмыйк, аның бусы да — ул чор өчен шактый кыюлык.

Ә шулай да Закир белән Галимә фаҗигасенең төп сәбәбе дин кануннары түгел, бәлки кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр: хөсетлек, үчлек, бер-береннең булганлыгын-уңганлыгын өнәмәү. Әсәрдә Галимәнең матурлыгы, хорлек сөюе, сау-сәламәтлеге, хезмәт яратуы, шул ук вакытта авылның бер дигән егете белән дуслыгы Гайнулла белән Сәлим кебекләрнең ачуын китерә, хөсетлекләгән арттыра. Шуның нигезендә алар бәхетле яшьләрдән үч алырга булалар. Сәйфулла белән Гәрәй кебекләр дә, яла ягу кебек зур гонаһны өсләренә алып, аларга кушыла.

Әсәрне укучы күреп тора: Сафи хәзрәтнең бу вакыйгага әллә ни исе китми, ул салкын акыллылык күрсәтә, шаһитләрнең капма-каршы әйтүләрен дә сизеп ала. Шуның өчен дә мәсьәләне хәл итүне иртәгә калдыра, яшьләргә кул белән ягылмаска куша. «Сез дошманлык белән сөйләмисезме?» — дип тә куя. Күгәрчен Сәлим исә гуаһларның капма-каршы сөйләүләренә игътибар юнәлтә, исемсез бер егет тә: «Алар сөйләшеп кенә утыралар иде»,— дип әйтергә җөрьәт итә. Менә ни өчен хәзрәт: «Бу җирдә шәригать хөкемнәрен йөртеп булмый, ләкин бозыклыкка каршы тору өчен, мондый эшләрне җәзасыз калдырып та булмый»,— дип акыллы гына әйтеп куя. Гомумән, хәзрәт бу әсәрдә кешеләрне аңлый торган, дини мәнфәгатьләрне дә күз уңында тоткан акыллы, мәһабәт кыяфәтле, абруйлы кеше булып күзаллана.

Әмма шунысын да инкарь итәргә ярамый: хәзрәт үзенең авылдагы ролен яхшы аңлый, ул халыкны буйсындырып тотарга тиеш. Шул ук вакытта ул — авыл байлары кулында тыңлаучы бер инструмент та. Тик мондый корал булу өчен, хәтта аның дин әһеле булуы да мәҗбүри түгел. Аның урынында надан десятниклар да, старосталар да нәкъ ул эшләгәнне башкарыр иде, чөнки теге ялган гуаһлар — бай балалары яки аларның тәлинкәләрен ялаучылар. Авыл халкы да, әлеге байлардан бөтен яклап бәйле булу сәбәпле, шушы фаҗигага кушылып китә. Тыныч кына яшәгән авыл тормышы әнә шулай чайпала-тулгана.

Күрәбез, социаль мәнфәгатьләр бер милләт кешеләрен дә төрле-төрле якларга ташлый, алар арасында дошманлык тудыра, бер-беренә рәхимсез мөнәсәбәтләрнең чыганагы булып тора.

Димәк, теге яки бу әсәрдә дин әһелләренең хезмәт иясләренә карата гаделсезлеге күренә икән, монда диннең гаебе шулкадәр генә. Эшнең төбе — икътисади хәлдә. Шул ук дин әһелләренең байларга, аларның азгын балаларына карата гадел хөкем кылырга фатиха биргәннәрен берәр әсәрдә күргәнегез бармы? Аларның башлары тишелсә — бүрек эчендә, куллары сынса — җиң эчендә, ягъни бөтен тормышлары халык күзеннән яшерелгән бу катламның гонаһлары дин әһелләре тарафыннан мул сәдакалар бәрабәренә «йолынып»

киленде. Нихәл итәсең, татар дин әһелләре русның попларына бирелгән матди өстенлекләрдән мәхрүм ителәр шул. Аларга хөкүмәт җир бирмәде. Кешечә яшәү өчен, мулла-мәзиннәргә дә икейөзлеләнергә, өстен катлауларга еш кына тәлинкә тотарга туры килә. Г. Ахуновның «Идел кызы» романындагы Габбас хәзрәт кебек, байның мәнфәгатен кайгырту түбәнлегенә төшмәгәннәрне исә ахыр чиктә фаҗига гына көтте.

Бу соңгы мисал шуны күрсәтә, татар әдәбиятында дин әһелләрен уңай итеп сурәтләүгә дә борылыш ясалды. Шуңа күрә дин әһелләренең халык тормышындагы уңай эшләрен күрсәтүне алга таба да дәвам иттерергә тиешбез. Мең ел буена халкыбызның әхлагын, рухын саклауда гаять әһәмиятле эшчәнлек алып барган дин әһелләре үзләренең бәяләрен алырга тиешләр. Мәктәптә әдәбият дәресләрендә укучылар аңында дингә, аның әһелләренә карата бары тик тәнкыйть күзе белән генә карау гадәте тәрбияләү һич тә игелекле эш түгел.

Инде В. И. Ленин турындагы әсәрләргә күз салыйк. Бу — бүгенге көндә шактый бәхәсләргә тарыган тема. Сүз дә юк, бу шәхес-кешелек тарихында урын алачак эшлекле лесе. Ләкин әлеге эшлекленең ялгышлары, йомшак яклары да булмады түгел. Бу барыннан да элек, аның элеккеге Россия империясендәге бөтен халыкларга да бертигез карамавында күренә. Мәсәлән, ул полякларга, финнарга тулысынча мөстәкыйльлек бирде. Татарларга исә РСФСР составындагы автономия дә җитәр, дип исәпләде. Анда да, бу республиканың артык көчәеп китүеннән куркып, хәзерге Башкортстан, Чувашстан, Мари республикалары, Оренбург, Ульяновск, Самара, Киров һәм башка өлкәләрдәге саф татар җирләрен Татарстаннан читтә калдыруга юл куйды. Яки аның икенче ялгышы — телләргә мөнәсәбәте «Мәҗбүри дәүләт теле кирәкме?» дигән мәкаләсендә (1914 елның 18 гыйнварында басылган) ул болай фикер йөртә: «Без, әлбәттә, Россиянең һәрбер кешесенә бөек рус телен өйрәнү мөмкинлеген булдыру ягында торабыз». (Ленин В. И. Әсәрләр, 20 т., 59—61 б.) Димәк, сүз Россиядәге рус булмаган барлык милләтләрне русча укыту мөмкинлеге тудырылу турында бара. Ә ни өчен «бөек рус теле?» Татар, яһүд һәм башка халыкларның телләре үзләре өчен һәм, әлбәттә, байлыклары ягыннан бөек түгелмени? Күпме еллар көнчыгыш илләрендә дипломатия хезмәтендә булган Вахит ага Юнысов әнә нәрсә ди: «Татар теле — гаҗәп матур, бай һәм гади тел. Әгәр аны яхшы белсәң, тагын утызлап телдә аңлашырга мөмкин. Димәк, татар телен әйбәт белгән кеше чын-чынлап үзен полиглот дип саный ала» («Яңа аваз», 1991, № 2, 7 бит).

Бездә шигъри Лениниана бик күчле. Ул, әлбәттә, Һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасыннан башлана. Әлеге әсәр татар әдәбиятында гына түгел, Ленин турында бөтен дөньясында беренче язылган поэма. Һәм, әйтергә кирәк, ул сәнгатьчә югары иҗат ителгән әсәр. Һ. Такташ тарих барышына диалектик караштан тора: ягъни 1917 елның 7 ноябрендә булган үзгәрешләрнең нинди дә булса аерым бер кешенең генә эше түгеллеген, ә бәлки җәмгыять үсеше тарафыннан китереп чыгарылуын әйтә. Шул ук вакытта, әсәрнең тексты турында сүз алып барганда, аның кайбер якларына тәнкыйть сүзе дә әйтергә туры килә.

Берден, автор Ленинны зур хәреф белән «Кеше» ди, икенчедән шунда ук аны канлы байраклы итеп тә тасвирлый. Димәк, аның кулы да канга буялган...

Һ. Такташ В. И. Ленинны «иске тормышны күмәргә килгән бөек каберче» дип атый. Әлбәттә, биредә К. Маркс һәм Ф. Энгельсның «Коммунистлар партиясе манифестындагы пролетариат-капитализмның каберчесе» дигән фикерен файдалану бар. Пролетариат каберче булгач, аның җитәкчесенең бөек каберче булуы шик тудырмый...

Һ. Такташ иҗаты турында сүз башлаганбыз икән, аның 1926 елда язылган «Нәни разбойник» дигән шигырен дә искә алыйк. Язылышы һәм шигъри техникасы ягыннан гүзәл шигырь, аның бик дөрес һәм матур фикерләре, образлары бар.

*Их!*
*Киче гене әле февраль иде,*
*Бүген давыл кырга кар ташый,*
*Март аеның нечкә билле җиле*
*Сузылып ятып җиргә, кар ашый.*

— кебек строфаларны язган шагыйрьнең талантына сокланасың. Шулай да, әлеге шигырьнең уңай ягыннан тискәре сыйфатлары күбрәк. Аны мәктәп укучыларына тәкъдим итү, зарарлы. Ә ул ничә дистә еллар буе мәктәп программаларына кертелде, көлке өчен сәхнә түрләреннән сөйләнде. Шигырь яки

теләсә кайсы әдәби әсәр, әгәр аннан килеп чыга торган фикер дөрес түгел икән, ул файда итми. Бу әсәргә килгәндә, аның үзәгендә хулиган тора. Ул әле карак та. Кешенең этәчен урлый, аны учак ягып пешереп ашый. Үрдәкләрне таяк белән кыйнап үтерә. Шушы эшләре өчен хаклы рәвештә авыл халкы аны иң актык сүзләр белән каргый, шаярып кына түгел, ихласлык белән «разбойник» дип исем бирә.

Татар халкында элек сүгенү сүзләре булмаган. Безнең авылда бер әби, мәсәлән, «рәхмәт төшкере!» дип ачулана иде. Менә сиңа, мә! Син аңа нинди дә булса начарлык эшләгәнсең, ә ул сиңа — «рәхмәт төшкере!» Ә «Нәни разбойник»тагы карчык «денеңнән яз, явыз...», — ди. Бу инде ачулануның иң соңгы чиге. Денеңнән яз бездә иң котычкыч нәрсә дип уйланылган, андый сүзне актык чиктә генә әйткәннәр. Шигырьдән күренгәнчә, алга таба бу малай, чыннан да, «денсез» булып әверелә. Шагыйрь дә «кабул булды аның теләге», ди. Ул гына җитмәгән:

*Сагынып сөйләр өчен ядкяр итеп,*
*Муллаларын кыйнап китермен,*

— дип тө куя. Герострат кебек, начарлык белән кеше хәтерендә калырга теләүче малай образы, теләсә ни әйтегез, укучы балада уңай хисләр калдырмый. Чөнки мулла кебек, ягъни авылның иң мәртәбәле кешесенә кул күтәрүгә җөрьәт иткән малай теләсә нинди начарлыклардан да тукталып калмаячак. Ата-анасы өмет өзгән малайның («Әткәй мескен кулын ташлады») — ә моны исә туган нигезеннән, халкыннан, аның асыл гореф-гадәтләреннән аерылган кеше дип аңларга кирәк — Ленин юл күрсәтүе белән генә ипкә килүе, шагыйрь булуы ышандырмый. Без мондый әсәрне алга таба яшь буын укучыларга тәкъдим итә алмабыз дип уйлыйм.

Һ. Такташның 90 еллыгына багышланган конференциядә (14.01.91) доцент М. Мәһдиев «Киләчәккә хатлар» поэмасын тоталитар режимны мактауга корылган әсәр дип белдерде. Әлбәттә, бу очракта мондый бәя белән килешергә дә, килешмәскә дә була. Була, димен чөнки нәкъ шушы әсәрдә Һ. Такташның кеше һәр шагыйрь буларак идея инанганлыгы, социализмны кабул итүе аеруча ачык билгеләнә. Шагыйрь үзе яшәгән утызынчы еллар башында барган вакыйгаларны бик тө яхшы белә, аларның гомуми тенденцияләрен яхшы тошенә, кешеләрнең көнкүрешендә нинди каршылыклар барын нечкә аңлый. Шулардан чыгып, җәмгыятьнең үсеш юнәлешен ихлас хуплый. Бу хәл Һ. Такташның, утызынчы еллардагы бик күпләр кебек, социализм идеяләренә чын күңелдән инанганлыгыннан һәм шуны әдәби әсәрдә чагылдыруда намуслы эш итүеннән килә иде. Әгәр дә ул:

*Сез яшәгән*
*Коммунизм кыры күренә,*

— дип язган икән, шагыйрь шулай булачагына бөтен җаны-тәне белән ышанган бит. Ул вакытта «эш шуңа таба бара» дип миллионнар илһамланып яшәгән һәм эшләгән. Димәк, бу очракта без Һ. Такташка карата «реаль булмаган әйберне язган» дип әйтә алмыйбыз. Киресенчә, чынбарлыкка тугры калып, утызынчы еллар рухын дөрес чагылдырган шигъри репортаж язган. Бу яктан Мохтар карт образы аеруча әһәмияткә ия. Крестьянның гасырлар буена килгән яшәү рәвешен һәм шуның нигезендә формалашкан психологиясен көчләп вату-җимерүнең кеше күңелендә нинди каршылыклар китереп чыгаруын шагыйрь бөтен фаҗигасе белән күрсәтеп бирә. Без исә моңа кадәр Мохтар картны комедия үзәгенә куелган образ диебрәк кабул иттек, укучыга да шулай аңлаттык, аның кыланышларыннан көлдек. Баксаң, без үзебезнең асыл тамырларыбызны кисүдән кызык табып, көлеп йөргәнбез икән! Дөресендә, Мохтар карт ул — трагик герой. Чөнки ул барлык крестьяннарга хас булган гадәт-сыйфатларны үзенә җыйган. Алар: җирне ярату, җиргә хуҗа булу хисе, крестьянның топ терәге булган атны үзеңнең җаның-тәнеңнең бер өлеше итеп карау.

Уйлап карасаң, нинди зур көч ул — үзеңне хуҗа итеп сизү. Дөрес, безне совет хакимияте елларында шулай ук «сез — җирнең чын хуҗалары» дип өйрәттеләр. Ләкин аерым кеше моны аңламады: кайда ул нәкъ менә мин хуҗа булган җир? Күрсәт, кайда? Колхоз басуына Гали дә, Вәли дә хуҗа. Шул кырдан бер уч арыш уып алсаң, берәр шалканны куеныңа кыстырсаң, берәр көлтә печән чабып алсаң, син карак булачаксың. М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасында авыл хатыны, ач балаларының тамагын аз гына да булса туйдыру өчен, колхоз басуыннан берничә бөреңге алып алъяпкычына сала. Ә шуның өчен Миңлекамал ни рәвешле аның котын ала?! Шуннан соң өлеге хатын үзен

бу колхозның хуҗасы итеп сизә аламы? Юк, әлбәттә. Ул үзенең кол икәнлегенә тагын да ныграк кына төшенәчәк.

Инде Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестендагы шундый күренешне исегезгә төшерегез: Солтан әтисе белән үзләренең борчак басуына бара. Ата белән улның үз басуларында кичергән рәхәтлекләрен күреп, йөрәккә шифа ява. Ата кеше басуга борчак ашарга кергән ят малайларны да ачуланмый, киресенчә, аларга җирне бик таптамыйча, әйбәтрәкләрен, өлгергәнрәкләрен җыеп ашарга үзе куша. Шулай итеп, ул биредә үскән ризык белән үзе теләгәнчә эш итә алуына кинәнә һәм малайларга да әхлак дәресе бирә: чәчелгән икмәккә сак мөнәсәбәт күрсәтергә, җиргә мәхәббәт белән карарга! Ә колхоздагы теләсә кайсы крестьян моны эшләргә хокуклымы соң? Юк, тагын бер мәртәбә юк!

Инде Мохтар картка килик. Ул, үзенең җаныннан суырып алып, атын колхозга тапшыра. Ләкин аты колхоз абзарында булса да, ул аны әле һаман үзенеке итеп исәпли. Җаен туры китереп, өстәмә ризыгын да бирә, аны карап-тәрбиялəп барырга тырыша. Берәр малай тырма-сукада вакытта атка сугып куйса, камчы үз аркасына төшкәндәй, авырттырып куя. Аты кинәт үлеп киткәч, бөтенләй кайгыга сабыша. Болар барысы да табигый, нәкъ шулай булырга тиеш. Чөнки крестьянны бөтәнчә күз алдына китерергә мөмкин түгел. Киресенчә булганда, тормышчанлыкка зур хилафлык кылу була.

Ләкин Һ. Такташ бик кискен борылыш ясый: атның хәзер инде күмәк хуҗалыкныкы икәне искә төшкәч, Мохтар карт хәтта шатланып та куя. Янәсе колхоз атының берсе үлсә, әле әнә ничәсе кала! Биредә Һ. Такташның күзәтүчәнлегенә хәйран каласың. Хуҗасызлык, күмәк милеккә битарафлык, арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит дип карау әнә ничек һәм кайчаннан бирле тәрбияләнеп киленгән икән бездә! Хуҗасызлык хисенең чыганагы егерменче еллар ахыры, утызынчы еллар башына барып тоташа икән!

М. Мәһдиев тагын бер нәрсәдә хаклы: утызынчы елларда кешеләрдән шикләнү, күрше-тирәдән дошман эзләү, бер-береңә ышанмау көчле булды. Бу инде тоталитаризмның урнаша башлавы иде. Кар башына кар житә дигәндәй, кеше башына кеше житүнең массовый хәрәкәтенә старт нәкъ менә шушы вакытта булды. Һ. Такташның моннан шигърият табуы бик кызганыч, әлбәттә.

*Безнең илдә әле дошман сыйныф*
*Нәслен саклап калу юлында*
*Көрәш алып бара,*
*Корткыч кулын суза һәр урынга,*
*Һәр кулакның обрез кулында...*

Нәкъ менә шушындый дошман эзләү атмосферасы кешеләрнең психологиясе дөрес булмаган юнәлештә калыплануга, җәмгыятебезнең иң аек фикерле, булдыклы шәхесләренең юкка чыгуына китерде. Димәк, марксизм-ленинизм теоретиклары тарафыннан эшләнгән шактый дөрес һәм кешелекле социализм төзү планнары кире кагылды, сталинчыларның террор сәясәте алгы мәйданга чыкты. Һ. Такташ исә үз поэмасында шушы хәтәрләрнең башлангыч дәрәҗәсен дөрес күрсәтте. Димәк, «Киләчәккә хатлар», безнең бер тарихи чорның шигъри документы буларак, үз әһәмиятен югалтмый. Ул безгә үткәнебезне аңлауда ярдәм итә.

Һ. Такташның «Сыркыды авылы» исемле озын шигыре дә шагыйрьнең олы талантына шаһит булып тора. Автор «комсомол ячейкалы Зур Сыркыды авылы»ндагы хәл-әхвәлне бик үзенчәлекле итеп, хәлләр күз алдына бөтен катлаулылыгы белән китереп басардай сүз сәнгате әсәре иҗат иткән. Һәр авылдагы кебек, биредә дә таза тормышлылар, урта хәлләләр, үтә ярлылар бар. Әлбәттә инде: муллалар, дингә ышанучылар, азып-тузып йөрүчеләр, пионерлар, «искелеккә бомба» булган комсомоллар да бар... Шушы зур авылны аркылысынбуйга йөреп, бөтен бу кешеләрне бер әсәр тукымасына теркәүче җил образы да Һ. Такташка хас җанлы итеп, социаль бурычны бик әйбәт үти алырлык деталь буларак файдаланылган.

Совет йортында каравылчы булып көн күрүче зимагур Шәхми карт образы да шул чорның типик кешесе. Аны Х. Туфанның «суыгаяк» Минаплары, Хабуллары язмышыннан аерып карап булмый. Ул үз өендә җылы таба алмый, шуңа күрә Шәхми картның бөтен ышанычы, язмышының азмы-күпме киләчәге совет хакимияте, Ленин белән бәйләнгән. Шуңа күрә бу «берәү»нең рәсеменә карап ул күңелен тынычландыра, «Ленинны сүккән байгуралар өстенә» нәфрәт белән карый. Шушы авыл егете Әсгать, рабфак тәмамлап, югары уку йортына керергә җыена, яшь политрук Мәхмүт искелек үлүенә, яңалыкның ныгый баруына

шатлана. Ягъни әсәрдәге шушы урыннарны гына сайлап яшь буынга җиткергәндә, алай бер дә күңелне кимсетә, рәнҗетә торган яклар юк. Без әлегә кадәр «Сыркыды авылы» әсәренә шәрехләү ясаганда үтә ярлы Шәхми картның Ленинга мәхәббәтен күрсәтүгә төп игътибарны юнәлттек. Мәсәлән, сигезенче класс дәреслегендә (1990 елда ул тугызынчы классныкы булып чыкты) 82 нче биттә болай диелә: «Һ. Такташның «Сыркыды авылы», «Еллар таңында», «Нәни разбойник» һ. б. әсәрләре дә Ленин исеме белән бәйләнгән. Шулай диелде, ләкин күңелдәгесе шулай бик тирәндә кала бирде, чөнки рәсми идеология телне тотлыктырды, кулны тоткарлады.

Безгә «Сыркыды авылы»нда нилэр ошамый иде соң? Һәр революция ике өлештән тора. Беренчесе — коралллы көрәш нәтиҗәсендә хакимиятне кулга алу, икенчесе — шуннан соңгы тыныч елларда икътисади, сәяси һәм рухи яктан шул казанышларны ныгыту, җиңелмәслек итү. Безнең илнең төп ялгышы шунда булды — тыныч төзелеш елларында да фронт хәленең дәвам итүе. Бу әсәрдәге хәрби кеше Мәхмүтне тыңлап карыйк әле:

*Без барабыз соңгы һәм*
*Канлы көрәшләр аркылы*
*Мәңге кояшлы кызыл таңга табан...*

Бу әсәр 1925 елның январь санында «Безнең юл» (№ 1) журналында басылган. Инде революция булганга сигез ел вакыт узган. Ләкин һаман да «канлы көрәш», «кызыл (канлы дип аңларга кирәк) таң» тәкъбирләре әсәрләрдә табигый урын ала. Комсомолларны «бомбалар» белән тиңләү дә ул еллар укучысын сискәндермәгәндер. Бездә исә ул, уңышсыз чагыштыру буларак, бик каршылыклы ассоциацияләр тудыра. Димәк, әгәр без намуслы булырга телисәк, тегe яки бу әсәрнең бер ягын гына алып түгел, бәлки тулаем, аны каршылыклары белән бирергә кирәк. Әлбәттә, моны чорга, тегe яки бу язучының дөньяга карашын калыплаган шартларга бәйләп аңлату зарур.

Ник дигәндә, дөньяга караш, гадәттә, даимилек белән характерланса да, ул үзгәрмичә тормый. Каләм әһелләре дә, җәмгыять белән бик күп җепләр белән бәйләнгәнгә күрә, әлегә чолганыштан тулысынча азат була алмыйлар. Һ. Такташ — халәте рухиянең үзенчә агарга тиешлеген, ягъни чын иҗат ирегенә хупланган шагыйрь. Әгәр тоталитар хакимият шартларында яшәмәсә, ул, әлбәттә, бик әһәмиятле һәм сәнгатьчә камил әсәрләр иҗат иткән булыр иде. Кызганычка каршы, инде егерменче еллар ахыры һәм утызынчы еллар башында язучыларның каләме белән идарә итү башланган иде. Партия Үзәк Комитетының 1925 елгы 18 июнь резолюциясе, яки аннан да элегрәк чыккан пролеткультчылыкка карата күрсәтмәләр шуның ачык мисалы булды.

Һ. Такташның бернинди «изм»нарга дучар булмаган беренче чор иҗаты бар («Җир уллары трагедиясе»н кертеп). Ул үзенең хатынына язган бер хатында шигырьләрдә алдамавын әйтә. Нәкъ менә Казанга килгәнче булган иҗатында ул, чыннан да, алдашмый, дөньяга карашларына тугры булып кала. Күрсәң, безгә яшь буынны ихлас күңелдән язылган шул әсәрләре ярдәмендә тәрбияләргә кирәктер.

Бүгенге көндә язучыларның тулаем иҗатына һәм аларның әсәрләренә карашның үзгәрүе табигый. Ул шулай булырга тиеш тә. Ник дигәндә, телисеңме-теләмисеңме, үткәннәр турында мәгълүматлырак була барган саен, безнең иҗтимагый һәм эстетик карашларыбыздагы кыйммәтләрдә дә үзгәреш булмый кала алмый. Ләкин моның дәлилле, сак һәм, әлбәттә, яхшы ният белән эшләнүе кыйммәт. Чөнки бүгенге көннән торып, егерменче-утызынчы яки аннан да элекке — соңгы чорлар турында фикер йөртү шактый ансат. Ә менә тегe яки бу каләм әһеленең үз вакытында нинди чолганышта һәм нилэр тәэсирендә иҗат иткәнлеген белеп, гадел эш итү кыенрак. Әмма моны эшләү зарури. Бары шул чакта гына безнең язучылар һәм аларның әсәрләре турындагы фикерләребез, нәтиҗәләребез дөрес тә, гадел дә булыр.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

## Александр Маклыгин

# ХАЛЫК ЯШЕ ТАМГАН МОҢНАР БУ



Тормышыбыз тирән үзгәрешләр кичергән кебек үк, музыкабыз да берсеннән-берсе катлаулырак борылышларга юлыгып тора. Гаҗәп тә түгел. Мәгълүм ки, мондый шартларда, ягъни замананың социаль тетрәнүләре вакытында, иҗат кешеләренең һәр кылган гамәле имтихан тота. Туры юлдан атлаганмы ул, иҗаты өчен сайлаган юнәлеше уңай булганмы, эстетик кыйбласы дөрес билгеләнгәнме — әсәрләр әнә шуңа охшаш сорауларга җавап бирергә мәҗбүр. Мондый шартларда кайберәүләр чынбарлыкның бөтен тирәнлеген дөрес аңларга омтыла; икенчеләр, күпчелеккә ярарга тырышып, арзанлы абруй казанып калырга ашыга; өченчеләр исә, иң беренче сайлап алган адымыннан һич тайпылмыйча, һичнинди иҗтимагый борылышларда да йөзгә кызыллык китермәстәй үз идеалына сабыр гына хезмәт итә бирә.

Композитор Шамил Шәрифуллин иҗаты әнә шушы өченче, иң ышанычлы җирлектә үсеш алды. Ул беренче талпынышында ук иҗат өлгесе итеп халык әсәрләренә мөрәҗәгать итте. Мөнәҗәтләрне, китапны көйләп уку алымын өйрәнде. Бу юлдан Шамил ялгыз барды диярлек. Совет идеологиясе халык музыкасындагы өлеге җанрларга һәрчак кырын карады, аларны дин белән генә бәйләп күрсәтергә тырышты, өзлексез тәнкыйть итте яки бөтенләй ишетмәмешкә салынды. Аңлашыла ки, бу күренешләргә игътибар биргән иҗат әһеле дә һичнинди шәфкать көтә алмый иде.

Чынбарлыкның шушы кырыслыгына да карамастан, Шамил Шәрифуллин үз күңелен биләгән бу җанрларга җаны-тәне белән тугрылык саклады, иҗатын да шушы юнәлештә, сабыр гына дәвам иттерде. Тыңлаучы исә бу тансык аһәңне күтәреп-күтәреп алды. Аңа нәкъ менә шул моңнар — мөнәҗәт ритмнары җитенкерәми иде.

Композиторның халык музыкасына мөрәҗәгате, бер караганда, һич тә яңалык түгел. Татар композиторлары иҗатында бу алым аеруча гадәти күренештән санала. Дөрес, тарихның төрле дәверләрендә бу алымга мөнәсәбәт үзгәреп-үзгәреп китә. Мәсәлән, 40—50 елларда композиторлар иҗатындагы халыкчанлык югары бәяләнә иде. 1950 елда Нәҗип Җиһановка татар халык көйләре темасына язылган Сюитасы өчен хәтта СССР дәүләт бүләге дә бирелә. Соңрак исә халык көйләреннән мул файдалануны композиторларның үшәнлегеннән күрүчеләр дә очраштыргалый.

Шамил Шәрифуллинның халыкка таныла башлау чорында, ягъни 70 елларда, композиторлар, халык иҗаты үрнәкләреннән шактый аерылып, бинигаһая шау-шулы әсәрләр язарга тотындылар. Яшьләр бигрәк тә бары тик чит-ят тарафлардан килеп ирешкән кыргый ритмнарны гына кабул итә башлады. Ял кичәләре, җыр-бию заллары дөбер-шатыр килүчән музыканы гына таный иде. Шамил, шушы хакыйкатьнең кырыслыгына да игътибар итмәстән, бик кыю төстә бары үзен кызыктырган халыкчан юнәлештә атлавын дәвам иттерде. 1977 елда ул скрипка һәм фортепиано өчен Соната язды. Әсәр

башкалар иҗат иткән сонаталардан нык аерылып тора иде. Монда яшь композитор татар халык музыкасындагы сыйфатларны додекафония (октаваның һәр унике тоныннан да файдалану) белән «килештерергә» омтылыш ясый һәм, аерым кыенлыкларга карамастан, образларның шактый ачык гәүдәләнүенә ирешә.

Шамилнең бу тәвәккәллеге — татар халкының борынгы музыкаль байлыгына йөз тотуы соңрак үзен аклап чыкты. Сүз дә юк, композитор бик шөбһәле юлга аяк баскан иде, шуңа да карамастан, үзе сайлап алган юнәлештән читкә тайпылмады. Ничек шулай кыюланган соң ул? Бу сорау торып-торып уйландыра. Эзләнә-сораша башлагач, кызыклы ачышларга да юлыктым. Шамилне татар халык музыкасының иң борынгы жанрлары дөньясына егетнең әбисе Хәлимә апа Кәримова мавыктырып алып кереп киткән икән.

Хәлимә апа авылда туып үскән һәм үз гаиләсендәгеләр күңелендә халык музыкасына кайнар мәхәббәт тәрбияләүгә ирешкән. Үз чиратында исә аңарга да бу сыйфат өүвәлге буыннар тарафыннан иңдерелгән булса кирәк. Шул рәвешле Шамилнең нәселе халык музыкасының тарихи үсеш баскычларын саклаучы роленда дә ихтирамга лаек.

Кызганыч ки, бүгенге композиторларыбыз арасында халыкчан тәрбияне мондый эзлеклелектә алучылар юк дәрәҗәсендә. Ифрат кыйммәтле мондый сабакны бирүчесе дә юк, өйрәнергә теләүчесе дә сирәгәя бара. Халык көйләреннән, аның үзәкләргә үтәрдәй яңгыраган моңыннан ләззәт ала алмаган композитор башканың җанын җилкендерерлек әсәрне ничек иҗат итсен соң? Музыкабыз үсешендәге табигый эзлеклелек ни сәбәпле бозылган? Бу яман хәлләрнең сәбәпләре әллә ни тирәндә түгел, әлбәттә. Безнең ялгышлар шуңа барып чыга — иҗатта гына түгел, гомумән, тормыш-көнкүрешебездә дә ата-баба гадәтләрен олылау тәрбияләнмәгән бездә. Халыкның җыр-моңын өйрәнүгә дә игътибар бирелмәгән. Шуңа күрә бүгенге иҗатыбыз тар тыкрыкка кереп терәлгән. Милли рух, милли яңгыраш томан артында калдырылган. Гаиләдә бала үстергәндә халык тәрбиясе чаралары бөтенләй исәпкә алынмаган. Буыннар мөнәсәбәте өзелгән һәм, кыскасы, имансызлык чорына аяк басканбыз. Хәзер шул коточкыч ялгышларыбызның әче җимешләрен татыйбыз.

Шамил Шәрифуллин язмышы, бәхеткә, бөтенләй башка тирәлектә тамыр алган. Бу җәһәттән шуны искәрергә кирәктер, мөгаен: булачак композитор халык моңнарына коенып, рәсми мәдәният учакларыннан еракта, Төрекмәнстанның Аму-Дәрья суы ярларындагы Фәрәб авылында үсә. Татарстаннан гына түгел, гомумән, элек Советлар Союзы дип йөртелгән зур мәйданның да иң читтәге төбәге бу. Туган Татарстаннан биниһая еракта яшәү гаилә өчен кыен булгандыр, әлбәттә. Шамилгә дә саф татарча моңнарны ишетми яшәү уңай тәэсир ясамагандыр. Әмма... һәр күренешнең яхшы ягы да булырга тиешлекне хәтердән чыгармыйк! Бу җәһәттән композиторның балачагы бәхетле язмыш кулына эләгә. Гаиләсе, нәсел-нәсәбе ифрат музыкаль күңелле кешелердән тора. Шуңа күрәдер, аның туганы Фәрит тә композитор булып китте. Шамилнең татар композиторы булып өлгерүендә исә гаиләсе тәэсирен иң алгы планга куярга кирәк, чөнки ул үскән шартларда кешене композиторлыкка әзерлүче бер генә башка мөмкинлек тә юк. Димәк, без арабызда Шамил Шәрифуллин кебек үзенчәлекле иҗат кешесенең булуы өчен беренче чиратта, аның әти-әнисенә мең рәхмәт укырга тиешбез.

Егетнең әтисе Камил әфәнденең җырга-моңга һәвәслеге, әлбәттә, аеруча зур роль уйный. Төрекмәнстанның Фәрәб авылында Камил агайдан да остарак музыкантны табуы мөмкин түгел. Ул берничә уен коралында да оста уйный, менә дигән итеп җырлый. Һәм, гадәттәгечә, мондый кеше тирәсенә җыелучылар да җыр-музыка дөньясына гашыйк җаннар була. Җырга мәхәббәт әллә ничә төрле милләт вәкилләрен берләштерә, төрледән-төрле уен осталарын бергә туплый. Гаҗәеп бер ансамбль оеша. Бары музыкага гашыйклык аркасында гына , ихтыярый шартларда тупланган мондый һәвәскәрләр турында хәзер сагынып-сокланып сөйләргә генә мөмкин.

Әлеге ансамбльда рояль белән думбыра, мандолина белән торба, балалайка белән баян, скрипка белән кубыз — һәммәсе үзара «уртак тел» таба. Башкарылган әсәрләр арасында исә әрмән, татар, украин, үзбәк, төрекмән, грек кебек әллә ничә төрле халыкның иң камил җырлары, бию көйләре яңгырый. Тыңлаучылар ихластан мөкиббән китеп, дөньяларын онытып тыңлыйлар. Аларны әсәрләрнең җанлы билгеләр алуы гына түгел, уйнаучыларның осталыгы да хәйран калдыра.

Шамилнең балачагына артык зур игътибар бирү укучыны гаҗәпләндермәсен иде. Композитор иҗатындагы үзенчәлекле сыйфатларны аңлау өчен бик тә кирәкле шарт бу. Минемчә, сәнгатьнең теләсә кайсы тармагында хезмәт күрсәтүче шәхеснең мәсләге кайсы уку йортында белем алуыннан бигрәк, нинди тирәлектә үсүеннән, тәрбиянең беренче адымын ничек башлавыннан чыгып та билгеләнә. Аның дөньяны танып белүенә ниләр тәэсир иткән, нинди вакыйгалар аны сокландырган яки аңарда нәфрәт уяткан — менә шулары аеруча әһәмиятле.

Дәлилгә Шамилнең әсәрләрендәге образларны китерергә мөмкин. Балачак чорын чагылдырган көйләрендә композитор якты, аяз төсмерләрне мул куллана. Балачак ваемсызлыгы, дөньяга гашыйклык киләчәкнең дә матурлыгына ишарә ясый кебек. «Әй, якты дөнья! — дип сокланып туя алмый кебек автор.— Нинди киң син, нинди иркен!» Бу аяз киңлектә, һичшиксез, тыңлаучының да бәхете канат җәйгән, тик эзләп табарга гына кирәк! Иренмә, эзлә! Тап! Балачак хыялларын гәүдәләндерү өчен моннан да кулай алым бармы?!

Композиторның бу төр өндәмәле музыкасы сюрреализмга тартым. Әлеге алым тамырлары белән XIX йөз башындагы хыялый затлар иҗатына барып тоташа. Алар җирдә таба алмаган гаделлекне күкләргә күтәреп тасвирлаганнар, бик еракларга яңгыратканнар: хыяллар, хыяллар... Әдәбиятта моңа охшаш тасвирлау ысулын Ф. Достоевскийның сюрреалистик омтылышларында очратырга мөмкин. Музыка даирәсендә моңа мисаллар аеруча күп. Әйтик, XX йөз француз импрессионисты М. Равель әсәрләре. Шамил Шәрифуллинның балалар өчен язган әсәрләрендә дә, фортепианода уйнау өчен иҗат иткән әсәрләрендә дә Равель музыкасының тәэсирен ачык тоярга була. «Борынгы халык моңнары» язмасы (балалар хоры өчен) исә моңа бигрәк тә ышандыргыч мисал.

Татар музыкасы йолдызларыннан үрнәкләр эзли китсәк, без, мәгаен, ике шәхескә — Нәҗип Җиһанов белән Алмаз Монасыйпов иҗатларына тап булырбыз. Шамил алар белән якыннан таныш. Казан консерваториясендә укыганда ул алардан композиция һәм инструментовка буенча дәресләр ала, музыкаль-техник осталыкка өйрәнә. Шул ук вакытта бу олы композиторлар егетне иҗади фидакярлеккә дә инандыралар. Алмаз Монасыйпов дәресләрендә Шамил әсәр төзелешен, ягъни композицияне, тирәннән өйрәнә. Нәҗип Җиһанов исә аңа уен коралларыннан дөрес һәм оста файдалану серләрен төшендерә. Бу остазларының сабагың сеңдерерлек җирлек, әлеге дә баягы, аңа балачагыннан, гаиләдә үк салынган була инде.

Казан консерваториясеннән соң Шамил Шәрифуллин Мәскәүдә аспирантурада укый. Монда аңа урысның зур композиторы Тихон Хренников өйрәт-



Рәсемдә *(сулдан уңга)*: Ш. Шәрифуллин, халык көйләрен җыючы Г. Гобәйдуллин, композитор Н. Җиһанов.

мәләрен ишетергә туры килә. Әмма бу тирәлек Шамилны аптыраштарак та калдыра. Башка дөнья, монда башка музыка. Шамилгә исә үз халкының моңы кадерле, аның күңеле сабый чактан ишеткән һәм җанны дәртләндереп торган туган як аһәңнәре белән тулган, ул шуларга тугрылык сакларга тырыша. Бу омтылышында ул дөнья күләмендә танылган композиторларыбыз Суфия Гобәйдуллина иҗатына мөрәҗәгать итә һәм әлеге бөек үрнәк аңа көч иңдергәндәй була. Кеше дөрес юл эзләп интеккәндә мондый биеклекләрнең әһәмиятен бәяләп бетерү мөмкин түгел! Бәхеткә, Шамил шәп күрсәткечләр таба белә, үз күңелендәге бөреләрне дөнья музыкасындагы казанышлар белән дөрес бәйли бара.

Өйрәнүләр юлы катлаулы. Музыка дөньясында бигрәк тә. Монда көй яңгырашын да, сүз кыйммәтен дә, уен кораллары серен дә һәм тыңлаучының кабул итү сәләтен дә — барын да иске ала белү мөһим. Камиллеккә ирешү өчен өзлексез эзләнү, өйрәнү, бик күпне белү шарт. Әнә Суфия Гобәйдуллинабыз безнең милли музыканы ничек оста рәвештә дөнья күләмендә яңгырата алды! Музыкабызга өр-яңа тосмерләр өстәде һәм үзе дә шөһрәт казанды.

Шамил Шәрифуллин шундый үрнәкләрдән көч алып, татар халык музыкасына яңалык өрде. Ул иҗат иткән әсәрләр дә, элекке СССР ны үтеп чыгып, Европада яңгырый башлады («икенче симфония», «Сфера диалоглары», «Фортепиано триосы» һ. б.) Бу әсәрләр шунысы белән үзенчәлекле ки, композитор монда, татар халык көйләрендәге үзәк өзгеч моңны саклап калган хәлендә, иң ачык вә көчле авазларда җиңүчән рухлы яңгырашка өстенлек бирә. Уйлап карасаң, бик дөрес нәтиҗә ясалган. Чынбарлыкта да, ахыр чиктә җиңүчән рух өстенлек итә бит.

Авторның әбисе истәлегенә багышланган Триосы да нәкъ шул алым белән язылган. Нигез итеп балачактан күңелгә ятышлы монәҗәт моңы яңгырый, ә фаҗигале Пассакалья (I бүлек), маҗаралы Каприччио да (II бүлек), шигъри Ария дә (III бүлек) монәҗәт рухындагы сихри яңгырашка омтылып үстерелә.

Шамил Шәрифуллинның оркестр өчен язылган «Җыен» исемле концертында башка төр үзенчәлекләрне дә тоярга мөмкин. Композитор мондагы образларны ифрат ачык төсләргә мана. Татар халкының күңел ачу тантаналарындагы ритмнар берсе артыннан икенчесе тезелеп кенә тора. Тыңлаучы күңелендә җыен күренешләре: көч сынашучы баһадирлар, чабышта катнашучы җайдаклар, узышып йөгерүче яшь җилкенчәкләр сурәте гәүдәләнгәндәй була. Халык көйләренең иң тантаналы яңгырашлылары оркестрда үзәккә чыга.

1988 елда Шамил Шәрифуллин «Туган якта» исемле кантата язды. Әсәр шигырь сөйләүче, балалар хоры һәм оркестр өчен иҗат ителгән. Монда С. Хәким, Р. Фәйзуллин һәм И. Юзеев шигырьләре файдаланыла. Кантата, темасы ягыннан, социаль тетрәнүләргә нигезләнгән булуга да карамастан, яңгырашы буенча гаять якты, шатлыклы көйләргә бай. Бу очракта хәтта авторның, шактый соңарып булса да, «соцреализм» шаукымына бирелгәнлеге хакында да уйларга җирлек бар кебек. Әмма хикмәт соцреализмда түгел, әлбәттә. Автор һич тә үткән көннәребезне алсуландырып күрсәтергә теләми. Хикмәт аның үзе сайлаган юлга тугры калуында. Биредә композитор, искене җимерү вакытында, халык өчен изге саналган сыйфатларны саклап калуны алга сөрә. Туган җир, газиз халык, табигать һәм шул изгелекләргә бәйле башка бик күп нәрсәләр — һәммәсе композитор йөрәге аша узып, тыңлаучы күңеленә күчә. Кантатаның балалар хорына багышланган булуы әлеге катлаулы бурычны үтәүдә бик отышлы алым булып гәүдәләнә.

Шәрифуллинның кайсы әсәрен генә тыңласаң да, һәрберсендә яңалык ачасың: йә көйнең сөрешендә ул яңалык, йә сюжетта күзгә ташланып тора. Мәсәлән, 1987 елда иҗат ителгән «Чәчәк турында җыр» балет-ораториясе үзенең сюжеты белән тыңлаучыларны тәмам гаҗәпкә калдырды. Чөнки монда автор, һич көтелмәгәнчә, Латин Америкасы һиндлеләренең фольклорына мөрәҗәгать итә. Әмма, тирәннән кызыксынсаң, татар егетенең бу алымына әллә ни гаҗәпләнергә дә кирәкми. Иҗатын гел камилләштерә барырга тырышкан талант иясе төрле халыклар көендәге уртаклыкларны эзли, таба икән — начармыни?! Әсәр һәр халыкка хас сыйфат булган өметкә, яктылыкка чакыра. Анда бик кыю, шатлыклы ритмнар күп . Тыңлаучы алар тәэсирендә дәртләнә, канатлана кебек. Заманында бик популяр булган Има Сумак җырлары да иске төшеп-

төшеп китә. Равельның «Дафнис һәм Хлоя» балетындагы хор да хәтергә килә. Әмма әсәр — безнең егетнеке, татарча яңгыравы белән әсир итә. Брамсның саф алманча язылган «Мадьяр биюләре» яки М. Глинканың Испания турындагы көйләре, йә Н. Җиһановның Кытай турындагы хатирәләренә нигезләп язган «Симфоник новеллалары» шикелле. Мондый аралаштырулар халык музыкасын дөнья мәдәнияте югарылыгына күтәрүдә, аны киң мәйданга алып чыгуда гаять отышлы.

Шамил Шәрифуллиның иҗаты бүгенге татар музыкасында аерым бер урынны биләп тора. Бу аерымлылык берничә үзенчәлеккә барып тоташа. Иң әүвәл композиторның мишәр гаиләсендә, мөнәҗәтләр моңын ишетеп үсүен кабат әйтергә кирәк. Өстәвенә, әле ул күпсанлы экспедицияләрдә дә йөри, туган халкының көйләп китап уку осталарын, мөнәҗәтчеләрне күрә, аларның чыгышларын язып-язып ала, өйрәнә. Өченчедән, Шамил үз иҗаты рухындагы классикларны тирәннән өйрәнә: Равель, Барток, Стравинский, Хачатурян, Гобәйдуллина һ. б. Аның эзләнүләрен, тырышлыгын һәм, әлбәттә, табигать биргән талантын күреп-тоеп торсаң, әсәрләрендәге уңышның сере бөтен тирәнлеге белән ачыла. Алай гына да түгел, Шамилнең бер әсәрен тыңлаганнан соң, тиздән яңасы туачагына ышанып каласың.

---

*Котлыйбыз!*

## Камил Мостафинга — 60 яшь



Камил Әхмәди улы Мостафин 1932 елның 26 ноябрендә Зеленодольск шәһәрендә туган. 1940 елны Саба урта мәктәбенә укырга керә, гаиләсе белән Чүриле районына (хәзерге Арча) күчеп киткәч, укуын Яңа Чүриле урта мәктәбендә дәвам итә.

1951—1956 елларда ул — Казан дәүләт университеты студенты. Укуын тәмамлагач, 1956—57 елларда Мәскәүдә, ә 1957 елдан бүгенге көнгә кадәр Уралда яши, Чиләбе фәнни-тикшеренү институтларының берсендә эшли.

Хезмәттәге уңышлары өчен «Почет билгесе» һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән бүләкләнә, 1991 елда исә СССР Дәүләт премиясенә лаек була.

Әдәби иҗат белән илленче елларда шөгыльләнә башлый (ул татар һәм рус телләрендә яза). Фикер һәм хис, эчтәлек һәм форма тәңгәллегенә омтылган, заманча рухлы, интонацияләргә бай шигырьләре укучылар һәм тәнкыйть тарафыннан хуплап каршы алына. 1966 елда Казанда шагыйрьнең беренче китабы — «Җыр сафка чакыра» басылып чыкты. Хәзер ул — сигез китап авторы (5 китабы Казанда татар телендә, икесе Чиләбедә рус телендә, берсе Мәскәүдә — «Современник» нәшриятында дөнья күрде). Русчага тәрҗемәләре «Огонек», «Юность», «Смена», «Урал» кебек абруйлы журналларда, күмәк җыентыкларда һәм антологияләрдә урын алды.

Камил Мостафин юмор-сатира өлкәсендә дә эшли, әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнә. Чәчмә әсәрләр — хикәя, очерклар язып та көчен сыный; тәрҗемә дә итә (җөмләдән Лермонтов, Маяковский, Хосе Марти шигырьләре аның тәрҗемәсендә журналыбызда дөнья күрде).

1981 елдан — Язучылар берлеге әгъзасы.

# Лирон Хәмидуллинга 60 яшь



Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин 1932 елның 10 ноябрендә Куйбышев өлкәсенең Кошки районы (хәзерге Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районы) Иске Төгәлбуга авылында туган. Аның тормышы яшьтән үк хезмәт белән бәйле. Туган колхозында эшләү, Казакъстанның Актүбә шәһәрендәге тимер юл техникумында уку, солдат хезмәте, Оренбург өлкәсенең Орск шәһәрендә тимер юл участогы бригадиры һәм өлкән мастер булып эшләү...

Әдәби иҗат эше белән кызыксыну Лирон Хәмидуллинны 1961 елны Казанга алып килә. Бирелә ул трамвай-троллейбуслар идарәсендә җитәкче эшләрдә эшли. Ә 1967—82 елларда Татарстан Язучылар берлегендә Әдәби фонд директоры вазифасын башкара.

Лирон Хәмидуллинның тимер юл транспорты эшчеләре тормышын чагылдырган «Юлда» исемле хикәяләр китабын (1968) һәм «Дала иртәсе» дигән повестен (1971) укучылар да, әдәби тәнкыйть тә җылы каршылый. Җитмешенче еллардан башлап исә язучының икенче иҗат тармагы — тәрҗемәләү эшендәге уңышлары ачылып китә. Ул аеруча төрки телле әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итүгә әһәмият бирә. Аның тәрҗемәләре арасында казакъ язучысы Ә. Әлимҗановның «Күкшел таулар итәгендә» исемле повесте, үзбәк язучысы Ә. Мохтарның «Чинар» романы, казакъ әдәбияты классигы Абай әсәрләре һ. б. үзләренең профессиональ югарылыкта эшләнүе белән аерылып торалар.

Л. Хәмидуллинның милли әдәбиятлар арасындагы дуслык элемтәләрен ныгыту юнәлешендә алып барган әдәби-гамәли эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Аның катнашы белән туганлаш әдәбиятлар хәзинәсеннән байтак китаплар татар телендә дөнья күрде, татар әдәбияты үрнәкләре исә казакъ, үзбәк, каракалпак телләрендә күләмле җыентыклар сыйфатында нәшер ителде.

1990 елда Л. Хәмидуллинның хикәяләрен һәм татарның күренекле әдәбият-сәнгать әһелләренә багышланган очеркларын эченә алган «Офыктагы рәшәләр» исемле китабы басылып чыкты.

1982 елда Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллинга Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

*«Казан утлары» журналы редакциясе һәм Татарстан Язучылар берлеге юбилярларны ихлас котлыйлар, аларга саулык-сәламәтлек, иҗат уңышлары телиләр.*

## ПРЕЗИДЕНТЫБЫЗ ТӨРКИЯДӘ

12—16 октябрьдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге делегация Төркия Республикасында визит белән булды. Визит барышында Татарстан Республикасы Президенты Т. Озал һәм Премьер-министры С. Демирель белән очрашты.

Визит тәмамланганнан соң кабул ителгән Белдерүдә түбәндәгеләр әйтелә: «Визит барлык тикшерелгән мәсьәләләр буенча карашларның якынлыгын яки туры килүен күрсәтте. ...сәүдә-икътисади һәм фәнни-техник хезмәттәшлек өлкәсендә ике яклы мөнәсәбәтләрне үстерү кирәк, дип табылды. Шулай ук якларның белем, мәдәният, спорт һәм туризм өлкәсендә мөнәсәбәтләрне үстерә баруга әзер торулары күрсәтелде».

Делегация составында күренекле әдип Мөхәммәт Мәһдиев тә бар иде.

## ДӘҮЛӘТАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Татарстан Республикасы вице-президенты В. Лихачев Кремльдә Литва, Эстония һәм Молдова хөкүмәтләренең рәсми вәкилләрен кабул итте.

Элек ирешелгән килешүләр нигезендә ике яклы мөнәсәбәтләрне үстерү, икътисади килешүләр әзерләү, үзара сәүдә вәкиллекләре ачу мәсьәләләре тикшерелде.

Шулай итеп, әкрен генә булса да, республикабыз тигезләр арасында тигез дәрәҗә яулый бара. Вице-президентның Германиягә эш визиты да әлеге фикерне ныгыта.

## ХӘТЕР КӨНЕ

15 октябрь — татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә Хәтер көне итеп билгеләп үтелә. Ә быел исә Казанның Иван Грозный гаскәрләре тарафыннан басып алынуына 440 ел тулды. Шушы кайгылы вакыйганы искә алып, эш көне булуга да карамастан, Казанның Ирек мәйданына бик күп халык җыелды.

Митингны Татарстан Диния нәзарәте мөфтие Габдулла хәзрәт ачып җибәрде. Аннан соң Нур Аллаһ мәчетенең имамы Фәрит хәзрәт Казанны саклаганда һәлак булган бабаларыбыз рухына багышлап дога укыды. Милли Мәҗлес исеменнән аның рәисенең беренче урынбасары Зәки Зәйнуллин сөйләде. Шулай ук «Суверенитет» комитеты рәисе Әмир Мәхмүтов һәм «Иттифак» милли бәйсезлек партиясе рәисе, Татарстан халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова, Татар иҗтимагый Үзәге президенты, Татарстан халык депутаты Марат Мөлеков һ. б. чыгыш ясады.

Аннан соң җыелган халык тигез сафләрга басып һәм тәкбир әйтә-әйтә Сөембикә манарасы янына барды. Биредә шәһит булган бабаларыбыз рухына дога кылу булды.

Казанны яклап һәлак булучылар хөрмәтенә куелачак һәйкәл урыны да күрсәтелде. Бу һәйкәлне салу өчен менәрләгән сум акча салучылар да булды. Ә кичен Г. Камал исемендәге театрда Хәтер көне уңаеннан бәетләр һәм мөнәҗәтләр кичәсе уздырылды.

## ЧЕЧЕН ТУГАННАР КАЗАНДА

Бәйсезлеккә омтылучы Татарстан һәм Чеченстан республикалары арасындагы үзара бәйләнешләр айдан-айга ныгый бара. Соңгы вакытта ике арада вәкилләр алмашу да ешайды. Хәтер көне уңае белән Казанга Чечен Республикасы Милли Конгрессы Президиумы Рәисе Ильяс әфәнде Сатуев, дәүләт секретаре Асланбәк әфәнде Акбулатов һәм дин эшләре буенча Президент ярдәмчесе Али әфәнде Хаҗи килде. Беренче көнне алар Язучыларның Тукай клубында республика журналистлары белән очраштылар. Икенче көнне исә Хәтер көнендә катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## КИНОСТУДИЯ АДЫМНАРЫ

20 октябрь көнне Татарстан дәүләт кинематографиясен үстерү фонды рәисе Рафаэль Насыйбуллин, әлеге фонд каршындагы «Мизгел» студиясе баш мөхәррире Әхмәт Гадел, Татарстан кино үзәге директоры Роберт Копосов, Казан киностудиясе директоры урынбасары Михаил Михайлов матбугат конференциясе үткәрделәр.

Анда билгеле булганча, «Татарфильм» студиясе Казанның Җиңү проспектында урнашачак. Моның өчен 6,25 гектар җир бүлеп бирелгән. Тәүге нәфис фильмны дөньяга чыгару буенча эш башланган. Режиссер Булат Мансуров белән язучы Гәрәй Рәхим «Исә Болгар җилләре» исемле фильмны иҗат итүгә алынганнар.

## КИЛЕШҮ ТӨЗЕЛДЕ

12 октябрь көнне Башкортстан Республикасының Матбугат һәм мәгълүмат министры Зөфәр Тимербулатов җитәкчелегендәге делегация Казанга килде. Ә икенче көнне газета-журналлар нәшриятының конференцияләр залында ике республиканың Матбугат министрлыклары арасындагы килешүгә кул кую тантанасы булды. Анда һәр ике яктан матбугат әһелләре дә катнашты. Килешүдә газета-журналлар арасында файдалы хезмәттәшлек, үзара әдәбият, мәгълү-

мат алмашу, уртак премияләр булдыру, шулай ук матбугат продукциясен күргәзмә-сатулар үткәрү һ. б. чаралар күздә тотыла.

## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Татарча беренче басма китапның дөнья күрүенә 270 ел тулуга багышлап, 9—10 октябрьдә Екатеринбург каласында «Татар мәдәнияте көннәре» үткәрелде. Бирeдәге М. Гафури исемендәге мәдәният җәмгыяте (җитәкчесе — Сөфхәт Надыйров) һәм Урал нәшриятлары ассоциациясе (директоры Рафаил Исхаков) чакыруы буенча әлеге калага Казаннан Татарстан җөмһүриятенең Фәннәр Академиясе академигы, татар китабы буенча танылган галим һәм язучы Әбрар ага Кәримуллин җитәкчелегендәге 20 кешелек делегация килде.

Кунаклар иң элек «Җәмгыятебез тарихында кешелекләлек һәм көч куллану» дигән фәнни-практик конференция эшендә катнаштылар. Аннары каланың Офицерлар мәдәният сараенда «Рухи хәзинәләребезне барлаганда» дигән исем астында зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Язучыларыбыздан Әбрар Кәримуллин, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Рәдиф Гатауллин, Лена Шагыйрьҗан, Шаһинур Әхмәтсафа, сәнгатебез осталарыннан җырчы Вафирә Гыйззәтуллина, Минхәмәт Гыйләҗев, скрипкачы Шамил Монасыйпов, баянчы Рамил Курамшин, пародияче Газинур Шиһапов һәм башкалар дүрт сәгать дәвамында залдагы халыкка игелекле хезмәт күрсәттеләр.

Фойеда исә Татарстан Милли китапханәсенең сирәк китаплар, газета-журналлар, кульязмалар бүлеге мөдире Рәиф Мәрданов тарафыннан оештырылган махсус күргәзмә эшләде.

## «КӨЗГЕ ОЧРАШУ»

Республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребездән Татарстан телевидениесе тапшыруларын карый алмаулары хакында еш ишетергә туры килә. Ульяновскида, шушы бушлыкны тутыру максатыннан, «Чишмә» дип исемләнгән тапшырулар оештырыла. Аның мөхәррире — Рамис Сафин. Ул һәр елны Казанда чыга торган газета-журнал редакцияләреннән кунаклар чакырып, аларга Ульяновск телевидениесендә чыгыш ясау мөмкинлеге бирә. «Көзге очрашу» дип аталган әлеге тапшырула быел «Казан утлары»ның бүлек мөхәррире Шамил Маннапов катнашты.

## АНГЛИЯДӘН ХӘБӘР

Композитор Мәсхүдә Шәмсетдинова Англиянең Кембриджгагы университет әһелләреннән хатлар алды. Бу хатларда композиторның хезмәте олы бәяләнә һәм аның турында белешмәнең «Кемнәр кем?» исемендә чыгачак энциклопедик җыентыкка керәчәге хәбәр ителә. Композитор М. Шәмсетдинова «Дөньяның мәшһүр хатын-кызлары» исемлегендә.

## ТӨРЕК КОЛЛЕДЖЫ

Чаллыда Төрек колледжы ачылды. Әзерлек курсына татарча яхшы белүче, 8—9 нчы классны тәмамлаган 50 егет алынды. Алар өч ел дәвамында татар, төрек һәм инглиз телләрен яхшылап өйрәнәчәкләр. Бирeдә дин тарихына да зур әһәмият бирелә. Мөгаллимнәр исә Төркиянең үзеннән килгән. Колледжның директоры — Әхмәт бәй Шаһим.

## АВТОРЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА!

Журналыбызда басылып чыккан әсәрләр өчен каләмхак (гонорар) күләме шактый арттырылды. Шул нисбәттән авторларга акча күчерү эшендә дә өстәмә кыенлыклар килеп туды. Күп кенә авторлар үзләренең саклык кассалары турындагы мәгълүматларны дөрес һәм төгәл итеп бирә белмиләр. Шунлыктан каләмхак акчаларының барып җитмәү һәм, тагын да кызганычрагы, хәтта югалу очраклары да бар.

Авторларыбызны искәртәбез, саклык кассаларына акча күчертергә теләгән очракта, түбәндәге таләпләрне истә тотып мәгълүматлар бирергә кирәк:

**1. Сезнең акчаларыгыз саклана торган саклык банкының почта индексы күрсәтелгән төгәл адресы.**

**2. Төп банкның тулы һәм төгәл исеме (чөнки хәзер банклар бик күп һәм төрледән-төрле), коды, исәп-хисап номеры.**

**3. Һәм, ниһаять, үзегезнең саклык кенәгәгезнең исәп-хисап номеры белән дөрес язылган исемегез, атагызның исеме (отчество), фамилиягез.**

Кыскасы, бухгалтерлар теле белән әйткәндә, тулы реквизит булу шарт.

Моның өчен авторларыбызга, иренмичә үз банкларына барып, кирәкле барлык мәгълүматларны язып алырга һәм безгә хәбәр итәргә тәкъдим итәбез.

Дөрес һәм төгәл язылган реквизит үрнәген сез журнал тышлыгының икенче битендә бирелгән белдерүдән укып белә аласыз. Анда журнал редакциясенең үз реквизиты күрсәтелгән.

# «АК ЧИЛӘК БИК МАТУР БУЛА...»

*«Ак чиләк бик матур була,*
*Су белән тулса гына...»*

Башкортстанда яшәп иҗат итүче рәссам Ринат Харис үзенең әсәренә зәңгәр фонда ак хәрефләр белән әнә шул халык җырын язып куйган. Һәм ул җыр әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итә торган бер ачкыч буларак кабул ителә.

Журнал тышлыгының беренче битендә бирелгән бу әсәр «беркатлы, наив сәнгать», примитив дип йөртелә торган сәнгать төренә керә. Аны, гадәттә, халык лубогы дип атыйлар һәм бу төр сәнгать тамырлары белән халык иҗатына — фольклорга барып тоташа. Бу очракта рәссам Ринат Харис сәнгатьтәге халыкчан традицияләрне үзенең шәхси иҗади күзаллавы белән көчәйтеп, үстереп бирә алган.

Ринат Зөфәр улы Харис Башкорстандагы татар авылларының берсендә 1953 елда туган. Ул бала чагыннан ук халык җырлары, әйтем-мәкальләр, әкият-бәетләр, табышмак-уеннар тыңлап-күреп үскән, шулар аша үз халкының акыл-тәҗрибәсен мирас итеп алган.

Хәзер инде Ринат Харис Өфедәге татар рәссамнарының «Чыңгыз хан» төркемендә, иҗади дуслары-фикердәшләре белән берлектә татар халкының үткәне-бүгенгесе аша киләчәккә дә кыю караш ташларга омтылып иҗат итә. Аның иҗади дусларының күпчелеге сәнгатьтә модернистик яңа агымнарга мөкиббән булсалар, Ринат Харис халыкчанлыктан аерылмаска тырыша.

Без күргән әсәр «Кое янында» дип атала. Ул татар авылының гомумиләштерелгән образын лирик-романтик төсмерләрдә һәм шул ук вакытта тантаналы-күтәренке композиция аша бирергә омтылган. Әсәрдә күңелләргә саркып иңә торган тыенкы моң-сагыш та тоемлана. Айны сызып кына калдырган кара түгәрәк әллә ай тотылган төн ул, әллә бер кайгы-сагыш символы гынамы — әйтүе кыен. Ак чиләккә коедан су алучы кызның башындагы ак яулыгы да сызылып киткән шул ай шәүләсен кабатлый сыман, аның айга таба иелгән башы әлеге моң-сагышны үзенә кабул итәдер, бәлки. Бәлки, ул кыз айлы төннәрдә коедан су алганда янында җан сөйгәне юклыктан моңланадыр, салалардан калаларга күпме яшьләр китеп таралды бит. Бу гади генә сюжетта шул ук вакытта беркатлырак ирония, наянлык та төсмерләнә. Монысы — автор позициясе, рәссамның дөньяга карашы-мөнәсәбәте, ә ул мөнәсәбәтнең асылы — тормышны сөю-ярату.

Әйе, әсәр шартлы һәм символик әсәр. Биредә барысы да бер яссылыкта, аппликация сәнгатенә хас сыйфатларда сурәтләнә.

Алгы пландагы кара авызлы коега ак чиләк, кызыл күлмәкле, ак яулыклы, сыгылма буйлы сылу кыз сурәтләре каршы куела. Кызның сыгылма сыны зәңгәр фонда йортның катып калган туры почмагы белән шулай ук контраст, шулай ук каршылыклы ассоциатив төсмерләр белән сугарылган.

Төсләр бәхәсендә борынгы символлар: кара төс — җир-су, алар тереклек-тормыш бирә; кызыл төс — ут төсе, җылылык-ягымлылык, өй яме; ак төс — пакьлек-сафлык, гаделлек-ихласлылык билгесе, ә зәңгәр төс исә җирләр-күкләрнең берлеген, галәмнең иксез-чиксезлеген чагылдыра. Су безгә тормыш бирә, су тулы ак чиләк ул тормышка рухи байлык өсти, яшәвебезнең мәгънәсен ача, ә кызыл күлмәкле, ак яулыклы кыз һәм ап-ак өй түбәсе, шул тормыш-көнкүрешебезне игелекле һәм матур итеп коруыбызга ишарәли.

Кыскасы, беренче карашка гади генә лубок булып тоелган рәсем бездә әнә шулай чиксез күп төрле уй-хисләрне кузгата.

Ринат Харис — үзенчәлекле, талантлы рәссам. Аның иҗаты халык иҗаты белән үрелеп, халыктагы сәнгать үрнәкләре белән сугарылып үсә бара. Ул үзен татар халкының бер улы итеп тоя һәм иҗат итә.

Уңышлар телик аңа!

Гүзәл **ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА**,
сәнгать белгече.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Кояш Тимбикова.

**Д. БУНТУКОВ** фотосурәте.

# ТУГАН АВЫЛЫМ ИСТӘЛЕГЕ

Мин туып-үскән авыл — Арча районының Кечкенә Өчиле авылы иде. Өч йөз ел буе яшәп тә унөч йорттан артмаганга күрә, аны тирә-яктагы авыллар, шүрәле каргаган, дип йөртәләр иде. Мин бәләкәй чакта, мәктәптә укып йөргән елларда, ул гел кими барды. Урта хәлле крестьянны кулак дип исәпләп, Себергә сөргәч, ул тугыз йортлы булып калды. Сугыштан соң тагын да кимеп, алты йортлы бәп-бәләкәй авылга әйләнде. Аннары... Алтмышынчы елдан башлап, ике-өч ел эчендә, ул бөтенләй юкка чыкты — Казанга, Арчага, күрше авылларга күченде авылдашларым.

Авыл һәлак булды — йөрәктә моң утырып калды.

Нинди матур, күз явынны алырлык авыл иде бит ул. Тау башына урнашкан иде ул. Ә тау итәгеннән ун чишмә агып ята иде. Юкка чыккан авылымның урынын, болыннарын, кайчандыр дүрт ташлы тегермән (Галимжан байдан калган тегермән!) урыннарын, челтерәп агып яткан көмеш сулы чишмәләрен күргәч, Сибгат Хәким «Бер тауда ун чишмә» дигән атаклы җырын язды.

Мин бәләкәй чакларда Кечкенә Өчилегә тирә-як авыллардан кунаклар килеп тула торган иде. Ул сабан туйлары, ул Калатау җыеннары! Ул шлея-чуклы, шөлдерле-кыңгыраулы атлар! Ул печән өстендәге тамашалар! Бар иде матур заманнар...

Кечкенә Өчиледән, нибары унөч йортлы Өчиледән 12 егет һәм кыз югары белем алып чыктылар. Профессор, Совет Армиясе полковнигы, врач-табиб, агроном, укытучы, язучы, механизаторлар, колхоз рәисләре булып җитештеләр дә дөньяның төрле якларына таралып киттеләр...

Авылым һәлак булды, ерактагы бер моң булып йөрәктә калды. Мин аны төшләремдә күреп, газапланып беткәч, аның турында җыр-бәет яздым, композитор Әнвәр Шәрәфиев аның музыкасын иҗат итте.

Татарстанда, замана җилләренең усаллыгына түзә алмыйча, юкка чыккан, һәлак булган авыллар байтак.

Авылсыз, туган-туфраксыз калган кешеләрнең йөрәк яраларына шифа булмасмы дип, шул җырны «Казан утлары»ның укучыларына тәкъдим итәм.

**Гариф АХУНОВ,**
язучы, Кечкенә Өчиле малае.

**Әнвәр Шәрәфиев**
музыкасы

**Гариф Ахунов**
шигыре

## Авылым сагышы

Өч гасырлык тарихың ла
Бар иде бит, авылым,
Нинди җилләр алып килде
Замананың давылын?

Йорт-җирләрең җимерелде,
Зиратларың тапталды,
Тау башында моңаеп ла
Ялгыз наратың калды.

Чишмәләрең өмет итә
Чиләк тавышын тыңларга,
Сине сагынып, туган авлым,
Кушып җырлыйм җырларга.



Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог